Әдәбияттан хрестоматия

11



ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

Әдәбияттан хрестоматия

Һәр галимнең, һәр шагыйрьнең сүзе
Җитсен иде һәрбер күңелгә,
Җилләр, сулар тавышы шикелле үк,
Үзләренең асыл теленддә.

Хәсән Туфан

Әдәбияттан хрестоматия

Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең 11 нче сыйныфы өчен

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән

Төзәтелгән дүртенче басма

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2011

УДК 373.167.1:821.512.145*11
ББК 84(2Рос=Тат) я721
Ә26

Төзүчеләре:

А. Г. Әхмәдуллин, Т. Н. Галиуллин, Н. Г. Юзиев

Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Әдәбияттан хрестоматия : татар телендә урта гомуми
Ә26 белем бирү мәкт. 11 нче с-фы өчен / [төз. : А. Г. Әхмәдуллин, Т. Н. Галиуллин, Н. Г. Юзиев].— Төзәт. 4 нче басма.— Казан : Татар. кит. нәшр., 2011.— 447 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-02054-1

УДК 373.167.1:821.512.145*11
ББК 84(2Рос=Тат) я721

ISBN 978-5-298-02054-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2011, үзгәрешләр белән
© Әхмәдуллин А. Г., Галиуллин Т. Н., Юзиев Н. Г., төзү, 2011

Гаяз Исхакый
(1878—1954)

КӨЗ

(повесть кыскартып бирелә)

[Көзге караңгы төндә елга буйлап баручы пароходта очраклы рәвештә ике хатын бер каютада урнаша. Ханымнар икешәр балалары белән сәфәр чыкканнар...]

Тышта пыштырдый торган ягъмур һаман туктамады. Пароходның поштыр-поштыр килүе бетмәде. Аның ара-сыйра моңланып кычкырып җибәрүе ике хатынны да үз уйларыннан яздырмады. Бераз гына тын ятканның соңында, хәерле кичләрне әйтеп йоклаган булып маташканның соңында, хатыннар тагын искәрмәстән сөйләшеп киттеләр... Никтер, бу хатыннар, берсенә берсе үзләренең эчләрендә ябылып яткан кайгылары-хәсрәтләрен, шатлыкларын чишәргә теләп торганга, хәзерге хәлләреннән үтеп, бик тиз сөюләренә, кияүгә чыгуларына барып җиттеләр. Яңа хатынның: «Ничек соң сез кияүгә чыктыңыз?» — диюенә каршы, озын уйлап тормаенча, Нәфисә мендәренә таянып сүзгә кереште. Аның күзе елмайды, йөзе нурланды, тавышына әллә нинди бер аһәң катышты. Яңа хатын, Нәфисәнең ачылган гөл кебек нурланып киткән йөзенә карап, моның бәхете минеке кебек түгелдер шул дип, ике колагын тыңларга әзерләде.

«Мин — Оренбург шәһәренең уртача бер сәүдәгәр кызы. Мөселманча яхшы гына укыдым. Урысча, өйгә китереп, бер марҗадан бераз укыттылар. Ләкин, шәһәр кызы булганга, урысчаны белә идем. Китаплар аңларлык булган идем. Безнең тирә-юньдәге кызларның кайберләре гимназиягә кереп укып китсәләр дә, аларның ак алъяпкычлары, соры киемнәре мине бик кызыктырса да, минем әти, бик иске кеше булганга, авыз да ачтырмады. Мин, 17—18 яшькә җиткәч, буй кыз булып яши башладым... Ара-тирә: «Сәхибә карчык яучы килгән икән, Каргалыдан Вахит

бай углына сорап карый, хәлфә баш кода булган икән»,— дигән сүзләрне ишеткәләсәм дә, бер колагымнан керде, икенчесеннән чыкты. Менә шулай көннәр үткәндә, театрда яңа әсәр куела дип игълан булды. Әти, үзе бармаса да, мине энем берлә театрга җибәрә иде. Ләкин һәрвакытта ложаны алып безнең янымызга йә күрше Мәрфугасын, йә исә асламчы Фәхриясен тагып җибәрә иде. Бу юлы, никтер, безгә кадәр ложалар сатылып беткән, энем партерда ике урын гына алып кайткан иде. Әтинең кәефе бик китсә дә, «Анда җыен малай-салай берлә чуалып йөрергә рөхсәт юк»,— дисә дә, безнең бик барасымыз килгәнгә, әни арага кереп, театрга киттек. Әти: «Сак булыңыз, пәрдә араларында чыгып йөрмәңез»,— дип кычкырып калды.

Урыннарны алып утырдык. Пәрдә ачылырга гына торганда, минем уң ягымдагы урынны бер урыс килеп алды. Безнең Оренбургта урысларның безнең театрга килүләре сирәк булмаганга, мин аңарга дикъкать итмәдем. Сул ягымда энем булганга, мин хәзер киләчәктәге әллә кемнәрнең «егетләр берлә утырды» дип лыгырдавына юл ябылыр дип кәефләндем дә. Уен башланды. Бик тиз уенга батып киттек. Менә бер пауза арасында күршем урыска күзем төште. Шул уенның эченә кергән кебек күзен теккән, тәмамән югалган... Урысның ихласына бераз гаҗәпләндем. Пәрдә төште. Ут яктысыннан һәммәбезнең күзләре камашып китте. Төрле җирләрдә бинокльләр берлә караулар, еraктан сәламләшүләр башланды. Минем энем ул вакыт, барымыздан да качып, тәмәке тартырга үгрәнә торган чагы булганга, ул бик тиз чыгып шылды. Мин, урынымда калып, биноклем берлә уйный башладым. Бердән, күршемдәге урысым: «Гафу итегез, туташ, программаңызны биреп тора алмассызмы, мин соң килдем дә программа таба алмадым»,— диде. Мин: «Рәхим итегез!» — дип, шул урысны җентекләп карадым. Хәзер дә бөтен кыяфәтләре күз алдымда... карасу бер костюм, бер зәңгәррәк, бер карарак булып китә торган муен бавы, ап-ак якалар, тирән генә уйлы күзләр. Күршем: «Бу мөгаллимә ролендәге артист бик яхшы уйный, ул искедән уйный торган кеше булырга кирәк»,— диде. Мин үзем белгән кадәр безнең труппамыз хакында мәгълүмат бирдем. Ул бердән: «Сез бәхетле, туташ, үз халкыңыз арасында яши аласыз, аның һәр шатлыгына катыша аласыз, менә мин читтә, үз театрымызны күргәнем юкка менә инде бер ел булган иде... Бу әсәрне мин белми дә идем. Ишеткәнем дә юк иде... Бу бит — бик зур мәхрүмлек...» — диде. Шуннан мин бу урысның урыс түгеллеген, әллә кайда читтә урыс арасында торса да, үз рухын сакларга маташа торган кеше икәнлеген күрдем. Шуны кызгандыммы: «Сез соң ник үз халкымыз арасында тормыйсыз?» — дидем. «Булдыра алмыйм, мин доктор, былтыр гына бетердем, әле менә үземне гаскәри хезмәткә алдылар да, кая җибәрсәләр,

шунда торырга мәҗбүрмен»,— диде. Шул сүзне кыңгырау тавышы бүлде. Пәрдә ачылды. Минем дикъкатем бүленде. Бер күзем берлә сәхнәгә карасам, икенче күзем берлә күршемне сөзә башладым. Ләкин ул, минем барлыкны да онытып, сәхнә эченә чумды. Андагы хәят берлә яши башлады. Анда көлсәләр көлде, кайгырсалар хәсрәтләнде. Икенче пәрдә арасында күршем тагы үзенең урыс арасындагы тормышының күңелсезлеген, өч айдан, менә тәмамән гаскәрилектән котылып, йә Казан, йә Оренбург, Әстерхан кебек бер шәһәрдә җирләшергә теләвен сөйләп китте. Сүз арасында гына: «Сез кем буласыз?» — дип, исемемне сорап алды. Бераздан: «Буфетка чыгып, берәр нәрсә эчмисезме?» — диде. Мин: «Рәхмәт, беләсез бит, безнең халык әле андый эшкә чит карый. Безнең эти дә алай бергәләп йөрүне бер дә яратмый, гафу итегез, чыгалмыйм»,— дидем. Шуннан: «Мин чыгып керим әле алай булса, мин әле яңа гына поездддан, вокзалдан килгәндә, театрның игъланнарын күрдем дә ашамадым-эчмәдем, юындым да килдем»,— диде дә чыгып китте. Мине әллә нинди яңа бер хис биләде. Бу яшь егет, урыс арасында тора торган яшь егет, мескен, ничек яши икән? Иртә чәенә аны кем уята икән? Бәйрәмендә-ниендә ничек көнне үткәрә икән? Ялгызлык хис итмиме икән?..

Шундый уйларны уйлап, уем агып, берәр марҗасы-фәләне бардыр инде, безнең егетләр шулай бит дигән фикергә килгән кебек булдым. Ләкин ул фикердә озак кала алмадым. Минем энем тәмәкесен тартып бетереп килә алмаса да, күршем килеп җитте. Ул кулына зур гына бер тартма шоколад тоткан, утырды да, ачып: «Рәхим итегез, туташ!» — дип, миңа сузды. Егетләрдән сыйлану безнең гадәткә сыймаса да, сүз кайтару моңа авыр тоелыр дип, рәхмәт әйтеп алдым. Ул арада минем энем дә килеп җитте. «Бу егет сезнең энегез буламы?» — дип сораганның соңында, аңарга да тәкъдим итте. Энем дә, авызындагы тәмәке исен бетерү өчен, бик рәхәтләнеп кабул итте. Өченче пәрдә башланды. Минем күрше егетем тагын онытылды. Мин аның, шулкадәр сусаган булуын кызганган булсам да, шулкадәр тиз ут кабып китүенә бераз гаҗәпләндем дә. Сәхнәнең яшьле җирләренә җиттек. Партерда мыңер-мыңер елау тавышлары ишетелә башлады. Мин, күземә яшем тыгылса да, күршемнән оялып, тешләремне кыстым. Үземне тыйдым. Күземнең очы берлә күршемне сөздем. Ни күзем берлә күрим, яшь егетем мер-мер елый. Мин аптырап калу берлә кызганудан җыелган бер хис астында калдым. Аны юатасым да килде, аны оялтасым да килде... Ләкин, театрны онытып, аны сөзә башладым. Күземез күзгә очрашты. Аның яшьле керфекле күзләрендә әллә никадәр кайгы-хәсрәт, әйтеп бетермәслек йомшаклык, мөлаемлык күрдем. Күземне бик тиз аласым килсә

дә ала алмадым. Аның йөзенә кызыл йөгерде, ул борылды... Пәрдә төште. Күзләрендәге яшьләрен киптерер өчен кебек, һәркем бик озак кул чапты. Минем күршем дә, әллә нидән оялган кебек кызарып, үзенең шоколадларын миңа тәкъдим итте. Теге юеш керфек арасындагы яшьле күзләре аша мин моның бөтен җанын күргән кебек булганга, күңлемдәге моңа ятлык бердән бетте. Мин, үзем дә сизми, моңарга үземнең хәлемне аңлата башладым. Үземнең тормышымны сөйләдем. Беркемгә дә сөйләнми торган кечкенә гаилә серләремне аңлаттым... Ахырда бер көлке куелачак булганга, без тагы калдык. Пәрдә ачылырачылмас, күршем: «Бу шоколад савыты, тулы булмаса да, сезгә булсын, рәхим итеп алыгыз»,— диде. Мин: «Бик рәхмәт, гафу итәрсез, гаепкә алмаңыз, безнең тормышта ул сыймый бит, минем, кайдан алдың аны дип, колак итемне ашаячаклар»,— дидем. «Аңлыйм, аңлыйм... Менә шул инде безнең тормышның фаҗигасе»,— диде... Тагын бераз уйлап торганның соңында: «Сезне тагын күреп буламы соң, туташ?» — диде. Мин, бердән уйламаенча: «Менә ике көннән соң тагы театр була, мин бер театрны да калдырмыйм»,— дидем. Театр бетеп, китәр өчен күрешкәндә дә, теге егет: «Сезне озату да мондагы йолага сыймый торгандыр инде, туташ»,— диде. Мин тагы: «Юк шул»,— дидем... Беренче мәртәбә үземнең шул йоладан җәберләнүемне хис иттем. Күрешкәндә, ул минем кулымны бик озак кысты. Мин кызардым... Киткәндә, ул, аерым китсә дә, мин чыкканчы әллә нишләп мавыгып торды. Ишек янында тагы күземез очрашты. Бер сүз әйтмәенчә генә, күз берлә хушлаштык.

Мин төн буе әллә нинди татлы төшләр күреп йөдәп чыктым. Икенче театрны көтеп ала алмаенча йончыдым. Менә көне җитеп, театрга киттек. Бу юлы безнең янымызга Мәрфуга әби дә тагылган иде. Мин, юлга чыккач та, Мәрфуга әбине калырга димләргә тотындым. «Соң бүген нишлиләр, Фәхри мирзаларның кызлары егетләр берлә кочаклашып биемиме соң?» — дип сооравына каршы, «Юк, бүген бию юк»,— дигәч, «Алай икән. Чыгып сөйли генәме, андый такмазаны мин үзем беләм»,— диде дә үзенең ахирәте асламчы карчыкка керергә булды. Аны ат берлә илтеп куеп, кайтышлый алырга булып, театрга юнәлдек.

Урынымыз ложада иде. Кереп утырыр-утырмас, күзем берлә таныш егетне эзләргә тотындым. Ул партерда ике ягыннан буш ике урын арасында күзе берлә эзләнеп утыра иде. Күзебез очрашты. Баш иештек. Ләкин шуннан соң ул аптыраган кебек, мин монда, сез анда дигән кебек борчылган бер хәлгә килде. Озак үтмәде, ул урыныннан торып чыгып китте. Безнең янга күрешергә килсә, инде каршы ложадагылар күрерләр дә сүз булыр дип куркынып торганда, кыңгырау шалтырады, утлар сүнде. Пәрдә күтәрелер-күтәрелмәс борын, егетем ложамызга

килеп керде. Күрешеп бетерер-бетермәс, уен башланды. Шуңарга ул безнең ложада утырып калды. Ләкин уен бик шәп булмадымы, без арткарак тартылып утырдык та акрынлап кына сөйләшергә тотындык. Пәрдә араларында энем тәмәке тартыр өчен чыкты, керде. Ләкин нә ул, нә мин урыныбыздан кыймылдамадык. Сүзгә мавыгып, мин тирә-юньнең сүзеннән куркуны да оныттым. Актык пәрдә арасында киләчәк театрда күрешергә булып аерылыштык.

Мәрфуга әбине алып, өйгә кайттык. Без кайтканда, әти яткан булса да, әни чәй әзерләп көтеп тора иде. Энем бик тиз чәен эчкәләде дә китеп ятты. Мин әллә нигә әнигә шул вакыйганы сөйләргәме-юкмы дип уйланып торганда, әни: «Нәрсә уйланасың, әллә берәр сүзең бармы?» — дип сорады. Әнидән яшерергә өйрәнмәгәнгә: «Бар шул»,— дип, энәсеннән җебенә кадәр әнигә сөйләдем. Әни башын саллый-саллый[1] тыңлады-тыңлады да: «Менә әтиең шул шуннан куркып театрга йөрүне яратмый, кем очраса, шуның берлә буй кызга танышып йөрергә ярыймыни?» — диде. Мин: «Юк, ул начар кеше түгел, фәлән»,— дип, бик кызып, аны якладым. Аннан ары үземнең сүзләремнән үзем дә оялып кызардым. Әни: «Башта бар да яхшы була ул. Аннары гына начарлана. Кызларга сак булырга кирәк. Ата-ана ул белмәенчә бала-чаганы сакламый»,— диде... Мин төн буе шатлыклы-куркулы төшләр берлә борчылдым. Иртә торып чәй эчәргә утырганда, әтинең кынгыр карамавын күреп, күңелем бераз тынычланды. Ләкин, ашка кайтканда, әти котырган эт кебек булган иде. Ул энемне бәреп җибәрде. Әнигә: «Балаларыңны үзең бозып бетерәсең!» — дип, бик каты бакырды. Миңа, килеп: «Сиңа кем кушты әллә нинди матамаллар[2] берлә театрда кичәләр үткәрергә, ничек оялмадың? Ничек, ата-анамның йөзенә кара ягам дип, Алладан курыкмадың?» — дип акырды... Мин кызардым, бүрттем, күзләреннән яшь ага торган әнине кызгандым, ләкин, ни өчендер, үземне гөнаһлы хис итмәдем. Эшләрем өчен бер вөҗдан газабы да сизмәдем. Әти, бик озак дулаганнан соң: «Моннан соң театрга барырга рөхсәт юк!» — диде. Иртәгә театрга дип алып кайткан театр билетларын күреп, алардан үч алган кебек, ваклап-ваклап ертып ыргытты. Аннан чәйнең тәме бетте, көн караңгыланды. Театр көнен, бигрәк тә кичен үткәрү бик авыр булды. Мин, чигешемне алып утырсам да, бизәкләремне ялгыш чигеп, үрнәкләремне бутап, бармакларыма инә чәнчеп йөдәп беттем. Әти һаман дулаган кыяфәттә булса да, әни миңа элгәрегә караганда да шәфкатьлерәк кебек кыланды. Сәгать унбердән утларны сүндереп яттык. Әти: «Аятелкөрсиләреңезне

---

[1] *Саллый* — чайкый.

[2] *Матамаллар* — төрле яктан җыелган вак-төяк кешеләр.

укыңыз!» — дип кычкырды. Мин йокыга китә алмадым. Әтиләр бүлмәсе дә бик озак йокламаенча сөйләшеп ятты. Кайвакытта салмак кына сөйли торган әнинең сүзләренең көе колагыма керде, кайвакытлар кайный торган самавыр кебек бер улап, бер гөжләп китә торган әтинең аерым сүзләре килеп бәрелде. Икенче көн тагы авыр булды. Минем эчем бик пошты. Теге егетне элгәре кызгандым, аннары сүзләрен ишетәсем килде. Аннан күптән бирле якынымнан аерылган кебек сагындым. Кулым эшкә бармады. Күңел күтәрелмәде. Көн үтте, тагын театр көне җитте. Әнидән тагы соратып карадым. Ул якын килмәде... Мин энемне генә җибәрергә уйладым. Аңарга тәмәке алырга үземнән акча бирергә дә булдым. Ләкин әти аны да җибәрмәде. «Шул театрга моннан соң аяк басасыңыз булмасын!» — диде. Көннәр миңа бик авыр иде. Әллә нигә күңел ташыды, күзгә яшь тыгылды. Мин җырлаштыргаладым, өйдән өйгә, бүлмәдән бүлмәгә йөреп, бер эшкә дә кулым бармаенча көн үткәрдем.

Иртәгесен иртә сәгать унберләр булганда безнең капка төбенә бер ат килеп туктады. Ни күзем берлә күрим, арбадан теге егет килеп чыкмасынмы!.. «Әни, килде!» — дип кычкырып җибәрдем. Әни, урыныннан торып: «Кем килде?» — дип, тәрәзә янына килде. «Теге егет!» — дидем. Әни: «Нәрсә кычкырасың, әллә кеше күргәнең юкмы?» — дип, мине шелтәләп алганның соңында, егетне җентекли башлады. Үзе инде ни эшләргә дигән мәсьәлә алдында аптырап калды. Кыңгырау шалтырады. Әни әллә нәрсә уйлап катты. Ул, бәлки, асраугa: «Бар, исемен, йомышын сора да, абзый өйдә юк, дип кайтар»,— дияргә теләгәндер. Шул арада икенче кат кыңгырау булды. Мин: «Ник кешене көттерәсең?» — дидем дә, тизләп, ишекне ачарга үзем чыгып киттем. Әни: «Нәфисә, ни эшлисең, тилердеңме әллә?» — дип кычкырып калды. Йөрәгем леп-леп итеп чыгарга теләгән кеби булганга, өйалдында бер сулу алдым да үземне тотыбрак төшеп ишекне ачтым. Алдында берәр асрау чыгуны көтеп торган егетем аптырап калды. Мин дә аның аптыравын бетерер өчен: «Боерыңыз, боерыңыз, хуш килдеңез»,— дидем. Ул кызарды, каушады. Минем кулымны кысты. Өйгә керде. Әни бу көтелмәгән кунакка, ничек кылыныргалыгын белмәенчә, шәлен ябынып: «Боерыңыз, кунак!» — диде. Минем шатлануым йөземә йөгерде булса кирәк, әни миңа күзе берлә әллә нәрсәләр ымлады... Ләкин мин аларны аңламадым да, тыңламадым да. Егетем: «Сез театрга бара алмадыңыз, туташ!» — диде. Мин беравыздан: «Кая театрга барырга, әле тегесенең гөнаһларын да юып бетереп булмый. Сезнең берлә сөйләшеп утыруны әтигә сөйләгәннәр дә, әти кыямәт кубарды»,— дип, гүя ул кыямәт беткән кебек сөйләп тә алдым. Әни тамак кырды, әллә нәрсәләр миңа ымлады, мин көлә-көлә, балалар кебек, егеткә сөйли бирдем.

Әни бер эш эшли алмаганга булырга кирәк: «Кызым, самавыр куярга әйт!» — диде. Егет: «Рәхмәт, рәхмәт, мин күрешеп чыгар өчен генә кердем, фәлән»,— дисә дә, мин дә, аны чәй эчерәсем килгәнгә, икенче әйгә чыгып, чәй урыны хәзерләргә куштым.

Мин кергәндә, әни: «Сез кайдан, кем буласыз, әтиегез, әниегез кем, монда ник килдегез?» — дип сорашып утыра иде. Егет тә миңа күптән мәгълүм үзенең докторлыгын, хәзер гаскәргә алынганга, гаскәр хезмәтен доктор булып үтүен, менә бер гаскәри һәйәт[1] берлә хәзер Төркестаннан кайтышлый Оренбургка ике атнага туктауларын сөйли иде. Әни юри, миңа күп сөйләргә бирмәс өчен кебек сөйли, сөаль артыннан сөаль бирә бара, егетем дә җавапларны агызганнан-агыза бара иде. Менә самавыр керде. Чәй урыны әзерләнде. Мин чәй салып ясарга утырдым. Әни, бер карарга килә алмаган кебек, әллә ни уйлана башлады. Ахырдан ул, икенче бүлмәгә чыгып, телефон берлә әтине чакырды. Без егетем берлә икәүләп бик шәпләп сөйләшеп утырганда, минем колагыма әнинең акрынлап, салмаклап әйткән сүзләре арасында әтинең кычкырган, бакырган тавышлары ишетелеп, куркытып куя иде. Мин тагы, кунагым берлә сүзгә чумып, аны оныта идем. Йөзе кәфен кебек ак булып әни керде. Урынына утырды. Үзе тирән иттереп: «Уф!» — дип сулап куйды. Аның авызыннан чыккан шул кайнар сулыш минем бөтен шатлыгымны яндырып, көйдереп китте. Минем йөрәгемә курку кабынды. Егетем дә әллә нәрсә сизенде. Әни: «Кызым, әтиеңә дә чынаяк куй, ул да хәзер кайта»,— диде. Шул сүзләр тагы мәҗлескә суыклык бирде. Егетем: «Сәүдәләр яхшымы, быел еллар ничек?» — дип, сүзне дәвам иттерергә маташты. Ләкин элгәре шактый ачылып киткән әни тагы тынды. Аның тавышына тутыгу кушылды, иреннәре иренеп кенә әйләнә башлады. Күзен ишектән ала алмады.

Менә өйалдында дөбер-шатыр тавыш чыкты. Әни калтыранып китте. Минем бөтен тәнем буйлап бер суык йөгерде. Йөрәгем каты тибә башлады. Башы киселергә хөкем ителгән кеше кебек, башыма төшәчәк бәлане каршы алыр өчен кебек, башым иелде. Егетем дә кызарды, бүртенде. Яшен ташы кебек әти килеп керде. Аның тавышына барымыз сикереп тордык. Ул әллә ни аптырап торган кебек булып китте. Беркем дә бер сүз дәшмәгәнгә, дәшә алмаганга, озын бер пауза булды. Ул пауза шулкадәр озын сизелде ки, мин инде тәмам картайдым, чәчләрем агарды дип хис иттем. Аякларым дер-дер калтырады. Тешләрем бер-берсенә тиеп шыкылдады. Ахырдан әти, акрын гына тавыш берлә: «Әссәламегаләйкем!» — диде... Шул дерелдәгән тавыш берлә әйтелгән сүз, ата-ата дип торганда читтән тәгәрәгән яшен уты кебек, безнең барымызны да: «Аллага

[1] *Һәйәт* — комиссия.

шөкер, калдык!» — дигән уйга китерде. Кызарган егет: «Вәгаләйкемәссәлам!» — дип күрешергә кулын сузды. Әни: «Монда, карт, чынаягың монда!» — дип, түргә урын күрсәтте. Мин: «Әти гафу кылды, егетне яратты»,— дип, көләч йөз берлә аның күзен эзли башладым. Күзләремез очрашты. Әти миңа: «Нигә бик сөендең? Бик зур эш эшләдем дип белдеңме?» — диде. Әни: «Менә чәең кайнарда эчеп ал!» — дип, әтинең фикерен борырга тырышты. Тагы авыр бер тынлык басты. Егет: «Гафу итәрсез, мин — Оренбургтан үтеп баручы бер мосафир, сезнең углыңыз, кызыңыз берлә театрда иттифакый[1] урыннарымыз күрше туры килде дә, сөйләшеп киттек. Шуның өчен сезгә кереп сәлам биреп чыгыйм дидем...» — диде. Әти тагы бер сүз дәшә алмаенча калды. Әни: «Рәхмәт, рәхмәт. Кунакка һәрвакыт ишегемез ачык. Безнең карт кунакны бик сөя»,— диде. Шуннан әни: «Кунак доктор икән. Менә әле Төркестанда әллә нинди бөтен авыруларны терелтә торган таш тапканнар икән. Шуны алып кайтып киләләр икән»,— дип, әтине сүзгә кушарга теләде. Әти кабылт итеп чәен эчеп ташлады. Тагы ясарга дип, шалтыратып, чынаягын миңа төртте. Мин, бөгелеп, чәй ясарга керештем. Морҗа эченнән чыга торган тавыш берлә генә әти: «Бик яхшы, алай укыган егет булгач, шулай театрларда кызларны котыртып йөриләрмени? Хәлфәләрегез сезгә шуны өйрәттеме?» — диде. Егет әллә нәрсә әйтергә авызын ачты. Әни: «Андый эш юк бит, карт!» — диде. Мин, кулларым калтырап, самавыр борынын вакытында ябарга өлгерә алмаенча, чынаякларымны ташыттырып, кулымны пешердем. Егет тагы кызарып бүртенде. «Мин урыс арасында яшим»,— дип, үзенең мөселман гаиләсенә керергә теләгәненә дәлилләр китерергә өлгермәде, әти: «Яшә, урыс арасында яшә! Урыс арасында марҗасы беткәндермени?.. Урысның себеркесе беткәндермени?.. Алай бик мөселман булсаң, мөселман кызын юлдан яздырырга йөриләр димени?» — диде. Егет: «Гафу итәсез...» — дип, тагы сүзгә керешә башлады. Әти ирек бирмәде, әлләниләр сөйләп китте. Ахырдан: «Әле тагы оялмый, көпә-көндез өйгә килә бит, хурланып үләрсең»,— диде... Әни: «Мөселман кеше мөселман өенә ник килмәсен, һәммәбез — бер ата-ана баласы бит»,— дип, сүз йомшартмакчы булды. Әти инде акырына-бакырына башлады. Егет берничә мәртәбә җавап бирергә маташты. Әти аны тыңламады. Мин аны кызгандым. Әтинең шулай кылануыннан хурландым... Аңарга ярдәмгә килер өчен генә: «Тагы берне ясыйммы?» — дип сорадым. Ул: «Рәхмәт, рәхмәт!» — дип баш иде. Әтинең йөзе агарды. Чынаягын тоткан кулы суыкта туңган бала кебек дер-дер килде. Минем күземә яшь тыгылды. Егет, догасын кылып, йөзен сөртте

[1] *Иттифакый* — очраклы.

дә аягүрә калыкты. «Рәхмәт хөрмәтегезгә, мин сезне борчыдым, гафу итегез!» — диде. Әти аптырап калды. «Утыр әле, берәрне эч!» — диде. Егет: «Рәхмәт... минем сезгә килүемдә һичбер начар уй, яман фикер юк иде... Урыс арасында яшәргә мәҗбүр булганга, үз тормышымызны сагынудан килгән бер яшьлек кенә иде. Гафу итегез!» — диде дә ишеккә таба борылды. Мин урынымнан тора алмаенча катып калдым, күземез күзгә очрашты. Мин күзем берлә әллә нәрсәләр әйтмәкче булдым, бик күп гафу үтенмәкче булдым. Күземнән, мөлдерәп, ике бөртек яшь тәгәрәде. Шуны күреп булырга кирәк, әти: «Бар, чык үз бүлмәңә!» — дип кычкырды. Мин, урынымнан торырга теләсәм дә, аягыма бик зур батман тимерләр тагылган кебек бер авырлык сизгәнгә, урынымнан кыймылдана алмадым.

Ишек ачылды, ябылды, егет югалды. Минем күземнән яшь агудан туктамады. Түр башында әни тавышланып еларга керәште. Әти котырган бүре кебек әлләниләр сөйләп, кычкырып-бакырып, идән буе йөреп-йөреп шелтәләргә, тиргәргә тотынды. Минем башым үз фикерләрем берлә мәшгуль булганга, этинең бер сүзен дә ишетмәдем. Кычкыру-бакыруына колак салмадым. Ләкин әнине бик кызгандым. Аннан да битәр мыскыл ителгән егетемне аядым. Аның алдында үземне бик зур гаепле хисаплап, эчемнән яндым, көйдем... Көн бик авыр үтте... Беркем берлә сөйләшмәдем.

Мин кич берлә намаздан соң бик озын Коръән укып яттым, күңелем бераз басылган кебек булды. Ләкин иртәгесен тагын бер авыр йөк басты. Шәмси кодаларга кызлар мәҗлесенә чакыру килде. Әни бик җибәрергә теләсә дә бармадым. Йомшарып килә торган әтинең сүзләренә җавап та кайтармадым. Әллә ник аның йөзен күрәсем, сүзен ишетәсем килми иде. Төн буе саташып, йөдәп чыктым. Егетемне әллә ничә төрле төстә: бер елый торган иттереп, бер көлә торган иттереп, бер әллә нинди марҗалар берлә бии торган иттереп күрдем. Ләкин һәммәсендә миңа таба омтыла, мине эзли кебек, бернәрсә күргән кебек булдым. Иртә берлә чәй дә эчмәдем. Аш вакытында аш та ашый алмадым. Әти дә, әни дә: «Аша, аша!» — дип кыстасалар да, моңаеп китеп, чыдый алмаенча еглый башладым, аштан торып китеп, үз бүлмәмә кереп бикләндем дә бик озак еглядым, әни килеп юатса да тәэсир итмәде. Мине бердән егетемне күрәсе килү хисе шулкадәр куәтле көенчә биләде ки, аңарга һичбер куәт каршы килерлек түгел иде... Мин, аны күрер өчен, юллар эзләргә тотындым. Телефон берлә сөйләшергә булдым. Номерына барырга кадәр җиттем. Ләкин нә адресын белмим, нә урамын, нә башкасын. Мине әллә нинди бер куәт урамга таба тартә башлады. Анда әллә нинди микънатис[1] ташы, бик көчле микънатис ташы мине

[1] *Микънатис* — магнит.

өстери башлады. Мин әнигә: «Башым бик авырта, ат берлә йөреп керим»,— дидем. Әни: «Бар, кызым, бар!» — диде.

Йорт караучы да, су ташучы да, ат башында йөрүче дә булып тора торган, бер кулы чулак, аягы чатан Зарифны ат башына утыртып чыгып киттем. Иң әүвәл урыс номерлары күбрәк урамнарга бардым. Күзем берлә урамның ике ягын да сөздем. Аннан соң халык күп йөри торган урамнарга борылдым.

(...) Кучер, минем капризларымны тыңлый-тыңлый йөдәп беткәнгә, мыгырдарга тотынды. Мин алай да сүземне иттем, киттем. Ни күзем берлә күрим, бер урамның чатында, акрын гына атлап, егетем каршы таба килә. Ерактан ук таныдым. Йөзен-кыяфәтен җентекләргә тотындым. Әллә нинди тирән уйга чумган кебек тоелды. Кем белсен, бәлки, мине уйлый торгандыр, дидем. Тугрысына килеп җиткәч тә кычкырдым. Ул аптырап китте. Каретам ябык булганга, тавышның каян килгәнен белмәенчә, тирә-юнендә эзләнә башлады. Мин тагы көлеп чакырдым. Аның күзенә, йөзенә әллә никадәр гаҗәпкә калу чыкты. Ул, ни эшләргә белмәенчә, арба янында аптырап торганда: «Утырыгыз, бераз йөрик!» — дидем. Утырып киттек. Мин үземнең мәшәкатьләрем мәгънәле чыкканга, тагы кәефем килде. «Ләкин, мәгаттәәссеф[1], нә сезнең адресыңызны белмим, нә телефоныңызны... Мин сезнең алдыңызда бик зур гаепле. Әтинең алай кылануы өчен, мине шелтәләмәгез инде, ул бит — иске заман кешесе, үз үлчәве берлә үлчи, сезне мыскыл да итте, мәсхәрә дә итте, гафу итеңез»,— дидем. Ул тагы күтелмәгән бернәрсә алдында баскан кебек аптырап китте булырга кирәк, миңа җавап бирмәенчә калды. Мин, моның хурлануы бик тирән икәнен хис итеп, тагы: «Беләмсез, бу эш минем күңелемдә шулкадәр ачы яра ачты. Минем җанымны шулкадәр өшетте. Минем яшь башыма шулкадәр авыр бер йөк такты. Мин аны күтәрә алмыйм. Ул мине баса, ул, минем башымны күтәреп, айга-көнгә карарга ирек бирми... Сез инде бәхил булыңыз! Миннән шул авыр бәхетсезлекне алыңыз, гафу итеңез!» — дидем, ялварып, аның йөзенә бактым. Аның күзләре зурайган, йөзе кызарган, төсенә әллә никадәр көчләнү чыккан иде. Мин шуны күреп курыктым да, аптырадым да, калтырап та киттем. Ул, бердәнбер сүз әйтмәенчә, калтыраган-дерелдәгән куллары берлә минем кулымны алды да авызына китереп үпте. (...)

«Бу мәсьәләдә бит гафуны сез түгел, мин сорарга тиеш. Мин бит, тәмле тормышыгызга тупасча кереп, тынычлыкны боздым. Мин бит сезнең берлә атаңыз арасында аңлашылмау ачылуга сәбәп булдым. Сез мине гафу итеңез!» — диде. Мин: «Димәк, бетте, сез үпкәләмисез?» — дидем. Егетем: «Бетте, ул сүз

[1] *Мәгаттәәссеф* — үкенечкә.

бетте, сезгә үпкәләмәдем дә, үпкәләргә хакым да юк. Ләкин менә, туташ, бу безнең очрашулар минем алдымда яңа бернәрсә ачты. Мин сезнең бик тирән күңелле икәнегезне күрдем. Шул олуглык минем, ихтыярлы-ихтыярсыз, башымны идерде. Хәзер миңа сездән аерылып китү бик авыр булачак. Еракта гына булса да, сезнең барлыгыңызны хис итмәү миңа бик зур мәхрүмлек булачак»,— диде. Мин, һәрнәрсәне онытып: «Сез китәсезмени?» — дидем. Ул да, кыска гына итеп: «Әйе»,— диде. Мин: «Бөтенләйгәме, һичбер кайтмаскамы?» — дип сорадым... Ул җавап бирмәде. Мин аптырап калдым, миндә, бердән, балалар кебек, мин дә барам дип елыйсы килү, ялынасым килү уянды. Икенчедән, үземнең кызлыгымны хис итеп, үземне тоту фикере алга килде... «Кайчан соң?» — дидем. «Иртәгә!» — диде. Тагы тынлык басты. «Ник соң бик тиз?» — дидем. «Шулай булды, безнең комиссия иртәгә китәргә карар ясады. Мин бүген, сезне күрә алмаммы дип, көн буе йөдәп чыктым. Берничә мәртәбә телефоныңызны кактым. Кибетне китерәләр дә бирәләр. Йортыңыз тирәсеннән әйләндем. Төрле хәйләләргә сапмакчы булдым. Ахырында тагын кыңгырау биреп өегезгә кадәр килергә дә уйладым. Сезне авыр хәлгә кую фикере тотып калды. Сезне күрмәенчә китсәм, мин үземне бик зур бәхетсезләрдән санаячак идем»,— диде. Мин дә ничек күрергә теләүләрдән ике сәгатьтән бирле шәһәр кыдырып йөрүемне сөйләдем. Бу сөйләүләр безнең арада калган соңгы бер пәрдәне дә алды. Ятлыкны бетерде. Безне тәмамән үзләштерде. Без, бер сүз дә әйтмәенчә, күздән күзгә вәгъдәләштек. Иреннәремез иренгә тиде... Егет: «Минем ике-өч айдан соң хезмәтем тәмам була, кулыма кәгаземне алгач та, минем беренче эшем монда чабып килү булачак. Сезне хәзерге кебек табуыма ышанып китәм»,— диде. «Ышан, ышан!» — дидем. Хатлар өчен адреслар алышып, озын көннәр күрешмәсәк тә, вәгъдәләрне беректереп аерылыштык. Егетем чулакка бер тәңкәлек көмеш тоттырганга, аның да мыгырдавы бетте.

Уема батып өйгә таба борылдым. Әллә нинди сүзне онытты кебек, әллә нинди бер хәрәкәтне ясап бетермәдем кебек, күңелемнең бер кырыен әллә ни кытыклый башлады. Ахырдан ник ядкяр өчен бернәрсәсен алмадым дигән уйга килдем. Аның артыннан, ник үзенә бер сагынмаклык бирмәдем дигән фикердә чуала башладым. Шул уйлар тагы әллә никадәр уйлар уятканга, иртәгә поездга, мотлака[1], төшәргә дип вә шунда бер бүләк чыгарырга дип карар ясадым. Бердән күңелемә бер фикер кылт итеп төште.

Чатанга: «Ашчы Сәхибәгә тукта!» — дидем. Чулагым мыгырдап туктады. Ут кебек сикереп төшеп, Сәхибә әбигә кердем:

[1] *Мотлака (мотлакан)* — шиксез, ничек булса да.

«Тозтүбәдә бер фәкыйрь кардәшемез кияүгә чыга, шуларга чәк-чәк бүләк җибәрмәкче булам. Иртәгә китүче бар, үземездә пешереп тора алмыйбыз, шуны иртәгә сәгать алтыга өлгертеп бирә аламсың, әби!» — дидем. Поезд сәгать җиде дә унбиштә китә иде. Әбием: «Хәзер бит йомыркасы бәһале, мае кыйбат, балы да искиткеч, утын да күп китә»,— дип, бик күп сөйләнде. «Күпме кирәк соң?» — дигәч, цифрны әйтмәенчә, тагы әллә ниләр сөйләп китте. Мин янчекне ачтым да бер егерме бишлекне бирдем. Әби, акчаларны күреп булырга кирәк: «Тагы берәр юкмы?» — диде. Тагы бер унлыкны төртеп, вәгъдәсен ныгытып чыгып, татлы уйлар берлә өйгә таба киттем.

Капкадан керү берлә мин башыма суык су койган кебек дерелдәп киттем. Баягы шатлыгым, кәефем бердән югалды. Әни дә шуны күреп бераз аптырады: «Әллә, кызым, берәр нәрсә бармы?» — дип сорады да. (...) Вакыты җитә башлагач, әнидән тагы йөреп керергә сорадым. «Бар инде, берәр нәрсә эшләп йөрми торгансыңдыр бит»,— диде... Рәтләп җавап та бирмәенчә, эти Мәкәрҗәдән бүләк итеп алып кайткан йөзегемне кидем дә Сәхибә әбигә таба киттем. Рактөш искиткеч уңышлы чыккан иде. Камыры килешкән, май сеңдермәгән, балы каралмаган иде. Аның өстенә әбием ике ягына да төрле конфетлардан «Нәфисә» дип язган иде. Бик кәефләнеп, төреп алып, вокзалга чаптырттым.

Поезд китәргә чирек сәгать кенә калган иде. Таныш-белеш очрар-фәлән дип уйламаенча да, платформага чыктым да икенче, беренче классларның тәрәзәләреннән күземне йөртеп эзли башладым. Менә ачык бер тәрәзә алдында егетем ак сакаллы бер урыс берлә басканнар да сөйләшеп торалар. Мине күргәч аптырап китте, кызарды. Карт урыс, көлеп, әллә нәрсәләр әйтте. Бу миңа каршы чыкты. Коридорда очрашып сөйләшә башладык. Ләкин бик күп кеше йөри башлагач, ул мине купеларына алып керде. Карт урыска башымны идем. Кулымдагы чәкчәкне өстәл өстенә куеп: «Сезгә юл бүләге»,— дидем. Аннан тиз-тиз итеп имән бармагымдагы алмаз кашлы йөзегемне суырып алдым да: «Сагынмаклык булсын, бер дә бармагыңнан төшермә»,— дип, кулына суздым. Егетем аптырады, карт урыстан да оялдымы, кызарды, әле бер бармагына, әле бер бармагына кимәкче булып карады, берсенә дә сыймады. Мин кулын алдым да чәнчә бармагына кидердем. Урыс та, мин дә көлештек. Шуннан соң тагы теге вәгъдәләрне берничә мәртәбә ишеткәннең соңында, мин китәргә калыктым. Бернәрсә оныткан кеби уйландым. «Нәрсә, тагы әллә берәр сүз бармы?» — диде. «Миңа сагынмаклык берәр нәрсәңне калдыр»,— дидем. Ул: «Мин очрашуны һич уйлый алмаган идем, бернәрсә әзерләмәдем»,— диде. Күзем өстәл өстендә ята торган бер китапка төште. «Бу синекеме?» — дидем. «Минеке»,— дип, Тургеневның «Беренче мәхәббәт» дигән хикәясен сузды. Теге

бабайга баш иеп, тагы күрешеп, атыма утырып, өйгә таба чаптым. Әтидән биш кенә минут элек өйгә кайтып өлгердем.

Әни әллә нәрсә сизенгән кебек булды. Мин хыял дөньясында гизә башладым. Менә әти тагы турсайды. Әтигә әллә кемнәр әллә ниләр килеп сөйләде. Мин өмет берлә өметсезлек арасында яши башладым. Юлдан, Мәскәүдән хатлар алгач, тагы тынычланып көтә башладым. Театрга, әдәбият кичәсенә әти җибәрмәгәнгә, кызлар мәҗлесенә үзем барырга теләмәгәнгә, мин бөтенләй өйдән чыкмас булдым. Һәр мәҗлестән, театрдан калмый торган бер кызның болай ябылуы бик күп гайбәткә сәбәп булды. Вокзалда, театрдагы очрашулар тагы әллә ничә төрле иттереп сөйләнде, ахырдан: «Нәфисә бер урыс егетенә гашыйк булган икән»,— дигән бер гайбәт бөтен шәһәрнең авызында тәсбих кебек йөри башлады. Шулар әтине бик хурландырды, әнине дә бик кайгыртты. Алар, кызымызга урын чыкмый кала инде дип, төн буе кайгырышып, сөйләшеп ята торган булдылар. Менә шул арада булмады, Орск шәһәреннән миңа яучы килде. Әтиләр, әниләр бик сөенделәр, тәмам бирергә вәгъдәләшергә әзерләнделәр. Мин бөтен көчем берлә каршы торырга тотындым. Мин кияүгә чыкмыйм, дидем, авыруга башымны салдым, еладым, илтифат иткән булмады. Ахырдан әтигә егет берлә булган соңгы вакыйгаларны тәмамән аңлаттым. «Башка беркемгә дә чыкмыйм»,— дидем. Әни минем яклы кебек булса да, көчсез булганга, бер эш эшләвенә ышана алмадым. Егетемә хат өстенә хат яздым. «Эшләр бик мөшкел була башласа, телеграм бирермен, килергә әзер тор»,— дидем.

Менә беркөнне әти: «Киләсе дүшәмбегә мәҗлескә аш-су әзерләңез, колак сөенече мәҗлесе. Мин кибеттән өндәү чыгартырмын»,— диде. Мин ап-ак булдым. Калтырандым, дерелдәдем... Әллә ни әйтәсем килде, авызымны ача алмадым. Ахырдан теге егетемне, аңарга биргән вәгъдәмне хәтерләдем дә, әтигә туп-туры иттереп: «Мин бармыйм, әти... Теләсәңез нишләгез! Бармыйм»,— дидем дә бүлмәмә чабып чыгып киттем. Ябылып бик озак еладым. Әнинең сүзенә дә, тиргәвенә дә, юатуына да карамыйча, чыгып китеп, почтага барып, озын иттереп, телеграм бирдем. Башым чуалган булганга, әллә ниләр язып бетердем. Шуннан тегеннән җавап көтә башладым. Хат та, хәбәр дә юк. Бик борчылдым. Гаскәр хезмәте тулыр өчен, әле тагы айдан артык вакыт калганга, килә алуына бик шөбһәләндем. Менә көтә-көтә көт булып өметсезләнергә җиткәндә, бер җомга көнне үземне әллә ничек җиңелчә хис иттем. Күңелле төшләр күреп уяндым. Җырлап-көйләп, бүлмәдән бүлмәгә йөри башладым. Шуны күреп, әни дә кәефләнде. Ахрысы, минем күңелемдә үзгәрү булды дип уйлагандыр, миңа ул: «Һәрвакыт шулай була, язганнан узып булмый, ата-ананың догасыны алсаң, бик һәйбәт

торырсың, фәлән»,— дип сөйләнде. Ләкин мин аны ишетмәдем дә, тыңламадым да. Менә җомга җитте, әти җомгага китте, әни, тәһарәтен алып, үз бүлмәсендә өйлә намазына утырды. Бердән телефон. Бардым, «Тыңлыйм!» — дим. «Нәфисә, синме?» — ди егетем, ачык тавыш берлә. Мин: «Синме, кайчан килдең?» «Бүген сәгать унда, менә, телефон итәр өчен, җомга башланганны көттем»,— диде. Мин бер минутта бөтен вакыйганы сөйләп ташладым. Сәгать дүрттә шәһәремезнең бер урыс кибетендә очрашырга сүз алдым. Аңгырча карт хәзрәткә барып, мәсьәләне аңлатып, аны яучы итеп җибәрүнең кирәклеген белгерттем. Сүз арасында: «Ничек җибәрделәр соң, әле гаскәр хезмәтең бетмәгәндер бит?» — дип сорадым. «Синең чәкчәк аркасында, ул карт минем башлыгым, профессор иде. Чәкчәкне бик яратты, сиңа да Чәкчәк дип ат кушты. Телеграмың килгәч тоттым да үзенә бардым. Мәсьәләне сөйләдем. Оренбургка командировкага бирде дә җибәрде»,— диде. Теге өйнең ишеге ачыла башлагач, телефонны кистек.

Мин, бик һәйбәтләп тәһарәт алып, зур бер ихлас берлә намаз укырга керештем. Егетемне китереп җиткерүе өчен, миңа ярдәме өчен Аллага шөкранам шулкадәр зур иде, мин, намазым беткәч тә, намазлыктан тора алмадым. Коръән укырга тотындым. Укыдым, укыдым, тагы аз булган кеби булды, тагы укыдым. (...) Догамны кылып, тәмам тынычланып, чәйгә чыктым. Әти дә, әни дә, мине Орскига бару фикеренә ияләшә дип уйлаганга, егетнең килүеннән хәбәрләре булмаганга, бик йомшак мөгамәләдә булдылар. Әти: «Менә кирәгеңез-фәләнеңез булса, кибеткә чыгыңыз, яңа маллар килде, сайлап алырсыз»,— диде. Әни: «Чыгарбыз да шул!» — дип куйды. Мин: «Сабак абыстай берлә күрешеп киләсем килә иде»,—дидем. Әни дә, әти дә: «Бар, бар! Ат җиктер дә бар»,— диделәр. Әни тагы: «Үзенә берәр күлмәклек алып бар»,— дип куйды.

Мин сәгать дүртләргә кадәр алай итеп, болай итеп вакытны суздым. Дүрттә тугры ук теге кибеткә килеп кердем. Егетем почмакта әллә нинди яулыклар сайлап тора иде. Мине күрү берлә каршы килде. Мин аз гына кочагына атылмадым. Тиз генә алган нәрсәләрне алып, атка утырып чыгып киттек. Зират янына барып бик озак сөйләштек, сүз беркеттек. Ул хәзрәткә барган, мәсьәләне аңлаткан. Хәзрәт тә бүген ястүдән соң яучы булып килергә вәгъдә биргән. Мин дә үземнең сабак абыстама,— хәзрәтнең тол кызына барып сөйләячәгемне белгертеп, төрле ихтималга каршы төрле вәгъдәләр ясашып аерылыштык. Сабак абыстама туп-тугры киттем, бүләгемне бирдем. Догасын үтендем. Үзем әллә ник моңаеп киттем дә еглап җибәрдем. Абыстай: «Яучы килгән дип әйтәләр, Алла хәерлесен тугры китерсен, Орск шәһәре бик матур, фәлән»,— дип, мине юатты.

Мин ачтым да мәсьәләне сөйләп бирдем. Сабак абыстай аптырап калды. Егетемнең монда килүен, карт хәзрәт берлә бүген бик озак сөйләшеп, аның яучы булып баруына вәгъдә алуын аңлаттым... Аңардан да: «Ярдәмдә булыгыз инде»,— дидем... Сабак абыстай: «Изге эшкә без һәрвакыт ярдәмдә, мин бит синең әниеңнән башканы күрә алмыйм»,— диде. Мин хәзрәткә сөйләргә үтенеп киттем.

Мин кайтканда, өйдә бер яңалык та юк иде кебек. Кичкә таба гына әти: «Ясигъдан соң хәзрәт киләм дигән. Пылау салып, чәй әзерләп көтегез!» — дип телефон итте. Мин көтәргә тотындым. Вакыт җитте, хәзрәт килде, чәй бирелде. Хәзрәтнең бер йомыш берлә килүе билгеле булганга, әни дә нәрсә сөйләгәнен ишетер өчен, мин дә әтинең ни җаваплар биреп, эшләр нигә барачагын күрер өчен, бүлмә ишеге янына килеп утырдык. Берәр чынаяк чәйдән соң хәзрәт сүзгә керешге. Миңа мәгълүм сүзләрне сөйләп әтидән җавап көтте. Моны ишеткәч, әни: «Уф!» — дип сулап куйды. Миңа күзен тирән иттереп батырды. Әти, яшен суккан кебек, бер сүз дәшә алмаенча, аптырап, җавапсыз калды. Хәзрәт, егетне сөйләп китеп: «Урыс арасында тора торган кеше, үзен үзе саклап, мөселман гаиләсенә катышырга теләве өчен, мин тәхсин[1] укыдым. Нишләр идек, бер марҗа тотып: «Хәзрәт, никах укы»,— дип килсә яисә, никахсыз-нисез балалар атасы булып, урыс күбәйтсә. Мин бу егетне бик яраттым»,— диде. Әти: «Хәзрәт, сез дә шундый сүзләр сөйләгәч, безгә, надан кешеләргә, ни кала инде»,— дип, хәзрәт белән моназарага керешге. Ахырдан: «Безнең инде, хәзрәт, Орскилар берлә ярты вәгъдәмез бар. Рәхмәт сезгә! Ләкин, хәзрәт, сез шундый ярты урыслар артыннан олуг башыгызны кече итеп йөрү кирәкмәс иде»,— диде. Хәзрәт: «Без — пәйгамбәр галәйһиссәламнең варислары. Кем безгә дин эшендә мохтаҗ — һәммәсенә ярдәм итешү — дини вазифабыз»,— дип, тагы җавап бирде. Әти тагы әллә ниләр әйткәләгәнгә, хәзрәт, кызып китеп: «Ахмак!» — дип, әтине тиргәп тә ташлады. Тагы йомшардылар, тагы сөйләштеләр. Әти, тагы кисеп: «Юк!» — дип җавап бирде. Хәзрәт: «Җәмәгатең берлә сөйләшеп карарга кирәк, кызыңның хәлен дә белергә кирәк»,— дисә дә, әти һаман үз сүзендә торды. Чыгып киткәндә, хәзрәт: «Хата итәсең, хата итәсең, үзсүзлек кенә итәсең, уйлаш, мин әле тагы килермен»,— диде. Әтинең: «Олуг башыгызны кече итеп йөрмәгез, хәзрәт»,— дигән сүзенә каршы ул: «Башымыз шул шулай вакытында кече итә белгәнгә күрә, ул олуг булган, изге эшне болай кисәргә ярамый, җәмәгатең, гаиләң берлә киңәшләш, иртәгә килермен»,— диде... Хәзрәт киткәч, әти тагы ду килде, әни тагы елады. Ләкин мин, ярты

[1] *Тәхсин* — яхшы дип әйтү, мактау.

эш бетте кебек хис итеп, һичбер борчылмадым. Иртә берлә сәгать уннарда тагы хәзрәт килде. Бу юлы хәзрәт, ачыктан-ачык минем хакта, минем разыйлыгым хакында сөйләп: «Эшне матур итәргә кирәк, егет бик һәйбәт. Сезгә нәрсәгә дәүләт кирәк, Алла бәхетләрен бирсен, фәлән»,— дип, бик күп үгетләде. Әти һаман сүзендә булды.

Өйләдән соң аш вакытында сабак абыстай килде. Әни ашасыннан әтигә бик күп сүз сөйләде. Әни разый булса да, әти тискәрелегеннән кайтмады. Мин, сабак абыстайны озату сылтавы белән чыгып, егетем янына киттем. Ул тәмам куырылган, пәҗегән[1] иде. Хәзрәтнең сөйләгәннәреннән әтинең кылынуларын белеп өметсезләнгән, аптыраган иде. Мин аңарга: «Мин актыгына кадәр барам, булмаса, синең берлә китәм дә. Уфага барырмыз да анда собраниедә мөфти хәзрәттән никах укытырмыз»,— дидем. Ул минем кулымны тагы бик каты кысты, аның йөзе ачылды. Күңеле күтәрелде. Төрле планнар уйлап, без тагы йөреп киттек. Сөйли-сөйли вакыт озаеп киткәнгә, кич булды. Мин өйгә кайтудан, тагы әтинең акыру-бакыруын ишетүдән курыктым. Шул мәсьәләнең эт эчәгесе кебек сузылып китүеннән эчем пошты. «Әйдә, хәзрәтләргә барыйк та никах укырга сорыйк»,— дидем. Ул, күзен тутырып, ышанмаган кебек: «Шуңарга кадәр барамсың?» — диде. «Ник бармыйм, әйдә!» — дидем. Ул: «Шуның ахырларын беләмсең, әтиең, әниеңнең никадәр рәнҗүләрен күрәчәксең?» — диде. Миңа шул сүзләр ул вакыт әллә нигә һич тәэсир итмәде. «Һәммәсенә разый!» — дидем дә атны хәзрәтләргә борырга куштым. (...)

Хәзрәт берлә бергә ястүдән соң әти керде. Ул мине каргады, егетемне тиргәде, хәзрәт берлә моназарага кереште. Мине көчләп алып китмәкче булды. Мин кайтмадым. Хәзрәт: «Болай булмый, әйдәңез, барымыз да барып, өеңездә иҗабе кабул итик[2]»,— диде. Әти һаман разый булмады. Мин абыстай ашасыннан хәзрәттән никах укуын үтендем. «Булмаса, без барыбер Уфага барып та укытачакмыз»,— дидем. Бу эш әтине тәмам тилертте, әнине дә шаштырды: «Син ни эшлисең? Син бит йөземезгә кара ягасың, фәлән»,— дип шелтәләргә тотынды. Ахырдан әти: «Ярый, әйдә, кайтсын, иртәгә карармыз, фәлән»,— диде. Мин: «Менә шунда никах укымаенча, бу өйдән чыкмыйм»,— дидем. Хәзрәт аптырады. Әтигә тагы нәсыйхәт итеп карады. Ахырдан: «Без — шәригать кешесе, без диннең хөкеменә каршы килә алмыймыз. Кыз, егет икесе дә шуны теләгәч, никах укыймыз»,— диде. Әти һаман: «Мин разый түгел!» — диде дә торды. Хәзрәт чалмасын киде. Метрикасын алды, мәдрәсәдән ике хәлфәне чакыртты. Шулар

---

[1] *Пәҗегән* — сулган.

[2] *Иҗабе кабул итү* — ярәшү.

алдында тагы бер мәртәбә этигә әйтте, тагы эти: «Юк!» — диде. Әни кычкырып егларга тотынды. Хәзрәт, кычкырып, безнең икемезнең дә разыйлыгымызны сорап, миннән, өч мәртәбә «разыймын» дип, үз авызымнан әйттереп, кычкырып, никах укыды. Шуннан соң, этигә карап: «Инде нишлисез, болар хәзер ирле-хатынлы булды, ләкин һаман сезнең балаңыз, тискәреләнмәгез!» — диде. Әти бер сүз эндәшмәде, әни еглады.

Барымыз урамга чыктык, әти берлә әни алдан киттеләр. Без икәүләп артларыннан киттек. Капка төбенә барып җиткәч, никтер, туктадылар. Минем күңелем йомшарды, бардым да әнигә: «Бәхил бул, әни»,— дип, муенына сарылдым, еглый башладым. Аннан этине кочакладым. Өчемез дә еглашырга тотындык. Егетем тик катып калды. Капка ачылды. Әти берлә әни керде. Мин басып калдым. Эти: «Әйдәгез, әйдә, Нәфисә!» — диде. Мин: «Ялгыз керә алмыйм, кермим»,— дидем. «Икеңез дә кереңез»,— диде. Кердек. Берәр атнадан соң мәҗлес ясап туй иттеләр, ләкин туемыз зур булмады. Бер атнадан мин киявем берлә Мәскәүгә киттем. Менә шуннан бирле бергә яшимез. Аллага шөкер, бу көнгә кадәр арамызга бер кер төшкәне юк»,— диде дә туктады. Үз бәхетеннән үзе шатланган кебек, аның йөзенә тагын елмаю йөгерде. Ул тәмле иттереп сулап куйды.

Гөлсем: «Сез бигрәк бәхетле булгансыз икән... Ләкин шулкадәр иттереп нык тотынырга сезгә кем гакыл бирде?» — диде. Нәфисә: «Беркемнән бер киңәш сорамадым. Беркем берни өйрәтмәде. Уйлап та тормадым. Күңелем ни кушты, шуны эшләдем, шул барып та чыкты»,— диде. Яңа хатын, тагы кызыгып карап торганның соңында: «Бу соң сезнең беренче сөюеңез идеме?» — диде. Нәфисә: «Беренче һәм соңынчы сөюем... Безнең әле сөешүемез беткәне юк. Мин әле менә иремә барам, теге көнге хәзрәтләргә баргандагы хис берлә, күңел теләге берлә барам»,— диде. Тагы көлемсерәп уйга батты. Аның күзе алдында тагы күрешү мәнзарәсе[1] үсте, күрәсең, ул тагы эченнән көлде. Гөлсем: «Иреңез кайда соң, кая барасыз?» — диде. Нәфисә: «Минем ирем — Мәскәүдә үпкә авыруы докторы. Үткән елны бик күп эшләп, приват доцентлыкка имтихан тотты. Ләкин, мөселман булганга, министр тасдыйк[2] итмәде. Шуңарга шактый борчылды. Иптәшләре арасында татар дип кимсетүгә дә хурланды. Бу урыс хезмәтнең кадерен барыбер белми, балачага да үсә, урыс арасында яшәүдән мәгънә чыкмас дип, йә Казан, йә Әстерханга урнашыр өчен эзләнергә, белешергә дип чыгып китте. Йөри торгач, рәтле урын очрамагач, Мәскәүдә үк калырга карар иткән. Безнекенең Мәскәүдә кадере бик зур.

[1] *Мәнзарә* — күренеш.
[2] *Тасдыйк* — раслау.

Ул — «Җәмгыяте хәйрия» рәисе, мәктәп комитетының башы. Аннан башка Мәскәүдә бер эш тә эшләнелми. Бөтен киңәш бездә, бөтен авырулар бездә, балаларга үз халкымыз арасында торырга җайлы булсын дип, бер зур мөселман авылы янында кечкенә генә җирле, сулы, бакчалы бер утар сатып алган. Менә хәзер беренче мәртәбә шуны күрергә барамыз. Киләсе елдан, насыйп булса, ат, сыер алып, бөтен җәйне шунда үткәрәчәкмез. Бала-чага нинди тирә-юньдә үссә, шуның гадәтен ала... Без тора торган җирдә һаман урыслар гына иде. Менә инде, насыйп булса, үз илемездә яшьлекләрен үткәрәчәкләр»,— диде дә туктады.

* * *

Гөлсемнең күңеленнән үзенең балалары кичте. Бу бәхетле кешеләрнең балалары хакында шулай уйлаулары гаҗәп кебек тоелды. «Минем балаларым кем булыр икән соң? Алар хакында кем төшенә соң?» — димәкче булды. Тагы әллә нинди сөальләр бирмәкче булса да, фикере балаларына, балаларының тәрбиясенә, киләчәгенә киткәнгә, шул уйда батып калды, каюта тынды. Пароход бердән озын гына кычкыртты. Шуңардан куркып, яңа бикәнең бер баласы, тагы сикереп торып: «Әни! Әти килә, әти!» — дип кычкыра башлады. Яңа пристаньга килеп туктадылар. Тагы кешеләр йөрде, керделәр, чыктылар. Гөлсем, балаларын тынычландырып яткырганның соңында, урынына килеп утырды. Тәрәзәдән төшә торган фонарь яктысы аның болай да ак йөзенә саргылт бер төс кушты, ул, мумия кебек катып, Нәфисәне, үзеннән, үзенең бәхетеннән разый Нәфисәне сөзде. Аның тирән йокыда ята торган балаларын бик озын җентекләде. Тирәннән чыккан тавыш берлә: «Сез бигрәк бәхетле икәнсез... Мин башка, минем тормышым бөтенләй икенче юлдан китте. Икенче яр якасына мине дә илтеп ыргытты»,— диде.

«Мин — бер мирза кызы. Мин кечкенә чакта әнием үлде.

Мин әти берлә ялгыз калдым. Берәр елдан әтинең сеңлесе, ире үлеп кайтты да шул миңа аналык итте. Бик тиз мине укыта башладылар, ләкин урысча укыта башладылар. Минем беренче таныган китабым урыс китабы булды. Беренче укыганым урыс тормышы булды. Шуннан мәктәпкә кердем. Анда да, билгеле, урыс мәктәбенә кердем. Тирә-юнемездә һәммәсе урыс иде, өйдә дә урысча сөйлиләр иде. Килгәннәр урыс була, барганнарымыз урыс була иде, бәйрәмнәр булганда гына, мин үземезнең әллә нинди икенче төрле урыс икәнемезне, рождество ясамаенча, корбан бәйрәмен, гает ясый торган урыс икәнемезне хис итә идем. Иптәшләрем арасында шул чынлап урыс булмавымыздан хурлана да идем. Әти бик күп эшли торган кеше булганга, тутакай, үзен әле яшь дип уйлап, киенү-ясануны бик яратканга,

миңа өйдә илтифат иткән кеше дә бик аз иде. Минем тәрбияче маржаларым әле берсе, әле берсе алышынып торганга, мин күбәләк кебек әле бер ут янына, әле бер ут янына оча идем. Җәйләрен кай елны Кырымга бара идек, кай елны Кавказга, кайбер елны Германиягә дә китә идек.

Менә шулай барганда, бер елны, җәйне уздырыр өчен, без Уфа губернасындагы әнинең әнисенә — әбиләргә киттек. Аларның Дим суы буенда бик матур утарлары бар икән. Андагы һавада да үзенә аерым төсле бер матурлык бар икән. Ул Кырымнан күңелле, Кавказдан төрле, Германиядән дә татлы икән. Мин бару берлә әби мине бик ныклап карады-карады да: «Анасына охшаган, тәмам анасы»,— диде. Мине сөйде. Моңарчы сөюләргә караганда йомшаграк сөйде. Монда өйдәге тормыш тәмамән урысча булса да, хезмәтчеләр бар да үз кешеләремез иде. Сүз, җыр — һәммәсе үз телебездә иде. Мин барган көндә үк тау башына утырып курай тарткан малайларны күреп, аларның әллә нинди моң-көйләрен ишетеп аптырап киттем. Мин үземне чит бер тирә-юнь эчендә күрдем. Ләкин әллә ничек болар һәммәсе дә чит булса да, әллә кайчан ишеткән идем, шуның эчендә булган идем кебек бернәрсә сизендем. Кунаклар килде. Кунакларга бардык, ләкин һәммәсендә дә ярты урысча, ярты үземезчә бер тормышка очрадым. Менә минем әти китте. Тутакай, бер шәһәргә барып, бер башка мирзаларга кунакка йөри башлады. Мин әбием берлә ялгыз калдым. Ул инде бик нык карчык булган иде, үзе мирза бикәсе булса да, башына зур калфак киеп, өстеннән яулык бәйли иде. Ул кайвакыт тәһарәт алып намазга да утыра иде. Миңа элгәре болар бик гаҗәп тоелды. Мин, үземнең чын урыслыгыма зарар килә дип, бераз курыктым да. Ләкин баратора өйрәндем. Менә беркөн, җәйнең иң матур вакытында, без җиләк җыеп кайтсак, бөтен өйнең асты өскә килгән дип таптым. Иданнәр юылган, мунчалар ягылган, әллә никадәр аш-су әзерләнгән. «Нәрсә бар?» — дип сорадым. «Бүген сәхәр ашыймыз»,— диделәр. «Нәрсә соң ул сәхәр?» — дидем. Хезмәтче кызлар, көлеп: «Иртәгә рузага керәмез»,— диделәр. Менә кич булды. Мин кызлар берлә бергә тәравих[1] әйткәнне тыңларга киттем.

Кич берлә сәхәр ашау бик күңелле булды. Ләкин, иртә белән торгач та, безгә чәй бирмәделәр. Җиләккә барырга рөхсәт итмәделәр. Мин уразага кердем.

Беренче көннәрдә ураза тоту бик читен булса да, мин бик тиз өйрәндем. Кызлар берлә азан әйткәнне, кич белән тәравих әйткәнне тыңларга бару бик күңелле булды. Әби миңа, рамазанда урысча киенергә ярамый дип, татарчалатып, итәкле күлмәк тектерде, башыма яулык бәйләтте. Менә мин шул тормышка

[1] *Тәравих* — уразада кич белән укыла торган намаз.

иялэшеп кенә беткән идем, тутакай кайтты. Ул: «Бу нинди эш бу? Мондый озын көндә баланы ураза тоттыр, имеш, ул болай да аз канлы, бу тилелеккә мин чыдый алмыйм, әтисенә язам, фәлән»,— диде. Әби берлә әйткәләшеп тә алдылар. Тутакай мине үзе берлә чәй эчерергә маташты. «Урысчасы бөтенләй онытыла торгандыр, менә класста калыр»,— дип, минем гувернанткамны тиргәп, безне дәрескә утырртты. Минем тормышымның рәте китте. Мин әбием өчен, шундагы кызлар өчен тутакайдан качып сәхәр ашый, азан тыңлый торган булдым. Тутакай өчен, әбидән качып, көндез чәй эчә торган булдым. Бәйрәмне көттермәенчә, баланы тәмам татарлатып бетерделәр дип куркып, тутакай мине алып китте.

Шул елны мин укый торган мәктәпкә тагы ике мөселман кызы укырга керделәр. Аларның әниләре, начальницага килеп сөйләшеп, мәктәпкә мулла китереп, дин дәресе укыттыра башладылар. Начальница миңа да керергә кушканга, мин дә дин дәресенә йөри башладым. Шунда укырга, язарга өйрәндем, шунда догалыклар бикләдем. Шул юлда барганда, мин буй үсеп җиттем. Мәктәпне бетердем, кыз булдым. Безгә Петербургның бөтен мирзалары, Кырым, Кавказның бөтен урыслашкан түрәләре таныш-белеш иде. Төрле җирләрдә хезмәт итә торган Кавказ әфисәрләре, төрекмән егетләре бар да килүчән-китүчән иде. Тутакай искедә бер әфисәр хатыны булганга, ул гаскәри киемдәге кешеләрне ярата, алар берлә чормалану, болгануны сөя иде. Картаеп килсә дә, ул әле яшь әфисәрләр берлә кылынгачлана иде, алар берлә әллә нишләп бетеп чуала иде. Мин кыз булып, үземне үзем кыз итеп хис итә башламадым, минем артымнан әллә нинди кешеләр йөри башладылар. Бер полковник миңа бик еш чәчәк китерде. Телефон берлә исәнлегемне сорашып, тутакайлар берлә театрларга алып китте, миңа кавалер булып йөри башлады. Бервакытны бу, минем алдыма тезләнеп, минем кулымны да сорады. Мин аптырап киттем, һичбер башымда, күңелемдә андый фикер булмаганга, бер сүз әйтә алмадым. Тутакай эшкә катышты. Полковникны миңа димләргә кереште. Миңа генеральша булып торуны, зур урыс дөньясына катышып китүнең юллары ачылуны озын иттереп бизәкләндереп сөйләде. Мин кызыктым да, ләкин, күңелемдә шул кешегә каршы һичбер төрле хис булмаганга, сүз бирә алмадым. Әти дә минем яклырак булганга, яшь әле дип, эшне кичектерделәр. Полковнигымның килүе сирәкләште, очрашканда, ул үпкәләгән кыяфәтне бирәсе килде. Ләкин бер ике-өч ай вакыт үтмәде, ул карт кына тол хатынга өйләнеп тә китте. Аның эзе югалырга өлгермәде, бер кыргыз студенты, кыргыз хатынының туруны[1] булып, безгә

[1] *Турун* — онык.

йөрергә тотынды. Ул миңа бик күп әрмән анекдотлары сөйләде. Кыргызларның урысча белмәүләреннән килеп чыккан көлкеле хикәяләрне аңлатты, үзенең, университетны бетереп чыккач, уездный булып, нинди генә түрә булып торачакларын бизәде, бизәкләде. Менә бу да, беркөнне театрның фойесында, тавышларын калтыратып, бик озын иттереп сөйләп, мине сөйгәнен, минсез тора алмаячагын белдерде. Нә сүзләре, нә кыланышлары миңа һичбер төрле тәэсир итмәгәнгә, минем күңелнең нечкә кылларына барып төртелмәгәнгә, моңарга да сүз кайтармадым. Бусында тутакай да каршы булмады, эти дә бер сүз әйтмәде. Ул озын хатлар язды, чәчәкләр җибәрде, ялынды, ялварды, ләкин мин һаман үз сүземдә калдым. Укып бетереп китте дә, андагы кечкенә вакытыннан әйттереп куйган кызын алды да начальник булып тора башлады.

Аның артыннан бер кавказ инженеры килеп чыкты, аның артыннан бер Литва татары, аның артыннан бер иранлы принц, шулар арасында өйгә килеп йөри торган урыс эфисәрләре, урыс студентлары хатлар яздылар, шигырьләр әйттеләр. Ләкин һәммәсе дә күңелемне керләтеп калдырудан башка бер хис уятмадылар. Менә шулай торган чакта, беркөнне безне татар студентлары түгәрәге үзенең кичәсенә чакырды. Кечкенә залда үз кешеләребездән генә җыелган кичә бик күңелле булды. Буфет милли ашлар берлә корылган, укучылардан милли оркестр төзелгән. Татарча кечкенә генә бер пьеса сайланган. Кычкырып укыр өчен, матур җырлар, шигырьләр чүпләнелгән иде. Кичә миңа әллә ник үземнең кечкенә чактагы теге әбиләрдәге авыз ачуларны хәтерләтте. Мин чын күңелдән шатландым, тирән бер кәеф берлә кәефләндем.

Егетләр, кызлар берлә уеннар уйнап йөргәндә, бер студент гаепле калды. Мин хан идем. Аңарга җәза иттереп ни эшләргә белмәенчә аптырап торганда, берсе: «Татарча бер шигырь декламациясе»,— диде. Ул «Син» дигән шигырьне укыды. Шундый матур укыды, миңа шундый зур тәэсир ясады, мин изрәп киттем, мин, хан булганга: «Тагын берне!» — дидем, яшьләр кул чабып каршы алдылар. Ул тагы берне укыды, тагы шәп чыкты. Шуннан без ул студент белән танышып киттек. Аның исеме бер төрек пашасының исеме булгангамы, әллә ул төрекләрне бик яраткангамы, аңарга Паша дип йөриләр иде. Мине дә Паша дип таныштырганнар иде. Ул үзе дә шул исемне яратканга, мин дә Паша дип эндәшә башладым. Мин аны үземезгә дә чакырдым. Ул килә башлады. Ләкин бер дә моңарга кадәр миңа йөргән егетләр төсле кылынмады, ул миңа татар әдәбияты, шигырьләре хакында сөйләде, хәзерге агымнар хакында мәгълүмат бирде. Ахырдан татарча китаплар китерде. Ул минем алдымда яңа бер дөнья ачты. Мин сусаган дәрт берлә шуңарга тотындым.

Әдәбият укыдым, шигырьләр бикләдем. Мәҗмугалар, гәзитәләр алдырып, шул хәятнең эченә керә башладым.

Менә җәй булды. Пашаны җәйгә безгә утарга кунакка чакырдым. Шуны да әйтеп китәм: баштан ук минем тутакай аны яратмады. Кешеләр алдында һаман аның гаепләрен табарга тырышты. Миңа аның хакында һаман шикләр уята торган сүзләр сөйләде. Ләкин боларның берсе дә миңа тәэсир калдырмаганга, минем Пашага мөнәсәбәтем үзгәрмәде, җәйнең матур чагында бу безгә килде. Тутакай үзенең үлгән иренең әллә нинди кардәшләрен көтә икән. Егетнең килеп төшүе берлә: «Инде моны кая урынлаштырыйк, фәлән бүлмә минем каен энем мирзага, фәләне минем тудыгым мирзага, фәләне Мәрьям Ивановнага, фәләне Суфия Салиевнага»,— дип, бөтен бүлмәне бүлеп куйды. Минем кунагыма чарлактан башка урын калмады. Минем шул эшкә кәефем китсә дә, тутакай берлә сүзгә керешә алмадым. Паша һичбер төрле үзенең күңеле кырылганын белгертмәде. Көннәр бик матур тугры килде, без, иртә торып, җиләккә киттек. Салкын төшеп, су буйлары шәрәләнгәч тә, балыкка бардык, күрше урманга самавырлар алып төшеп хозур кылдык. Пашам көннән-көн өйрәнде, үзләнде. Тирә-юньдәге бөтен кеше үзенә мәхәббәт куйды. Әти дә аны яратты, хезмәтчеләр дә хөрмәт итте. Ләкин тутакай һаман үз сүзендә булды. «Каен энем мирза килсә нишләрмез, моны ни дип таныштырырбыз, моның бит өсте-башы да беркатлы, үзен тотуы да татарча. Нәсел-нәсәбен дә Алла белсен, кызы җиткән йортларда кунак чакыруда бик сак булырга кирәк»,— дип, этигә бәйләнде. Егетнең бер генә җитмәгән җире булса, шуны зурайтып, ямьсезләтеп сөйләде. Карт хезмәтче хатын берлә аңа «затсыз» дип исем кушты. Кунак-төшем булганда, аңарга урынны иң түбәндә, энидән калган карт экономка берлә беррәттән ясатты. Ләкин Паша сизмәдеме, сизенмәгәнгә сабыштымы, һичбер төсен, йөзен бозмады.

Ул миңа бик күп яңа татар китаплары алып килгәнгә, без кайвакыт бакчадагы шәүләле бер почмакта сәгатьләр буе китап укыдык, кайвакыт, сүзгә керешеп китеп, аяклар кай таба барганны сизмәенчә дә, урманга кадәр йөреп киттек, кайвакыт икемез, ике кармакны салып, сузылып киткән тын суның тирәнендәге нәрсәләрне күрер өчен, күземезне суга батырып, судагы бер-беремезнең шәүләләре берлә күңелдән-күңелгә сөйләштек. Бик озак тын торгач кына, берсүзсез елмаешып алдык. Кармактан өзелеп киткән көмеш кебек балыкның, «чулт» итеп төшеп, суны ярып җибәрүеннән, зур бер көлке кебек, чын күңелдән көлештек... Кайвакытларда чәчәктән чәчәккә очып йөри торган умарта кортының бызылдавы, ерактагы чикерткә туеның җырлавы, әле югары менеп, әле түбән төшеп, лезгинга бии торган чиркәс кызы кебек әйләнә-бәйләнә торган карлыгачның моңнары, дәртләнүе

астында изелеп киттек. Үземезне үземез югалттык, тирә-юньне оныттык.

Көннән-көн үтте, көн үткән саен, минем күңелемә бер тынычлык урынлашты, үзем күрмәгән бер бәхет мине томалады. Сизеп бетермәгән әллә нәрсә мине сөйде, иркәләде. Мин ачылганнан-ачылдым. Көн буе көлдем, җырладым, музыка уйнадым. Кич булдымы, биләүсәдәге бала кебек, тирән йокыга чумдым. Иртә үк мине тагы шул ук бәхет, шул ук татлы тормыш каршы алды. Мин тазардым. Йөзләрем кызарды. Кулларым тулды. Үземдә әллә нинди зур бер көч хис иттем. Кара урманнан үтү дә куркыныч булмас кебек күренде. Кичелмәс таулар аша атлау да берни тормас кебек сизелде. Паша да кызарды, янды, каралды. Аның күзләре тагы нурлыланды. Аның көлүе, елмаюы тагы җанлыланды. Ләкин минем тутакай һаман сеңерләнгәннән-сеңерләнде. Ул мине: «Кызлар үзләрен шулай тотамыни?» — дип шелтәләде. Мине егет берлә калдырмас өчен, әллә нинди хәйләләргә сабышты. Паша артыннан ухаживать итәр өчен, күрше боярларның сарыпсыз[1] бер кызын чакырып китерде. Өйдә әллә никадәр буш бүлмә булса да, аны егетнең күрше бүлмәсенә чарлакка җирләштерде. Теге кыз бик тырышып кылынгачлана башлады. Пашаны артыннан йөртергә маташты, әллә нинди капризлар ясады. Атларга атланып урманнарга китте, егетне анда өстерәде, монда өстерәде. Берни эшли алмаса да, минем элгәреге татлы тормышымны тынычсызландырды. Пашаны да әллә нинди уңайсыз хәлләргә куеп сеңерләндерде, безнең бергә йөрүемез, сөйләшү, көлешүләремез авырайса да, бу нәрсә мөнәсәбәтемезгә күңелсез бер сызык сыза алмады.

Ләкин эти белән тутакай әллә нәрсәләр киңәшләшә, әллә нинди җитди бер төс берлә сөйләшә башладылар. Кайвакытларны сәгатьләр буе бүлмәдә ябылып калдылар. Менә беркөнне теге кодаларның юлга чыгуларыннан телеграм килде. Тутакай ут булды. Өйләрне җыештырттырды, бүлмәләрне әзерләтте. Аш-су кирәк-ярагы, әчемлекләр алыр өчен, шәһәргә кеше җибәреп, бөтен йортны аякка калкытты. Мине үзенә чакырып: «Каен энем мирзалар киләләр. Алар — нәсел-нәселдән мирзалар. Үзе охрана величествода хезмәт итә. Олуг кенәзләр берлә таныш. Тагы аның кардәше килә. Анысы тагы — дикий дивизиядә эфисәр. Студентны нишлимез? Борчак оны берлә балны бергә бутап булмый. Ничек аларны бергә кушып кунак иттереп йөртәсең? Кайчанга китә инде ул?..» — диде. Мин кызардым. Бер яктан хурландым, бер яктан, Пашаның мирза булмавы өчен кәефсезләндем. «Әүвәл аңа аңлатырга кирәк... Ул үзе аңламас, ул бит общество күргән кеше түгел. Әйтергә кирәк, туп-туры

[1] *Сарыпсыз* — талымсыз, тотнаксыз.

иттереп әйтергә кирәк, инде юлыңда бул, егет, дияргә»,— диде. Мин: «Кунакны ничек алай итәсең»,— дидем, ләкин каты иттереп Пашаны яклап китә алмадым. «Үзе дә китәм дип тора иде, шул арада китә инде»,— дидем. Тутакай тагы: «Син үзеңне кеше төсле тот... Безнекеләр — бик үткен кешеләр. Аяк басуыңнан сизәрләр. Ул егетне синең кавалерың дип уйлый күрмәсеннәр... Аннан соң эш харап»,— диде...

Чынлап та, менә өч тройкада кунаклар килеп төште. Бөтен йорт яңа ирләр, яңа хатыннар берлә тулды. Кичке аш искиткеч тантаналы үтте. Тутакай кырык төрле аш әзерләткән, кырык төрле эчемлек берлә өстәлне тутырткан. Мине яңа әфисәр янына утырттылар. Ул, бертуктамаенча: «Виноват, виноват, прикажите!» — дип, мине сыйлап йөдәтте. Аш араларында миңа әллә нинди полктагы хикәяләрне сөйләде. Пашаны тутакай, теге марҗага кавалер иттереп, өстәл артына гына, почмакка гына урынлаштырган иде. Мин аны рәтләп күрә дә алмый идем. Сүзен дә ишетә алмый идем, ләкин теге марҗаның чыр-чыр сөйләүләре, кайвакыт кылынгачланып көлүләре генә ишетелеп, эчне пошыра иде. Картлар эчештергәләделәр, минем күршем дә мине сыйлап-сыйлап җибәргәләде. Мин дә, аз гына капкаласам да, йомшабрак киттем... Аштан соң картлар, ликёрлар берлә бүлмәләргә кереп, карта уйнарга керештеләр. Яшьләр бакчага йөрергә чыгып таралды. Тутакай, мине чакырган булып, әллә ниләр сөйләп тотты. Паша янына теге марҗа килеп култыклап алгач кына, ул, яңа әфисәрне чакырып китереп, әллә нинди йомышлар кушкан булып: «Йөрергә чыгасызмыни?» — дип, безне парлаштырып чыгарып җибәрде.

Төн тын иде, күк айлы-йолдызлы иде. Чәчәк, үлән исе тирәюньне аңкыткан иде... Әллә нинди йомшак бер җылылык бөтен тамырлардан йөри, акыртын гына исә торган җылы җил, яңадан-яңа хуш исләр китереп, битне-чәчне сыйпый иде, сөя иде... Яңа әфисәрем, бераз кызып алгач, бертуктамаенча, анекдот артыннан анекдот сөйли иде. Бакчаның теге почмагында чырлый торган теге марҗа кычкырып-кычкырып әллә нинди әмерләр бирә иде. Еракта гына мәче башлы ябалак ямьсез тавыш берлә кычкырып күңелгә тынычсызлык бирә, курку сала иде... Бакчаны без бер әйләнә идек, ике әйләнә идек... Керергә вакыт җитсә дә, мин, Пашаны очратырмыз дип, кавалерымның тәмсез сүзләреннән көлгән булып, һаман йөри идем. Менә без өйгә таба борылдык. Ишек төбенә барып җиттек, өйдәге лампадан багана кебек сузылып чыккан ут яктысында бердән Пашам килеп басты. Төнге якты берләндерме — аның йөзе саргылт иде, күзләре тирәнәйгән, эченә әллә нәрсә яшергән кебек караңгыланган иде. Йөзенә әллә нинди бер аңламаслык төс, сыкрану төсе чыккан иде. Бүген без бер сүз дә әйтешә алмаганга, мин: «Нихәл, исәнмесез?» — дип,

татарчалап сөйли башладым. Әфисәрем, гафу үтенеп, өйгә кереп китте. Без бер-ике сүз әйтешергә, күңелдәге төеннәрне әйтергә өлгермәдек, тутакай ут кебек чыгып җитте. «Әйдә, сине көтәләр, Гөлсем, өй хуҗасына шулай ярыймыни?» — дип, җилтерәтеп алып кереп китте. Кич берлә музыка уйналды, танец булды, яңа кунаклар бик шәп танцевать иттеләр. Мин дә әле берсе берлә, әле берсе берлә бии-бии арып беттем. Паша почмакта ялгыз утырды да тик калды. Ул карта уйный торганнар арасына да керә алмады, биючеләр янында да катыша алмады. Ликёр эчеп-эчеп гайбәткә чума торган хатыннар да урын була алмады, ялгыз калды, ялгызлыкка батты. Ул йөзеннән дә, күзеннән дә үзенең ялгызлык хисен яшерә алмады. Арып бетеп ятарга аерылганда, бөтен яңа кунаклар минем кулымны үбеп күрешкәндә, ул ялгыз гына, үпмәенчә: «Хәерле кичләр!» — дип югалды. Бик арыганга, аз-маз шәраб, ликёр эчештергәләгәнгә, бик начар йокладым.

Иртә тору берлә без, ашамак-эчмәкләр төяп, дүрт-биш атка төялеп, су буенча хозурга киттек. Әти, кода, тутакай бер атталар иде, мин, яшь әфисәр, бер кечкенә бала икенчедә идек. Башка хатыннар, вак-төяк кунаклар өченче, дүртенчеләрдә иде. Юлда арбалар әле берсе үтеп, әле берсе узышып, уйнашып баралар иде. Ләкин Пашаларның арбасы гына һаман артта иде. Карт ат берлә, ул һаман үз юлында лырт-лырт йөгертеп килә иде. Егетнең мыскыл ителүе өчен, күңелем бик борчыла иде. Эчем поша иде. Ләкин каты итеп аны яклап катышырга минем көчем җитми иде. Тирә-юньдәге гадәт, өемездәге тутакайның башлыгы, әтинең өй эшләренә бик йомшак булуы, Паша берлә минем арадагы мөнәсәбәтнең ачылып бетмәгәнлеге мине кулым-аягым бәйләнгән кебек тота иде. Менә елганың борылып ага торган бер җирендә атлар туктады. Хәтфә төсле яшел чирәм өстенә мәҗлес корылды, зур иттереп, ут ягылды. Самавырлар куелды. Ашау-эчү китте. Сыйлану башланды. Ирләр, хатыннар урманнарга, болыннарга чәчәк җыярга, йөрергә таралдылар. Мин берничә мәртәбә Паша берлә берләшеп сөйләшеп китәргә теләсәм дә, әле тутакай, килеп чыгып, мине алып киткәнгә, әле бер яңа хатын, килеп, берәр йомыш берлә сүзгә катнашканга, әле теге марҗа егетне, җилтерәтеп өстерәп, анда-монда тарткалаганга, бер минут вакыт бергә була алмадык, көн буе мин яңа әфисәрем берлә калдым. Көн буе хуҗа кыз булып әле бер кунакның күңеле өчен, әле бер хатынның мәгънәсез сүзе өчен Паша берлә сөйләшергә биш минут вакытымны бүлә алмадым.

Халык бик күп булганга, баш тегермән кебек әйләнгәнгә, вакыт үткәне сизелми дә калды. Ирләр коеныга киткәндә, без кызулап аш урыны әзерләдек. Алар ликёр эчәргә утырганда, без коенырга киттек, күрше алпавытлар килгәч, тагы шәпләп чәй эчеп, көн үткәнне, кич булганны тоймый да калдык. Ай

яктысында судан килә торган йомшак салкынча астында без бик озак куыш-куыш уйнадык. Әллә нинди уеннар берлә эштән чыктык, биедек, танцевать иттек, бергәләп, аерым-аерым җырладык. Яңа әфисәр берлә бер кунак хатын лезгинга да биеделәр. Соңгы төндә генә, арбаларга төялешеп өйгә таба борылгач кына, мин әллә нинди авыр бер хискә баттым. Әллә нинди үзем дә сизеп бетермәгән бер начарлыкны эшләгән кебек, күңелемнән сыкрана башладым. Арыган башым рәтләп эшләп бетерә алмаса да, ни булдыгы хакында ачык хисап бирә алмаса да, күңелемнең бер җирен әллә нәрсә кырды, бәгъремнең бер почмагы әллә ни өчендер көенде, еглады. Яньмдагы әфисәрем әллә ниләр сөйләсә дә, рәтләп тыңламаенча гына, өйгә кайтып җиттек.

Халык бик күп булганга, тавыш-туыш зур булганга, мин, әллә нинди бер белмәгән нәрсә тарафыннан басылганымны хис иткәнгә, рәтләп көрешмәенчә дә, үз бүлмәмә кереп яттым. Урынга сузылып, уйларымны бер җепкә тезгәч кенә, бүген тагы Паша берлә бер сүз сөйләмәвемне, аның берлә кич күрешмәенчә дә керүемне хәтерләдем, кайгырдым. Аңарга каршы ясала торган шул бойкотта мине дә бергә дигән фикердә булмадымы икән, дип уйладым. Юктыр, дидем. Бардыр, дидем, иртәгә үзе берлә сөйләшергә булып, мәсьәләне хәл итмәкче булып, борылып яттым. Өй дә зур умарта кебек уылдады, гөрләде. Бик озактан соң ул да тынды. Мин, әллә ничә мәртәбә йокыга китә башласам да, тагы куркынып уяндым, тагы төрелеп яттым. Тагы өн берлә төн арасында чуалдым. Ахырдан тирләп-пешеп, башым янып, сикереп тордым. Пәрдәне тартып, тәрәзәне ачтым. Бәрәкәтле кул берлә ташланган айның яктысы бүлмәмне тутырды. Күзне кытыклады, тыштан кергән салкынча һава, тамырлардан йөгереп, мине калтыратты.

Мин өстемә киеп айны, айның нуры берлә челтәрләнеп ага торган аклы-сорылы болытларны карарга, тик, тын тора торган агачларны сәер итәргә тотындым... Балалыгым күз алдыма килде... Беренче сәхәр тагы искә төште. Моннан бер генә атна элекке тынлыгым, тынычлыгым күздән үтте. Бүгенге күңелемдәге үземнән разый түгеллегем, бүгенге көндәге бәгырьнең әллә нинди тетенсез, утсыз ут берлә януы алга басты. Ни булды, нинди үзгәрү булды, мин ни эшләдем? Уй китте, уй артыннан уй китте. Мин үз тирә-юнемдәге шул якыннарымны, шул кодаларны, шул кунакларны җентекләдем. Аларның табигатьләрен, йөрешләрен, кыланышларын тикшердем. Шуларның бер әгъзасы иттереп куйгач та, тәмәке тарта торган кешеләр белән шыгрым тулган, бизәнгән, буянган хатыннарның тәмсез сүзләре берлә «у-у» килгән, тәрәзәсе ябык, ишеге юк дүртенче класслың вагонындагы кебек үземне хис иттем... Йөрәгем жу итте, тәнем калтырады, күңелем сыкрады, ишекнең юклыгы, бу сасыдан,

бу былчырактан чыгарга, котылырга юлның юклыгы минем котымны алды. Мин көчсез, ярым һушсыз көенчә урындыгыма сузылдым. Ай мине коендырды. Акрын гына искән җил агач башларын, берсенә берсен бәрештереп, моң гына тавышландырды. Еракта гына мәче башлы ябалак кычкырды да кычкырды. Мин куркудан аякка калыктым. Әллә ни эзләгән кебек, күземне бакчага тектем. Агачлар арасында әллә нинди бер шәүлә акрын гына селкенә кебек булды. Шул тынлык, шул ялгызлык эчендә шул шәүләне табуыма сөенгән кебек булдым. Шул шәүлә генә мине шул авырлыктан коткара кебек булды. Мин шуны күрергә зур өмет белән шәүләнең якынаюын көтәргә керештем. Менә ай яктысы берлә тулган яланга шәүләм чыкты. Ни күзем берлә күрим, Паша!.. Туктады, бик озак бер ноктага таба карады. Бәлки, айга карагандыр, бәлки, йолдызларны сәер иткәндер, ләкин ул вакыт ул минем тәрәзәмә карый кебек булды... Мин тәрәзәдән башымны тыктым. Паша калтырап китте. Акыртын гына: «Сезме?» — дидем. «Әйе»,— диде. Ни эшләгәнемне белмәенчә: «Хәзер чыгам!» — дидем дә, өстемә шәл салдым да, туфли берлә генә чыктым да киттем.

Паша тетри, калтырый, тешләре шак-шок килә иде, үзе каткан кебек тик тора иде. Кулы суп-суык иде. Бу авырлыктан чыгар өчен: «Ник йокламыйсыз?» — дидем. «Сез ник?» — диде. «Мин бик арыганмын, халык бик күп булды, баш бик чуалды, фәлән»,— дидем. Акыртынлап сөйли-сөйли, беседка артындагы бөтен кешеләрдән яфраклар белән капланган үземезнең сөйгән урынымызга кереп утырдык. Минем күңелем тулган булгангамы: «Сез гафу итегез, бу эштә минем гаебем юк»,— дияргә булдыра алмадым. Бернәрсә дә булмаган кебек, бер җитди эш тә юк кебек күренергә тырыштым. Паша чыдый алмады: «Мин, туташ, сезне өч көннән бирле күрә алмадым, сөйли дә алмыйм... Ләкин шул өч көн эчендә мин бик күп нәрсә күрдем, бик күп нәрсәгә күзем ачылды. Бик күптөрле карарлар да ясадым. Ләкин берсен дә эшкә куя алмадым. (...) Кечкенә генә туган өметләр мине биләде, минем аягым-кулымны баглады. Мыскыл өстенә мыскылны күтәрергә мәҗбүр итте. Башымны игәннән-иргә әмер бирде. Сезнең мондалыгыңыз, микънатис ташы кеби, мине тартты, тотты. Канаты көячәк булса да, утка чаба торган күбәләк кебек, мине дә шул ут тирәсендә әйләнергә кушты. Ни эшлим, туташ, шулай булды... Ләкин боларның барысын да, туташ, мин сездән бер күз каравы алыр өчен, сездән бер елмаю күрер өчен эшләдем... Бәлки, бу яңа кунаклар килмәсә, мондагы яңа планнарны белмәсәм, мин элекке кебек сезне хөрмәт итеп, сезне эчтән бик зур күреп, киләчәктәге көрәшүләргә ышанып китеп тә барыр идем. Ләкин хәзер китә алмадым. Китә алмыйм. Мин шул өч төндә һич йокламадым. Мин бик күп сыкрадым,

бик күп газапландым. Мин сезне шулкадәр тирән сөю берлә сөйгәнемне аңладым. Миңа сездән башка тормыш юк»,— диде. Мин аптырадым. Бер сүз әйтә алмадым, ләм-мим дип җавап бирә алмадым. Күңелемнән шуны көтсәм дә, бу кадәр дары кебек бердән шартлар дип уйламаган идем. «Шулай булгач, мин никадәр хурлыклар күрсәм дә, ничек сезне шул баткаклык эчендә, шул сазлык эчендә калдырып китим... Сезгә каршы корылган шулкадәр ямьсез планнарны күрә торып, мин сезне ничек ялгыз ташлыйм! Бу минем көчемнең читендә... Сез, туташ,— сазлыкта үскән бер гөл. Тирә-юнегез баткаклык, эчкәнегез сазлык суы, сулаган һаваңыз черегән сазлык һавасы, монда гөлгә үсәргә, гөл булып яшәргә имкян[1] юк. Бу тирә-юньдә сез бетәчәксез, сез дә, башкалар кебек, сазлыкка батачаксыз. Сезне бу сазлыктан алсаң гына, сез мәңгегә гөл булып кала беләчәксез... Чыгыңыз моннан... Чыгыйк моннан, сарылыңыз минем кулыма, туташ»,— диде... Мин: «Алай ук түгел, сезнең хыялыңыз бик зур, фәлән»,— дидем. Ул ишеткән, күргәннәрен сөйләде. Иртәгә йә берсекөнгә мине теге әфисәргә рәсмән сораячакларын, әтинең разыйлыгын, тутакайның шуны булдыру өчен көчен сарыф итүен — һәммәсен аңлатты. Мин, үзем дә күңелемнән шуларны сизенеп торсам да, әллә нинди җепләр белән шул йортка, шул кардәш-кабиләгә, шундагы гореф-гадәткә бәйләнгән булганга, Пашаның чын күңеленнән чыккан сүзләренә: «Ярый инде»,— дип җавап бирә алмадым. Икеләнебрәк: «Әле сөйләшермез, фәлән»,— дидем. Мәсьәләне озайттым.

Шул араны аяк тавышы ишетелде, акрын гына сөйләнгән сүзләр колакка бәрелде. Без тындык, аларның сүзләрен ишетер өчен түгел, үземезне сиздермәс өчен тындык. Аяклар павильонга кереп утырдылар. Акрынлап тагы сүзләрендә дәвам иттеләр. Сөйләүчеләр тутакай берлә кода иде. Коданың сүзләрен ишетеп бетереп булмаса да, тутакай, ачык тавыш берлә: «Минем сүзем сүз, мин кызның вәгъдәсен алдым, аны сөйләп тору да уңайсыз... Ләкин шуны онытма... Мин бит тол, электән полковник хатыны, мин аена шул илле тәңкәлек пенсиягә тора алмыйм. Тора алмыйм... Менә кияү дә, син дә кул куеп, 40 мең тәңкәлек вексель бирсәңез, туйны эшлим... Юк булса, мин үземне бушлайга урамга ыргыттырыр хәлем юк... Гөлсем кияүгә чыккач, мин кем?.. Юк!» — диде. Кода тагы әллә нәрсә сөйләде, тутакай: «Әйтәм бит, ул — авыру, безнең Гали — авыру (ул минем этием хакында иде), йөрәк авыруы берлә авыру, бүген ярты рюмка артык эчте исә, иртәгә юк... Мин аңарга ышана алмыйм. Шул вексельне бирсәңез, иртәгә — бетте»,— диде. Паша минем күземә карады, мин агардым, бүртендем. Чыгып: «Мине сатарга

---

[1] *Имкян* — мөмкинлек.

телисезме, мине үз акчама сатарга телисезмени?» — дип кычкырасым килде. Булдыра алмадым, аягым калтырады, тешләрем шак-шок бәрелде. Тегендә базарлык бетте. Килештеләр. Акрын гына сөйли-сөйли киттеләр. Мине Паша кызганды булырга кирәк, җәрәхәтемә тоз сибәчәк бер сүз дә әйтмәде, яңа җәрәхәтемә зәһәр салмады. Мин тордым, ул акрын гына җиреннән калыкты. Бер сүз дәшмәенчә, бакчаны үттек, яланга чыгар алдыннан ни булса да бер сүз әйтеп аерылырга кирәк дип уйлап торганда, теге сарыпсыз марҗаның бүлмәсендә ут алынды. Анда нечкә пәрдә ашасыннан теге яңа әфисәр берлә теге марҗаның башлары күренде. Кыяфәтләре, кием-салымнары кемне дә оялтырлык булганга, мин яшен суккан кебек булып киттем, дерелдәдем, калтырадым, егылмас өчен, бер агачка сөялдем. Паша мине бик озак сөзде, бераздан: «Аңладыңызмы? Бу сазлык сезнең җир түгел. Аңлаңыз, туташ! Сезгә башка һава кирәк, әйдәгез!» — диде. Минем кулымны тарткан кебек каты кысты. Минем бөтен тәнемнән суык йөгергәнгә, дерелдәп, моңланып күзенә карадым. Бик озактан соң: «Минем башым хәзер эшләми, иртәгә сөйләшермез. Иртәгә»,— дидем. Өйгә чабып кереп киттем. Ул баскан урынында катып калды.

Мине моңаргача һичбер булмаган яңа бер хис биләде. Мин хурландым. Үз-үземне сарык кебек сатарга теләүләренә хурландым. Җирәндем, үз-үземнең шул былчыраклар арасында булуымнан җирәндем. Мин яндым, көендем, үз-үземнең шул батканлыкны ташлап китәргә көчем юклыгыннан яндым. Шул тирә-юнемне чормалаган былчырак бака күлмәкләреннән арынып китәргә куәтем юкка яндым, көйдем... Бер яктан тутакайның «40 меңлек вексель бирегез!» дигән сүзләре колагымда чыңлады. Тәрәзәдә күргән теге сарыпсыз марҗа белән теге әфисәрнең кыланышлары күз алдымда уйнады. Чын күңеленнән моңланып әйткән Пашаның өметле тавышлары, рәхмәт фәрештәсе суры[1] кебек, минем җәрәхәтле бәгыремне сылады, сыйпады, иркәләде. Күземнән, актарылып, яшь агарга тотынды. Тавышланып, тавышсыз бик озак елладым. Күңелем басылган кебек булып тагын яттым, тагы ямьсез фикерләр мине чолгады, тагы елладым, тагы киенеп чыгып, бакчада Пашаны эзләмәкче булдым. Тагы ишек төбенә баргач, бусаганы атларга көчем җитмәде. Тагы чишендем, тагы яттым. Тагы көйдем, тагы яндым, тагы елладым. Иртә булды. Кояш чыкты. Кошлар сайрарга тотынды, умарта кортлары безелдәргә керешге. Минем керфегем керфеккә тимәде. Еглый-еглый кызарып беткән күзләремне күрсәтмәс өчен, үземнең эчемдәге яна торган ялкынсыз утны күрсәтмәс өчен, суык сулар берлә юындым. Күзләремә

---

[1] *Сур* — быргы.

сөрмәләр тарттым, киендем, ясандым... Йөземә көләчлек бирмәкче булдым. Ләкин, көзгегә барып карагач та, үземнең сары йөземне, уелып, тирәнәеп киткән өметсез күзләремне күрдем дә тагы ихтыярсыз яшькә баттым. Әллә кемгә барып серемне сөйлисем килде, әллә кемнең муенына асылынып кайгымны аңлатасым, хәсрәтемне чишәсем килде. Әллә нинди мине бик аңлый торган кешегә бөтен кайгымны түгәсем килде. Күз алдыма үләр алдындагы анам килеп басты. Аның моңлы күзләре миңа карый кебек, айый[1] кебек булды. Күземнән ятимлек яше тәгәрәде. (...)

Ишек шакылдады. Кызгылт кофта кигән, чәчләрен бөдрәләтеп тараган тутакай килеп керде. Аның берлә әллә нинди ислемай, пудра исләре бүлмәне тутырды. Мин аның йөзенә куркынган кеше кебек карадым. Ул миңа шулвакытта зур шәһәрләрдә кызлар тотучы юан, симез яһүд хатыны кебек күренде. Җирәнгеч бер хис уятты. «Әйдә, кунаклар тордылар. Тиз бул! Бөтен халык сине чәйгә көтә!» — диде. Минем күлмәгемнең якаларын рәтләгән кебек булды. «Чык моннан, кит, йөзең кара!» — диясем килсә дә әйтә алмадым. Көчсезләндем. Изрәдем. «Ярый, хәзер»,— дидем. Йөзләремне тагы бер мәртәбә одеколон берлә сөртеп, акрын гына аш бүлмәсенә төштем. Ду килгән кунаклар, бар да аягүрә торып, миңа юл бирделәр. Теге эфисәрем, килеп, кулымны чуп иттереп үпте. Аның авызыннан кулыма әллә нинди бер былчырак селәгәй ябышып калды кебек булды. Паша калтыраган кулы берлә кулымны кысты. Күземнең эченә карады. Беркем дә бер сүз дә дәшмәенчә, берәр чынаяк чәй эчтек. Эфисәр миңа әллә ниләр сөйләсә дә тыңламадым. Тутакай әллә нинди көлкеләр берлә миңа мөрәҗәгать итсә дә җавап бирмәдем.

Чәйдән соң мине эти бүлмәсенә алып керделәр. Анда тутакай селкенә торган урындыкка утырган да, тибрәнеп-салланып, әллә ни сөйли иде. Мине күрү берлә, эти, көлеп: «Нишләп торасың, Гөлсем!» — дип сүз башлады. Үзе әллә ни әйтергә теләсә дә, сүзе чыгып җитмәде. Аңарга ярдәмгә тутакай җитеште. Көлепкөлеп сүзгә керешге. Ул, нигәдер, тугрыдан-тугры әйтеп бетерә алмаенча, каен энесен, теге эфисәрне бик мактады. Сүзен очлап бетерә алмады, ишек шакылды. Аннан яңа гаскәри киемнәрдә кода берлә теге эфисәр килеп керделәр. Кода, керер-кермәс, урысчалап: «Мине гафу итегез, менә бу егет кызлар тәрбияле, оялчан, эченнән янса-көйсә дә, үз хисен әйтергә батырлык итә алмый»,— диде. Теге эфисәр дә, команда иткән солдат кебек, бик тиз килде дә минем алдыма тезләнде, русчалап: «Мине бәхетсезлеккә салмагыз, колыгыз булырга рөхсәт итегез!» — диде дә минем кулымны үпте. Мин аптырадым. Бер сүз әйтә алмадым. Тутакай мине шул уңайсызлыктан чыгарыр өчен

[1] *Айый* — кызгана.

кебек: «Сез аны оялттыңыз, ул бит әле яшь кыз, әнә күрәмсез, йөзенә кызыллык йөгерде, ул инде разыйлык галәмәте... Алла сезгә мәхәббәт бирсен»,— диде. Мин күземне ачтым, башымны күтәрдем, үземнең сатылганымны ныграк сиздем, дерелдәдем, калтырадым. Каушаган тавыш берлә русчалап: «Гафу итәсез, мин һичбер вакыт сезнең хатыныңыз булачак түгелмен, һичбер вакыт!» — дидем. Күземә яшь тыгылганны хис иттем дә сикереп тордым. Әллә ни оныттым кебек булдым. Тагы борылып, кечерәеп калган этине, кызарып-бүртенгән тутакайны, пәҗегән шалкан кебек булган коданы, нишләргә белми торган яшь әфисәрне сөздем дә, кычкырып: «Һичбер вакытта!» — дидем дә, ашыгып чыгып үз бүлмәмә кереп бикләндем.

Түбәндә тавыш купты. Анда чаптылар, монда чаптылар, кычкырдылар, бакырдылар, минем ишекне килеп кактылар. Берсенә дә җавап бирмәдем. Яттым, егладым-егладым да яттым. Башым янды. Тәнемне суык алды. Калтырадым, өшедем, кайнарландым, тирләдем, пештем. Калкынган кебек булдым, йоклаган кебек булдым, ишекне тагы шакыдылар, ачмадым. Тагы шакыдылар, урынымнан кыймылдамадым... Менә колагыма кыңгырау тавышлары керде. Әллә нинди тавыш ишеткән кебек күземне ачтым. Тәрәзәгә бардым. Бер начар гына чуваш аты җиккән авыл тарантасына Паша менеп килә иде. Минем йөрәгем жу итте. Китә дип, актык өметем югала дип котым очты. Өстемә шәлне салдым. «Китмә, китмә, кал!» — дип чыгып асылыначак булдым. Ишекне ачтым. Ләкин тагы бусаганы үтә алмадым. Аягым калтырады, йөрәгем типте. Тәрәзәгә килеп, ичмасам: «Хуш!» — диясем килде. Авызымнан сүз чыкмады. Паша минем тәрәзәмә борылып карады да, чуваш аты кузгалды. Мин хәлсезләнеп егылдым. Тагы шакыдылар. Тагы кыңгырау тавышлары ишетелде. Мин өн белән төн арасында саташырсаташмас бикләнеп калдым.

Икенче көнне юынып чәйгә төшкәндә, бездә бер кунак та калмаган иде. Тутакай картайган, изрәгән, ләпшерәгән иде. Әти тәссезләнгән, күңелсезләнгән иде. Без, бер сүз сөйләшмәенчә, көнне үткәрдек, кичкә таба әти: «Мин Петербургка барам, иртәгә әзерләнеЗ»,— диде. Мин дә, тутакай берлә каласым килмәгәнгә: «Әти, мин дә синнән калмыйм»,— дидем. «Алай булгач, мин ник калыйм, буе җиткән кызны ялгыз җибәрергә ярыймыни, әле нилəр булганны күрмәдеңмени?» — дип, тутакай карышты. Мин бер сүз дәшмәенчә тыңладым да, тордым да чыктым. Икенче көнне, вакыт килмәгән булса да, без, барымыз җыенып, тирә-күрше боярлар белән күрешмәенчә дә, Петербургка киттек. Киткән чакта гына, хезмәтче кыз: «Туташ, теге чарлакта торган егет, сезгә бирергә дип, бер хат биргән иде. Тутакай кулымнан тартып алды»,— диде. Мин: «Шул көнне ни булды соң?» — дип

сорадым. «Сөйләмә инде, мондый мәсхәрәне минем гомеремдә дә күргәнем юк иде»,— дип сөйләргә тотынган иде, тутакай килеп тагы сүзне бүлдерде.

Мин Петербургта Пашадан хат булмый булмас дип көтә башладым. Бер атна көттем, ике атна көттем, ай көттем, һичбер хәбәр булмады. Көз килеп уку башлангач, аны сораштым, Петербургтан күчеп киткән, диделәр. «Кая соң?» — дииюемә, кайсылары Мәскәүгә, кайсылары Киевка диделәр. Шулай итеп, Паша югалды. Аның берлә бергә минем өметем дә югалды. Менә моң гына кыш үтеп килгәндә, әти читтә юлда чакта иртә берлә телеграм килеп төшмәсенме! Ни күзем берлә күрим, телеграмны әллә нинди бер стансадан станса начальнигы бирә. «Әтиеңез поезда үлгән табылды. Тиз килеңез, фәлән поезда» дигән хәбәр миңа шулкадәр авыр тәэсир итте, һушымны югалттым.

Мин күземне ачканда, әти инде өйгә китереп салынган. Аның баш очында мулла Коръән укып тора иде. Мин җансыз шәүлә кебек бүлмәдән бүлмәгә йөрдем, һичбер нәрсә аңламаенча, һичбер нәрсәгә күңел куя алмаенча йөдәдем, йончыдым. Әллә кемнәр килде, әллә ниләр сөйләде, берсен дә тыңламадым. Менә төн үтте. Озын караңгы төн үтте.

Гәзитә китерделәр. Минем берлә тутакай исеменнән әтинең үлүе, җеназасы хакында бирелгән матәм игъланы янына, зур хәрефләр берлә: «Надежда Ивановна кадерле ире, балалары Коля, Лёля кадерле әтиләре үлүен игълан итәләр, фәлән мәчет йортында җеназа укылачагын белдерәләр»,— дип, икенче игълан басылган иде. Бу хәбәр мине кайнарлатты, өшетте, суытты, еглатты, газаплатты, мыскыл итте. Җеназа вакытында, чынлап та, җеназа артына кара кием кигән юан гына, карт кына бер марҗа ике бала берлә безнең янда урын тотты. Әллә нинди без танымаган урыслар, марҗалар аңарга килеп тәгъзия итте[1], ул еглаган тавыш берлә әллә нинди җаваплар бирде. Ул булмады, мирас хакында суд китте. Мин әтинең бер генә баласы булганга, бөтен дәүләт миңа калырга тиеш иде. Теге хатын мәхкәмәгә[2] бирде, мине судка чакырдылар. Ике балалы хатын мәхкәмәдә, әллә нинди тәмсез сүзләр сөйләп, әтинең исемен былчыратты. Мин хурландым, еглап җибәрдем. Шуны күреп, теге марҗаның ике баласы да еглады. Шул күз яше арасында, чынлап та, болар минем сеңелләрем, энеләрем түгелме икән дигән сөаль башыма килеп басты. Мәхкәмә минем файдама хөкем итте. Ләкин эчемнән мин шул эштә хаклылыгыма ышанып җитә алмаганга, эчем пошып калды. Теге марҗа бик тәмсез телле пычрак марҗа булганга, үзе бик алдакчы булганга, аның берлә сөйләшеп, мин хакыйкатьне аңлый алмадым.

---

[1] *Тәгъзия итү* — юату.

[2] *Мәхкәмә* — суд, хөкем йорты.

Шул авыр кайгылар астында изелгәндә, минем өметем һаман теге Пашада иде. Әтинең үлүе мәхкәмәләре гәзитәләрдә язылганга, ул аларны укыячак, миңа, кечкенә генә булса да, бер тәгъзия язачак дип ышана идем. Ләкин бу өметем дә бушка чыкты. Мин тиздән тормыштан туеп, тутакайдан арып, әтинең ерак бер кардәше тутакайга Уфа губернасында кыш үткәрергә киттем... Анда бераз тындым, башымны җыйдым. Дөньяда үз башыма үзем генә калганны хис итеп, ялгызлыкка чумдым, аннан да арыдым. Нишләргә белми аптырап торганда, бер җәй көнендә хәзерге иремне очраттым. Ул миңа ул вакыт бик йомшак кылынды. Минем кайгыларым өчен бик хәсрәтләнгән кебек булды. Сүзләремне бик ихлас берлә тыңлады. Озак үтмәде, шулай иттереп, минем ышанычымны казанды. Көннәрнең берендә бу минем кулымны да сорады. Күңелемдә аңарга карата һичбер хис булмаса да, ялгызлыкка бик туйганга, тутакай янына барып тагы бергә торудан курыкканга разый булдым. Туй ясадык, өйләндек... Ләкин бал атналарымыз үтмәде, мин иремнең лаякыл исерек икәнен белдем. Мин үземнең бер тәмугтан икенче тәмугка күчкәнемне сиздем. Менә инде ун ел шул тормышны өстерим. Кайчанга кадәр тартырмын, анысын да белгән юк»,— диде. Аның күзләренә яшь тыгылды, ул тавышланыр-тавышланмас елый башлады.

Нәфисә: «Юк, иншалла, рәтләнер әле»,— кебек сүзләр сөйләде, юатты, ләкин Гөлсем яшь арасыннан: «Хәзер ни булсын инде, яшьлек харап булды, көч бетте, дәүләт бетте. Калган нәрсә менә шулар»,— дип, балаларына күрсәтте. «Болардан да ни чыгачак, алкоголик балалары бит»,— диде... Тагы үксеп-үксеп еларга кереште. Нәфисә су салып эчерде. Тагы юатты. Тагы өметле сүзләр сөйләде. Нәфисә, ахырдан гына: «Мин шунысына гаҗәпкә калам: ник соң ул егет тагы бер хат язмаган, ник соң ул тагы бер мәртәбә ничек булса да сезне күрергә тырышмаган?» — диде. Әллә нинди бер кадерле нәрсәсе мыскыл ителгән кебек, Гөлсем сикереп торды: «Язган ул! Бик күп мәртәбә язган. Мин кияүгә чыккач, моннан дүрт-биш ел элек, безнең уртак танышымызга — ул вакыттагы бер курсисткага очрадым, шул аңлатты. Ул хат язган, ләкин мин берсен дә алмадым. Миннән җавап булмагач, ул, бәлки, мине дә үзенә каршы кампаниядә бергәдер, уртактыр дигән фикергә килгәндер. Килерлек тә бит инде... Тагы бәхетсезлек инде. Минем бәхетсезлегем»,— диде дә тагы елавында дәвам итте. (...)

* * *

Иртә торганда, күк йөзе зөмрә кебек зәңгәрләнгән, болытлар, яланнар яшәргән, урманнар сарылы-яшелле кушымталы бер төс алганнар иде. Идел дә, бик күп язларны, бик күп көзләрне күргән Идел дә, йомшак нурлы кояшка каршы, күп агудан

арыган кебек, моңланып, сузылып яткан иде. Пароход тирәсен чолгап алган акчарлаклар да җылы матур һавага, тышка тулган халык берлә туктамаенча сөйләшеп-кычкырышып баралар иде. Киләчәктәге пристаньга төшәргә булганга, Нәфисәләр, Гөлсемнәр дә, балаларын киендереп, әйберләрен әзерләп, ерактан күренгән пристаньны көтәргә тотынганнар иде. Пароходта иттифакый[1] туры килгән ике хатын, озын бер караңгы төнне бергә үткәреп, әллә ничек сүзгә кереп китеп, берсенә берсе йөрәкләрен, йөрәкләренең эчендә җиде йозак берлә бикләнгән почмакларындагы серләрен түгеп салышканга, иске белешләр кебек, мәктәп аркадашлары кебек дуслашканнар иде, берсенә берсе кардәшчә, туганча бер хис биләшкәннәр иде.

Менә, озын иттереп, моң иттереп, тагы пароход кычкыртты. Нәфисәнең балалары, әниләрен чолгап алып: «Әни, әтигә килдек, әтигә!» — дип сөенешә, сикерешә башладылар. Гөлсемнең балалары да, әллә нинди зур бер куркыныч бүкәйне көткән кебек, әниләре янына килеп: «Әни! Әти юкмы? Әти булмасын иде!» — дип, аңарга катыдан-каты сарыла башладылар. Пароход, бии торган куштан кызның әйләнүе кебек матурлап борылып, пристаньга якынайды. Гөлсем дә, Нәфисә дә пристаньга таба күзләрен тектеләр, икесе дә шуннан көтә торган ноктaларын — берсе үзенә бу кадәр бәхет биргән, тынычлык, дуслык багышлаган, аерылуына еллар үткән кебек сагынган ирен, әтиләрен; икенчесе яшьлеген харап иткән, кыска гына гомерендә аны яшьли картайткан, карчык иткән үзенең кара язмышын, үзенең бәласен эзли иде. Татлы көтү, матур өмет берсенең күзенә йомшак кына, җылы гына елмаю куйды. Курку, кот очу, өметсезлек, көзән җыерган кешедәге кебек, икенчесенең йөзенә бер җәберләнү, көчәнү, җирәнү төсен бирде. Нәфисәнең балалары беренче булып әтиләрен таныдылар, алар: «Әти, әти!» — дип кычкыра башладылар. Нәфисә яулык селкеде. Пристаньнан тагы яулык селкү җавабын алды. Ерактан гына күзләр күзгә очраштылар. Теге беренче мәртәбә театрда очрашкан тәм белән очраштылар. Алар икесе дә елмаештылар. Бик мәгънәле елмаештылар.

Шуның берлә мәшгуль булганда, Нәфисә Гөлсемне дә онытты. Ләкин пристаньдагы ярты гаскәри киемдәге бер кешенең исерек көенчә әле күпернең бер ягына барып бәрелүен, әле бер яктагы бөккән, калач, алма сата торган марҗаны барып кочакларга теләвен күреп, чыдый алмаенча, шаркылдап көлеп җибәрде. Теге пристаньдагы кеше һаман әллә ниләр кычкырып, төрле кешеләргә бәйләнеп йөргәнгә, алар да аны һич шәфкатьсез бәреп, төртеп, туп кебек, күпернең бер ягыннан бер ягына, бер юан марҗадан икенче марҗага төртеп йөрткәнгә, бу кәмитне

[1] *Иттифакый* — очраклы.

бүлешер өчен, күршесенә: «Гөлсем ханым, Гөлсем ханым! Кара әле, зинһар, шул тилене»,— дип, көлүенә чыдый алмаенча, аңа борылды. Аның йөзе үләргә әзерләнгән кебек ап-ак, иреннәре зәңгәр, күзе курку, өметсезлеккә баткан дип тапканга, Нәфисәнең көлүе яртысындаябылды. Ул, аптырап, кызганып, Гөлсемне сөзде. Гөлсем дә, тагы сүзгә керешмәс өченме, калтырана-калтырана борылып китте. Әйберләрен күтәреп, ишеккә таба юнәлде. Нәфисә, пароход өстеннән ире берлә, исәнме-саумы дип, берәр сүз алышып алмаенча китәсе килмәгәнгә, пароходның якынлашуын көтте вә шуның берлә чыгарга соңга калды.

Пристаньга чыга торган халык агымы эченнән хатынын, балаларын көтә торган доктор, һич уйламаганда, көтмәгәндә, Гөлсем берлә кара-каршы килде. Аларның күзләре очрашты. Доктор, бу карчыкны кайда күрдем соң дип, озак уйлап торганның соңында, җимерелгән, кипкән карчыкта ул 18—19 яшьлек, күбәләк кебек оча торган Гөлсемнең, үзе бер вакытларны бөтен хәятен фида[1] итәргә йөргән Гөлсемнең шәүләсен күрде. Бу минутта аның күз алдыннан үзләренең бөтен үткән вакыйгалары үтте. Ике кулында ике баласы барлыгын күреп торса да, ул: «Гөлсем туташ, сезмени?» — дип, кулын сузды. Гөлсемнең боздай суык кулларын кысканның соңында, ул Гөлсемнең көчләнеп көлгәннән чыккан йөзендәге җыерчыкларны күреп аптырады, кызганды, аяды. «Сез һаман мондамыни?» — дип сорашырга тотынды. Сүзләргә җавап булыр-булмас, теге исерек — бер эполеты[2] бөтенләй төшкән, берсе иңсәсенә аткырыйлы итеп эленгән, гаскәри шинельдәге исерек — докторны килеп төртте. Гөлсемнең кулыннан әйберләрен алмакчы булды. Доктор бу исерек, башка марҗаларга бәйләнгән кебек, Гөлсемне мыскыл итәргә тели дип уйлап, аны сакларга маташканга, исерекнең йөзе кызарды. Ул, урысчалап: «Бу минем хатыным, бу минем хатыным!» — дип, тагы докторны төртте, Гөлсем кулыннан төенен алды. Доктор аптырап Гөлсемгә карады. Гөлсем, күзе күзгә очрамасын өчен, башын иде, тизләп култыклап исерек ирен алып китмәкче булды.

Шул ара да булмады, Нәфисәләр килеп чыктылар. Балалар этиләренең муенына сарылдылар. Әллә нинди сөальләр берлә, сүзләр берлә тирә-юньне тутырдылар. Нәфисә, иренең култыгына кереп, тагы бер мәртәбә: «Нихәл, исән тордыңмы?» — дип, бәхетле күзе берлә, ирен сөзде. Кулын кысып алып, алга таба атлый башлады. Күпернең яртысына җиткәндә, тагы тавыш чыкты, теге исерек, Гөлсемнең кулыннан ычкынып китеп, күпернең уртасына килеп, ике аягын җәеп басты. Үзе сәгать теле кебек әле бер якка, әле бер якка селкенеп, үтә торган кешеләргә юл

---

[1] *Фида* — корбан.

[2] *Эполет* — хәрбиләрнең киеменә тагыла торган парад погоны.

бирмәскә маташты. «Туктагыз!» — дип кычкырды. Кычкырып көлә торган, калач сата торган марҗаларга карап: «Понимаете, потомственный почётный дворянин!» — дип, күкрәгенә сукты. Халык аптырап туктап калды. Гөлсемнең балалары еларга тотынды. Үзе тоз кебек эреп югалды. Нәфисә иренең култыгыннан ычкынды да, исерекнең янына барып, аны култыклады. Юлны ачып, алга таба бара башлады. Аңарга татарчалап әллә ниләр сөйләде. Исерек тагы туктап Нәфисәгә гаскәри сәлам бирде, аның кулын үпмәкче булды. Нәфисә аны, каты иттереп тотып, җибәрмәенчә, күпердән алып чыкты. Бердән Гөлсем балалары-ире берлә, Нәфисә балалары-ире берлә докторның аты янында тупландылар. Һәммәсе ни эшләргә белмәенчә аптырап торганда, Нәфисә: «Кая таба барамыз соң?» — диде. «Гөлсем ханымны болай балалары берлә калдырып китәргә ярамый бит!» — дип, иренә мөрәҗәгать итте.

Сөйләшә торгач, боларның борылышка кадәр бергә барачагы мәгълүм булды. Исерек түрәгә Нәфисә берлә бергә барырга карар ителде. Гөлсем: «Рәхмәт, без инде өйрәнгән»,— дип караса да, Нәфисә ирек бирмәде. Бер арбага балалар берлә Гөлсем, доктор утырдылар. Икенче арбага Нәфисә, кочләнгән кебек иттереп, исерекне утыртты. Исерек тагы сикереп төшеп кычкыра, бакыра башлаганга, Гөлсемне бик каты иттереп үз арбасына чакырганга, Нәфисә: «Сезнең берлә мин утырып барасым килә»,— дип, аны үз янына утыртты. Кәрван кузгалды. Беренче арбада балалар бертуктамаенча кычкырып сөйләп барсалар да, Гөлсем дә, доктор да тирән-тирән уйларга, үзләренең үткән гомерләрен, баштан кичкән хәлләрен яңадан күздән кичерүгә чумдылар. Икенче арбада исерек әллә ниләр кычкырды, бакырынды, әллә кемне тиргәде, әллә кемгә ялынды, йодрыгын йомарлап, әллә кемгә янады. Ахырдан ул еларга тотынды. Нәфисәнең кулын үпте. «Сез — алтын кеше, сез — бәхет савыты, ә минем хатыным кем? Ул — чүпрәк, мине харап итте»,— диде дә күзләреннән елгалар кадәр яшь агызып еларга тотынды. Аның елавы куәтләнгәннән-куәтләнде. Ул яшь арасында: «Менә сез миңа очраган булса идегез, ничек дөньяны тетрәткән булыр идек»,— диде... Нәфисә, гомерендә мондый моназарага[1] очраганы булмаганга, ачулану берлә кызгану арасындагы бер хистә буылып калды. (...) Исерек, елмайган кебек авызын ачып, Нәфисәнең тасвир иткән матур манзараларын күргән кебек тыңлады. (...) Озак та үтмәде, ул Нәфисәнең җилкәсенә башын сөяп йокыга да китте. Нәфисәдә элгәре сулавыннан искергән аракы исе аңкый торган кешене төртеп җибәрү хисе уянса да, аны кызгану җиңде. Ул: «Йокласын, мескен»,— дип, үзенә уңайсыз булса да, исерекне кузгатмады.

---

[1] *Моназара* — сүз көрәштерү, бәхәсләшү.

Арбада ялгыз калганга, ире, балалары теге арбада булганга, ул теләр-теләмәс уйга чумды. Теге арбадагы гомерен, яшьлеген харап иткән Гөлсемне, бу арбадагы шул кешелектән чыккан исерекне күз алдыннан җибәрә алмады. «Ник соң бу болай? Ник болар уртача гына бәхет берлә тора алмаганнар? Ниләре җитешмәгән, икесе дә укыган, икесе дә тәрбия күргән... Икесе дә яшь булган... Икесе дә бай булган... Ник?» — дип башын ватты. Бу сөальләргә җавап тапкан кебек булса да, берсе дә канәгатьләндермәгәнгә, уйга тыныш куя алмаенча, үз тормышына күчте. Яңадан үзенең яшьлегеннән бирле үткәргән гомере, көне-көне берлә кебек, күз алдыннан үтте. Ул тормышындагы тулы бәхетне тагы татыды. Шуның тәмнәре, татлы хыяллары эчендә ул рәхәтләнеп изрәп китте. Шул тулы тормышны багышлаган ирен хәзер барып кочаклыйсы килде. Аның кулын барып үбәсе килде. Аңарда иренә каршы сөю, ир итүгә башка әйтеп бетерелмәслек зур бер хөрмәт уянды. Язмышыннан разыйлык аны биләде. Ул шул сөю-сөешү эчендә үткән гомере өчен, хәзер аталы-балалы тыныч тормышы өчен әллә кемгә, әллә нигә каршы тез чүгәсе, тезләнәсе килде. Әллә кемгә, әллә нигә: «Рәхмәт, рәхмәт, мең мәртәбә рәхмәт, мин бит менә болай булмадым, болар да бит адәм баласы, рәхмәт, миңа мондый тулы тормыш бирдең. Рәхмәт, мине шундый газаплардан котылдырдың»,— диясе килде.

Аның күңеле йомшады, ул көзге кояшка каршы чабып бара торган арбаның җиле астында акрын гына Коръән укырга керешге. Исерекнең авызыннан чыгып тора торган искергән аракы исе аны борчыганга, кайвакыт аның авызына кадәр кереп китеп телендә әйләнә торган Коръән сүзләрен мәсхәрә итә кебек тоелганга, ул, иңсәсендә яткан исерекне уятмаслык итеп кенә, башын борды. Үзе аңлап бетермәгән Коръәннең сүзләре, бигрәк тә шуның көе, аның күңеленә әллә нинди йомшак бер җылылык бирде. Аның тамырларына әллә нинди әйтеп бетерә алмаслык җылылык таралды. Ул, үзе дә сизмәенчә, тавышын зурайтканнан-зурайтты. Коръән моңы, көпчәк тавышына кушылып, яңа бер төс алды. Акрын гына исә торган көзге җил ул тавышны алга-артка чәчте, сипте. Нәфисә, үз көенә үзе батып, Коръән артыннан бара торган бер тирән шөкрана берлә басылганнан-басылып, башын иде, бик түбән иттереп башын иде. Шул тормышны биргән Тәңресенә каршы сәҗдә кылмакчы булып, буен сынды.

Аның колагына исерекнең гырлавы ишетелде. Аның борынына исерекнең искергән аракысының исе бәрелде. «Ирең шундый булса, ни эшләр идең?» — дигән куркулы бер фикер аны килеп сукты. Язгы көннең болыты кебек, ул да тиздән югалды. Тагы тормышның кояшы ялтырады. Ул кулын догага күтәрде. Үзе белгән бөтен догаларны укып бетерде. Аның берлә генә тулмады кебек хис иткәнгә, ул кулын төшермәде. Кыска сүрәләр укыды.

Татарчалап Аллага ялынырга, ялварырга, шул биргән бәхетле тормышын озын иттерергә ялварырга тотынды. Аның күңеле моңайганнан-моңайды, күзеннән ике бөртек яшь тәгәрәде. Шуның берлә күңеле дә тәмам тынды, тынычланды. Ул, йөзен сөртеп, догасын бетерде. Атлар баруында булды. Исерек гырлавында дәвам итте.

Теге арбада бик озакка кадәр сүз юлына кереп китмәде. Балалар берсе-берсе берлә шаярышып, чупырдашып барсалар да, әле оча торган бер кош хакында, әле мәрҗән кебек тезелгән миләш хакында сөальләр биреп зурларны йөдәтсәләр дә, нә Гөлсем, нә доктор үз уйларыннан аерыла алмадылар. Иске дусча яисә яңа танышча сүзгә чумып китә алмадылар. Арада үткән вакыйгалар, шуннан соң булган хәлләр боларны әллә ничек берсеннән берсен, көчләтебрәк булса да, ераграк тотарга мәҗбүр иткән кебек булды. Менә балалар арбаның йомшак саллануы астында изрәнгәләп, берәм-берәм йокыга киттеләр. Гөлсем берлә доктор икесе генә күзгә-күз калдылар. Гөлсем, бер яктан, кичә Нәфисәгә ул кадәр ачылуыннан үкенеп, икенчедән, көтелмәгәндә килеп чыккан шул очрашудан аптырап калып, язмышының шул авыр йөге астында башын игәннән-игән иде. Ул докторга күзен күтәреп карый алмады. Эченнән генә: «Мине гафу итегез, теге вакыттагы эшләр өчен!» — димәкче булды. Авызын ачарга булгач кына, сүзе онытылды. Фикере чуалды. Икенче яктан, серен бирмәенчә: «Аллага шөкер, бик шәп торам»,— дигән уйны калдырыр өчен, искене оныткан кебек сөйләп китмәкче булды. Исерек иренең кыланышлары күз алдына килде дә тагы ул карарны эшли алмады... Доктор да элгәре моңарга каршы үпкәләгән, бик күп хатларга җавап булмаганга хурланган итеп үзен һавалы тотарга теләсә дә, язмыш тарафыннан шулкадәр изелгән Гөлсемнең йөзен күрү берлә, ул да вазгыятьне[1] саклый алмады, аны кызгану басты. Менә Гөлсемнең бер баласы бердән куркынып уянды. Гөлсем: «Менә тиктән шулай куркыныш уяна, сез бит доктор кеше, аны ни эшләтергә кирәк?» — дип, докторга карады. Доктор: «Сеңерледер, тынычрак тотарга кирәк!» — диде дә, тагы сүз өзелде.

Тагы икесе дә, сүзне башлап китәр өчен, берәр хәйлә эзләргә тотындылар. Доктор: «Соң сез, Гөлсем туташ, һаман шунда торасызмы, мин инде сезне моннан киткән дип ишеткән идем»,— диде. Гөлсем: «Юк, вакытлы гына киләмен, эшем генә бар»,— дип җавапланды да, сүз киселде. Үзе эченнән: «Соң сез минем язмышымны беләсеңез килсә, минем кайдалыгымны белмәгән булыр идеңезмени?» — дип шелтәләмәкче дә булды. Ул сүз дә авызыннан чыкмады. Доктор: «Кайда торасыз соң, әтиеңез үлгәч, мин сезгә Петроград адресыңыз берлә дә, мондагы адресларыңыз

[1] *Вазгыять* — торыш, халәт.

берлә дә берәр хат язган идем. Җавабы да булмады, хаты да кире кайтмады»,— диде... Гөлсем кып-кызыл булды: «Мин сездән һичбер хат алмадым, һичбер! Теге көнге күрешкәннән соң, бер сүз ишетмәдем, бармак буе бер кәгазь алмадым... Мин бик көттем... Сез мине, үзегез әйткәнчә, шул баткаклыкта ялгыз калдырмассыз дип көттем, бик көттем, ләкин бер сүз ишетмәдем, бер хат алмадым»,— диде дә тагы башын иде. Доктор: «Минем китүемнең ничек булганын белә торгансыз, сезнең теге әфисәргә «бармыйм» җавабыгыздан соң бөтен бәла миңа ауды. Бөтен кеше мине гаепләргә тотынды. Теге әфисәр мине дуэльгә чакырам дип бәйләнде, карт мирзасы мине эт итеп сүкте. Сезнең тутакаегыз бөтен халык алдында: «Чыгып кит!» — дип, мине куды. Мин, шулкадәр хурлану, мәсхәрәләнү алдында сезне онытмасам да, сезне күрергә һичбер төрле юл булмагач, берничә адрес күрсәтеп, сезгә хат язып калдырдым, аны шундагы сезнең хезмәтче кызыгызга бирдем». Гөлсем: «Ул хатны минем тутакай алган, мин аны күрә алмадым»,— диде. Доктор: «Аннан җавап булмагач, мин сезнең ике адресыгыз берлә дә хат яздым, тагы җавап булмады, тагы яздым, Петроградка бардым. Сезне күрер өчен, кулдан ни килсә, шуны эшләдем. Театрга йөрдем, сезнең өй тирәсендә көннәр буе каравылладым, телефон шалтыраттым. Ләкин сезгә һичбер тугры килә алмадым, аннан соң беркөнне үземнең адресым берлә бөтен хатларым кире кайтты. Сезнең язуны, кул түгелме икәнен белмәгәнгә, тагы шул арада сез әллә нинди бер кавказлыга кияүгә чыгасыз дигән хәбәр йөрегәнгә, бу сезнең тарафтан эшләнгән эш дип ышандым. Шуның өчен өметсезләндем. Петроградта яшәү бик авыр булды. Киев дарелфөнүненә[1] күчеп киттем. Аннан да әле бәйрәмдә сезгә котлап тәбрик җибәрдем»,— диде. Гөлсемнең күзләрен ут алды. Ул кып-кызыл булды.

«Ышанасызмы, юкмы, ни кадерлегез бар, шуның берлә ант итәм, валлаһи, бер хатыгызны алмадым, һичбер хатыгызны кире кайтармадым»,— диде. Үзенең күзеннән ике бөртек яшь тәгәрәде.

Шуңарга каршы доктор ни эшләргә белмәенчә торганда, ат туктады. Кучер: «Менә шунда инде аерылыш»,— дип борылды. Гөлсем тагы калтырады, тагы дерелдәде. Тагымыни аерыла, әле генә кушылган иде, тагымыни аерыла? «Аерылмасын!» — димәкче булды. Күзе дүрт балага төште. Ул күзен күтәрде, докторга карады. «Әйе, шунда юл аерыла шул!» — диде. Арба туктауга, бердән бөтен балалар калыкты. Тирә-юньдәге миләш асылган агачны күрү берлә, мәче балалары кебек, берсе артыннан берсе йолт-йолт җиргә сикерде. Арттан килеп туктаган арбадагы Нәфисә, кулы берлә изи-изи, боларны чакыра башлады. Доктор да,

[1] *Дарелфөнүн* — университет.

Гөлсем дә, әллә берәр нәрсә булдымы дип куркынып, Нәфисә арбасына ашыктылар. Анда алар Нәфисәнең иңсәсенә башын аударып яткан исерекне тирән бер йокы эчендә, селәгәйләре аккан көенчә, Нәфисәне дә капкынга кысылган кебек тартылып башын тискәрегә борган хәлдә таптылар. Беренче хисләре икесенең дә, Нәфисәне котылдырыр өчен, шул күсәкне төртеп җибәрү булды, ләкин Нәфисә: «Акрын-акрын, бер мендәр генә китерегез, бик шәп йоклый, мескен, йокласын, азрак айныр»,— дигәнгә, икесенең дә кызгану хисе җинде. Кызулашып, мендәр алып киленде, уятмаенча, баланы урыныннан күчергәндәге кебек йомшаклык берлә, исерекнең башы Нәфисәнең иңсәсеннән мендәргә куелды. Нәфисә азат ителде. Уйланмаенча утырышканга, Нәфисә берлә исерек докторларның арбаларына утырган булганга, хәзер аны, уятып, арбадан арбага күчерү аны тагы исерек хәленә кайтару булачак булганга, тегенең йокысы туюны, айнуны көтәргә карар бирелде.

Көн иртә матур булганга, су буендагы яланга атлар да туарылды. Бик күп коры-сары җыелып ут ягылды. Ялчыларның чәйнекләре алынып, чәй әзерләнде. Урман эченнән әллә никадәр миләш, балан җыелып киленде. Көзге кояшның җылы, йомшак нуры астында бөтен җәмәгать чәйгә утырды. Нәфисәнең күңелендә үзенең хәленнән шөкрана хисе бик тулы булганга, ул шул кызганыч хатынны, шул хаста балаларны бик кадерлисе килде. Аларга аз гына булган шул тыныч вакытны тулырак үткәрәсе килде: ул, өендә кунак кабул итә торган ханым кебек, бөтен эшне эшләде, чәйне әзерләде, кәрзиннәрне ачты, ашамак-эчмәк чыгарды. Балаларны җирле җиренә утыртты. Аларга тәмле-томлы таратты. Чәй ясарга утырды. Мәҗлес күңелле үтте. Чәй тәмле чыкты. Гөлсемнең йөзендәге җыерчыклар качты, аның йөзенә бер кызару йөгерде, битенә елмаю килде. Ул, үз-үзен онытып, рәхәтләнеп, бер сулыш алды. Чәй бетәр-бетмәс, балалар тагы урмангааралдылар. Доктор берлә Гөлсем дә, акрын-акрын атлап, әллә кайчан куелган очрашуга барган кебек, урман арасына кереп югалдылар. Нәфисә генә, ашны-суны җыя-җыя, кучерларга чәйне эчерә-эчерә, соңга кала язды. Урман бала тавышы берлә тулды. Яфраксыз, шыр ялангач агач араларыннан күренгән кызыл миләш сабаклары аларны әле бер якка, әле бер якка йөгертте. Агач башында гына эләгеп калган дүрт-биш чикләвек аларның бөтен көчләрен шуны алырга сарыф иттерде. Агачтан агачка сикерә торган тиен элгәре аларны куркытты. Аннары көлдерде, аннары йөгертте. Гөлсем дә, доктор да, бер сүз эндәшмәенчә, һаман алга атлауларында дәвам иттеләр.

Менә бердән икесе дә туктадылар. Көтелмәгән бер киртәгә терәлгән кебек туктадылар да берсенә берсе караштылар. Алларында зур бер агач сап-сары яфракларга сарылып, һаваланып

утыра иде. Аның төбендә кечкенә генә итеп төшкән яр астында су борылып-борылып китә, борылганда, әллә нигә әләгеп китеп, шырлап-шырлап, көйләп ага иде. Суның теге ягында озын киң ялан, ямь-яшел чикләвеккә батып, иртәнге чык бөртекләре берлә кояшка каршы җемелдәп-җемелдәп уйный иде. Аның артында зур урман, башыннан аягына кадәр яшелгә бөркәнгән чыршы берлә шалтыраган тавыш чыгара торган сары яфраклар берлә бизәлгән усак. Бу төсләр бер генә түгел, йөз генә түгел, меңләп-меңләп, берсе арасына берсе кереп, озын-озын, зур-зур аклы-сарылы бер букет ясыйлар, берсен берсе куа торган төрле киемдәге кешеләр кебек, берсеннән-берсе узышып, еракка-еракка китәләр иде. Доктор да, Гөлсем дә шул манзара астында изелгән кебек катып калганнар иде. Күзләрен еракка таба текәннәр дә калганнар иде, икесенең дә күз алдында элгәреге көннәр үтә иде. Элгәреге татлы өметләр, тәмле хыяллар, манзаралар кичә иде. Әнә бу җирдә алар икәү генә балыкка килгәннәр иде. Гөлсем алсурак бер күлмәктән, чәчләре бераз тузгыган көенчә, шул ярга утырган иде. Әнә теге таштан битләре янган тап-таза егет Хәлил икенче кармакны суга салган иде. Гүя судагы көмеш балыкларны эзләгән кебек, бер-берсенең күзләрен эзләгәннәр иде. Судагы шәүләләргә әллә никадәр сүзләр сөйләшеп, мәхәббәтләрен белгерткәннәр иде. Әнә шунда... Менә Гөлсем тагы кармагын тартты. Аның җебенең очында ялтыраган көмеш балык, сикеренә-сикеренә, су өстенә чыкты, менә ул тагы өзелеп, «чолт» итеп суга төшеп китте. Менә тагы су тынды. Тагы бер-берсен күрделәр, тагы елмаештылар. Ихтыярсыз куллары кулга очрады. Хәлилнең кайнар кулы эченә Гөлсемнең суык кулы кереп, суыктан җылына башлады. Берсенә берсе карадылар. Хәлил: «Менә шунда бит без бергә балык тоткан идек»,— диде. Гөлсем: «Әйе, шунда...— диде дә сүзен дәвам иттерә алмады, күзеннән яшь мөлдерәде.— Мин сезнең алдыгызда гаеплемен, ул вакытта, сезгә каршы эшләнгән начарлыкларда катышым булмаса да, сезне яклап бер эш эшли алмадым. Гафу итегез, көчем булмады. Менә шуның җәзасын күрәм»,— диде. Үзе үксеп-үксеп егларга тотынды. Хәлил аны биленнән алды. Башын үзенең иңсәсенә куйды. Балаларны сөйгән кебек, аның башын, чәчен сыйпады. Гөлсем, әллә нидән качкан кебек, аның кочагына кергәннән-керде. Әллә нинди зур бәладән сыенган кебек янашканнан-янашты[1]. Аның кайнар сулышы Хәлилнең битенә бәрелде. Аның йөрәк тибүе Хәлилнең колагына ишетелде. Ул юешләнгән керфекләре арасыннан йөзенә моңланып-моңланып карый торган Гөлсемне йомшак кына иягеннән тотты. Акрын гына иттереп битен борды. Бит биткә тиде, авыз авызга очрашты... Бердән урман

---

[1] *Янашу* — якынаю.

җанланды. Анда да, монда да балалар кычкыра башлады. Гөлсем балаларының, еглаган тавыш берлә: «Әни, әни!» — дип акырулары, Хәлил балаларының: «Әти, әти! Син кая!» — дип аваз бирүләре боларны уятты. Бердән берсе берсеннән читкә киттеләр... Берни аңламаган кебек, берсенә берсе карашып тордылар. Менә «А-ау!» дигән, Нәфисәнең ерактан эзләгән тавышы килде. Гөлсем куркып селкенеп китте. Хәлил: «Әү!» — дип, сузып җавап бирде. Гөлсем куәтенә туплады, көчләнеп, тагы форсатны качырмыйм дип: «Мин һәрвакыт сине сөйдем, хәзер дә сөям»,— диде... Хәлил җавапка авызын ачарга өлгермәде, балалар өеме килеп чыгып, кайберләре аталарына, кайберләре аналарына сарылдылар. «Елан күрдек, елан!» — дип сөйләргә тотындылар. Хәлил Гөлсемнең күзенә бик мәгънәле иттереп карады, балаларны күздән кичерде: «Инде көз булды, Гөлсем туташ, көз; һәр агачның җимеше пеште, миләшнеке миләшчә, алманыкы алмача!» — диде... Күзенә яшь тыгылды. Шуны куәтләгән кебек, урман өстеннән бер җил үтте. Агач ботаклары берсенә берсе бәрелде. Бик күп сары яфрак Гөлсемне каплады. Ул арада булмады, Нәфисә килеп җитте. Ул, боларның аптырабрак торганнарын күреп: «Нәрсә бик моңайдыгыз?» — диде. Гөлсемдә шул хатынның бәхетеннән көнләү уянды, аз гына булса да шуны чәнчәсе килде, ул: «Яшьлекләр искә төште, без монда тормышның язында Хәлил әфәнде берлә очрашкан идек, менә тагы көзендә дә тугры килдек»,— диде... Нәфисә: «Сез электән таныш идегезмени?» — дип, Хәлилгә карады. Хәлил: «Әйе, мин студент чакта!» — диде.

Нәфисә, озын гына иттереп: «Алай икән»,— диде дә икесен дә сөзде. Үзе бераз икеләнеп торган кебек булды да, бер кулы берлә ирен җитәкләп, бер кулы берлә Гөлсемне алды: «Әйдәгез, әнә тагы болыт чыгып тора. Көзге кояшка ышанырга ярамый»,— диде. Гөлсемгә: «Сезнең ирегез дә торды»,— диде. Акрынлап, арбага таба юнәлде. Юлга әзерләнү бик тын үтте. Исерек айнып уянганга, ул бик оялды, хурланды, күзен югары таба күтәреп карый алмады. Яшьлегенең иң матур, иң пакь бер битенең көтелмәгәндә болай бердән кырт киселүе, йөрәкнең иң тирән почмагында сакланган соңгы өметнең көзге сары яфраклар берлә каплануы, томалануы Гөлсемне тагы басты, тагы изде. Тормыш йөге астында изелгән аның билен тагы бөкте. Нәфисә берлә үткән тулы мәгънәле тормыш эчендә күптән онытылган яшьлек хатирәләре, көтелмәгәндә килгән шайтан туе кебек, Хәлилнең тыныч күңелен болгатты, дулкынлатты. Бәхетле гаилә тормышының калын өресе астында үзенең эсселеген, кайнарлыгын яшергән, саклаган аның йөрәк уты шул көзге җилнең искәрмәстән исүе берлә пәрдәсез, калкансыз калды. Аның уты тышка чыкты. Аның дулкыны дөньяга күренде. Ул йөрәкнең көйгән исе Нәфисәнең йөзенә бәрелде. Хәлил үзенең бәхетле

тормышының остасы, зур күңелле шул саф хатынының алдында оялды. Аның олуглыгы астында муеныи иде. Башын бөкте.

Нәфисәдә, бөтен гомерен кешеләргә ышануга, кешеләрнең яхшылыгына корган Нәфисәдә, ун ел эчендә баштанаяк иренә ышануга, инануга баткан, чумган Нәфисәдә, шул ара-тирә кызыл миләшләр, баланнар берлә генә бизәкләнгән, сары яфрактан сары кәфен киенгән көзге урман эчендәге шул юешле, суыклы көзге җил аның күңелендә иренә каршы беренче мәртәбә шөбһә уятты. Иренең тугрылыгына каршы, кешеләрнең яхшылыгына каршы йөрәгенә шик салды. Ул шөбһәне тиздән бетерә алмаганга, шуны кирәкмәгән чүп кебек читкә төртеп ташлый алмаганга, тормышының кәкреле-бөкреле тыкрыклары, почмаклары эчендә ул адашкан кебек булды, ул да көләчлеген югалтты, күңелендә әллә нинди бер исемсез эчпошыргыч [нәрсә] җирләште, әллә нинди күрелмәгән бер көя аның тынычлыгын ашый башлады.

Коры гына күрешеп, атларга утырдылар. Юлның аерылган почмагыннан ике арба ике якка киттеләр. Ихтыярсыз ике арбадагы күзләр дә берсен берсе сөзеште. Ике арбадагы күзләр дә берсенә берсе әйтелеп бетмәгән соңгы сүзләрне әйтеште. Озак кына тик барганның соңында, Нәфисә Хәлилнең йөзенә карады, күзенә карады. «Шулмыни беренче мәхәббәтең?» — диде. Хәлил: «Әйе!» — дип башын иде. Бераз паузадан соң: «Әллә көнләдеңме?» — диде. Нәфисәнең күзе ялтырады, йөзе кызарды, әллә нинди бер авырткан җиренә тигән кебек сыкранган тавыш берлә: «Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, моннанмы? Шул мескеннәнме?» — диде. Тавыш туктады. Бераздан, шул фикерен дәвам иттергән кебек, Нәфисә Гөлсемгә каршы сузып кына: «Тиле!» — диде. Шул сүзен авыррак таптымы... кешенең бәхетсезлегеннән көлү кебек булып киттеме: «Мескен...» — диде.

Икесе дә Гөлсемнәрнең арбалары китеп барган юлга күзләрен тектеләр. Анда көзге җил өермә куптарган иде. Шайтан туе, сары яфраклар, сары саламнар, иске тузаннарны җыеп, Гөлсемнәрне куа иде, аларны җитәм-җитәм дип ашыга иде. Менә тагы җил, тагы бер өермә, әнә аларның өстенә сары яфраклар, көзге яфраклар оча... Әнә арбаның дугасы гына күренә, әнә ул югалды, әнә ул да юк... Менә көзге вак яңгыр акрын гына сибәли башлады. Менә ул, тирә-юньне томалап, һаваны басты. Нәфисә аркасыннан әллә нинди юеш бер суык йөгергәнне хис итте. Ул тыгызрак итеп иренә таба сыенды. Хәлил таза кулы берлә аны кысты... Күзләре күзгә очрашты, елмаешты, көлеште. Орышканнан соң килешкәндәй була торган кебек бер җылы икесен дә бәйләде. Хәлил кучерга: «Тизрәк тот, яңгыр җиткәнче кайтыйк!» — диде. Кучер чыбыркыны шартлатты. Атлар алдырып киттеләр. Кыңгыраулар, берсенә берсе җитә алмаенча, өйгә таба, җылы вә яңгырсыз, җилсез өйгә таба ашыга башладылар.

1923—1938

Нәкый Исәнбәт
(1899—1992)

ИДЕГӘЙ

(трагедия кыскартып бирелә)

ВАКЫЙГАДА КАТНАШАЛАР:

Идегәй.
Норадын — улы.
Туктамыш — хан.
Яникә — ханча.
Ханәкә
Кәнәкә } кызлары.
Кадыйрбирде — уллары.
Җанбай — хан киңәшчесе.
Арслан — батыр.
Субра — халык җырчысы һәм сынчы карт.
Янбулат — егет.
Килмәт — сукачы.
Чулпан — кызы.
Нугайби — күчмәләр башы.
Аңгысын
Тыңгысын } сарай коллары.
Аксәет — пирмәмәт, пәйгамбәр нәселеннән баш рухани, карт.
Таңгатар — котүче.
Сарраф — ростовщик.
Шәйхемисрый — коллар белән сату итүче бер килмешәк.
Казыйхан — баскак.
Илче.
Аргын — байракчы.
Башмакчы.
Марук.
Атамыш — тәгърифче (герольд).

Хан курауч**ы**лары[1], коллар, кәнизәкләр, гаскәр, халык һәм башкалар.

Вакыйга Алтын Урдада XIV йөз ахырларында һәм XV йөз башларында Сарай шәһәрендә һәм аның җирләрендә бара.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәхнә I

Сарай шәһәрендә хан сараенда бер бүлмә. Еракта барабан тавышлары.

Аңгысын *(ишектә торып)*. Ишетәмсең? Ханның тәкәббер кызы Ханәкә солтан Кырымнан кайтып җитте. Ханчаның боерыгын онытма, утыңны кабыз. Тыңгысын!

Тыңгысын. Әйе! Ләкин мин утымны аның өчен түгел, дустыбызның сау кайтып җитүе өчен кабызам... *(Чыгып ут кабыза. Күтәреп тотып.)* Идегәй өчен!

Аңгысын. Акрын! Кобогыл би[2] дип сөйлә. (...)

Саз, думбра авазлары. Алдан җариәләр керә. Юл киемнәреннән, сәхтиян төенчек күтәргән Ханәкә, аны култыклаган Кенәкә һәм Яникә ханәш ишеккә туктала. Артларында төен күтәргән кәнизәкләр[3].

Яникә *(Ханәкәгә)*. Тукта! *(Алдан кереп, йола кушуы буенча тантаналы рәвештә утны алып, кызына каршы бара.)* Атаң сараена керәсең, йөгенеп[4] ал, кызым! *(Каршыдан ут бирә.)*

Ханәкә *(бусагага тезен чүгеп, утны ала)*. Атам бусагасында тез йөгендем, ут алдым. *(Алып, анасына кире биреп, аңа тотынып тора.)*

Яникә. Күзе ияргәннең күзе калсын, яманы ияргәннең яманы калсын! *(Ут белән өч әйләндереп.)* Кер, кызым!

Ханәкә. Торлагым имин булсын!

Керәләр.

Яникә *(әйләнеп)*. Сусын![5]

Кәнизәкләр җамаяк белән кымыз бирәләр. Аңгысын белән Тыңгысын чыга.

---

[1] *Курауч**ы**лар* — озатып йөрүчеләр, куршап алучылар; русча — свита.

[2] *Би (бәй, бәк)* — башлык, түрә, гомумән, морза чинындагы кеше.

[3] *Кәнизәк* — кол хатын-кыз.

[4] *Йөгену* — иелеп, тез бөгеп хөрмәт күрсәтү.

[5] *Сусын* — кунакның сусавын басар өчен бирелгән эчемлек. Аны авыз итү изге йола итеп, кунакны кабул итү һәм ак күңеллелек билгесе дип каралган, шунлыктан сусын кымыз, сөт, әйрән шикелле ак нәрсәдән булган. Кәрван алларында «сусынчылар» торган булуы ярлыклардан аңлашыла. *(Н. И.)*

К ө н ә к ә *(Ханәкәгә).* Без синең өчен бередә куркышып беттек! Кырымда бик зур чуалыш купкан, имеш, дип сөйләделәр. Мин ишеткәч еладым.

Х а н ә к ә. Җаным! Мин үзем дә ни хәл була икән инде дип кенә тордым. Төлкетимер җизнине хан баскагы[1] дип тормадылар, кешеләрен үтереп, сараена ут сала башладылар. Ярый бередән Кобогыл белән Арыслан батыр килеп төште.

Я н и к ә. Шуннан? Килде дә Кобогыл фетнәчеләрне тотып астырдымы?

Х а н ә к ә. Мин дә шулай итәр дигән идем, ул килде дә... җизнинең үзен тотып яптырды.

Я н и к ә *(гаҗәпләнеп).* Ничек? Кобогыл килеп җизнәңне зинданга салдырдымы? Олуг хан нәселен? Юк! Моның өчен ул атаң белән минем алдымда җавап бирер!

К ө н ә к ә *(Ханәкәгә).* Бик матураеп кайткансың. Сине Норадын озатып алып килдеме?

Х а н ә к ә *(илтифатсыз гына).* Ул.

К ө н ә к ә. Чыннан да, ул — бик сөйкемле егет, әйеме?

Х а н ә к ә. Кем? Шул кара сөяк Норадынны әйтәсеңме?

К ө н ә к ә *(гаҗәпләнеп).* Ник кара сөяк булсын? Ул Кобогыл би улы.

Я н и к ә. Кобогыл би? Аты би булгач та, көтүче Кобогыл ла ул. (...)

Х а н ә к ә *(төенчекне ача).* Анам! Сиңа тутам җибәргән бүләкләр.

Карыйлар. Материяләр чыга. Н о р а д ы н керә, куенында алмалар.

Н о р а д ы н. Сәлам, олуг ханәш!

К ө н ә к ә *(үзалдына).* Ул! Йа Тәңре! Ул минем белән исәнләшми дә!

Я н и к ә *(аңа рәтләп карамыйча).* Кая югалдың син? Ханәкә солтанны сарайга китереп тапшыру сиңа боерылган түгелме соң? Кобогыл улының угланлык[2] кылуы шул төсле булса, аты корысын.

---

[1] *Баскак* — ханның өлкәләрдәге урынбасары, гаскәр көче белән халыкларны буйсындырып, ханга салым җыючы башлык.

[2] *Угланнар* — сарай хезмәтендә булган яшь егетләр; күбесенчә морза балаларыннан алынган. Соңыннан шушы сүздән алып элекке Россиядә булган «Улан полклары» дигәндә, яки «Улан-Батыр», «Улан-Удэ» кебек географик урыннарда да бу сүз очрый. Татар халык җырында, «Төн урталарында үкереп елый буйга гына җиткән кыз углан» диелүгә караганда, бу сүз ир җенесен генә аңлатмавы күренә. Киңрәк мәгънәдә «ыланнар» сүзе русчада олы кешеләргә дә яратып әйтелгән «ребята» сүзенә тора. Инде «ул», «угыл» сүзләренә килсәк, аерым, ялгыз мәгънәдә әйткәндә — «угыл», гомумән, малай мәгънәсендә һәм шулай ук кимсетебрәк әйткәндә, «ул» сүзе кулландык. *(Н. И.)*

Кызлары белән материялләрне карыйлар. «Бусы рәтле, ефәге йомшак» дигән шикелле сүзләр ишетелә.

Норадын. Нигә? Мин Ханәкә солтанны сарай бакчасына кадәр алып килдем дә. Мин аңа, бакча аркылы үтик, дидем. Ул үзе күнмәде. *(Көнәкәне яңа күреп, әһәмиятсез генә.)* Саумы, Көнәкә солтан... *(Куеның ачып, Ханәкәгә.)* Күрәсезме? Менә алмалары, Ханәкә!

Аңа бирәү дә карамый.

Көнәкә *(үзалдына)*. Ул Ханәкәне сөя!

Яникә *(Ханәкәгә)*. Туган бик асыл нәрсәләр җибәргән.

Ханәкә. Әле бусы бар. *(Килеп сәхтиян чемоданын ача.)* Менә. Мин аны юл буенча тез өстендә генә тотып алып кайттым. *(Кечерәк бер кыйммәтле ваза чыгара.)*

Яникә. Йә! Кара! Кытай осталары сапкандыр моны!

Ханәкә. Тутам әйтте инде, бәясенең чиге юк, диде. Ул әле тузанлы. *(Өрә.)* Менә!

Көнәкә. Бигрәк тә чын, җылык-җылык итеп тора!

Яникә. Сөрт тә атаңа тапшырырбыз. Ул бик шатланыр.

Норадын *(алма ашый)*. Таптылар искитәрлек нәрсә! *(Күрсәтеп.)* Матурлык әнә бакчада! Хәтерендәме, Ханәкә, мин былтыр анда сиңа алма ыргыткан идем. Син миңа үпкәләп киттең! Янәсе, мин сине мыскыл итеп аткан булам. Мә, менә безнең Идел буе алмасын авыз ит! *(Ыргыта, Ханәкә: «Ай!» — дип кычкыра, ваза төшеп ватыла.)*

Яникә. Һай Кобогыл улы, ни кылдың?

Ханәкә *(башын тотып)*. Ай!

Норадын *(килеп)*. Борчылмагыз! Зыян юк!

Яникә. Зыян юк! Ах, нәселсез углан!

Норадын. Нәселсез? Минме нәселсез?

Яникә. Син! Кырым баскагы Төлкетимер безгә бүләк күндереп гозер үтенә. Син аны ватып көл кылдың!

Көнәкә *(ялынычлы)*. Анай!

Норадын. Мин гаепле. Ярый. Хан алдында мин җавап бирермен. Син, Ханәкә, борчылма!

Ханәкә. Кит.

Норадын. Гафу, Ханәкә, мин сарай гадәтегезне белмим. Мин далада үскән.

Ханәкә. Кит, углан.

Быргы ишетелә.

Яникә. Хан хәзрәте килә. *(Норадынга поднос сузып.)* Җый шуңа ватыкларын. Җый да тезләрең өстендә шуып килеп, тапшырып гафу үтен.

Н о р а д ы н. Тез өстендә шуарга? Шул җамаяк өченме? Юк, бу булмас! *(Чыга.)*

Я н и к ә. Карагыз аны! Асра көтүче малаен!

К ө н ә к ә *(узалдына)*. Юк! Син кол булып тумаган, Норадын, ир булып туган! Ничек ул минем йөрәгемне аңламый!..

Т у к т а м ы ш керә.

Т у к т а м ы ш *(Ханәкәгә)*. Алты яшәр юлдан килсә, алтмыш яшәр каршы ала, дигәннәр. Саумы, кызым?!

Х а н ә к ә. Эти... *(Күрешә.)*

Я н и к ә. Моны күрче, падишаһым!

Т у к т а м ы ш *(тукталып)*. Нәрсә ул?

Я н и к ә. Күрмисеңмени? Баскагың сиңа, кызың аркылы йөгенеп, кадерле бүләген җибәрә, Кобогыл улы аны бәреп төшерә. Менә аннан калган нәрсә.

Т у к т а м ы ш *(рәтләп карамыйча ук)*. Байназарга җибәр, ватыкларын казанга салдырсын.

Я н и к ә *(ныклы)*. Падишаһ! Шуны да онытма: бу бүләкне сиңа күндергән кардәшең шушы вакытта Кобогыл мәрхәмәте аркасында зинданда утыра!

Т у к т а м ы ш *(аңа якын килеп)*. Кобогыл дисең син? Кобогыл белән үзем сөйләшермен. *(Ханәкәгә.)* Син бар, кызым, ял ит. Сез дә барыгыз.

К ы з л а р чыга.

Шуны да онытма, ханәш: дөньяда миңа каршы бер генә көч тора — ул да булса Аксак Тимер. Мин аның йортын чабарга, үзен суярга тиеш! Миңа Кобогыл бием кирәк!

Я н и к ә. Шуның өчен генә Кобогылның үзсенүен гафу итәсеңмени?

Т у к т а м ы ш. Йортыңа кара, ханәш. Кырымда кырылыш. Болгарда буталыш. Хәзер илне шым тотарга кирәк. Кобогыл — минем уң кулым!

Я н и к ә. Димәк, халкың сине тыңламый, аны тыңлый! Шулай Кобогылның даны сине дә басып китте буламыни?

Т у к т а м ы ш. Ничек? Ничек дидең син?

Я н и к ә. Мин бары синнән шуны гына үтенәм, олуг хан: Кобогыл каршыңа килеп кергәндә, падишаһ башыңны кол итеп, урыныңнан үрә тормассың, утырып каршы алырсың!

Т у к т а м ы ш *(йөзе каралып)*. Ялганлыйсың син, ханәш! Көтүчедән би булган, түрәм булган Кобогыл өрәге миндәй була алмас! Чыңгыздан булган затыма минем колым тиңә алмас[1]! Ул торганда, мин тормам! Ул торганда, мин торсам, Туктамыш хан мин булмам! *(Горур кыяфәттә чыга.)*

---

[1] *Тиңә алмас* — тиңләшә алмас; бу юллар дастаннан алынды.

Я н и к ә *(ялгыз)*. Димәк, син моны үзең үк сизми эшлисең. Яхшы. Хәзер син аны кабул итәрсең. *(Түшеннән энәсен алып.)* Күрербез, син ничек урыныңнан торырсың икән! *(Чыга.)*

Сәхнә II

Тәхет залы.

Барабан. Ишеккә А ң г ы с ы н, Т ы ң г ы с ы н кереп баса. А р с л а н белән Җ а н б а й, у г л а н н а р һәм К а з ы й х а н б а с к а к керә урын ала.

А т а м ы ш *(керә дә югары тавыш белән)*. Дөньялар падишаһы, гаделлек солтаны, олуг хан Туктамыш каган[1] килә, бисмилла!

К а д ы й р б и р д е, Я н и к ә х а н ә ш, Т у к т а м ы ш х а н һәм к у р а у ч ы л а р ы керә. (...) Туктамыш тәхетенә чыгып утыра. Яникә яныннан урын ала.

Т у к т а м ы ш *(Арсланга)*. Йә, алга чык, батырым! Читлеген ваткан арыслан шәһәремне кырганда, ялгызың чыгып үтереп, тиресен суеп алган син идең! Йә, сөйлә! Ничә сөңге сындырдың? Кырым дигән йортымда буйсынудан баш тарткан дошманымның ничәсен ора суктың, Арслан?

А р с л а н. Хәер, хәер, ханиям! Кырым дигән йортыңда идегәйчеләр баш тартса, гаскәр башың Кобогыл дауны кансыз бетерде. Сөңге кирәк булмады.

Т у к т а м ы ш. Идегәйчеләр? Ул нинди идегәйчеләр?

А р с л а н. Әлепбай, падишаһым! Анысын Кобогыл би белмәсме?

Т у к т а м ы ш. Сусын! *(Аңа зур җамаяк белән сусын бирелә, барабан, быргы ишетелә.)*

А т а м ы ш. Гаскәр башы Кобогыл биең килде, каган!

Т у к т а м ы ш. Керсен!

Я н и к ә *(үзалдына)*. Күрик. *(Туктамыш ханның чабуын сиздерми генә энә белән тәхеткә кадый.)*

Чыңгыздан калган кара туны[2] күтәреп, байракчы А р г ы н, аннан И д е г ә й керәләр. Идегәй элек ишектәге Аңгысын белән Тыңгысынга карый, күз кыры белән исәнләшә. Аннан туры ханга юнәлә. Туктамыш хан, үзе дә сизмәстән, урыныннан сикереп тора. Киеме тәхеткә эләгеп кала.

И д е г ә й. Сәлам, олуг хан!

Я н и к ә. Эһем!

Т у к т а м ы ш *(гаебен сизеп, ык-мык итеп утырып)*. Хуш... Хуш кайттың, Кобогыл би! Сөйлә! Ханияңә нинди җиңү китердең?

---

[1] *Каган* — ханнар ханы, олуг хан титулы. Гарәп язуында «хакан» рәвешендә языла.

[2] *Ту (туг)* — ат кылыннан, уртасына ай куеп ясалган байрак.

Идегәй. Каган! Кулыма биргән гаскәрең барлыгы ун мең кеше иде. Исән-аман юл йөрттем. Дауны кансыз бетереп, кызыңны да исән китердек. Кырым юлы ачылды, беренче сәүдә кәрваны артыбыздан килә, падишаһ!

Туктамыш. Кәрван килә, дисең?

Биләр *(йөзләре ачылып, сакалларын сыйпап)*. Һай, бәрәкәт, бисмилла! Базар була, мал килә!

Туктамыш. Ярый, миңа җавап бир: ул фетнәче халыкны ник идегәйче дип атыйлар? Кем соң ул Идегәй?

Тыңгысынның кулындагы сөңге ава башлый. Аңгысын аны тотып кала, Тыңгысынга кире тоттыра.

Идегәй *(күкрәгенә кулын куеп)*. Әлепбай, падишаһ!..

Туктамыш. Әйтә алмыйсың, Кобогыл? Заты Чыңгыз кардәшем Кырымдагы баскагым Төлкетимер ир икән, аны ни өчен яптырдың?

Идегәй. Заты Чыңгыз баскагың Төлкетимер кардәшең, тамга малын[1] угырлап, үз казнасын баеткан. Дау сәбәбе шул икән. Ясак хөкеме буенча, аны тотып яптырдым. Алты арба алтынын казнагызга алдырып, аны да бергә алып кайттым. Үзең тот, падишаһ... *(Читкә.)* Җитешә алсаң!..

Туктамыш. Алты арба алтынын? Кардәшемнең казнасын? Ничек кыеп алдың, Кобогыл? Үземнең куйган хөкемемне үз затыма каршы кулландың? Хәзер кире...

Җанбай *(колагына)*. Алты арба бит, ханиям... казнагызның хәле үзегезгә мәгълүм...

Туктамыш *(уйланып)*. Ул да дөрес. Сугышыр өчен, казна кирәк. *(Төпле бер карарга килеп.)* Ул чагында... Алты арба! Аны без тотып торыйк! Баскакның эшен карарбыз. *(Идегәйгә.)* Җантимер улы Кобогыл! Бу хезмәтең каршына дәрәҗәң тагын зур булсын: гаскәремнән бушатып, сиңа хөкем эшемне тапшырам... Яныма сул би булырсың!

Җанбай *(Арсланга)*. Гаскәр китте кулыннан!

Идегәй. Ярлык сездән, падишаһ! *(Ханның сулыннан урын ала.)*

Тышта тавыш.

Янбулат тавышы. Җибәрегез! Яки мин сезне...

Тавышлар. Тот, тот! Каер кулын, каер!

Туктамыш. Кем ул? Җибәрегез үзен!

Кулы бәйләнгән Янбулатны, кертеп, хан алдына ташлыйлар.

---

[1] *Тамга малы* — читтән керә һәм чыга торган товарларга тамга сугып җыела торган салым (таможня). Алтын Урда зур сәүдә юлларында ятканлыктан, бу салымның килере бик зур булган.

Туктамыш. Сөйлә, кем син?

Янбулат. Мин — бер сукачы. Атым — Янбулат.

Туктамыш. Кара сәяк? Ничек син ханиянң алдына басып керергә кыйдың? Йә?!

Янбулат. Сакчыларың җибәрми... Мин бер атнадан бирле каршыгызга керә алмый йөрим, олуг хан!

Туктамыш. Ни кирәк сиңа миннән?

Янбулат. Мин Болгар җиреннән. Унҗиде авыл мине сезгә илче кылды.

Туктамыш. Илче? Минем ачуыма дучар булган илдән киләсең син! Чишегез кулын! Сөйлә!

Янбулат. Ярдәм ит, без таландык, олуг хан!

Туктамыш. Таландыгыз? Кем талый соң сезне?

Янбулат. Илне яклап таландык, олуг хан, шәфкать ит! Бер яктан князь безне килеп баса, икенче яктан сезнекеләр үк безне талый, олуг хан! Казан таланды. Саба янды. Ибраһим каласы бетте. Әле тагын князьдән качкан юлбасарлар төшеп, унҗиде авылны талап, яндырып киттеләр, олуг хан!

Туктамыш. Ярый. Без князьгә әйтербез. Ул юлбасарларны тотып бирер.

Идегәй *(читкә)*. Бирер микән, ай-һай!

Янбулат. Салымны чигер, безне һәлак итмә, олуг хан!

Туктамыш. Болгарда минем баскагым тора. Аңа барыгыз.

Янбулат. Баскак? Мәрхәмәт ит, баскак үзе безне талый, бездән кол җыя! Сез безгә үз халкыбыздан гаскәр тотарга әмер бирегез, олуг хан!

Туктамыш. Ай-һай! Син безнең әмеребез өстенә сөйлисең? Менә ул!

Янбулат *(күреп)*. А-а, ул үзе дә бире килеп җиткән!

Казыйхан. Фетнәче ул! Халыкны сезгә салым түләмәскә котыртучы ул, ханиям!

Туктамыш. Күрәм: бу да шул идегәйче? Сөйлә: беләмсең син аны?

Янбулат. Идегәйнеме? Беләм, ник белмәскә!

Туктамыш. Ишетәмсез, ул аны белә! Кайда соң ул хәзер?

Янбулат. Кайда? Анысын каян белим мин! Хозыр[1] галәйһиссәламнең кайда икәнен кем белгән?

Туктамыш. Хозыр? Ничек ул Хозыр?

Янбулат. Шулай... Тере суы эчкән! Теләгән кешесенә күренә, теләмәгәнгә күренми. Ул бит Төкле-Чәчле әүлия нәселеннән! Котлыкыя углы.

Туктамыш. Нәрсә сөйли ул?

---

[1] *Хозыр* — бәла-каза килгәндә ярдәм итә торган, тере суын эчкән бер пәйгамбәр исеме.

Җанбай. Ни дәрәҗәдә аңгыра! Күрәсең, ул Котлыкыяның бөтен бала-чагасы белән әллә кайчан ук сезнең хөкемегез буенча чабылган икәнен дә белми, ханиям!

Туктамыш. Әйе. Аксак Тимергә сатылган ул нәсел — юк!

Янбулат. Ник булмасын? Бар! Без аңа сыенабыз.

Туктамыш. Ә?! Сыенасыз? Кемнән сыенасыз?

Янбулат. Кемнән дип... Кем явызлык тидерсә, шуннан. Юлбасардан, менә баскактан...

Туктамыш *(гаҗәпкә калып)*. Баскактан? Ха-ха! Бәлки, син аның догасын да белә торгансыңдыр? Әйтеп бир!

Янбулат. Беләм. *(Күкрәгенә ике кулын кысып, югары карап.)* «Әй Идегәй! Аты юкка ат булган, адашканга юл булган, ялгызга ясак, җәяүгә таяк булган Идегәй, үзең коткар!»

Туктамыш. Ничек? Минем илемдә ниндидер бер фетнәче Идегәй яши? Шушындый байгыш аңа дога кыла! Җилкәләп чыгарыгыз үзен! Илче, имеш! *(Янбулатны чыгаргач, Идегәйгә.)* Кобогыл! Хөкем эше синдә! Шул Идегәйне миңа табып тотып бирәсең!

Идегәй. Каган! Әгәр дә ул Идегәй дигән кеше, чыннан да, дөньяда бар булса, тиздән син аны үз күзең белән күрерсең!

Туктамыш. Яхшы. Ханәш, ни фикердә?

Янике. Кобогыл бигә сусын бирелсен!

Туктамыш *(залга)*. Безне калдырыгыз!

Чыгалар. Идегәй, Туктамыш һәм Янике калалар. Җария сусын китерә. Янике аны, алып, Идегәйгә суза.

Идегәй *(алып, Аңгысын белән Тыңгысынга карый. Аннары кечкенә хәнҗәрен биленнән алып, аның белән болгатып, эчеп җибәрә. Яникәгә.)* Иләмле икән иләгең, куксымый[1] микән чиләгең? *(Җамаякны бирә дә чыга.)*

Туктамыш *(Яникәгә)*. Йә?

Янике. Йә? Менә күрдеңме Кобогылның өрәген?

Туктамыш. Мин аны гаскәр башлыгыннан төшердем.

Янике. Ярый, күрдеңме соң кымызыңны ничек эчкәнен? Пычагы белән болгап, сиңа дошманлыгын күрсәтеп эчте түгелме соң?

Туктамыш. Дошманлык?

Янике. Әйе шул! Дус булса, пычагының сабы белән болгар иде. Безен сиңа каршы тотып болгап эчте бит!

Туктамыш. Моны ул уйлап тормаган, син уйлап чыгарган!

Янике. Ярый, мин моны уйладым, ди. Күрдеңме син ничек болгавын?! Пычак белән башта дүрткә кисте түгелме?

Туктамыш. Киссә!

---

[1] *Куксымый* — исләнми.

Я н и к ә. Киссә, шул: синең илеңне дә шулай кисәрмен дигәне аның! Уртасын болгаса, Болгар белән Сараеңны да шулай итеп болгармын дигәне аның! Белдеңме?

Т у к т а м ы ш. Ырым! Ырым!

Я н и к ә. Аны да ырым диген, йә ярый. Иләк-чиләк дигәнен, анысын кая куясың?

Т у к т а м ы ш *(ачулы)*. Анысы тагы ни?

Я н и к ә. Анысы шул: олы кызың Ханәкә, кече кызың Көнәкә; берсен иләк дигәндә, берсен чиләк диюе. Берәвен углым тиң күрсә, аңа сакла диюе.

Т у к т а м ы ш. Кобогыл улына хан кызы? Минем кызым? Шуларның барын да Кобогыл әйттеме? Юк! Хатын-кыз мәкере шундый нечкә җептән тукылган, без, ирләр, аңа уралып бетсәк тә сизмибез. Син, ханәш, көнче! Җантимер улыннан, шуның кечкенә даныннан мине көнлисең! Ә мин аның янында бүген коралсыз йөрим. Әгәр дә ул миңа яу булса иде... юк, юк! Бу мөмкин түгел!

Я н и к ә. Яу юк димә — яр астында, бүре юк димә — бүрек астында, ханиям! Мин әйттем дә беттем, бәлки, ул, чыннан да, синең яхшы кешеңдер. Син аның алдында аягыңа торасың... Миңа барыбер! *(Чыга.)*

Т у к т а м ы ш *(чагылып)*. Юк! Бу сиңа барыбер, миңа барыбер түгел! Йа Тәңре! Мин Аксак Тимергә каршы җыенам! Шушындый вакытта илемдә Идегәй, кулымда Кобогыл! Аның алдында мин аягыма торам! Кем ул? Әйтегез, керсен Җанбай!

Җ а н б а й *(керә)*. Боер, ханиям. Мин монда.

Т у к т а м ы ш. Бер сүз белән әйтеп бир миңа, Җанбай: Кобогыл кем?

Җ а н б а й. Кобогыл кем? *(Читкә.)* Менә эләктем! *(Туктамышка.)* Башта көтүче иде. Аннан ул батырлыгы һәм хөкемнәре белән халык эчендә бик дан тота башлагач...

Т у к т а м ы ш. Синең киңәшең белән, мин аны сараема алдым. Юк, син аны миңа сөйләмә. Син әйт: Кобогыл кем?

Җ а н б а й. Синең киңәшчең Җантимернең ятим улы...

Т у к т а м ы ш. Ятим угыл... Йа Тәңре! Бәлки, ул Җантимер улы да түгелдер? Мин аны даладан алдым. Син дәшмисең?

Җ а н б а й. Ул чагында, ханиям, син дә белмәс эш икән, мин дә белмәс эш икән! Алай да бер сүз булсын: Алты суның буенда йөз туксан биш яшәгән Субра дигән бер карт бар. Җырчы дисәң — ул җырчы, сынчы дисәң — ул сынчы. Адәмнең йөзенә карый да кем икәнен җырлый да бирә икән, ди. Кобогылның аслын ул белмәсә, кем белер?

Т у к т а м ы ш. Субра? Әйе. Ул карт турында мин күп ишеттем. Илемдә шундый бер карт бар икән, мин аны күрергә тиеш! *(Үзалдына.)* Ә бәлки, ул миңа синең дә кемлегеңне әйтеп бирер!

(Аңа.) Әйт чабарга[1]: алып килсен миңа шул Субраны!.. Килсен, күреп багыйк! *(Чыга.)*

Җанбай *(ялгыз)*. Кобогыл... Күптән шикләнәдер идем мин. Димәк, бу шул... үзе! Минем дәрәҗәмне дә кисәргә йөрүче Идегәй! Төштең кулыма! Ничек тәмләп эчәрмен хәзер мин синең каныңны. Ләкин сине коры кул белән генә тотып алу мөмкин түгел, сине үзегезнекеләр кулы белән тотарга кирәк. Мин дә Субраны чакырттым. Әйе. Ул карт анда далада тыныч кына Идегәйне мактап, думбра кагып ятмасын, килсен, җырын хан алдында җырласын! Һәм шул чагында тугыз батырның кылычы берьюлы Идегәй күкрәгенә кадалачак! Бас, Җанбай! Алай да сак бул: арыслан белән юлбарыс арасына төштең, тиреңне алдырма! *(Чыга.)*

Сәхнә III

Сарай шәһәре. Коллар базарының бер башы күренә. Кул-аяклары бәйле ирләр, хатыннар, балалар. Алар арасында Килмәт карт белән кызы Чулпан.

(...) Янбулат *(керә)*. Юк! Бу мөмкин түгел! Базарның очыннан очына чыга алмыйм! Өч йөз кеше! Бөтен Зөя буен сөреп китергәннәр! Бар да бәйле! Бар да таныш! Бөтен илебезне бәйләп саталар! Җитмәсә, кызлар, балалар!.. Тукта! *(Чулпанны күрә.)* Мин ни күрәм? Чулпан!

Чулпан *(аны күреп)*. Янбулат!

Янбулат *(бәреп керә)*. Чулпан? Ничек? Син — кәнизәк?

Чулпан. Юк! Бу хурлыкка мин түзә алмыйм! Йә мине коткар, йә мине үз кулларың белән бу, Янбулат!

Янбулат *(аны кочып)*. Юк, юк! Тукта! Елама! Исемә килим! Әтиең дә бире!

Килмәт. Күрәсең, хайван көненә калдык, энем. Үзем өчен дә кайгырмыйм, кыз әрәм! Кыз сатыла, кыз!

Янбулат *(сакчыларны этәреп)*. Юк! Мин моңа юл куя алмыйм!

Чулпан. Өз минем җепләремне! Бир пычак, кисеп чыгабыз, Янбулат!

Казыйхан *(килеп чыга. Чулпанны төртеп җибәреп, Янбулат каршына басып)*. Кая киләсең? Бу кем? *(Танып.)* Ах, синмени минем өстән йөрүче? Синең кәләшең сатыламыни? Кызганам! Өч йөз генә тора ул. Бәлки, сатып алырсың? Ә бәлки, кызы урынына атасын гына алырсың? Ул бер йөз генә тора? Ал! Ха-ха-ха!

Янбулат. Җибәрегез! *(Ташланмакчы була.)*

Марук *(аны тотып)*. Эшеңне бозасың гына, егет!

---

[1] *Чабар* — курьер.

Башмакчы. Бар әнә Саррафка! Сорап бак бурычка!

Казыйхан. Барып сал күлмәгеңне! Сарраф сиңа өч алтын бирмәсме? Хәерче!

Янбулатның ике ягыннан тотып акрын-акрын артка чигендерәләр. Казыйхан, кылыч сабына кулын куйган килеш, аның йөзенә текәлеп карап берничә атлаганнан соң, шаркылдап көлеп, борылып китә. Тимерче белән башмакчы Янбулатны Сарраф кибете алдына китерәләр.

Янбулат *(Саррафка туктап, тынып)*. Сарраф! Миңа бурычка дүрт йөз акча бирәсең!

Сарраф. Дүрт йөз? *(Чөйдән бер янчыкны алып.)* Дүрт йөз генәме? Менә ул. Рәхим ит! *(Алга сала.)*

Янбулат. Син миңа... бирәсең? *(Сузыла.)*

Сарраф *(янчыкны алдан басып)*. Мөддәт?

Янбулат. Мөддәт?

Сарраф. Әйе. Күпме мөддәт белән?

Янбулат. Бер ай! Бер атна! Мине тотма, кәләшем сатыла минем, Сарраф!

Сарраф. Акрын, егет. Акча алу — хатын алудан нечкәрәк эш. Бер ай мөддәт белән булса, син миңа мең сум итеп түләрсең. Бер атна мөддәт белән булса...

Янбулат. Риза! Китер! *(Сузыла.)*

Сарраф *(янчыгын басып)*. Рәһен[1]?

Янбулат. Рәһен? Нинди рәһен?

Сарраф. Әйе, рәһен. Нәрсәңне саласың син? Җиреңнеме, малыңнымы?

Янбулат. Җирем дә, малым да юк, җен алгыры! Мин сиңа ничек тә табармын, түләрмен!

Сарраф. Табарсың! Акча — таш астында, таш — аждаһа башы астында, егет! Ничек син аны табарсың? Урласаң — асылырсың, таласаң — чабылырсың! *(Кире элеп куя.)*

Янбулат. Аңлыймсың, карт, минем кәләшем сатыла! Җаның бармы синең? Коткарыш аны, атам бул, мөселманлык ит!

Сарраф. Рас әйттең, егет! Мөселманны коткару — мөселманның бурычы! Рәхим ит! Ул чагында үз башыңны рәһенгә салырсың!

Янбулат. Ничек? Үз башымны? Мин? Димәк, шул мөддәт эчендә түли алмасам, мин синең колың булам? Мөселманны коллыктан яхшы коткарасың син!

Мәчеттән Идегәй белән Дәрвиш чыга. (...)

Янбулат. Ярый. Мин аңа да риза. Китер акчаңны!

Сарраф. Яхшы. Вәкилең кем булыр?

---

[1] *Рәһен* — залог, заклад.

Я н б у л а т. Юк. Син, чынлап та, тычкан белән уйнаган мәче шикелле, минем белән уйныйсың. Күрәм: син моннан тәм табасың! Нинди вәкил?

С а р р а ф. Мин сине белмим. Бәлки, син акчамны алырсың да бикәчең белән качарсың. Синең өчен кем вәкил булыр?

И д е г ә й *(алга чыга).* Мин вәкил булырмын!

С а р р а ф. Кобогыл би үземе? Бик яхшы. Рәхим ит. Кулыңны куй.

И д е г ә й. Китер!

С а р р а ф. Онытма, би: әгәр дә бу егет бер атна эчендә түли алмаса, үзе яки бикәче минем иркемдә булыр. Инде Кобогыл да миңа түли алмаса...

И д е г ә й. Мин синең иркеңдә булырмын! Мине сатарсың! *(Кул куя.)* Китер!

С а р р а ф *(кәгазьне алып, акчаны тотып).* Менә акча. Мин аның аша атлап чыга алган батырны әле күрмәдем, би! *(Бирә.)*

И д е г ә й *(янчыкны Янбулатка бирә).* Ашык, егет!

Я н б у л а т *(тезләнеп).* Кобогыл би! Бу кешелегең өчен... *(Кулын үбәргә итә.)*

И д е г ә й *(торгызып).* Кирәкми... Тор! Ашык, егет!

Янбулат колларга таба бара, Идегәй икенче якка үтә.

С а р р а ф. Һәй! Кешелек — акча ул! Алар өчесе дә хәзер минем кулымда! *(Кибетендә югала.)*

Я н б у л а т *(килеп).* Чулпан! Килмәт бабай! Сез котылдыгыз! Әй! Чишегез аларны! Кайда Казыйхан?

Ч у л п а н. Ай, әти! Чынмы бу, Янбулат?

К а з ы й х а н *(күренә).* Кем ул? Тагын син?

Я н б у л а т. Чиш колларын! Карт белән кызны мин алдым!

К а з ы й х а н. Акча китердең? Кара син байгышны! Хан салымына булса — акча юк, кәләшенә дигәндә таба! Ах эт! *(Халыкка.)* Хөрмәтле биләр! Сәүдәгәрләр, бу кызыйга күз салыгыз! Кулы белән — эшче. Авызы белән — җырчы. Аягы белән — биюче. Байга —җария, хатынсызга — хатын, баласызга — асрау. Өч йөз акча. Кем арттыра? Юкмы? Кем арттыра? Юк? Өчкә чаклы саныйм: бер, ике... кем арттыра? Өч!

Я н б у л а т. Минеке! Ал акчаңны! Мә! *(Ыргыта.)*

К а з ы й х а н. Синеке, эт! Ләкин бит бер ай да үтмәс, кәләшең белән бергә янә шушы басмада сатылырсың!

Т а в ы ш л а р. Коткарды! Кәләшен коткарды! Менә егет! Әй, әй! Кем ул! Карагыз анда, Шәйхемисрый килә! Өлгерә алмады! Күрегез ничек мышнаган. Ха-ха-ха!

Ш ә й х е м и с р ы й *(бай, калын адәм).* Кайда ул? Туктачы, карыйм! Шушы кызыймы? Болгарыйлымы? Әссәламегаләйкем бирәхмәтулла! Өч йөзме? Мин өч йөз илле бирдем!

К а з ы й х а н. Өч йөз илле! *(Янбулатка.)* Кыздан кулыңны ал, егет!

Т а в ы ш л а р. Хәрәмли, хәрәмли! Кул сугылган, эш беткән! Җибәрмәгез әле кызны шул карунга. Әй! (...)

К а з ы й х а н. Менә күрәсез: Шәйхемисрый миннән бүген илле кол алды. Тагын ала. Миңа хак арттыра ул!

Т а в ы ш л а р. Шам базарына илтә бит ул аны! Сугып ал, егет, җибәрмә!

М а р у к *(түбәтәен тотып, янындагыларга)*. Җибәрмибез, салыгыз, сал акча!

Я н б у л а т. Кызга дүрт йөз!

Ш ә й х е м и с р ы й. Ак сакалым белән ант итәм, син аны ала алмассың, егет! Биш йөз!

Ч у л п а н *(башын тотып)*. Ах!

Я н б у л а т. Юк. Мин моңа юл куя алмыйм. Пычагым белән ант итәм, син аны ала алмассың, фиргавен! *(Кизәнгәне һәм Шәйхемисрыйның ауганы күренә.)*

Т а в ы ш л а р. Ай! Чәнечте! Алай кирәкмәс иде! Кыз өчен! Егет! Ай, ай! Хараплар гына булды!

К а з ы й х а н. Тотыгыз! Кеше үтерде! Бәйләгез үзен! *(Марукка.)* Ник ышыклыйсың...

Выргы.

А т а м ы ш *(керә)*. Китегез! Китегез юлдан! Олуг ханбикә Яникә килә!

Сорнай, кернай уйнатып, угланнар, алар артыннан Я н и к ә, Х а н ә к ә, К ә н ә к ә, җарияләр һәм К а д ы й р б и р д е керәләр. Халык сәламгә иелә.

К ө н ә к ә *(Шәйхемисрыйга абына язып)*. Ай, кан!

Х а н ә к ә. Юләрләнмә инде! Адәм каны күрер хәлең юк, айвай киләсең! *(Әйләнеп.)* Күрәмсең, Кадыйрбирде?

К а д ы й р б и р д е *(шатланып, кулын кулга сугып)*. Адәм суйганнар! Их! Күрми калдым!

К а з ы й х а н *(Ясавылдан бәйләтеп, Янбулатны алга чыгара)*. Менә ул! Үтерүче! Чабыгыз башын!

Я н и к ә. Ах, бу бит сарайда булган егет!

К а д ы й р б и р д е. Башын чабалар аның! Күрәбез, Ханәкә!

Ч у л п а н. Коткарыгыз аны! *(Яникәнең аягын кочып елый.)* Юлыгызда тузан булыйм, тик бер генә шәфкать сүзе әйтегез! Сезнең бер сүзегез җитә, олы ханбикә.

Я н и к ә. Тор! Шушы кыз өченмени? А, баскак. Мин синең мондый чибәр кызың бар икәнен белмәдем. *(Кулбашына кулын сала.)*

Т а в ы ш л а р. Ханбикә кулын салды!

К а з ы й х а н. Олуг ханбикә кулы тигән мал безнең иркебездә түгел. Ал аны, ханәш!

Янбулат. Ничек? Аңа акча түләнгән? Ул ирекле!

Марук. Дөрес!

Казыйхан. Акча түләнсә, атасы коткарылыр. Чишегез картны.

Килмәт. Акча кызый өчен түләнгән.

Тавышлар. Дөрес! Моңа шәригать кирәк! Хөкем кирәк!

Марук. Шушында иде, кайда хөкем башы Кобогыл би?

Идегәй. Бу ни? Үтереш? *(Янбулатка.)* Моны син кылдың?

Янбулат *(аның алдына төшеп)*. Мин! Мин үземне белешмичә үтердем! Коткар, Кобогыл!

Идегәй. Яман эш кылдың! *(Аңгысын белән Тыңгысынга.)* Илтегез аны зинданга! Иртәгә шул урында башы чабылыр!

Марук *(үзалдына)*. Нәрсә бу?

Янбулат *(сикереп торып)*. Синең дә хөкемең шулмыни? Син? Минем өчен вәкаләт бирүче! Их сез! Сез барыгыз да бертөсле! Еланнар! Нәләт сезгә!

Аны алып китәләр.

Чулпан. Минем өчен үтерелә. Юк! Алыгыз мине, үтерегез аның өчен!

Кадыйрбирде. Нык тотыгыз! Ычкына алмассың, чая кыз! Юл бирегез, әй! Әй! *(Чыгалар.)* (...)

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәхнә I

[Бу күренештә вакыйга шәһәр читендәге бакчада төнлә бара. Монда Идегәй яклылар яшерен җыелалар. Янбулатны да китерәләр. Үзен җәзалап үтерергә алып килделәр дип уйлаган егет Кобогыл бине каһәрли, ләкин аның Идегәй булуын, үзен коткаруын белә. Ул да азатлык сугышына катнашачак. Идегәй үз фикердәшләренә — алар арасында Нугайби дә, Килмәт карт та, Марук та, Аңгысын белән Тыңгысын да бар, — хәлиткеч сәгать сукканын әйтеп, көрәшкә әзер булып торырга куша, һәрберсенә эш йөкли.][1]

Сәхнә II

Хан сараенда бер бүлмә. Ишектә **Тыңгысын**. Бер яктан **Яникә**, **Ханәкә**, **Кенәкә** һәм **кызлар** керәләр. Каршыдан бер **җария** йөгермә[2] белән кереп Яникә алдына йөгенә.

Яникә. Киендереп беттегезме? Бире чыксын, күрим.

Җария ишеккә бара да аннан **Чулпанны** җитәкләп килә. Ул сарайча киенгән.

---

[1] Кыскартылган өлешләрнең эчтәлекләре хрестоматияне төзүчеләр тарафыннан бирелде һәм җәяләр эченә [ ] алынды.

[2] *Йөгермә* — вак йөгерү.

Я н и к ә. Карагыз аны! Киендергәч, нинди булган!

Һәммәсе дә соклана.

К ө н ә к ә *(Ханәкәгә)*. Кара, нинди сылу!

Х а н ә к ә. Нәрсәсе бар? Фи! Кием!

К ө н ә к ә *(читкә)*. Сиңа ошамас инде.

Арттан сиздерми генә Кадыйрбирде килә, Чулпанның чәченнән тарта.

Ч у л п а н. Ай!

Я н и к ә. Ни булды?

Ч у л п а н *(әйләнеп)*. Әйтегез аңа, ханбикә, чәчемнән тартмасын ул!

Я н и к ә. Тартса ни булган! Бит хан кызы түгелсең!

К а д ы й р б и р д е *(көлеп)*. Кара сукачы кызын, ә! Тәти күлмәк кигәч тә, ничек назлана!

Х а н ә к ә. Ярабби! Аның белән хан углы сөйләшә. Тез дә йөгенә белми!

К а д ы й р б и р д е *(җарияләргә күрсәтеп)*. Бусының ире бар. Бусын да анай кияүгә бирде... *(Чулпанны күрсәтеп.)* Бусының гына ире юк икән. Миңа бирәсеңме аны?

Көлү.

Я н и к ә. Йә бар, ул әле яңа килгән, оялтма. Өлгерерсең...

К а д ы й р б и р д е. Әйе. Берсенә тотып бирерсең әле.

Я н и к ә. Бик бәйләнсәң бирермен дә!

К а д ы й р б и р д е. Кемгә?

Я н и к ә. Кемгә булса да. Менә Тыңгысын басып тора. Ул да хатынсыз. *(Чулпанга.)* Нәрсәгә йөзеңне япкан буласың син? Ач! (...) *(Кычкырып.)* Тыңгысын!

Тыңгысын алга чыга.

Син — буйдак. Сараебыз йоласы буенча, син буйдаклыктан чыгасың. Мин Чулпанны сиңа бирдем. Ал аны.

Ч у л п а н. Ай! Моңа риза булганчы, муеныма пычак салганым артык!

Т ы ң г ы с ы н *(тезләнеп)*. Гафу боер! Мине коткар бу никахтан, олуг ханбикә!

Я н и к ә. Ничек? Әле син безнең биргән бүләгебездән баш тартасыңмы? Таякларга кирәк сине!..

Т ы ң г ы с ы н. Олуг ханбикә!

Я н и к ә. Тор! Чыгыгыз! Анда сарай мулласы никах укыр!.. *(Чыга.)*

К ы з л а р. Шундый кыздан баш тарта! У!.. Бәхетеннән шашкан кол! Ха-ха-ха! *(Аларны алып чыгалар.)* (...)

И д е г ә й белән А ң г ы с ы н керә.

Идегәй. Син яхшы ишеттеңме? Субра монда Җанбай киңәше белән китереләме?

Аңгысын. Әйе.

Идегәй. Ах, эт Җанбай! Димәк, ул безнең әзебезгә төшкән. Беләм: ул мине үз кулы белән тотып бирергә безнекеләрдән курка! Мине үзебезнең Субра кулы белән ханга тотып бирмәкче була! Кара, Аңгысын! Субра мәҗлеснең чамасына карап җырлар. Эшнең кая барганын миңа җырында сиздерер... Абайлап тор! Әгәр дә мин тамак кырсам чык та батырларның ияр бауларын кис! Минем Тимчуар атымны гына калдыр. Аңладыңмы? Бар!

Аңгысын. Аңладым. *(Чыга.)*

Идегәй *(ялгыз)*. Артык ышаныргә мөмкин дә түгел. Алай да мондый вакыйганың башыннан төшеп калмаска гына кирәк! (...)

Тыңгысын керә. Идегәй Тыңгысын белән чыга. Аңгысын ишектә кала. Туктамыш хан керә.

Туктамыш *(туктап, тыңланып)*. Бу нинди шау-шу?

Аңгысын. Субра җырчы сарайга җитеп килә, олуг хан!

Туктамыш *(тәрәзәгә якын туктап)*. Субра, әйе. Минем алтын арбамда ул килә. Алды-арты халык... Бар, чык! *(Аңгысын чыга.)* ...Бер кара сөяк җырчыга шулкадәр алкыш! Кем соң ул? Шагыйрь! Әнә ул килә. Нинди куәт бар соң аның кулында? Тел! Шагыйрьнең тавышы көчле. Моннан кычкырса, Әстерханга ишетелә. Мин аларны үз гомеремдә бик күп күрдем. Алар безне урынлы да, урынсыз да мактыйлар. Шуның каршына зур бүләкләр өмет итәләр. Шулай да шагыйрь вакытлы кычкыра белсә генә яхшы. Вакытсыз кычкырган әтәчне суеп ашыйлар!

Аңгысын әйләнеп керә.

Йә? Ник керми ул?

Аңгысын. Ул арбасыннан төшми, ханиям!

Туктамыш. Соң?

Аңгысын. Ул әйтә, олуг хан мине үзе ат җибәреп алдырса, үзе чыгып каршы алсын, шулай булмаса, мине кире илттереп ташлатсын, ди.

Туктамыш. Ай-һай! Мин шагыйрьләрнең тулаем әрсез халык икәнен беләм, алай да бу чаклысын күргәнем юк иде... Ярый. Мин аны чыгып каршы алыйм. Инде дә ул минем көткәнемне бирмәсә, телен тиштереп, җеп тагып, урам йөрттерәчәкмен! *(Ишеккә туктап.)* Һа! Менә ул! Хуш киләсең, карт!

Бер кулын Идегәй кулбашына таянып, бер кулына саз тоткан Субра керә. Бик мәһабәт, көмеш сакаллы.

Идегәй. Боер, картым. Бу — Туктамыш хан.

Субра, Туктамыш дигәндә аңа әйләнә төшеп, баштанаяк бер карый да, баш ишарәсе белән исәнләшеп, янынннан түргә узып китә.

Түшәк бирегез картка! *(Түшәкләр салына.)* Утыр, газизем!

Т у к т а м ы ш *(гаҗәпләнеп карап тора).* Һа! Кара син аны, ул нинди карт! Бөтенләй көмеш ука шикелле. Мин аны бу чаклы булыр дип уйламаган идем. Сусын!

Ишектән бер-бер артлы биләр керәләр. Алар белән Җанбай, Арслан, Казыйхан, Аргын һәм Нугайби. Алар, үтеп әйләнеп, паласка утыралар. Нөгәр бер аяк кымыз алып кереп, бер тезенә чүгеп, Субрага сона. Субра алмый.

Т у к т а м ы ш *(Җанбайга борылып).* Ул сусын алмый!

Җ а н б а й. Үз кулың белән биреп бак, ханиям!

Т у к т а м ы ш. Шулаймы? Бер өлкән картым икәнсең, боер! *(Бер тезен чүгеп, иренենә илтә.)*

Субра, бер-ике йотып, кире этәреп, алырга ишарә итә.

Сөйлә, картым. Юл бик ватмадымы? *(Әйләнеп.)* Чукракмы әллә ул? Берни дә сөйләми. Чишегез яңагындагы бавын!

Җ а н б а й. Юк, олуг хан. Без ул бауны яңагы төшмәсен өчен бәйли дип ишетәбез. Кымызыңны ул алмады. Үз кулыңнан бер аяк бал биреп кара, ханиям.

Т у к т а м ы ш. Яхшы. *(Идегәйгә.)* Кобогыл би! Бал чапчагын кертсеннәр! Үзең аякчым булырсың! *(Идегәй чыга.)* Җанбай! Арслан! Биләрем! Бу карт хәзер миңа, Кобогылны сынап, җырлап бирергә тиеш. Абай булыгыз, әгәр дә ул миңа аның дошманлыгын ачса, пычакларыгыз җиң очында әзер торсын! Төшендегезме?

Б и л ә р. Төшендек, ханиям.

Нөгәрләр ишеккә якын кертеп, бал чапчагын утырталар. Җамаяклар китерелә. Идегәй кереп утыра. (...) Кулдан-кулга бал җамаяклары китә. Туктамышка килеп җиткәндә, ул аны Субрага суза. (...) Субра, кулы белән барысына да эчәргә ишарә итеп, үзе эчеп җибәрә...

Т у к т а м ы ш. (...) Моны яхшы ала икән карт. *(Янында торган сазны алып, Субрага бирә.)* Кулыңда сазың уйнаган, телеңдә сүзең уйнаган ил өлкәне Субра би, мәҗлес сиңа тәрәлде. (...) *(Өстеннән туның салып, Субра җилкәсенә сала. Үз кулыннан янә бал бирә.)*

Кара самур тун сиңа,
Үз кулымнан бал сиңа.
Аны да кара, җыручым,
Каршымда ике ирем бар.

(Җанбай белән Идегәйгә ишарә кылып.)

Берсе монау, берсе ул,
Шуларның ни ир икәнен
Җырында әйтеп бирсәңче!

Җанбай *(үзалдына)*. Ничек? Хан мине дә сыныймы?

Субра *(бармагы белән ишарә кылып, Җанбай белән Идегәйне каршына чакырып ала. Аларга бал тотып.)*

Яхшы пешкән сары бал!
Ике яхшы бергә килсә,
Таныштырган сары бал.
Ике яман бергә килсә,
Сугыштырган сары бал.
Ике сукыр бергә килсә,
Күрештергән сары бал.
Сары балны кем эчәр?
Хан өлеше сары балны
Кайсыгыз батыр — ул эчәр.

Җанбай Туктамышка карап ык-мык итә. Идегәй алып эчә. Гомуми гаҗәпләнү.

Субра *(җамаякны кире алып)*.

Яшә, батыр икәнсең,
Туйга барсаң, борын бар,
Ишек төптә урын бар...
Борын бар да борын кайт,
Атаң белер мәгънәсен!

Идегәй *(ишарә белән)*. Әһем! *(Аңгысынга.)* Әйт, яңа чапчакны ачсыннар! *(Ишек төбенә утыра. Аңгысын чыга.)*

Туктамыш. Әйтеп җибәр, җыручым.
Без дә белик мәгънәсен.

Субра *(сазын алып)*.

Каршыңда торган ике ир,
Берсе аның бу угыл. *(Җанбайга ишарә кыла.)*
Янтая биреп утырган,
Куштан булыр шул угыл.
Кәмалның углы киң Җанбай,
Сүзгә чичән ир Җанбай
Киңәш бирер картларга;
Яуга чыгар ятларга;
Бездән дәүран[1] үткәндә,
Та[2] кем калды ханнарга!

Җанбай *(үзалдына)*. Һай, мин сине, карт әрәк, үз башыма китерттем!

Субра *(Идегәйгә карап)*.

Аргы угыл да бирге угыл,
Шул читтәге Кобогыл,
Күкрәге киң, биле нык,

---

[1] *Дәүран* — дәвер.
[2] *Та* — ахыр чигендә.

Батыр икән шул угыл.
Үзәге нык, күзе нык,
Татар икән Кобогыл.
Ирне юка күренә,
Чичән икән Кобогыл;
Куллары ипле күренә,
Мәргән икән Кобогыл!

Б а р ы д а *(көч биреп)*. Һай ир!

Т у к т а м ы ш *(бал биреп)*. Янә берне ал, картым. (...)

С у б р а *(дәвам итә)*.

Бу шул инде Кобогыл!
Ач көзәндәй бөгелеп,
Ач бүредәй чыелдап,
Ачы сөрән салыр[1] ул,
Алтыннан суккан ак урдаң,
Көмештән суккан ишегең
Бер бәрүдә ачар ул.
Кисмә-кисмә алтының
Кисеп илгә чәчәр ул;
Картайганда аямый,
Сине дә, әй хан, басар ул!

Т у к т а м ы ш. Тукта!

С у б р а *(ишетми. Күтәрелә төшеп)*.

Кол базарың туздырып,
Колдан вәзир куйдырып,
Комга баткан чүлеңне,
Коедан сулар койдырып,
Гөл сахрасы ясар ул!

Т у к т а м ы ш. Ничек?

С у б р а *(дәвам итә)*.

Син аны чабыйм дисеңме?
Чабылмас ул синнән, хан.
Син аны тотыйм дисәң дә
Тоттырмас ул Кобогыл!
Син аны ектым дигәндә,
Торып басар Кобогыл.
Син аны тоттым дигәндә,
Сикереп качар Кобогыл!

Т у к т а м ы ш. Әйтеп бир, әйтеп бир, кем ул Кобогыл?

С у б р а. Инде мин кеше танымам,
Әгәр дә мин танысам,
Котлыкыя би углы
Идегәй — бу Кобогыл!

---

[1] *Сөрән салу* — яуга чакырган аваз.

Бары да. Аһ! (...)

Туктамыш *(торып, Идегәйгә сөзелеп бара).* Идегәй? Котлыкыя улы? Ничек? Аксак Тимергә минем лачынымның токымын озаткан хыянәтче Котлыкыя улы Идегәй, син? Син чабылмый калдың? А! Хыянәтче нәсел! Бөтен фетнәләр башы син — Идегәй! Син мине чабарга җыендың? Тотыгыз! Мин эзләгән Идегәй — шул!

Бары да сикереп тора, шым гына аңа елыша.

Идегәй *(янындагы сакчының кылычын тартып алып).* Әлбәттә! Ә син ничек уйладың? *(Кылычын айкый да ишектә юк була.)* (...)

Туктамыш. Хыянәт! Бу алдан уйланган! Тукта! *(Субрага.)* Барын да белгән син булдың! Аңа качарга син ишарә кылдың! Әһә! Идегәйчеләрнең бер башы син, карт? Алыгыз аны! Илтегез зинданга! Сез, батырлар... төшегез артыннан!

Бары да чыгалар. Барабан, тавыш. (...)

Пәрдә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәхнә I

Хан сарае. Туктамыш ханның йокы бүлмәсе алды. Кич. Түшәмдә кандил. Пәрдә ачылганда, моң гына музыка ишетелеп тора. Сәхнәдә Җанбай, Аргын, Арслан. Төшенке тынлыкта утыралар. Коллар һәм кәнизәкләр аяк очына басып кына хезмәт итәләр. Алар арасында Чулпан. Атамыш шым гына кереп иелә, Җанбайга хат тапшыра.

Яникә *(уңдагы калын чаршауны ачып чыга).* Тсс! Йоклады!

Музыка туктый.

Аргын. Көчкә! Өч төн бит инде, үзе дә йокламады, безгә дә тынгы бирмәде. (...)

Җанбай *(хатны ачып).* ...Болгар алынган! Кадыйрбирде солтан кайта!

Яникә. Йа Алла!

Арслан. Димәк, бодай кайта!

Җанбай. Чыңгыз булып чыкты синең бу углың, олуг ханбикәм!

Яникә. Минем Кадыйрбирдем! Тукта, хәзер ул Янбулатны җиде юл чатына асар! *(Чулпан җамаяк белән үтә, Янбулат дигәндә, җамаяк кулыннан төшә.)* Акрын! Син нишләдең? Ханияне уяттың!

Туктамышның йокы арасында кычкыруы ишетелә. (...)

Т у к т а м ы ш *(йокы җиләне кигән, яланбаш чыга, Җанбайны селкеп).* Юк! Юк дим мин сиңа! Ялганлыйсың син, Җанбай!

Җ а н б а й. Әлепбай, падишаһым! Мин төш юраучы түгел. Әмма кем дә әйтер. Бу — хәерле төш!

Т у к т а м ы ш. Син — икейөзле маймыл! Син — арыслан сые белән симерүче күсе! Бөтен төкләреңә чаклы ялган үскән синең! Кемне алдыйсың син? Мин — ханнар ханы каган Туктамыш! Мине хатындай юатырга кирәкми! Табып китер, кайда ул шагыйрь Субра!

Җ а н б а й. Субра? Бу дөньяда юк инде ул.

Т у к т а м ы ш. Ул үлмәс карт минем базымда утыра! Алып кил үзен! Нәрсә аягыма асылынасың син?

Җ а н б а й *(бер аягын кочып).* Ул — алҗыган бер карт. Мин сиңа аның белән сөйләшмәскә киңәш бирер идем, олуг каган!

Т у к т а м ы ш. Йа Алла! Минем аякларыма бер батман ялган асылган! Миңа кемне киңәшче кылдың? Кая барыйм мин!

Я н и к ә. Юкка кызасың, Җанбаең дөрес әйтә, ханиям! Субра синең дошманың, ул сиңа ни әйтер?

Т у к т а м ы ш. Ялган дустан туры дошман артык! (...) Минем тәхетем энҗе-гәүһәрдән тукылган иде, аны Аксак Тимер Сәмәркандка күтәреп алып китте! Бүген мин өч тиенлек диванда утырам! Ә бит шул Идегәй булмаса, аксакны мин җиңгән идем! Мин — Туктамыш! Хәзер шул Идегәй белән сугышырга калдым! Ул миңа унбиш мәртәбә һөҗүм генә итте...

Җ а н б а й. Һәм соңгысында яраланып, хур булып качып китте. Син аны җиңдең, син янә — каган!

Т у к т а м ы ш. Мин җиңдем! Ул ук минем туфрагымда яши! Кайда соң ул? Тотып бир миңа шул фетнәне! Җанбай! Җанбай!..

А т а м ы ш *(керә).* Субра китерелде. *(Бер ягыннан җитәкләп, Субраны кертә, аның кулында таяк.)*

С у б р а *(таянып торганнан соң).* Әле исәнме, хан!

Т у к т а м ы ш. Субра? *(Урыныннан сикереп тора. Үзалдына.)* Ничек ул үлмәгән? Ничаклы гомерле карт! *(Аңа.)* Кил, кил, картым! Түремнән утыр! Сусын! Тукта. Бирергә бар икән. *(Ужау[1] белән җамаякка үзе сала, янындагы кечкенә урындыкка утырып, аңа суза.)* Юл булсын, картым, эч!

С у б р а *(алмый).* Рәхмәт...

Т у к т а м ы ш. Мин сине урынсызрак җәбер кылдым, карт... Беләм! Аннан бирле күп сулар акты... Мин сине сынадым, әйткәннәрең бары да килде, карт. Ләкин мин турылыкны тәкъдир дә итә беләм. (...) Тыңла, мин сиңа төшемне сөйлим... (...) Төшемдә мин ак куян тоттым. Тоттым — качырдым! Ишетәмсең? Нәрсә соң ул куян?

---

[1] *Ужау* — аш чүмече.

Субра. Дәүләт.

Туктамыш. Дәүләт дисең? Тукта. Чыңгыздан калган бу дәүләт — ул яңадан минем кулымда! Бусын әйтә белмәдең... Ярар. Шуннан шул: киләм, киләм икән, атымны кызыл балчыкка батырдым. Нәрсә булыр ул кызыл балчык?

Субра. Халкыңның каны.

Туктамыш. Халкымның каны? Ә? Булыр, булыр. Монысын әйбәт әйттең! Ләкин мин анда батып калмадым, чыктым исә, сараема килеп, зур туй бирдем...

Субра. Туй — гауга.

Туктамыш. Гауга? Тагын гауга? Тукта, мин сөйләп бетим. Туй! Ханнар-солтаннар утырган. Мин бер көмеш табакка оча[1] белән янбаш ите салып, үз кулым белән мәҗлескә чыгардым. Уртага куюым булды, һавадан кыелып бер шоңкар кошы төште дә ике итне дә эләктереп алды китте...

Субра. Шоңкар — Идегәй.

Туктамыш. Ә? Идегәй? Ничек? Ничек дидең син? Идегәй дидең син? Моны ничек әйттең син? Ә оча? Ә янбаш?

Субра. Ни диим? Алары кызларың булмасын!

Туктамыш *(тынып кала, куркып).* Син шулай дисең, карт?.. Тукта!.. Әнә... *(Тора, тәрәзәгә ишарә кылып.)* Күрәмсең ул тирәкне? Күрәмсең син? Гомерлек торган ул төшемдә җиргә егылды! Туксан икән яфрагы, туксаны да коелды!.. Баудагы кара лачыным өркеп очты һавага. Чакырдым, кире кайтмады... Моңа ни дисең янә, карт?

Субра. Ни дип әйтим сиңа, хан? Тирәк ауса, ул үзең! Туксан яфрак коелса, туксан башлы шул урдаң. Бауда торган лачын кош — тәннән чыгар татлы җан! Ул да чыкса, ни чара!

Туктамыш *(сикереп торып, йөзенә кычкырып).* Ничек? Ничек дидең син?

Яникә *(керә).* Тукта, ханиям! Нишлисең!

Туктамыш. ...Син миңа юри юрадың, ялганчы! Мин андый төш тә күрмәдем! Сыналдың, идегәйче! Алып китегез хәзер күз алдымнан бу өрәкне! Югыйсә мин аны!.. (...)

Сәхнә II

Сарай шәһәре якынында лагерь. (...)

Нугайби *(керә. Башын артка ташлап, эчен тотып, тешен агартып көлә).* Һәй, һәй! Ха-ха-ха! *(Беренче нугайга сугып.)* Йә, сөйләп бир әле үзләренә, ничек Әстерханны бастык? Җиде төн уртасында җиде башыннан ут салдык! Ә кешеләр! Кешеләр! Ха-ха-ха! Кайсы йокылы, кайсы уяулы, кайсы ишектән, кайсы тәрәзәдән! Ха-ха-ха! Ә күпме кием алдык? Күпме мал? Ә кызлар

---

[1] *Оча* — койрык сөяге. Мәсәлән, «Куян очасы кебек җиңел», — диләр.

ничаклы! Бар, эзләгез Әстерханны хәзер урыныннан! Ха-ха-ха! *(Килмәткә төртеп.)* Кызыкмы, ә?

К и л м ә т *(ачулы)*. Бик кызык!

Н у г а й б и *(кинәт көлүдән туктап)*. Уһу! Карагыз аны! Безнең сүз аңа ошамый. Нинди чытык халык бу сукачы? Әй, алып барыгыз аны минем чатырга! Бирегез аңа тары бузасын!

К и л м ә т. Тары бузасын! Син иктеңме әллә ул тарыны! Эшем иясе!

Н у г а й б и. Эшме? Эшне бездә хатыннар эшли аны! Мин — ир! Сугышчы! Атыма менеп атландыммы: һәй! Юлымда торма инде син! Намуска китсә, безне тоталмыйсың инде син!

К и л м ә т. Намус! Ә нәрсә соң ул, синеңчә, намус?

Н у г а й б и. Намус нәрсәме? Әнә Туктамыш безнең ыруның атларын басып алдымы? Хәзер без аныкын басып алабыз! Намус! Туктамыш Котлыкыяны суйдымы, хәзер Идегәй белән Нурадын аны суя — намус! Ә ни өчен сугышабыз соң? Шуның өчен түгелмени?

К и л м ә т. Шуның өчен! Фи!

Н у г а й б и. Ә нәрсә өчен йөрисең син?

К и л м ә т. Минме? Мин нәрсә өчен йөримме? *(Туфрак учлап алып.)* Менә мин ни өчен йөрим!

Н у г а й б и. Туфрак? Җир?

К и л м ә т. Әйе, җир! Аны миннән тартып алдылар! Җиремдә изге Болгар, Казан бар! Алар көл булды. Йортым кол булды. Мин аны кайтарып алыр өчен йөрим! Минем намус — Ватан! Аңладыңмы? (...)

Тыштан Чулпан тавышы: «Җибәрегез! Тотмагыз мине!»

Н у г а й б и. Тукта! Бу нинди тавыш?

Б а ш м а к ч ы. Кыз тотканнар, кыз!

Н у г а й б и. Безнекеләр тоткан! Бире китерегез аны! *(Чулпанны китерәләр.)* Каян тоттыгыз? Шәһәр астыннанмы? *(Күзен кыса.)* Кайсыгыз аңа кул салды? Синме, синме? Кулы да бәйләнмәгән.

I-н у г а й. Ул кулга бирелми!

Н у г а й б и. Уһу, кылычлы! Менә минем кулга бирелер! Кил!

Ч у л п а н. Кая биредә башлык?!

Н у г а й б и. Менә мин башлык. Кил, җаным, курыкма, якын кил! Әй, әзерләгез минем чатырны!

Ч у л п а н. Син әле мине, ханнан качып, сиңа җария булыр өчен килеп ята дип уйлыйсыңмыни? Миңа Идегәй башлык кирәк.

Н у г а й б и. Ә мин Идегәйдән начармы? Ха-ха-ха! Тимә! *(Мыекларын сыпыра.)* Минем хатыннарым күп! Син дә сыярсың!

Чулпан. Моны син әйттеңме? Миңа? Олы кешегә бер дә килешми! Мин сөйләшсәм, сине намуслы бер кеше дип белеп сөйләшәм. Менә... Менә син кызардың!

Нугайби *(читкә)*. Аның алдында мин чынлап кызарам! Юк! Бу минем хатыннар шикелле түгел!

Килмәт, Аңгысын керәләр.

Аңгысын. Җибәрегез аны!

Килмәт. Тукта, бу кем? Кызым!

Чулпан. Әти!

Килмәт. Сине дә күрер көннәрем бар икән! Һай, балам! Ике күзем!

Аңгысын. Чулпан? Шәһәрдән киләсең? Безнекеләрдән? Әйдә Идегәй янына!

Килмәт. Минем кызым ул! Ханнар тырнагыннан качып килгән ул! Әйдә, кызым, әйдә!

Чулпан, Аңгысын, Килмәт чыгалар.

Башмакчы *(Нугайбигә)*. Менә син Зөя буеның кызы, ә? Сине дә кызартты, Нугайби.

Нугайби *(аңа акрын)*. Ә беләсеңме, күпме бирер идем мин ул кызга? Миң баш елкы! *(Чыга.)*

Быргы.

Берәү. Нәрсәгә бу быргы? Кем килә?

Җанбай *(керә)*. Илчегә юл бирегез, юл!

Берәү. Йә Алла! Җанбай белән Аксәет!

Җанбай. Пәйгамбәрнең мөбарәк нәселе Аксәет каршыгызга килә! Аның аягына ханнар егыла! Егылыгыз!..

Идегәй керә. (...)

Аксәет *(Идегәйгә)*. Бисмилла... Миннән иман укыган син идең. Безнең башыбызга ни кылдың, сөйлә!

Идегәй. Илче булып син килдең. Без торыйк, газизем, син сөйлә!

Аксәет. Җирдә Алланың күләгәсе булган ханыңа кул күтәрдең, көфраны нигъмәт кылдың, гасый булдың! Остаз хакын таптадың! Мал бастың, җыен азган-тузган, җыен юлсызга баш булдың!

Идегәй. Рас әйтерсең, газизем. Җыен юлсызга баш булдым!

Аксәет. Йа Алла! Туктамыштай зур ханның баштанаяк тимер кигән гаскәренә каршы бу сәләмәне алып килдең? Һәлак булдың, Идегәй. Иман яңарт, тәүбә кыл!

Идегәй. Сез ишетәмсез, башлыкларым? Илчеләр бездән разый түгел. Начар каршы алдык без аларны! Зурлап быргы бирелсен! Урданы һәйбәт торгызыйк! Син дә сызгыр, Нугайби. Кучмәләрең ат менсен! Һөнәребезне күреп китсеннәр!

Барабан һәм Нугайбинең ачы сызгыруы астында күтәрелгән корал тавышлары. Арткы саф бары да ат өстендә була. Кылычлар күтәрелә.

Җанбай *(үзалдына)*. Бу ни?

Норадын *(пычагын күрсәтеп, алга чыгып)*. Нәрсә алар белән сөйләшеп торырга? Менә пычак! Аны да белеп кит, Җанбай! Ханыңның башын кисмәсәм, атамның үчен алмасам, түренә түшәк салмасам...

Идегәй *(боерып)*. Норадын!

Норадын *(дәвам итеп)*. Хан улы хан булмасам...

Идегәй *(бүлеп)*. Бу синең башыңа каян килде?

Норадын. ...дигәнемне кылмасам, атамның хәрәм углы булыйм!

Сәет. Ничек? Моны сөйләгән аның углымы?

Идегәй. Күп начар сүз сөйләдең, Норадын! Син бу таңда миңа кушылдың, белер-белмәс сүз сөйләп, Җанбай кебек җан дошманыңны мыек астыннан көлдердең! Ярый, бар, мен атыңа! Бәлки, бу гаебеңне син кылыч уеның белән капларсың! Әй! Минем кызым Чулпанга да яхшы ат, яхшы кылыч бирелсен! Ул да чабар алдымнан!

Җанбай *(Чулпанны күрде)*. Бездән бәйле калган кыз! Ничек? Багананы җимереп качканмы ул? *(Акрын.)* Отылдык! Башла, Сәет!

Сәет *(тавышын күтәреп)*. Беттең, беттең, Идегәй! Бәддога кулым күтәрдем! *(Җиңе белән ишарә ясый.)*

Идегәй. Бәддога кулын күтәрмәдең, Туктамыш туын күтәрдең!

Калку артыннан ту күтәрелә.

Җанбай *(Аксәеткә)*. Йа Алла! Ул барын да белә!

Аксәет. Алдыңда синең — таш коймa, артыңда синең — Туктамыш! Камалдың, Идегәй! Төш! Бирел!

Идегәй. Алдымда минем — таш койма, ике суксам алырмын! Атлан, минем халкым! *(Атка менә.)* (...) Гаскәр! Минем артымнан! Шәһәр капкасына! *(Кураучылары белән күздән югала.)*

Сәхнә буш кала. Барабан. Идегәй эзеннән Туктамыш, Кадыйрбирде, Аргын, Казыйхан, кураучылар һәм гаскәр керә.

Туктамыш. Чигенәләр! Бас, шәһәр коймасына кыс үзләрен! Коймада безнекеләр! (...)

Чыгалар.

Аргын *(янындагыларга)*. Күрәсезме Идегәйне, шәһәргә җитте! Егыгыз байракны! Йә хәзер безнекеләр эчтән шәһәр капкасын ачар, йә...

Еракта шыңгырдап ачылган капка тавышы.

Ачтылар! Шәһәр безнеке! Җырт, сындыр кара туны! *(Байракны сындыралар.)* Бир быргы! Кач!

Быргы бирелә, качалар. Туктамыш угланнары кире кайта. Паника.

Тавышлар. Бу ни? Артыбыздан төштеләр! Уралдык, камалдык! Кайда безнең ту?

Кадыйрбирде *(керә)*. Чигенмәскә боерам! Ишетәмсез? Кайда хан атам?

Җанбай *(керә)*. Ул монда.

Туктамыш *(чал чәчле, яланбаш, кулында кылыч)*. Ни булды, улым? Без камалдыкмыни? Кая безнең ту?

Кадыйрбирде *(ертыкларын күтәреп)*. Ту менә! Хыянәт. Безнең эчебездә идегәйчеләр! Аргын өзгән моны!

Туктамыш. Аргын! Ул да идегәйче! Йа Алла! Кемем калды минем? Кайда йөз меңле гаскәрем, Арслан?

Арслан. Пычак керсен ул гаскәргә! Сул канат Идегәй ягына чыкты! Бер уч кеше калдык!

Казыйхан. Идегәйне капка ачып керттеләр! Анда да алар! Хыянәт!

Туктамыш. Ышанмыйм! Ничек? Без җиңелдекмени? Җиңелдекмени?

Җанбай. Күз җитмәс эш булды, олуг хан! Алай да әле эш үтмәгән. Бар кешебезне ал да чиген, ханиям!

Туктамыш. Чигенергә? Миңа? Бире чыгарга киңәш син бирдең! Аш өемдә ни пешәсен һәр көн алдан белгән эт! Моны белмәдең?.. *(Суга.)*

Җанбай. Үтер, суй, падишаһым! Әмма җаныңны сакла, чиген, ханиям!

Туктамыш. Кемгә калдым! Йа Алла! Кая барыйм мин? Болгаргамы? Кырымгамы? Бөтен җирдә идегәйче!

Җанбай. Көнбатыш короле синең дустың! Аңа сыен, олуг хан!

Туктамыш. Корольгә?

Җанбай. Ул сиңа ярдәм итәр! Син — ханнар ханы, каган! Аның көче белән син сарайны кайтарып алырсың!

Кадыйрбирде. Ул дөрес әйтә, атам!..

Туктамыш. Минем шәһәрем! Минем сараем! *(Сарайга табан китеп бара, аны тоталар.)* Алтыннан акча кистереп, шул алтынның мөһерен үз исемемә суктырып, егерме ел мин сине тоттым! Сине калдырып китәргә? Юк, юк! Монда мин олуг хан! Шәһәр минеке! Урда минеке! Минеке! *(Кулларына авып төшә. Аны күтәреп чыгалар.)*

Пәрдә.

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәхнә I

Тәхет залы. Идегәй ялгыз. Тәхет уңына басып, бер аягын тәхет баскычына куеп, тезенә һәм янагына таянган килеш, уйда тора. Норадын керә.

Норадын *(кызу)*. Әти, мин ишеттем...

Идегәй *(әйләнеп, аны бүлеп)*. Норадын? Әйе, әйе. Якын кил, улым!.. *(Баштанаяк күздән кичерә.)* Яшьлегеңдә якыннан сине күрә алмадым. Мин кача йөргәндә, син Нугайби кулында үсеп буй җиттең. Менә син нинди ир! Егерме яшемдә мин дә шундый булганмын!.. Сөйлә, сөйлә, газиз улым!

Норадын *(нык)*. Мин ишеттем, син нугайларны көчләп утрак итәргә җыенасың!

Идегәй. Әйе, улым. Аларга да бер утырырга вакыт. Шулай түгелме? Мин беләм: ат өстендә йөрүдә синең тиңең юк. Алай да, күрәсең, без шәһәр алдык. Син дә бирегә кайтасың!

Норадын. Миңа? Бирегә кайтырга? Монда торырга?

Идегәй. Әлбәттә. Ә ничек уйлыйсың син?

Норадын. Тыным тарыга минем монда! Ниндидер авыр ишекләр!.. Кара син кузгалмас итеп корган бу таш өйне! Нәрсә бу? Этеп җибәрәсем килә минем аны!

Идегәй. Мин ни ишетәм, йа Алла! Шулай ук ялгыштыммыни? *(Текәлеп карый.)* Тукта. Син нинди кеше? Син — бөтенләй дала!

Норадын. Дала! Әйе! Менә, ичмасам, аны әйт! Исеп торган җилен әйт! Атыңа менеп алдыңмы — атылып чабар урын бар! Җаекны әйт тә, Димне әйт! Нинди сахра, тугай юк! Дөрләп аккан су кебек, көтү-көтү куен әйт. Киез өен күтәртеп, кичке тында җыр белән күчеп барган илен әйт! Шушы халыкны утрак итәргәме? Сукачы булыргамы?

Идегәй. Начар эшмени? Аны да әйткәч, моны да әйт: икмәк өчен нугаең баласын сата, аны әйт! Күрәсең быел ашлыкны? Болгар таланды, Мәскәү аерылды. Каян алыр халкың икмәк? Кием? Күршесен талар? Кала бозар? Тагын шул урда булырмы?

Норадын. Булыр! *(Йодрыгын күтәреп.)* Моңарчы күчмәләр утрак өстендә баш булган! Шулай булыр!

Идегәй *(коры)*. Ярый! Алар сине «Норадын хан» дип йөртәләр! Бу ничек? Ничек син «хан»?

Норадын. Ә шулай хан! Ни өчен мин Чыңгыз булалмыйм?

Идегәй *(якын килеп)*. Чыңгыз?

Норадын. Әйе. Чыңгыз! Менә ул ат өстеннән төшмәгән, таш өйдә яшәмәгән. Алай да шундый ил төзегән!

Идегәй. Ләкин шул ук Чыңгызның үзләрендә моны әйткән: «Ат өстендә төзегән илне ат өстендә идарә итеп булмый!» Күрәм, күрәм хәзер: сине Нугайбигә бирүем ялгыш булган! Син бозылган, Норадын! Ташла Нугайбине! Бирегә кайтасың!

Норадын *(кызып)*. Әти! Мине сүк, әмма Нугайбигә тел тигезмә!

Идегәй. Аһа! Мин күрәм: хәтта син атаңны Нугайбигә алыштырырга да әзер торасың! Юк! Минем сине югалтасым килми, Норадын! Минем тугры, намуслы улым! Син аска карыйсың? Син... дәшмисең?

Норадын. Һәрдаим мине хурлыйсың? *(Туры карап, гайрәт белән.)* Хурласаң мине, атам, хурлыгына чыдамам!

Идегәй *(үзалдына)*. Ни дәрәҗәдә ул туры һәм... куркынычлы!

Шыгавыл *(керәп)*. Көнбатыш короленнән илче килде.

Идегәй. Керсеннәр!

Илче, Аңгысын һәм башкалар керә.

Идегәй *(Норадынга)*. Норадын! Мин әйткәннәрне хәтереңдә тот.

Илче *(керә)*. Олуг корольдән сиңа! *(Төргәген ыргыта.)*

Идегәй *(аны алмыйча)*. Сөйлә, күршебез синең теләңнән ни әйтә?

Илче. Минем олуг королем гаскәр белән синең туфрагыңа басты. Сөйләшү өчен, сиңа минем артымнан барырга кушты.

Идегәй. Без корольдән бары тик дошманыбыз Туктамышны безгә тапшыруын сорадык. Ни өчен ул җиребезгә гаскәр белән килде?

Илче. Туктамыш хан үз гаскәре белән безгә кушылды. Шуның белән Урда да безнеке була.

Идегәй. Тагын ни?

Илче. Тагын шул: бүгеннән алып, биредәге тәңкәләргә король исемен суктырып, аларны минем олуг королемә дань итеп түләрсең. Ул сиңа атай, син аңа угыл хөкемендә булырсың. Угыл хөкемендә булырга күнмәсәң, кол булырга риза булырсың. Ул сиңа хәзер үк минем артымнан үз чатырына барырга куша.

Идегәй *(садактан[1] ук алып)*. Илче! Менә бу куышлап койган көмеш ук — минем угым. Иң элек аны тыңла! *(Аңгысынга бирә.)* Бир авазын!

Аңгысын аны иреннәрә ала. Бармагын баса. Уктан шыңырдаган курай тавышы ишетелә башлый. Аннан берничә кат сугышчан көй ишетелеп тора.

---

[1] *Садак* — ук-җәя сала торган, билгә тагылмалы күн савыт.

Идегәй *(укны алып).* Атып җибәргәннән соң, ул шулай шыңырдап оча. Аны шушы җәя белән королеңә тапшыр. Тартып карасын. Керешен җиткерә алса, безнең белән сугышырга килсен. Бездә мондый ук та, моны ата белүчеләр дә күп. *(Бирә.)* Сугыш тели икән, кире кайтарсын.

Илче *(алып).* Ничек? Олуг корольгә шулмы җавабың?

Идегәй. Юк. Ул гына түгел. *(Кәгазьне күрсәтеп.)* Синең королең мине углы урынына саный, акчабызга үз исемен суктырып дань итеп түләргә куша; әш картлык-яшьлеккә карап йөри торган булса, королеңә әйт: мин аңардан олыракмын, теләсә, миңа үзе угыл булсын да акчасына үзе минем исемне суктырсын.

Илче. Бу хурлык! Мин синең угыңны хәзер үк кире кайтардым! Гаскәр якын! Иртәгә ул бире тәхетеңдә булачак! *(Ук белән җәяне алдына ташлый да чыга.)*

Идегәй. Тәкәббер король! Ул, Туктамыш көченә таянып, Урданы басып алырга уйлый. Без андый эшләргә риза булачак халык түгел! Укны мин күтәрдем. Король өстенә Норадын белән мин үзем юнәләчәкмен. Ә Туктамыш нугай юлыннан килә, аның өстенә Нугайби барыр.

Норадын. Юк! Син яхшы беләсең, атам. Туктамышны кисәргә мин шушы пычагым белән ант иткән!

Идегәй *(үзалдына).* Ярабби! Ул тагын Нугайби белән булачак! *(Тынып.)* Мин синең антыңны җиренә җиткерүеңә ышанам. Ярый! Шуның өчен генә рөхсәт итәм. Ярый... бар. Бар, Норадын! Кайткач та, минем янымда булачаксың!

Норадын. Ләкин минем икенче антым да бар, атам! Бире сарайда Ханәкә солтан ябулы утыра. Атасын мин җиңгәндә, кызы минеке булырга тиеш!

Идегәй. Нинди синең зәүкың! Син мине шаштырасың, Норадын! Торгызыгыз Урданы! Атланыгыз, киттек төмән[1], мең башларым!

Чыгалар. Идегәй арткарак калып килгәндә, **Янбулат** керә.

Янбулат. Идегәй. Атай!

Идегәй. Янбулат! Газизем! Бик вакытлы килдең син! *(Коча.)* Баһадирлыгыңны ишеттем, яшә! Кадыйрбирденең олауларын алдыңмы?

Янбулат. Мин аларны бире китердем.

Идегәй. Бодай китердең? Яхшы. Иртәгә үк халыкка өләшербез. Сөйлә! Болгарда ни хәл?

Янбулат. Болгарны князь Юрий белән Кадыйрбирде яндырып, талап китте. Бетте Болгар! Хәзер урынына Казан үсә!

---

[1] *Төмән* — ун мең гаскәр. Төмән башы, мең башы, йөз башы — шул саннардагы гаскәр башлыклары.

Идегәй. Казан? Син беләсеңме Туктамыш улы Кибәкнең, Биләр шәһәреннән чыгып, Казанга юл тотканын?

Янбулат. Беренче ишетәм!

Идегәй. Ун мең гаскәр белән. Ул аны яндырачак!

Янбулат. Ун мең! Димәк, безгә ашыгырга кирәк!

Идегәй. Әйе, безнең хәзер төп көчебез Туктамыш өстенә бара. Кибәкне син кисәргә тиеш!

Янбулат. Яхшы. Аннан соң...

Идегәй. Әйтергә кыймыйсың! Күрәм, баһадир егет! *(Ишеккә.)* Чулпан!

Чулпан *(керә)*. Мине чакырдың, агам?

Идегәй. Мин сине егет алдында калдырам. *(Чыга.)*

Янбулат *(үзалдына)*. Йә Алла! Минем йөрәгем чыга!

Чулпан. Бу кем? Ай! Янбулат! *(Ташлана.)*

Янбулат. Чулпан! *(Коча.)* Ничек сагындым! Ничек курыктым мин синең өчен! Бәхетем, йолдызым! Намусым!..

Сәхнә II

Шул ук тәхет. Кич. Түшәмдә кандил яна. Тышта барабан, ат тоягы тавышлары. Идегәй белән Аңгысын бер-берсенә каршы ишектән керәләр.

Идегәй. Ул нинди тавыш?

Аңгысын. Норадын кайтты! Туктамышны үтереп, Җанбайны үзе белән алып кайткан!

Идегәй. Җанбайны алып кайткан! Ялгыз баланың кылыгы яудан яман, диләр иде. Булды бер яу!

Аңгысын. Ул гына түгел, Нугайби дә бергә. Бөтен урдасы белән.

Идегәй. Нугайби? Бусы яу өстенә яу? Кем җибәрде аларны шәһәргә? Юк! Мин гаскәремне, өч көнгә дип, иген-тару җыярга гына җибәрдем. Монда болар төн буе ач шәһәрне талап, туй ясап йөрсеннәрме? Аңгысын! Хәзер үзләрен кабул итәргә дә бердән озатырга! Уң бүлмәдә Субра. Ул да чакырылсын!

Чыгалар. Җанбай керә.

Җанбай. Сарай... менә ул хан сарае! Бу минем түрем иде. Алтын Урданы бердән торып Туктамыш хан кулы белән мин идарә итә идем. Биргә мин киерелә биреп керә идем. Бүген мин аяк очларыма гына басып керәм. Идегәй! Төлке белән бүре токымыннан ясалган хәйләкәр, мәкерле Идегәй! Син ике дошманны бер-берсенә җибәреп зәгыйфьләндерәсең дә дәүләтләр басып аласың... Ләкин сак бул, Идегәй! Син дә бит улың белән дус түгел! Беркатлы улың Норадын минем якка ауды. Аның артында күчмәләр тора. Бәлки, мин дә аны синең өстеңә җибәрә алырмын!

Х а н ә к ә керә.

Тукта... Чү! Бу кем керә? Ханәкә! *(Ышыкланa.)*

Х а н ә к ә *(тәхет алдына чүгеп).* Бәхетсез атамның тәхете! Минем дә соңгы сыенып җирем булып син калдың! *(Елый.)*

Җ а н б а й. Ул елый! Ела, ела, бәхетсез хан кызы! Хакың бар! Ни үкенеч. Син дә атаңның башын чабып өзгән бер көтүче малаеның куенында булачаксың. Бүген синең туй!

Х а н ә к ә. Туй! Дошманнар атам мәете өстендә үлем туе иткәндә, син дә туй ашы ашарга килдең, сатлык, кара йөз Җанбай! Алдандыгыз, затсыз түрәләр! Чыңгыз затым, асыл буем көтүче малайлары өчен үсмәгән! Атам тәхете минем дә үлем түшәгем булсын! *(Хәнҗәр белән үзен чәнечмәкче була.)*

Җ а н б а й *(аның хәнҗәрен тотып).* Бик арзан сатасың син Чыңгыз каныңны! Ничек? Синең энең Кадыйрбирде бүген дөньяда калмадымыни? Бүген безнекеләр анда Чирүле күлгә җыелып *(каранып алып)* атаң тәхетен кайтарып алырга торганда, син дә аларга ярдәм итәрсең дип көткән идем.

Х а н ә к ә. Кадыйрбирде? Ләкин син мине Кадыйрбирдегә ярдәм итә алырлык хәлдә дип уйласаң, бик ялгышасың, Җанбай.

Җ а н б а й. Сарай төбендә Норадын белән Нугайби гаскәре тора. Ә соң шул гаскәрне Идегәй өстенә җибәрү синең иркеңдә түгелмени?

Х а н ә к ә. Норадынны Идегәй өстенә җибәрү? Нәрсә сөйлисең син?

Җ а н б а й. Нәрсә сөйләсәм дә, бик белеп сөйлим. Сиңа шул нечкә билеңне берәр нәрсә урап зурайту бик авыр эшмени?

Х а н ә к ә. Миңа? Билемне зурайтырга? *(Аптырап көлә.)* Саташтыңмы әллә син?

Җ а н б а й. Әйе, зурайтырга һәм, Норадын күргәндә, сине йөккә узган дип уйларлык итеп зурайтырга, аннан инде, бу кем эше дип сораганда, атаңнан сора, дип кенә җавап бирергә!.. Ни булганын анда күрерсең!

Х а н ә к ә. Мин? Үз кулым белән эчемне зурайтып, Норадын алдында, атаңнан йөкле булдым, дип җавап бирергәме? Моны син әйтәсең, миңа! Ах, оятсыз, оятсыз Җанбай!

Җ а н б а й. Мин нәрсә! Әйттем дә кайттым, синең иркең! Теләсәң — утка, теләсәң, суга керәсең! Мин тик атаңның тәхетен Кадыйрбирдегә алып бирәсем килеп кенә әйткән идем... Үзең беләсең, хуш!.. *(Чыга.)*

Х а н ә к ә *(ялгыз).* Кадыйрбирде!.. Тәхет!.. Әйбер урарга? Тукта, ул ничек инде? Юк, юк! *(Биленә карый.)* Ә бит чынлап та! Моны эшлисе бик җиңел! Минем эчемдә калырмыни ул? Кем мине гаеп итәр? Хан кызы Ханәкә йөкле? Юк. Әйтегез, нишлим мин? Тукта! Бире киләләр. *(Ашыгып чыга.)*

Барабан. **И д е г ә й**, **Н о р а д ы н**, **Н у г а й б и**, **А ң г ы с ы н**, **Т ы ң г ы с ы н** һәм башкалар керәләр. Султан **С у б р а** кертелә.

И д е г ә й. Боер, картым. Утыр уңымнан! Киңәшемнең алды бул, мәҗлесемнең түре бул! *(Утырып.)* Сөйлә, тыңлыйм, Норадын!

Н о р а д ы н. Әти! Син тәкәббер корольне кискәндә, мин дә Туктамышны куа җитеп, бермә-бер сугышып, башын кистем. Менә ул. *(Төенне алдына куя.)*

Н у г а й б и. Чиш, баһадир Норадын, бар да күрсеннәр!

Норадын чишә.

Китегез, киясе сукмасын! *(Кулына төкереп, Туктамыш башын чәч чугыннан эләктереп алып тәлинкәгә утырта.)* Менә!

Т а в ы ш л а р. Һай баһадир Норадын! Каган башын алган ир!

Н о р а д ы н *(чүгеп).* Ата-бабадан килгән үчемне алдым. Ул баш — сиңа бүләк, атам. *(Сона.)*

И д е г ә й. Юк, син аны минем өчен түгел, халык өчен суйдың, Норадын. Яхшы иттең! Тәреп чыгарыгыз, юк итегез башын!

Н о р а д ы н. Мин сүземдә тордым. Онытма, әти! Туктамыш башы өчен миңа Ханәкә вәгъдә ителгән. Мин аны күрмим, кайда ул?

И д е г ә й. Ханәкә китерелсен!

Сакчылар чыга. **Җ а н б а й**, кереп, Идегәй алдына егыла.

Кем ул?

Җ а н б а й. Иске дус дошман булмас. Иске дусың — киң Җанбай. Аны да кичер, Идегәй!

И д е г ә й. Башымнан михнәт киттеме дигән идем, әле киткәне юк икән! *(Норадынга.)* Норадын! Туктамышны качыручы бу икейөзле юха ни өчен суелмады?

Н о р а д ы н. Мин аның тугрылыгын сынап, бу киселгән башны аңа күрсәттем. Әгәр дә ул мине алдымда моның өчен мактаса, ул — юха, мин дә аны суячак идем. Ләкин ул мине мактамады, сүкте. Мин дә аны ханына тугрылыгы өчен гафу иттем.

И д е г ә й. Ханына тугрылыгы, үзеңә дошманлыгы өчен гафу иттең? Гаҗәп! Алыгыз бу тимсахны[1]! Ябыгыз зинданга! Миңа кирәкми ул!

Җ а н б а й. Идегәем!

Н о р а д ы н. Әйткән сүз — каккан казык! Мин аның канын багышладым. Мине ике сүзле ясыйсың, атам!

Н у г а й б и. Рас әйттең, морзам! Ничек син, Идегәй? Баш игән бер дошман алдында шундый баһадир улыңның сүзен егасың? Юк! Бу — Норадынга җәбер!

---

[1] *Тимсах* — крокодил.

Идегәй. Тик тор син, Нугайби! Норадын миңа ят түгел, үз углым! Ләкин ул да дәүләт дошманын гафу итә алмый! Алыгыз аны! *(Җанбай чыгарылгач, Нугайбигә.)* Ә син гаскәреңне ни өчен шәһәргә төшердең, Нугайби? Син беләсең: шәһәрдә безнең мал көтүләребез юк, урдабызны шәһәр тышында тотабыз. Бүген үк гаскәрең шәһәрдән чыгарылсын!

Нугайби. Сугышып алган шәһәрдә безгә төшәр урын юк, кардәш!.. Ярый... Алай да мин аларны төнлә кузгатмыйм. Иртәгә!

Ханәкә, җарияләр керә. Ханәкәнең биле кабартылган.

Ханәкә. Ни өчен чакыртылдым?

Норадын. Ханәкә солтан! Атаң минем кулымнан үтте! Син, үлсәң дә, калсаң да, безнең иркебездә. Ләкин мин сине үземә алмый калмам дигән антым бар. Син бүген минем никахымда торырга тиешсең. *(Якын килә.)* Хәзер сине киендерерләр. Әзер тор... Син ник йөзеңне күтәрмисең? *(Билен күрә.)* Тукта, бу ни? Йа Тәңре? Нәрсә күрәм мин! Син йөкле! Ничек? *(Әйләнеп.)* Сарайның миңа саклаган әманәте шушымыни? Бу — мине мыскыл! Елдырым ташыннан коелган шушы кылычым белән ант итәм, моны кылган кешенең башы шунда тәгәрәп төшәчәк! *(Кулыннан нык тотып.)* Җавап бир! Бу кем эше!

Ханәкә. Кулымны... кулымны җибәр, Норадын.

Норадын. Исемен дә әйтмисең? Шул дәрәҗәдә бер түбән кешемени?

Ханәкә. Ник син аны миннән сорыйсың? Атаңнан сора!

Норадын. Атам?

Бар да. Ах!

Идегәй. Ни ди ул? Хатын-кызга кул күтәрү ирлек түгел, ләкин, кыз сынында моңдый еланны күргәндә, минем чарам юк. Торган җиреңдә парә бул! *(Кизәнә.)*

Норадын *(кылычын кылычы белән сугып төшереп)*. Син... Атам! *(Үзен үзе белештерми.)* Йа күкләр!

Идегәй. Норадын!

Норадын. Юк! Син аны үтереп кенә үз гаебеңне яшереп кала алмассың! *(Ташлана.)*

Субра *(арага тора. Идегәйне киң ак җиңе белән каплап, бер кулы белән Норадынны этәргән кебек.)*

Исеңә кил, Норадын!
Шул колларны би иткән,
Кара җирне гөл иткән
Идегәйдәй атаңа
Кул күтәрдең, Норадын!
Исеңә кил, Норадын!..
Алдына чүк, Норадын!

Норадын. Миңа! Моның өчен аңа тез чүгәргә?!

Нугайби. Намус, намус, беләрем! *(Кылычын кынынннан алып, алдына кайтарып салып.)* Бу чаклысына безнең кылычыбыз юл куймас!

Идегәй. Нугайби? Минем ант эчешкән кардәшем — син! Бүген моны миңа син әйтәмсең?

Нугайби. Әйе, ант кардәшем... Миңа җиңел түгел. Ләкин антны башлап син боздың! Син үз каның Норадынның да хакын таптадың! Артык син минем антым түгел. Менә хөкем итсен беләрем. *(Аларга әйләнеп.)* Ошармы бу эш, ошармы? Күчеп йөргән нугайны утырсын дип әмер иткән, киленен алып, углын хур иткән Идегәйнең алдына углы төшсә, ошармы?..

Нугайлар. Юк, юк!..

Нугайби. Ул чагында кайтарып салыгыз кылычыгызны, беләрем! Син хур булдың, Идегәй! Артык син безгә баш түгел! Без, күчмәләр, синнән аерылдык! Норадын — безнең хан! Монда, минем гаскәрем! Әй! *(Чыга.)*

Идегәй *(Норадынга)*. Ә!.. Менә ни булып чыкты синең аңгыра мәхәббәтнең төбе! Күчмәләр шәһәр өстенә килде! Корал булдың?! Хан кызын алып, үзең хан булырга уйладың!.. Беләсеңме син бу илне?.. Нәкышләп кылыч коя белгән останы, туфракта гәрәбә шикелле бодай үстерә белгән игенчене суярга килдең?.. Норадын! *(Йөзенә карап тора. Чигенеп.)* Юк, юк! Бу минем углым түгел. Ниндидер кырагай! Алыгыз аны! Иртәгә хөкем булыр! Ябыгыз зинданга!..

Норадын *(кылычын ача)*. Мине зинданга ябарга? Мине?

Быргы. Тәрәзәгә тыштан утлы кисәүләр күтәрелә. **Нугайби** күчмәләр белән керә.

Нугайби. Норадын — безнең хан! Сарай камалды! Күрәсең? Бирел, Идегәй!

Идегәй. Юк, башкисәр! Без, алай җиңел генә бирер өчен, хакимлек алмадык. *(Үзенекеләргә.)* Алыгыз кылычларыгызны, төшегез алдыннан! Кырга! Гаскәр янына!

Нугайби. Ха-ха-ха! Кылыч! Сарай минем ун мең кешем белән камалган! Чыгыгыз! Чык! *(Идегәй артта калуга.)* Әһә! Тотыгыз юлына кылыч! Бирел, Идегәй!

Идегәй. Бирелмәбез, Нугайби! *(Кылычын туры күтәрә дә кылычларын кистереп үтеп юк була.)*

Нугайби. Ах, җен! Ничек үтте ул?.. Басыгыз артыннан!

Норадын. Ярый. Бара алса барсын, китсен сакчылары янына! Сарай безнеке!

Нугайби. Сарай безнеке! Син — хан!.. (...)

Норадын. Сарай минеке! Мин — хан! Китерегез бире Ханәкәне!

Ханәкә белән Көнәкә керәләр.

Көнәкә. Сәлам, Норадын хан!

Норадын. Хан дисең? Сәлам дисең? Әһә, Туктамыш кызы. Минем хан булуымны син таныйсың! Яхшы. Ләкин мин Ханәкә белән сөйләшергә телим. *(Аңа килә.)* Әйт: атамның шәүкәте синең дә тәкәббер күзләреңне сукырайттымыни? Яки син, элеккә эрелегеңә барып, миңа үч итеп, бу хыянәткә үзең бардыңмы? Әйт. Ник дәшмисең син?

Ханәкә. Җибәр! Тотма мине!

Норадын. Юк! Син миңа җавап бирерсең! Син, уйнаш хөкеме буенча, юл чатында дүрт казыкка кагылырсың! *(Бармакларын каергалап, аны өерә.)*

Ханәкә *(каерылып)*. Ай! Ул котырган! Аһ! *(Әйләнеп чигә, билендәге ураган материясе уралып төшә бара. Биле нәзек булып кала.)*

Норадын *(туктап)*. Алай да синең билбавың бик озын! Ничек? Синең билең дә элеккечә нечкә! Тукта! *(Аңлап.)* Димәк... бу чүпрәк... Коры чүпрәк! Минем атам гаепсез! Син моны... атам белән мине сугыштыру өчен кылдың? Син моны юри кылдың?! Син моны... мине яратмаганлыктан, миңа чыкмас өчен эшләдең, җавап бир!

Ханәкә. Ә син ничек уйладың? Малай! Атамның башын чаптың, шул кулларың белән минем билемнән кочарга уйладың! Затсыз. Мин — Чыңгыз заты, Ханәкә солтан! Үзеңә тиңне кара, Норадын!

Норадын. Юк! Син минем белән икенче төрле сөйләшерсең!

Көнәкә *(арага төшеп, тезләнеп)*. Норадын! Кичер аны! Без синең кылыч астында! Сиңа сыенган!.. Ханәкә белешми сөйли... Кичер!

Норадын. Норадын кызлар суйсын! Юк! Китегез! Күзләрем күрмәсен! *(Чүпрәкне алып.)* Йа Тәнре, чүпрәк! Нинди мәкергә уралдым!

Пәрдә.

БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәхнә I

Чирүле күл буенда Кадыйрбирде чатыры. Чатырда Яникә белән Кадыйрбирде.

Кадыйрбирде. Менә бит ул яза: Норадынны сиңа китерәм, тотарга әзер тор, дигән.

Яникә. Һәм китерер дә. Җанбаймы? Аның кулыннан килмәгән эш юк. Күрдеңме, ничек ул атасы өстенә улын җибәрде?

К а д ы й р б и р д е. Ярый ла шулай итсә. Әгәр ул Норадынга серне ачып, өстебезгә гаскәр белән килеп төшсәләр? Беттек!

Я н и к ә. Килмәс. Җанбай минем казанымнан күбрәк ашаган.

К а д ы й р б и р д е. Ә ни өчен Норадынны сата ул? Янымда баш вәзир булыр өченме? Ләкин бит ул мине дә шулай сатачак. Юк! Хан гына булыйм, мин ул этнең үзен дә теленнән асачакмын!

Җ а н б а й *(чатырны кырыйдан ачып керә, үзалдына).* Ах, шулай кайтарасыңмы син минем хезмәтемне!

К а д ы й р б и р д е *(күреп, шаккатып).* Ай! Кем бу?

Җ а н б а й. Сәлам, Кадыйрбирде хан!

К а д ы й р б и р д е. Җанбай! Тукта! Ничек? Син биредә булдың? *(Читкә.)* Ах, бу ала төлке!

Җ а н б а й. Яникә ханәшкә сәлам. *(Бөгелә.)*

Я н и к ә. Уң аягың белән уз, Җанбай. *(Әйләнеп.)* Сусын!

К а д ы й р б и р д е. Җир йотсын әгәр, ничек бирегә килдең син? Күрәсеңме син пычаклап торган бу урынны? *(Пычакларын ачып яба.)* Ул Норадын өчен әзерләнгән. Ләкин синең сүзең ялганга чыкса, монда син утырырсың!

Җ а н б а й. Төшендем, яшь хан.

К а д ы й р б и р д е. Кайда Норадын?

Җ а н б а й. Ул биредә.

К а д ы й р б и р д е *(сискәнеп).* Гаскәре беләнме?

Җ а н б а й. Юк. Тыныч бул, хан, ул ялгыз. Бар коралы — кулында бер ау лачыны гына.

К а д ы й р б и р д е. Ах, син аны ауга чыккан җиреннән бирегә китердең? Тотарга үзен! Әй! Бирегез атымны!

Җ а н б а й. Кирәкми, хан. Аны хәзер генә синең кешеләрең муенына корык ташлап атыннан ектылар.

К а д ы й р б и р д е. Әһә! Ул тотылды! Аны хәзер бире китерәләр! Идегәй улы Норадын! Атам тәхетен басып алган ул!

Җ а н б а й. Синең Чыңгыз куәтең аны да сындырды, хан! *(Читкә.)* Мин булмасам...

К а д ы й р б и р д е. Әй! Кертеп салыгыз бире чөй тактаны.

Кадаклы такта кертеп салалар.

Син чыгып тор, анакай.

Я н и к ә. Юк. Мин ул явызның шушы кадакларга басып үткәнен үз күзләрем белән күрәсем килә. Бу пычаклар аның тез астына шытырдап кисеп кергәнен карап торасым килә.

С а к ч ы. Норадын китерелде.

К а д ы й р б и р д е. Кертегез!

Иң элек тургачы[1] белән кара лачын күтәреп керәләр. Аның артыннан, куллары артка каерып бәйләнгән килеш, яланаяк Н о р а д ы н кертелә.

---

[1] *Тургач* — ау лачыннарын куңдыра торган агач (тур + агач).

Ул йөзен күтәреп карый. Түрдә Кадыйрбирде, аның уңында Җанбай утырганын күрә һәм кая эләккәнен аңлый.

Аһа, лачын! Туктамыш ханның бөтен дөньяга дан тоткан ау лачыны! Аксак Тимер аның өчен уникe шәһәрне көл итте. Аның өчен синең бабаң чабылды, атаң бишектә вакытта ук үлемгә хөкем ителде. Минем лачыным! Минем горурым! Син аны угры кулларыңа күтәреп чыктың, малай?

Норадын. Урынсыз горур! Ул лачынны минем бабам Котлыкыя тоткан! Ул асраган!

Кадыйрбирде. Ах, синекемени ул дәүләт кошы? Синең тәхеткә утырасың килдемени? Әнә юл, менә тәхет. Рәхим ит, утыр, «хан»!

Норадын тактадан басып үтә һәм йөзен чытмый, ә туры басып килеп, үз тәхетенә утыргандай, пычаклы урынга утыра.

Яникә. Карагыз нинди эре! Көтүче Кобогыл малае! Юк! Йөзеңне чытарсың син, юлбасар!

Кадыйрбирде. Йә, «батыр», сөйләп бир миңа: сарайдан чыккан алты арба, алтавы да казна арба, алтын-көмеш тулы иде, аны кая илттең, Норадын?

Норадын. Сарайдан чыккан алты арбаң, алтын тулы казна арбаң, кемнән талап алгансың, шуңа өләшеп биргәнмен...

Кадыйрбирде *(Җанбайга)*. Юк, мин монда сүз таба алмыйм. Ул шунда да хан шикелле утыра. Нинди кеше ул?..

Яникә. Бирегез миңа бер казан кайнар су, башына актарыйм!

Кадыйрбирде. Бу чаклы дип белмәгән идем, яман чая икәнсең. Ни җәза бирик, Җанбай?

Җанбай. Ни дип әйтим, солтаным? Турысын әйтте Норадын. Алай да ярасы бик зур. Иярсез генә ат биреп, тутасына озатсаң, ни булыр? *(Күзен кыса.)*

Кадыйрбирде *(сакчыларга)*. Ярый, чишегез аны. Җитәкләгез, күрәсез, аягын ала алмый... иярсез атка мендереп, апасына озатырга. *(Норадынны алып чыгалар.)*

Җанбай. (...) Иярсез атка мендердең, аның өчен моннан да яман үлем юк. Ярасына тик ат тире генә үтсен. Ягыр булып үләчәк.

Кадыйрбирде *(кулбашына суга)*. Дөрес! Дөрес әйттең, эт Җанбай! Ягырга дару юк. (...)

Җанбай. Хәзер инде, кузгалып, сарайга барасың, хан. Юл ачык. Тәхетең сине көтә.

Кадыйрбирде. Дөрес. Әй, әйтегез Арыслан бигә! Урдамны торгызсын! Юнәлдек сарайга!

Быргы. Арслан, Казыйхан һәм башкалар керә.

Биләр! Тәхетемә кайтып менгәнче үк өзә торган бер эш бар: улы белән эш бетми, атасы Идегәй сау калды, аны да басып алмыйча, мин тыначак түгелмен. *(Җанбайга.)* Беләмсең, Җанбай, син аның бүген кайда ятканын?

Җанбай. Канлы күлдә дип ишетәм. Ләкин...

Кадыйрбирде. Соң...

Җанбай. Ашыга төшмисеңме? Гаскәр кучерәсең бар. Идел туңганны көтсәң, ничек булыр?

Биләр. Бу да бер акыл.

Кадыйрбирде. Һа, сөйләдең син дә, киң Җанбай! Идел туңса, кем кичмәс? (...)

Казыйхан. Мин ишеттем, аның урдасы кыр эшенә таралган, ул аларны «ә» дигәндә генә җыеп ала алмас!

Янике. Хәзер ул хәлдән хәбәрсез. Синең ун мең кешең бар. Башын бетер шул атаң дошманының. Син — хан!

Кадыйрбирде. Мин — хан! Бирегез зәһәр кылычымны! Минем кулымнан бетте Идегәй! *(Чыгалар.)*

Сәхнә II

Күл буе. Камышлык. Ике яктан калку җир. Күл артындагы калкудан бер юл төшеп, әйләнеп сәхнә алдына килеп чыга. Уңда Идегәй чатыры. Идегәй белән Чулпан.

Чулпан. Син яраланган арыслан шикелле! Тынычлан, тынычлан, агам!

Идегәй. Юк, юк! Туктамыш ханны бергәләп җиңгәннән соң?! Бу ничек? Кырагайлар бүген шәһәрдә утыра! Норадын! Йа Тәңре! Ничек мин аны шул чагында үз кулым белән чәнчемәдем! Ул анда хәзер шәһәр яндыра! Ул яңадан Чыңгыз көннәрен кайтара! Юлында шәһәрләр көйри, иген кырлары яна! Ләкин... юк! Чыңгыз көннәре инде үтте! Шәһәрләр күтәрелде. Сукачыга чаклы кузгалды. Ул үләргә тиеш! Норадын... Юк, юк! Ул минем углым түгел! Минем углым — Янбулат! Минем кызым — син! Син! Ә Норадын — ул үләргә тиеш! Ишетәмсең?.. Мине шушы көнгә куйган ул — минем кылычымнан үләргә тиеш! Син елыйсың, Чулпан? Әйе. Атаң синең шәһәрдән чыга алмады, алар кулыннан үтте. Син аның өченме?..

Аңгысын *(кереп)*. Сиңа илче килде, Идегәем. *(Казыйханны кертә.)*

Идегәй. Казыйхан? Кемнән ул?

Казыйхан. Кадыйрбирде хан мине сиңа җибәрде.

Идегәй. Кадыйрбирде дигән хан? Ишеткәнем юк. Бәлки, «Норадын хан» диюеңдер?

Казыйхан. Ул яктан мин сине шатландырырга тиешмен. Кичә сине тәхетеңнән куган Норадын — бүген Кадыйрбирде хан кулында тоткын.

И д е г ә й. Норадын тоткын, дидең син? Ялган!

К а з ы й х а н. Әйе. Углың Норадын Җанбай белән күл буена ауга чыкканда...

И д е г ә й *(бүлеп)*. Җанбай аны сезнекеләргә тотып бирдеме? *(Үзгәреп, өстенә килеп.)* Норадын... Ә хәзер кайда соң ул?

К а з ы й х а н. Ул исән. Яшь ханыбыз аңа карата ирлек һәм намус күрсәтте. Бары тик... Пычактан корылган тәхетенә генә утыртып сорау алды да атына атландырып тутасы йортына озатты.

И д е г ә й. Яралы килеш? Иярсез аттамы? Йа Тәңре! Мин ни ишетәм? Минем бәхетсез углым Норадын! Бу кадәресен үк көтмәгән идем. Нишләде ул? Бала! *(Аңа.)* Күрәм: яхшы ирлек һәм намус күрсәткән синең ханың! Бәлки, ул миңа да бирелергә кушадыр?

К а з ы й х а н. Ни чараң бар, Идегәй. Гаскәреңне син «ә» дигәндә кырдан җыеп алалмыйсың. Мин беләм: синең яныңда хәзер нибары йөз кеше. (...)

И д е г ә й. Илчегә үлем юк, шымчыга бар! Син минем янымдагы кешеләрне бик белеп санадың.

Выргы бирелә. Ашыгып, **М а р у к** керә.

М а р у к. Камалдык, Идегәй! Сакчылар туралды. Нишлибез?

И д е г ә й. Ул чагында эш кылычка калды. Бәлки әле, без кичкә чаклы аларны тотып тора алырбыз! Алып чык бу шымчыны, Марук, килер юлларына каенга ас! Кешеләрең белән сакла юлны! Ә син, Аңгысын, кичүне сакла! Мин унҗиде кешем белән үзәкне тотам. Тапшырдык! *(Кораллана.)*

М а р у к.
А ң г ы с ы н. } Тапшырдык... *(Чыгалар.)*

Ч у л п а н. Ә мин?

И д е г ә й. Син, Чулпан, минем кылычым күләгәсендә сыенган әманәт. Биредә булырсың.

Ч у л п а н. Юк... Кара көндә хан кызлары да муеннарыннан муенсаларын салалар. Минем ялгыз җаным бар. Ул да — илем өчен әманәт. Җибәр, мин синең уңыңнан торып сугышыйм.

И д е г ә й. А-а, син рухландырдың мине, баһадир кыз! Мондый кызлары булган халык бервакытта да җиңелмәс. Тор шушы калкуда. Элемтәче булырсың, Чулпан!

Кылыч тавышлары.

Б а ш м а к ч ы *(керә)*. Марук... Марук туралды! Аның өстенә мең кеше килде. Аларны кисеп бетерергә мөмкин түгел. Алар килә, Идегәй!

Б е р г а с к ә р и *(керә)*. Ат әзер, Идегәй.

И д е г ә й. Һайди, атландык! *(Кешеләр белән чыга.)* (...)

Кылыч тавышлары. Тояк тавышлары. **К а д ы й р б и р д е, Җ а н б а й, б е р н и ч ә б и** һәм **у г л а н н а р** керә.

Кадыйрбирде. Менә ул! Биредә аның чатыры. Басыгыз үзен! Әһә! Синең белән дә бер исәпне өзәр көн килде, Идегәй.

Углан. Ул чатырында юк!

Икенче углан. Камышта да юк!

Кадыйрбирде. Ах, җен! Тукта, аны Арслан батыр тотып алып китмәдеме?

Бер углан. Мин күрәм: берәү бире килә.

Яралы бер нөгәр керә.

Кадыйрбирде *(карап)*. Яралы. Арслан кешесе! Кайда ул Арсланым?

Нөгәр *(иелеп, канлы төз кылыч сонып)*. Минем кулым белән ул сиңа соңгы әманәтен тапшыра. Ул Идегәй кулыннан үтте. Без туралдык, хан.

Кадыйрбирде *(кылычны алып)*. Идегәй сау калдымы?

Бер би *(карап)*. Ул бире килә!

Кадыйрбирде. Әйе, ул! Аны теге Чулпан җитәкләгән! Яралы! Көчкә атлый!

Җанбай. Безгә посарга кирәк, хан!

Кадыйрбирде *(угланнарга)*. Посыгыз ташка! Без — чатырга! Көтегез минем ымны! Басабыз үзен, пос!

Посалар. Яраланган, хәлсез Идегәйне Чулпан җитәкләп керә.

Чулпан. Агам, синең хәлең авыр. Яраң каты. Тукта, бәйлик, агам.

Идегәй. Миңа тыгыз... Ычкындыр муен төймәмне. Аһ, аһ!

Чулпан. Хәзер. *(Ычкындыра, ярасын бәйли башлый.)*

Идегәй. Юк, әле мин тына алмыйм. Көмеш угымны... бир, Чулпан! Бәлки әле, мин... *(Җәясен кора.)* Бәлки әле, мин... *(Тарта.)* Чак кына... чак кына тартып... җиткереп булмады! *(Ата.)*

Һавада чынлап очкан ук тавышы ишетелеп тора да тына. Еракта җавап быргысы.

Чулпан. Бу — Янбулат быргысы!

Идегәй *(җанланып)*. Ә? *(Янә тыңлый. Икенче яктан янә быргы ишетелә.)* Бу Тынгысын! Алар килә! А-а! Димәк, ишетелде... Ишетелде минем бу чакыруым! Бар, бар, Чулпан... Син бар, алып кил аларны, кызым.

Чулпан. Сине калдырыпмы? Юк. Күрәмсең, агам, анда... ул! Кадыйрбирде килә!

Идегәй *(пышылдап)*. Мин әле аны гына тотармын! Мин камышлыкта көтәрмен! Син яшь. Җитез. Алар сине тоталмас. Бар, бар!

Ч у л п а н. Киттем, агам!.. *(Югала.)*

И д е г ә й. Китте. Аһ, нинди китте, болан. Алар килер... Аһ! Тик мин генә бу якты дөньяда булырмынмы? *(Хәлсезләнеп, агач төбенә, җиргә төшеп, кырын сөялеп утыра. Сызгыру. Посудан Кадыйрбирде һәм башкалар чыга.)*

К а д ы й р б и р д е. Әләктең, Идегәй, башың белән саубуллаш! Иманыңны әйт, син безнең кулыбыздан туралачаксың!

И д е г ә й. Әйе. Сез күмәк, мин берьялгызым. Ярам җитәрлек тирән, алай да мин, синең кулыңнан, углым шикелле, намуссыз киселмәм, дип уйлыйм.

Җ а н б а й. А-а, шушы хәлендә дә ул бермә-бер сугышырга кеше чакыра, хан!

К а д ы й р б и р д е *(Җанбайга)*. Күрәсең, аның бер кизәклек эше калды. Үлемен сиңа тапшырдым, тот Арсланның төз кылычын, чап, Җанбай! *(Кылыч бирә.)*

Җ а н б а й *(кылычны айкап, кире төшереп)*. Юк!

К а д ы й р б и р д е. Юкмы? *(Баш очында кылычын ачып.)* Иманыңны әйт, хыянәтче! Син дә телеңнән тотылдың!

Җ а н б а й. Юк, хан. *(Тартылып.)* Идегәйдән үч алу бүген үзеңә насыйп. Синнән дә узып кул күтәрергә кыялмыйм, хан.

И д е г ә й. Батыр бул, Кадыйрбирде. Мине намуслы үлем белән үтер!

Җ а н б а й. Кабул ит чакыруын, хан. Ул бетеренгән! Аны син бермә-бер чыгып үтергәндә, гомерлек даны синең кулга күчәчәк! Менә кылыч! *(Сөртеп, кайтарып бирә. Читкә.)* Мин аны зәһәрле мамык белән сөртеп бирдем.

К а д ы й р б и р д е. Яхшы. Кабул иттем! *(Идегәйгә чыга.)* Йә? *(Түрәләрен күрсәтеп.)* Түбәдә торган дүртәүгә түрә булыр көн тудымы? Казан, Кырым, Әстерхан, Мәскәү белән Дагстан янә минеке булдымы? Синең дә иелмәс башыңны мин чабар көн тудымы?

И д е г ә й *(утырган җирдән)*. Юк, Кадыйр! Артыңда синең түрәң бар, әмма халык юк, Кадыйр. Казан, Кырым, Әстерхан, Мәскәү белән Дагстан инде сиңа булалмас. Кадыйрбирде, хан булып, янәдән урда коралмас!

Кадыйрбирде кылычы белән аны чәнечмәк була. Идегәй утырган җиреннән үз кылычы белән аның һәр кизәнүен кире кайтара. К ө н ә к ә, Х а н ә к ә, Я н и к ә керәләр.

Х а н ә к ә. Менә алар!

К ө н ә к ә. Ай! Кирәкми! Ул яралы! Ташла кылычыңны, Кадыйрбирде! *(Анасының алдына егыла.)*

Я н и к ә. Кис, үтер, Кадыйрбирде. Углына килгән көн атасына да килде.

К а д ы й р б и р д е *(гайрәте ташып, Идегәйне күзе белән ашап)*. Кантарда[1] яуган болыттай зәһәрле, суык төсем бар. Әле дә башың салмыйсың? Бер суярлык эшең бар.

И д е г ә й. Шаярма син, яшь егет! Арыслан хәлдән тайса да, бер сарыклык көче бар! *(Кинәт урыныннан калкып тора да аны чәнчә. Кадыйрбирде ава. Идегәй шул арада камышлыкта юк була.)*

Б а р ы д а. Ул аны үтерде! Ах! Ах!

Җ а н б а й. Тотыгыз үзен! Камышлыкка керде. Чап! Чап!

Ике морза аның артыннан камышлыкка төшә, камышлык селкенә. Анда сугыш. Кылыч очлары чагылып тора.

К ө н ә к ә *(анасына)*. Канга туймадың... туймадың, әни! Күрдең? *(Елый.)*

Х а н ә к ә. Син мине бу сүзең белән үзеңнән генә биздерәсең, Көнәкә. Белсәң, синең агаң ир булып үлде.

Я н и к ә. Аһ, аһ! Зәһәрем эчемә сыймый! Син шул елан Кобогыл нәселен мәңге минем алдымда якладың! Юк! Син миннән сөт иммәгәнсеңдер! Минем каным, минем батыр Кадыйрбирдем, аһ! *(Мәет өстенә ава.)*

Б е р б и *(камыш янында)*. Камыш тынды... Күрәсең, ул аларны да үтерде... Шулай ук сау калдымыни үзе?

Җ а н б а й. Идегәй? Ул Кадыйрбирдене үтерде, ләкин үзе дә аның зәһәрле кылычыннан яраланды. Аңа котылу юк. Ләкин юанмыйк, беләрем. Аның халкы кырдан килә. Алыгыз биредән ханның мәетен! Боер, ханча!

Кадыйрбирде мәете чыгарыла. Артыннан Я н и к ә н е Җ а н б а й белән Х а н ә к ә җитәкләп чыгалар.

К ө н ә к ә *(таш өстендә йөзен күтәреп)*. Йа таш! Кайгыдан син дә ярылмыйсың! Сине күз яшьләре дә эретми. Адәм бәгъре шундый катымыни? *(Елый.)* Ыру белән ыру, халык белән халык бер-берсенә бәрелде... Алтын Урда таралып төште, шәһәрләр көл булды. Шулар арасында минем дә мәхәббәтем тамыр тартмады, үлде. *(Акрын гына сүзсез көйли. Бара торгач, ул көй ерактан, күл аръягыннан ишетелә торган думбра белән кушыла. Көнәкә туктый, көй дәвам итә.)* Тукта! Мин ни ишетәм? Әллә мин саташа башладыммы? Миңа табигать үзе көйли шикелле...

Күл аръягындагы калкуга бер процессия килеп чыга. Алдан, ике яшь е г е т култыклаган хәлдә, С у б р а, аның артыннан думбра тоткан ике е г е т.

Б е р е г е т *(туктап)*. Күрәмсең? Әнә ул юл биредән төшеп, күлне әйләнеп, анда барып чыга. Нинди күл соң бу?

[1] *Кантар* — декабрь.

Субра. Инде мин күл танымам. Әгәр дә мин танысам, бу «Канлы күл», оланнар. Идегәйнең урдасы шушында булыр.

Бер егет *(әйләнеп)*. Әй! Арбаларны бире кертмәгез. Без биредән җәяү чыгарбыз. Күтәрегез Норадынны.

Калку артыннан сөңгеле носилкага күтәрелгән авыру Норадын үткәне күренә. Процессия, калкудан иңеп, думбра авазлары астында күздән югала.

Кәнәкә *(ялгыз)*. Норадын! Аны күтәреп киләләр! Субра алар белән... Күрәсең, ул Норадынны атасы белән килештерергә алып килә. Китим? Юк... Китә алмыйм. Бу соңгы кат мин аны күрергә тиешле! Тукта, алар бире киләләр!

Кинәт думбра якын яңгырады. Камыш буйлап, Субра, Норадын һәм егетләр килеп керә.

Субра *(Норадынга)*. Төш бирегә, бала. Хәзер син бу җирдә атаңның йөзе алдында торачаксың.

Норадын *(хәлсез-авыру. Калтыранып)*. Атамның йөзе... Тәңрем! Мин аның йөзе алдында ничек торырмын? Ничек туры карармын? *(Йөзен куллары белән басып, елап җибәрә.)* Юк, юк... Миңа оят, бабам. Бар син, бар, бабам. Минем өчен аңа син сөйлә.

Субра. Тынычлан, бала. Мин, камыр эченнән кыл суырган кебек, күңелегездәге булган кинәне суырып алырмын. Кулымнан тот. Атла...

Кәнәкә *(алдына торып)*. Йа Тәңре! Норадын!..

Норадын *(туктап)*. Ә? Кем ул?

Кәнәкә. Бәхетсез Кәнәкә. Йа Тәңре! Нинди баһадир ир идең... Бүген син ни булдың!

Норадын. Туктамыш кызы? Син ничек бирелә?

Кәнәкә *(алдына тезләнеп)*. Мине кума... Кичер, Норадын! Мин синең каршыңда гаепсез. Тик бер генә нәрсә минем күңелемне әрнетә... Ул да булса сиңа әйтелми калган бер сүз: мин сине сөйдем, Норадын! *(Кулыннан тота.)*

Норадын. Мине? Син? *(Кинәт тартылып.)* Җибәр, атаңны үтергән минем бу кулымны тотасың.

Кәнәкә. Атам... Синең кулыңнан үтте. Син... Кадыйрбирде кулыннан бу көнгә төштең. Кадыйрбирде дә... әле генә шушы җирдә атаң кулыннан үтте. Әтиең...

Норадын *(кузгалып)*. Әтием? Кайда ул минем әтием? Тиз әйт: бирелә сугыш булдымы? Әллә юкса ул...

Кәнәкә. Юк, юк! А! Мин сиңа ни сөйлим! Күз алдым караңгы... бу мине, үз кулларың белән үтер, Норадын.

Норадын. Аh!

Тавышлар. Аның ярасы ачылды, тотыгыз!

Кәнәкә. Мин ни эшләдем! Әни! Әти! Аh! *(Ава.)*

Субра. Кылыч кылычка бәрелгәндә, ике арада күбәләк үлә. Адашты. Юл тапмады ханның бәхетсез кызы. Торыгыз! Без Идегәйне табарга тиешбез.

Быргы. Султан **Чулпан**, **Тыңгысын** һәм аның **кешеләре** керәләр.

Тыңгысын. Монда безнекеләр! Тукта. Бу ни? Алар аны эзлиләр? Тиз әйт, сеңел, кайда калды ул?

Чулпан. Ул биредә калды. *(Камышлыкка барып.)* Туктагыз! Кем ул? А! *(Бары да тын була. Камыш селкенә. Кангабалчыкка буялган Идегәй күренә.)*

Норадын. Әти!

Идегәй, кылычына таянып, тураерга тырышып, аңа табан бер-ике атлый. Таянган кылычы сыгыла. Авыр бернәрсә егылган кебек, гөрс итеп авып төшә, үлә.

Чулпан. Агам! *(Идегәйнең кулын алып.)* Аһ! *(Өстенә егыла.)*

Субра. Китерегез углын! *(Җитәкләнеп, хәлсез Норадын китерелә.)*

Норадын *(тезләнеп, кулын алып, көч-хәл белән).* Әти! Әти! Бер генә күзеңне ач! Күр мине! Мин нинди булдым! Синең адашкан, бәхетсез углың — мин сиңа кайттым. Бәхил бул, әти! *(Кулына йөзен куя, үлә.)*

Быргы. Каршы яктан **үз кешеләре** белән **Янбулат** керә. Кулында Идегәйнең аткан көмеш угы.

Янбулат. Туктагыз, дусларым! Мин ни күрәм? Субра, Тыңгысын... бар да тын! *(Килеп.)* Бу ни? Аһ! Бу ул? *(Чүгеп, кулыннан алып.)* Әле генә, әле генә мин синең чакыруыңны ишеттем. Әле генә аткан — бу синең угың! Ул минем кулымда. Халкым юлында. Мин әле дә исемә килә алмыйм. Әйтегез, мөмкинме бу? (...)

Чулпан *(җәяне биреп).* Тор, Янбулат! Идегәйнең угы синдә. Минем кулым белән ул сиңа җәясен дә тапшыра. Аның керешен җиткерә алучы — син калдың, Янбулат.

Янбулат. Һәм мин җиткерәчәкмен! Ант!

Чулпан *(Субрага думбрасын биреп).* Сазыңны чал, бабам.

Субра *(думбрасын алып).*

Бары да үлә, дусларым,
Үлмәгәндә ни үлми?
Батыр кеше үзе үлми.
Батыр үзе үлгәндә дә,

Эше белән сүзе үлми,
Аңа чыккан җыр үлми.
Тор, торыгыз, улларым!
Батыр каны җирдә калмас,
Байрак итеп, гәүдәсен
Кулга алыйк, улларым.
Дошман безнең юлда икән,
Көмеш уклар кулда икән,
Кыл җәяне нык тотып
Кузгалыйк, улларым!

Идегәй кулларда югарыга туп-туры күтәрелә. Көмеш уклар иренгә алына, җәяләр лира шикелле кулга тотылып, керешләре чиертелеп, процессия юлга юнәлә. Субра калку өстендә кала. Аның озын сакалы, кием чабулары җилдә җилферди.

1941

Муса Җәлил
(1906—1944)

ШАГЫЙРЬ

Төн утырып, шагыйрь шигырь язды,
Ак кәгазьгә тамды яшьләре.
Тышта давыл иде; бертуктаусыз
Күк күкрәде, яшен яшьнәде.

Җил, ишектән кереп, өстәлдәге
Кәгазьләрне чәчте, туздырды.
Аннан чыгып тышка, йөрәк яргыч
Ачы тавыш белән сызгырды.

Тау-тау булып дәрья дулкынланды,
Яшен сукты калын имәнне.
Эчпошыргыч шомлы тынлык басты
Тирәдәге карсак өйләрне.

Тик төн буе шагыйрь бүлмәсендә
Ут балкыды көннән яктырак.
Давылланып, аның йөрәгеннән
Ак кәгазьгә хисләр актылар.

Шагыйрь торды, тынып таң алдыннан,
Язганнарын җыйнап яндырды.
Үзе китте чыгып...
Җил басылды,
Давыл тынды, ал таң кабынды.

Төн утырып, шагыйрь нәрсә язды?
Нинди хисләр аны ярсытты?
Язганнарын биреп җил иркенә,
Таңда үзе кая ашыкты?

Сез сорагыз аны исәр җилдән,
Яшеннәрдән, дулкын тавыннан;
Һәм сорагыз, ямьсез төнне куып,
Таң тудырган көчле давылдан.

1942

БЕР ҮГЕТ

(кешелек турында)

Мин күп күрдем филдәй кешеләрне:
Киң күкрәкле, тимер бәдәнле.
Тик күрәсе иде эше белән
Кеше булган иң чын адәмне.

Кем сокланмас көчкә, тимер сынса
Һәм су чыкса баскан эзеңнән.
Тик ни файда, көчең филдәй булып,
Эшең булса чыпчык тезеннән.

Эзе калсын керсез намусыңның,
Ни үтсә дә синең кулыңнан.
Көчлелегең белән горурланма!
Кешелегең белән горурлан!

Һәр адымыңда синең туры акыл,
Көчле йөрәк эзен күрсеннәр,
Кылыч белән түгел, турылык һәм
Чынлык белән көчле кешеләр.

Син яшәмә җирдә файдасыз бер
Түмгәк булып тигез урында.
Янып калсын гомрең маяк булып
Үзеңнән соң килгән буынга.

Утта булган балчык кире купмас,
Эштә булган тимер тутыкмас.
Эш күрсәткән ирне ил онытмас,
Каберенә эзне суытмас.

1943

ОКОПТАН ХАТ

(Гази Кашшафка)

Кадерле дус!
Кайнар йөрәгемдә
Дәрт кабызган җылы хатыңны
Укыдым да, тотып мылтыгымны,
Кабатладым изге антымны.
Мин кечкенә кеше, тар окопта
Кечерәям булыр тагын да.
Ә шулай да бөтен дөнья бүген
Урын алган минем аңымда.
Тар окобым —
чиге капма-каршы
Ике көчнең, ике дөньяның.
Хәл ителә анда кешелекнең
Киләчәге, якты идеалы.
Сизәм, дускай: бөтен халыкларның
Күзе хәзер безгә караган.
Йөрәккә көч, кулга сәләт өстәп,
Сәлам ява һәрбер каладан.
Сизәм: анда, айлы төннәр буе
Йокламыйча, ана җеп эрли,
Фронттагы батыр улларына
Җылы бияләйләр әзерли.
Сизәм: кызлар — безнең иркә дуслар,
Станокка кушып йөрәген,
Гранаталар ясый безнең өчен,
Сындырырга дошман терәген.
Балалар да, Тимур командасы
Төзеп, безнең капка төбендә
Киңәшәләр ятим семьяларга
Ничек итеп булышу турында.
Тәүлек буе чыкмый заводтан,
Эшли безгә Лондон эшчесе,
Менә кайда дуслык тойгысының
Иң тирәне һәм иң көчлесе!..

Юк, мылтыгым,
синең утың белән
Мин сакламыйм бары үземне,
Мин кабатлыйм Гитлер бандасына
Халкым кушкан җавап сүземне.

Күңел тоя:
илнең көчле тавышы
Яңгырый һәрбер мылтык атуда.
Күңел тоя:
миңа терәк булып,
Бөек халкым тора артымда.
Ничек тоңсын йөрәк
тоеп тәндә
Шул халыкның йөрәк җылысын!
Ничек сүнсен өмет
сизеп илнең
Җиңү утын, кайнар сулышын!
Канат җәеп, үлем куркынычы
Торган саен окоп алдында,
Мин көчлерәк тоям ирек тәмен,
Яшәү дәртен кайнар канымда.
Күзләрдә яшь,
беләм: алар горур
Яшәү хисе белән яшьләнгән.
Нәрсә артык җирдә,
илне саклап,
Тар окопта батыр яшәүдән?!

* * *

Рәхмәт, дустым,
салкын чишмә төсле
Татлы сүзең җанга көч бирде,
Илдәге дәрт, ирек, яшәү хисен
Хатың аша миңа күчерде.
Кил, дускаем, шушы хат аркылы
Саубуллашып, кайнар үбешик.
Соңгы теләк:
Җиңеп фашизмны,
Якты илдә тагын күрешик.

1941

КИЧЕР, ИЛЕМ!

Кичер мине, илем, синең бөек
Исемең белән килеп сугышка,
Данлы үлем белән күмәлмәдем
Бу тәнемне соңгы сулышта.

Юк, мин сине тузан бөртегедәй
Сансыз гомрем өчен сатмадым.
Волхов шаһит: изге сугыш антын
Соң чиккәчә керсез сакладым.

Курыкмадым, өстән яңгыр төсле
Яуганда да туплар, ядрәләр.
Каушамадым, кан һәм үлек белән
Тулганда да тирә-әйләнәм.

Алда, артта, уңда һәм сулымда
Киселсә дә юлым; күкрәгем
Яраланып канга төренсә дә,
Көчсезләнеп, мин яшь түкмәдем.

Мин алдымда күрдем шыр сөяктән
Котылгысыз үлем шәүләсен.
Кил син миңа, үлем, бары гомрем
Коллык белән төгәлләнмәсен!

Мин түгелме дуска хат язучы:
«Борчылма, дип, тормыш юлдашым,
Соңгы тамчы каным тамса тамсын,
Тик антыма таплар кунмасын!»

Мин түгелме шигырь утым белән
Ант итүче канлы сугышта?
«Үлемгә, дип, ачы нәфрәт белән
Елмаермын соңгы сулышта».

«Соң чиктә, дип, синең мәхәббәтең
Җиңеләйтер үлем газабын,
Илемне һәм сине сөюемне
Каным белән җиргә язармын».

«Тыныч булыр йокы, тормышымны
Бирсәм, диеп, туган ил өчен».
Ышан, илем, шушы ант сугарды
Йөрәгемнең соңгы тибешен!

Язмыш көлде, үлем кагылмыйча
Үтте яннан, минем тирәләп.
Нишлим, нишлим, соңгы минутымда
Пистолетым итте хыянәт!

Чаян чага үзен соңгы чиктә,
Бөркет ярдан түбән ташлана.
Мин соң бөркет түгел идеммени,
Баш ияргә шуннан башкага!

Ышан, илем, шундый бөркет идем
Мин дә, соңгы минут килгәндә,
Әзер идем мәгърур канат җәеп
Ташланырга ярдан түбәнгә.

Нишлим, сугыш дустым — пистолетым —
Соңгы сүздән кинәт баш тартты.
Богау салды дошман кулларыма
Һәм хурлыклы юлдан атлатты.

Тоткынлыкта хәзер мин... Һәр көнне
Көн чыгышын комсыз күзәтәм.
Шигырь булып чыга үч ялкыны
Яраланган лачын йөрәктән.

Көн чыгышы, дуслар кулындагы
Байрак булып, көн дә кызара.
Белмисез лә, дуслар, тоткын күңел
Күкрәктәге җәрәхәттән түгел,
Канлы үчтән шулай кыза ла!

Тик бер өмит: кара август төне
Илтер мине шунда, җитәкләп.
Өстен килер түбән әсирлеккә
Үч һәм илгә керсез мәхәббәт.

Тик бер өмит, дуслар: сезнең сафта
Табар соңгы көрәш теләген
Яраланган, ләкин тар коллыкка
Баш имәгән керсез йөрәгем.

1942

КОШЧЫК

Чәнечкеле тимерчыбык белән
Уратылган безнең йортыбыз.
Көне буе шунда казынабыз,
Әйтерсең лә тирес корты без.

Кояш чыга койма аръягында,
Күрше кырлар нурга коена.
Тик нигәдер, аның нуры безгә
Тими үткән төсле тоела.

Ерак түгел урман, кыр...
Кемнеңдер
Ишетелә чалгы кайравы.
Кичә шуннан бер кош очып килеп,
Шул коймага кунып сайрады.

Чакырсам да, кошчык,
Син бу йортка
Үзең теләп очып кермәссең.
Керә күрмә, безнең кан-яшь йотып
Интеккәнне үзең күргәнсең.

Сайра безгә, шушы нәләт төшкән
Койма аша гына булса да,
Шунсы да бит безгә зур юаныч,
Җырларыңнан күңел тулса да.

Син очарсың, бәлки, минем илгә,
Син ирекле, җитез канатлы.
Тик әйт, кошчык:
Синең минем янга
Бу килүең соңгы кабатмы?

Соңгы кабат булса, тыңла,
кошчык,
Соң теләген мәгъру р җанымның:
Оч син илгә нәфрәт һәм мәхәббәт
Җыры булып тоткын шагыйрьнең.

Ук шикелле үткен канатыңнан,
Таң шикелле якты җырыңнан
Таныр сине халкым:
«Бу, дип, аның
Соңгы җыры керәш кырыннан.

Чәнечкеле чыбык бәйләсә дә,
Дип, шагыйрьнең аяк-кулларын,
Бер көч тә юк җирдә богауларлык
Аның кайнар йөрәк моңнарын».

Оч син, кошчык,
кочле җырым булып,
Шушы сиңа соңгы теләгем.
Тәнем калсын монда,
(Нәрсә ул тән?)
Барсын илгә минем йөрәгем.

1942

БҮРЕЛӘР

Кешеләр сугыша, кан коя,
Киселә меңнәрчә гомерләр.
Төн буе улашып, якында
Иснәнеп йөриләр бүреләр.

Күпме кан, күпме яшь ат ите!
Ялтырый бүренең күзләре.
Бит моны төн буе атышып
Тураган кешеләр үзләре.

Бүреләр башлыгы карт бүре,
Исереп кешеләр канына
Йөргәндә, сискәнеп туктады
Бер авыр яралы янына.

Яралы ыңраша, саташа,
Каенга терәгән башкаен.
Кызганып егетне, җил белән
Тибрәнеп сыкрана ак каен.

Кызганып егетне, елыйлар
Миләүшә һәм лалә чәчәге.
Тәгәри үләнгә чык түгел,
Гөлләрнең гөнаһсыз яшьләре.

Карт бүре егетне иснәде,
Аптырап күзенә карады.
Һәм кинәт, нидәндер сискәнеп,
Бер читкә тайпылды яралы.

Яралының зәгыйфь сулышы
Бәрелде бүренең борнына.
Юк, бүре тимәде,
сак кына
Борылып юнәлде юлына.

Таң белән килделәр кешеләр,
Күрделәр яралы егетне.
Яртылаш ул тайган исеннән,
Шулай да яшәве өмитле.

Кешеләр егетнең тәненә
Кыздырып шомполлар бастылар.
Туйганчы җәфалап,
соңыннан
Ялгыз ак каенга астылар.

Кешеләр сугыша, кан коя,
Киселә меңнәрчә гомерләр.
Төн буе улашып, якында
Исәнеп йөриләр бүреләр.
Бүреләр,
аһ... ләкин бүреләр
Бу кадәр үк ерткыч түгелләр.

1943

ДУСКА

(А. А.)

Кайгырма, дус, яшьли үләбез дип,
Без алмадык сатып гомерне,
Үзебезчә яшәп, үзебезчә
Без чиклибез аны түгелме?!

Билгеләми гомер озынлыгын
Еллар саны, картлык җитүе.
Бәлки, менә шушы үлем безгә
Мәңге бетмәс яшәү китерер?!

Мин ант иттем җанны кызганмаска,
Саклар өчен халкым, илемне.
Йөзәү булса гомрең, син барсын да
Шушы юлга бирмәс идеңме?

Шатландыра безне көн дә илнең
Бер-бер яңа уңышын ишетү;
Нинди зур көч читтә үз-үзеңне
Халкың белән бергә хис итү!

Мин тиремне саклап исән калсам,
Үлем миннән аша сикерсә,
Шул яшәүме булыр, «хаин!» диеп,
Ил битемә минем төкерсә?!

Юк, теләмим мин бу «исәнлекне»,
Йөрәк минем моңа үчекмәс.
Кешеме мин илем үги иткәч,
Җирдә миңа эчәр су беткәч?!

Юк, кайгырма, дускай, безнең гомер —
Ил гомеренең тик бер чаткысы,
Без сүнсәк тә, безнең кыюлыктан
Арта бары аның яктысы.

Батырлык һәм илгә турылыкны
Шушы үлем белән белдерик.
Безнең яшьлек шушы хисләр белән
Данлы иде, көчле иде бит!

Чикләнсә дә гомер, яшьлек безнең
Эзсез сүнә, диеп уйлама!
Әйтсен яшьләр: менә шулай яшәп,
Шулай үлсәң иде дөньяда!

1943

БАТЫРЛЫК ТУРЫНДА

Беләм, егет, синең җырыңда
Күп иленә сөю, якынлык.
Тик әйт: авыр сугыш елында
Син күрсәттең нинди батырлык?

Син бастыңмы сафка, кыенлык,
Кайгы йөген илең тартканда?
Кыенлыкта күренә кыюлык,
Ил батырны сыный батканда.

Ирлек сорый көрәш егеттән,
Ирешер өчен бөек өмиткә.
Ирек китәр, качсаң ирлектән,
Ирлек белән иреш иреккә.

Коткарырмы ялыну, елаулар,
Тоткын итсә дошман йөрәкне?
Буа алмас ләкин богаулар
Кылыч йөртә белгән беләкне!

Ни мәгънә бар эзсез яшәүдә,
Түбәнлектә, тарлык, кимлектә?
Яшәү хозурлыгы хөрлектә,
Гомер озынлыгы ирлектә.

Ил онытмас, бирсәң каныңны
Ватан өчен изге көрәшкә.
Хаин каны тама чиләккә,
Батыр каны тама йөрәккә.

Батыр үлә, үлмәс ат алып,
Батырлыклар белән макталып,
Исмең калсын, үзең үлсәң дә,
Тарихларда укып ятларлык.

1943

КҮЛМӘК

Җырлый-җырлый, Дилбәр күлмәк тегә,
Кулларында көмеш энәсе.
Җырлар түгел, җилләр җитә алмас
Ерак җирдә күлмәк иясе.

Кулы йөгрә ефәк сатин буйлап,
Тирән сагыш уйчан йөзендә.
Ефәк чигеш булып ятып кала
Йөрәк сере энә эзендә.

Атлас белән кайый ул якасын,
Ука белән тота җиң очын.
Шул күлмәккә җыйнап биргән төсле
Йөрәгенең бөтен җылысын.

Һәр чигештә күпме яшь тамчысы,
Күпме сагыш һәрбер җөендә.
Шул күлмәкме булмас яшь егетнең
Йөрәк дусты йөргән җирендә!

Җырлый-җырлый, Дилбәр күлмәк тегә,
Күлмәккәем дусын тапсын дип.
Шул күлмәкне киеп сөйгән егтем
Сугышлардан җиңеп кайтсын дип.

Тагын бизәк... Аннан күлмәк әзер.
Тик тагасы кала чукларын.
Көлемсерәп, Дилбәр карап тора,
Үз эшенә үзе сокланып.

Тәрәзәдән сузылып кояш карый,
Күк күлмәктә алсу шәүләсе.
Кояш булып күлмәк үтәсеннән
Күренә төсле егет гәүдәсе.

Ашыгып шунда берәү килеп керде,
Хат тоттырды Дилбәр кулына.
Хатта язган: «Егтең батырларча
Үлде, диеп, сугыш кырында».

Озак торды Дилбәр сүзсез катып,
Каны качты юка иреннән.
Тик күкрәге еш-еш күтәрелде,
Күл тирбәнгән кебек җил белән.

— Юк, ышанмыйм...— диде,
тавышы чыкты
Калтыранып, авыр көрсенеп.
Ике генә тамчы яшь чылатты
Гөл чуклары төсле керфеген.

Ә аннан соң тиз-тиз пөхтә итеп
Төрде дә ул зәңгәр күлмәкне,
Китте ашгып почта бүлегенә,
— Алыгыз, диде, минем бүләкне!

— Ул бит үлгән.
Ничек илтик аңа?
— Сез илтегез, үлгән булса да!
Кигерегез аңа бу күлмәкне,
Тәнен туфрак күмгән булса да.

Ул терелер кигәч бу күлмәкне,
Йөрәк уты тагын кабыныр.

Мин бит аны сөйдем чын күңелдән,
Мин бит аны көттем, сагынып...

Тыңладылар аны. Сөйгән кызның
Сүзе чындыр кебек күренде.
Һәм күлмәкне илтеп яшь егеткә
Кигерделәр...
Егет терелде.

Кояш калка, Дилбәр тәрәзәдә,
Ул ашкынып көтә сөйгәнен.
Егет кайта, йөзе кояш төсле,
Ә өстендә зәңгәр күлмәге.

— Әкиятме бу?
— Әйе.
Тик әйт миңа,
Йөрәгемнең назлы иркәсе,
Син түгелме сөю нурың белән
Кабызучы гомрем иртәсен?

Азмы күрдем окоп алларымда
Мин үлемнең кыргый биюен,
Йөз үлемнән мине тартып алды
Синең керсез, кайнар сөюең.

Йөз үлемнән калдым, йөз үлемнән
Терелеп бастым аякларыма.
Яшең белән чиккән күлмәгеңне
Киеп кайттым менә янына.

1943

СӨЮ

Өзелеп сөйде егет,
Кыяр-кыймас
Ачты аңа беркөн йөрәген.
— Сөям...— диде, ләкин назлы кызның
Ишетмәде: «Мин дә!» — дигәнен.

Кыз яратып юри әйтмәдеме,
Әллә чынлап яратмадымы?!
Тик көчәйде егет йөрәгенең
Сөю белән канатлануы.

Сугыш килде... Аерып иркәсеннән,
Ут чүленә тартып китерде.
Сөю аны алга җитәкләде,
Ярасыннан канын киптерде.

Кызы өчен, туган йорты өчен
Ул алдында булды көрәшнең.
Егетлеген шунда күрсәтмәсә,
«Егет!» диеп аңа кем дәшсен?

Сөю белән үзен көчле сизеп,
Ул атлады дәртле, өмитле.
Җиңү таңы җирдә кабынганда,
Ядрә екты, ахры, егетне.

Ул саташты соңгы сулышында,
Үлем исе аны исертте.
— Сөям...— диде,
                    һәм ул иркәсенең:
— Мин дә! — дигән тавышын ишетте.

1943

ЮЛЛАР

Юллар, юллар! Мине туган йорттан
Аерып ерак алып киттегез.
Җитәр инде, озак кунак булдым,
Хәзер кире өйгә илтегез.

Бик сагындым таныш кырларымны,
Урманымны, күпер башымны,
Бик сагындым мине өзелеп сөйгән
Нечкә билем, кара кашымны.

Көн яңгырлы иде мин киткәндә,
Карап калды боегып сердәшем,
Юешләтте аның керфекләрен
Яңгыр түгел, назлы күз яше.

Читен дә соң читкә киткән чакта,
Ярты җаның калса өзелеп!
Ярый әле, сөю белән бергә
Бар йөрәктә корыч түземлек.

Юллар, юллар! Сез бит барыгыз да
Минә шундый каты, аяусыз!
Я, әйтегез, кемнәр үтте сездән,
Салындыгыз башлап каян сез?

Минем кебек кайсы шашкын йөрәк
Беренче кат шуннан атлады?
Кемне шулай өмит, дәртләндереп,
Еракларга илтеп ташлады?

Беләм: дәртләр ташый, безне шулай
Яшьлек куша кыдырып йөрергә!
Сезне, юллар, аяк эзе түгел,
Йөрәк хисе салган бу җиргә.

Кая гына ләкин китсәк тә без,
Сукбайлыкка яшьли салышып,
Шул юллардан кире алып кайта
Туган йортка йөрәк сагышы.

Юллар, юллар! Мине, илкәемнән
Аерып, ерак алып киттегез.
Яңа дәртләр, яңа хисләр белән
Сөйгәнемә кире илтегез.

1943

ДАРУ

Кыз авырды, тәне ут шикелле,
Сулгып-сулгып тибә йөрәге.
Гаҗиз калды доктор: авыру кызга
Бер дару да файда бирмәде.

Яткан чакта авыру түшәгендә,
Авыр төшләр белән саташып,
Ачылды да ишек, юл киеменнән
Кайтып керде кызның атасы.

Маңлаенда батыр яра эзе
Һәм биләндә поход каешы.
Еллар буе кызны зарыктырды
Шул атаның йөрәк сагышы.

Таныш йөзне күреп, кыз елмайды:
«Әти!» — диеп, аңа үрелде.
Шул төнне үк йөздән тире чыкты,
Кызу кайтты, тәне сүрелде.

Гаҗәпләнмә, доктор, күреп кызның
Дару эчми кинәт савыгуын.
Белмәдеңме җирдә «сөю» дигән
Иң куәтле дәва барлыгын?!

1942

КАР КЫЗЫ

Кышкы бер җиләс кояшлы көндә,
Авылның данлы «Көмеш тавында»,
Эрер-эремәс соңгы кар җирдә
Күз яшен сыгып яткан чагында,

Шаян балалар карда тәгәрәп
Һәм кар атышып уйнап туйдылар.
Шуннан җыйнаулап, карны әвәләп,
Бер кыз сурәте ясап куйдылар.

Кич булды, салкын карны катырды,
Балалар арды һәм ирекледәр.
Кар кызын тауда ялгыз калдырып,
Җылы өйләргә кайтып киттеләр.

Төн буе кызны иркәләп, назлап
Исте көн яктан апрель җилләре,
Батыр Кояшны һәм язны мактап,
Җил кызга серле әкият сөйләде:

«Син әле, диде, белмисең безнең
Ут тәнле, кайнар Кояш батырны;
Таң кала һәркем күреп ал йөзен,
Яндыра җирне аның ялкыны».

Кыз әйтте, көлеп: «Кояшыгызга
Һәм языгызга һич китми исем,
Нәрсә ул ялкын карга һәм бозга,
Карбикә белми мәхәббәт хисен.

Мин мәңге салкын, юк миндә ялкын,
Мин кыш иркәсе, әллә белмисең?
Мин боз йөрәкле, миңа кирәкми,
Теләсә, Кояш үзе баш исен!»

Таң атты, Кояш көчле, ялкынлы,
Чыкты елмаеп урман артыннан.
Кар кызын ымлап язга чакырды,
Тапшырды букет нурдан, ялкыннан.

Кар кызы кинәт карап ымсынды,
Ярсытты аны бу көләч иртә.
Сөю ул шундый серле, тылсымлы,
Боз йөрәкне дә үбеп эретә.

Карбикә ярсып язга ашкынды,
Ул гашыйк булды көчле Кояшка.
Кузгатты җилләр язгы ташкынны,
Кудылар бозны яз килгән якка.

Кояш Кар кызын назлый, иркәли,
Яндыра аны кайнар кочагы.
Иелеп үпте ул Карбикәне,
Тартты үзенә бозлы көч аны.

Һәм кинәт кызның боз канлы ирнен
Сихерле ялкын көйдерде.
Кыз, бар хисләрен Кояшка биреп,
Гөрләвек булып гөрләп йөгерде.

Кызның йөзеннән тама тамчылар,
Бу — аның кайнар сөю яшьләре,
Ул елый, сөю язын каршылап,
Сүтелә җилдән көмеш чәчләре.

Кайда боз канлы мәгърур Кар кызы?
Акты, сөйгәне куенында эреп.
Сөю һәм яшьлек утын кабызып
Ага ул, җырлап, шашып, тилереп.

Ул тынды узган яшь гомер төсле,
Тик соңгы яше җирне чылатты.
Кыз җырлап аккан җирдә гөл үсте,
Ул Кояш төсле ал чәчәк атты.

Мәхәббәт, мине иркәм куенында
Эрет, хисләрем ташып аксыннар.
Сөю сугарган гомрем юлында
Гөлләр таң төсле чәчәк атсыннар.

1943

ЫШАНМА

Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
«Ул егылган арып»,— дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!
                    Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, якын күрсәләр.

Байрагыма каным белән язган
Антым чакра алга барырга,
Хаккым бармы минем абынырга,
Хаккым бармы арып калырга?

Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
«Алмаштырган илен»,— дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!
                    Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, мине сөйсәләр.

Илдән киттем ил һәм синең өчен
Автоматым асып аркама.
Илемне һәм сине алмаштыргач,
Җирдә миңа тагын ни кала?

Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
«Муса инде үлгән»,— дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!
                    Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, сине сөйсәләр.

Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас
Ялкынлы җыр тулы күңелне,
«Үлем» диеп әйтеп буламы соң
Җиңеп үлгән мондый үлемне?

1943

Фатих Кәрим
(1909—1945)

КЕРЕШ ҖЫР

Мин рядовой солдат бу сугышта,
Тик бер нәрсә белән аерылам:
Рядовойлар төнен йоклаганда,
Мин йокламыйм шатлык, кайгыдан.

Бер минут та башка тынгы бирми,
Окоп почмагында утырам,
Аламын да куен дәфтәремне,
Янып җыр язарга тотынам.

Ут булмаган җирдә ай яктырта,
Җыр хакына кала йокылар;
Окопларда язган җырларымны
Хөрмәт белән дуслар укырлар.

1942

ТЕЛӘК

Матурлык сайлауда мине
Кем куып җитәр икән?
Сөюдә һәм сөелүдә
Мине кем җиңәр икән?

Яшәдем, яшел урманнар
Иркәләде, көйләде,
Инде мин сугыш кырында,
Тик бер генә теләгем:

Дошманга ялкын сибүче
Җил булып барсам иде,
Тәвәккәллек, батырлыкта
Җыр булып калсам иде.

1942

ЮЛ

Үзен аска, җиңен баш очына
Салам да мин соры шинельнең,
Карап барам ачык тәрәзәдән
Урманнарын Туган илемнең.

Каеннарның көзге яфраклары
Манчып алган кебек алтынга,—
Ялтырыйлар алар тын офыктан
Кичке кояш сипкән ялкында.

Тагын барам, мин сугышка барам,
Паровозның моңсу тавышы:
— Кайтырсың! — ди; димәк, алда әле
Көтә мине тагын кавышу.

Кайту да юк ләкин, кавышу да,
Дошманнарны әгәр җиңмәсәк,
Данлы җиңү байраклары белән
Илнең кайгы яшен сөртмәсәк.

1942

БЕЗДӘ ЯЗДЫР

Бездә хәзер ямьле яздыр, иркәм,
Көн кояшлы, төннәр айлыдыр,
Идел буендагы бакчаларда
Сыерчыклар ярсып сайрыйдыр.

Кошлар моңы уятадыр сине,
Челтәр пәрдәләрне күтәреп,
Язгы таңны күзлисеңдер ялгыз,
Чәчәк аткан гөлләр үтәли.

Ә биредә, без фашистлар белән
Бугазлашкан урман, кырларда,
Күңел өчен бер генә кош та юк,
Язны хәтерләтеп җырларга.

Дулкынланып, шаулап торган урман
Сынып беткән, изеп тапталган,
Чәчәк үсә торган киң болыннар
Кеше каны белән тапланган.

Фашист тырнагына капкан кеше
Сыкрамыйча монда тын алмый,
Янган авылларның төтеннәре
Язгы таңның нурын томалый.

Фашист илгә үлем генә китерә,
Фашизмның таңы, язы юк.
Яшен уты белән күккә язып әйтәм:
Язы юкның яшәү хакы юк!

1942

УРМАН ТЫН ИДЕ

I

Тавыш-тын юк, җил дә исми,
Урман тын иде,
Йолдызлар коелып торган
Кышкы төн иде.

Тын иде төн, тик командир
Каен төбендә
Тора кочаклап каенны
Бу серле төндә;

Үзе билдән карга баткан,
Карый: төн үтә,
Керфекләрен дә селкетми,
Сулышсыз көтә;

Көтә күктә очкыннарның
Ялтырауларын,
Урманнар, текә тауларның
Калтырауларын.

II

Командир каен төбендә
Егетне көтә,
Ә егет дошман постларын
Шуышып үтә;

Үтә ак халатлы егет
Куак астыннан,
Үтә күзгә чалынмаслык
Ак шәүлә сыман.

Менә вокзал, караңгыда
Эшелон тора,
Безнең егет бак астына
Шартлаткыч кора;

Кора да алга суза ул
Бикфорд шнурын,
Сайлый очкын җибәрергә
Уңайлы урын...

Һәм кинәт гөрселди дөнья,
Күккә атылып,
Янар тау кебек үкерә
Бензин ялкыны.

III

Ургып гөрләсә дә ялкын,
Урман тын иде,
Йолдызлар коелып торган
Кышкы төн иде.

Фашистларның автомобиль,
Бар танкларын,
Аларга сулыш китергән
Бензин бакларын

Коңгырт күзле, карсак кына
Казан егете
Бу йолдызлы кышкы төндә
Кара көл итте.

IV

Командир каен төбендә
Егетне көтә,
Башыннан җырларга сыймас
Хыяллар үтә.

Көткән минут җиңү алып
Килергә тиеш,
Тик кайтырмы киткән егет,
Сау-исән килеш?

Бәлки, ул киткән җиреннән
Кайтмас, югалыр,
Ләкин исеме, дан күтәреп,
Җырларда калыр;

Җыр булып калыр елларга
Яшьлек иртәсе,
Яшьлекнең канат җилпегән
Романтикасы.

1942

МИН — ГУМАНИСТ

Фашист-автоматчик ак каенның
Очына ук менеп утырган.
«Аксын, вандал, аксын үз каның!» —
Йөрәгенә төзәп аттым аның,
Яңгырады таңгы тын урман.

Нәфрәт агуына манчып аткан
Үч алучан пулям сызгырды.
Сыны катып бертын торды да
Актарылып төште югарыдан
Күзе тонган фашист козгыны.

Мин бер шагыйрь — тойгы, хис кешесе,
Яратам мин кошлар сайравын;
Мин — гуманист, сөям дөньяны,
Акмасын, дим, җирдә кеше каны,
Гуманизм — минем байрагым.

«Мин — гуманист»,— дидем, үзем менә
Бу кешенең гомерен бетердем...
Юк, кеше гомерен бетермәдем,
Сабыйларның яшен суыручы,
Бәхет бакчаларын корытучы
Иң әшәке кортны үтердем.

Фашистларны кем күбрәк кырса,
Ул үзенең Туган илендә
Чын гуманист булып мактала,
Даны җырга күчеп кабатлана
Ирек сөйгән халык телендә.

1942

НЕМЕЦ ҖИРЕНДӘ

Каберлеккә кердем, гел мәрмәр таш,
Төбәбрәк күз салсам,—
Бер мәрмәр юк, бөтенесе эрзац,
Юктан-бардан ясалган.

Хәтта иген үскән туфрагында
Үчем булган бу илнең,
Авыз-телем кибеп сусасам да,
Суын эчәсем килми.

Аккан суларында су тәме юк...
Һава җитми сулышка.
Чөнки өйләр тормыш өчен түгел,
Җайланылган сугышка.

Ашкынамын ләкин җиңеп, җимереп
Барырга Берлинына.
Берлин аша гына тыныч, шат юл
Идел аккан илемә.

Идел дулкыннарын сагынам мин,
Кызарып таң атканда;
Дошман юлын кисеп, таң алдыннан
Күперләр шартлатканда.

1944

ИСӘ ҖИЛ

1

Исә җил, тирбәлә тирәк,
Ул тирбәлә, ә йөрәк?
Йөрәгем яна минем,
Яна көндез, яна кичен,
Синең өчен, Туган илем,
Синең язмышың өчен.

2

Исә җил, тирбәлә камыш,
Ул тирбәлә, ә сагыш?
Ник бу чаклы сагынам?
Сагынсам да, ничек барыйм?
Карыйм мин Урал ягына,
Офыклар аша карыйм.

3

Исә җил, тирбәлә нарат,
Ул тирбәлә, ә Хәят?
Хәятем нишли икән,
Патронны мин аткан санда
Ул ясап өлгерә микән,
Өлгерә микән анда?

4

Исә җил, тирбәлә тирәк,
Ул тирбәлә, ә йөрәк?
Йөрәгем яна минем,
Яна көндез, яна кичен,
Синең өчен, Туган илем,
Синең язмышың өчен.

1942

УМЫРЗАЯ

Туган илнең туфрагында үскән
Умырзая чәчәген,
Өзеп алып, хат эченә салдым,
Хат белән китәчәк ул.

Хат алырсың тиздән, мине сагынып,
Моңаеп утырганда;
Күкрәгеңә када бу чәчәкне,
Хатымны укыганда.

Җавап язсаң, берничә җыр яз син,
Җыр өметне яңарта;
Мәхәббәтнең нечкә, саф серләрен
Тик җыр гына аңлата.

1943

КҮЛ ҺӘМ КҮҢЕЛ

Күлне сыйпап, җил исә,
Тирбәлеп, камыш үсә,
Аккош йөзә бу күлдә,
Ә син минем күңелдә
Аккош булып йөзәсең,
Тик күңелнең чиге юк,
Күңел — диңгез, күрәсең.

1943

ТИМЕР ҺӘМ ТИМЕРЧЕ

(баллада)

1

Колхоз тимерчесе Саттарга,
Яше урләгәндә иллегә,
Гранаталар тагып биленә,
Туры килде илен сакларга.

Ник бугаздан буа бу һава,
Нигә колак чыңлый окопта?
Җир сискәнеп китә һәр туптан,
Яңгыр булып җиргә ут ява.

Карый Саттар, карый үрелеп,
Үлем килә, күзгә күренеп:

Танк килә — кара тәреле,
Улап килә Саттар янына;
Тимерчеме тимер тавына,
Таумы тимерчегә бәрелер?

2

Үлем урләмәсен терегә,
Тере тәгәрәтсен үлемне!
Моның өчен уйны, күңелне
Кирәк броняга төрергә.

Җан кадерле, дуслар, сугышта,
Сугышырга чөнки җан кирәк,
Үлә калсаң, әйдә, бу йөрәк
Сер бирмәсен соңгы сулышта.

Карый Саттар, карый үрелеп,
Үлем килә, күзгә күренеп:

Танк килә — кара тәреле,
Улап килә Саттар янына;
Тимерчеме тимер тавына,
Таумы тимерчегә бәрелер?

3

Нинди шәүлә артка йөгерә?
Күзләр аңа табан әйләнә;
Бу йөгергән куркак гәүдәгә
Саттар мылтык төзәп өлгерә.

Вөждан рөхсәт итә атарга,
Ава җиргә куркак гәүдәсе —
Калмый эзе, калмый шәүләсе,
Һәм кабер дә булмас аңарга.

Нәфрәт кенә килер янына,
Җир чирканыр аның каныннан.

Кеше тапмый зарын сөйләргә,
Яшен яшереп елар анасы,
Егерме ел сөйгән баласын
Теле бармас «улым» диярга.

4

Илгә биргән антын бозарга
Кем башында кара уй йөри,
Саттар әзер аның гомерен
Яшәү дәфтәреннән сызарга.

Фашистларның канлы юлына
Гранит кыя булып басарга;
Ут айкаучы таулар ясарга
Ватан корал биргән кулына.

Ватан юл бикләргә кушканда,
Куркак капка ача дошманга.

Тимер бикле капка янында
Үлсен башта капка ачучы!
Ул — Ватанын ташлап качучы,
Аның эзе дошман ягында.

5

Танк килә, җирне туздырып,
Үлем богаулары шалтырый,
Бомбалардан таулар калтырый,
Мина, туплар оча, сызгырып.

Яшереп булмый, курка тимерче:
«Ычкынмасын кулдан бу «үлем»,
Үзем үлсәм, бәхил бул, илем»,—
Дип, тимерче җыйный бар көчен.

Ул кулына гранат тоткан,
Ул үрмәләп чыга окоптан;

Улап килгән танк янына
Ул үрмәләп каршы бара да
Танк боргаланган арада
Бәрә төзәп бензин багына.

6

Гөрселди җир кичке шартлаудан,
Канатлана бензин ялкыны;
Соңгы тапкыр танк талпынып
Туктый безнең җирне таптаудан.

Тимерченең тимер йөрәге
Ачу уты белән тулышкан,
Күрек кебек калка сулыштан
Колачка чак сыяр күкрәге.

Сулый Саттар танк янында,
Гүя аны өреп яндыра.

Үлем арбасына каныкты,
Каныкты җил көзге салкында,
Йолкый-йолкый талый ялкыннар
Кара тәре таккан танкны.

7

Яна дөрләп ләгънәт утында,
Яна танк — кара тәреле;
Тимерчегә килеп бәрелде
Тимер тавы сугыш судында.

...Җиңү җәелер тиздән һәр якка,
Тимерченең туган иленнән
Мәгърур тавыш яңгырар: «Суд кылә!»
Юлбасарлар басар аякка.

Җинаятьләр тавы чишелер,
Өсләренә килеп ишелер.

Танк ватыкларын сандалга
Салыр бу көн безнең тимерче,
Чүкеч үтә йөртеп бар көчен,
Богау ясар һәрбер вандалга.

1942

ӨМЕТ ЙОЛДЫЗЫ

Искә алып, әрнеп сагынырлык
Үткән матур көннәр күп күбен;
Кара чәчем кардай агаргач та
Онытмас хәл күрдем мин бүген.

Язгы кичтә шаулап бозлар ага,
Ярларына сыймый киң елга;
Бозлар аша кичеп киң елганы,
Килеп кердек без бер авылга.

Ярты авыл янып күмерләнгән.
Кешеләре, белмим, тереме?
Янмый калган ялгыз өйләрдән дә
Аңкып тора кайгы сөреме.

Кайда халык? Аның хакын даулап,
Күпме немец, мадьяр үтердек.
Сөйгән халык кайда? Без бит аңа
Азатлык һәм шатлык китердек!

Авыл урамында шомлы тынлык,
Бөтенләйгә тормыш сүнгәнме?
Ник җырламый язгы кичтә бер кыз,
Нигә искә алмый сөйгәнен?

Тик сыерчык — язның фәрештәсе —
Кунган да ул көйгән тирәккә,
Җырлый ярсып, канатлары белән
Бер ашкыну җилпи йөрәккә.

Ашкынулы адым көче белән
Тетрәндереп җансыз урамны,
Үч яшене итеп алып барабыз без
Антлар биреп алган коралны.

Без барабыз. Менә безгә каршы,
Ак яулыгын болгап, кем килә?
Хәсрәтенә шатлык чәчәк сипкән,
Сабыйларча үкси һәм көлә.

Гүя аның калку күкрәгенә
Килеп кунган өмет йолдызы;
Каршыбызда тора бәхет көтеп
Күзе талган белорус кызы.

Күпме көткән бит ул күз яшенең
Куанудан беркән тамасын;
Күкрәгенә кулын салып сулый
Без китергән язның һавасын.

Янып алсулана иреннәре,
Кулын суза килгән ягына:
«Ниләр генә әйтим, әй туганнар,
Ашыгыгыз халык янына!

Бер сарайга җыйды авыл халкын
Утта яндырырга дип дошман;
Халык сыкрый анда, үлем көтә,
Өметләрен өзеп тормыштан.

Мин ындырдан карап тордым качып,
Дошман өлгермәде, ашыкты;
Ут чорнады үзен, каушады ул,
Халык белми тик бу шатлыкны.

Өлгермәде дошман яндырырга,
Тупларыгыз яуды юлына;
Сезнең ядрәләрнең яшене сукты
Утлы кисәү тоткан кулына.

Ашыгыгыз, әйдә, минем арттан!» —
Дияргә ул бары өлгерә;
Борыла да, чәчен сирпи-сирпи,
Ак яулыгын болгап йөгерә.

Нинди көчләр тыя алсын бу чак
Ут буасын ерган агымны;
Омтылабыз без дә, йөрәкләрнең
Тибешенә тиңләп адымны.

Тукталабыз барып таш сарайга,
Бикле аның тимер ишеге;
Чыннан дамы бире тутырганнар
Авылдагы бөтен кешене?

Чиләк белән бензин, каплы шырпы
Торып калган ишек төбендә;
Без кичексәк, сөремләнгән ялкын
Дөрләр иде авыл күгендә.

Янар иде дошман яккан утта
Акылларын җуеп аналар;
Уйлап кына кара: нинди дәһшәт,—
Утта янар иде балалар!

Шундый сыкрау каплар иде җирне...
Гамьсез йөзәр иде ай гына...
Юк,
Хәтта айның, хәтта йолдызларның
Яше тамар иде кайгыдан.

Таш сарай тын, тимер ишек бикле,
Аркылыга такта кагылган,
Бу тактага йөрәк яргыч бер сүз:
«Яндырырга!» — диеп язылган.

Безгә ачык: бары көч һәм корал
Айкап ташлый коллык тәхетен;
Көч һәм корал нурлы кояш итә
Дошман томалаган бәхетне.

Ялкынлана ачу, кайный нәфрәт;
Шинельләрнең җиңен сызганып,
Лом, балталар белән каерабыз
Ишектәге михнәт йозагын.

Каерабыз, авызын ача йозак,
Теше сынган арыслан сыман;
Артка чигә куркып караңгылык,
Ава ишек аяк астына.

Кешеләргә төшә көн яктысы,
Алар нәрсә өмет итәләр? —
Дымлы җиргә тырнакларын батырып,
Бу кешеләр үлем көтәләр.

Сарай тулы халык: картлар, яшьләр,
Йөзе җыерчыклы сабыйлар;
Сабыйлар да монда гомерләрен
Сулыш саны белән саныйлар.

Иреннәре кипкән янып, әрнеп
Һәм сагынып, зарыгып сулаудан;
Күңелләре ләкин тапланмаган
Түбәнсенеп шәфкать сораудан;

Утыралар каш астыннан карап,
Бу сыйфат хас илем халкына:
Коллык упкынына төшмәгәннәр,
Вөҗдан сатып яшәү хакына.

Ава ишек, төшә көн яктысы,
Тик ишекне кемнәр ватканын
Белми халык... белми бәхетенең
Кочагына кире кайтканын.

Шуңар, ахры, горур караш белән
Бөтенесе артка авышып
Текәләләр ишек яктысына,
Тыңлар өчен безнең тавышны.

Ә кыз һаман хисләр ташкынында
Әйтә алмый сүзен... Күзенә
Тулган яше кайнар эзен сала
Аның сула язган йөзенә.

Күзен йомып, башын күтәрә кыз,
Ятлый гүя әйтер сүзләрен;
Озын керфекләре тирбәлешә,
Кинәт шатлык бөрки күзләре.

«Каерып ыргытыгыз кайгыгызны,
Безнекеләр килде — яз килде!»
Бу сүзләре сулган яфракларга
Җылы яңгыр булып сибелде.

— Безнекеләр?
— Әйе, безнекеләр!..—
Кычкыра кыз бөтен көченә;
Һәм колачын җәеп ташлана ул
Дулкынланган халык эченә.

Күзнең көче җитми һәр кешенең
Куануын аерым карарга;
Шарлавыктай гөрләп, тар ишектән
Ургылалар безнең арага.

Еллар буе хәсрәт уты йотып
Саргаешкан халык тын ала;
Шатлык диңгезенең ярлары юк,
Бу диңгездә дулкын кузгала.

Сизгер күзләр сискәнәләр кинәт,
Текәләләр: безнең каршыда
Шәрә тәнгә иске толып кигән
Бер карт тора. Аның башында

Бүреге юк, керләнгән ак чәче
Киң кашларын каплый, таркалып;
Как сөяккә калган күкрәгенә
Пәрдә булып төшкән сакалы;

Ике кулын сузган — калтырана,
Күктә түгел аның уйлары;
Сөйкемле карт кочакларга тели
Үзен азат иткән улларын...

Бу минутта уйлар илне каплый,
Искә төшә авыр үткәннәр:
Окоп төпләрендә ялкын йотып,
Хыял белән җиңү көткәннәр;

Урманнарда, җил-яңгырлы төндә
Якын иптәшләрне күмүләр;
Ил язмышы кыл өстендә чакта,
Җиңү өчен җирне үбүләр —

Күз алдыннан үтә бөтенесе,
Берсен берсе алга этәреп;
Җиңү ләззәтендә йөзә күңел,
Бөтен җилкәннәрен күтәреп.

Корал тотып халык бәхете өчен
Көрәшүнең якты шатлыгын
Бөтен көче белән татый күңел,
Бизи аны кояш аклыгы.

1944

Гомәр Бәширов
(1901—1999)

НАМУС

(романнан өзекләр)

Унбишенче бүлек

I

Сугышчыларга җибәрәсе бәйрәм бүләген күптән үк әзерли башлаганнар иде. Тимергали агай ферма сарыкларыннан алган йоннан ун пар киез итек бастырып куйды, берничә кыска тун тектерде.

«Фронтка делегат булып йә Наташа, йә Нәфисә китәсе икән, алар бүләкне сугышчыларга үз куллары белән тапшырасылар икән!» дигән хәбәр ишетелүгә, һәр йорт, хәлле — хәленчә, үз бүләген хәстәрләргә кереште. Кыр эшләре бераз җиңеләя башлау белән, кызлар, кич утырып, җырлый-җырлый, яулык чигәргә, оекбашлар, бияләйләр бәйләргә тотындылар.

Бер якшәмбе көнне шул бүләкләрне җыю башланды.

Мыек Шәмсетдиннең, таягын болгый-болгый, аваз салып бер әйләнүе булды, Байтирәкнең хатыны-кызы, култык асларына төенчекләрен кыстырып, клубка агыла башлады.

Айсылуның мич буендагы кызыл япкан киң өстәле янына берсе артыннан берсе, үзенә бертөрле тантана белән, бәйрәмнәрдә генә кия торган яңа бишмәтен яисә бәрән әчле яңа тунын киеп, башына калын шәлен ураган әбиләр, олы яшьтәге апалар, җиңгиләр, кызлар киләләр. Менә, аягына тирән кунычлы галош киеп, башына мамык шәлен урап, озын буйлы Мәүлиха түти, аның белән Айтуган бабай карчыгы Җәмилә һәм яшел тәнҗылыткычын кигән, тагын да юанаеп киткән бригадир Йөзлебикә килеп керәләр. Айсылу алдына ап-ак итеп юган йомшак оекбашлар, ике бармаклы солдат перчаткалары өелә. Әбиләрнең үз гомерендә бик күп матур эшләр башкарган, бик күп балалар

сөеп үстергән, җәй тегеп бөтен семьясын киендергән эшчән кулларын үзләре йонын эрләп, үзләре бәйләгән йомшак перчатка һәм бияләйләрне сыйпап куя. Алар, эчке бер дулкынлану белән, акрын гына әйтеп, бүләкләрен яздыра башлыйлар.

— Шунда теркәп куй әле, кем, Айсылу. Ике пар бияләй, бер пар оекбаш, бәти йонынннан гына. Әйе.

— Миннән бер бәрән тиресе яз, аннары менә бер колакчын бүрек дип тә әйтеп куй.

— Киез итек белән кулъяулык...

— Оекбаш белән бер пар бияләй...

Айсылу, аягүрә торып, аларның кулларын кыса, аркаларыннан сөеп кала:

— Бик рәхмәт! Зурладыгыз! Бу бүләкләрегез беркайчан да онытылмас! Беркайчан да!..

Шуннан соң, аяк очларына гына басып, Хәйдәр сөйләгәнне тыңларга дип, залның түренәрәк узалар.

Хәйдәр өстәл артына кереп баскан. Өстендә шинель, биленде каеш, кара бөдрә чәче күперең тора. Бер кулындагы хатына, бер каршысында тыгыз төркем булып басып торган җитди чырайлы әбиләргә һәм апа-җиңгиләргә карый-карый, Гөлзәбәрнең Сталинградтан җибәргән соңгы хатын укый. Аның тавышы бер акрыная, бер дулкынланып, яңгырап китә, ара-тирә ул, йодрыгын селти-селти, кемгәдер янап та куя иде.

«...Егерме икенче тәүлек дигәндә, фашистлар трактор заводы турысында Идел буена килеп чыктылар. Сугыш дәһшәте бу батыр шәһәрнең урамнарына күчте. Шуннан бирле монда көн дә юк, төн дә юк. Икесе дә бер. Шәһәр меӊ җирдән яна, аның өстендә берьюлы йөзләрчә самолётлар үкерә, урамнарында берьюлы меңнәрчә бомбалар ярыла. Төне — көндезге төсле якты, көндезләре — төн кебек караңгы. Бөтен шәһәр өстен ачы төтен баса, кара сөрем баса. Монда янган тимер, кызган кирпеч һәм көек исеннән тыннар кысыла. Урамнарында буйдан-буйга туплар гөрселди, бөтен нәрсәне сытып, җимертеп, үкерә-үкерә, танклар йөри. Бишәр катлы таш йортлар, күзең йомганчы, тузан белән кирпеч ватыгына әйләнә. Җир тетрәнеп тора. Иделдә сулар айкала. Инде түзәрлек чама юк, инде безнекеләр кырылып беттеләр, харап булдылар, дисең... Юк, туганкайларым, юк! Алар һаман сугышалар! Аларның керфекләре көя, чәчләренә ут каба, канга батып, аяктан егылалар. Тик барыбер чигенмиләр! Юк, чигенмиләр, сөеклеләрем!

Тагын ниләр языйм? Таш өстендә таш калмады, агач затыннан агач калмады, куаклар калмады, бернәрсә калмады — һәммәсе янды, көйде, кара күмергә әйләнде. Тимер булып тимер бөгелде, корыч булып корыч тетелде. Әмма безнең совет сугышчысы анда

да бирешмәде, баскан җиреннән шунда да чигенмәде! Туганнар! Дускайларым! Сөекле авылдашларым! Башларыгызны күтәрегез! Идел суы кирегә таба акса агар, әмма Сталинград башын имәс! Сталинградны дошман беркайчан да ала алмас!..»

Үз гомерендә өч-дүрт сугышны башыннан уздырган, үз баласын гына түгел, балаларының балаларына кадәр сугышка озаткан, каныңны өшетерлек дәһшәтле хәбәрләрне дә тешен кысып тыңларга өйрәнгән ак чәчле әбиләр, ку рыс чырайлы солдат хатыннары күзләрен сөртә-сөртә кул чабалар.

Ишектән һаман керә торалар, төенчекләр һаман чишелә тора.

— Менә монысын кызым чикте, монысын үзем бәйләдем,— диләр, Айсылу алдына чиккән кульяулыклар, янчыклар, оекбашлар өеп куялар.

— Менә питрау тиресе. «Үзенә» тун тектерербез дип әйтеп саклаган идек тә, хәзер инде тун кайгылары түгел, Туган ил кайгысы, язып куй шуны, Айсылу! — диләр, тун теккәнне көтеп, келәт киштәсендә эленеп торган тәкә тиреләрен, аның янына кушып, колакчын бүрекләрен, кыска туннарын китереп салалар.

Берсе артыннан берсе керә торалар, өстәлгә өя торалар, сугыштагы улларын, ирләрен, кияүләрен, үз эшләре белән китеп, шул эшләрен бетерүгә озакламый кайтып җитәсе кешеләр турында сүз баргандай, җылы сүзләр белән искә алалар.

— Гөнаһ шомлыгы, былтыр бит аның кышы да нинди рәхимсез булды. Ничек чыдамак кирәк? Мылтыклары тимер, машиналары тимер, башларына кигән чүлмәк кук нәмәрсәләренә хәтле тимер — һәммәсе тимер!

— Ничек кенә булмасын, барыбер туңарга ирек бирмәбез! Быел киез итек тә күп булыр, кыска тун да җитәрлек булыр, колакчыны да, башкасы да — бөтенесе булыр, боерган булса.

Айсылу бүләк әйберләрне өсте-өстенә өя бара, һәм аңа шушы бүләкләрдән халыкның күңел җылысы бәрелеп торадыр шикелле тоела. Халык перчатка һәм бияләйләр генә түгел, сөекле Туган иленә, аның сугышчыларына иң ялкынлы туганлык сәламен, кайнар мәхәббәтен, төпле ышанычын да алып килә, аналар күңеленең бетмәс-төкәнмәс шәфкатен, изге теләген алып килә. Менә бу йомшак перчаткаларның матур күзәнәкләренә яшь киленнәрнең нинди генә кайнар теләкләре бәйләнмәгән дә, бу яулыкларга колхоз кызларының нинди генә нечкә тойгылары чигелмәгән!

Ул, бер кочак әйберне алып, икенче өстәлдә аларны дистәләп бәйләп торучы Хәдичә түтигә илтеп аударды.

— Күрдеңме, Хәдичә түти! Күрдеңме, ничек агыла! Болай булса, мөгаен, Аланбашлардан күбрәк җыябыз! Уенсыз, менә күрерсең!

Хәдичә түти, иреннәрен еш-еш кыймылдатып, оекбашлар саный торган килеш:

— Әйе, әйе! — дигәндәй, башын селкеп куйды.

Бүләкләрне арбага төягәндә, Хәдичә түтине тагын бернәрсә куандырды.

Олаучыларның берсе Илгизәр иде. Ул тыгызлап тутырылган үзе кадәр бер капчыкны җилкәсенә ала башлагач, Хәдичә түти, кабаланып, аңа ярдәмгә ашыкты:

— Ай, балам, сабыр ит, биленне имгәтерсең!

Ләкин карчык кулын сузарга өлгерә алмый калды, килбәтсез зур капчык, күз ачып йомганчы, улының аркасына ук менеп китте. Хәдичә, каударлана торгач, ничектер, стена белән капчык арасына килеп керде. Тик аңа улының, көлемсерәп:

— Әни, кысыла күрмә! — дигәне генә ишетелеп калды.

Икенче күтәрелеп караса, исе китеп бот чапты: аның моңарчы вак-төяк йомышка йөгертеп өйрәнгән чандыр гына төпчек малае урынына ишектән шактый таза гәүдәле яшь бер егет кереп килә иде. Ие, Хәдичә түти Газиз хәсрәте, тормыш мәшәкате белән миңгерәп йөргән арада, аның төпчек улы егет булып җитә язган лабаса! Карасана! Изүләрен чишеп җибәргән, биленә, әтисе крушник чагында бәйләгәндәй итеп, очларын салындырып, зәңгәр пута ураган. Аягында гармун кунычлы күн итек, кулында күн бияләй... Көрәшчеләр кебек, терсәкләрен киереп, алпан-тилпән атлаган була... Хәтта ул чәчен дә, абыйсы Газиз кебек, артка таба тарап йөртә башлаган!

Шушы үзгәрешкә хәйран калып торганда, Хәдичә колак төбендә генә Мәүлиха тавышын ишетте:

— Үсәләр, яшьләрне әйтәм... Менә төпчегең дә күтәрелеп килә инде. Күрдеңме нинди!

Хәдичә түти башын чайкап куйды:

— Үземнең дә исем-акылым китеп тора. Тагын бер солдатым үсеп килә икән лабаса! Кара син, ә! Ни арада, ничек шулкадәр тиз үсә бу яшьләр?!

— Эш үстерә булыр, Хәдичә түти, басу җиле, җир сулышы шулай тиз үстерә булыр. Былтырдан бирле басудан кайтып кергәннәре дә юк бит.

— Тәгаен шулайдыр, Мәүлиха! Кырда эшли башлаганнан бирле, үзалдына бертөрле буыннары ныгып, килеш-килбәтенә тикле үзгәреп китте.

Хәдичә түти авызын каплый төшеп елмаеп куйды. «Менә сиңа мә! Тегеләй итәсем бар, болай итәсем бар, имеш! Карасана кыланышларын!»

Шул ук вакытта Газиз үлгәннән бирле беренче мәртәбә үзендә дә элекке сыман төпле бер сабырлык, ныклы күңел тынычлыгы урнашып килүен сизә иде.

II

Бүләк төялгән зур-зур өч йөкне бер төркем хатын-кыз, олы урамнан күпергә борылып төшкәнче, карый-карый бардылар.

Бу бүләкләрнең сугыш эченә үк барып җитәчәкләре, аларны сугышчыларның сөенә-сөенә һәм туган-үскән җирләрен сагынып сөйли-сөйли киячәкләре күз алдына килеп дулкынландыра да, солдатларны озаткандагы сыман, бераз ямансулата да иде.

Йөкләр тыкрыкка кереп күздән югалганнан соң, Мәүлиха түти:

— Бүләкләребез бәйрәмгә барып җитәр лә, Айсылу! — диде.— Шәт, соңга калмаганбыз бит?

— Тәгаен барып җитәчәк! Әле бит Октябрь бәйрәменә башланмаган ун көн бар. Тик менә кайсы алып китәр икән безнең бүләкне? Нәфисәме, әллә Наташамы?

Ул арада Иделнең югары ягыннан, якын-тирәне шаулатып, бомбардировщиклар төркеме килеп чыкты. Беренчесе артыннан икенче, өченче төркемнәре узды. Айсылу, аларга кул изи-изи, сәламләп калды.

— Киттеләр, җанкисәкләрем! Сизәсезме: бөтен ил кузгалды, бөтен совет халкы! Ярсыды халык, апакайларым, халыкның ачуы кабарды!

— Берүк хәере белән!..

Ниндидер бер куанычлы хәл исенә төшкәндәй, Хәдичәнең йөзе яктырып китте:

— Кара әле, сез дә искәрәсезме? Боларны әйтәм, соңгы көннәрдә гел ишәя баралар бит! Гел уза, көне-төне гел узып кына тора. Болар барысы да шул Сталинградка баралардыр инде.

— Шунда, туганкайларым, барысы да шунда! — Байтак сүзсез барганнан соң, Айсылу: — Әйе, Сталинград ягына! — дип әйтеп куйды.— Күңелем сизә, апакайларым: бер хәл булыр анда, булмыйча калмас. Бик нык куандырыр әле безне Сталинград!

— Шулай гына була күрсен.

Шушы арада Солтангәрәйдән дә хат килгән икән. Хәдичә шул турыда сөйләп алды.

— Бик исән-сау дигән, ил-күршегә бик күп итеп сәлам әйткән. Ул да шул Сталинград янында сугыша булса кирәк. Илгизәр белән атасы, шулайга охшый, диләр. Әпипәсе теге вакытны, вагын-төяген сатып, кала белән авыл арасында әвеш-түеш китереп йөрүче бер бәндәгә ияреп киткән иде ләбаса. Әле анысы, Әпипәнең бөтен маен имеп бетергәннән соң, Чистай пристаненда кара җәяү калдырып ташлап киткән, ди, тагын. Ул турыда да язган. «Кешенең кемлеге шундый кыен вакытта тизрәк беленә икән. Сугыш булмаган булса, ул кара еланны гомер буе куенымда асрыйсы икәнмен. Муены астына килсен.

Баш исән булса, илдә чын иптәш булырлык тәүфыйклылар да бетмәс әле,— дигән.— Әле инде Кәтүшә җанкисәгем белән бик дуслашып торабыз. Көне-төне бергә, бер минут аерылышканым юк»,— дип язган.

Мәүлиха түти, сузып кына:

— Ә-ә-ә, чибәр нәрсә очраган инде, алайса, бер-берсен ошатканнар, күрәсең,— дип куйды.— Язасыгыз калган. Кәтүшәсен Байтирәккә озатсын иде. Йорты поста тора бит.

Айсылу белән Хәдичә бер-берсенә карашып көлә башладылар. Айсылу, Мәүлиханың иңбашыннан кагып:

— Юләрем, синең ишеткәнең юкмыни? — диде.— «Катюша» дигәне безнең совет инженерлары уйлап чыгарган шундый яңа корал ич ул! Гитлерчыларны йөзәрләп берьюлы кырдыра торган әйбәт бер нәмәрсә!

Мәүлиха түти хәйран калды.

— Китсәнә аннан! Үлмәсәң, әлләниләр ишетерсең. Мин тагын Солтангәрәйне Кәтүшә исемле яшь кәләш алып кайта дип торам.

Колхоз канцеляриясе каршында Айсылу, нидер әйтәсе бар кебек, акрынлый төште.

— Бүген сезгә кереп чыга алмадым, Хәдичә түти. Тимергали абзый төнне ничегрәк уздырды? Бик ватылмадымы? Бәйрәмгә чаклы аягына басар бит инде, ә? Ничегрәк, синеңчә?

Карчык, Айсылуга ягымлы күз салып:

— Бу нинди рәхмәтләр яуган яхшы җан икән! — дип уйлап куйды.— Менә бит, һәркайчан шулай: сине бер сүзе белән эретеп җибәрә, җаннарын ярып бирерлек булып өзелеп тора. Ә үзе, Тимергали өчен эшли-эшли, бер ай эчендә әнә нинди ябыкты! — Тимергали абзыең, Алланың биргәненә шөкер, ярыйсы гына. Күңеле дә көр шикелле. Күптән торасы да бит кана, күптән аякка басасы — йөрәк бик чуар. Күп төннәрен йокламый уздыра.

— Шул булыр инде аның, тынгысыз җан! Тагын нәрсә ди, ни җитми?

Хәдичә түти, кемгәдер ишеттермәскә теләгәндәй, тавышын акрынайта төште.

— Бу арада гел шул инде: кем өстен чыгар икән, янәсе, делегат кемнән китәр икән? «Чулпан»нанмы, әллә Аланбаштанмы? «Чулпан» халкы, ди, Тимергали абзаң әйтә, быел алдынгылыкны үзенең маңгай тире белән казганып алды! Аның фронтка үз кешесен җибәрергә полный хакы бар!

Айсылуның чырае җитдиләнеп китте:

— Шулайдыр. Борчылыр шул. Ашлык чыгаруда инде хикмәт, Хәдичә түти. «Интернационал» белән ярышу — уен түгел ул! Әле ярый МТС машинасы килеп булышты...— Аннары ул башы белән каядыр ымлап куйды.— Әнә кемдә тагын эшнең башы!

Хәдичә борылып караса, алар янына, идарәнең туры атына утырып, өстенә кара пальто кигән, башына мамык шәлен ураган Нәфисә якынлашып килә иде.

Теге күңелсез төннән соң каенана белән киленнең беренче очрашулары диярлек иде әле. Хәдичә, нигәдер, бишмәт төймәләрен боргалый, башындагы шәлен төзәткәли башлады. Теге кичне кызулык белән әйтеп ташлаган сүзләре өчен хәзер ул үзе дә ояла. Нәфисәне бәхилләтмичә, барыбер тынычлык табачак түгел иде. Ул Нәфисәдән якты чырай көтми, Хәдичә уенча, аның беркөнге үпкәсен онытуы мөмкин дә түгел, ул аңар һаман да рәнҗеп йөри булырга тиеш иде. Тик алай булып чыкмады. Аты килеп туктауга, Нәфисә, тарантасыннан төшеп, аңа ачык чырай белән иң элек үзе дәште.

— Исәнме, әнкәй, таза-сау гына йөрисеңме? Әткәй ничегрәк?.. Йөри башладымы инде?

Хәдичә, каушап:

— Бик, бик шөкер, бик әйбәт... Исән генәме...— диде. Бер куанды, бер уңайсызланып китте. Карасана, үпкә сакламый икән бит, менә рәхмәт төшкере! Ул турыда әле бөтенләй уйламый да бугай. Хәер, аңа бу карчыкның юк-бар турында мыжылдаулары хәзер бик кечкенә нәрсә булып калганга охшый. Ул гүя аны, битенә ябышкан тоҗымдай, сыпырып кына ыргыткан. Аның уенда бөтенләй бүтән нәрсә, зуррак нәрсә булырга охшый. Хәдичәгә, ничектер, тагын күңелсез булып китте. Ул үзен бик ялгыз хис итә башлады. Нәфисәнең үзләрендәге шундый ямьле тормышны болай тиз онытуы аңа һич ошамый, хәтта ул Нәфисәнең үзләреннән аерым да шулай матур гына тормыш итүеннән көнләшә дә иде кебек.

Нәфисәнең эше ашыгыч иде булса кирәк, Айсылу белән сөйләште дә тагын тарантасына менеп утырды.

— Мин киттем инде, Айсылу апа! — диде.

— Хәерле юл, Нәфисә! — Айсылу борчылган кыяфәт белән атның, ялларын төзәткәләп, тәртәсен тигезләде.— Хәерле юл, аппагым. Делегация белән китәсе булсаң, монда чылтырат. Кирәк-ярагыңны әзерли торырбыз.

Нәфисә сүзсез генә башын иде дә дилбегәсен кагып китеп тә барды. Болары Нәфисә артыннан тыкрыкка борылганчы карап калдылар.

— Райкомга китте, Мансуров янына. Менә анда билгеле була инде...— Айсылу, Нәфисә киткән яктан күзен алмыйча, нидер бераз уйланып торды.— Элек әйтәләр иде: «Килен кеше — ким кеше, көчек белән тиң кеше!..» — диләр иде. Шулаймы әле, Хәдичә түти?

Карчык, тамагын кыргалап, читкә таба карады.

— Бер дә хәтерләмим, әйтсәләр әйткәннәрдер...

Айсылу аңа көлемсерәп карап алды.

— Ниләр генә күрмәде, ниләр генә ишетмәде бу бала! Шулай да, турысын әйтергә кирәк, изелеп төшмәде, үзенекен итте. Менә бит хәзерге киленнәр нинди! Бик намуслы, бик инсафлы кеше булып чыкты безнең Нәфисә, Хәдичә түти, бик, бик!

Хәдичә аркасы туңып киткәндәй булып бөрешеп куйды. Көне кояшлы булса да, көз дигәнең үзенекен итә, җиле шактый усал иде.

III

Алтынчы ноябрьнең кичен түземсезлек белән көтеп алдылар. Караңгы төшәр-төшмәс, Шәмсетдиннең өндәвен дә көтмичә, яше-карты клубка җыела башлады.

Ул елны көз бик аяз килде. Сентябрь генә бераз вак яңгырын сибәләде дә, октябрь бөтен ае белән диярлек кояшлы булды. Менә хәзер ноябрьнең беренче атнасы инде, көннәр исә һаман да коры әле. Иртә белән, өй түбәләрен, каралты башларын, урамнарны агартып, ап-ак кырау төшә, инеш кырыйларына, пыяладай юка гына булып, боз ката. Ләкин көн урталары якынайдымы, аяк астын тагын җебетеп җибәрә, яшь боз эреп юк була.

Су буендагы әрәмәләр белән урманнар башта саргайды, урыны-урыны белән кызарды, миләш төсенә керде. Тора-бара яфракларын очырып, сирәкләнеп калды. Картлар бу хәлне дә, борынгы тәҗрибә буенча, яхшыга юрадылар:

— Быел агач яфрагын үз вакытында койды, кышка калдырмады, халык өстендә, шәт, авырлык булмаска кирәк! — диделәр.

Моның шулай булачагына бик ышанасылары килә, ул сүзләрне яхшы теләк белән, чын күңелдән әйтәләр иде.

Әйтүен әйтәләр, әмма хәзергә әле халык тирән борчуда, халык күңеле бик тынгысыз иде.

Сугыш башланганнан бирле, өсте-өстенә бик күп хафа, бик күп ваем җыелды. Дошман кулына төшкән һәр совет шәһәре, сугышчы тәнендәге ярадай, күңелләрдә тирән эз калдырды. Сталинград шәһәрендә барган дәһшәтле сугышлар бер генә минутка да халык күңеленнән китми иделәр.

Сталинград үзе бу тирәләргә ул кадәр якын түгел. Яхшы пароход белән дә, шәт, ике тәүлек төшелә булыр. Ләкин бөтен ил белән бергә типкән сизгер йөрәк өчен бу араның нинди еракльгы бар? Кичен Иделнең түбән ягына күз салсаң, анда, ургылып-ургылып, кара сөрем күтәреләдер, ул яктан туплар гөрселдәгәне ишетеләдер кебек.

Шулай да соңгы көннәрдә, томан ярып килгән пароход уты төсле, борчулы күңелләрне ышаныч нуры яктырта башлады. Сугыш самолётлары да, гаскәр белән корал төялгән пароход һәм баржалар да, Казан каласыннан Ульянга таба болын буй-

лап чабып уза торган яңа тимер юлның җитез поездлары да — һәммәсе дә торган саен ишәя баралар, бере артыннан бере көнетөне шул бер юнәлешкә агылалар.

Озакламыйча зур үзгәрешләр булыр, тиздән куанычлы хәбәрләр ишетелер!

Сентябрь башыннан бирле һәр көнне Шәмсетдин, иртәнге чәйгә кайткач, Совет информбюросының белдерүен тыңлап китә иде. Һәр көнне иртән ындырчылар аннан иң элек шул турыда сораша торган булдылар.

— Шәмсетдин абый! Сталинград ничек? Идел буйлары, Кавказ яклары ничек? Безнекеләр берәр кала алмаганмы?

Шәмсетдиннең кечкенә күзләре аска карыйлар, ул, үзенең йөрәк әрнүен басарга теләгәндәй, каһәрләнеп аксый-аксый, ачу белән кулын селтәп:

— Сорама миннән, сорама! — дип кычкырып җибәрә.— Нишләсен, яна Сталинград, яна!..

Соңгы көннәрдә Шәмсетдин бөтенләй үзгәреп китте. Ул хәзер үзе шәһәр алгандай киерелеп атлый, хәзер аның тавышы да, сүзләре дә дәртле һәм гайрәтле иде.

— Сталинградмы? Ничек булсын? Сугыша Сталинград! Якалаша безнең Сталинград! Кирәген бирә немеснең! Кыра фашистны Сталинград, тураклый!

Башкаланың һәрвакыттагыча тавышы көр, әйткән сүзе нык һәм йөрәккә үтә торган, газеталарның башындагы ялкынлы сүзләр өтеп ала торганнар иде.

«Сугышчы, йөрәгеңнең актык тибешенә кадәр, актык тамчы каныңа кадәр батыр бул, нык бул! Үтер дошманны, чәнче, туракла!.. Сталинградның һәр урамы, һәр йорты фашистның каберенә әверелсен!»

Әйе, бүген таңда нидер булыр кебек, инде шушы арадан да калмас, бәйрәм кичне шул турыда, мөгаен, ни дә булса әйтерләр, әйтмичә калмаслар кебек.

Бәйрәм кичен болай түземсезләнеп көтүнең тагын бер сәбәбе бар иде. Бүген көндез Айсылу белән Нәфисәне тагын районга дәшеп алдылар.

«Бәйрәмгә каршы алдынгы колхозларны бүләклиселәр икән. Безнекеләрне шуңа чакырганнар»,— диделәр. Клубка җыйналган халыкның телендә шул булды.

— «Интернационал» өстен чыкканмы, әллә «Чулпан»мы икәнне моңарчы кистереп әйтә алмаганнар икән. «Икесе дә яхшы эшләде, дәүләткә ашлыкны икесе дә бәйрәмгә кадәр тапшырып бетерде»,— дип әйтәләрдер, ди. Шулай да фронтка Наташаны җибәргәннәр, ди.

— Алайса, Аланбашларга шул бик җиткән инде. Калганы «Чулпан»га...

— Кем белә, бәлкем, безнең Нәфисәне дә чакыртырлар әле? «Чулпан» да болай гына калмас.

Урамда тарантас чылтыраган саен, тәрәзәгә ташландылар, ничә мәртәбә малайларны телефонга җибәреп кайтардылар. Айсылу белән Нәфисәне бөтен колхоз белән зарыгып көтәләр иде.

VI

Җыелыш беткәннән соң, клубтан чыгып барганда, Айсылу белән Нәфисәгә кемдер дәште. Ул да түгел, ишек буендагы караңгыдан Әпипә килеп чыкты. Өстендә шактый искергән кыска бишмәт, аягында ямьшәйгән туфли, култык астында кечерәк кенә кызыл төенчек. Икесенә дә, берни дә булмагандай, кыю гына кулын сузып:

— Сау гынамы үзегез! — диде.— Бакчи, вәт мин дә кайттым. Мине, этәм, юксынгансыз! Кая булды бу безнең Әпипә, дигәнсез. Мин юкта, шәт, җыелышларда бәйләнүче дә булмагандыр үзегезгә. Хи-хи-хи!

Айсылу, аның көчәнеп булса да шәбәергә тырышуына игътибар итеп:

— Алай сагынып акылдан язучыларны мин үзем очратмадым очратуын,— дип әйтеп куйды.— Син бөтенләйгә киткән идең түгелме соң?

— Киткәним дә, бакчи, вәт тагы кайттым.

— Ничек алай бик тиз?

— Сагындым, кәбәм. Ничек әйтәләр: агы иләмсез, суы тәмсез, үемә кайткым киләде. Үенә кайтуның ояты юк, дир бабайлар.

Айсылу:

— Алай икән...— дип сузып куйды.— Теге ниең... яңа белешең, димме, ул кайда соң әле?

— Әй, төкердем лә бер сасы танавына! — Әпипә, төенчеген урындыкка куеп, авызын кыйшайта-кыйшайта, чәчләрен төзәткәли башлады, бармагында көмеш йөзеге ялтырап китте.— Шындый яным бизде, кәбәм, шындый бизде, тфү, әҗәткана! Әдә, кадалып китсен! Миңа дигәне тагы да бардыр әле. Яраклы түмә җирдә ятмас, дир бабайлар.

Әпипә, мутланып, тамак төбе белән генә тагы көлде.

Тик аның бу көлүе бик күңелсез тәэсир калдырды. Элекке янып торган тулы гәүдәле Әпипәнең хәзер яртысы гына калган иде. Ул шушы берничә ай эчендә бик нык таушалган, күз төпләре капчыклана башлаган, битләре дә, иреннәре дә сулган. Айсылу аңа кызгануга якын бер хис белән карап торды. Никадәр генә хыйхылдамасын, Әпипә хәзер йөрисен йөргән, чәчәген койган иде инде.

Аның әле кайтып килеше генә булырга охшый, ул боларга йомышы төшкәнгә дәшкән иде булса кирәк. Тик Айсылу белән Нәфисә үзләре сүз башламадылар.

Ахырда, ишектән чыгып барганда, Әпипә, нәкъ элек бергә эшләп йөргәндәге кебек бик гамьсез бер кыяфәттә, Нәфисәдән үзе сораша башлады:

— Иртәгә ындыргамы чыгасыз?

— Шулай итәсе булыр, ахрысы.

— Мине бүтән эшкәме кушасың, ындыргамы чыгарга... Бакчи, синең бригаданыкы бит мин.

— Кайчандыр. Хәзер белмим шул. Иптәшләр ни әйтерләр бит. Аннары алай ансат кына булмый торгандыр әле ул. Айсылу апа, ничек синеңчә?

— Әйе. Бүгенгесе көнне Әпипә колхоз члены булып исәпләнми.

Әпипә, башын чайкап, телен чартлатып куйды.

— Атакай гынам!.. Карале боларны! Китче, кит! Ул тикле мин нишләгән? «Чулпан»ның амбарынмы басып качкан, атынмы орлаган?

— Шунысы гына җитмәгән иде. Ни әйттек бит, тыңламадың! Бер кеше кырыкка ярылыр вакытта, колхоз эшенә төкереп, эт туе ясап йөрдең, бөтенесен ташлап качтың.

— Ай, канатым, Айсылу, кайсы малне дүрт аяклы хайван да сөртенә. Әйдә, кузгатмыйк, кәбәм, искене! Колхозда миңа гына эш табылыр әле. Әнә бит үебез дә буш тора.

Айсылу белән Нәфисә, бик сәерсенеп, бер-берсенә карашып алдылар. Күрәсең, Әпипәнең үз акылы үзендә, ул намус дигәнне бик үзенчә аңлый иде булса кирәк. Айсылу аның әрсезлегенә кытыклана башлаган иде инде.

— Тукта әле, Әпипә,— диде.— Без синең белән сукыр тәкә уйнамыйк әле, яме? Нинди өй ул тагын? Солтан йортыннан үз өлешеңне алып, аны туздырып, бөтенләй аерылып киттең бит.

Әпипәнең моңа бер дә исе китми икән. Кулын селтәп, көлеп кенә уздырды.

— И канәтем, кил, кирәкмәскә тартышып, тәмсез булышмыйк. Солтангәрәем исән генә кайтсын, кулыма гына төшсен, янымда бөтерелеп йөрмәсә, битемә төкер! Бер кочагыма эләктерүем җитә, бөтен үпкәләрен оныттырам мин аның.

Нәфисә шаркылдап көлеп җибәрде:

— Һаман да шул Әпипә, һаман да шул тел! Ха-ха-ха!

Айсылу, ачуы килә башлап, китәргә кузгалды.

— Ярар. Ул ягын үзең чамаларсың. Анысында минем эшем юк. Тик мин Солтан рөхсәтеннән башка аның йортына кеше кертә алмыйм. Закон! Калганы — иртәгә.

— Ай-яй, харап икән! Закон дигәченнән дә инде ул тикле. Китче, кит!

Айсылу белән Нәфисә өйләренә таба киттеләр. Никадәр генә ваемсыз булып күренергә тырышса да, Әпипәнең борчылуы һәм үкенүе ачык сизелә иде.

Айсылу бераз киткәннән соң борылып карады. Әпипәнең күләгәсе һаман да клуб янында айкала иде. Айсылу, борчылып:

— Кунар урыны юк бит бу нәмәрсәнең!..— диде.— Төне дә салкынаеп килә тагын, җитмәсә.

— Күршеләре кертмәс дисеңме?

— Кая ул! Якын да җибәрмәсләр. Бөтенесенең җанын биздереп китте бит.

— Барысы да үзеннән, Айсылу апа. Йөрмәс эшәкеләнеп! Ул аны гына белмәслек кешемени?

— Шулай да бит анысы. Акылы кушканча түгел, күңеле кушканча гына йөри торган бәндәләр дә була бит.

Алар бераз сүзсез бардылар. Айсылу, ни турындадыр уйланып, теләр-теләмәс атлый иде. Ниһаять, Нәфисәләр турысына җитәрәк тагын туктады.

— Тукта әле, Нәфисә! — диде.— Әллә кызганам да инде шунда үзен.

Нәфисә Әпипәнең эшәкелекләрен алай бик тиз онытып бетерүне өшатмый иде.

— Мин андыйларга катырак куллы булу ягында, Айсылу апа,— диде.— Халыкның нәфрәтен ныграк татысын! Үзенә дә, бүтәннәргә дә сабак булыр... Мин аны үземнең бригадама якын да китерәчәк түгелмен.

— Мин дә аның аркасыннан сыйпарга җыенмыйм! Юк! Уйлама да! Бөтен халык алдында тәүбә иттерәм әле мин аны. Әмма ничек кенә булса да, кеше бит ул. Безнең илебездә кеше мондый хәлгә төшмәскә тиеш.

— Ихтыярың. Бәлки, шулай кирәктер.

— Әйдә, тагы бер сынап карыйк. Үкенечкә калмасын. Йә, сау бул. Тыныч йокы сиңа!

— Хуш иттек, Айсылу апа!

Айсылу, кире борылып, җитез һәм тавышсыз адымнар белән клуб ягына таба китте.

VII

Җыелыштан соң Нәфисә һаман да тынычлана алмый иде әле. Өй эчендә әрле-бирле йөри торгач, радиога колак салды. Мәскәү бере артыннан берен маршлар уйната иде. Сукыр лампа гына төтәп утырган ярым караңгы өйалды аркылы аш өенә чыкты. Җиңгәсе Йөзлебикә кайтып җитмәгән иде. Почмак якка кереп, төрлесе төрле урында йоклап яткан балаларны сөеп, өсләрен рәтләп чыкты. Атасы түр яктагы тар кәнәфидә ята иде. Ул, чалкан ятып, кулларын күкрәге өстенә куйган. Аның йомык күзләре зәгыйфь ут яктысында кара чокыр гына булып күренәләр. Нәфисә якынрак килеп карады. Әтисе бик авыр итеп, гыжлап тын ала, аның күкрәгендә ниләрдер гырлый һәм

сызгыра. Этисен аллә нинди авырулар азаплыйдыр, көне-төне эшләп бик арый да торгандыр, бәлки, тәрбиясе дә җитмидер. Нәфисә, үзе таза-сау булгач, атасының авыруы турында моңарчы уйлап та караганы юк иде. Берәр көнне районга алып барып, Михаил Павлычка күрсәтсә ни була соң инде!..

Нәфисәгә ул хәзер аеруча кызганыч һәм мескен булып күренә башлады. Бая җыелышка чыгып әйткәнче, бодайны бүләк итеп бирергә теләве турында, олы кеше итеп, атасы белән тагын бер сөйләшәсе калган икән бит. Ә Нәфисә киңәшмәде. Бу бит эти кешене санламау була инде... Электән надан кеше, ул һәммәсен дә яшьләр кебек тирән итеп аңлый аламыни? Әгәр, нәселдән килә торган авырудай, яшь чагыннан ук канына, бөтен җелегенә кереп утырган ул комсызлык чиреннән үзе генә котыла алмый икән, аңа Нәфисәләр ярдәм итәргә тиеш түгел идеме соң?

Ипләбрәк караса, этисе уянган, имеш. Нәфисә, аның күзләре елтыравын күргәч, уңайсызланып калды.

— Өй бик тартылган, туңа торгансың, өстеңә ябыйм дигән идем...

Нәфисә этисенең юрганын иңбашларына тартып, аякларын урый башлады. Карт бер сүз дә әйтмәде, киреләнмәде дә. Кызының җайлап кына аягын төрүе һәм, гомумән, болай кайгыртуы аңа ошый иде булса кирәк, аның, үзен төрергә ирек биреп, күзләрен ача-йома кинәнеп ятуыннан шулай сизелә иде. Ниһаять, ул, бөтенесенә ризалыгын белдереп: «Инде хәзер сезнең дөнья, берни эшләр хәлең юк...» — дигән сыман, тирән итеп бер сулады да, кулларын юрган астына яшереп, тагын күзләрен йомды.

Нәфисә куануыннан этисен кочаклардай булды. Ул күңеленнән: «Эти күнде, ачуланмый!..» — ди иде.

Дөрес, хәтта атасы өеннән куып чыгарган сурәттә дә, Нәфисә үзенә тиешле ашлыгын фронтка бүләк итүенә барыбер үкенмәгән булыр иде. Әмма бу изге эшкә эти кешенең дә ризалыгын алу — монысы инде бөтенләй башка нәрсә.

Ак өйгә чыкканнан соң да, Нәфисәне ашкынулы, дәртле бер омтылу, нигәдер өнди торган бер тынгысызлык һаман дулкынландырып тора иде әле. Менә бодайның да эше бетте инде. Аласы уңыш алынды, үз урынына тапшырылды. Шуның белән алга өндәп, үзенең кыенлыклары, шатлыклары белән җилкендереп торучы читен эш тә калмады кебек. Хәзер ул кеше аягы басмаган биек һәм серле тауның башына менеп җиткән тынгысыз сәяхәтче кебек. Бер менгән сукмактан кире төшәсе килми, бер тау өстендә озак юануның да мәгънәсе юк. Ярый ла, монысыннан да биегрәк, монысыннан да мавыктыргычрак бүтән бер тау булса!

Аның берәр якын дусты белән бик иркенләп, бик үз итеп сөйләшеп утырасы, серләшәсе килә башлады.

Нәфисә өстәл өстендәге китапларын караштырды, радионы көчәйтебрәк куйды. Ләкин барыбер тынычлана алмады, һаман да нидер эшләнеп җитмәгән кебек иде. Ул өстен киенде дә урамга чыгып китте.

Айсылуның эшләрен бетереп кайтып кына кергән чагы иде. Ул төнге кунакны, сизелерлек дәрәҗәдә сәерсенеп, аягүрә каршы алды.

— Әйдүк, Нәфисә, әйдә, утыр...— дип, аңа урындык китереп куйды, үзе, кечкенә кулы белән чәчен төзәткәләп, Нәфисәдән күзен алмастан, идән уртасында тора бирде.

— Әйдим, Айсылу апа. Мин йөрим әле, төнлә белән кеше борчып.— Нәфисә, шәлен иңнәренә кайтарып, урындык аркасына таянды.— Минем килүемә бик гаҗәпләндеңме? Көтмәгәндә, кара төндә, ә?!

— Юк. Синең белән без һәртөрле көтелмәгән хәлләргә күнегеп киләбез бит инде. Йә, утыр! Хәзер самавыр була, бергәләп чәй эчәрбез.

Нәфисә һәрвакыттагыча тыныч кебек күренсә дә, дулкынлануы сизелеп тора, сүзен башлап җибәрергә җаен тапмый кебек иде. Ниһаять, ул утырды.

— Син борчылма, Айсылу апа, син дә утыр! — диде.— Бүген бәйрәм кич, шундый шатлыклы көн... Менә, иң якын кешем итеп, синең янына килдем. Күңелем урынында түгел, тагын нидер эшлисем бар, әле иң зурын һаман да башкармаганмын шикелле... Җыебрак әйткәндә, болай инде ул, Айсылу апа...— Ул, сүзен бүлеп, Айсылуның аңа төбәлгән акыллы күзләренә карап алды.— Болай ул. Күптән үк күңелем түрендә саклап йөргән бик зур бер теләгем бар минем. Менә ничә тапкыр тилпендем инде, ничә тапкыр уйлап карадым, тик һәркайсында үземне үзем тыеп калам. Үсеп җитмәгәнмен, чыныкмаганмын кебек. Йөрәгенең бөтен ялкынын, бөтен сәләтен революция юлына биргән Дзержинский кебек батыр йөрәкле революционерлар, йә булмаса үзебезнең Сарьян абыйлардай нык большевиклар искә төшә дә: «Юк әле,— дим,— миңа иртәрәк булыр». Тик күңел һич тынгылык бирми, сугыш башыннан бирле һаман тарта, һаман өндәп тора. Менә хәзер сизәм: вакыт! — Ул, торып, Айсылуның каршысына килеп басты.— Айсылу апа! Ни әйтерсең, мин партиягә керергә телим!

Айсылу, акрын гына көлеп, Нәфисәнең иңбашыннан кочып алды.

— Менә нинди яхшы теләк белән йөри икән бу төнге кунак! Шундый көттем мин синең бу сүзләреңне, шундый зарыгып көттем! Дөресен әйтим, шулай булачагына чын күңелдән ышанып көттем. Йә, хәерле юл сиңа, Нәфисә! Кояшлы юл!

VIII

Менә Нәфисә яңадан үз өендә. Аның каршысында кечкенә рәсемнән, пилоткасын кыңгыр салган, беләгенә кызыл хач бәйләп, янына дәү сумка аскан солдат дусты Гөлзәбәр елмаеп тора. Ак кәгазь өстендә, — дустына җибәрер өчен, түгәрәк аланнан алып кайткан киртләч кырыйлы имән яфрагы. Түгәрәк алан, айлы төн, җилкенчәк Гөлзәбәр күз алдына килде, дәртле тавышы ишетелде. Әле менә хәзер генә булып узган хәл кебек. Әйләнеп карасаң, өч ай үтеп тә киткән. Ниләр генә күрмәгәндер ул шушы вакыт эчендә!

Өй эче тын иде. Бары сәгать йөргәне, каләм кыштырдаганы гына ишетелә.

«...Сине шундый сагындым, гөлкәем, язасы сүзләрем шултикле күп, кайсы башыннан тотынсам да, күңелемдәген әйтеп бетерә алмамдыр кебек...

Иң элек үз хатың турында. Ул монда бик күпләрнең күз яшен киптерде, йөрәкләргә сүнмәслек ут кабызды. Белсәң иде, Гөлзәбәр! Сталинград урамнарындагы ул тиңсез сугышлар, һәр урам өчен дип әйтмим, һәрбер йорт, һәр тәрәзә өчен җаннарыгызны аямыйча сугышуыгыз күңелләрне шундый күтәрә, әйтәм бит, әллә ниләр эшләрдәй буласың. Күңел әйтә: юк! Безне җиңә алмаслар! Юк! Ул кара болыт тиздән таралыр. Бөтен ил өстендә яңадан безнең кояшыбыз балкыр. (...)

Беләсеңме, быелгы эшем мине бик күп нәрсәгә өйрәтте. Мин үземне хәзер канатларым ныгып җиткән очар коштай сизәм. Иген кырларында бабайларның төшенә дә кермәгән могҗизалар күрсәтәсем, игенчене элеккедәй күктән яңгыр көтеп уфылдаулардан котылдырасым килә! Хәзергә минем фронтым менә шул, гөлкәем! Өндәрмен, димләрмен, эшләп күрсәтермен, әмма әйткәнемне булдырмый калмам!

Тагын ниләр дисеңме? Сәйфи турында ишеткәнсең инде. Азгын кеше, әшәке кеше булып чыкты ул. Шыпырт кына тик кимереп яткан колхозны. Сизеп торам: сине ул түгел, «музыкант» кызыксындыра. Дөресен әйткәндә, аның язмышы бөтенебезне дә борчый иде. Хәзер ничек дисеңме? Хәзер Зиннәтең, бөтен районны шаулатып, үзе оештырган бригада белән колхозларда концерт биреп йөри. Кышка таба укый торган мәктәбенә китәсе икән. Җәүдәт абый булышкач, алырга булганнар. Сиңа хаты барып җитмәдемени әле? Язар, язмый калмас!

...Тагын бер сүзем бар әле, гөлкәем. Моңарчы язарга кыймый йөрдем. Нигә дисәң, тәгаен шулай булуына ышанып җитүе дә кыен. Аның яшьлек тирәгенә узып барышлый кунган очраклы бер кош кына булуы да мөмкин бит! Газиз искиткеч әйбәт кеше иде, мин аны бик озак оныта алмам. Дөрес, бүтәннәрнең үзеңне

сөюләрен хис итеп яшәү, бәлки, бик рәхәттер дә. Шулай да чын-чыннан бәхетле булу өчен ул гына җитми, гөлкәем! Гөлзәбәр! Әйтсәнә шуны: кырдагы игеннәрем белән бергә үз күңелем дә чәчәк атса, бу соң нур өстенә нур гына булачак түгелмени?!»

Нәфисә, үзенә буйсынырга теләмәгән күңел давылын тыярга тырышып, идән буенча йөрергә тотынды. Күз алдына тагын әлеге озын буйлы, бөдрә чәчле егет килеп басты.

...Ул төнне алар, бер-берсен култыклап, тын урамны күп мәртәбә әйләнделәр. Хәйдәрнең ягымлы тавышы колакны иркәли, ул иң гади нәрсәләрне дә йотлыгып тыңларлык итеп түгәрәкләп, җанландырып сөйли белә иде. Сүз арасында Әлфия ясаган әлеге панораманы да телгә алды. Нәфисә күз алдына «Чулпан»ның һәм Идел буйларының киләчәге, тормышның үзендәге төсле, бөтен яме һәм гүзәллеге белән чын булып килеп басты.

Нәфисә үзенең беләгендә аның ирләрчә нык кулын, чәченә сулышы бәрелгәләп китүен тоеп бара. Ул аннан бераз тартына, аны үзендә туып килә торган әлеге тирән хиснең артык көчле һәм ялкынлы булуы уңайсызландыра. Әллә ничек. Бик сәер, бик... Кыз чагындагы шикелле. Юк, алай гынамы соң? Бу нинди дер татлы авыру кебек. Ул йөрәкне шуңа сызлатадыр...

Бәлки, бу егеткә берәр шаян сүз әйтергә дә өйгә кереп китәргәдер?

Шулай да аның Хәйдәр яныннан китәсе килми иде.

Алар Нәфисәләрнең капка төбендә туктап калдылар.

Хәйдәр, аның ике кулыннан алып, башын ия төште.

— Менә килеп тә җиттек...

Нәфисә, бая гына Хәйдәр сөйләгән яңа, якты бәхет дөньясына беренче мәртәбә аяк баскандай дулкынланып, аңа күтәрелеп карады. Аның:

— Килеп җиттек тәмени инде? — диясе килде.

Нәфисәнең азрак башы әйләнеп китте. Ул йөрәген чорнап алган бу татлы ялкынны сүндерә алмавына, бу егетнең үткен күзләреннән хәзер инде берни дә яшерергә көче җитмәвенә офтана, шул ук вакытта шушы таза беләкләргә үз итеп таянасы, аның бөдрә чәчен сыйпыйсы, күкрәгенә сыенып иркәләнәсе дә килә иде. Бу минутларны ул бик сагынып, бик зарыгып көткән иде бит, урак өстеннән бирле, урман буенда күргәннән бирле... Аның күңеле көне-төне эзләнгән, юксынган иде бит. Хәзер менә ул аның каршысында... Менә генә ул...

Тик шунда Нәфисә, акрын гына, ишетелер-ишетелмәс кенә:

— Хуш, Хәйдәр! — ди.— Мин керим. Миңа бик вакыт! — Ул, Хәйдәрнең җавабын да көтмәстән, ашыгып, капка келәсенә барып тотынды. Хәйдәр, аның артыннан барып:

— Тукта әле, Нәфисә... бер генә минутка!..— диде.

— Бик соң инде, Хәйдәр, гафу ит! Хуш! Тыныч йокы...

Нәфисә тәрәзә янына килде. Шомырт агачлары арасыннан Хәйдәр карап торадыр кебек. Аның бүген Хәйдәрне шундый күрәсе, шундый сөйләшәсе килгән иде... Ләкин нишләмәк кирәк, кайвакытны, янында утырса да, бер авыз сүз әйтә алмыйсың. Мәктәбеннән кайтышлый, Нәфисәнең тәрәзәләренә генә булса да күз салып узар бит? Әйе, әнә алар күрешмәсеннәр дә, әнә сөйләшмәсеннәр дә. Юк! Тик ул, тыкрыктан узышлый беразга туктап, шомырт агачлары арасыннан аның тәрәзәсенә генә карап торсын иде. Бераз гына. Берәр генә минут. Бәлки, ул Нәфисәне күрә дә алмас. Юк, бәлки генәме соң? Ничек күрсен? Аның тәрәзәләре томаланган бит! Шулай да бер күз салсын иде. Нәфисә аны күрер иде дә: «Шушы минутта да минем турыда уйлый икән»,— дияр, аңа бик рәхәт, бик тә рәхәт булып китәр иде.

Нәфисә, моның бары хыял гына икәнлеген, Хәйдәрнең күренү ихтималы бөтенләй булмавын бик яхшы белсә дә, тышка күз салмыйча булдыра алмады. Әмма анда беркем дә юк иде.

Нәфисә одеялны акрын гына япты. Яңадан өстәл янына утырып, кулына каләм алды. Ләкин аны бүлдерделәр.

IX

Капка келәсе чылтырап китте дә, кемдер, авыр итекләре белән дөпелдәп, өйалды баскычына менде. Нәфисә, дулкынланып, урыныннан торды. Әгәр Хәйдәр булса? Юк, ярамый! Бу вакытта ул үзе дә килмәс... Ул да түгел, каты гына ишек шакыдылар.

— Кем анда? Керегез!

Ишектән өстенә сары кожан, аягына зур күн итекләр кигән юл кешесе килеп керде. Маңгаена төшкән колакчын бүреген күтәрә төшеп:

— Исәнлекме, сеңел! — диде.— Мин ялгыш кермәгәнменме? Нәфисә син буласыңдыр бит?!

— Ие, мин булам...

— Әһә! Булды гына, алайса!

Әлеге кеше, чыбыркысы белән бияләен ишек янына куеп, сөйләнә-сөйләнә, эчке кесәләрен актарырга тотынды.

— Син инде, сеңелем, болай туп-туры өеңә басып кергәнгә ачулана күрмә,— диде.— Правлениегездә бер кеше дә юк. Председательне эзләп йөрергә вакыты бик аз калган. Эше шундый. Иртәнге өчтә районда булырга куштылар. Анда самолёт көтеп тора... Әһә, менә икән!

Берни дә аңламыйча, бик сәерсенеп торган Нәфисәгә куеныннан бер пакет чыгарып бирде.

Бу кәгазьдә, республика Югары Советы Президиумының карары буенча, Нәфисәнең фронтка бүләк алып баручы делегация составына кертелүе һәм җиденче ноябрьдә Идел буендагы шәһәрләрнең берсенә барып җитәргә тиешлеге әйтелгән.

Телеграммага, делегация председателенең урынбасары дип, Җәүдәт Мансуров үзе кул куйган иде. Нәфисә сәгатькә күз салды. Беренче ярты булып килә иде.

— Алай... Бик ашыгыч икән...

Райком кучеры, бияләйләрен алып, чыгарга җыена башлады.

— Әйе, бик ашыгыч, сеңел, бик! Яктыра башлауга, самолёт очып китәргә тиеш. Мансуров иптәш Казаннан телефон белән дә бик кисәтеп әйткән. Алайса, син, сеңел, җыена тор инде, мин, председателегезгә барып, кәгазьләрне әзерли торырга кушыйм.

Тагын берничә минуттан бөтен йорт ыгы-зыгы килә башлады. Тупырдашып күрше кызлары керде, каяндыр ишетеп, Карлыгачлар, Зәйнәпбанулар килеп җитте. Берсе самавыр куя, бүтәннәре юл кирәкләре әзерли, кием-салымын рәтли, күлмәкләрен өтели, чемоданнарын хәстәрли иде.

Озак та үтмәде, аягүрә генә булса да, юл чәе дә эчелде, өс-баш та алмашынды. Йөзлебикә белән Карлыгач делегатның бөтен кирәк-ярагын чемоданга тутырып, ишек төбенә үк китереп куйдылар. Төн уртасы дип тормадылар, тагы әллә никадәр халык җыелды, озатырга килүчеләр белән бөтен өй тулды.

Кайберәүләр, Нәфисәнең фронтка делегат булып баруына чын күңелдән кызыгып:

— И бәхетле дә инде син, Нәфисә! — диештеләр.— Үз күзләрең белән күреп, үз кулың белән кулларын кысарга барасың бит! Кемнәргә генә тигән мондый бәхетләр.

Карчыклар арасыннан киңәш-табыш бирүчеләр дә булды.

— Барырсың, күрерсең,— диделәр.— Сугыш җире дип, тартынып торырга ярамас. Халык күңелендәген кистереп әйт: бөтен өметебез — аларда! Шакшы фашист кулын гына суза да, Идел суы хурлыгыннан ярга ташланыр. Кырсыннар дошманны, Иделгә җибәрмәсеннәр!

Инде кузгалыр вакыт та җитеп килә иде. Айсылу, йөгерә-йөгерә, язуларны да китереп җиткерде.

— Монысы — таныклык! — диде, берсен кулына тоттырды.— Менә монысы «Чулпан»ның «Сталинград атнасында» фронтка күпме ашлык, күпме бүтән төрле бүләк бирүе турында. Менә монысына синең бригадаңның ничек эшләве, күпме уңыш алуы язылган! — ди-ди, Нәфисәнең пальто кесәсенә әллә нихәтле кәгазь тутырды.

Кучер агай кереп, чемоданны да алып чыгып китте, атны баскыч турысына китереп, борып куюы да ишетелде. Әйе, кузгалырга вакыт бик җиткән, тик, нигәдер, Хәйдәр генә күренми иде.

Нәфисә, юк эшләрен бар итеп, почмак яктан да әйләнгәләп чыкты. Аш өенә кереп, йоклап яткан сабыйларның кайсын үпте, кайсын сөеп узды. Әтисе белән дә саубуллашты.

Менә кучер, ишекне ачып:

— Кузгалсак, ничек булыр икән? — диде.

Әйе, кузгалырга бик вакыт инде вакытын да, тик һаман юк бит әле...

Менә карчыклар, хәерле юл теләп, кул да күтәрделәр. Карлыгач мамык шәлен сузды. Йөзлебикә җиңгәсе кулына перчаткасын тоттырды. Кайсы кулын кысты, кайсы кочаклады. Кайсылары биек итеп печән тутырган тарантаста урынын көйли башладылар.

...Шулай ук килмәве микәнни соң? Әллә мәктәбендә утырып, ишетми үк калдымы? Алай дисәң, әнә авыл башындагы Карлыгачлар да ишеткән бит, карчыкларга кадәр торып килгән.

Капканы ачарга гына торганда, атлый-йөгерә, тыны-көне бетеп, Мәүлиха түти килеп керде.

— Кая, менә моны да шунда бер җиргә кыстырыйк әле,— дип, аяк очындагы печән арасында кыштырдарга тотынды. Ничектер, бик үз итеп, аеруча якын итеп, Нәфисәнең үзенә генә берике сүз әйтеп куйды: — Нәфисә, алтыным, карап кына йөри күр берүк. Сугыш җире ләбаса, әллә кем әйтмешли, җайлы-җайсыз, үз белдегең белән читкә тайпыла күрмә... Нәчәнникләр белән бергә йөр!..

Кайсыдыр, сәламенең барып җитәсенә чын күңелдән ышанып:

— Солтангәрәйләргә, Гөлзәбәрләргә бик күп итеп сәлам әйтерсең инде,— дип куйды.

Әйтерсең Нәфисә күрше авылга кунакка бара! Йөзлебикә Нәфисәнең ялгыз китүенә борчыла башлады:

— Кара әле, Айсылу, районга тикле озатырга берәрсен җибәрмәгәнсең икән. Төне якты яктысын да бит...

Айсылу уены-чыны белән җавап кайтарды:

— Төне якты, аты яхшы, дигәндәй, әйдә, ул турыда кайгырып баш ватмыйк әле, яхшы кеше ялгыз булмый ул.

Капканың ачылып китүе булды, халык ике якка тайпылып кына өлгерде, зарыгып торган айгыр атылып чыгып та китте.

— Хуш, хәерле юл!

— Исән йөреп, сау кайтырга булсын!

Агайның аты бик җиңел сөякле хайван икән. Тын урамнан пошкыра-пошкыра элдертте генә!..

Йолдызлы күктә көмеш ай балкып тора. Урам өсләре, капка төпләре яп-якты һәм буш.

...Шундый күрәсе килгән иде... Аның бит китәренә дә өч атна гына калып бара. Аңарчы Нәфисә кайтып җитәме, юкмы бит әле...

Менә колхоз идарәсе, менә клуб, менә мәктәбе. Тәрәзәләре караңгы. Бу вакытта нигә анда утырсын икән? Юктыр. Алдарактыр, үз капка төпләрендә көтә торгандыр.

Агайның юртагы шундый шәп элдертә... Менә чатка да ерак калмады инде. Аннары инеш буена борыласы да күпер генә чыгасы кала.

Нигә шулкадәр куа икән соң бу абзый! Бераз тыя төшсен иде; урамны атлатып кына узса да ярый бит...

Нәфисә, үзе дә сизмәстән, атның дилбегәсенә үрелгән иде, агай артына борылды.

— Трр... Хайван! Берәр күрәсе кешең бармы әллә, сеңел? Туктатыйммы әллә?

Нәфисә шунда ук кулын кире алды.

— Юк, юк, абзый! Бер кешем дә юк! Болай гына...

Абзый чөңгереп җибәрде. Айгыр, сузылып, бер тилпенде дә тын урамны шаулатып, пошкыра-пошкыра, алга очты.

Нәфисәнең кызган битенә салкын җил бәрә башлады. Ул, дилбегәне тартмас өчен, чытырдатып тарантас кырыена ябышты. Ул атның тагын да ныграк чабуын теләде, шул ук вакытта аның алга текәлгән күзләре һаман эзләнәләр, ул, өзелеп-өзелеп, Хәйдәрнең каршыга килеп чыгуын көтә иде.

Әллә Нәфисә ялгыштымы икән? Әллә болар барысы да буш хыял гынамы? Алай дисәң, күңеленең моңарчы беркайчан алдаганы булмады. Юк, юк! Ул бик яхшы сизә, моның кысыр чәчәк кенә булып калуы мөмкин түгел.

Абзыйның аты олы юлга борылды. Ул акрынлый төшкән иде инде...

Нәфисә, тирән сулап, барачак юлына күз салды. Таш юл өстендә, читләреннән чыгардай мул булып, тулган айның зәңгәрсу ак нуры балкый. Юлның ике ягындагы өянкеләр, зөбәрҗәттәй яшькелт нурга коенып, төннең гаҗәеп яктылыгына, күк йөзенең биеклегенә һәм сафлыгына хәйран калып, тыныч утыралар.

Әйе, аларның киләчәге дә әнә шушы якты юлдай балкып күз алдына килә иде бит. Шундый ук якты, шундый ук бераз серле, бераз хыялга да тартым.

Нәфисә, ялыгып кына, күзен йомган иде, ат туктап калды. Юк, Нәфисәнең йөрәге юкка гына ярсып типмәгән икән. Хәйдәр, айның үзеннән төшкәндәй ак нур булып, атның алдыннан калкып чыкты:

— Рөхсәтме? Сине самолётка кадәр озатып куярга дигән әмер бар!

Нәфисә, аның көләч күзләренә карап, башын иде.

1947

Хәсән Туфан
(1900—1981)

И ТАТАР

Әйтерсең байрагын
Күтәреп иңенә,
Һәр халык дөньяга
Бүләген китерә.

Иң гүзәл сыйфатын,
Иң яхшы якларын,
Бүтәннәр өчен дә
Кадерле затларын

Китерә һәр халык
Кешелек сафына,
Гасырдан-гасырга
Тапшыра-тапшыра.

Синең дә, и татар,
Сыйфатың, саның бар,
Холкыңда, йолаңда
Соклангыч ягың бар:

Синең төп сыйфатың —
Батырлык, кыюлык.
Синең бу гадәтең
Байрагың булырлык!

Тапшырып син шуны
Буыннан-буынга,
Һәйкәлләр тезәсең
Тарихың юлына.

АК КАЕН

Яфраклары яшел ак каенга
Юл буеннан аклар килделәр,
Ак каенның ярлы авылдашын
Билбавына асып киттеләр.

Асучылар киткәч сорый каен:
— Авыртмыймы муенын, Хәйбулла?
— Авыртуга түзәр идем, каен,
Тын алуы бигрәк авыр ла.

Билбау кыса, каен, сулышкайны,
Бушатсана шушы билбауны!
— Бушатыр да идем билбавыңны,
Мин каенда андый кул бармы?

— Бөгелсәнә, каен, иелсәнә,
Аякларым җиргә тимәсме?
— Бөгелер идем, буем каты минем,
Үтәр хәл юк синең киңәшне.

— Сәлам тапшыр, каен,— диде егет,
Тынып калды шунда аннары...
Бер эндәште каен, өч эндәште,
Бүтән бер сүз ишетә алмады.

Яфраклары коела ак каенның,
Яфраклары коела яшь кебек.
Әле булса тирбәләдер төсле
Шул каенга аскан яшь егет.

Әйтсәгез лә шушы ак каенга:
— Елама син, каен, аппагым,
Киң кырларда үзе генә түгел,
Эзе дә юк инде ятларның.

1933

КАЕННАР САРЫ ИДЕ

Кайгының ни сүз икәнен
Белмәгән сабый бала
Моңая, сагына, күрәсең:
Ал йөзе сарылана.

Әттәсе киткән тарафка,
Юлларга карый-карый,
Шәлләргә төренеп, суыкта
Уйланып утыра сабый...

Көз иде... Җирнең шушындый
Күңелсез чагы иде;
Астралар, гөлләр кыраулы,
Каеннар сары иде...

Исән-сау диләр әтисен,
Сугышта йөри диләр...
Аңардан никтер сабыйга
Сәлам-хат китермиләр.

Кайгының ни сүз икәнен
Белмәгән сабый бала!
Ни булды сиңа, гүзәлем,
Йөзләрең сарылана?

Синең дә бардыр, күрәсең,
Әрнүләр, җәлләүләрең:
Яшьләрең юа лабаса
Күзеңнең зәңгәрләрен...

1942

ИРТӘЛӘР ҖИТТЕ ИСӘ

Әминә Җәлилгә

Иртәләр җитте исә
Аклысын кия ярың:
Юлларда күзе аның...
Ә юлда — җилләр исә,
Иртәләр җитте исә...

Аклысын кия ярың,
Карасын кими әле:
Белми ул, белми әле
Сугыштаниләр барын,
Аклысын кия ярың...

Юлларда күзе аның...
Ә юлда — күе тузан.
Син килеп чыгар сыман
Тузанга батып тагын,
Юлларда күзе аның...

Ә юлда җилләр исә:
Җил, йөгереп килеп кереп,
Сөенечләр бирер кебек...
Күзләре юлда гизә...
Ә юлда — җилләр исә...

Иртәләр җитте исә,
Уян да, терел дә син,
Кайт әле өеңә син:
Күр, гомере ничек кичә,
Иртәләр җитте исә...

1944

ГӨЛЛӘР ИНДЕ ЯФРАК ЯРАЛАР

Гөлләр инде яфрак яралар,
Хәбәр итеп язлар җитәсен.
Язлар җиткәч, сугыш бетәсен
Көтеп утыра сабый балалар:
Гөлләр инде яфрак яралар!

Хәбәр итеп язлар җитәсен,
Кояш керә кайбер көннәрдә
Утыны беткән ятим өйләргә.
Керә дә котлый алар иртәсен,
Хәбәр итеп язлар җитәсен.

Язлар җиткәч, сугыш бетәсен
Салют кыла «сугыш алласы».
Чү, елама, солдат баласы:
Туплар әйтә әнә, иштәмсең,
Язлар җиткәч, сугыш бетәсен.

Көтеп тора сабый балалар
Аждаһаның башын өзгәнне.
Ә ул инде җиңелеп тезләнде.
Дар элмәге лаек та аңар,
Карап тора сабый балалар...

Гөлләр инде яфрак яралар,
Язы җитте, язы дөньяның!
Ас җәлладны, солдат туганым,
Беләләр бит барыбер балалар...
Гөлләр инде яфрак яралар!

1945

ЧӘЧӘК СИБЕЛӘ ҖИЛДӘ

Төштә миңа нәни кызым килде,
Чәчләремне сыйпап тарады.

М. Җәлил

Җилләр исә исәр-исмәс кенә,
Чәчәк сибелә сибелер-сибелмәс...
Уйлады ул: беркем белмәс инде,
Шулай яшерен һәлак ителгәч...

Ике кулын артка куйган килеш
Үтеп бара алан үтәли.
Сабыр гына искән урман җиле
Айлы юлга чәчәк сибәли.

Ул әйтерсең бары эштән, менә
Бары өйгә кайткан чагында,
Уйлап бара җирнең киләчәге —
Сыйныфларсыз чоры хакында.

Ике кулын артка куйган көйгә
Үтеп бара айлы аланны.
Иркәлисе килә аның шунда
Юл буена үскән баланны.

Гөлләр исе сипкән җылы җилләр,
Юлларына яуган чәчкәләр,—
Нәрсәдәндер боек төсле алар,
Моңсу алар әллә нәрсәдән...

Ә сандугач, никтер, уйга талган,
Дәшми кошчык, күңеле тулган күк.
Кәккүк кенә кайчак үксеп куя,
Елап арыган ятим олан күк...

Ул баш иеп уза
Имән картка,
Сеңелләр күк сылу каенга.
Горизонттан кояш килеп чыга,
Бәхилләшеп, күреп калырга.

Китеп бара,
Устав боерганча
Артка куеп
Бәйле кулларын,
Югыйсә ул сыйпап узар иде
Боегып торган балан куагын...

Табигатькә — тере мәңгелеккә —
Азакны кат өзелеп соклана:
Алып бара аны кырыс конвой,
Илтә бара теге дөньяга.

Туктадылар,
Күзен бәйләделәр,
Яшергәндәй шушы әшләрен.
Ә җир барыбер аның төсе итеп
Алып кала соңгы эзләрен.

Атты фашист...
Урман үкереп куйды...
— Үтерәләр бит кешене,— дигән кук
Борылды да читкә китте пуля,
Читкә китте, протест биргән күк.

Винтовкасын озак төзи җәллад:
Йөрәк турысын эзли шикелле...
...Әллә шунда
Кошлар кычкырдылар,
Әллә аңа шулай ишетелде:

Бик еракта, Идел буйларында,
Җавап көтеп,
                үксеп,
                        тилмереп,
Нәни балан кебек сабый бала:
«Минем эти кайда?» — ди кебек.

Тыныч кына әйтте:
— Башыма төбә.
Минем җаным шунда — башымда.
Туган илен өзелеп сөйгән өчен
«Гаепле» ул
                фашист каршында.

Уйлады ул:
— Шулай яшерен үлгәч,
Кем белсен,— дип,— соңгы хәлемне.
...Үксеп искән җилдә чәчәк сибелә,
Чәчәк күмә
Яңа каберне...

1947

КАЯН АЛДЫҢ?

Әй син, йөрәк,—
Сансыз йолдызларның —
Матдәнең бер җанлы кисәге!
Каян алдың сөю, сагынуларны,
Каян алдың син бу хисләрне?!

Киләчәктә
Кирәк булмас, бәлки,
Юксынулар, сагыну, сөюләр,
Күңелдәге изге һәйкәлләрне
Искә алып башны июләр?!

Киләчәктә, бәлки, кирәк булмас,
Ташлап киту кирәктер, бәлки?
Ә ташланмый,
Матәм көне саен
Йөрәк, мескен, әрни дә әрни.

Кешенең син, ахры, һәрбер хисен
Киләчәккә алып барырсың;
Анда да син шулай сөя торган,
Сагына торган булып калырсың!

Егерменче гасыр уртасына
Килеп җиткән бөек мәхәббәт,
Күрәм, күрәм: җиңә алмый сине
Һичкем, һични, һичбер һәлакәт!

1947

АГЫЛА ДА БОЛЫТ АГЫЛА

Агыла да болыт агыла
Туган-үскән җирләр ягына;
Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр
Нәрсә әйтер туганнарыма?!
Агыла да болыт агыла...

Нәрсә әйтсен: берни белми ул,
Хәбәре юк минем йөрәктән.
Мине бары чылатып үтте
Кукурузлар белән беррәттән...
Нәрсә әйтсен: берни белми ул.

Роман кебек күңелле син, юл!
Азмы синдә гомер уздырдым,

Ничә кием чабата синдә,
Ничә кием итек туздырдым!
Роман кебек күңелле син, юл!

Ә син, яңгыр, искә төшермә
Итегемнең ничек икәнен...
Яланаяк килдем дөньяга,
Шулай гына, бәлки, китәрмен.
Ә син, яңгыр, искә төшермә!

Зират бит ул Сабантуй түгел,
Нигә анда киенеп китәргә?
Бу дөньяның бер пар итеген
Нигә юкка әрәм итәргә?
Зират бит ул Сабантуй түгел.

Агыла да болыт агыла
Таулар аша Казан ягына;
Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр
Нәрсә әйтер туганнарыма?!
...Агыла да болыт агыла...

1951

СИҢА

Тагын бер яз саубуллашып китте,
Ядкяр итеп чәчәкләр биреп...
Син дә киттең,
Төсеңне тик миңа
Гомерлек бер истәлек итеп.

— Ут эчендә йөргән чакларында
Җуйгандыр ул мине,— дисеңме?
Юк,
Җаным белән ышыклап алып чыктым
Һәлакәтләр аша мин сине.

Ничә тапкыр гизеп үттем инде
Җир шарының орбитасын мин;
Тик беркайда очратмадым сине,
Табалмадым, табылмадың син.

Очрашып бер тагын вокзалларда,
Саубуллашып үтәсе иде;
Йөрәгемдә синең иреннәрнең
Җылысын алып китәсе иде!..

Әйт булмаса,
Озак истәлеккә
Бер җылы сүз әйт син, булмаса.
Бу чиге юк озын мәңгелектә
Бер генә кат яшибез ләса.

1952

СӨЙЛИ ТОРГАН МАТЕРИЯ

Юл читенә басып, уйга талып,
Карап тора гүзәл миләүшә.
Кайларгадыр барган юлчы аңа
Йомшак кына итеп эндәшә:

— Йөрәгем дә арыды юлда,
Аяклар да талчыкты бүген,
Туктап шунда, сүз кушарга сиңа
Рөхсәт итче, таныш түгелем.

Тартынма син, сеңлем, ятсынма син,
Сөйләшик бер утырып янәшә.
Ятлар түгел, сиңа минем аша
Бертуганың — матдә эндәшә.

Еракләрдан, галактикалардан
Без бу җиргә бергә килдек ич,
Без матдәнең безне тудырачак
Потенциаль көче идек ич.

Ничә миллион гасыр үтте инде,
Безнең шушы җиргә килгәнгә...
Син бер гөлгә инде әверелгәнсең,
Ә мин менә — кеше дигәнгә.

Тартынма син, сеңлем, ятсынма син,
Серләшик бер утырып янәшә,
Ятлар түгел, сиңа минем аша
Бертуганың — матдә эндәшә.

Ах, синең бу яшьлек матурлыгың
Аяктан ук ега йөрәкне.
Шундыйлыкка сине кояшлармы,
Йолдызлармы — кем соң өйрәтте?

Күрәм:
Син дә бөек яшьлек әшен,
Гүзәл хәлне хәтерләтәсең;
Җирдә тормыш дәвам итсен өчен,
Тормышка син әзерләнәсең.

Синең парың еракларда түгел,
Шул далада, сеңлем, якында;
Күбәләкләр белән, җилләр белән
Серләшә ул синең хакында.

Алъяпкычын гөлләр тузанында
Алтынлаган зәңгәр күбәләк,
Сөйгәнеңнән сиңа сәлам китереп,
Күзләреңне синең үбәчәк.

Ә минеке? Ә минеке ерак,
Ерак әле моннан шулкадәр;
Бу төшләргә килеп җитә алмый
Ни бер сәлам, ни хат, ни хәбәр!

Эх, очар да кайтып китәр идем,
Җаным әгәр күбәләк булса;
Тормышларым әгәр ватык түгел,
Сынык түгел, түгәрәк булса.

Җил-яңгырлар аны каксалар да,
Суксалар да ташка мескенне,
Сыгылмаска, саргаймаска тырыша,
Күзге көнге астра шикелле.

Тартынма син, сеңлем, ятсынма син,
Серләшик бер утырып янәшә,
Ятлар түгел, сиңа минем аша
Бертуганың — матдә эндәшә.

Мин — бу кырлар, сулар, җилләрдәге
Атомнарның иске туганы;
Материя мин, җаным,
Аның бары
Сөйли, җырлый, сагына торганы.

1953

СУЗ КУШАСЫ КИЛӘ ТАЛЛАРГА

Уйга талган
Дәрья таллары...
Шундый уйчан аулак таңнарда
Суз кушасы килә талларга:
— Сез беләмсез кая барганны,
Уйга талган дәрья таллары?

Шундый уйчан аулак таңнарда,
Танышларын күргән шикелле,
Туктый кеше, узып китешли,
Һәм баш ия моңсу талларга.

Шундый уйчан аулак таңнарда
Суз кушасы килә талларга,—
Әйтерсең тал татарча белә.
Белми дә бит, чиксез мәңгедә,
Тере хәлдә очрый алганда,
Суз кушасы килә талларга:

— Сез беләмсез кая барганны?
Тере хәлгә килгән бу матдә
Каядыр бит бара, әлбәттә.
Яфрак ярып — санап заманны —
Сез беләмсез кая барганны?

Уйга талган дәрья таллары
Дәшми генә яфрак яралар,
Дәшми генә карап калалар
Кеше кая китеп барганны...
Уйга талган
Дәрья таллары.

1953

ТУРГАЙ НИГӘ ЭНДӘШМИ?

С. Л.

Көзге салкын җилләр искәч
Әйткән идем тургайга:
— Яз килгәндә, хәбәр китер,
Юлың безнең уңайда.

Язлар җитте,
Кошлар килде.
— Сау кайттыңмы, тургаем!
Сәлам бардыр, хәбәр бардыр,
Күргәнсеңдер, мөгаен?

Нигә дәшми?
Ник эндәшми?
Ник сөйләшми бу тургай?!
«Әйтермен дә йөрәге ярылыр,
Егылып китәр...» — ди бугай...

1955

КИЕК КАЗЛАР

Яңгырларда-явымнарда,
Давылларда-җилләрдә
Киек казлар кыйгылдаша
Мин белмәгән телләрдә.

Киек казлар кыйгылдаша,
Җырлашалар микәнни?
Туган илләр кала бит, дип
Елашалар микәнни?

Безнең дә бит шулар сыман
Киткән еллар бар иде;
Кыйгак-кыйгак, илем ерак,
Дигән чорлар бар иде.

Киек казлар кыйгылдаша,
Сау бул, якташ, диләрдер;
Әллә кайтыр, әллә кайтмас
Безнең башлар, диләрдер.

Казлар кебек очасылар,
Китәселәр юк инде;
Кыйгак-кыйгак, илем ерак,
Дияселәр юк инде.

Кыйгылдашып болытларда
Мин белмәгән телләрдә,
Киек казлар китеп бара
Мин күрмәгән илләргә.

1956

ТАМЧЫЛАР НИ ДИЛӘР?

Луиза Салиаскаровага

Сандыгыңда ята
Синнән калган
Белешмәләр салган ридикюль:
Миннән сиңа — гомер юлдашыма —
Иң беренче бүләк иде ул.

Ридикюльдә калган белешмәләр...
Алардагы кайбер билгеләр
Тормышыңның соңгы хәбәрләрен
Бүген миңа сөйләп бирделәр...

Һәркайсында
Тамчы-тамчы эзләр,—
Алар нинди тамчылар икән?
Болыттанмы алар,
Әллә синең
Керфекләрдән тамдылар микән?..

Тәрәзәңә «җилләр» бәрелгәннәр,
«Сагынма!» — дип янап киткәннәр...
Күнмәгәнсең... Эштән сөрелгәнсең...
Еллар сине донор иткәннәр...

Посылкалар белән ярдәм иттең:
— Без бит илдә... өйдә бит...— дидең.
Ә ул ярдәм
Каныңа алыштырган
Паекларың икән бит синең...

Алдарсың дип уйлый идеммени? —
Ә син мине алдагансың ич:
Өзелер хәлгә җиткән гомеремне син
Җаның белән ялгагансың ич!

Соңгы таңың беленеп килгәндә дә
Күрешү көнен көткәнсеңдер дә,
Ләкин ирек
Бераз кичегеп килеп
Эзләп тапты мине Себердә...

Баш иям дә рәсмең каршында мин,
Күзләреңә багам тилмереп,

Яшьле күзен Мадоннага текәп
Сүзсез калган Рафаэль кебек...

Тирбәлешеп куя
Уйчан гөлләр,
Бер-беренә хәбәр биргәндәй:
«Кеше булсак әгәр,
Без дә шулай
Сыкрар идек, бәлки...» — дигәндәй...

1957

ТУГАН ТЕЛ ТУРЫНДА ҖЫРЛАР

1

И телем, сансыз гасырны
Исән-сау кичкән телем!
Сыкраулар теле түгел син,
Күкрәүләр теле бүген.

И безнең батыр телебез,
И безнең гәүһәр мирас!
Күпләрне күргән башыңны
Инде син күтәр бераз.

2

Тарихым истәлеге син,
Болгарым истәлеге,
Гасырлар аша үтелгән
Юлларым истәлеге.

Чишмәләр исән чагында,
Иделләр кибәмени?
Гасырлар күммәде сине,
Дәверләр күмәмени?

Иңгә-иң безнең теләкләр,
Кулга-кул уйларыбыз,
Якты язмышларга таба
Барасы юлларыбыз.

Син — минем тере тарихым,
Син — минем киләчәгем,
Тик синдә, газиз туган тел,
Бәхеткә җитәчәгем.

И телем, синдә нәфислек
Чишмәсе кибәрмени?
Гасырлар сиңа тимәде,
Дәверләр тиярмени?

* * *

Бу елларда мин дә шулай инде:
Бер йокыда җиде уянам!
Урман өсләрендә җил тузына.
Мин — уйланам... Һаман уйланам...

Кул озайта кайчак өермәләр —
Сугылып карый өлкән имәнгә,

Кубарып ук ташлардай итенә...
Ташлар иде — тамыр тирәндә!

Без — давылда: очрашкалый башлар
Нәкъ шундый ук ямьсез фактка.
Тик... соңлаган, шом җил өлгермәгән
Тамыр шактый өстә вакытта.

Һичбер нинди кара өермә дә,
Аласы да безне егалмый —
Тамыр тирән безнең! Җирлек бакый!
Хаклык — бездә, хаклык югалмый.

Без түбәннән — җирдән күтәрелдек.
Азмы — юлда азап чикмәдек?!
Кайсы фасикъ инде вата алсын:
Без — алмаз кук каты чикләвек!

Тукмады соң дөнья! — Үртәнмибез:
Без табышта калдык, табышта!
Рәхмәт аңа, безне изә торгач,
Чыныктырып уткән язмышка!

Без пыяла түгел, чатнамадык!
Аткан ташлар коелып төштеләр.
Безгә тигән саен, теләктәшләр,
Яклаучылар санда үстеләр.

Күкрәк түгел,
Йөзгә, күзгә басып,
Кара максатына
Ирешмәкче булган битсезләр,
Безне белгән ничә меңнәр өчен
Без — мәгънәви һәйкәл!
Сез — кемнәр?!

Ялкынланып,
Рухи алыплардан
Таш билгеләр калган төбәктә
Нурланабыз:
Алар васыять иткән
Гүзәл гамь бар безнең йөрәктә!..

Әмирхан Еники
(1909—2000)

МАТУРЛЫК

(бер карт әдип авызыннан)

Күптән, бик күптән булган вакыйга, әмма бүгенгедәй күз алдымда: без, өч шәкерт, бер атка утырып, өяз мәдрәсәсеннән авылыбызга кайтырга чыктык. Дөресрәге, Гыйлемдар белән без икәү бер авылга — Чуаркүлгә кайтабыз, ә Бәдретдинне юл өстендәге Ишле авылында калдырып китәргә тиешбез. Тагын шуны да әйтим: безне ялкау гына юыртып алып кайткан күк алаша Гыйлемдарларныкы иде. Без авылда алар белән күрше генә торабыз. Шул сәбәпле Гыйлемдар белән мине алырга бер язын безнең ат килсә, икенче язда алар аты килә торган иде.

Ә Бәдретдин — безнең очраклы юлдашыбыз. Дөрес, без мәдрәсәгә бер вакытта җыелабыз, бер вакытта таралабыз, ләкин моңарчы аның белән бергә кайтырга туры килгәне юк иде әле. Бәдретдин кешегә бер дә йөк булырга яратмый иде. Укулар беткәч тә, ул базарга килгән авылдашларының берсенә ияреп китә дә бара, яки ялгыз үзе генә утыз чакрымдагы авылына җәяүләп сыптыра торган иде. Бу юлы инде без аны, үзебез сорап дигәндәй, бергәләп кайтырга күндердек.

Бәдретдин безнең мәдрәсәдә иң ярлы шәкерт иде. Аңа авылыннан бернинди дә ярдәм килми иде. Тик Ишледән базарга килүче берәрсе бик сирәк кенә аңа әнисенең киндер чүпрәккә төреп җибәргән тары ипиен яки берәр йомарлам маен кертеп чыга торган иде. Бәдретдин, шуны да бик кыенсынып: «Нигә инде бу? Әнкәйгә әйтегез, мин ач түгел, үзеннән өзеп җибәрмәсен!» — дип алып кала иде. Һәм шул майны ул, ни өчендер, без белән чәнчеп ашый иде. Шәкертләр аңардан: «Нигә алай итәсең?» — дип сорагач, Бәдретдин, көлгән булып кына: «Без белән ашагач, озакка җитә ул!» — дип җавап бирә торган иде.

Илдә чыпчык үлми дигәндәй, безнең Бәдретдин дә, бик интегеп, ачка киселеп булса да, укуын әнә шулай алып бара иде. Һәм бик яхшы укый иде ул. Хәер, бу күп сыналган нәрсә: рәхимсез нужада торып укыган ярлы шәкерт, гадәттә, бик сәләтле булып чыга. Башкача аңа мөмкин дә түгел. Бай шәкерт, әйтик, туң күчән булса да, мәдрәсәдә теләсә күпме ята ала, ә ярлы шәкерт, начар укыдымы, беренче кыштан ук мәдрәсәдән очарга мәҗбүр була... Аннары ярлы шәкерт, бик яхшы укыса гына, үзенең матди хәлен дә беркадәр җиңеләйтә ала.

Менә безнең Бәдретдингә дә, ул замандагы тел белән әйтсәк, истикамәтле[1] вә иҗтиһатлы[2] шәкерт булганга күрә, байлар иганәсеннән[3] ара-тирә ярдәм тия иде; начар укучыларның дәресләрен хәзерләшкән өчен дә аңа аз-маз тама иде, хәлфәләргә дә ул булышкалый иде, аннары авыру-сырхауларга догалыклар, аятелкөрсиләр күчереп тә азрак бакырлар төшергәли иде. Кыскасы, эшсез тормый иде шәкерт. Ләкин эшне дә, ярдәмне дә ул үзе бервакытта да сорап алмый иде. «Мин бит ярлы, миңа ярдәм итү сезнең вазифагыз» дигән әрсез мескенлекне без аның йөзендә беркайчан да күрмәдек.

Табигате белән үк ул, ничек дим, шундый тигез, сабыр холыклы бер егет иде. Ялагайлана да белмәс, масая да белмәс, яхшы белән яхшы, ә яман белән алыш-биреше юк,— андыйлардан үзен, ничектер, бөтенләй читтә тота белә иде. Тагын шунысы кызык: никадәр генә ярлы булмасын, ул берәүдән дә бернәрсә дә сорарга яратмый иде. Гадәттә, шәкертләр аңардан гел анысын-монысын сорап торалар, чөнки аның үз кулы белән ясаган каеш тупсалы, әрҗә сыман сандыгында мәдрәсә тормышы өчен кирәк бөтен нәрсәсе: энәсе дә, җебе дә, уймагы да, безе дә, пәкесе дә, эскәге дә, көзгесе дә, төрле каләмнәре дә, кәгазь-дәфтәрләре дә, хәтта җилем белән балавызы да саклана торган иде. Ничек җыйгандыр ул аларны, ләкин һаман шул ярлылыгым кешегә йөк булмасын дип, тамагыннан өзеп булса да тырышкан, күрәсең, инде. Дөрес, ул калын-калын дәрес китапларына бик мохтаҗ иде. Ләкин булган кадәресен бик пөхтә тышлап, битләре керләнмәсен өчен көмеш кәгазьдән тоткыч ясап, кадерләп кенә саклый иде.

Ул заманда, ягъни революция алды елларында, шәкертләрнең яңа әдәбият белән мавыгуы искиткеч көчәйгән иде. Икмәк шикелле үк зарури бернәрсәгә әйләнеп киткән иде безнең өчен әдәбият!.. Һәрбер шәкерт төпләп алган калын дәфтәренә җыр күчерә, шигырь күчерә, хәтта романнардан өзекләр дә күчерә. Ике шәкертнең берсе шигырь яза. Бик күпләр Сәгыйт Рәми

---

[1] *Истикамәт* — турылык, намуслылык.
[2] *Иҗтиһат* — тырышлык.
[3] *Иганә* — ярдәм, булышлык.

белән тилерә. Аңа иярәләр, аңа охшарга тырышалар, аны яттан сөйләп йөриләр... Дөрес, безнең барыбыз өчен дә бөтенесеннән өстен, бөтенесеннән якын Тукай иде, иң күп күчерелгән, иң сөеп укылган да Тукай иде.

Шигырь чире безнең Бәдретдингә дә йоккан иде, ул да яза иде, ләкин язганын бервакытта да күтәреп, очраган берәүгә укып йөрми иде. Аны сорап та укырга күндерүе читен иде. Инде укый калса, аның әйберсе башкаларныкы төсле зар еламыйча гына язылган, күбрәк табигать күренешен гади генә сурәтләгән яки үзенчә берәр тормыш фәлсәфәсе әйтергә тырышкан кыска гына шигъри парча булып чыга торган иде.

Әнә шундый сәер генә, серле генә һәм сөйкемле генә бер егет иде безнең Бәдретдин шәриктәшебез[1]!

Ярый, сүз озынга китте, без бит әле өчәүләшеп читән тарантаста хозур гына авылыбызга кайтып барабыз. Юл такыр, тузан юк; күк алаша, эченә кату төшүдән «горт-горт» иткән тавыш чыгарып, үз көенә салмак кына юырта... Күптән түгел, май урталарында, беренче җылы яңгырлар явып узган иде. Хәзер бөтен нәрсә дәррәү кузгалып, күтәрелеп үсеп бара: арышлар сабакка сузыла башлаган, бодайлар куе булып, кучкыл-яшел булып, егетләр мыегыдай сызылып кына чыгып килә; сөрелмәгән чирәмнәрдә яшь үлән былтыргы корыган үләнне басып, каплап та киткән, кайберләре инде чәчәкләрен дә ачарга өлгергән... Юл буенда әнә эт эчәгесенең беренче ал «кыңгыраулары»... Әйтәсе дә юк, табигатьнең иң саф, иң садә, иң ямьле чагы!..

Безгә, кыш буе мәдрәсәдә кибеп беткән шәкертләргә, бу чиксез иркен, якты, җылыкай дөнья искиткеч тансык иде, шифалы-рәхәт иде, без аны иснәп тә, сулап та, күзләребез белән күреп тә туя алмый идек. Баштарак без, әледән-әле тарантастан төшеп, аякларыбыз җирнең җылысын бер рәхәтләнеп татысын дигәндәй, чирәмгә кереп киттек, йөгерештек-куыштык, иелеп, чәчәкләр өздек. Бәдретдин тау юасы тапты, аны өзеп чәйнәдек. Мин безнең авылда «тәмлекәй» дип йөртелә торган, сабагы дүрт кырлы озын гына бер үсемлекне җыеп алдым. Аны да тиресен суеп ашап карадык. Бәдретдин әйтә, моны башкортларда «кияү камчысы» дип йөртәләр, ди, чөнки очындагы менә шушы бөреләре зәңгәр чәчәк булып ачылгач, ул, чынлап та, чуклы камчыга охшап китә.

Ә безнең Гыйлемдар, озын сыйрак, гел йомран эзләп чапты, туктап, ике учын кушлап сызгырып та карады, ләкин хәйләкәр җәнлек пәкерт сызгырганын сизә иде, ахрысы, оясыннан чыгып, колакларын торгызып, арт тәпиләренә утырмады.

---

[1] *Шәриктәш* — иптәш, сабакташ.

...Юл буе безне тургайлар сайравы озатып барды. Гүя менә төпсез нурлы аяз күктән өстебезгә сихри бер моң тибрәнеп-чыңлап, өзлексез явып торды. Ә беләсезме, тургай сайравының сихере нәрсәдә?.. Иң элек, сынаганыгыз бардыр, тургай сайраганда, җир өстенә җиңелчә генә уйчан-моңсу бер тынлык җәелә. Әйтерсең барлык табигать, барлык җан иясе, әдипләр әйткәнчә, сөкүт[1] калып, тәмам мөкиббән[2] китеп, бары аны гына тыңлый, аны тыңлап сөенечле, сагышлы, ләззәтле бер рәхәткә чума... Икенче сихере шунда ки, тургай сайраганда, дөнья, ничектер, искиткеч җәелеп, киңәеп, яктырып киткәндәй була. Әнә шул югарыда кечкенә кошчык талпынган күкнең үзе шикелле үк, Җир йөзе дә иксез-чиксез булып, гаҗәеп тын, нурлы булып тоела башлый...

Белмим, бу вакытта бүтән кошлар сайрый торгандырмы,— игътибар иткәнем юк, әмма бер кошның тавышы, бөтен җир өсте тургайлар сайравыннан өзлексез чыңлап торса да, безне сискәндереп, колагыбызга килеп керә. Бу — кәккүк! Кешеләрнең исләренә ниндидер бик мөһим нәрсәне төшерер өчен, табигать тарафыннан яратылган күзгә күренмәс сәер кош!.. Юлдан шактый читтә торган күксел урман яныннан узганда, без аның да тынып калырга мәҗбүр иткән кисәтүле тавышын ишеттек.

Шулай кәефләнеп, күңелле генә кайта торгач, без, ниһаять, кызыл ярлы тауларга каршы тигез үзәнлектә сузылып утырган Ишле авылына якынлаштык. Юлга чыккач та, Бәдретдин безне, Ишледә туктап, чәй эчеп чыгарга чакырган иде. Без, билгеле, кыстатып тормадык, шәриктәшеңә кереп, чәй эчеп, күңел ачып чыгу — шәкертләр өчен табигый бер низам[3] инде ул.

Авылга җиткәндә генә, Бәдретдин, дилбегәне үзенә алып, атны олы юлдан уңга каерды да бәбкә үләне түшәлгән җир өстеннән генә иң арткы урамга таба алып китте. Һәм озак та үтми, шул урамның иң читендәге, бүтән йортлардан аерылыбрак, ялгызы гына торган бер өйнең каршысына безне китереп тә туктатты.

Без фәкыйрь кешеләргә керәсебезне белеп килә идек, әмма бу кадәр ярлы хуҗалыкны күрербез дип һич тә көтмәгән идек. Хәер, моның хуҗалык дип атар җире дә юк иде. Шыр кырда утырган бәләкәй генә ялгыз өй үзе искереп-тузып, яртылаш җиргә кереп беткән. Салам түбәсе, череп, каралып, тирескә әйләнә башлаган. Әйтерсең шуның авырлыгыннан өйнең кайбер бүрәнәләре бүселеп чыккан, ишек-тәрәзәләре кыйшайган, ә тәрәзә пыялалары тора-тора инде яшькелт-зәңгәр төскә кергән... Капка юк, койма

---

[1] *Сөкүт* — дәшми тору, тын калу.
[2] *Мөкиббән* — чиксез (бирелү).
[3] *Низам* — тәртип, кагыйдә.

юк, тик урам яклап та кыр яклап кына ике рәт киртә сузылган... Ишегалдын кыр үләне басып киткән. Анда чикерткәләр тыз-быз сикерешәләр. Димәк, бернинди дә аяклы мал юк.

Без инде хәйран булып, гаҗәпләнеп калуыбызны Бәдретдиннең үзенә ничек тә сиздермәскә тырыштык. Арба эзе төшмәгән ачык ишегалдына узып, түбәсе чыбык-чабыклар белән ябылган иске генә бер читән абзар алдында атыбызны туктаттык. Өйдән кечерәк буйлы, ак чырайлы, җирән сакаллы, арык-өшән генә бер абзый чыкты. Аның өстендә киндер күлмәк, тез башларына зур ямаулар салынган киҗеле[1] ыштан, башында мескен бүрек, аякларында тула оек белән тузган чабаталар иде. Ул, тарантас янына килеп, бары: «Улым!» — дип кенә, Бәдретдин белән күреште, аннары безгә дә шулай сүзсез генә ике кулын сузды һәм шунда ук, ат башына барып, аны тугара да башлады...

Бәдретдин, сандыгын күтәреп, өйгә ашыкты. Өй ишегендә бер хатын күренде, ләкин ул, ни өчендер, кире борылды. Бу Бәдретдиннең әнисе булгандыр инде, тик менә аның ишектән чыгар-чыкмас кире чигенүе безне бераз гаҗәпләндерде.

Атны тугарып бетүгә, Бәдретдин өйдән чиләк белән су, чүмеч һәм тастымал күтәреп чыкты. Чирәм өстендә генә чиләктән бер-беребезгә су коеп юынып алдык. Күңелгә «Комганнары юк, күрәсең» дигән уй килде. Һәм без бернәрсә күрмәгән, белмәгән булып кыланырга яки ваемсыз гына сөйләнергә, ничектер, сүз дә, сәләт тә таба алмый идек. Ләкин Бәдретдин үзе тыныч иде, һәрхәлдә, оялу-уңайсызлану кебек бернәрсә дә сиздерми иде.

Юынып беткәч, сәлам биреп, өйгә кердек. Бәдретдиннең әтисе, бер читтәрәк торган килеш, безне бик гади генә: «Әйдәгез, шәкертләр!» — дип каршы алды.

Караңгырак кына өй эче дә тышкы ягы кебек үк искереп, тузып беткән икән инде. Ләкин күпме генә искереп-тузып бетмәсен, аның бүрәнәләре тома балавыздай сары-көрән иде әле, тапталып, кырылып ашалган идәне дә чип-чиста иде... Өйнең бөтен түрен иңләп, өстенә киез җәелгән зур сәке тора, ике урындык, бер эскәмия, мич буенда тагын бер букән тора,— менә җиһаз дигәне бары шул гына. Мич алды иске генә чүпрәк чаршау белән бүленгән, анда кемнеңдер озын гына итеп чыра телүе ишетелә.

Өйгә кергәч тә, безнең иң элек күргән кешебез сәке түрендә, стенага терәлеп, текә генә утырган бер бабай булды. Бабай Хозыр Ильяс төсле ап-ак сакаллы, ап-ак күлмәк-ыштаннан иде. Бары тик башындагы беленгә әйләнгән түбәтәе генә аның күксел-кара иде.

Без бабайга, күрешер өчен, кулларыбызны суздык. Бабай селкенмәде. Бәдретдин ашыгып әйтеп куйды:

---

[1] *Киҗе* — кызыл төстәге мамык җеп.

— Бабакай, шәкертләр синең белән күрешергә телиләр.

— Ә, шулаймыни, бәрәкалла! — диде бабай, аз гына җанланып, һәм безгә кипкән, зур, каты кулларын сузды. Күзләре ачык булса да, ул дөм сукыр иде.

Без утырышып дога кылдык һәм, шәкертләрчә кулларыбызны тез өстенә куеп, бермәлгә тынып калдык. Безнең үзебезгә сүз башлавы, билгеле, кыенрак иде, аннары нидер менә телебезне һаман бәйләп тора иде. Гомумән, бу өйдә сүз бик аз сөйләнә булса кирәк,— ничектер, бик тиз без шуны сизгәндәй булдык. Бабай, үзенең эчке дөньясына киткәндәй, текә каткан килеш, тып-тын утыра. Бәдретдин әрле-бирле йөренә, нидер әйтмәкче дә шикелле, ләкин сүз таба алмый кебек... Әтисе башта мич буендагы бүкәндә безгә бераз шаккатып утырды да аннары, торып, сәке кырыена чәй урыны әзерли башлады. Иске генә киҗеле ашъяулык китереп җәйде, мич кашагасыннан кайсы замазка белән ябыштырылган, кайсысының сабы кителгән өч кенә чынаяк алып куйды, кыска гына чалгы пычагы, чүпрәккә төргән ярты ипи, тустаган белән сөт китереп куйды. Шуннан соң бүкәненә барып утырды. Бәдретдин үзенең сандыгыннан бер-ике уч шикәр алып, шуны ашъяулыкның уртасына салды.

Бераздан чаршау артыннан әкрен генә «Булды, улым!» дигән тавыш ишетелде. Бәдретдин, кереп, самавырны алып чыкты. Бу самавырның да борын һәм колак төпләре кургашын белән ямалып беткән иде.

Бәдретдин безгә сәкегә менеп утырырга кушты. Без менеп, аякларны бөкләп утырдык. Шуннан соң алдыбызга өчаяк белән йомырка тәбәсе килде. Без әле, ашка сузылмыйча хуҗаларның утырганын көтә идек. Ләкин бабай да урыныннан кузгалмады, абзый кеше дә бүкәненнән тормады. Шул чагында Бәдретдин, йомшак кына, чаршау эченә дәште:

— Әнкәй, чәй ясарга үзең чык инде.

— Әткәң соң? — диде чаршау эченнән әнисе, акрын гына.

— Әткәйме?.. Юк, син үзең яса инде безгә,— диде Бәдретдин, ничектер, бик ихластан үтенгәндәй итеп.

Чаршау эче бераз тынып торды, аннары киндер күлмәк өстеннән шундый ук алъяпкыч бугач оек-чабаталы хатын ситсы яулыгының читләрен битенә тартып һәм башын иеп кенә чыкты да самавыр артынарак килеп утырды.

Аңа күтәрелеп карагач та, минем йөрәк әллә нишләп китте. Дөресрәге, яшермичә әйтим, бер чиркану тойгысы йөрәкне өшетеп җибәргәндәй булды: бичара хатынның бөтен битен-күзен кайчандыр кичергән рәхимсез чәчәк зәхмәте тәмам бозып бетергән иде. Өстенә карап, моны сурәтләп торуы авыр, ничектер, тел бармый, ләкин шулай да сул күзенең бөтенләй кысылып, ә уң күзенең иләмсез зураеп калуын әйтмичә булдыра алмыйм,

чөнки шушы яшь пәрдәсе аша караган кашсыз-керфексез күзендә бичараның бөтен әчке җаны чагылырга гына тора кебек иде. Әйтерсең бу һич йомылмас яшьле-моңсу күз — аның шәрәләнеп калган бердәнбер күңел көзгесе!

Аны күреп беренче чиркану һәм кызгану тойгысын кичергәч тә, күңелгә иң башлап шундый уй килде: ничек итеп Бәдретдин бу бәхетсез әнисен чакырып алырга һәм безгә күрсәтергә җөрьәт итте икән? Без, гадәттә, кешене куркытырлык ямьсез яки гарип туганнарыбызны ятлар күзенә күрсәтмәскә тырышабыз. Хәтта әниебезне дә, әгәр ул менә шушындый булса, үзебез чакырып алып күрсәтергә кыймас идек, уңайсызланыр идек, оялыр идек. Бәдретдин бу кыен хәлне бөтенләй күрми, аңламый микәнни? Әллә, күрсә, аңласа да, бик тирән яшерә беләме?

Ә җиңги шул арада чынаякларга чәй ясап, йөзен самавыр артына яшерә төшеп, безгә сузды. Без, башларны күтәрмичә генә, сүзсез генә, чәебезне эчәргә тотындык. Бәдретдин, безне кыстап:

— Йәгез әле, шәрикләр, ни бары белән ашап кына эчегез, ашап кына! — диде, һәм аның тавышында мин көткән уңайсызлану яки оялу ник кенә бер ишетелсә иде!

Йомырка тәбәсен капкалап, икешәр чынаяк чәй эчкәч, без чынаякларыбызны каплады. Бәдретдин, сыеның ярлылыгыннан булса кирәк, үзалдына, сиздермәскә тырышып кына, бер сулап куйды. Аннары кисәк кенә аягүрә басты да:

— Булмаса, мин сезгә үземнең китапларымны күрсәтим әле,— диде һәм тәрәзә башына ясаган кечкенә шүрлектән бер өем китапларын алып безгә бирде. Без, бер эш чыкканга куанып, шуларны карый башладык. Монда яңа әдәбияттан ике-өч роман, дүрт-биш шигырьләр мәҗмугасы, иске әдәбияттан шактый тузган «Буз егет», «Тутыйнамә», «Ләйлә вә Мәҗнүн», «Каһарман катыйль[1]» кебек китаплар һәм гарәп, фарсы телендә берничә дәреслек бар. Без, күбрәк вакыт үтсенгә, бу китапларның кайсы укылган, кайсысы укылмаган, кызыклымы-түгелме,— шул турыда сөйләшкәләп, карап чыктык.

— Минем бит әле сезгә, шәрикләр, тагын бер күрсәтәсе нәрсәм бар,— диде Бәдретдин һәм, яңадан торып, шүрлектән кечкенә генә скрипкә алды. Бу кулдан гына ясалган, буялмаган, хөрти генә бер скрипкә иде.

Без гаҗәпләнеп сорадык:

— Кайдан бу синдә?

— Үзем мәтәштергән булдым инде,— диде Бәдретдин һәм скрипкәнең тонык кына тавыш чыгарган кылларын көйләргә

---

[1] *Катыйль* — үтерүче; үтерелгән.

тотынды. Аның кубыз уйнавын, мандолина чирткәләвен без белә идек. Әмма скрипкә!..

— Әй Бәдри, нигә моңарчы яшердең? — дидек без.— Мәдрәсәдә, Сәгыйт скрипкәсен алып, үзеңнән уйнаткан булыр идек бит!

— Оста барда кулың тый! — диде Бәдретдин, тыйнак кына елмаеп.

Ул айлар буе кул тимичә яткан скрипкәсен шактый озак азапланып көйләде. Шулчак мин аның әнисенә күтәрелеп карадым: ана үзенең шәкерт улына шундый бер бәгырьгә төшәрлек мәхәббәт белән, бәхет-сөенеч белән сихерләнеп, ереп, мөкиббән китеп карап утыра иде ки, мин хәтта йөрәгем-тәнем белән әллә ничек тетрәнеп куйгандай булдым. Аңлыйсызмы, күз алдыгызга китерә аласызмы,—гүя бу зураеп ачылган сыңар күздәге өнсез караштa бер адәм затына гына түгел, бөтен җан иясенә хас ниндидер менә үзе эшләгән могҗизага таң калу һәм шуңа чиксез куану, шуның белән әйтеп бетергесез горурлану ап-ачык чагылып тора иде: ул тапкан бит бу баланы! Ул имезгән бит аңа күкрәк сөтен! Ул — шушы сөлек кебек егетнең әнисе бит! Шәкерт әнисе, гыйлем иясе булачак кешенең әнисе... Ихтыярсыздан йөрәгем үкси башлап, мин тизрәк башымны түбән идем.

Бәдретдин, маташа торгач, ахырда скрипкәсен көйләде, иңбашына терәде, җәя сыман смычогы белән сызгаларга тотынды. Скрипкәнең тавышы бик зәгыйфь иде, чеби тавышыдай көчсезнечкә иде, ләкин бу минутта безнең күңелләргә ул да бик ягымлы, бик тансык иде. Бәдретдиннең уйнавын барыбыз да шылт та итмичә, тып-тын калып тыңлап утырдык. Бу ярлы өйнең һавасында ук ниндидер бер авыр сагышлы моң — мәңгелек моң йөзә кебек иде. Текә генә катып утырган ап-ак бабай ни уйлый, букәне өстеннән бер генә дә кузгалмаган абзый кеше ни кичерә,— моны белүе һич мөмкин түгел иде. Тик шушы моң эчендә, томан аша караган тулы ай төсле, Бәдретдиннең әнисе үзенең сүзсез шатлыгы белән яктырып утыра. Нинди язмышлар бәйләгән бу кешеләрне, нинди серләр саклана алар арасында?

Бер-ике көй уйнагач, Бәдретдин, ниһаять, әнисенә дәште:

— Әнкәй, сиңа нәрсә уйныйм?

Әнисе бермәлгә балаларча кызарып, шул ук вакытта куанычыннан тагы да балкыбрак китте, ләкин кайтарып сүз әйтә алмады.

— Әнкәй, син шушы көйне ярата идең бит! — диде Бәдретдин һәм «Салкын чишмә» не уйный башлады. Аның сүзләре, сүзләреннән дә бигрәк, шулкадәр гади, табигый, җылы-якын итеп дәшүе минем соңгы шикләремне дә чәлпәрәмә китерде. Әнисе өчен уңайсызлану дигән нәрсәнең әсәре дә юк икән Бәдретдиндә!.. Кайда ул уңайсызлану! Берәүне дә күрмичә, бары әнисенә,

әнисенең әнә шул башта безне чирканырга мәҗбүр иткән шадра, чалыш, акайган күзле йөзенә генә карап, ул скрипкәсен уйнады. Аның бу аз гына моңсу уйчанлык, яшерен генә кызгану белән өртелгән җитди-җылы карашында әнисен өзелеп ярату гына түгел, аны беткәнче аңлау, кадерләү, юату сизелеп тора иде кебек. Белмим, болай карый алыр өчен күңелләрдә нинди генә тирән мәхәббәт дәрьясы ятарга тиештер инде?! Әллә бу шулай бик ямьсез ана белән бик матур бала яки, киресенчә, бик матур ана белән бик ямьсез бала арасында гына буламы икән? Соңгысы, ихтимал, еш очрый торгандыр, әмма беренчесен ишеткән дә, күргән дә юк иде.

Шулай да безгә кузгалырга вакыт иде инде. Бәдретдин уйнап туктагач, без хуҗалардан дога кылырга рөхсәт сорадык. Абзый кеше ямаулы тез башларын ышкып куйды, ә Бәдретдин, бабасына үрелеп:

— Бабакай, шәкертләр сездән фатиха бирүегезне сорыйлар,— диде.

Бабай башын какты, һәм без кулларны күтәрдек.

...Күк алашаны җигеп, капкасыз-коймасыз, кыр үләне басып киткән «ишегалды»ннан урам уртасындагы тигез юлга чыктык. Бәдретдин һәм әтисе безне озатып, киртә буенда янәшә басып калдылар. Юк, алай гына түгел, алар белән бергә безнең артта авыл читендәге иң фәкыйрь йорт, бу йортның безгә билгесез нindидер тирән сере,— бәхетсезлегеме, фаҗигасеме, әллә без аңлаудан гаҗиз бөек өмете-бәхетеме торып калды.

Кояш баюга таба борылган иде инде. Ә шулай да тургайлар, көн яктысыннан туя белмәгәндәй, тагын да биеккәрәк менеп, тагын да сузыбрак, ярсыбрак берөзлексез сайрыйлар да сайрыйлар. Дөнья киң, киң, киң, әләләләләүү! Җире-күге тын, буш, моңсу... бик моңсу миңа! Берни эшли алмыйм үзем белән: самавыр артыннан гына улына карап утырган ана күз алдыма килә дә, эчемнән тагын үкси башлыйм... Кемгәдер йодрык селкеп кычкырасым килә: ямьсез түгел бит ул, матур бит ул, матур, матур Бәдретдиннең әнисе!

1961

Гариф Ахунов
(1925—2000)

ХӘЗИНӘ

(романнан өзекләр)

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

I

1951 елның җылы июнь ае Көбәшләр нигезенә бәхетсезлек алып килде. Көн кичкә авышып килә, кояш Загфыран таулары артына баерга җыена иде.

Йөзлекәй карчык, кулларын каш өстенә куеп, баеп баручы кояшка, Зәй буеның яшел әрәмәләрен алсу төскә манган шәфәкъ нурына озак кына карап торды, кичке салкынча һава белән болын буйларыннан, басулардан кайткан үлән исен, өлгереп килүче игеннәрнең салат ипие исен борын канатларын киереп иснәде.

Ишегалдының мал-туар таптамаган почмагында шайтан сөяген күмәрлек булып үскән алма үләне, песи борчагы, кайчандыр кем тарафыннандыр чәчелеп тә, инде үз белдеге белән читән буен сарып ала торган әрсез колмак аның күңелен аеруча бер җилкетү белән җилкетеп, сагышларын көчәйтеп җибәрде. Ул, әкрен генә, ашыкмый гына, кулын каш өстеннән алды, йомшак киез каталарын аягына җайлабрак киде һәм, кәкре муенлы артыш таягына таянып, үзләренең бакча буендагы тау асты чишмәсенә төшеп китте.

Йөзлекәй карчыкның үзе кебек үк борынгы иде бу чишмә. Ул белгәндә генә дә, аның тугыз-ун мәртәбә улагын алыштырдылар, ташу сулары агызып алып төшкән юшкыннарын чистартып, төптән бәреп торган вак чишмәләрен көчәйтеп җибәрделәр. Чишмә, үзенең мәңгелек суларын олы туганы Зәйгә илтеп тапшырырга ашыккан чакта, бормалана-бормалана юл ярып, үзенә озын бер канау ясаган, әнә шул канау тирәсендә, каз-үрдәк керсә

адашырдай булып, кыяк үлән, чаж үләне һәм искиткеч хуш исле бөтнек үләне үсә. Кәлимәт кешеләре бөтнекне, чишмәгә суга килгән чакларда яки бозау арканларга чыкканда, көлтәсе-көлтәсе белән җыеп алып китәләр, аннан, киптереп, төеп, ашка салу өчен порошок әзерлиләр, авырганда, кайнатып эчәләр, ә бөтнек монда күпме җыйсаң да бетми, көн саен үсә, көн саен артып тора иде.

Йөзлекәй карчык чишмәнең кер бәләкли торган басмасына аякларын сузып җибәрде, яулык читләрен колак артына кыстырып, яшьләрчә җитез генә битен юып алмакчы булды. Ләкин аның алай җитез эшли торган заманнары узган иде шул инде.

Кәлимәт кешеләре аның ничә яшьтә икәнен чама белән генә беләләр. Бер ишеләре, Көбәш Йөзлекәенә инде йөз дә өч яшь икән, аңа яңа теш чыккан икән, йөз яшәгәннән соң, адәм баласы янә дә сабый хәленә кайта икән, дип сөйлиләр. Икенчеләре исә, булмас, аңа җитмешне дә бирерлек түгел бит әле, йөз яшәсә, ул шулай таза булыр идемени дип, бәхәскә керешеп китәләр. Йөз яшәр кеше ни рәвешле сабыйга әйләнәдер, анысын табиблар тикшерер, әмма шунысы хак: Йөзлекәй карчык безнең татар авылларында сирәк очрый торган озын гомерле һәм хәсрәт-кайгыны батыр күтәрә алган чыдам кешеләрнең берсе иде.

Ул әле хәзер дә яртышар сәгать мунча чабына ала, балаларын юксынып, болыннарга, иген басуларына чыга; кеше ярдәменнән башка энәгә җеп саплый; илнең төрле якларына кош балалары кебек таралып киткән улларының, оныкларының төсен-битен, хәтта исемнәрен хәтерендә саклый, шуңа күрә ул Кәлимәт кешеләренә беркайчан да үлмәскә, беркайчан да авыру-сырхау күрмәскә яратылган могҗизалы кеше булып тоела иде.

Ләкин карчык соңгы вакытта үз хәлен үзе генә белә: нәрсә генә эшләмәсен, нинди генә хәрәкәт ясамасын, барысы аңа узган озын гомеренең аерым кисәкләрен искә төшерә, һәм ул хәзер шул истәлекләре дөньясында яши иде.

Гобәйдуллага, — авыл халкы телендә йөргәнчә, Көбәшкә — ул егерме җиде яшендә, аның беренче хатыны үлгәннән соң, кияүгә чыкты. Акылын җуяр дәрәҗәдә дуамал кеше иде, мәрхүм. Көчендә чакта берәүгә дә баш бирмәде: урманга барса, тугыз аршынлы плавайлыкны берьялгызы кулазак арбага салып кайтты, җигүле аты белән чытырманлыкларны ерып, урман каравылчысыннан качып котыла белде. Көннәрдән бер көнне, бүрәнә төялгән йөкне казылмага төшергән атының савырына имән күсәк белән кундырып имгәтеп ташлаганнан соң, берьялгызы буранда адашып йөреп, таң вакытында гына өйгә кайтып егылды. Шул егылудан берничә ел урын өстендә ятты. Йорт алып баруның бөтенләе белән үз җилкәсенә күчүе Йөзлекәйгә тормыш мәрхәмәтсезлекләренә каршы торырлык көч бирде. Язын кар

әреп беткәннән көзге суык җилләр исә башлаганчы, хаста ирен, арка кочтырып, сахрага алып чыкты; карлыган кагы, каен суы һәм язгы яшь кычыткан белән, тагын әллә ниткән үләннәр һәм җимеш сулары белән дәвалап, ике ел эчендә ирен аягына бастырды һәм, ел аралаш томраеп торган унбер бала табып, шуларны, чебеш анасы кебек, канат астына җыя барды.

Көбәше гүр иясе булганда, олы баласы Шәвәли кул арасына керерлек иде инде. Икесе кызамык чиреннән үлде, өчесе герман сугышына китеп юк булды. Унбер баладан алтысы исән калды.

Шәвәли өйләнеп башка чыкты. Өч кызы күрше-тирә авылларга кияүгә чыгып киттеләр. Бишенче баласы Баязит, үзбәк ягына китеп, зур укымышлы булды. Ватан сугышы алдыннан әнисен үз янына чакырып, гозерләп хатлар язса да, үзе алмага кайтса да, карчык аның белән китәргә риза булмады. Кая ул! Көбәш нигезен ташлап, ком бураннары уйнаган үләнсез-сусыз якларга китәме соң! Әле бит аның төпчеге бар — Әбүзәре. Аның игелеген күрә әле ул. Ләкин аңа Әбүзәренең дә игелеген бик озак күрергә насыйп булмаган икән, Ватан сугышына китеп хәбәрсез югалды егет. Ире белән ун еллар чамасы яшәп тә бала китермәгән чибәр Сәлимә, Әбүзәрнең үле хәбәре килү белән, кыз малы булган мендәрләрен култык астына кыстырып, атасы йортына кайтып китте.

Йөзлекәй карчык төп йортта япа-ялгызы торып калды.

Хәзер аңа бердәнбер юл авылда төпләнеп яшәүче беренче улына,— инде үзе илле яшьтән узып, бер оя бала үстергән Шәвәлигә күчү иде. Ләкин Шәвәлинең хатыны — каруңлыгы белән авылда дан тоткан Мәгыйшә — каенанасын үзләренә алдыруга теше-тырнагы белән каршы торды.

Авыл кешеләре, моңа ни дип әйтергә дә белмичә, Йөзлекәй карчыкны колхоз карамагына алырга дип киңәш корып утырганда, идарә йортына Шәвәлинең олы кызы Фәйрүзә килеп керде дә бусагадан ук кычкырып җибәрде:

— Бер анамны мир кулына калдырырлык булгач, ир исеме күтәреп йөрмим дә! Кәлимәткә ыстырам булсын, үзем күчәм әби янына!

Идарәдә утыручылар җиңел сулап, селкенешеп куйдылар: Фәйрүзә әйттеме — егылып үлсә дә, әйткән сүзеннән чигенми инде. Акыл җитмәс дәрәҗәдә дорфалык, күздән яшь китерердәй нечкә күңеллелек бу үзсүзле ирдәүкә кызның канына сеңгән иде. Сугыш чыгар алдыннан, ул, унтугыз яшьлек тап-таза чибәр кыз, уттай урак өстендә, моңлы җырлар җырлап, лапас күләгәсендә ятты. Урамнар буйлап, изүләре ачык кыска күлмәктән, оекчабата кимичә, шәрә балтырларын ялтыратып, чишмәгә суга йөрде. Гомер-гомергә ир-аттан тәнен яшереп, авызын яулык чите белән каплап сөйләшергә гадәтләнгән татар хатыннары

өчен бик тә сәер хәл иде бу. Аңа күзләрен акайтып, ашардай булып карап узалар, ләкин аның бу затсызлыгына каршы чара күрергә батырчылык итмиләр, ник дисәң, Фәйрүзә тешләгән җиреннән өзеп чыгара торган усал кыз иде. Өстәвенә заманның хатын-кыз ягында икәнен дә тоеп алган иде ул. Аның өчен авылда җанатучы егетләр дә аз булмады — Фәйрүзә күтәрелеп тә карамады. Күрәсең, мәхәббәт аның өчен юк нәрсә иде.

Кеше күңеле — дәрья. Сугышның өченче елында, Фәйрүзә әбисе янына күчеп килгәч, Кәлимәт якларыннан нефть эзләүче геологик разведка узды. Разведка башлыгы — янып торган яшь егет Булат Дияров — квартирга Йөзлекәй карчыкларга тукталды. Иркен итеп тегелгән көрән комбинезоны, җиргә ышаныч белән нык басып йөрүе, аннан да бигрәк үзсүзле дуамал кызга тиң итеп, хәтта беркадәр сокланып та каравы белән ул Пәйрүз-башкисәр йөрәгендә ут кабызды. Башкалардан аерылып торган бу егетне кинәт үз итте Фәйрүзә, атна буена күзенә ак-кара күренмичә, иләс-миләс йөрде, ә беркөнне Булатның эш урынына кичке аш илтә барган җирдән таң беленә башлагач кына әйләнеп кайтты.

Бер ай чамасы торгач, разведка, эшлисе эшен эшләп, үз юлына китте. Ә Шәвәли кызының «нифтече» егет белән кәеф-сафа коруы турында өйдән өйгә яман сүз таралды.

Кырык дүртенче елның җәендә, фронтлардан безнең гаскәрләрнең алга баруы турында куанычлы хәбәрләр күпләп ишетелә башлаган бер чорда, таң кошлары әле йокыларыннан уянып та җитмәгән бер вакытта, Фәйрүзә, өйалды чоланына бикләнеп, газапларын берәүгә дә күрсәтмәс өчен иренен чәйнәп, дөньяга ир бала китерде.

Фәйрүзәнең йөрәгендә кинәт ана хисе уянды.

Күңел кузгатырдай моңлы җырлары белән, ара-тирә дорфа сүзләр кыстыргалап, ул Тансыгын иркәләде. Бу табигать балаларының үзара чебердәшүләрен ян тәрәзәдән җемелдәвек йолдызлар карап торды. Йөзлекәй карчык, гүя яшьлеге кире кайткандай, адәм баласының җанын мыскыллый торган гореф-гадәтләргә кул селтәп, өченче буын баласын багарга кереште.

Тансыгы сәке йөзлегенә ябышып үрмәләп йөрер хәлгә җиткәч, Фәйрүзә колхоз эшенә чыкты: ат җигеп көлтә кертте, станцага задание бодае ташыды, өч җәпле агач сәнәк белән кырда эскерт куйды. Бер селтәнүдә мунча түбәсе хәтле итеп күтәреп алган салам чүмәләсенә хәтта күпне күргән авыл картлары да баш селкеп, тел шартлатып тордылар:

— Җеннәре эшләтә торгандыр бу дуамалны!

Аңа гомерлеккә дип тагылган «ирдәүкә», «затсыз», «ялкау» кушаматлары әкренләп онытылды. Кешеләр Пәйрүз-башкисәр күңелендә дә ана хисе һәм хезмәт дәрте уянуына сөенеп бетә алмадылар.

Тансык үсте, тоз кебек җете күзле, ут борчасы кебек тере малай булды. Ләкин, шапалак малайларның күбесенә хас булганча, биш яшькә чаклы җүнле-рәтле теле ачылмады. Әмма авыл кешеләре аның бу кимчелеген дә гаеп итмиләр, ул хакта сүз чыкканда, үзара якын итеп көлешәләр генә иде.

Кичке якта, эскерт куючылар ялга туктаган арада, Тансык әнисе янына йөгереп килә:

— Анаты, мати-кати-ка! — дип кычкыра ул ерактан ук. Бу аның «Әни, ими бир әле» дигән сүзе.

Фәйрүзә сәнәген батырып кадап алган салам чүмәләсен, әкият батырыдай җилләнеп, эскерт түбәсенә ыргыта, сәнәген җиргә кадый һәм, кешеләрдән тартынып-нитеп тормастан, бераз гына иелә төшеп, мул күкрәген чыгарып сала.

— Мә, им, җен әвәләгән бәйрәмгали!

Тансык колын кебек аягүрә баскан килеш имә дә үз юлына китеп бара. Бераздан нидер исенә төшеп тагын әйләнеп килә:

— Анаты, туартын тыертан туртамыу?

— Курка, улым, күгәрчен сыердан курка,— ди Фәйрүзә, улының патый-потый килүен кеше теленә күчереп. Гүя ул моның белән Тансыгының да кеше төсле сөйләшә белүен күрсәтергә тели.— Әбиеңә әйт: мин кайтканчы, эремчекне сөзеп куйсын. Кич белән эремчек пилмәне пешерербез.

Тансык аңа җавап итеп үз телендә тагын нидер пытылдый һәм, кара табаннарын елтыратып, авылга, әбисе янына йөгерә. Эскерт куючылар, керфек какмыйча, уйчан бер елмаю белән, аны күздән югалганчы озатып калалар.

...Йөзлекәй карчыкның икенче юанычы Арслангали иде. Аның бик кадерләп, бар кешедән артык күреп йөрүче шушы оныгы, Шәвәлинең икенче баласы, моннан биш ел элек өйгә килен төшерү хакында әнисе белән даулашты да, авылда бер көн тормый, калага китеп барды. Шул китүдән әйләнеп кайтмады. Авылда беркемгә бер генә юл да хат язып салмады. Ярар, әтиәнисенә язмасын да, ди, алар аның хәтерен калдырганнар. Нигә дип ул әбисенә язмый? Нигә дип ул дөньяда кече күңелле Йөзлекәй карчык барын оныта? Ичмасам, елына бер генә мәртәбә, күңел өчен генә күзгә-башка күренеп китсә, укасы уңмас иде бит. Авыл кешеләренең күзе сукыр түгел, күрделәр, ул бит аны карап-багып үстерде, ул бит аңа күпме әкият сөйләде, күпме җыр өйрәтте, Кәлимәтнең салкын сулы чишмәләрен, каен урманнарын, таң атуын, шәфәкъ батуларын күрсәтте. Шуларның хасиятен, сер-хикмәтләрен берәмтекләп, вәземләп аңлатып йөргән булды. Оныттым дигәч тә, ул чаклы каты бәгырьле булырга ярамый бит инде...

Менә бу чишмә ул белгәннән бирле ага. Улагын рәтләп, язгы ташкын сулары белән агып төшкән юшкыннарын тазартып-

күрәп җибәрсәң, ишәебрәк, тавышланыбрак ага. Кеше күңеле дә, әнә шул чишмә төсле, якын иткәнне, тәрбияләгәнне ярата. Әгәр аңа юшкын утырса, ай-һай, тиз генә тазартып булыр микән?

Арслангали оныгының бәләкәй чакта, менә шушы басмада кер бәләкләгәндә, таң кошы кебек чебердәп янында йөрүләрен, инде әнә шул дус вакытларга хыянәт иткәндәй, дәшми-тынмый калада ятуын уйлап, карчык тагын сагышка бирелде...

Көтү кайтты бугай инде: мал-туар авазлары тынды. Ерак басуда гына ниндидер машинаның туктаусыз гүләгәне ишетелә. Дөрес булса, җир астыннан май тапканнар, ди. Нифте мае, диме, керәчинме — белмәссең хәзергене. Үлмәсәң, әллә ниләр ишетерсең әле. Һәммәкәй төшне тишеп, җир мае суыртасылар, ди. Анысы тагын ниемә кирәк инде? Чишмә суларын былчыратып, үләннәрне корытып бетермәсәләр ярарые. Арслангали кайтмый. Онытты малай авылны. Әбисен гомер буе яшәр ди микән. Кеше гомере кичке шәфәкъ кебек: бер сүнә башласа, туктатып кала алмыйсың. Тик менә җеназаң, гүр газапларың авыр көнгә туры килмәсен ие. Кече атна көн гүр газаплары җиңел булыр, дигән. Атна ара көн белән чәршәмбе — гүр газаплары авыр буласы. Кәфенне кискәндә, сәдака-хәер бирергә тиешле. Ир-атны кәфен белән биш кат төрәләр. Хатын-кызны җиде кат бугай. Нигә җиде кат? Кәфен теккәндә, энә-җепнең тотылмаганы кирәк — арулык өчен. Хәзерге яшьләр белми инде аларны. Машина белән башлары әйләнгән. Ипи булып ипине урта бер җиреннән кисәләр. Уртасыннан киссәң, бәрәкәте очканны да аңламыйлар.

Йөзлекәй карчык, инде бик күп утырган булуын, Фәйрүзәсе эштән кайтса ачуланачагын уйлап, урыныннан тормакчы булды — аяклары буйсынмады. Тезләренә таянып, ыңгырашып күтәрелде, ләкин шундук гөрселдәп басма өстенә авып төште...

Шул көнне кич чишмәгә суга чыккан Фәйрүзә әбисенең хәрәкәтсез яткан гәүдәсе янына тезләнде. Кәлимәт кешеләре, ат җиткән җиргә ат җибәреп, ат җитмәгән җиргә телеграм сугып, Йөзлекәй карчыкның үлеме турында аның балаларына, балаларының балаларына хәбәр иттеләр. [...]

III

Шәвәлинекеләр кайчандыр Кәлимәтнең күренекле кешеләре иде. Түбәсе юкә кабыгыннан ябылган булса да, усак бүрәнәсе белән сөяннең тазасын сайлап, алты почмаклап салынган иркен йорт, урыс капкалы, ак мунчалы каралты-кура, өстәвенә агач бакчасында җете кызыл, ачык зәңгәр төсләре белән балкып утырган бер дистә умарта аларны Кәлимәтнең гадәти генә йортлары арасында иркен тормыш белән яшәүче хәлле кешеләр итеп күрсәтә, ә көндезләрен кояш җылысына күтәрелгән умарта

кортлары бала-чаганы капка-койма тирәсенә якын китерми, шуның белән бу йорт бераз серлерәк тә булып санала иде.

Вакыт җилләре Шәвәли абзаңның да каралты-курасына эзен салмый калмады. Алты почмаклы йортның түбәсе, урта бер җиреннән иңеп, дөя өркәченә охшап калды, капка баганалары кыегайды, ак мунча эшкә ярамый башлагач, карт аны узган ел көзен, кечерәйтеп, кара мунча итеп салды һәм шул көннән башлап күңелендәниндидер бер моңсулык, канәгатьсезлек урнашып калуын тоеп йөри башлады.

Ә бит заманында күпме көч салган иде ул аларга!

Көбәш йортыннан аерылып чыгып, үз куышын корып җибәргәнче, катлаулы заманнарның шактый борылмаларын узарга туры килде Шәвәлигә. Герман сугышында әсирлектә йөреп кайтканнан соң, ул утыз чакрымдагы авылдан, Печмән ягыннан, бөлгән бер мирзаның сазаган кызы Мәгыйшәне ябыштырып алды. Килен кешенең өшәнчеге кечкенә бер төенчеккә сыеп бетсә дә, бәясе юк-бар ястыкларыңны, кашага-чаршауларыңны әйләндереп салырлык иде. Хәситә-мәрҗән дисеңме, чулпы-беләзек дисеңме — барысы да алтын-көмештән, асылташтан булып, берәмтекләп сатканда да, кеше гомеренә җитәрлек иде.

Килен булып төшкәннең икенче көнендә үк Мәгыйшә амбар-келәт ачкычларын, баз-нәүрәпне үз кулына алырга теләде. Ләкин үз белдеге белән яшәргә күнеккән Йөзлекәй карчык нык иде әле, зиһенле иде. Хуҗалык тезгенен каяндыр килгән сипкел битле, нечкә сыйраклы җиде ят кулына бирергә теләмәде. Шул нигездә каенана белән килен арасында низаг чыгып, Шәвәли ике-өч айдан соң ук Зәй буеннан җир өлеше бүлеп алырга, үз казыгын үзе кага башларга мәҗбүр булды.

Хуҗалык эшенә җәптәш иде Шәвәли, җирнең кадерен белә торган ир иде. Зәй буендагы сазламыкны киптереп, бакча ясады, бакча түренә кое казыды. Көбәш йортыннан алып чыккан сукыр биянең колынын үстереп, йөрәк кагып йөри торган байтал җитештерде. Бар да җайга салынып килә иде. Шәвәлинең тимер келәшчә кебек таза бармаклары эләктергән әйберсен ычкындыра белми иде. Исәбе алга таба Мәгыйшәнең хәситә-мәрҗәннәрен дә хутка җибәрү иде. Ләкин аяк астыннан килеп чыккан бер бәла Шәвәлинең көйле тормышын чыгырыннан чыгарып ташлады.

Мәгыйшә Йөзлекәй карчыкның явызлыгын онытмаган иде. Баш-күз алып, тернәкләнеп киткәч, ул, иренә әйтмичә генә, каенанасыннан үч алырга уйлады. Кыз малы булган өшәнчеген, кеше яллап, Йөзлекәй карчыкларның печәнлегенә күмдерде дә авыл буйлап разбуй салды.

Пүнәтәйләр өй борынча йөреп, бөтен авылны тентеп чыктылар, ләкин берни дә таба алмадылар. Йөзлекәй карчык олы килененең явызлык эшләргә җыенуын шул ук әйберләрне

күмүчедән белгән, төнлә белән аларны дөрләп янган мичкә аткан, ә көлен җил иркенә сибеп җибәргән иде.

Мәгыйшә, өшәнчеге яшерелгән җиргә ятып:

— Менә шушында гына иде, шушы төштә генә иде ич! — дип, җир тырмашып елады. Һай, елау белән генә кайтарып булса икән ут авызына эләккән хәзинәне!

Шәвәли, нахак бәла белән каенанасын төрмәгә тыгарга теләп, кыйммәтле әйберләреннән колак каккан хатынын, ишекне бикләп, төне буе кыйнады. Ахмаклыгы, киңәшеп эш итмәве, бөтен авыл алдында хур итүе өчен кыйнады. Ләкин Шәвәли нигезенә салынган хурлыклы тамга алай тиз генә җуелмады, аны җую өчен, Шәвәлигә революциягә чаклы да, революциядән соң да кара тир түгеп эшләргә, авылдашларының ихтирамын казанырга туры килде: колхоз төзелгән елларны ул, беренчеләр рәтеннән колхозга кереп, келәте белән амбарын җәмәгать милкенә яздырды. Дөрес, соңыннан алар өчен хатыны Мәгыйшә аны ике-өч ел буена талады, ләкин бу хәл Шәвәли нигезенә салынган хурлыкны алып ташлауга сәбәп булды.

Ватан сугышы башланган елларны Шәвәли абзыйның яше солдат хезмәтеннән чыккан иде инде, ләкин әле ул нык иде, әтисе Көбәшләр ягыннан килә торган гайрәт бар иде аңарда. Бер үк вакытта амбарчы да, бригадир да булып, авылның ихтирамлы олы кешесе булып яшәде. Тормышы да көйсез түгел иде, балалар үсеп җиткәч кенә көйсезгә китте. Фәйрүзәсе белән Арслангалие ата нигезен үз итмәделәр. Быел унынчыны бетергән Мәрзиясе дә йортка бик күңел салмый. Телендә гел шәһәр. Төпчеге Габделхәй кайчан карама — кармак күтәреп су буенда. Йөрәкләре үлгән. Мүк баскан йөрәкләрен!

Сугыштан соңгы елларда арка-җилкәсе сызлаштырып, каты кара сакалы җитен сүсенә әйләнгәч, бер-бер артлы йортны ташлап чыккан балалары өчен, көн саен туза, җимерелә барган хуҗалыгы өчен борчылу, кайры корты кебек, йөрәген кимерә башлады.

Аның инде бөтен Кәлимәткә дан тоткан гайрәтле заманнары үтеп бара, ул инде әүвәлгечә җир җимертеп эшли алмый, эшли алмавы өчен үрсәләнә, өстәвенә авыл урамнарын тутырган машиналар, актарылып ташланган урам чирәме аның борчуларын арттырып җибәрә. Вакыт-вакыт аңарда, боларның барысына кул селтәп, агач күләгәсенә сузылу, гамьсез-ваемсыз яшәү теләге уяна, ләкин язлар җитеп, тау башлары тимгелләнгәч, кипшергән туфрак исе, абзарлардан чыккан дымлы тирес исе борыннарга бәрелгәч, бөтен гомерен буразна арасында, басуларда үткәргән бу кешенең йөрәге чабыш аты кебек ярсый башлый. Әмма шундый чакта хатыны, нәфесенә баш була алмыйча, юк кына мәшәкатьләре белән килеп тыгыла да, картның кәефен кырып, эштән күңелен биздереп куя иде.

Быел да шулай булды.

Иген басуларын урап, күңелләре кузгалып кайтканнан соң, шимбә көнне, кичкырын, Шәвәли абзыйның ачы бал татып карыйсы килде.

— Кая, бер чүмеч бал китер әле! — диде ул почмак якта былтыргы рамнарның күгәргән кәрәзен кырып утыручы хатынына.

— Нинди бал ул тагын: ни бәйрәм, ни Сабантуй!

— Әйдә, телеңә салынма. Янбашлары авыртып тора, сихәте булмасмы...

— Сихәте, сихәте...— Мәгыйшә түти, ирен үчекләп, черек умарта рамын мич буена ыргытты.— Көне буе эшсез аунагач, янбашларың түгел, әллә кай төшләрең авыртыр. Капка баганалары кыегайган. Төз лапасның өрлеге җимерелергә тора. Синең өчен мин кагар дип белдеңме? Балта-көрәк тотып бер селкенеп керсәң, эчең төшмәс иде.

Чүп өстенә чүмәлә булды бу сүзләр. Шәвәли абзыйның йөрәге усалланып, яңак сеңерләре бүртеп чыкты:

— Утыз ел буена каныма тоз салдың бит, тавык мие эчкән нәрсәкәй! Мин какмыйчы кем каккан аларны?! Кем?! Синең себер киткән этиең килеп каккан мәллә?!

Мәгыйшә түти иренең эчкә баткан күзләрендә хәтәр ут кабынуын күреп каушый калды.

— Туктале, этисе... чамалап. Нәрсә син шул тамаша...

Ләкин картны алай гына тыеп калырлык түгел иде инде. Фәйрүзәсенең йорттан чыгып китүен, Арсланг алиенең калага китеп олагуын, йортта калганнарының да бер тиен торгысыз, игелексез балалар булып үсеп килүен — барысын, барысын хатыныннан, хатынының комсызлыгыннан күреп, шуларның үчен берьюлы кайтарырга теләгәндәй, идәндә аунап яткан кәрәзле рамнарны тибеп очырды да, читлектән ычкынган арыслан кебек, бөтен өйне бер итеп йөри башлады; мич башында җылыда чыпырдап утырган бал мичкәсен, күтәреп, идәнгә тондырды.

Туптан аткан авазлар чыгарып, мичкә шартлауга, Мәгыйшә түти аңын җыярга да өлгермәде, тәрәзә пыялаларын зыңгырдатып, бөтен көченә ишек ябылды.

— Харап итте мичкәмне, котырган! Минем башыма җилкенә,— дип, Мәгыйшә түти күз яшен сыгып чыгарды, күңел кайтаргыч нечкә тавыш белән такмаклап елый-елый, идәнгә күл булып җәелгән балны җыештырырга керешге: — Балым бал гына түгел иде, колмак салып ясаган идем. Струйлек Гарапшага нәрсә эчертим инде, а-а-а... имән баганалыкны каян алыйм инде?.. Ветмәде бит башы да, сынмады бит муены да, кулларың корып каткыры!..

Такмаклап арыгач, колак салып урамны тыңлады. Урамда тавыш-мазар ишетелми, тик бал исен сизеп кергән умарта корты гына өй эчендә безелдәп йөри иде.

IV

Шәвәли абзый Көбәш йортына ярсып барып керде. Исәбе энисен хәзер үк үзләренә алдырту, тәрбия итү иде. Житте. Булды. Мәгыйшәнең толып жиңе чаклы бугазын туйдыру өчен бик күп кирәк.

Караңгы чоланда дөбердәтеп буш чиләкне аударып жибәрде. Күтәреп-нитеп тормады, ишекне этеп ачты:

— Өйдә кеше бармы?

Ярым караңгы өйнең почмак ягыннан, кулына сукыр лампа тотып, чәчләре тузгыган Фәйрүзә килеп чыкты. Керүченең йөзен ут белән яктыртып, күзләрен күтәрде:

— Кем йөри анда?

— Мин әле бу. Нигә фонарь куймыйсың? Чоланда башымны яра яздым,— диде Шәвәли абзый, кырыс кына. Ачык изүләре, тузгыган чәчләре белән каршысында басып торган Фәйрүзәгә жикерде: — Яп ул изүләреңне! Нәрсә монда! Атаң алдында зиначы катыннар кук басып торасың! Кем дип белдең син мине, ыштырбит?!

Күрәсең, Фәйрүзәнең аңына бу сүзләр дә барып житми — күзләрен киереп ачкан да йоммый-нитми басып тора.

Шәвәли абзый бу юлы үзе сагая калды:

— Нәрсә бар? Ник дәшмисең?

— Әби үлде ич...— диде Фәйрүзә, иңрәп чыккан хәлсез тавыш белән. Әйткән сүзләренең мәгънәсе үзенең дә аңына барып житте бугай, ачык изүен буш кулы белән ябып, сукыр лампасын баш очына күтәргән көе, киредән почмак якка кереп китте.

Шәвәли абзый баскан урынында катты да калды. Ярсуы да, хатынына булган ачуы да — барысы берьюлы башыннан чыгып киттеләр. Күрер-күрмәс күзләрен бер ноктага төбәп, энисенең үле гәүдәсенә таба кузгалды. Мәетнең йөзенә бөркәгән яулыкны күтәргәч, мәрхүмәнең кәфен япкандай агарып калган, ләкин мөлаемлыгын югалтмаган йөзенә карап, башын иеп, беравык сүзсез торды. Шул берничә генә секундка сузылган тынлык вакытында йөрәген үкенү тойгысы яндырып узды. Тәрбияли алмады. Дөнья малы житмәде. Мәгыйшәнең бугазын тыгындырырга күп кирәк булды. Инде менә хәзер ул, ятып еласа да, чәчләрен йолкыса да, энисен кире кайтара алмый. Юк ул, үлде ул, аңа хәзер берни кирәкми.

Яулыкны кире бөркәде. Гыжылдап чыккан ят тавыш белән әйтте:

— Туганнарга телеграм сугарга кирәк. Кәфенлеге бармы?

— Каян булсын. Үләргә жыенмый иде бит...

— Кыяфәтеңне рәтлә. Кеше күрер. Тансык кайда?

— Күршеләргә кертеп жибәрдем.

— Ылыс суың бармы?
— Каян булсын...
— Ислемай?
— Шкафта нәрсәдер бар бугай. Тансык тукмәгән булса...
— Җылы су әзерлә. Тотылмаган энә-җеп. Йә, нәрсә тәрәлеп каттың? Кәфенлек ягын үзем җайлармын.

Ләкин кәфенлек ягы, Шәвәли абзый уйлаганча, алай ансат кына җайлана торган нәрсә булып чыкмады. Икенче көнне иртән, төн йокысыз мәет саклап чыкканнан соң, керфек төпләре кызарган күзләрен күтәреп, Шәвәли абзый хатыны Мәгыйшәгә дәште:

— Синең теге ак бәзең ничә метр?
— Кайсы бәз? Сиңа ыштан теккән бәзне әйтәсеңме? Бетте ич инде ул.
— Әйдә, башыңны юләргә салма. Утыз метр бер ыштанга кереп бетми.
— Бетмәсә, әллә аны гел шул килеш тора дип беләсеңме? Синең эшсез йөргән балаларыңа бәз түгел, дуңгыз тиресе дә төтмәс. Үзең өйрәттең дә эшсезлеккә, трай тибәргә, инде мин гаепле...
— Житте, диләр, сиңа. Яп авызыңны! Кайда кәфенлек?

Мәгыйшә түти, сөйләвеннән кинәт туктап, юка иреннәрен кысты:

— Бирмим! — диде, катгый итеп.

Картның сабыры бетеп килә иде. Сакал баскан бит тиресе астында әрле-бирле кыймылдашкан яңак сеңерләренең хәрәкәтен басарга тырышып, ясалма сабырлык белән сорады:

— Кәфенлек кайда дим мин сиңа? Башың ике булмаса, китер!
— Бирмим! — диде Мәгыйшә түти, үҗәт бер ныклык белән кабатлап.— Нигә бирим мин аны? Ул минем кыз малымны утка атты. Ул минем кадерле әйберләремне яндырып көл итте...

Моннан утыз еллар элек булган хәлне тагын күз алдына китерде — күзенә яшь бәреп чыкты. Күпме хәзинә шул явыз карчык аркасында юкка чыкты. Хәзер аңа кәфенлек бирергәме? Аны үзеңнең ап-ак бәзеңә төреп күмәргәме? Тотсын менә!

Мәгыйшә түтинең бер тамчы күз яше кайнарланган битендә шундук кибеп бетте. Бәбәкләре корып, усалланып киттеләр. Бирер ул аңа кәфенлек, бирмәгән кая! Суык җиргә кәфенсез иңсен әнә. Хет аркасына мылтык тәрәсеннәр, хет кыйнап үтерсеннәр, ул җәһәннәм кисәвенә кәфенлек эләкмәс. Алсалар, аның үле гәүдәсе, мәете аркылы кереп алырлар!

Мәгыйшә түти хәзинә сандыгына ташланды. Ләкин иренең тимер гер кебек каты йодрыгы аны бер сугуда идәнгә дөмектерде...

...Арслан өйдә ачыргаланып кычкырган тавышны капкадан керүгә үк ишетте. Аңа һаман да бер үк күренеш кабатлана сыман тоелды. Ул өйгә ашыкты. Баскычтан йөгереп менде. Ачыргалану тавышы икенче мәртәбә ишетелде. Ишекне ачып җибәрүгә, аның

күз алдында шундый күренеш пәйда булды: әнисе, җан ачысы белән кычкырып, сандык йозагына асылынып тора. Әтисенең башыннан түбәтәе төшеп киткән, әнисенең баш өстенә күтәргән йодрыгын ул, менә сугам, менә сугам дип, әзер тотып тора. Авызыннан ниндидер гыжылдавык сүз кисәкләре атыла.

Арслан, бусага төбендә беравык басып торганнан соң, әкрен генә сорады:

— Нишлисез сез?

Шәвәли абзый, кан баскан күзләрен күтәреп, тавыш килгән якка карады. Кинәт эшне аңлап алып, йодрыгын кире төшерде һәм җәнҗалның мәгънәсен аңлатырга теләгәндәй сөйләнә башлады:

— Ояты да юк кешеләрнең, үлгәннәр белән булыша бит, ыштыр каплаган бит...

Кинәт күңеле тулып китте, йомшаклыгын улына күрсәтмәс өчен, ашыгып кире борылды.

Мәгыйшә түти, өстендә асылынып торган куркынычның бетүен аңлауга, ачы күз яшьләре белән сулкылдап елап җибәрде.

V

Кайгылы тынлыкта мәетне өйдән алып чыктылар. Алдан икәү бара: Арслан белән Фәйрүзә. Алар колашаны тыныч алып баралар. Артта икәү: Баязит белән Шәвәли. Баязит яланбаш, ак чәчен җил тузгыта; Шәвәли абзый бүрек кигән, бөкрәйгән; аякларын, ничектер, тотрыксыз китереп баса.

Баязитның хатыны Таһирә ханым — юаная башлаган врач-хирург һәм тагын Йөзлекәй карчыкның тирә-күрше авыллардан килгән өч кызы, авыл халкының борынгы йоласына ихтирам йөзеннән, капка төбендә калдылар: хатын-кызга зиратка керергә ярамый. Алар белән бергә Фәйрүзәнең җиде яшьлек улы Тансык та калды. Әбисенең гәүдәсен туфрак күмгәнне малай күрмәсен, йөрәге бозылыр, диделәр. Шуңа күрә хәзер ул алма апаларының әле берсе, әле икенчесе янына килә. Авыл буйлап кешеләрнең җилкә өстендә колашалы кабыкта баручы май әбисенә, колга башы тоткан кешеләргә моңаеп карый.

— Алма апай, май әбине күмәргә апкиттеләрмени?

— Күмәргә, бәбкәм...

VIII

Зәй буеның таптальп беткән шомырт куаклары янында басып торган чакта, Арслан кемнеңдер, чиләкләрен шалтыратып, суга килүен күрде. «Кем икән бу таң фәрештәсе?» — дип уйлап бетерергә дә өлгермәде, суга килүченең Мөнәвәрә икәнен танып алды. Йөрәге кинәт сикереп чыгардай булып тибәргә, дөпелдәргә тотынды. Эндәшергәме, тавыш-тынсыз гына китеп барыргамы?

Аның шундый якын булуыннан, юаш киектәй, сакланып кына суга керүеннән рәхәт бер каушау белән, телсез калып басып торганда, Мөнәвәрә аны үзе күрде. Күрде һәм, аучыга юлыккан болан кебек, дерт итеп сискәнде — качып китте. Арслан аның ялангач табаннары җемелдәшүен, кулына тоткан косынкасының җилфердәп баруын, толымнарының атынгалап җилкәсенә бәрелүен төштә күргән кебек кенә хәтерләп калды. Иртәнге тыныч су өстендә ул калдырып киткән дулкыннарга сүзсез генә карап торды.

Аннары кайту юлына борылды. Уйланып кайта торгач, яңа Кәлимәткә — төзелеп ята торган нефтьчеләр шәһәренә килеп чыгуын күреп аптырап китте. Монда яссы табанлы ике трактор, аллы-артлы йөреп, урамга асфальт җәя; киндер алъяпкычлы хатын-кызлар, беләкләрен сызганып җибәреп, носилка белән сумала ташыйлар, алар түшәп киткән сумала, җылы пар бөркеп, әкрен генә суынып ята иде. Нәкъ әнә шул урында Арслан, көтелмәгән бер хәлгә тап булып, ихтыярсыз туктап калды.

Асфальт җәйгән төшкә бер көтү малай җыелган. Арада берсе, иң кечкенәсе, батыраеп, асфальт эченә үк кереп киткән, ләкин урамны аркылы чыгып җитә алмаган, асфальт өстенә агызган куе сумалага аяклары ябышып, урта бер җирдә торып калган. Ул кызганыч кыяфәт белән әле асфальт җәючеләргә, әле малайлар ягына таба күз сала. Тик аңа берәү дә ярдәм итми. Асфальт җәюче хатыннар аны күрми, ә малайларның кызык ясыйсылары килә, аңардан кычкырып көләләр иде.

Арслан сумала өстеннән урам ярып эчкә кереп китте дә малайны, култыгына кыстырып, бер читкә алып чыкты. Үзенең дә ботинка табаннарына күп булып сумала ябышты. Ул аны озаклап чирәмгә ышкыды, җиргә ышкыды, ләкин сумала бетмәде, киресенчә, туфрак белән оешып, тагын да калынайды, авырайды.

— Йә туганкай, нишләтәбез инде моны? — диде, малайга карап.

Бәладән котылган малай, башын аска иеп, аягына карап торды, аяк бармагы белән җиргә сызыклар сызгалады. Аннары башын күтәреп, зур кара күзләре белән Арсланга төбәлде: белмим шул, абый, син үзең уйлап тап инде, булмаса!

— Өең еракмы соң синең?

— Өй елак.

— Кем соң син?

— Әнвәл.

— Кем малае?

— Кәлим малае.

Арсланның күңелен коточкыч бер сизенү яндырып узды.

— Әниең ни исемле? — дип сорады ул, ашыгып.

— Мөнәвәлә,— диде Әнвәр, шуны да белмисеңмени дигән сыман, кашларын җыерып карады.

Арсланны алмаштырып куйдылармыни! Ул, йотылып, малайның күзләренә карады, чыраенда, күзләрендә Мөнәвәрә чалымнарын тапты, тик аның борыны гына әтисенекенә охшаган, карчыга борын иде. Арслан кисәк кенә иелде, малайны култыгына көрәп алды һәм якындагы тыкрыктан борылып күздән югалды. Үзләренең ишегалдына кайтып җиткәч кенә, инде шыңшый башлаган малайны җиргә төшерде, битләреннән, күзләреннән үбәргә тотынды. Бернәрсә аңламаган малай башта куркып калды, соңыннан, сабыйларча беркатлы ышану белән, аның ихтыярына буйсынды — Арсланның муеныннан чытырдатып кочаклады...

...Мөнәвәрә, «дәү абыкай» озак кайтмый торгач, Миләүшәсен күтәреп, урамга чыкты. Әнвәр уйный торган бура эчләрен, тыкрыкларны, күрше-колан ишегалларын карап бетерде. Бала-чагадан, Әнвәрнең иптәшләреннән сорашты. Берәү дә малайны күрмәгән, берәү дә аның белән уйнамаган булып чыкты.

Мөнәвәрә борчыла башлады.

Урамнарда бик күбәйгән машиналар турында, казылып ташланган чокырлар турында, тапталып үлгән малайлар турында уйлагач, йөрәге жу итте. Аек уйдан, сабыр итеп уйлый алудан мәхрүм калып, анда сугылды, монда сугылды, кызын күтәргән көйгә, урамнар буйлап йөрде. Юк, малай суга төшкән күк югалды. Еларга җитешеп, исән-сау кайтса, ялгызын гына беркая да чыгармас идем дип, унынчы тапкыр тәүбә итте. Ашыкты, кабаланды. Чаба торгач, коточкыч арыганын сизде. Болай булмый. Миләүшәне күтәреп йөрерлек хәле калмады, әниләренә илтеп куярга кирәк тә милиция идарәсенә барып карарга кирәк.

Әниләренә барышлый Көбәш Шәвәлиләре капкасы яныннан узарга кирәк иде. Ничектер, үзеннән-үзе ачык капкага күзе төште. Тез буыннары хәлсезләнеп китте, күзенә яшь килеп тыгылды: аның улы, аның Әнвәре, дөньясын онытып, Арслан белән таш тәти уйнап утыра!

Мөнәвәрә бер мизгел, капка баганасына сөялгән килеш, сүзен әйтә алмый торды. Бу өнсезлектән аны Миләүшә чыгарды. Ул абыйсын танып кычкырып җибәрде. Миләүшә тавышына Арслан белән Әнвәр икесе берьюлы борылып карадылар. Әнвәр, күлмәк итәгеннән таш тәтиләрен коя-коя, әнисе каршысына йөгереп килде.

— Әни, бу Алслан абый... Без аякны сабын белән юдык. Келосин белән дә юдык. Әни, мин Алслан абый белән дус булам, яме, әни?..

Арслан, чирәм өстеннән күтәрелеп, чалбарыннан үлән чүпләрен кагып төшерде. Үзенең яланаяк булуыннан, кулында вак

ташлар булудан, өстәвенә Әнвәрнең тузга язмаган сүзләр әйтеп ташлавыннан уңайсызланып, тораеп басты.

— Исәнме... Мөнәвәрә...

— Исәнме, Арслан...

Һәм икесе тиң сүзсез калдылар...

IX

Шәвәлинекеләр кич белән табын янына җыелды.

Өстәлнең түрендә — этиләре. Аның күршесендә — Фәйрүзә. Бире табарак керле кулын өстәл артына яшергән Габделхәй кыбырсый. Кояшта кубалакланып беткән борынын әледән-әле шыштырдатып тарткалап куя ул, апасы Мәрзия аңа таба ачуланып карап алган чакта, үчекләп, телен чыгарып күрсәтә.

Мәрзия тәти абыйсыннан күзләрен алмый. Арсланның үзен иркен тотуы да, олысымак сабырлыгы да — барысы да ошый аңа. Ул менә хәзер дә аның кебек, кулларын иягенә таянып, бер ноктага карап утыра. Гел шулай сабыр гына утырыр иде дә, Габделхәй тынгылык бирми аңа, үртәшә. Кеше-кара күрмәгәндә, Мәрзия аңа йодрык селки дә, иягенә таянып, тагын тын кала. Арслан, сеңлесенә күз төшергәч, аның шундый сабыр булырга тырышып та, сабыр була алмавыннан ирен чите белән генә көлемсерәп тә куйды.

Мәгыйшә түти табын уртасына алюминий табак белән итле токмач китереп утыртты. Иреннәрен кыймылдатып, уң кулы белән табакның читен сыпырып чыкты. Иренең күзен акайтып бер карап алуын сизенеп (каян килде әле сиңа шундый диндарлык?!), тәлинкәләргә тизрәк аш бүләргә кереште. Ләммим бер сүз әйтмәде. Сүз әйтәсе кеше бүген — Шәвәли абзый. Бу көнне ул озак көтте. Зарыгып көтте. Гаилә дилбегәсен бүген кулга нык итеп чорнап тотарга да җибәрмәскә кирәк. Җитте, моңарчы да йомшаклык күрсәтте, балаларны үз ирекләрендә күп йөртте.

— Ягез, җитешегез! — дип, сүзне боерык рәвешендә бик коры башлап җибәрде ул һәм, бу корылыкның ничегрәк тәэсир итүен белү өчен, Арсланга күтәрелеп карады. Арслан гүя аның сүзен ишетми, өстәл астына иелеп, нәрсәдер алып маташа иде. Бер-ике кашык аш кабып куйгач, Шәвәли абзый ризыкның кадерен белү турында, тәүфыйклы һәм йорт җанлы булу турында озаклап сөйләмәкче булып авызын ачкан иде, Арслан аны ярты сүздә бүлдерде:

— Эти,— диде,— әгәр син каршы килмәсәң, мин бер «ярты»ны алган идем. Очрашмаганга да күптән. Кайгылы да көннәр. Дөрес, безнең семьяда олылар белән бергә эчеп утыру гадәте юк инде югын... күп эчик дип әйтмим, хәсрәтләрне онытыр өчен, стакан төбенә генә салып бирәрне тотыйкчы.

Шәвәли абзый, куе сакал-мыегы эченә күмелгән ираннәрен ачмыйча гына, сузып кына бер тамак кырып алды. Гаилә дилбегәсенә малайның беренче булып үрелүе ошап җитми иде картка. Шулай да кире сүз әйтергә базмады — әнә шул тамак кырудан аңларлар, дип уйлады. Габделхәй пырхылдап җибәрергә җыенган Мәрзиянең, өстәл астына иелеп, ботын чеметте. Ә тегесе, кыланалар бит, карале, тәти абый, дигәндәй, Арсланга күзләрен мөлдерәтеп бер карап алды.

Арслан эшнең җүнлегә таба бармаячагын шундук сизде. Стакан тутырып әтисенә салды, үзенә салды һәм, әтисе белән тартышыр чамасы зур икәнне күрсәтергә теләгәндәй, аракыны бер күтәрүдә сүзсез-нисез тамак төбенә койды — чыраен да сытмады. Шәвәли абзый биниһая бер гаҗәпләнү белән улына карады: керфек төпләрен кымырҗытып, яшьлеге исенә төште, шуннан соң инде кыланып та, тәкъваланып тә утырырга теләмәде, Арслан күтәргән җитезлек белән стаканны авызына китерде, шундый ук җитезлек белән аударды, ләкин азагын Арслан кебек матур очлый алмады, тончыкты — мылтык аткандай каты, коры тавыш белән, тамак төбен ярып йөткерергә тотынды.

Мәгыйшә түти, кулына майлы калҗа тотып, аның тирәсендә чабалана башлады.

— Ялгыш юлдан китте, каһәр! — дип, Шәвәли карт юаш кына сукранды, күзеннән бәреп чыккан яшь бөртеген кара тырнаклы калҗайган бармаклары белән яңагына сылап куйды.

Ул көтмәгәндә исереп китте. Ризыкка кагылмас булды. Тирәсендә майлы калҗа күтәреп чабулап йөргән Мәгыйшә түтигә, чебенне куып җибәргәндәй, кул гына селтәде.

Карт киң күңелле иде бүген. Балаларына акыл өйрәтү турында, үгетләү турында ул уйлап та карамады. Куе сакал-мыегы эченнән елмаеп, ниндидер ягымлы сүзләр әйтеп утырды, хәтта бер мәртәбә, күңеле артык нечкәреп, Габделхәенең башыннан да сыйпап алды.

Әйе. Хәзер ул — почётлы урында. Хөрмәтле атага тиешле урында. Әйтеп карасыннар Шәвәлинең балалары әтиләрен ихтирам итми дип. Шушы түгелмени ихтирам, шушы түгелмени зурлау?! Арсланга күз төшерде. «Кайсы кылны чиертергә белә бу хитри!» — дип уйлады. Күз карашын Фәйрүзәгә күчерде. Шомырт кара ике күз аны яндырып алды. «Нигә шулай усал итеп карый инде? Белми, белми бит ул минем дә йөрәктән кан тамганын...» Күзенә мөлдерәп яшь килде. Иренен әчке яктан тешләп, күңеле җебеп китүен берсенә дә күрсәтмәс өчен, сүзсез утырды, балалары моны сизделәр, аптырашып тын калдылар.

— Замана хәзер яшьләрнеке! — дип, көрсенеп, сүз башлады Шәвәли абзый.— Без үләсе, яшьләргә каласы дөнья. Гомергомергә шулай килгән. Әти мәрхүм әйтә торган иде, хәзинә бик

дәү таш астында ятар, аны күтәрер өчен, бик күп тир түгәргә кирәк булыр, ләкин күп тир түгеп кенә дә берни кырып булмас, дияр иде. Әмәлен белеп, хәйлә белән эшләргә кирәк, ул чагында барып чыга инде, барып та чыга, бәреп тә ега, ди торган иде. Көч куймадым, тир түкмәдем, дип зарланыр хәлем юк. Көч куйдым, ташның авырын күтәрдем. Әмма ләкин хәзинәне таба алмадым. Ни өчен дип әйткәндә, хәйләсен белә алмадым. Менә хәзерге заман яшьләре аның хәйләсен дә белделәр, ташын күтәреп, хәзинәсен дә чыгара башладылар. Әйе. Шулай. Замана яшьләрнеке. Тик менә минем күңелемне бер сорау галәмәте, һич кенә дә тынгы бирмичә, кыймылдап тора. Син менә, Арслангали, укыган кеше инде, улым. Заводта да байтак еллардан бирле эшлисең. Пролетар сыйныфы булдың дигән сүз, димәкки. Сиңа ялган, миңа чын дигәндәй, әйтеп кара әле син менә миңа: ул хәзинә, ягъни мәсәлән, безгә нәрсә бирәчәк соң?

Шәвәли карт бик зур игътибар белән, тормыш бөтенләе белән шуңа гына бәйләнеп торгандай итеп, Арсланга төбәлде, Мәрзиягә нәрсәдер пышылдап маташкан Габделхәенә кычкырып алды.

Арслан тиз генә җавап бирмәде. Тиз генә җавап бирерлек сорау түгел иде бу. Беренче карашка, бик тә гади иде ул, авыл кешеләренә хас турылык белән маңгайга төрәп куелган иде. Арслан әтисенең хәзер аңардан үзенең тормыш мәгънәсен хәл итә торган җавап көтеп торуын аңлады.

— Нефть безгә, әти, күп нәрсә бирәчәк. Бу якларда моңарчы шәһәр булмады. Хәзер булачак. Гудронизированный юллар салыначак...

— Юк. Аларын әйтмә син миңа. Авылны бетерәләр инде — беләм. Бетерергә тотынгач, бер эш тә эшләр хәлең юк...

— Безнең якларда, әти, Татарстанның үз нефтьчеләре булачак.

— Анысына да ышанам. Мазутлы кожанның чуты юк хәзер. Тагын?..

Арслан уйга калды. Әтисе соң нәрсәне белергә тели? Өемнән китәргә мәҗбүр итәрләр дип шүрлиме икән әллә? Аның уе, һәрхәлдә, әнә шул тирәдә булырга тиеш. Шул турыда уңай җавап алмый торып, аның җаны тынычланмаячак.

— Сине нәрсә борчый соң, әти? Шуны яшермичә әйтсәң, мин сиңа теләгәнеңне әйтеп бирермен.

— Ярый. Бик шәп. Кәлимәт авылы бетәме?

— Бетми.

— Ни өчен?

— Бездә әле, хезмәт кешеләрен торак белән тәэмин итү өчен, кимендә егерме ел вакыт кирәк. Әгәр Кәлимәт кебек җиде-сигез йөз йортлы борынгы авылны бетереп ташласаң, сигез

йөз семьяга сыеныр почмак каян табасың? Өстәвенә шуны ук кешеләр, Кәлимәт кешеләре, промыселларда эшләп яталар бит. «Авыл үзгәрәме?» — дип сорасаң, минә анысы дөрес, авыл үзгәрә. Авылга газ керә, ут керә, су керә. Авылга культура килә.

— Уты белән суы керсә дә, әйбер әйтмим. Газы кирәкмәс, Арслангали! — дип, бик кискен рәвештә каршы төште Мәгыйшә түти.— Шартлый дип сөйлиләр аны. Мордар үлем белән үләсе килми бит.

— Белгән кеше кебек сөйләп утыра бит бу да! — дип, хатынының сүзен мыскыллап бүлдерде Шәвәли абзый.— Синең ише корткаларны шартлатырга ишалуны белән кирәк ул газ. Бүген ул тамашаны каян аласың, ди, әле аны... Яшермичә генә тагын бер сорауга җавап бир әле, Арслангали: минем, мәсәлән, бәрәңге бакчамны алалармы, юкмы?

— Ә нигә алсыннар аны? — диде Арслан, гаҗәпләнеп.

— Ә вышка куярга урын кирәк булса?

— Вышка куярга кирәк булса, бакчаң өчен акча түләрләр, акча алмыйм, дисәң, башка урыннан бирерләр.

Карт күзгә күренеп яшәрде, алга сөрлекте.

Иртәгесен Арслан китәргә җыенды. Аның рөхсәт срогы тулган иде. Габделхәй белән Мәрзия өйдә юк иде. Әнкәсе Арсланга, юл күчтәнәче итеп, бер кадак бал төрә башлады. Шәвәли карт аның төргәген кире суттерде дә хатынына гыжылдап әйтте:

— Нәрсә төрәсең син, кортка? Кушманда балың беткәнмени синең? Оятың качып бетмәгән булса, хәзер алып ташла бу күгәргән кәрәзләреңне. Башламаган рам төреп тык, дүрт килолысын. Ишеттеңме? Ишетсәң, менә шул, син биздереп бетердең балаларны!..

...Автовокзалда машина менә-менә китәм дип торганда, тыны-көне бетеп, Мәрзия йөгереп килде. Чәчләре чуалган, косынкасын кулына тоткан иде. Бите алсуланып тирләп чыккан иде.

— Тәти абый, җаным! Ал әле мине дә үзең белән. Тормыйм мин ул йортта. Әйткән иде дип әйтерсең, тормыйм!

Арслан игътибар белән аның күзләренә карады. Бу юаш кызыйның да тамырларында Көбәш нәселеннән килә торган ярсу кан кабынганлыкны күрде.

Сеңлесенең тузгыган чәчләрен рәтләде, иң якын туганлык хисе белән маңгаеннан үпте.

— Кайгырма, сеңлем. Тиздән мин үзем кайтам.

— Чынмы?

— Чын.

Автобус кузгалгач, Арслан сеңлесенең яулык болгап калуын чаттан борылганчы карап барды...

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

III

Юлга чыгуларына ике тәүлек тулганда, Кәлимәткә килеп җиттеләр. Лотфулла абзыйның йорт кирәк-яракларын Куйбышевның ике йөк машинасы, гаиләсен егерме кеше сыешлы автобусы китерә килде. Лотфулла абзый үзе, трестны борчымыйм дип, машина-мазар сорамаган иде. Күчкәндә, поезд белән күчербез, әйберләрне контейнер белән Бөгелмәгә җибәрермен дип йөри иде. Аның кайгысын Дорогомилов кайтырткан икән. Шул турыда автобус шофёрыннан сорашып белгәннән соң, Лотфулла абзыйның кабат күңеле нечкәреп, кордашыннан аерылу сагышын Тәүфика җиңги белән уртаклашмакчы булган иде, ләкин карчыгы сөйләшергә дә теләмәде. Ул ике тәүлек буена керфек тә какмаган иде: юл мәҗараларыннан бик тәэсирләнгән балаларының тамакларына начар ашаганына борчылып, авырып китмәгәйләре дип куркып утыра иде.

Машиналар Кәлимәткә килеп җитеп, барак тибындагы озынча бер бина алдында туктагач, Лотфулла абзый, җиңел сулап, автобустан төште. Кожаныннан юл тузаннарын кага-кага, ашыгып кына болдырга таба юнәлде дә бинаның түбәсенә беркетелгән зур гына тимер вышка макетына күзе төшеп туктап калды. Кулларын каш өстенә куеп, беравык әнә шул макетка карап торганнан соң, болдырдан күтәрелде, ишекнең ике ягына стенага беркетелгән кара пыялада көмеш хәрефләр белән эре итеп:

«Кәлимәтбурнефть» тресты

дип язылган сүзләрне укыды.

Трестта аның килүен беләләр икән. Болдырга, ашыгып кына, ике кеше чыкты. Чыгучыларның берсе озын буйлы, кырыс чырайлы, илле яшьләр тирәсендә иде. Көн шактый ук бөркү булуга карамастан, аның өстендә тулы форма: һәйбәтләп үтүкләнгән көрән костюм, кер-мазар кунмаган чытыр ак күлмәк һәм бик пөхтәләп, җиренә җиткереп бәйләгән кара галстук иде. Беләгенә плащ салган иде ул.

Лотфулла абзыйны беренче булып ул каршылады. Кара төк баскан дәү кулын мастерга сузып:

— Таныш булыйк. Трест управляющие Кожанов,— диде. Лотфулла абзый аңа үзенең кем икәнен әйткәч, управляющийның соры үткен күзләрендә бер генә секундка ягымлы җылы нур кабынды, ләкин ул бик озакка бармады. Кожанов, үзе белән чыккан икенче кешегә таба борылып, әүвәлге төсле үк җитди-кырыс чырай белән, әмер итү тонында әйтте:

— Митрофан Панасович, иптәш Дияровны сезнең карамакка тапшырам. Танышыгыз, сөйләшегез, урнаштырыгыз. Шул

турыда миңа иртәгә махсус хәбәр итәрсез.— Лотфулла абзыйга таба борылды, сизелер-сизелмәс кенә баш иде.— Гафу итегез, иптәш Дияров, киңәшмәгә ашыгам. Сезнең белән тагын бер иркенләп сөйләшербез. Хәзергә хушыгыз! — Беләгенә салган плащын өстенә киде, трест бинасы буенда гөрелдәп утырган «Вездеход» машинасына кереп, ишеген шап итеп япты. Машина, үзе артыннан сарымсак исле әчкелтем зәңгәр төтен бөркеп, үзе күтәргән тузан эчендә күздән югалды.

Лотфулла абзый, управляющий киткән якка карап: «Монысының талканы бик коры күренә»,— дип уйлап бетерергә өлгермәде, управляющий аның карамагына калдырып киткән кеше, болдырдан килеп чыгучыларның икенчесе, холкы белән Кожановның капма-каршысы булып чыкты. Өстендә аның бернинди рәсми кием түгел, ул, гади генә итеп, чигүле ак күлмәк өстеннән билбау тагып куйган, әнә шул ефәк билбау аның тәбәнәк йомры гәүдәсен, таралып китмәсен өчен, урта бер җиреннән юри кыршаулап куйган сыман тоела иде. Сүзгә дә ул управляющийга караганда юмартрак икән. Кожанов үзенә йомыш кушу белән, кечкенә йомры гәүдәсен резин туп урынына атындырып, Лотфулла абзый янына килеп тә җитте:

— Мастер иптәш Дияровмы? Куйбышевтанмы? Бик шәп! Бик вакытлы! Без хәзер сезне урнаштыру ягын карарбыз. Семья яклары ничегрәк сезнең?..— дип, өзлексез сөйләнә-сөйләнә, каты коры кулын Лотфулла абзыйга сузды. Нык кына селкеп торды. Сөйләвеннән бер генә минутка да туктамыйча, автобус ишеген барып ачты. Ишек буена өелгән төрле калибрдагы алтыҗиде баланы күрүгә, артына чүгеп куйды: — Болар бар да сезнең беләнме?! Ничә семья монда?

— Бар да минем белән. Бер семья,— диде Лотфулла абзый, тыныч кына.— Арыдылар. Талчыктылар. Кайдадыр урнашып, ял итеп аласы иде бит... иптәш кем, сезне кем дип дәшим соң?

— Сез миңа контор директоры Митрофан Зозуля дип дәшерсез. Хәтерли алмасагыз, мәгънәсен дә әйтеп бирәм: Зозуля — украинча кәккүк дигән сүз. Ягъни кеше гомерен санаучы яз кошы. Нәкъ шул үзе. Инде квартир мәсьәләсенә килгәндә, бездә ул як йөз процент көйләнеп җитмәгән. Кыенрак. Шулай да без сезгә, җирле Советлар белән килешеп, бер буш йорт табып куйдык. Дөрес, ул комфорт түгел. Эшләп бетерәсе вак-төяк эше бар. Анысы әллә ни зур кайгы түгел. Безнең хлопецлар батыр. Күрми дә калырсыз — айт-два! — ремонтлап та куярлар. Ремонтлап та куйган булыр идек, әле кичә генә таптык. Халыкның күбесе авылларда яши. Моңарчы палатка корып та яшәгән чак булды. Ну, ничаһо, кайгырмагыз, җайланыр, шунда беррәттән булачак бригадагыз белән дә танышып алырсыз...

Зозуля, татар колагына сәеррәк ишетелә торган йомшак һәм көйле украин акценты белән, сүз энҗеләрен туктаусыз сибеп тора иде. Лотфулла абзый ихтыярсыз: «Вәйт сөйли адәм, ничек теле арымый»,— дип уйлап куйды.

Митрофан Зозуляның сүзе артыгы белән расланды. Яңа килүчеләр сыенырга тиешле почмак — байтак еллар буена кешесез торган иске йорт — Лотфулла абзыйларны караңгы чырай белән каршылады. Аның тәрәзәләренә аркылы такта кадакланган, ишеге кыегаеп, бер күгәнендә генә асылынып тора, идән сайгаклары булган урында кара җир дымлы күгәрек исләрен аңкыта иде. Үзләренең йортларын ихлас күңелдән яраткан миһербанлы бәндәләр, күрәсең, рөхсәт-мазар сорамыйча гына, аның идән сайгакларын ташып бетергәннәр.

Тәүфика җиңги, озак еллар тик торудан кеше җылысы качкан буш каралты эченә килеп кергәч, дымлы күгәрек искә бөтен гәүдәсе белән калтыранып, ишек төбендә туктап калды. Куйбышевтагы өч бүлмәле якты квартирның барлык уңайлыкларыннан соң ишле балалар белән монда килеп керү җәһәннәмгә керү белән бер иде аңа. Ләм-мим сүз дәшмәстән, ул иренә күтәрелеп карады. Әмма иренең кысыла төшкән күзләрендә, тетрәнгән иреннәрендә тирән бер әрнешү, сүз белән әйтеп бирә алмастай газап барлыгын күреп аптырап калды.

Лотфулла абзыйның әрнешүе менә нәрсәдән иде.

Кәлимәтнең яңа өлешендәге чүлмәк түбәле фин йортлары, озын такта бараклары һәм тирә-ягына коры кызыл балчык өелгән тирән-тирән траншеялары һәм әрдәнәләп өелгән соры таш таулары яныннан өч машина бер-бер артлы сакланып кына үткән чакта, ул моннан егерме биш еллар элек үзе белгән Кәлимәтне танымады. Юк, монда элекке Кәлимәтнең бернәрсәсе дә юк, бөтенесе яңа, бөтенесе башкача иде. Башкача булганга күрә, ул аны дулкынландырмый да, күңелен дә кузгатмый иде. Мондый төзелешләрне азмы күрде ул ил буйлап йөргәндә. Урам саен чокыр, чат саен цемент ящигы, кая карама — төзелеш чүбе, өем-өем йомычка, өем-өем ватык кирпеч. Урамнардагы тәртипсезлек әле күптән түгел генә башка чыккан һәм җиң сызганып үз хуҗалыгын корырга керешкән яшь хуҗаның бинихая зур ишегалдын хәтерләтә иде. Андый чакта, үзеннән-үзе билгеле, төзелеш чүбенә игътибар ителми, тизрәк йортны җиткезәсе, тизрәк яңгырлардан, суык җилләрдән ышыкланасы килә. Ә чүп ул — нәрсә! Аны көрәп ташлавы берни түгел. Һәм, чыннан да, әнә шундый чүп-чарлы ике урамны узуга, машиналар асфальтлы киң проспектка килеп чыктылар. Лотфулла абзый урамны шундук таныды: бу иске Кәлимәтнең үзәк урамы ич. Карале, ничек матур итеп бизәгәннәр аны. Элегрәк аның матурлыгы чокыр-чакырлы булганга гына сизелмәгән икән ләбаса. Асфальт җәеп җибәргәч,

кыл кебек тураеп калган ич бу. Олы урамдагы иркенлеккә, чисталыкка сөенергә өлгермәде, аның йөрәген рәхәт-рәхәт авырттырып, иске Кәлимәтнең тар урамнары, ул аунап үскән тыкрыклары башланды. Бу Кәлимәтне бер дә үзгәртмәгәннәр. Әйтерсең, нефть шәһәре белән чагыштырып карау өчен, юри шулай калдырганнар. Салам түбәле, кабык түбәле Кәлимәт. Тукта, чү! Кайчандыр ул яшәгән аулак почмакка — Көбәшләр тыкрыгына борылалар түгелме? Шунда бит. Шунда лабаса! Йә Хода, никадәрле истәлек! Тукта, бу ни бу: алар өе турындагы йөзьяшәр өянке кая киткән? Ә бу күрше йорт кемнеке? Бу соң Көбәш Шәвәлиләре түгелме?

Машиналар, Шәвәли йортын узып, тәрәзәләренә такта кадакланган йорт алдына килеп туктагач, Лотфулла абзыйның дулкынланудан йөрәге кысылды. Ул туып үскән йорт иде бу. Үзе югында, үзе ил кайгысын кайгыртып йөргән чакта, аның атабабасы нигезен менә нинди хәлгә китергәннәр.

Ир белән хатын, бер-берсенә күтәрелеп карарга кыймыйча, буш йортның бусага төбендә сүзсез генә басып торган чакта, йомры гәүдәсен туп урынына тәгәрәтеп, Митрофан Зозуля тагын килеп җитте:

— Әйттем бит, бераз гына ремонтлыйсы бар моны: пыяла куясы, морҗа чыгарасы, идән җәясе. Ничаһо! Безнең хлопецлар батыр: ялт ремонтлап куябыз аны. Күрми дә калырсыз. Әгәр ошамый икән — баракка. Мин баракка киңәш итмәс идем: анда тыгыз, анда тавыш күп. Үз җаегызга карагыз. Баракка дисез икән — баракка!

Лотфулла абзый, йорт стеналарына төбәлгән хәлдә, кискен итеп:

— Мин беркая да китмим! — диде һәм, тешен кысып, йорт тирәсен әйләнеп чыкты.

Тәүфика җиңги, иренең усалланып киткән күзләрен, тетрәнүче мыек чылгыйларын күреп, тизрәк автобуска менеп чүмәшүне кулайрак күрде. Ә директор аларны, шофёрга аңлатып, якындагы ашханәгә озатып җибәрде. Йөк машиналарының шофёрлары да, автобуска утырып, тамак ялгап алырга киттеләр.

Алабута баскан ишегалдының урта бер җиренә туктап, Лотфулла абзый тәмәке кабызды. «Куйбышев машиналарын кайтарып җибәрергә кирәк. Кеше кайгысы кештәктә. Синең җимерек йортыңны саклап утыра алмаслар»,— дип уйлады.

Уңайсызланып һәм аптырап калган Зозуля, аның каршысына басып:

— Хәзер бригада килеп җитә. Без аны рәтлибез!..— дип, гадәтенчә тагын җиңел генә сүз башлаган иде, Лотфулла абзый аны:

— Кайдан сез, иптәш? Туган якларыгыз кайсы яклар? — дип, ярты сүздән бүлдерде.

— Минем туган яклар? Украина. Хатыным белән ике балам Киевта калды, Крещатикта. Чәчәкле яклар безнең, гөлгә бай яклар...

— Теләп килдегезме, көчләп җибәрделәрме?

— Көчләп, дип... Партия кушкан эштән ничек баш тартасың? Татар хлопецларын нефть эшенә өйрәтергә кирәк бит.

— Утырыгыз, нигә басып торасыз?

Зозуля, кая утырсам чалбарымны буярмын икән дигәндәй, тиз генә тирә-ягына карангалап алды. Аннары, кесәсеннән кулъяулыгы чыгарып, шуны җиргә җәйде дә, алабута сабакларын сындыргалап, яулыгы өстенә утырды.

— Ала-аай...— дип сузып куйды Лотфулла абзый, ул утыргач.— Туган яклар чәчәкле дисез, алайса. Ә менә мин шушы авылныкы.

— Шушы авылныкы?

— Әйе. Бу йортта минем яшьлегем үткән...

Зозуля, ничектер, уңайсызланып, җилкәләрен җыерып, тапландык йортка таба тагын бер мәртәбә күз төшереп алды да бораулау остасының хәленә кереп сорады:

— Киткәнеңә күптән идемени соң? Хат-хәбәр алмадыңмыни?

— Киткәнемә, туган, егерме биш ел. Хат алмаганыма ун ел. Әти, мин киткәч, гүр иясе булды. Монда минем туганнан туган энекәш калган иде. Киев тирәсендәме, Харьковны саклагандамы үлеп калды. Читтә булгач, үз нигезеңне кайтып карамагач, аларның үлеме дә ул чаклы ук сизелми иде. Йөрәк ярасына кагылды бу йорт. Изде бу йорт мине...

Лотфулла абзый авыр көрсенеп тынды. Күп сүзле Митрофан Зозуля да, чит кеше кайгысына ихтирам йөзеннән, бу юлы дәшмәде. Алар шулай, һәрберсе үз уйларына бирелеп, сүнгән папиросларын кулларында тоткан хәлдә, байтак вакыт сүзсез утырдылар.

Җәйге озын көн инде сүнеп бара, Шәвәли йортының кара күләгәсе, дәү бер кул булып, ишегалдына үрелә башлаган, кичке талгын җил алабута башларын кыймылдатып, йорт эргәләрендә ыңгырашып йөри иде.

Нурихан Фәттах
(1928—2004)

СЫЗГЫРА ТОРГАН УКЛАР

(тарихи романнан өзекләр)

БЕРЕНЧЕ КИТАП

Кыскача тарихи белешмә

Моннан ике-өч мең еллар элек Борынгы Кытайдан төньякта — хәзерге Монголия һәм Төньяк Кытай далаларында — күчмә халыклар яшәгән. Борынгы Кытай чыганакларында бу халыклар (русча язылышта) сюн яисә сюнну дип атала. Сюн (сюнну) сүзен бүгенге китапларда хун (хунну), гун дип тә язалар.

Кытай хроникаларында әйтелгәнчә, сюн (сюнну) кабиләләре беркемгә буйсынмыйча, аерым дәүләт булып яшәгәннәр. Аларның үз патшалары һәм халык белән идарә итүдә үз тәртипләре булган. Кырыс табигатьле дала шартларында шәһәрләр кору, иген игү мөмкин булмый. Шунлыктан сюннулар малчылык белән көн күрәләр һәм туктаусыз хәрәкәт итеп, күченеп яшиләр. Сюннуларның Борынгы Кытай чыганакларында тасвирланган дини карашлары, гореф-гадәтләре һәм хуҗалык итү ысуллары соңгырак чор төрки халыкларның хуҗалык ысулына, дини карашларына һәм гореф-гадәтләренә тулысынча туры килә.

Сюннулар сугышчан халык булалар. Безнең эрага кадәр III—II гасырларда алар аеруча көчәеп китәләр. Борынгы Кытай җирендә оешкан беренче үзәкләштерелгән дәүләт — Чин империясе таркалып, аның урынына Хань дәүләте барлыкка килгән елларда сюннулар Кытайга басып керәләр. Сюнну гаскәре кытайларның өч йөз егерме меңлек гаскәрен камап ала. Камалучылар арасында Хань дәүләтенең патшасы Гаоди да була. Җиде көннән соң сюннулар камап торуны туктаталар һәм үз җирләренә кайтып китәләр.

Бу хәл безнең эрага кадәр 200 елда була. Шушы вакыйгадан соң Хань дәүләте Сюнну дәүләтен үзе белән бертигез дип таный, һәм Кытай императорлары шактый озак вакытлар дәвамында төньяктагы күршеләренә калан (хәзергечә әйткәндә, контрибуция) түләп торалар. Шулай итеп, Сюнну дәүләтенең дәрәҗәсе бермә-бер арта. Борынгы кытайлар белән көрәштә тиңдәшсез җиңүгә ирешкән Сюнну патшасының исеме кытайча Маодунь, Маодуньның атасы Тоумань дип языла.

«Сызгыра торган уклар» романында менә шушы вакыйгалар тасвирлана. Сюн — хун — гун сүзенең кем сүзе булуы һәм аның нәрсә аңлатуы билгеле түгел. Романда сюн — сюнну «сөн» дип алынды. Татарстанда, Башкортстанда һәм күрше өлкәләрдә Сөн елгасы, Сөн — Шөн авыллары бар. Бүгенге көндәге Сөн — Шөн атамалары бик борынгы сюн — сюнну сүзенең калдыклары булырга мөмкин. Кеше исемнәре мәсьәләсенә килгәндә, Кытай язмаларында Тоумань дип аталган исем романда Туман дип, Маодунь — Албуга дип бирелде.

Роман Борынгы Кытай чыганакларына (аерым алганда, тарихчы Сыма Цянь язмаларына) һәм бүгенге фән казанышларына нигезләнеп иҗат ителде.

Монда шундый сорау туарга мөмкин: географик яктан да, вакыт ягыннан да бик ерактагы сюннуларның безгә ни катнашы бар соң? Бит безнең бабайлар гомер-гомергә Идел, Урал буйларында яшәгәннәр. Аларның дәүләте башта Болгар дип, соңыннан Казан ханлыгы дип аталган. Анысы шулай. Ләкин Казан ханлыгы моннан биш йөз еллар, Болгар мең еллар чамасы элек барлыкка килгән. Аңа кадәр безнең тарих булганмы соң? Булган, әлбәттә. Тик безнең бабайлар Болгар чорына кадәр башка төбәкләрдә яшәгәннәр һәм башка исемнәр белән аталып йөртелгәннәр. Мәсәлән, безнең эраның IV—V гасырларында Идел буйларында гун дип аталган халыклар яшәгән. Алар Көнчыгыштан килгән булганнар. Аттила җитәкчелегендәге гуннар V гасырда хәзерге Италиягә, Франциягә кадәр барып җитәләр һәм Рим империясен тар-мар итүдә катнашалар. Гуннар союзының төп халкы төркиләр була, гун төркиләре арасында исә болгар кабиләләре күпчелек тәшкил итә.

Шул рәвешчә, Аттила чоры гуннары арасында да, борынгы Сюнну дәүләтендә дә болгарларның, кыпчакларның һәм башка төрки халыкларның токымы булган дип әйтә алабыз.

Автор

[Түбәндә романнан Туман каган һәм Албуга мөнәсәбәтләренә караган вакыйгалар китерелә.]

Икенче баб

XII

Төш юрауга, күрәзәгә һәм һәртөрле ырым-шырымнарга чын күңелдән ышана торган Туман каган бер генә зур эшен дә камнар, күрәзәчеләр белән киңәшмичә эшләми иде. Инде шундый куркыныч, буталчык төш күргән икән, иң элек аны, билгеле, төш юраучыларга, күрәзәчеләргә сөйләргә кирәк иде. Баштарак ул шулай дип уйлады да. Ләкин ныклап торып уйлана торгач, ул бөтенләй капма-каршы фикергә килде. Үзенең карт юлбарыска әйләнүен, юлбарысны каракош күтәреп алып китүен кемгә дә булса сөйләү дөрес булырмы? Бу бит төштә генә түгел, өндә дә үз-үзеңне нindидер явыз каракошларга тотып бирү белән бер булачак! Синең шундый төш күрүеңне көнчел туганнарың, дошманнарың ишетеп калса, ул чагында алар сине терелэй тотып ашамаслармыни?!

Шулай булгач нишләргә?

Бу бик авыр, бик катлаулы сорау иде. Моны хәл итмичә торып, моннан соң яшәргәме, яшәмәскәме? Яшәсәң, ничегрәк итеп яшәргә дигән сорауны хәл итеп булмаячак кебек иде. Төшне беркемгә дә сөйләмичә, мәңге аны күңелеңдә яшереп калырга да булыр иде. Төш аркылы ата-баба, изге иярләр исән калганнарга киңәш бирәләр, аларны кисәтәләр, аларга туры юл күрсәтәләр.

Шулай булгач, теләсәң дә, теләмәсәң дә, төшнең серен ачыкларга кирәк булачак. Туман каганның барлык киңәшчеләреннән дә якынрак бер киңәшчесе — сердәше бар иде. Ул да булса, Баргынтай баба иде. Баргынтай баба аның үлгән атасының ана ягыннан үги агасы иде. Сөнәнкә ыруында ул каганнар тамырының иң карт кешесе, бөтен ыруга ата урынына калган кешесе иде.

Торып, иртәнге йомышларын йомышлагач, киенгәч, тарангач, Туман каган Баргынтай бабаны алырга кеше җибәрде. Баргынтай баба урданың уртанчы божрасында яши иде. Көттермичә, ул тиз арада килеп тә җитте. Каганның үзенә генә әйтәсе нindидер сүзе барлыгын ул билгеле сизенми калмады. Шулай да иртәнге аш янында ул-бу турында бернинди сүз булмады. Бары тик ашап-эчкәч һәм өч аяклы түгәрәк өстәлне, табак-савытларны ашчылар Ак өйнең икенче ягына алып чыгып киткәч кенә, каган Баргынтай бабага үз янына күчебрәк утырырга кушты.

Күк гөмбәзедәй биек, иркен өйнең ярты ягында Баргынтай баба белән икәүдән-икәү генә калгач, калын чыбылдык артыннан берәрсе тыңлап тормасын дигән сыман тавышын әкренәйтеп, Туман каган аңа әлеге төшен сөйләде. Ул аңа барысын да түкмичәчми сөйләде, тик ахырга таба гына аны тагын икеләнү биләп алды. Үзенең карт юлбарыска әйләнүен әйтергә аның шулай да кыюлыгы җитмәде.

Каганның нидер яшереп калуын Баргынтай баба сизеп утырды. Ләкин ул берни сорашмады. Бөтен ыруда иң карт кеше булса да, мондый икәүдән-икәү сөйләшүләрдә, киңәш-табышта аеруча сак булырга кирәклеген ул инде белә иде. Шуңа күрә зур гәүдәле, бай киемле ир уртасы каган алдында тезләнеп, башын иебрәк утырган чандыр карт беренче булып сүз башларга ашыкмады.

— Ник эндәшмисең, Баргынтай баба? — диде каган, тынып утыру озакка сузыла башлагач.

— Изге төш бу, углым,— диде Баргынтай баба, башын калкытып.

Каган, җиңеләеп, ат сыман пошкырып куйды. Тезләре өстендә авыр, җансыз булып яткан авыр йодрыклары үзеннән-үзе язылып китте.

— Беркайчан да синең мондый изге төш күргәнең булмады,— диде шулай ук күңеле күтәрелеп киткән карт.— Өндә син үзең карт юлбарыс үтердең. Төштә — менә тагын карт юлбарыс! Изге бу, изге төш. Карт юлбарыс ул — карт Чин иле...

Баргынтай бабаның шулай дип әйтүе булды, Туман каган, әле генә җиңеләеп сулыш алгандагы кебек, янә дә ат пошкырган сыман... көрсенеп куйды. Шул ук мәлдә аның ирексездән сул күз кабагы тартыша башлады. Иң ачуын китергәне аның менә шул сул күз кабагының тартышуы иде. Бик нык эче пошса, үртәлсә, ачуланса һәм шул ук вакытта үзенең күңелсез тойгыларын эченә яшерсә, аның шулай сул күз кабагы тартыша башлый иде. Моны Баргынтай баба да, башкалар да беләләр һәм мондый чакта ничек тә аннан читтәрәк булырга тырышалар иде. Шулай да Баргынтай баба батырларча төш юравын дәвам итте.

— Берәм-берәм сыерларны бугазлаган сыман, бер-бер артлы алты йортны аяк астына салып таптаган Чин юлбарысы чәнчелер, иншалла! — диде ул.— Аның үзен кем егар, кем сөзеп эчен айкар, яшь җирән бога сыман? Синме? Күрәсең, шулайдыр, углым.

— Бирсен Тәңрем! — диде каган.

— Бу әле төш юрау түгел,— диде Баргынтай баба.— Бу — минем теләк, синең теләк. Дөньяда эшләр синең теләк, минем теләк буенча гына бармый. Барлык эшләр изге ата-бабаларның теләге буенча, Тәңренең боерыгы буенча бара. Без — бары Тәңренең боерыгын үтәүчеләр генә. Синең төшеңдә аңлашылмаган нәрсәләр бар, изге каган.

Үз уйларына бирелеп утырган каган шундук башын калкытты. Бу юлы ул шаулатып көрсенүдән үз-үзен тыеп кала алды.

— Карт юлбарысны Чин дип, яшь боганы Сөн дип уйласак, бу дөрес булмаячак,— диде Баргынтай баба, каш астыннан гына каганны күзәтеп.— Сөн иле яшь богадай көчле булса да, аңа инде күптән мең яшь тулган. Сөннәр чиннардан да, башка

барлык халыклардан да элегрәк барлыкка килгәннәр. Сеннәр — Тәңренең иң сөекле балалары. Шуңа күрә дә алар иксез-чиксез көтүлекләрне, тау-ташларны, урманнарны үз кулларына алганнар. Җунго әнә төрле яктан биек таулар белән, диңгез белән чикләнгән тар, кысан үзәнлектә торып калган. Инде карт юлбарысны бүгенге Чин йорты дип уйласак, монысы бөтенләй хата булачак. Чин әле аягына да баса алмаган сабый бала кебек кенә.

— Сүзләрең изге, Баргынтай баба,— диде каган, тыңламыйча.— Яхшы сүзләрең өчен миннән сиңа кеш якалы тун, йөгәнле, иярле кашка ат илтеп бирерләр.

— Бай бул, изге каган! — диде Баргынтай карт, җиңел сулап.

— Инде турысын әйт: сөйләргәме юраучыларга бу төшне? — диде каган, чандыр картның йөзенә туры карап.

— Төшең буталчык, углым,— диде Баргынтай баба.— Анаң Кортка-бикәдән башка беркемнең башы җитмәс бу төшне юрарга.

XIII

Анасы Кортка-бикә янына Туман каган үзе китте. Берүзе. Бай киемнәрен дә кимәде, егетләрен дә алмады. Карт алашасына атланды да, күңелендәге каршылыклы уйларын җиңеп, тешен кысып, башын иеп, анасы янына китте.

Туман каганның анасы Кортка-бикә урдадан биш-алты чакрым читтә, төн ягында кечерәк бер күл буенда яши иде. Каган урдасы кая гына күченеп китмәсен, кайда гына утырып калмасын, теләсә кайда, теләсә кайчан ул үзенең өлкән углыннан шулай биш-алты, кайчагында сигез-тугыз чакрым чамасы читтә, төньякта булырга тырыша иде. Бары тик су ягы кыенга туры килгәндә генә, ул урдага, димәк, суга якынрак җиргә утыра, ләкин беркайчан да каганның биек Ак өен әйләндереп алган боҗралар эченә керми иде. Каган өеннән кала, аның өе якын-тирәдә иң биек, иң зур өйләрдән санала иде. Каган өен өч кат тыгыз боҗра булып атлы, кораллы торгаклар әйләндереп алган булса, аның өен дә шулай ук, өч кат боҗра булып тыгызланып, кечерәк, ярлырак өйләр әйләндереп алган иде. Тик ул өйләрдә бернинди торгаклар да, кораллы ирләр дә юк иде. Ул ярлы өйләрдә Кортка-бикәнең үз кешеләре: йөзләгән, меңләгән ырудашлары, коллары, төрле авырулар, ярлылар, аяк-кулсыз карт-корылар яши иде.

Карт атка атланган таза ир кешенең туп-туры үзләренә таба килүен аксак-туксак ирләр — элекке сугышчылар — ерактан ук күреп алдылар. Беравык алар аны танымыйчарак тордылар. Танып алдылар да барысы берьюлы диярлек куанып кычкырып җибәрделәр. Титаклап, бер-икесе шундук өйгә — Кортка-бикә янына йөгерде, калган бер-икесе — тазарак, төзегрәк күренгәннәре — каган каршысына ашыкты. Атын үз көенчә генә атлатып

килгән Туман каган тышкы божрага барып җиткәнче, алар аның каршысына килеп тә җиттеләр, атының йөгәненнән тотып та алдылар. Шунда берсе, олы кунакка иярдән төшәргә булышып, аның аяк табанына зур учын куйды, икенчесе, биектән сикергән баланы тотып алырга җыенган сыман, аны тотып алырга әзерләнеп торды, өченчесе дәрте сүнгән юаш карт алашаның сөякчел маңгаеннан, күкрәгеннән сөештергән булды. Каган җиргә баскач, аксак-туксакларның берсе, юл күрсәтеп, алдан китте, икенчесе, куанычыннан нишләргә белмичә, туктаусыз алаша белән сөйләнеп, алдан титаклады.

Ярлы, караңгы өйләр артында каганга, сәләмә туннарына төренеп, өй буенда утырган ниндидер карчыклар, үзара ыгы-зыгы килеп, кузна уйнаган бала-чагалар очрады. Мондагы ярлылык, мондагы күңелсезлек каганның ачуын китерде. Бу аксак-туксак ирләрне, авыру корткаларны караеп, тишелеп беткән, кырык җирдән ямаулы өйләре-ниләре белән аның бөтенесен бер өемгә өеп, ут төртеп яндырасы, я булмаса тау-ташлар арасындагы берәр упкынга илтеп аударасы килде. Анасы белән, билгеле. Тик менә төшине генә юрасын да...

Каганның анасы Кортка-бикә үзе болай бер дә ярлы түгел иде. Аның үзенә беркетелгән унике мең өйле иле, көтүләре, көтүлекләре бар иде. Теләсә, ул үз өен дә, үзен әйләндереп алган башка өйләрне дә өр-яңа киездән кордыра алган булыр иде һәм, теләсә, аның тирәсендә бер генә сәләмә киемле карт-коры да булмас иде. Каганның анасы буларак, ул биек Ак өйнең һәрвакыт түрендә, табынның мулында утыра алган булыр иде. Ләкин ул әнә теләми. Аның менә шундый ярлы булып, углы каган тарафыннан кыерсытылган булып күренәсе килә.

Моннан унҗиде-унсигез еллар элек ул бер дә андый түгел иде. Туманның атасы — Кортка-бикәнең ире каган үлгәч, Алан ыруының Бай-Тимер яклылар Сөнәнкәнекеләргә каршы баш күтәрделәр. Бай-Тимернекеләр урда аксөякләренең шактыен үз якларына аударып өлгергәннәр иде инде. Урдада бик каты суеш булыры көн кебек ачык иде. Менә шунда Кортка-бикә, каршы яктагыларның кайберләрен үз ягына аударып, кайберәүләрне иркәләп, кайберләрен куркытып, тиз арада дилбегәне үз кулына алып өлгерде һәм өлкән углы Туманны биек Ак өйнең түренә утыртуга ирешге. Бай-Тимер җиңелде. Аның яклы бик күпләрнең башлары аяклары астына тәгәрәп төште.

Каган булгач, Туман, ни теләсәм, шуны эшләрмен, дип уйлаган иде. Ләкин чынлыкта эшләр бик үк алай булып чыкмады. Әледән-әле аның эшенә, тормышына Кортка-бикә кысыла башлады. Ире каган исән чакта, аны уч төбендә биеткән усал, үзсүзле, холыксыз хатын үзенең өлкән углын да уч төбендә биетмәкче булды. Һәм, чыннан да, тәхеткә утыруның беренче елларында

каган ничек тә анасы теләгәнчә эшләргә, ул теләгәнчә яшәргә тырышты. Шулай да тора-бара аның вак-төяк киңәшләре, еш кабатланган холыксызлыклары ачуын китерә башлады.

Көннәрдән бер көнне алар бозылышып киттеләр. Бик каты бозылыштылар! Туман каган әйтте: «Алтын тәхеткә мин синең итәгеңә ябышып яшәү өчен утырмадым»,— диде. Анасы әйтте: «Мин утырттым анда сине, мин! Мин булмаган булсам, син инде күптән атаң янында җир куенында яткан булыр идең,— диде.— Атаң исән чакта, мин бөтен Сөн илен үз кулымда тоттым, син каган булгач, миңа сигез мең өй бирдең дә коры таякка калдырдың»,— диде. Дүрт мең өйлек Сөйбүләр аның бирнә буларак артыннан килгән үз байлыгы иде.

Шушы ызгышудан соң Кортка-бикә шулай да углының эшенә, тормышына кысылмый башлады. Ләкин шул ук вакытта ул урдадан аерылып, «башкаланып» чыгып китте. Урдадан аерым яшәсә дә, ул углы яныннан бик үк читкә дә китмәде. Болай яшәү аның өчен бик тә җайлы иде. Әкренләп ул урданың барлык камнарын, күрәзәчеләрен, имче-томчыларын үз тирәсенә туплады һәм алар аша итәк астыннан ут йөртә башлады. Озакламый ул үзен Ана-кам дип белдерде һәм барлык дин-йола эшен үз кулына алды. Шулай итеп, ул барыбер җиңелмәде!

Хәер, Туман каган беркайчан да аны җиңәргә уйламады да. Нинди генә булмасын, ана изге иде, үз анасына каршы кул күтәргән кешене яшен сугачак иде. Шулай ук Кортка-бикә дә үз углына каршы беркайчан да бернинди яманлык эшләмәде бугай. Итәк астыннан ут йөрткәндә дә, ул турыдан-туры каганга зыян ясамаска тырышты.

Анасы башкаланып яши башлаганнан бирле, Туман каганның менә шулай аның биләмәсенә беренче мәртәбә аяк басуы иде.

XIV

Кортка-бикәнең тыштан караганда каганныкы кебек биек, иркен өе, янына килгәч, якын-тирәдәге ярлы өйләрдән әллә ни аерылып тормый иде. Кайчандыр кардай ак булган киезләр караеп, ямалып беткән. Өйнең итәкләре тетелгән, теләсә ничек ямап, тарттырып куелган. Өй янындагы казыкларда изге ата-бабаларның — Бүре, Аю, Куян кебек абаларның[1] — җилдә-яңгырда шомарып, агарып беткән баш сөякләре ыржаеп тора; казыктан казыкка сузылган кыл арканнарда очлы тешләр, усал тырнаклар тирбәлә, йомшак койрыклар җилферди. Ишек катындагы иң биек казык башында, канатларын киң җәеп, кара бөркет чайкала.

[1] *Аба* — мифик ата-ана, баба. Ыруның, кабиләнең нәсел башы. Абалар, гадәттә, берәр ерткыч кыяфәтендә булганнар.

Өйнең үгез тиресе белән тышланган ишеген билсез карт ачты. Беренче ишектән кергәч, эчтә, бусага төбендә, каганны икенче бер гарип каршылады. Кулыннан тотып, ул аны бусага янындагы агач утыргыч янына алып килде, утыртты. Икенче бер аксак карт, олы кунак килүен әйтергә дип, өйнең түр ягына таба атлады. «Ничек кылана!» — дип уйлады каган анасы турында, яратмыйча.

Каган углының үз янына килерен Кортка-бикә бөтенләй көтмәгән иде, ахрысы. Әлерәк кенә ниндидер тире кисәкләре, канатлар, койрыклар белән булашкан җиреннән ул, бар эшен ташлап, шулай да өстендәге сәләмә киемнәрен алыштырмыйча, илтотмыш бикә сыман, өенең уң ягында, биек ятагында аякларын бөкләп утыра иде. Шунда ук, Кортка-бикәнең аягы астында, сәләмә киемле, корышкан йөзле берничә карчык тынып калган иде. Башына Кортка-бикә куян тиресе тотылган мескен бүрек, өстенә җирән йон күлмәк, күлмәк өстеннән тире күртәнә[1], аякларына кыршылып беткән болан итекләр кигән иде.

Ябыклыктан ияк очлары, яңак сөякләре күзгә төртелердәй булып торган чандыр карчык үзенең чак-чак кына каушап калган игелексез углына сынап, исе китеп һәм шактый ягымлы итеп карады. Туман каган исә, мышнап, кызарынып, авырлык белән генә анасы алдында билен бөкте, баш киемен салып, башын иде.

— Кичер, анам,— диде ул, таштай авыр, кытыршы сүзләрен каяндыр төптән тартып чыгарып.

Анасының ни өчен үзен кичерергә тиешлеген ул үзе дә аңлап җитмәде, ләкин бу очрашуда, мондый очрашуда ул аңа бары тик шундый гына сүз әйтергә тиеш иде сыман.

— Анаңның ничек яшәгәнен күрергә килдеңмени, балам? — диде Кортка-бикә, җиңелчә мыскыл белән.— Менә күр: мине ачлар туендыра, тунсызлар киендерә. Аксак-туксаклар минем көтүләремне көтә, тишек-тошык өемне җылыта. Мин инде күптән атаң янына киткән булыр идем — изгеләр җибәрми. Миннән алда алар сине көтәләр, углым!

Еллар буена җыелып килгән сүзләрен, ачуын-үпкәсен тизрәк әйтеп бетерергә тырышкан сыман, Кортка-бикә ашыгып, кабаланып сөйләде. Аның чатнап торган чәрелдек-яңгыравык тавышы каганга куркыныч һәм шомлы булып ишетелде. Анасының соңгы сүзләре аның йөрәгенә агулы ук булып кадалды. Ул, үзенең тирли башлавын тоеп, авыр кулын битенә якынайтты.

— Мин сине чакырып кеше җибәрәм, син килмисең,— диде ул, мышнап.

---

[1] *Күртәнә* — кыска тун, куртка.

— Куалап җибәргәнеңне оныттыңмыни? — диде Кортка-бикә, тыңламыйча.

— Мин сине куаламадым, анам. Син үзең киттең,— диде каган.

— Син мине чүплек башына чыгарып ташладың! — дип кычкырды Кортка-бикә, кинәт ярсып китеп.— Син мине үлсен диден. Мин әле үлмәдем. Мине изгеләр яклый. Кул күтәреп, бер дога кылсам, менә шунда сине җир йотачак, игелексез! Биек Ак өйгә баш булу өчен, син күпме туганнарыңның, күпме ырудашларыңның канын койдың?! Тәмугта синә барысы өчен дә җавап бирергә туры киләчәк.

— Анам! — диде каган, түземлеген җуя башлап.

— Әйе, мин — синең анаң. Изге анаң! — дип кычкырды биек ятакта аякларын бөкләп утырган Кортка-бикә, нурсыз күзләреннән усал очкыннар чәчрәтеп.— Нишләп аны әле генә исеңә төшердең?

— Мин сине гел исемдә тотам, изге анам,— диде каган, ялганлап.— Менә синең шундый көнгә төшүеңне ишеттем дә, үз күзләрем белән күрмәкче булып, янына килдем. Мин сиңа, изге анам, туену өчен... өч мең өйлек ил-көн, көтүләр, көтүлекләр бирмәкче булдым.

Ул моны әле генә уйлап тапты. Күрешми торган арада, Кортка-бикә бик нык үзгәргән иде һәм, берәр майлы калҗа ташламыйча торып, күрәсең, аның күңелен җиңел генә яулап алып булмаячак иде. «Майлы калҗа», чыннан да, үзенекен итте. Тиле кортка, углының соңгы сүзләрен ишетеп, кисәк кенә тынып калды, юашланып калды һәм тыела алмыйча елап җибәрде.

— Атаң исән булса, мин дә, менә монда аксак-туксак белән бер табактан ашап, каткан киез өстендә йокламас идем,— диде ул, борынын тарткалап.

— Урдага кайт, янымда гына булырсың, изге анам,— диде каган.— Алдыңда алтын табаклар булыр, баш астыңда мамык түшәкләр булыр.

— Юк, юк! — диде карчык, йокыдан уянган сыман.— Мин инде бу өемне теләсәм дә ташлап китә алмыйм. Әнә күрәсеңме, алар мине дүрт күз белән күзәтеп торалар! Мине алар җибәрми.

Ул очлы тешләрен ыржайткан баш сөякләренә ымлап күрсәтте. Туман каган ирексездән изге абаларга карап алды. Аңа, чыннан да, өйнең барлык төшеннән — астан, өстән, ян-яклардан — кемнәрдер күзәтеп, сагалап торалардыр сыман тоелды. Аның тизрәк төп сүзгә күчәсе килде.

Углының уйларын сизенгән кебек, Кортка-бикә шундук кымыз китерергә кушты. Кымызны бары үзе генә эчә торган савытка — юка алтын калай белән тышланган, эчке ягы исә көмеш калай белән капланган баш сөягенә агызды. Атаклы Чжао батыры Йүлән бәкнең баш сөяге иде бу. Моннан күп еллар

элек Йүлән батырны яуда аның ире үтергән иде һәм аның баш сөягеннән ясалган әлеге кәсәне дә ул аңа — үзенең сөекле бичәсенә — бүләк итеп биргән иде. Кымызны Кортка-бикә, йола буенча, иң элек Ут-анага[1] бирде, аннары үзе авыз итте дә углына тоттырды, каган кымызны эчеп бетергәч, ул, кулын селтәп, өй эчендәгеләрнең барысына да чыгып китәргә боерды. Шуннан соң бөтенләй тынычланып, юашланып калган изге бер кыяфәттә:

— Төшеңне сөйлә, углым,— диде.

— Төшне?! — диде Туман каган, шаккатып.

— Куркыныч төшеңне сөйлә, балам,— диде Кортка-бикә.

— Син... изге анам, каян беләсең аны? — диде каган.

— Мин барысын да беләм,— диде Кортка-бикә, тыныч, серле бер өстенлек белән.— Миңа изге абалар җиткереп тора. Кара аны, бернәрсәңне дә яшереп калдырма.

«Баргынтай баба җиткерде микәнни?» — дип уйлады каган, әле булса исенә килә алмыйча. Ләкин, алай дисәң, Кортка-бикә белән алар — дошманнар.

Углының икеләнүен Ана-кам шундук чамалап алды.

— Миңа ышанмагач, ник килдең монда? — диде ул, усал гына итеп.

«Ул, чыннан да, изге!» — дип уйлады Туман каган, исе китеп.

XV

Төшне каган анасына түкми-чәчми сөйләде.

Тыңлап бетерү белән, Кортка-бикә сикереп урыныннан торды, шомарып беткән баганадагы шомарып беткән дөңгерен кулына алды һәм шундук бөтенләй икенче кыяфәткә керде. Күзләрен акайтып, бөтен тәне, өстендәге сәләмәләре белән калтыранып, дөңгердәге шөлдерләрен, тимер, сөяк кисәкләрен шакылдатып-шалтыратып, бар көченә: «Алас! Алас!» — дип кычкырып җибәрде. Атка атланган килеш, як-якка тирбәлеп, чайкалып баргандагы сыман, кызу-кызу атлап, ул өй эчен өч мәртәбә әйләнеп чыкты. Шуннан соң, кемнәр беләндер бик каты сугышкан шикелле, кемнәрнедер куа-куа, арып-алҗып, хәлдән таеп, яңадан үз урынына килеп ауды. Килеп ауды да, күзләрен йомып, кул-аякларын хәлсез салындырып, беравык мәрткә китеп ятты.

Ниһаять, ул башын калкытты. Берни эндәшмичә, беркемне күрмичә, шактый тынып утырды. Каяндыр җир астыннанмы, калын киез артыннанмы сөйләшкән сыман, тавышын үзгәртеп, серле һәм шомлы итеп:

— Кем син, и адәми зат? — диде.

---

[1] *Ут-ана* — борынгы төркиләр утка табынганнар. Ут-учак өйнең уртасында, иң хөрмәтле урында булган. Ашар-эчәр алдыннан, һәрвакыт Ут-анага корбан бирелгән.

Анасының күз алдында шулай үзгәрә алуы игелексез угланны янә тетрәндереп җибәрде.

— Синең өлкән углың каган бу, изге Ана-кам,— диде ул, дер-дер калтыранып.

— Син Кара тау иясен... изге абаны аткансың,— диде Кортка-бикә, бераз көттереп.— Кара тау иясенә атап корбан бир.

— Бирермен, изге анам,— диде Туман каган.

— Ул төнне ятагыңда үзеңнән башка кем бар иде? — диде Кортка-бикә.

— Ы-ы,— диде каган, тертелеп.— Яшь кыз. Табылдык атлы.

— Аны абаларга бирерсең,— диде Ана-кам, боздай салкын, дәртсез бер тавыш белән.

— Бирермен...— диде каган, әкрен генә, һәм шул ук мәлдә, сөекле Табылдыгын, аннан да бигрәк гүзәл чин кызын уйлап, кинәт тирләп чыкты.

Болай булгач, Куяннар белән, чынлап та, бозылышырга туры килер микәнни? Әллә соң киңәш сорап карарга мы? Ярамас. Ул чин кызы турында авыз ачсаң, аны да үзенә тартып алырга күп сорамас бу... изге анаң! Юк, аны әлегә бирмибез абаларга!

Кортка-бикә, углын сынаган сыман, озак кына эндәшми утырды.

— Яшь җирән богадан саклан,— диде ул аннары, каганның тынычланганын күреп.

Яшь җирән бога турында ишетү белән, Туман каган икенче мәртәбә уянып киткәндәй булды.

— Кем ул, кем яшь җирән бога? — диде ул, ашыгып.

— Ул синең баш балаң — уң кул тучи бәк тәгин углан Албуга булыр,— диде Ана-кам, ап-ачык итеп.— Аны ничек тә үзеңнән ераграк тот.

— Ничек аңларга моны, изге анам?! — диде каган, коты алынып.— Ул — минем сөекле углым! Ул мине үлемнән коткарды!

— Син кем өчен яшисең, Туман каган? —диде Ана-кам, корыган агач шыгырдаган сыман дәртсез, салкын бер гамьсезлек белән.

— Мин... ни... синең өчен, изге анам,— диде каган.— Илем-көнем өчен, балаларым өчен!

— Ялган сөйлисең, Туман каган,— диде Ана-кам, усал итеп.— Син үзең өчен генә яшисең. Сиңа Тәңре көч бирде, ил-көн бирде, тәхет бирде. Көчең киткәнче, тәхетеңне кулыңнан ычкындырма. Көчең киткәч, Тәңре барысын да үзе тартып алыр.

— Нишләргә соң, изге анам? — диде каган, яшь җирән боганы күз алдында тотып.

— Барысы да Тәңре ирегендә,— диде Ана-кам, аның тел төбен аңлап.— Үзең бармак белән дә чиртәсе булма. Чин карасыннан дүрт курчагын ясат, дүрт якка күмдер. Курчак ясаучыны Кара тау иясенә корбан итеп бир.

— Бирермен, изге анам! — диде каган, төштәге сыман.

— Хы-хы! — диде Ана-кам, явыз көлемсерәп.— Бүре дә тук булсын, сарык та исән калсынмы?! Булмый ул алай!

— Син... анысын да беләсеңмени?! — диде каган, яңадан гаҗәпкә калып.

— Беләм, барысын да беләм! — диде серле карчык.— Син генә белмисең минем ниләр белгәнемне. Мин барын да күреп, ишетеп торам. Миңа изгеләр җиткерә!

Туман каган исерек кебек тынып, басылып утырып торды да, авыраеп калган аякларын көчкә кузгатып, алпан-тилпән атлап, ишеккә таба юнәлде. Аның тизрәк моннан — изге, куркыныч анасы яныннан чыгып китәсе килде. Ул нәрсә уйларга да белмәде, аның күңелендәге бөтен нәрсә бергә буталып баш-аяк килде. Баргынтай баба белән сөйләшер алдыннан да, монда килер алдыннан да, ул үзе, ничектер, башкачарак фикер йөрткән иде. Үзе яралы юлбарыс булган очракта да, яшь җирән бога, аныңча, өлкән углы Албуга түгел, бөтенләй икенче берәү — үзенә баш бирмәскә тырышкан берәр башбаштак булырга тиеш сыман тоелган иде. Баксаң, әнә ул ничек икән эшләр!

Кортка-бикә беркайчан да Куяннарны яратмады. Элек-электән ул аларны яманларга җай табып кына торды. Ире каган исән чагында, ул Куяннарга каршы этлек эшләүдән дә тартынып тормады. Куяннан килен булып төшкән Күрекле бикәне дә, аның балаларын да ул бик үк өнәп бетермәде. Аларга карата нишләп шулай дошманлык саклагандыр ул, чынын гына беркем дә белми иде. Яшь чагында Котлуг бәк белән аның арасында ниндидер серле, күңелсез нәрсә булган, ахрысы, имеш-мимеш шулай сөйли иде.

Менә хәзер дә, бөек углы каганның төшен юраганда да, ул Куяннарга карата әүвәлге шул дошманлыгын исендә тотмады микән? Анасының Куян ыруыныкыларга карата мөнәсәбәтен яхшы белгән Туман каган шулай дип уйлый ала иде, билгеле. Ләкин алай дип уйларга аның хәзер нишләптер башы җитмәде. Ана-камның изгелеге, серлелеге алдында аның тәмам зиһене томаланды. Ул бары шаккатты, аптырап, каушап калды һәм, үзен өермәдәй бөтереп алган каршылыклы уйларына, тойгыларына баш була алмыйча, куркыныч язмыш алдында — күзгә күренмәгән, ләкин әледән-әле үзен сиздереп торган яшерен көчләр алдында — ихтыярсыз сыгылып төште.

XVI

Урдага ул бик төшенке күңел белән кайтты. Аның ниндидер кайгысы барлыгын өйдәгеләр барысы да күреп алдылар, тынып калдылар һәм, йорт башының күзенә күренүдән куркып, су сипкәндәй, каядыр юкка чыктылар.

— Бүзбала кайда? — дип кычкырды каган, түргә узып.

— Бүзбала! Бүзбала! — дип пышылдадылар анда-монда өйдәгеләр, карачыны эзләп.

Бүзбала нииндидер эш белән Атсыз күл аръягына көтүчеләр янына киткән иде. Аны тиз генә алып кайтырга дип, йомышчыны җибәрделәр. Йомышчы Бүзбаланы тиз арада эзләп тапты һәм, серле пышылдап: «Атабыз ачулы!» — диде. Бүзбала барысын да аңлап алды. Урдага кайткач, ул каган янына үзеннән алда Табылдыкны кертеп җибәрде.

Каган янында үзенең нинди зур көчкә ия булуын белгән яшь, сылу кырнак, көлеп-елмаеп, кыю гына, тәхет янына килде.

— Син арыгансың, хуҗам! Сине чишендермәгәннәр дә! — дип сөйләнде ул, кайгылы-ачулы ир кешенең өстен-башын чишендермәкче булып.

Каган аның сүзләрен әйтерсең ишетмәде дә,— кыз килеп кергәндә, ничек утырган булса, ул килеп үзенә орынгач та, шул килеш кымшанмыйча утыруында булды.

— Абау, синең төсең качкан! — диде Табылдык, куркып.

Ул йомшак кайнар кулы белән ир кешенең тез өстендә яткан җансыз кулын сыйпады, шаяртып, кытыклап, аның салынып төшкән мыек чылгыйларына кагылгалап алды. Ләкин, яшь, сөекле кырнагы күпме генә тырышмасын, таш кыядай калкып утырган куркыныч ирнең таштай йөзе барыбер ачылмады. Яшь кыз курка калды, хуҗасының тезләренә утырды да, ике куллап аның юан муеныннан кочып, тирәнгә яшеренгән төпсез күзләренә карады. Кирәк чакта утлы очкыннар чәчрәтеп яна торган, кирәк чакта җылы нур таратып елмая торган тере күзләрдә Табылдык тетрәндергеч моң-сагыш һәм кайгы күрде.

— Чирләдеңме әллә, хуҗам? — диде яшь кыз, чын-чынлап куркуга төшеп.

— Юк,— диде каган, авыр гына.

— Алайса, ни булды? — диде кырнак.

— Берни булмады,— диде каган.

— Син мине яратмый башладың! — диде Табылдык һәм үпкәләп еларга да керешеп китте.

Каганның нииндидер гүзәл чин кызы турында уйлап кайгыруын ул инде белеп өлгергән иде. Хәзер дә ул: «Каган, күрәсең, шул кыз өчен бетеренәдер»,— дип уйлады һәм аның яшь күңелен көнчелек ялкыны өтеп алды. Аның кайнар яшьләре таш кыяның таш йөрәген урыныннан кузгатты. Авыр кулын көчкә күтәреп, ул, сирәк була торган бер ярату белән, иркәләү һәм саклык белән, кызны күкрәгенә кысты.

— Мин сине генә яратам... беләсең ич,— диде ул, сүзләрен бик авырлык белән сайлап...

Яшь кызга шуннан артыгы кирәкми дә иде — ул шундук елмаеп җибәрде, битеннән агып төшкән күз яшьләрен теле белән

ялый-ялый, йомшак чәчләре, кайнар яңаклары белән кырыс ирнең киң күкрәгенә сыенды.

Бик нык ашыккан булып, шул чагында өйгә Бүзбала килеп керде. Ярыктан ул барысын да күзәтеп торган иде. Сөекле кырнагын иркәләп утырган каганны ул инде тынычланды дип уйлады һәм, түргә үк килеп җитмичә, тезләнеп баш иде дә, тамак кырып:

— Мин монда, бөек каган,— диде.

Каган аны күрде, ишетте, шулай да, Бүзбала көткәнчә, Табылдыкны тез өстеннән төшерергә ашыкмады. Карачыга бу бик сәер тоелды: каганның әле беркайчан да үзенең карачысы белән тезендә гүзәл кызлар утырган килеш сөйләшкәне юк иде. Яшь кырнак та, ике ир янында үзенең артык икәнлеген аңлап, аягына басмакчы булды. Каган аны ычкындырмады.

— Мин монда! — диде Бүзбала, кабатлап.

— Күрәм,— диде каган, тонык кына.— Бире кил, Бүзбала.

Бүзбала якынрак килде.

— Мин үтереп алып кайткан теге юлбарыс тиресен анам Кортка-бикәгә илтеп бирсеннәр,— диде каган, каядыр читкә карап.

— Ник? — диде Бүзбала, гаҗәпләнеп.

Үзе кадап алган юлбарыс тиресе каганның иң зур куанычы иде.

— Кара тау иясе булган ул,— диде каган.

— Ярар, илтеп бирерләр,— диде Бүзбала.

— Аннан соң...— диде каган, көчәнеп,— менә... Табылдык кырнакны да... Ана-камга... Кортка-бикәгә...

— Аһ! — диде Табылдык, сискәнеп, күзләрен зур ачып. Йомшак, кайнар билдән кысып тоткан тимер куллар да, таштай каты муеннан кочып алган яшь куллар да — дүртесе берьюлы бушап калдылар. Беркем беркемне тотмады, тоткарламады. Яшь кыз, кылыч белән чабылган дошман башы сыман, балта белән чабылган агач сыман, сынсыз калып, идәнгә шуып төште.

Каган да, Бүзбала да, бер-берсенә күзләрен күтәреп карарга кыймыйча, ачуланышкан кешеләр кебек, икесе ике якка карап тик тордылар. Яшь кыз кинәт исенә килде, сикереп урыныннан торды һәм алтын тәхетендә кымшанмыйча утырган ир кешенең алдына килеп капланды.

— Кызган мине, хуҗам! Ана-кам мине абаларга бирәчәк, ул мине утлы табада кыздырачак, ул мине тереләй җиргә күмәчәк! — диде ул, такмаклап, өзгәләнеп.— Бөек хуҗам, коткар мине. Яратмасаң яратма, мин тамчы да көнләшмим. Гүзәл чин кызының ялчысы булырмын, көн дә аның аягын юармын — яныңнан гына җибәрмә!

Туман каган Бүзбалага ым какты. Бүзбала, шуны гына көтеп торган кебек, тиз арада урыныннан купты, яшь, сылу кырнакны ике куллап тотып күтәреп алды да каядыр китеп тә барды.

— Кызганыгыз, кызганыгыз! Бирмәгез Ана-камга, бирмәгез! — дип кычкырды Табылдык, Бүзбаланың каты кулларыннан ычкынмакчы булып.

Бишенче баб

VI

Каган боерыгын тыңларга, бикә белән тәгин угланнан тыш, өлкән бичәнең барлык балалары, туганнары чакырылды. Шулай ук мең башы Кәлтә, йөз башы Җирән, бүтән йөз башлары, ун башлары, аксакаллар, агалар килде. Боерыкны Салчак алып үзе түгел, аның исеменнән сүз остасы — чәчән әйтте.

— Мин — Сөн йортының башы Туман каган боерам: өлкән бичәм Күрекле бикәдән туган уң кул тучи бәк тәгин углан Албуга үзенә буйсынган мең ире белән, кирәк-ярагы, өч аты, кораллары, азыгы белән, тугызынчы айның егерме җиденче көненнән дә соңга калмыйча, Урта кичү янына килеп җитсен. Минем боерык үтәлергә тиеш. Үтәлмәсә, баш тартучының башы чаптырылачак, бар байлыгы тартып алыначак.

Чәчән боерыкны ашыкмыйча, ачык итеп, кычкырып әйтте. Барысы да, каган исеменә хөрмәт йөзеннән, баш киемнәрен салып, аягөсте тыңладылар. Чәчән әйтеп бетергәч, өйдә бик озак тынлык сакланды. Барысы да, авызларына су капкан кебек, миңгерәүләнгән кебек, нәрсә уйларга да, нәрсә әйтергә дә белми тик тордылар.

— Тагын кабатласынмы? — диде каган илчесе, өйдәгеләргә күз йөртеп.

Эндәшүче булмагач, ул чәчәнгә тагын кабатларга кушты. Чәчән шул ук сүзләрне яңадан әйтеп чыкты.

Күрекле бикә кинәт битен каплап еларга тотынды.

— Яраткан колымны тартып алды, имгәтеп ташлады! Инде бердәнбер таянычымны да тартып алмакчы,— диде ул, яшь аралаш.

— Яудан беркем читтә кала алмый, бикә,— диде Салчак алып.

— Әни! — диде тәгин углан.

— Синең яраткан колың масая башлады, шуңа җәзасын татыды, бикә,— диде Салчак алып, тупас кына.

Ул болай да тупас, шөкәтсез бер кеше иде. Каган илчесе булу өчен ул бөтенләй яраксыз иде. Шундый кайгылы вакытта аның кирле-мырлы сөйләнүе өйдәгеләрнең күрәләтә ачуын китерде.

— Салчак алып, илче булсаң да, бу өйдә син — кунак. Кунакка тыйнак булу килешә,— диде Албуга, кызарынып, энисен яклап.

— Колыгызны имгәтүдә минем бер гаебем дә юк, олуг уң кул тучи бәк тәгин углан,— диде Салчак алып, түбәнчелек белән.

Туңгак алыпның имгәтелүендә үзенең катнашы булуын ул мондагылар беләләр дип, бикә дә шуңа ишарәли дип уйлады, ахрысы. Мондагылар исә бу турыда берни белмиләр иде.

— Без сине гаепләмибез, Салчак алып,— диде тәгин углан. Мондый сүз ишетеп, Салчак алып авызын ачты да калды. Бөек далада каганның тугы теләсә нинди чирүдән көчлерәк булса да, монда Байык буена ул шулай да шүрләбрәк килгән иде. Шундый киң күңеллеме соң бу тәгин углан, әллә соң алар, чыннан да, берни белмиләрме?

— Урдадан чыгып киткәндә, ул исән булган, бикә,— диде Салчак алып, баштагы тупаслыгын йомшарта төшеп.

— Ул анда үлеп ята! — диде бикә.

— Кайда үлеп ята, бикә? — диде Салчак алып, бөтенләй ягымлы итеп.

Аның шулай кинәт үзгәрүендә тәгин углан яшерен мәгънә тотып алды.

— Әни! — диде ул тагын әнисенә.— Каган илчесе белән сүз көрәштерү урынсыз. Боерык үтәлергә тиеш. Боерыкны мин үтәрмен, Салчак алып.

— Менә моны мактыйм! — диде илче, ачу китергеч бер өстенлек белән.

— Миңа синең мактавың кирәкми, Салчак алып,— диде тәгин углан.— Атамның — бөек каганның — боерыгын мин сөенеп үтәячәкмен. Ул мине олы яуга чакыра. Уң кул тучи бәк тәгин углының элеккечә яратуына ул чын күңелдән ышана. Минем өчен, әни, туганнарым, илем-көнем, моннан да зур куаныч юк. Бүген мин көне буе юлга җыеначакмын, иртәгә таңнан кузгалып китәчәкмен.

Өлкән углының бу күтәренке, тантаналы сүзләренә бикә ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Ул аны бары каган илчесе алдында гына шулай тантаналы итеп сөйлидер дип уйлады. Өлкән углының барысын да шулай тиз чамалап алуы, иң кыен чакта каушап, коелып төшмәве аңарда Албугага карата янә дә ышаныч тойгысы тудырды.

— Салчак алып, мин сине кунак итә алмыйм, кичер мине,— диде ул, кинәт хәлсезләнеп, урынына утырып.— Углым, ирләрем яуга җыенганда... мин генә кул кушырып утырмам лабаса!

Каган илчесе чыгып киткәч, Албуга әнисе каршысына тезләнде, аның тез өстенә салынып төшкән хәлсез кулларын үз кулына алды.

— Әнием! — диде ул, яратып, иркәләп.— Мондый боерыкны мин күптән көттем. Бөтен ил-көн Чингә каршы яу чабарга җыенганда, минем генә читтә калуым гел күңелемне тырнап торды. Бөтен ил-көн яуда чагында, минем дә алып ирләр белән бергә буласым килә. Атам каганның күңеле йомшаган — ул

мине үз янына чакыра. Менә күрерсең: яуда батырлык, кыюлык күрсәтсәм, ул безне яңадан Ак урдага тарттырып алачак! Ул чагында сиңа ялгыз башың кайгырырга туры килмәячәк.

— Ышанмыйм,— диде әнисе, хәлсез пышылдап.

— Мин барыбер аның боерыгына каршы килә алмыйм, әни,— диде Албуга, нык итеп.

— Әүвәл син аның беренче боерыгын үтәргә тиешсең, улым,— диде әнисе.

— Нинди беренче боерык ул тагын? — диде Албуга.

Бикә корыша башлаган йомшак кулларын углының маңгаена куйды, сукыр кеше сыман аның битләрен, колакларын сыйпалап, капшап карады, беләкләренең ныклыгын, тазалыгын чамалагандай итте.

— Улым! — диде ул, йөрәк түреннән чыккан бер җылылык, якынлык белән.— Син Елдырым бәк кызы Алтын-Бөртеккә өйләнеп китәргә тиешсең. Ул синеке булып калырга тиеш. Яудан... кайтмасаң... улыңны сөеп юанырмын.

— Әни, мин!..— диде шул чакны Адай, нидер әйтмәкче булып... Кулын күтәргәндәй итеп, әнисе аңа эндәшмәскә кушты.

— Адай синең урынга калыр,— диде бикә, аның ни әйтергә теләвен белгән кебек.

— Әни, мине дә абый белән җибәр! — диде Адай.

Албуга күкрәген киерде, аягына басты.

— Адай, мин сиңа боерам: әни... туганнар, ил-көн — барысы да синең карамакка кала,— диде ул.

— Абый! — диде Адай, каршы килмәкче булып.

— Каган боерыгы гына түгел, минем боерык та үтәлергә тиеш,— диде тучи бәк тәгин углан, коры гына.

VII

Шулай итеп, яңа җирдә кешеләр иркенләп, тынычлап урнаша да алмадылар.

Яу чабуга, иксез-чиксез даланың бер читеннән икенче читенә тиз арада күченеп китүләргә, сугыш-талашларга кешеләр инде күптән күнеккәннәр иде. Аерылышу, озатышуларны да алар инде үз гомерләрендә күп күргәннәр иде. Яуларның-сугышларның берәүләргә байлык, бәхет, икенче берәүләргә үлем, коллык һәм мәңге кайгы-хәсрәт китерүен алар шулай ук бик яхшы беләләр иде. Шуңа күрә, яу турында хәбәр килгәч, тыштан алар гамьсез-тыныч калдылар, эчтән исә һәркемнең йөрәге янды. Берәүләр сөекле иреннән, сөекле баласыннан аерылды, икенче берәүләр карт ата-анасын ташлап китәргә тиеш булды. Берәүләрнең коралы, каты киемнәре бик үк яхшыдан түгел иде, икенче берәүләрнең юллык азыгы җитеш түгел иде. Һәркемнең кайгысы — хәл ителмәгән олы һәм кечкенә борчуы, мәшәкате бар иде.

Эссе җәйдә кинәт күктән китереп койган яңгыр кебек, кыш көнендә томалап яуган тоташ кар кебек, искәрмәстән килеп төшкән каган боерыгы бар нәрсәне үзенчә хәл итте. Бөтен ил кайгысы алдында вак-төяк кайгы-мәшәкатьләр, кар астында тигезләнеп калган җирнең кутырлары, кирәксез агач-ташлары сыман, томаланып, тигезләнеп калды.

Алар көне буе юлга әзерләнделәр. Әзерлек төнгә дә калды. Китәсе ирләр коралларын, тәңкәле каты киемнәрен, ат кирәк-яракларын барладылар, каласы кешеләр юлга төенчекләр төйнәделәр, ирләрнең тегелеп бетмәгән киемнәрен тегеп бетерергә тырыштылар. Сугымчылар ал-ял белми терлек суйдылар, туңдырып, юлга ит әзерләделәр.

Ирләрнең һәркайсына бер айга җитәрлек азык-төлек, өчәр ат, ун кешегә бер казан, ике кешегә бер өй-күтәрмә алырга кушылды. Шуның өстәвенә һәрбер сугышчы, ат карау, корал ташу, өй кору, ашарга пешерү өчен, үзенә бер кушчы-булышчы алырга тиеш иде. Кушчыларның беркадәре коллар, каралар иде. Ярлырак сугышчылар исә кушчы итеп үзләренең хатыннарын, үсмер малайларын, я булмаса турыдан-туры сугышка катнаша алмаган элекке сугышчыларны — яралы аталарын, улларын алдылар.

Төн урталарына барысы да әзерләнеп бетте. Уң кул тучи бәк тәгин углан Албуга әнисе өендә, туганнарын, аксакалларны, йөз башларын, ун башларын җыеп, үзенең саубуллашу сүзләрен әйтте.

— Оясыннан очып китәргә талпынган яшь бөркет кебек канат кагарга өлгермәдем — буран чыкты! Анасыннан аерылмаган яшь колын кебек тояк ныгытырга өлгермәдем — давыл купты! Минем үз өем дә, үз бичәм дә булмады. Сөеклемнең күзләренә карый алмадым, йомшак чәчләреннән сыйпый алмадым, үз углымны күкрәгемә кысып, ата булып куанмадым. Әнием! Мин синең яшь бөркетең, мин синең яшь колының, мин синең яшь бозавың. Туганнарым, энеләрем-сеңелләрем! Илем-көнем! Сезнең кебек мин далада — көтү арасында тудым, сезнең кебек ит-сөт ашап үстем. Мине бөек атам Туман каган яуга чакыра. Мин үлемгә каршы яу китәм. Кире яныгызга кайталмасам, мине мәңге онытмагыз! Әнием! Учагыңа ягып казан асканда, минем өлешне дә салырга онытма. Сезнең өчен, җирем-суым, илем-көнем өчен каным коеп, Тәңре катына очсам, мине дә яныгызда дип белегез. Яз көнендә төнлек аша бер күбәләк кереп битеңә, кулыңа кунса,— куалама, ул мин булырмын, әни!

Аның саубуллашу сүзләрен бикә күз яшьләрен агызып тыңлады. Башка хатыннар да мышык-мышык борыннарын тарттылар. Бары ирләр генә, кырыс, тантаналы бер тынлык саклап, ирлек дәрәҗәләрен саклап, таш кыядай басып тордылар.

Саубуллашу сүзеннән соң тәгин углан агач күбәтәдән кымыз эчте. Кымызлы күбәтә өй эчендәге барлык кешеләрнең кулында

йөреп чыкты. Шуннан соң Албуга үзенең соңгы боерыкларын әйтте. Беренче булып, ул Җирәнгә эндәште:

— Җирән! Син минем әниемне саклаячак чиругә баш булып каласың,— диде ул аңа.— Әниемне, туганнарымны, илемне-көнемне моңарчы ничек саклаган булсаң, моннан соң да шулай ук сакла. Мин сиңа карата кырыс булдым. Оныт аларны. Мин синең кичерүеңне үтенәм.

— Минем сиңа бернинди үпкәм юк, олуг тучи бәк тәгин углан,— диде Җирән.

— Кәлтә! — диде углан үзенең мең башына.— Син минем белән яуга барасың. Син хәзер үк тугыз йөз кешелек алай белән Диңгез-күл ягына китәсең. Мин, үземнең җегетләремне, йөз иремне алып, Елдырым бәк кышлавына юл тотам. Ярәшелгән Алтын-Бөртеккә өйләнеп, анда бер өчне куныл, мин туп-туры Диңгез-күл буена юнәләчәкмен. Мине шунда көтеп торырсың.

— Көтеп торырмын! — диде Кәлтә.

— Адай! — диде Албуга, энесенә эндәшеп.— Син минем белән кияү-егет булып барырсың. Мине Диңгез-күлгә чаклы озатып куярсың. Шуннан кире монда әни янына кайтырсың. Диңгез-күл буенда торып калган теге алып ирне дә белеп китәрсең.

— Юк, юк! — диде кинәт бикә, каршы килеп.— Белешмәсен. Ул инде кучте — төшемдә күрдем.

Албуга әйтәсе сүзен онытып төртелеп калды. Әнисеннән ул бөтенләй мондый сүз көтмәгән иде. Салчак алып алдында имгәтелгән колны исенә төшергәч, тәгин углан әнисен һаман аны исендә тота дип уйлаган иде.

— Төштә күргәннең газабын без менә өндә татыйбыз, әни,— диде ул, бераздан күңелсезләнеп, әнисенә каты бәрелмәскә тырышып.— Син дә, башкалар кебек, төштә күргән өчен генә, аны читкә тибәрсәң, бу кансызлык булыр иде.

— Куркам, улым, куркам,— диде бикә.

— Төштә күчкән, өндә күчми — син аны беләсеңдер, әни,— диде Албуга.— Ул күчмәгән, ул исән, әни!

— Мин берни әйтә алмыйм, балам... балаларым,— диде бикә, ыңгырашып.

— Синең белән миңа, әни, куркуны гына түгел, үлемне дә җиңәргә кирәк,— диде тәгин углан.— Мин үлемгә барам. Мин үлемне җиңә алмасам, безгә яшәү юк! Имгәтелгән алып ир безгә шул турыда кисәтте түгелме соң?!

— Мин синең теләгеңә каршы килә алмыйм, улым,— диде бикә, килешеп.— Тик анда... Диңгез-күл буена Салчак алыптан алданрак барып җитәргә кирәк. Ул монда каган боерыгын гына алып килмәгән, ул аның... тегенең кайдалыгын да аңышып килгән. Күңелем шулай сизенә.

— Мин дә сиздем аны! — диде Албуга.

— Без, бикә, Салчак алыпны монда бер-ике көн буза белән сыйлап тоткарларбыз,— диде Җирән, күрәсең, үз гомерендә беренче мәртәбә тапкырлык күрсәтеп.

— Мин, бикә... олуг тучи бәк, Салчак алыпка сиздермичә генә, хәзер үк... менә төн уртасында юлга чыгармын,— диде Кәлтә.

— Мин, әни, теге алып ирне таза-сау килеш синең яныңа алып кайтырмын! — диде Адай.

— Мин, әни, яудан җиңеп, бик күп байлык төяп кайтырмын! — диде Албуга.

— Ак юл сезгә, балаларым! — диде ана, ике як күкрәгенә капланган ике улының аркаларыннан сөеп.

Җиденче баб

XIV

Түрә буенча, каганның өлкән бичәсеннән туган өлкән углы уң кул тучи бәк яу вакытында уң кул чирүгә субаш булырга тиеш иде. Ләкин Туман каган бу юлы түрә белән исәпләшмәде: уң кулның җитмеш меңлек чирүен ул шикле углына ышанып тапшыра алмады. Уң кулга Туман каганның бертуган энесе Кара-Тире би җитәкчелек итте.

Чәнсине Тарлавыкка илтеп тапшыргач, Албуга Урта кичүгә көчкә килеп җитеште. Юлда тагын берәр ничек тоткарланган булса, күрәсең, аңа башы белән саубуллашырга туры килгән булыр иде.

Үзенең мең кешелек чирүе белән ул Кара-Тире би кулы астында сугышты. Кичүне чыгып, Аръяк далаларында урнашкач, Кара-Тире би аны үз янына чакырып алды. Кара-Тире би туры сүзле, тик бераз кискенрәк, тупасрак кеше иде.

— Олуг уң кул тучи бәк! — диде ул, Албугага эндәшеп.— Агам каганның сине читкә тибәрүен мин өнәп бетермим. Мин сине туры ук астына җибәрмәячәкмен. Син үзең кайда булырга телисең?

— Син кая куйсаң, мин шунда булачакмын! — диде уң кул тучи бәк Албуга, күп уйлап тормыйча.

Аның ачык җавабы бигә ошады.

— Син артта булырсың,— диде ул аңа.

— Юк, мин иң алда булырмын, Кара-Тире би! — диде Албуга, үзенә үзе каршы килеп.

— Син бер генә төрле сөйләш, олуг уң кул тучи бәк,— диде би.— Башта уйла, аннан әйтерсең.

— Мин инде уйладым: мин яуга беренче булып ташланачакмын, Кара-Тире би! — диде яшь углан, кайнарланып.— Минем батырлык күрсәтәсем, атам каганга турылыклы булуымны белдерәсем килә! Яуда дошман башын чабып алып, атам каганның

аягы астына китереп ташлыйсым килә, атам каган кулыннан буза эчәсем килә!

— Синең теләгеңне мин истә тотармын, олуг уң кул тучи бәк,— диде Кара-Тире би, аның мондый теләгенә артык куаныч белдермичә.

— Минем турыда атама яхшы яктан гына сөйлә, Кара-Тире би,— диде яшь углан.

— Мин синең сүзләреңне каганга җиткерермен,— диде Кара-Тире би.

Менә бу сөйләшү турында Албуга соңыннан кайта-кайта уйланды. Бу сөйләшүдә аңа нәрсәдер ялган булып, кирәксез булып тоелды. Кара-Тире бинең аны алдан ук, никтер, кисәтергә теләве ялган идеме, әллә соң үзенең би алдында кирәгеннән артык атлыгып торучы булып күренүе ялган идеме?

Ни булса булды, Кара-Тире би аның теләген аяк астына салмады. Ул аны туры маңгайга куйды. Яуга ул, уң кул тучи бәк, беренче булып ташланды. Ләкин аңа әллә ни батырлыклар күрсәтергә туры килмәде, шулай ук, атасы каганның аягы астына үтерелгән дошман башын китереп ташлап, аның кулыннан буза эчәргә дә насыйп булмады. Сирәк урман белән капланган калкулык янындагы куркыныч үзәнгә аның мең кешелек алае ташкын уртасындарак барып керде. Чин уклары аның кешеләре арасына килеп төшә башлаганда, аларга инде артка борылырга да, читкә чыгып, дала ягына таярга да мөмкинлек юк иде. Алар, язгы ташу агызып алып киткән чүп-чар кебек, агач ботаклары кебек, тыелгысыз рәвештә туры упкынга барып керделәр. Каршыдан, як-яктан очкан ук-сөңгеләр аның иң якын егетләрен егып салды. Куркыныч ук-сөңге иң элек Кәлтәнең атланган атына тиде, аның муенын тишеп чыкты. Кәлтә җиргә егылып калды. Икенче ук бер егетнең эчен тишеп чыкты — ул шулай ук егылып калды. Өченче ук Бавырның атын чөйлектерде. Боларның барысы да Албуганың күз алдында булып үтте. Үз егетләренең ул кинәт кычкырып җибәрүләрен ишетте, җан-фәрманга чабып барган атларыннан ычкынып-ычкынып калуларын, бозылган кызганыч йөзләрен үз күзләре белән күреп калды. Бер мәртәбә куркыныч ук аның яңагы яныннан гына ыжгырып үтте. Ул, ярсып: «Алас! Алас!» — дип кычкырып җибәрде. Шул ук мәлдә Тишек-Ташның бар көченә кычкыруын ишетеп, ул ялт кына уң ягына әйләнеп карады — куркыныч ук Тишек-Ташның күкрәгенә килеп кадалган иде, ул арты белән атыннан төшеп авып бара иде.

Үлем угы аның үзенең атына тиде. Шап итеп, атның тимерле маңгаена килеп кадалды. Ул хәтта маңгай тимереңең, маңгай сөягенең шытырдап ватылганын да ишеткәндәй булды. Бичара ат, авыртуга чыдый алмыйча, кызганыч итеп чинап, кешнәп җибәрде һәм, маңгайдагы ук тимерен селтәп алып ташларга

теләгәндәй, башын каты чайкап, кинәт тигезлеген югалтты, сөрлекте һәм, бөтен авыр гәүдәсе белән, өстендәге кешесе-ние белән, каты җиргә барып төште.

Ул егылды. Аның сул аягы атның корсагы астына туры килде. Аның яныннан, өстеннән, корсак асларын күрсәтеп, башка атлар чабып үттеләр. Аның битенә, күзенә тояклардан ычкынган каты кар, балчык кисәкләре килеп тиде. Берзаман, гөрселдәп, аның янына яралы ат килеп төште. Якында гына кычкырган, елаган, йөрәк өзгеч тавышлар белән кешнәгән авазлар ишетелде. Меңләгән тояк тавышларының каты җир күкрәгенә тибеп барабан кагулары көчле, дәһшәтле булып яңгырап торды-торды да, кинәт барысы да тынып калды.

Шуннан соң ул башка берни ишетмәде, берни күрмәде. Аның өстеннән, үле ат гәүдәләреннән дә авыррак, куркынычрак булып, ниндидер караңгылык, томан каплап алды.

XV

Күпмедер вакыт үткәч, ул айнып-уянып киткәндәй булды. Каяндыр астан, ян-яктан салкын бәрә иде, аннары өстән һаман да ниндидер зур, иләмсез нәрсә басып тора иде. Уянгач, ул үзенең кайдалыгын чамаларга тырыша башлады. Тирә-як тып-тын иде, караңгы иде. Ул капшанырга, үзенең аяк-кулларын барларга тотынды. Куллары, аяклары исән иде, тәнендә яраланган җире дә юк иде бугай, тик менә бер аягы гына нишләптер бик каты авырта сыман иде.

Үзен басып, кысып торган нәрсәне кузгатудан курыккан шикелле, ул иплән кенә, сакланып кына кыймылдый башлады. Капшана-кыймылдый торгач, ул үзенең ике ат арасына кысылып калуын аңлап алды. Атларның икесе дә инде үлгән иде, тик икесе дә әле туңып катарга өлгермәгәннәр иде. «Мин исән! Исән!» — диде ул үз-үзенә, кыргый бер куаныч белән. Ул үзенең бик күп атлар, кешеләр белән каядыр чабып баруын, егылып калуын исенә төшерде. Ләкин менә хәзер ул кайда — үзләре ягындамы, чиннар ягындамы — даладамы, елга буендамы — моны инде ул берничек тә белә алмады. Башта ук егылган төштә — далада булса, никтер, аңа һаман да якында гына коточкыч тавыш, шау-шу ишетелеп торырга тиеш кебек тоелды.

Ул кыймылдаудан, каядыр чыгарга азапланудан туктап уйлаштыра башлады. Әгәр дә мәгәр алар җиңгән булсалар, аны бу килеш калдырмаслар иде. Аны барыбер эзләрләр, табарлар иде. Эзләмәскә, тапмаска аларның хаклары юк! Кая аның ышанычлы егетләре, кая аның коралды ирләре?

Аның кычкырасы килде. Ләкин, ике ат гәүдәсе арасына кысылган килеш, ул берничек тә кычкыра алмады. Ярсып, ул яңадан кыймылдарга, каядыр шуышырга тотынды. Һәм өзәңгедә

килеш ат астында калган сул аягын көч-хәл белән тартып чыгарды да хәрәкәтен тоткарлаган ук-җәя савытларының каешларын ычкындырды. Бушанып, җиңеләеп һәм терсәкләре белән эткәләп-төрткәләп, ул, кыймылдый-кыймылдый, ниндидер ачыграк урынга килеп чыкты. Иркенләп, күп итеп, ул тын алды һәм сагаеп тыңлап тора башлады.

Бик якында гына ниндидер ыңгырашкан, шыңшыган, хәтта кычкырган тавышлар ишетеп, ул аптырагандай итте. Бу ни бу?!

Ул моның ни икәнлеген ачыклый алмады — кайдадыр якында, бик якында ашыгып пышылдашкан икенче төрле тавышлар ишетелеп китте. Ул әлеге пышылдашучыларның кайдалыгын да чамалый алды, тик аларның ни сөйләгәннәрен генә аңлый алмады. Алар ниндидер ят телдә пышылдашалар иде! Алар, ахрысы, чин кешеләре иде! Әйе, ыңгырашмый торган, сызланмый, кычкырмый торган ул таза кешеләр монда бары чиннар гына булырга мөмкин иде.

Әле генә гөлт итеп кабынган сөенеч тойгысы, гөлт итеп, шундук юкка да чыкты. Димәк, чиннар җиңгән. Димәк, ул чиннар ягында калган.

Ул кинәт тынып калды. Кычкыру, кемне дә булса ярдәмгә чакыру уе үзеннән-үзе истән чыкты. Инде нишләргә? Шушында ат үләксәләре арасында кысылып калган килеш мәңге юкка чыгаргамы, әллә соң, таң атканчы, берәр ничек качып котылыргамы? Кая, ничек качарга?

Ул берни дә уйлап таба алмады, кузгалырга, тын алырга куркып, һаман тып-тын ята бирде. Ләкин аңа кинәт болай хәрәкәтсез яту үлем белән бер булып тоелды. Ул яңадан каядыр үрмәли, шуыша башлады һәм искәрмәстән үле ат гәүдәләре өстенә килеп чыкты.

Кышкы төн серле һәм караңгы иде. Бик еракта, кара-кучкылланып торган төпсез күктә, кар бөртекләредәй генә булып, йолдызлар җемелдәшә иде, кар бөртекләредәй җемелдәшкән йолдызлар арасында сызылып кына чыккан яңа ай балкып күренә иде. Яңа ай, яшь, көчле ай. Сөннәрнең атасы, сөннәрнең алласы... Менә ул — аның улы Албуга, уң кул тучи бәк — дошман ягында ат үләксәләре арасында җирдә аунап ята. Нишләп бер көнгә иртәрәк чыкмадың соң, Тәңрем, Атам?

Әйе, ул менә дошман ягында. Чин ягында. Моңа әле ышанасы да килми, ләкин моңа ышанмый да булмый. Чиннарның явызлыгы, кансызлыгы турында аның күп нәрсәләр ишеткәне бар. Үз кулларына төшкән «ху»ларны алар йә кол итәләр, йә терелә́й җиргә күмәләр, йә булмаса, текә яр янына китереп, чүпчар түккән кебек, шаулап аккан елгага коялар дип сөйлиләр.

Тәңрем, олуг Атам! Нишләтерләр алар мине? Мине терелә́й җиргә күмәрләрме, шаулап аккан елгага ташларлармы әллә соң,

бакыр ташы, тоз ташы казырга дип, кеше кире кайтмый торган тау-таш араларына озатырлармы? Мине... синең изге углыңны шулай җиңел генә юкка чыгарырлармы? Мөмкинме бу, олуг Тәңрем? Минем анда — туган даламда — изге анам калды, Алтын-Бөртек бичәм, туганнарым калды. Анда минем җирем-суым, анда минем илем-көнем. Шушы яшьтән мине үз яныңа алып, син аларны ятим калдырырсыңмыни?! Коткар мине бу тозактан, Тәңрем!

Күңеленнән шулай ялваргач, ул үзендә көч артуын тойды һәм тагын бер мәртәбә омтылыш ясап карарга булды. Аягының авыртуын онытырга тырышып, ниндидер үле гәүдәләргә, җансыз аякларга басып, ул ары үрмәләде. Якында гына тагын да чит телдә пышылдашып сөйләшкән тавышлар ишетелеп китте. Болар мәет талап йөрүче угрылар иде, ахрысы.

Ат, кеше мәетләре өстенә менеп баскан бер кешене алар күрмәделәр бугай. Ләкин Албуга үзе аларның, күсәк белән сугып, бер яралыны үтергәннәрен аермачык күреп калды. Куркып, ул яңадан мәетләр арасына егылды. Бераз тыңлап, тынып ятты да, канга сусаган чүл бүреләре сыман иснәнеп, капшанып йөргән шикле бәндәләрдән ерагаерга тырышып, түше белән читкә шуыша башлады. Уң кулына ул мәетләр арасында тапкан саллы, яхшы сөңге тотты, сул кулына билендәге хәнҗәрен алды. «Башка күсәк белән китереп тондырганны көтеп ятмыйбыз әле!» — диде ул үзенә үзе, күңелен күтәреп...

ИКЕНЧЕ КИТАП

Икенче баб

X

Кышкы кояш, караңгы җир астыннан чыгып, бар далага салкын яктылыгын тараткач та, Кортка-бикә авылында көндәгечә тормыш башланды. Көтүчеләр терлекләрен кудылар, учакларда утлар тергезелде, казаннар асылды.

Шулай ашыкмыйча гына, сүлпән генә яшәп ятканда, бөтенләй уйламаганда, көньяктагы тәбәнәк калкулыклар арасыннан ниндидер атлылар килеп чыкты. Шул тирәдәге көтүчеләр аларның кем икәнлекләрен белергә тырышкан арада, шундый ук атлылар көнчыгыш якта да күренде. Көньяктан килүчеләр дә, көнчыгыштан килүчеләр дә нишләптер бик ашыгалар һәм ничек тә тизрәк Кортка-бикә авылына килеп җитәргә тырышалар иде сыман.

Күп тә үтмәде, атлы сугышчылар төньяк калкулыклар арасында да күренә башладылар. Ныгытып карый торгач, Кортка-бикәнең көтүчеләре танып алдылар: болар чиннар иде. Алар, күрәсең, Кортка-бикә авылын төнлә төрле яктан уратып алганнар һәм хәзер менә, барысы бергә кузгалып, сөннәргә якынлашып киләләр иде. Чиннарның килүен ачык даладагы яисә калкулык

өстендәге ирләр генә түгел, Кортка-бикә авылындагы кешеләр дә күреп алдылар. Барысы да, эшләрен-шөгыльләрен ташлап, тышка йөгереп чыктылар, төркем-төркем булып бер тирәгәрәк җыелдылар. Берәүләр, яхшырак күрмәкче булып, арба өсләренә менделәр, икенчеләре булган коралларына тотынды, өченчеләре, атка атланып, иң кирәк нәрсәсен эләктереп, беркем күренмәгән көнбатыш якка таба качып китте. Ул якка китүчеләр шактый күп булып чыкты. Ләкин алар әллә ни ерак китә алмадылар, кырт борылып, кире авылга таба ашыктылар. Көнбатыш яктан да кара болыт булып чиннар килә иде.

Кортка-бикәнең рәтләп коралланмаган, таркау һәм аз санлы чирүен чиннар җиңел генә туздырып ташладылар; берәүләрен ук-сөңге белән юк иттеләр, икенче берәүләрен атлары белән таптап үттеләр. Һәм шулай, бернинди каршылыкка очрамыйча, Кортка-бикә авылына, биек киез өй янына килеп тә җиттеләр. Кортка-бикәне һәм аның янындагы баерак, дәрәҗәлерәк ирләрне, хатын-кызларны җылы өйләреннән салкын тышка өстерәп алып чыктылар; кешеләрнең баш киемнәрен, аяк киемнәрен йолкып алып, кар өстенә бастырдылар.

Ментйәнгә Туман каган кирәк иде. Кар өстенә тезеп бастырылган кешеләрдән ул каганны таптырды. Кар өстендәге кешеләрнең берсе дә берни әйтә алмады. Ментйән кешеләре кулга төшкән башкалардан да сорау алдылар. Барысы да бер үк сүзне әйттеләр, каган яуда, ул кайтмады, диделәр.

Ментйән ышанмыйча булдыра алмады. Моннан бер-ике көн элек әсир төшкән хуннар да шул ук сүзне сөйләгәннәр иде. Ул чагында Ментйән ышанмаган иде. Каганны ул, һичшиксез, үзенең кышкы урдасында, Сары су буенда булырга тиеш дип исәпләгән иде. Туман каганның әле булса тоттырмыйча качып йөрүенә аның бик нык ачуы килде. Кортка-бикәнең каган анасы булуын белгәч, шулай да аңарда канәгатьләнү сыман бер тойгы барлыкка килде. Димәк, азапланып шушында кадәр килү бөтенләй үк бушка булмаган!

Кулга төшкән ирләрне, картларны, балаларны Ментйән бернинди кызганусыз юк итәргә боерды. Яшьрәк хатын-кызлар турында сүз чыккач, чиннарның субашы икеләнгәндәй итте... Яуда әле беркайчан да беркемнең дә хатын-кызны үтергәне юк иде.

— Миңа кызлар, хатыннар кирәкми — каган кирәк! — диде Ментйән хатын-кыз турында сүз кузгатырга батырчылык иткән чин иренә.

Шихуандинең даланы яуларга җибәргән атаклы сугышчысы бары терлек-туарны гына исән калдырырга боерды — шәрә, туң, ач далада аның үзенә һәм ирләренә азык... бик күп азык кирәк иде!

Кортка-бикәнең авылын талап-яндырып, кешеләрен үтереп һәм терлекләрен азыкка әйләндереп, бик нык арыган гаскәренә

Ментйән өч көнлек ял бирде. Ул инде үзе дә бу далада туктаусыз килеп арыган һәм йончылган иде. Түгәрәк өй уртасындагы учак каршысына иркенләп утырган килеш, ефәккә һәм затлы, йомшак тиреләргә төренгән килеш, тәненә һәм күңеленә бераз ял бирмәкче булып, ул күзләрен генә йомган иде, шул чакны яңа хәбәр китерделәр. Моннан ярты көнлек ераклыкта, боз тоткан елга буенда, калку тау башында каганның изге корылмасы бар, диделәр.

— Яндырыгыз,— диде Ментйән, йомылган күз кабакларын ачып карамыйча гына.

Моңарчы ул далада бернинди таш, агач өй, сарай ише нәрсә күрмәде. Ярым йокылы хәлендә ул Чиндагы гүзәл сарайларны, андагы якын, ягымлы кешеләрне, тәмле, кайнар ашамлыкларны күреп утыра иде. Изге корылма? Каган корылмасы? Нинди-рәк икән ул? Нәрсәгә һәм ничек табына икән каган?

Әлегә ул Кортка-бикәне үтермәгән иде. Ул аны үзе белән алып китәргә һәм, алай-болай Туман каган белән очрашырга туры килсә, Кортка-бикәнең үзендә икәнлеген әйтеп, мондый нәрсәдән берәр төрле файда күрергә мөмкин булыр диеп уйлаштыра иде. Анасы белән улын бергә җәзалаганда яисә, әсир итеп, икесен дә башкалага алып кайтканда да, начар булмаячак иде.

Туман каганның тау башындагы изге корылмасы турында ишеткәч, Ментйән әлеге уеннан кире кайтты. Аягында көчкә басып торган картканы үзең белән йөртүдән, күрәсең, әллә ни мәгънә чыкмас, дип уйлады ул. Шул ук көнне Ментйән сөннәрнең изге тавына китте. Тау башына аны бамбук колгалар өстенә беркетелгән утыргычында утырып торган килеш күтәреп менделәр. Тау башында ул җиргә төште һәм, ефәк белән тышланган озын тун чабуларына төренеп, сөннәрнең изге корылмалары тирәли әйләнеп чыкты, аның эченә керде, игътибарсыз гына җир идәнгә, корымланган бүрәнәләргә күз төшереп алды. Түбәндә җил басылган булса да, монда ул шактый көчле иде. Кышкы ачы җил озын җиң очларыннан, җылы чабу араларыннан үтеп керде, биткә-күзгә бәрде һәм тиешенчә капланмаган колакларны чеметеп-чеметеп алды. Суык иде, күңелсез һәм пыксыз иде Ментйәнгә монда — сөннәрнең Изге тауларында.

Ул шулай, артык исе китмичә, ялгыз бураны һәм тау башын карап чыкты да түбәсе ябулы утыргычына кереп утырды.

Сөннәрнең изге бураларын яндыру өчен, чиннар тау башына күп итеп коры камыш, чыбык-чабык ташып куйганнар иде. Ментйән, кул изәп, «башларга» дигән боерык биргәч тә, бура тирәли чыбык-чабык, камыш өяргә тотындылар. Барысы да әзер булгач, коры камышка ут төрттеләр. Күп тә үтмәде, Изге тауда, ялкынланып, кара төтеннәр чыгарып, бик зур учак яна башлады. Һәр елны изге корбан вакытында ялкынланып янган кебек,

Сөн баба мәңге йокыга талган биек тау башында, дәртләнеп, Ут-ана биеде.

Ментйән белән бергә Изге тауга Кортка-бикәне дә алып килгәннәр иде. Учак кызгач, Кортка-бикәне чиннар утка якынрак китерделәр һәм ялкын эченә ыргытмакчы булдылар. Ләкин чиннар тотып алганчы, ул аларны селтәп җибәрде дә бар көченә кычкырып, калтыранып көләргә тотынды. Чиннар каушабрак калдылар һәм, «бу ни булды?» дигән сыман, бер-берсенә карашып алдылар.

— Ут-ана! Ут-ана! — дип кычкырды Кортка-бикә һәм, агарган сыек чәчләрен җилфердәтеп, сөякчел кулларын югары күтәреп, батырларча утка ыргылды.

Сөенеп, тилереп кычкыруыннан туктамыйча, ул, чандыр гәүдәсен төз тотып, туп-туры ут авызына барып керде. Яланаяклары белән утлы кузларга басып, ул изге бура уртасындагы изге кылычка таба атлады. Аның киемнәренә ут капты, чәчләрен ялкын чорнап алды һәм шаулап янган ут тавышында аның кычкыруы кинәт өзелеп калды. Ут-ялкын белән уратып алынган килеш, ул әкрен генә урталай бөгелә башлады һәм барысының күз алдында учак уртасына йөзтүбән капланып төште.

Чиннар шаккаттылар. Түбәсе ябулы утыргычының тар ярыгыннан карап торган Ментйән телсез калды. Шул чакны аның күңеленә: «Мондый куркусыз халыкны җиңү мөмкин түгел»,— дигән күңелсез уй килде.

Алтынчы баб

XIX

Аръякта чиннар белән канлы сугыш вакытында юкка чыгуына өч ел тулып дүртенчегә киткәндә, җәй башында, көтмәгәндә тәгин углан Албуга кайтып төште.

Бу вакытта каган иле, Урта җир даласын үтеп, Сары су буена якынлашып килә иде. Урда торгаклары биек Ак өйгә юлбасарга охшаган ниндидер берәүне алып килделәр. Өстенә ул эт тиресеннәнме, бүре тиресеннәнме тегелгән һәм керләнеп беткән киндер тышлы кыска тун, башына шулай ук ниндидер ят бүрек кигән иде. Үзен ул Кәлтә дип белдерде һәм: «Мине монда тәгин углан Албуга җибәрде»,— диде. Торгаклар арасында Кәлтә дигән кешене белгән-ишеткән кеше табылмады. Аны шулай ук каган да хәтерләмәде. Ләкин, «Албуга» исемен ишетү белән, ата кеше сискәнеп китте.

— Албуга?! Исәнмени ул?! — диде каган, исе китеп, хәтта коты алынып.

— Исән,— диде Кәлтә.

Каганга ул, кыска гына итеп, Албуга турында, үзләренең Чинда бөлгенлектә булулары, качулары турында сөйләп бирде.

Боз тоткан олы елга аша алар исән-имин дала ягына чыктылар, озын текә ярдан өскә менделәр. Алар алдан ук уйлап, куркып килгән төштә әллә ни куркыныч булмады — койма өю эшләре чынлыкта инде туктап калган иде. Тиешенчә өелеп җитмәгән койма тирәсендә чин сакчылары да, чин каралары да юк иде. Алар инде кайсы кая таралышып беткәннәр иде, ахрысы. Тик шулай да коймага якын җирләрдә зур-зур авыллар торып калган иде. Менә шул бушап калган ташландык авылларда, кышкы куышларда, җиргә казып кергән базларда җан асрап яткан берән-сәрән кешеләр очрады да, калдык-постык иснәнеп йөргән, кыргыйлашып беткән ач этләр очрады.

Чикне алар бик җиңел үттеләр. Авыры далада, туган якта булды. Шулай бик җиңел котылуларына сөенеп, аны-моны уйламыйча барганда, көтмәгәндә далада ниндидер ят көтүләр, ят авыллар очрый башлады. Якынрак килеп карагач, бу ят кешеләр бөтенләй икенче телдә сөйләшүче, икенче төрле кыяфәттәге кешеләр булып чыкты. Болар Сөннән көнбатышта, чүлләр, таулар арасында яшәп ятучы йуечиләр иде. Берни булмагандай иркенләп, алар Сөн җирендә көтү көтәләр иде. Бик гаҗәп иде бу. Ялгышып кергәннәрме соң алар Сөн җиренә, әллә... басып алганнармы?

Беренче очрашуда алар йуечиләрнең берсен калдырмый кырып салдылар. Шуннан соң күп итеп ит суйдылар, ит пешерделәр һәм, туйганчы ашап-эчеп, үз җирләрендә, тик үзләренеке булмаган өйләрдә беренче төннәрен уздырмакчы булдылар. Ләкин аларга тынычлап йокларга туры килмәде. Караңгыда аларны күп санлы йуечиләр чолгап алды. Алар көчкә качып котылдылар. Йөз кешенең бик күбесе төнге сугышта, далада ятып калды.

Моннан соң алар саграк булдылар һәм, Чин ягындагы кебек кача-поса, бары төнлә генә хәрәкәтләнделәр. Алар хәзер чиннар өйгән Озын коймага якынрак килделәр, көтүләр, өйләр, кешеләр күренү белән, шундук читкә тайпылдылар.

Бик кызык булды бу. Еллар буена алар иреккә, далага омтылдылар, котылдылар һәм яңадан күзгә күренмәгән ниндидер коллыкка төштеләр. Таулар арасында өч өйлек бер авылга килеп төртелгәч, барысы да аңлашылды. Авыл сөннәрнеке иде. Ала тау, Җылан тау буйларына моннан ике ел элек үк инде йуечиләр басып кергән икән. Алар хәзер көчәйгән. Әкренләп-әкренләп, алар сөннәрне һаман көнчыгышка таба, төньякка таба кысрыклыйлар икән. Ләкин көнчыгышта да эшләр шәптән түгел икән — Диңгез-күл буйларыннан алып Байык буйларына кадәр булган җирләрне дунхулар басып алган икән.

— Бетте Сөн.

— Бер яктан берсе кимерә, икенче яктан икенчесе кимерә Сөнне.

— Бүген килеп үтерәләрме, иртәгә килеп үтерәләрме дип, кан калтырап торабыз.

— Безне яклардык беркем калмады Сөндә.

— Өмет киселде,— диештеләр каралар, кайгыга бирелеп.

— Мин кайттым! Ишетәсезме, мин — тәгин углан! — дип кычкырды Албуга караларга, ярсып.— Күтәрегез башларыгызны. Сез бит — сөннәр! Ягы алдында коелып төшәргә сез сарык түгел, сез — курку белмәс ирләр!

Очраган бер җирдә ул шундыйрак сүзләр әйтте. Һәм ничек тә кешеләрнең күңелләрен күтәрергә тырышты. Ләкин атасы Туман каган урдасына якынайгач, ул йуечиләрдән коты алынган каралардан ким каушамады.

Ничек каршылар аны атасы каган? Очрашырга теләрме читкә тибәрелгән улы белән? Урдадан бер җирдә әле дә дүрт якка дүрт курчагын күмдерә микән аның? Күмдерсә, ничек үтәргә ул серле чикне? Теге алып ир аңа әйткән иде: җиргә күмелгән курчакларның көчен бетерү өчен, дүрт үлемне җиңәргә кирәк дигән иде. Җиңде микән соң ул дүрт үлемне, әллә соң дүртне генә түгел, инде кырык үлемне дә җиңде микән?

Каган урдасына җитәргә өч-дүрт чакрым калгач, ул шулай да алдан Кәлтәне җибәрде. Иртән иртүк киткән Кәлтә төшкә таба кире әйләнеп килде.

— Атаң Туман каган сине үз янына чакыра, олуг тучи бәк тәгин углан,— диде ул, куанычыннан авызын җыя алмыйча.

XX

Атасы Туман каган Албугага бик нык картайган һәм симерә башлаган булып күренде. Аннан соң ул, ничектер, юашланып, хәтта мескенләнеп калган кебек иде. Төсендә-битендә, үз-үзен тотышында, сүзләрендә аның элекке олылыкның, үз-үзенә ышаныч һәм горурлыкның эзе дә юк иде.

Бусагадан атлау белән, Албуга, тезләнеп, атасына буйсыну белдерде. Туман каган, ашыгып, кулларын җәеп, улына таба атлады. Ул аны чын күңелдән яратып, сөенеп кочагына алды; аның ныклыгын, тазалыгын белергә теләгән шикелле, беләкләрен, кулбашларын тоткалап карады, йөзенә-күзенә карады һәм, тыела алмыйча, күз яшьләрен агызып алды.

— Улым! — диде ул.— Мин сине көттем. Кайтырыңа ышанып көттем.

— Мине дә ышаныч алып кайтты, эти,— диде Албуга.— Мин дә сиңа, илемә-көнемә изге ышанычымны саклап кайттым. Туптуры сиңа кайттым. Нишләтсәң дә, синең ихтыярың.

Алар шулай кочаклашып, елашып торган арада, биек чаршау артыннан яшь бала күтәргән бер хатын килеп чыкты. Кыю гына атлап, ата белән ул янына килде. Албуга аны беренче күрүдә үк таныды. Бу, әлбәттә, кайчандыр ул яраткан чин карасы Сөенеч иде. Ләкин шул ук вакытта ул инде бөтенләй икенче кеше иде,

ул бик нык үзгәргән, тулыланып, чибәрләнеп киткән. Элекке тартыну-кысылуның, киреәксез тәкәбберлекнең һәм әрсезлекнең эзе дә калмаган. Үз-үзен ул бикәләрчә иркен, җиңел һәм кыю тота. Аякларын ышанып, нык-нык басып атлый. Аңарда шулай ук яшьлек, гүзәллек һәм теләсә нинди ир кешене кабып йотарга хәленнән килә торган яшерен көч ташып тора иде.

Албуга аңа туры карамаска тырышты. Шулай да аларның күз карашлары очрашты, һәм шундук икесенә дә, ничектер, уңайсыз булгандай булды.

— Бу синең үги әниең Сөенеч бикә, улым,— диде Туман каган, яшь хатын тәхет янына килеп туктагач.— Буйсыну белдер аңа, улым.

Албуганың йөзенә кинәт кайнар кан бәрде, күзен элпә томалап алды. «Сөенеч — бикә!» — диде ул үзалдына, исе китеп. Ләкин шул ук вакытта ул икенче бернәрсәне дә шәйләп өлгерде: дөньяда үлемнең әле менә мондые да — кояштай балкып, сихри нур таратып торган таныш чибәр хатын төслесе дә була икән! Ихтимал, җир астына күмелгән курчакларның серле чиген үтеп чыкса да, аңа әле үлемнең менә монысын да җиңәргә кирәк иде, ахрысы.

Ул аны җиңде. Йөзендәге үзгәрешне атасы каганга күрсәтмәс өчен, башын шундук түбән иде, ике аягы белән тезләнде дә Сөенеч бикәнең ир кешене үчекли торган җиңел, хуш исле озын күлмәк итәгенә кулын, иренен тидерде.

— Үги анам... Сөенеч бикә,— диде ул, ишетелер-ишетелмәс мыгырданып.

Атасы Туман каган аны, кулыннан тотып, аягүрә бастырды. Сөенеч бикә, елмаеп, улы белән сөйләнгәләп, аны ике куллап биек урынга утыртты. Шуннан соң ул баланың артына чыкты, аны биленнән тотып алды, чак-чак кына көлемсерәгән килеш, үзенең үги улы Албугага күтәрелеп карады. Матур ирен читләрендә, чак-чак кысылган, очкынланып торган сөрмәле күз карашында аның Албуга улына карата мыскылмы, кызганумы бар сыман тоелды.

— Улым, Албуга,— диде ата кеше, тыгыз тәнле алып улына эндәшеп.— Без синең исәнлегеңне белмәдек. Ил-көн белән, агай-эне белән киңәшеп, Сөенеч бикәнең Өлешле углын уң кул тәгин углан дип таныдык. Аңа да буйсыну белдер, улым.

Албуга мондый нәрсә көтмәгән иде. Мондый нәрсәнең булуын башына да китереп карамаган иде! Аның бурлаттай кызарынган йөзе агарынып калды, аннары яңадан бит очында тимгел-тимгел кызыл таплар калкып чыкты. Колак төбе шаулады, һәм ул, берни аңламыйча, әле атасына, әле балага карады. Таза ир бала, кулларын, аякларын бутап, кычкырып, идәнгә төшмәкче булды.

Сөенеч бикә бер сүз әйтмичә, сөрмәле матур күзләрен кысыштырып, көлемсерәп, тыныч кына көтеп торды. Сул күз

кабагы үзеннән-үзе тартыша башлаган ата кеше шулай ук көтеп торды. Албуга, тез буыннары хәлсезләнгәнен тоеп, түбән чүкте. Калтыранган куллары белән ул оятлы йөзен каплады һәм идәнгә бала алдына егылды. «Монысы нинди үлем икән, ничәнче үлем икән?» — дип уйлады ул үзалдына һәм, ярдәм эзләгәндәй, куенындагы бөтиен исенә төшерде. Бөтине учына алмакчы булып, ул кулын әкрен генә түшенә таба шудырды.

Аның бу хәрәкәтен күреп, Сөенеч бикә җиңелчә генә кычкырып җибәрде һәм баланы җилтерәтеп алды да тиз генә читкә тайпылды. Туман каган да дерт итеп китте, ләкин, бернинди куркыныч нәрсә юклыгын күреп, тиз арада тынычлана төште.

Албуга үзе үги әнисенең кычкыруын ишетмәде дә, ахрысы. Куеныннан бөтиен алып, аңа карап торгандай итте дә:

— Менә шул алып кайтты инде мине, эти,— диде.

Ата кеше җиңел сулап куйды. Сөенеч бикә дә үзенең ялгышуын аңлап елмайгандай итте һәм, улын күтәреп, чаршау артына китеп барды. Туман каган, баягыча кулын сузып, Албуганы аягына бастырды.

— Мин синең әниең Күрекле бикәне кичердем, урдага күченеп килергә куштым, улым,— диде ул.— Әниең килмәде. Өлкән улым кайтмыйча торып, мин анда күченә алмыйм, дигән. Мин каршы килмәдем. Менә син кайттың. Инде әниеңә күрен, ул да сөенсен. Ул хәзер Елдырым бәк җирендә. Теләсә, минем янга алып килерсең, теләмәсә, синең белән торыр.

— Мин үзем кайда торырмын икән соң, олуг каган? — диде Албуга.

— Мин барысын да уйладым, улым,— диде ата кеше.— Мин синең батырлыгыңа сокландым. Син минем иң турылыклы улым булып чыктың. Мин сине үземнең төмән бәгем итеп билгеләрмен, ил-көн, җир бирермен.

— Эти! — диде Албуга, яратып, күңеле нечкәреп.

— Минем үземә төньяк җирләр ныграк ошый,— диде Туман каган.— Моннан соң мин Табын үзәне якларында калырмын. Син монда, көньяк тау буйларында, Сары суга якын җирләрдә яшәрсең. Килештекме, улым?

— Килештек, эти! — диде Албуга, сөенеп.

Җиденче баб

I

Күрекле бикәнең уртанчы улы Адайны сул кул углан дип таныгач, Туман каган аны, өйләндереп, ил-көн, җир-су биреп, көнбатышка күчерде. Адайның җирләре йуечиләр басып алган Сөн җирләренә чиктәш иде. Адайның бөтен көче ун-унике меңнән артмады. Шулай да ул әледән-әле яу белән килгән һәм

елдан-ел оятсызлана барган йуечиләргә каршы нык торды. Йуечиләрнең үз биләмәсенә аяк баскан вак-төяк алайларын, барымтага килгән һәртөрле юлбасарларын юкка чыгара торды. Тик шулай да әлегә ул үзе бар көче белән йуечиләргә каршы яуга чыгарга батырчылык итмәде. Ул үзен әлегә чын-чынлап сугыш остасы итеп сизә алмады, аннары үзенең көче аз булуын да танырга мәҗбүр булды.

Туман каган сул кул углының өлгерлеген, чыдамлыгын һәм дошманга каршы нык торуын күреп алды. Көнбатыш җирләрен саклау өчен, ул Адайдан да кулайрак кешене эзләсә дә таба алмас иде, күрәсең. Ләкин аңа хәзер көнбатышны гына түгел, көнчыгышны да теше-тырнагы белән сакларга кирәк иде. Дунхулар, Сөн җирләрен тартып алып, анда урнашып кына калмаганнар, кыюланып, яңа җирләргә, көтүлекләргә үтеп керә башлаганнар иде. Һәм аларның Сөн ягына чыгулары, чик буе авылларына, җәйләүләренә басып керүләре турында моңлы-зарлы хәбәрләр килеп кенә тора иде.

Менә шуларның барысын да уйлап, Туман каган үзенең Сары су буйларындагы, Диңгез-күлгә якын җирләрдәге бай көтүлекләрен Албуга улына бирергә булды да. Дунхулар, барыннан да бигрәк, менә шул җирләргә омтылалар иде. Үз җире, үз биләмәсе булгач, Адай кебек үк тырышып сакламас микәнни аның Албуга улы көньяк җирләрне? Саклар, сакларга тиеш. Үз биләмәсен саклап, ул, билгеле, атасы Туман каганны да, бөтен Сөн илен дә саклаячак. Инде анасы Күрекле бикәне дә үз янына ала икән, үз җирләре аңа икеләтә-өчләтә кадерле булачак.

Туман каганның күңелендә, билгеле, башка төрле уйлары да бар иде. Албуганы ул турыдан-туры үз кулы астындагы түмән бәге генә итеп билгеләде. Дәрәҗәсе буенча ул Сөенеч бикәнең бердәнбер улы — уң кул тәгин углан Өлешледән дә, сул кул углан Адайдан да түбәнрәк иде. Атасы Туман каган, зур җыен җыеп, ыру башлары белән киңәшләшмичә дә, теләсә, аны түмән бәгеннән дә түбәнрәк төшерә ала яисә, киресенчә, аннан да югарырак күтәрә ала иде. Тагын да югарырак күтәрә-нитә калганда, ул аны субашы итеп билгели ала иде.

Үзенең язмышындагы бу кадәр кискен борылышларны, үзгәрешләрне Албуга әлегә тиешенчә төшенеп тә җитә алмады. Ул үзенең исән-имин далага, туган җиренә кайтуына, каган урдасына бернинди каршылыксыз диярлек үтеп керүенә сөенмичә булдыра алмады. Аннан соң ул үзенең җирле-сулы булуына да, көньяк җирләрдә яшәргә тиешлегенә дә сөенде. Ләкин шул ук вакытта аның бу сөенечләре бик үк тулы да булмады. Аның әле күп нәрсәгә эче пошты. Барыннан да бигрәк, аның атасы Туман каганның үзен әле булса якын итмәвенә, чин карасы Сөенечнең бикә булып, биек өйдә түшен киереп йөрүенә һәм яңа

аягына басып йөри башлаган баланың тәгин углан була алуына эче пошты.

Тагын шунысына да күңеле тырналды Албуганың: аның кайтуын котлап, атасы Туман каган биек Ак өйдә аш-су да ясамады, зурлап, җыен да җыймады, корбан биреп, бүләкләр дә таратмады. Дөрес, ул аның, юлдашларының тамагын туйдырды, киемнәрен алыштырырга боерды һәм икенче көнне үк аның эшен карачыларга тапшырды. Карачылар аңа теңлек-туар, илкөн бүлеп, санап бирергә, аңа тиешле җирнең-суның чикләрен билгеләргә тиешләр иде.

Бер ун көн чамасы каган урдасында булгач, төмән бәге Албуга, үзенә бирелгән көтүләрен, илен-көнен алып, атасыннан башкаланып аерылып чыкты һәм күрсәтелгән җиргә — Сары су буендагы таулар ягына күченеп китте.

VI

Бер-ике көннән Албуга, Бавырны, Җидекулны алып, Яман саз ягына юнәлде. Төмән бәге Албуганы Җидекул Кызыл кыя үзәненә, этисе Иммәт авылына алып барды. Үзара киңәшкәч, алар Албуга ары бармаска тиеш дигән карарга килделәр. Иммәт карт авылыннан читтә, аулак бер болында, аерым өй кордылар. Булгак алыпны алырга Йәке китте.

Булгак алып белән Албуга аулак болынга корылган ялгыз өйдә очраштылар. Албуга ялгыз өйдә берүзе күңелсезләнеп утыра иде. Кинәт ишек ачылып китте, һәм өй эченә, ашыгып, кемдер килеп керде.

— Улым! — диде зур гәүдәле, көчле куллы кеше, аны кочагына алып.

Албуга элек тә үзенең аңа карата «улым» булуын сизенә иде, ләкин аның үз авызыннан чыккан мондый сүзгә ул гаҗәпсенеп калды. Ләкин мондый сүз ишетү бик күңелле иде. Беркайчан да аның шундый ягымлы итеп, яратып әйтелгән сүзне ишеткәне булмагандыр сыман тоелды. Бит ул беркайчан диярлек ата кеше иркәләвен тоймады. Ул бары әнисен генә белде, әнисен генә якын күрде. Әйе, бала вакытында да, үсмер вакытында да ул читтән генә күреп була торган бөек каган атасын түгел, менә шушы бераз шадрарак, тупасрак, көчле атасын күрәсе, аның иркәләвен тоясы килеп сагышланды.

— Улым! — диде зур кеше, кабатлап.

Ул аны кочагыннан чыгарды да, яратып, җентекләп, аның йөзенә карады. Шул ук вакытта Албуга да башын калкытты, һәм ул да, сынап, аның йөзенә карады. Аның бөтен бите төрткетөртке кара бизәкләр белән капланган иде.

— Әти...— диде ул.

Беренче «әти» көчсезрәк, кыюсызрак чыкты, тик шулай да ул чыкты һәм, бизәкле кешенең йөзенә бәрелеп, кире аның үз йөрәгенә керде.

— Моннан соң мин сиңа гел шулай «әти» дип әйтермен, иеме, әти? — диде ул бераздан.

— Синең «әти» дип эндәшүең күңелемә сары май булып ята, улым,— диде ата кеше, елмаеп.

— Минем өчен дә шулай, әти,— диде углан.

Беренче очрашу, күрешү шатлыгы кимегәндәй булгач, Булгак алып тавышын әкренәйтә төште.

— Без моны икебез генә белергә тиешбез, улым,— диде ул.

— Әни дә белмәскә тиешме? — диде Албуга, ашыгыбрак.

Булгак алып елмаеп куйды.

— Без моны өчебез генә белербез,— диде ул,— башкалар алдында мин сиңа — Булгак алып, син миңа — уң кул тәгин углан!

— Мин инде уң кул тәгин углан түгел шул,— диде Албуга.

— Син тумыштан уң кул тәгин углан! — диде әтисе.— Син — Туман каганның беренче бичәсе Күрекле бикәнең өлкән улы. Күк улы!

VII

Үз җәйләвенә Албуга очынып, канатланып кайтты. Аның өчен хәзер бер генә аңлашылмаган нәрсә дә калмады. Үзендә ул искиткеч бер көч-куәт ташыганын тойды.

Беренче адымыннан ук ялгышмас өчен, ул аерылышыр алдыннан әтисен үзе янына чакырды.

— Карап-күзәтеп торырсың, булышырсың, төзәтерсең,— диде ул аңа.

— Карап-күзәтеп, төзәтеп торсам, мин сиңа бары тышау гына булырмын, улым,— диде Булгак алып.— Бик-бик кирәк булсам, кеше җибәрерсең.

Албуга кыстап тормады. Әтисе үзе белән шулай ачылып, иркенләп сөйләшсә дә, башкаларга аның бик үк күренәсе килмәгәнлеген ул сизми калмады. Ул әле үзенең буялган, бизәлгән йөзеннән дә, гариплегеннән дә тартына иде бугай. Аннан соң аның, бәлки, яңадан Туман каганга да, Күрекле бикәгә дә күренәсе килмәгәндер. Ни генә булмасын, алар аерылыштылар. Һәм аларның аерылышулары да бик сәер генә булды. Ялгыз өйдә алар ике-өч көнне сөйләшеп уздырдылар. Албуга үзенең әсирлектә күргәннәрен сөйләде, Булгак алып элекке яуларны исенә төшерде. Соңгы төнне алар бөтенләй диярлек йокламадылар һәм, бары тик таң беленә башлаганда гына, тышка чыгып, атларына, кешеләренә күз ташлап керделәр дә башларын мендәргә терәгәндәй иттеләр. Албуга шундук йокыга талды. Булгак алып исә шыпырт кына яңадан тышка чыкты да, саубуллашып та тормыйча, үз аланына кайтып китте.

Көн туып, кояш кыздыра башлаганда, Албуга да Сары су ягына кузгалды. Кайтып җиту белән, ул йөз кеше сыешлы өендә иң якын кешеләрен киңәшкә җыйды. Аның уң ягына Кәлтә, сул ягына Бавыр утырды. Җидекулны ул әле ныклап белми иде, шуңа күрә урынны аңа учак белән түр арасына — уртага билгеләде. Уң ягына, Кәлтә янына, ул Сөмәтәйне утыртты, Бавырдан читкәрәк, сул якка, Кече-Тайны урнаштырды. Кече-Тай, үсмер генә булса да, кереш тарта ала иде һәм ничек тә олы абыйсына ярарга тырышып кына тора иде.

Җидекул янына Албуга Чәнсине утыртты. Чәнси дә, бага Чун белән тылмач Пи дә, чикне аша чыкканда да, йуечиләр белән төнге сугыш вакытында да үзләрен батырларча тоттылар, һәрнәрсәдә Албугага буйсыну, тәләктәшлек белдерделәр.

Түргә, киезгә, ул тагын үзенә бик якын булган яисә якын булырга тиешле мең башларын, йөз башларын утыртты. Аларның барысы да үзе кебек яшьләр иде.

— Туганнар, аркадашлар! Ил-көн! — диде ул, сүз башлап.— Язмыш мине Чинда әсирлектә тотып торганда, безнең туган йортыбызда яман эшләр булган. Атам Туман каган, мине кайтмас дип уйлап, минем тәгинлегемне алган, карабашны бикә ясап, аның улын тәгин дип таныган. Мин атам каганга үпкә сакламыйм. Кемне тәгин иту, кемне итмәү — аның эше. Ул миңа менә илкөн бирде, җир-су бирде. Мин атам Туман каганга берсүзсез буйсыну белдердем. Минем бары язмыш алдында гына бил бөгәсем килми. Сөннең хәле шәптән түгел. Уңнан да, сулдан да, арттан да, алдан да Сөнне ягылар кысрыклый. Сазга кереп баткан болан кебек бүгенге Сөн. Аны саз тарта, аны кортлар кимерә, явыз кошлар чукый. Кем коткарыр Сөнне? Сез! Без! Аңа булышка килердәй беркем юк. Шуңа күрә боерам: миңа буйсынган, кереш тарта алган... ундүрттән алып алтмышка чаклы булган барлык таза ирләр бүгеннән башлап сугыш уены өйрәнәләр. Бүгеннән башлап без яңача коралланачакбыз, яңача тупланачакбыз. Минем уң кулым — субашы Кәлтә алып, сул кулым — мең башы Бавыр алып. Кәлтәнең булышчысы — мең башы Сөмәтәй алып, Бавырның булышчысы — мең башы Җидекул алып. Болар минем дүрт мөгезем. Барлык мең башлары, барлык алыплар миннән кала аларга буйсына. Минем боерыклар, дүрт мөгез боерыклары берсүзсез үтәлергә тиеш. Карышкан, сүз тыңламаган теләсә кемнең башы чаптырылачак!

Соңгы сүзләрен ул эчке бер күтәренкелек белән, көчле итеп әйтте. Өй эчендәге ирләрнең тәннәре чымырдап куйды. Каганның өлкән улы Албуганың кансызлыгы турында инде болай да сүзләр күп йөри иде. Мондый сүзләрне турыдан-туры аның кулы астында булмаган һәм аның турында башкалардан берәр нәрсә ишетеп калган кешеләр тарата иде. Хәзер дә куркучыларның

күбесе яңа кешеләр булды. Албуганы белгән һәм аның белән утны-суны кичкән ирләр үзләрен тыныч сизделәр.

Менә шулай беренче танышу-сөйләшүдән соң өй эчендәге ирләргә җиңелчә сый килде. Ашагач-эчкәч, Албуга үзенең ирләрен таулар ягына алып китте. Ике тау арасындагы иркен генә тигезлеккә килеп җиткәч, ул ирләргә туктарга кушты. Үзе, алгарак чыгып, җәясен-угын алды да якыннан гына очып барган бер тилгәнгә атып җибәрде. Шулчаклы ят, ямьсез, куркыныч сызгыру тавышы ишетелде. Ирләр сискәнеп киттеләр, атлар өркеп, кайсы чабып китмәкче булды, кайсы, чинап, арт аякларына басты.

— Ишеттегезме? — дип кычкырды Албуга үзенең ирләренә.

— Ишеттек! — диделәр ирләр беравыздан.

— Ишетсәгез, менә шул — Сөн угы моннан соң менә шундый булачак! — диде түмән бәге.— Сызгырып оча торган Сөн угының тавышын ишетү белән, ягының йөрәгенә курку йөгерәчәк. Сез әле бер укның тавышына сискәнеп киттегез. Берьюлы йөз ук, мең ук сызгырып очса, кем безгә каршы тора алыр? Беркем дә!

VIII

Шул ук көнне түмән бәгенең боерыгы барлык ирләргә җиткерелде. Мең башлары үзләренә буйсынган йөз башларын җыйды, йөз башлары ун башларын җыйды. Һәркемгә боерыкның асылы аңлатып бирелде. Барлык җәйләүләрдә, көтүлекләрдә, тәртипле рәвештә тупланып, яу осталары күзәтүендә сугыш уеннары башларга, диелде.

Боерык белдерүнең өченче көнендә Албуга, иң якын кешеләре белән бергәләп, иртә таңнан җәйләүләргә, көтүлекләргә юнәлде. Алар, җиңелчә юырттырып, бер көндә бөтен биләмәне әйләнеп чыкмакчы булдылар һәм, әлегә артык төпченмичә, читтән генә карап-күзәтеп уздылар. Күп җирдә ирләр, унар-унар булып, ук аталар, сөңге ыргыталар иде...

XVI

Сөн йорты каганының үтерелүен, аның урынына калган яшь каганның кырыслыгын һәм урдадагы башка хәлләрне дунхулар да, йуечиләр дә, чиннар да белеп тордылар. Белделәр һәм тын да алмый көтә башладылар. Нишләр сөннәр — яңадан бергә туплана алырлармы, көч җыя алырлармы, әллә үзара талашып, таркалып бетәрләрме? Яшь каган нindirәк булып чыгар?

Урдага иң якыны Начин нойон иде. Ул инде үзен нык һәм көчле сизә иде. Бик кыска вакыт эчендә ул да ныклы гына тәртип урнаштырды, иленә-көненә, сөннәр кебек күченеп йөрү өчен, җир-су бүлеп бирде. Шул ук вакытта барлык ирләрен, исәпкә алып, унлы, йөзле, меңле, түмәнле алайларга бүлде;

алай башлары итеп үзенең ышанычлы харасуннарын билгеләде. Шуның өстәвенә ул аларны сөннәр кебек үк тәртипкә һәм боерык тыңларга өйрәтә башлады.

Сөннәр ягыннан дунхуларга көн саен диярлек хәбәрләр килеп торды. Каган улы Албуганың атасын яуда үз кулы белән атып үтерүе, урда аксөякләрен кыерсытуы, күпчелек бәкләрнең, ыру башларының аны каган итеп танымаулары һәм башка нәрсәләр турында аңа сөннәрдән качкан кешеләр сөйләде. Сөйләгәндә, алар бик нык күпертеп, арттырып сөйләделәр. Сөннәрдәге тәртипсезлеккә, башбаштаклыкка Начин нойон, билгеле, сөенде генә. Аның ничек тә Албуга каганның ниндилеген беләсе килде һәм, өлкән бичәсе Бага-Хатун белән киңәшеп, ул аннан тулпар ат сорап карарга булды.

Соралган тулпарны сөннәр бирделәр һәм, җитмәсә, дунхулар белән үзара тату яшәргә теләүләрен белдерделәр. Начин нойонның күңеле күтәрелеп китте. «Курка!» — дип уйлады ул яшь каган турында.

Кыш узып, җылы яз җиткәч, көннәрнең берендә Албуга каган урдасына дунхулардан тагын илче килеп төште. Бу юлы оятсыз илче үзенең бәге Начин нойон өчен Албуга каганның атасы Туман каганнан калган бер бичәсен — гүзәл Сөенеч бикәне сорады.

Биек Ак өйдәгеләр дунху бәгенең тулпар сорап әрсезләнүен әле онытып бетермәгәннәр иде. Ярар, атны алды. Бер ат биргәннән каган ярлыланмады. Ләкин яшь каганның яраткан бичәсен, бөтен Сөн илендә иң чибәр бикәне сорарга ничек кыюлыгы җиткән ул дунху Нойонның?! Кызын да түгел, кыз туганын да түгел — турыдан-туры бичәсен, бикәне! Мондый хәлнең булганы юк. Булмас та!

— Бирмәскә! Илченең башын чаптырырга! — диделәр киңәшчеләр, ачулы шаулашып.

— Бер бикә аркасында күршеләр белән бозылышу акылсызлык булыр иде,— диде Албуга каган. — Сөенеч бикәне дунху илчесенә бирергә.

«Бирмәскә» дигән киңәшчеләр шундук шып булдылар.

— Мин сезне бер тапкыр кисәткән идем инде,— диде яшь каган үзенең киңәшчеләренә.— Мин сезгә сүзегезне уйлап сөйләргә киңәш иттем. Бу юлы да мин сезне кичерәм. Моннан соң да ялгышсагыз кызганып тормам.

Сөенеч бикәне яхшылап киендерделәр, яхшы атка атландырып, илче белән бергә Начин нойонга биреп җибәрделәр. Бикәне, илчене, зурлап, чик буена кадәр озатып куйдылар.

Сөенеч бикәне дунхуларга биреп җибәргәч тә, Албуга каган Кәлтә белән Бавырны, Җидекул белән Сөмәтәйне үз янына чакыртып алды. Ул аларның һәркайсына сызгыра торган уклар салынган берәр садак бирде.

— Менә сезгә Сөн илен коткарачак уклар,— диде ул аларга.— Һәркем үзенә билгеләнгән якка китсен. Һәрбер ыруга минем исемнән берәр ук тапшырыгыз. Бөтен Сөн йортында шундый уклар ясый башласыннар, барлык ирләр көн-төн сугыш уены өйрәнсеннәр.

Начин нойон, Сөенеч бикәне алгач, масаюыннан нишләргә белмәде.

— Курка! — диде ул тагын да Сөн йортының яшь каганы турында.

Ләкин аның акыллырак өлкән бичәсе әлегә әллә ни куанычбелдермәде.

— Куркамы, юкмы, билгеле түгел,— диде ул.— Тагын берәр нәрсә сорап карарга кирәк. Менә шунда беленер барысы да.

— Курка! — диде Начин нойон, кабатлап.— Курыкмаса, шундый чибәр бичәсен биреп җибәрәмени?! Көче юк Сөннең. Йуечиләр өлгергәнче, даланы яулап алырга кирәк.

— Ашыкма,— диде Бага-Хатун.— Берәр ел көтик — анда күз күрер.

— Ярар, көтик,— диде нойон, килешеп.

Ләкин күңеленнән аның һич тә бер ел көтеп торасы килмәде. Үзенең кешеләренә ул, әкренләп-әкренләп, ике арадагы буш җирләргә басып керергә боерды. Шуны гына көтеп торган дунхулар терлекләрен көнбатыштагы буш җирләргә куалый башладылар. Һәм, сөннәр ягыннан бернинди каршылыкка очрамыйча, Диңгез-күл ярларына кадәр килеп җиттеләр.

Көз җиткәч, Начин нойон Сөн каганына тагын үзенең илчесен җибәрде. Оятсыз илче, битен карага буяп, буйсыну белдереп, тагын Албуга каган алдында бил бөкте һәм үз бәгенең оятсыз теләген белдерде.

— Сөн белән дунху арасында киңлеге йөз чакрым, буе биш йөз чакрым чамасы буш җир ята. Моннан соң мин анда көтү көтәчәкмен. Сөннәр анда кермәсеннәр, көтү көтмәсеннәр,— диде илче, Начин нойон әйткән сүзләрне кабатлап.

Албуга каган илченең сүзләрен бүлдермичә тыңлап торды. Илче сөйләп бетергәч, ул үзенең киңәшчеләренә күтәрелеп карады. Киңәшчеләр нәрсә уйларга да белмәделәр. Яшь каган инде ике мәртәбә дунхуларның теләген үтәде. Кем белә, бу юлы да аның күрше белән тату булып каласы киләдер, бәлки. Берәүләр әйтте, бирмәскә, диде, икенче берәүләр әйтте, бирсәң дә ярый, бирмәсәң дә ярый, диделәр.

Шул чакны яшь каган урыныннан торды һәм куркып башларын түбән игән киңәшчеләргә усал күз карашы ташлап алды.

— Сез, киңәшчеләр, мин белмәгәнне белергә, мин аңламаганны аңлатырга тиеш идегез,— диде ул.— Сезнең уйламыйча биргән киңәшегезгә таянып, мин ялгыш боерык бирсәм, Сөн иленә

талау, кыран киләчәк. Сез алдан ук шуны уйларга тиеш идегез. Ил-көн язмышын кайгырту урынына, сез иң әлек үзегезне кайгыртасыз. Сөннең җире болай да таланган, йолкынган, тараеп калган. Нәрсә уйлап сез дунхуга биш йөз чакрымлык җирне бирмәкче буласыз? Йорт нигезе — җир! Сөн җиренең бер карышы да беркемгә дә бирелмәячәк!

Яшь каган оятсыз илченең башын чаптырырга боерды. Шулай ук ул кирле-мырлы сөйләнгән, ялгыш киңәш биргән киңәшчеләрне дә башсыз калдырды. Шул ук көнне бөтен ил буенча кереш тарта алган барлык ирләргә яуга кузгалырга дигән боерык бирелде. Начин нойон үзенең җир сорарга киткән илчесен көтеп яткан арада, Сөн йортының барлык якларыннан Сары су буена кораллы чирүләр агылды.

Сөннәрнең барлыгы утыз мең чамасы чирүе җыелды. Албуга каган чирүне үзе алып барды. Юлда очраган аерым авылларны, көтүләрне сөннәр күрмәгәндәй узып кына киттеләр. Алар туптуры Начин нойон урдасына юнәлделәр һәм тиз арада Байык буена барып та җиттеләр. Үз-үзенә артык ышанган, масайган дунху бәге өчен бу бөтенләй көтелмәгән нәрсә булды. Сөннәргә каршы ул ашык-пошык тупланган алайларын җибәрде. Сөннәр ягыннан сызгырып очкан меңнәрчә куркыныч ук тавышын ишетеп, дунхулар каушап калдылар. Атлар чыгымчылый башлады. Ашкынып килгән, ябырылып килгән сөннәргә каршы торуның файдасызлыгын күреп, котлары алынып, дунхулар төрлесе төрле якка качыша башладылар.

Бер тында сөннәр Начин нойон чирүен кырып салдылар, урдасын камап алдылар, Дунху бәгенең башын чабып, Албуга каганның аягы астына китереп ташладылар. Дунхуларның хатын-кызлары, бала-чагалары, мал-туары — барлык байлыклары кулга төшерелде. Кулга төшкән хатын-кыз арасында акыллы бикә Бага-Хатун да, сөннәрдән җибәрелгән Сөенеч бикә дә бар иде.

Бик тиз генә, җиңел генә барлыкка килгән дунху йорты, шулай итеп, тиз арада юкка да чыкты.

Сөннәр канатланып киттеләр. Албуга каган үзенең кешеләренә, атларына бер көнлек ял бирде һәм, дунхуларның тармар ителүе турындагы хәбәр бөтен далага таралып өлгергәнче, ашыгып, көнбатышка таба кузгалды.

Айның әле беренче яртысы бетмәгән иде, шулай булгач, Күктәге Тәңре сөннәргә булышырга тиеш иде. Албуга каган, тиз арада бөтен даланы аркылыга үтеп, искәрмәстән Ала тау янындагы җирләргә барып чыкты. Дунхулар кебек үк йуечиләр дә, үз көчләренә артык ышанып, аны-моны уйламыйча, иркенләп, Ала тау буйларында яшәп яталар иде.

Йуечиләр биләгән элекке Сөн җирләренә Албуга каган кинәттән бәреп керде дә күп санлы, тик тиешенчә оеша, туплана

алмаган кечерәк алайларны бер-бер артлы юк итте; Сөн йортының борынгы чикләренә кадәр барып җитте һәм шуннан соң Җылан тау ягына — төньякка борылды. Энесе Адай үтерелгән җирдә ул аеруча ярсып, усалланып сугышты. Йуечиләрнең бик күп халкы, мал-туары, байлыклары кулга төшерелде. Шул ук вакытта йуечиләргә буйсынып яшәгән сөйбүләр коткарылды. Сатлык Тук-Тимер бәкне, үзенең үги анасы Сырга бикәне Албуга каган ат койрыгына тактырды.

Сары су буеннан кузгалып китүенә бер ай булды дигәндә, Сөн йортының башы Албуга каган, йуечиләр белән эшен бетереп, Куксай үзәне ягына борылды.

XIX

Корбан җыены, җиңү җыены бер айга якын сузылды. Шушы вакыт эчендә яшь каган йортка, илгә-көнгә кагылышлы күп кенә эшләрен башкарды. Сөн йортының аксөякләре саналган өч ыруга ул яңа ыру башлары билгеләде.

Аның өчен иң авыры һәм иң четереклесе Куяннар булды, әнисе Күрекле бикә булды. Элегрәк аңа дәү әнисе Кортка-бикә турында төрле сүзләр ишетергә туры килгән иде. Әнисе Күрекле бикә үзенең каенанасы турында гел яратмый сөйләде, улы каганга гел аяк чалды, урдадагы бар кешене үз кулында тотарга тырышты, диде.

Менә хәзер инде Албуга каган уйга калды: әнисе Күрекле бикә Кортка-бикә кебек булмасмы? Өлкән улы Сөн йортына баш булгач, ул үзен ничегрәк тотар? Аннан соң этисе Булгак алып та бар бит әле!

Яшь каганны борчыган нәрсәләр турында Күрекле бикә беркөнне үзе сүз башлады.

— Улым, балам,— диде ул.— Менә син биек Ак өйгә баш булдың, алтын урынның иң югарысына менеп утырдың. Сиңа хәзер җиңел дә, авыр да булыр. Син инде сөрлекмәссең, егылмассың. Шулай да минем сиңа бер сүзем бар. Җиңелмәс өчен, алып иргә дә көчле кирәк, ялгышмас өчен, акыллыга да киңәшче кирәк. Син мине... әниеңне, туганнарыңны кая куярсың икән — шуны беләсем килә.

— Син үзең ничек әйтсәң, шулай булыр, әни,— диде Албуга. Күрекле бикә җиңел сулап куйды.

— Сиңа күз көеге булып, синең эшеңә кысылып, каенанам сыман урда артында яшисем килми,— диде ул.— Минем туган ыруыма, Куяныма кайтасым килә. Кече-Таемны, Куянга баш итеп, уң кул тучи бәк итеп куйсаң, мин аның янында яшәр идем, улым.

«Шулай булырга тиеш тә иде ул»,— диде Албуга үзалдына. Кортка-бикә кебек урда эшенә кысыласы килмәүдән бигрәк,

аның теге иреннән... үлеп терелгән иреннән ераграк буласы килә.

— Җидекулны кая куйыйм соң, әни? — диде ул.

Күрекле бикә сорауның болай йөзгә туры карап әйтелүен көтмәгән иде бугай — уңайсызланып башын читкә борды.

— Син аны Кече-Тай карамагына тапшыр, улым,— диде ул, көттереп.

— Ярар, син дигәнчә булыр, әни,— диде яшь каган.— Минем сиңа бер сүзем бар. Теге ирне... мәрхүм Туман каганның гариплəндереп ташланган ирен күрәсең килмимени?

— Юк,— диде Күрекле бикә, коры гына.— Ул үлде. Үлде ул, улым. Үлеләрдән ераграк булганың яхшы. Икенче аны исемә төшермә.

— Төшермәм, әни,— диде Албуга.

Күрекле бикә ашыгып китеп барды. Албуга аның борын тартып, елый-елый баруын ишетеп торды. Аңа бик кыен, бик күңелсез булды. Әнисен ул ачулана да алмады, юата да алмады.

Бер биш-алты көннән ул үзе өчен әнисе кебек үк якын булган икенче кеше белән дә очрашып сөйләште. Яшь каганга әле аның да тормыштагы урынын ачыкларга кирәк иде.

— Әти! — диде ул аңа, авыз тутырып, үз өендә.— Иң авыр чакларда син минем күңел таянычым булдың. Яуда, әсирлектә иң куркыныч чакларда мин сине күз алдына китердем, синең сүзләреңне, акыллы киңәшләреңне исемә төшердем. Сине уйлау, синең белән килешү миңа бетмәс-төкәнмәс көч бирде. Әлек тә, бик кечкенә чагымда, мин һәрвакыт сиңа охшарга, синең кебек карусыз, тәвәккәл булырга тырыша торган идем. Хәзер мин сиңа кулдан килгән барлык яхшылыкларны эшли алам. Әйт: кайда кем буласың килә, нишлисең килә?

Мондый сүзләр ишетеп, Булгак алып күз алдында тынычлыгын җуйды. Күңеле нечкәреп, ул яшь каганны кочаклап алырга да укталып карады, ләкин, үзе белән аның арасындагы аерманы искәреп, шундук кулын кире алды, хәтта кире чигенгәндәй итте. Шул ук вакытта аның иреннәре, борын яфраклары калтыранып-калтыранып куйды. Анысы гына җитмәгән, күз төпләре кызарып, юешләнеп чыкты.

— Улым! — диде ул, йөрәк түреннән ургылган бер ярату белән.— Менә шулай аулакта сине «улым» дип атарга ярасa, миңа хәзер берни дә кирәкми.

— Юк, әти,— диде Албуга, каршы төшеп.— Алай артык тыйнакланма. Мин синнән баш тартмадым, тартмаячакмын.

— Әйе шул,— диде Булгак алып, кинәт сүрелеп.— Чын, минем үземә күп нәрсә кирәкми, улым. Мин бик азга да риза. Минем үз тормышым бар, яшь хатыным, балаларым, якын кешеләрем бар. Шунда таулар арасында яшәп ятсам, миңа шул да җитә.

— Сиңа җитсә дә, миңа җитми, Булгак алып! — диде Албуга каган, этисенең мескенләнүен ошатмыйча.— Син һаман үзеңнең элекке коллыгыңны оныта алмыйсың. Оныт син аны. Миңа син кирәк, бик кирәк! Мин сине элеккечә каравыл агасы итә алам.

— Юк,— диде Булгак алып.

— Мин сине төньяк җирләргә бәк итеп куя алам,— диде яшь каган.

— Юк,— диде Булгак алып.

— Мин сине, алайса, көнбатышка куям,— диде Албуга.

— Юк,— диде Булгак алып.— Син мине, улым, Диңгез-күл буена куй. Мин шунда Ябалак карт кебек тыныч кына көтү көтеп, балалар үстереп, дулкыннар шаулавын, камышлар кыштырдавын тыңлап... балык тотып яшәп ятармын. Яз көне, көз көне кошлар күченгәндә бик күңелле була. Нинди генә кошлар юк анда! Нинди генә моңлы тавышлар ишетелми анда! Диңгез-күл буйларын яшь чагында синең әниең бик ярата торган иде. Син дә яз көне шунда күченеп килерсең яшь бичәләрең, балаларың белән. Мин сезне ауга алып барырмын, балаларыңны атта йөрергә, җәя тотарга өйрәтермен. Онытканмын: мәрхүм Туман каган тартып алган хатынымны, балаларымны эзләп табасым килә. Аларга аерым өй, яшь хатыныма аерым өй корырмын. Аннан соң минем бик якын танышым бар... Имче карт. Теге Табылдыкны аңа кияүгә бирдем.

— Табылдык! — диде Албуга, онытылып китеп.— Исәнмени ул?

— Исән, улым. Аларның инде ике балалары бар,— диде Булгак алып.— Имче карт... чын исеме Хучи... бик белемле, башлы. Им-том, дәва кирәк булса, кеше җибәр. Ул сиңа кирәк булыр. Аны да Диңгез-күл буена алып килермен.

— Мин синең теләгеңә каршы килмәячәкмен, әти,— диде Албуга каган, уйчан гына.— Шулай да мин синең Сөн йортына олы терәк булуыңны теләр идем. Син әле ишеттең микән — Чинның асты өскә килә башлаган бит. Ул яктан качаклар килә. Буйсынган бәкләре Чин каганына каршы баш күтәргәннәр.

Булгак алып, мондый хәбәр ишетеп, шундук сагаеп калды. Уртадан бөгелә төшкән зур, авыр гәүдәсе турая төште, һәм күз карашында дәртле очкыннар елтырап китте.

— Ишеткәнем юк,— диде ул.

— Ишетмәсәң ишет — аларның чик буен саклаучы чирүләре качышып беткән. Безнең якка да чыгалар. Озын койма буйлары бушап калган. Безгә нишләргә, әти, кошлар тавышын, камышлар шаулавын тыңлап, тыныч кына Диңгез-күл буенда йоклап ятаргамы, әллә?..

— Юк! — диде кинәт Булгак алып.

Ике кулын йомарлап, күкрәген киереп, ул тиз-тиз генә атлап китте. Киез читенә җитте дә ярсып кире борылды һәм, бөтен тәне белән калтыранып:

— Юк! — диде тагын да.— Йоклап ятарга ярамый! Мин синең белән, улым. Бары синең белән генә.

XXI

Күк асты илендәге җунгошеннәр, бер-берсен үтереп, үзара якалашкан арада, сөннәр, Озын койманың әле бер төшеннән, әле икенче төшеннән үтеп, көньяк җирләргә басып керделәр. Бер кышны алар, күршеләренең көчен сынап карарга теләгәндәй, Йән җирләрен тартып алдылар, икенче кышны Дайны талап кайттылар, өченче кышны исә, зур көч туплап, боз тоткан елга аша Арьякка чыктылар һәм, шулай итеп, үз җирләрен тулысынча яңадан үз кулларына алдылар.

Шул ук вакытта Албуга каган, көнбатыштагы йуечи калдыкларын тар-мар итеп, ерактагы чүлләргә кадәр барып җитте. Шуннан соң икенче кышны ул, Алтай таулары аша үтеп, төньяктагы иксез-чиксез киңлекләргә барып чыкты. Куптәнге теләген исендә тотып, Албуга туктаусыз үзенең чирүен арттырды, коралланды һәм көч туплады.

Биек Ак өйнең түренә утыруына ун ел булды дигәндә, кыш башында, Сары су буендагы Изге тауга менеп, җир-су иясләренә, ата-баба рухына зурлап корбан биргәч һәм үзенә буйсынган барлык биләмәләрдәге көрәш тартырдай ирләрнең төгәл саны билгеле булгач, Албуга каган үзенең күптән көтелгән боерыгын белдерде. Сөннәр, бөтенесе бер булып, чиннарга каршы олы яуга кузгалдылар.

Соңгы елларда яуга, чирүгә, коралланутга кагылышлы барлык эшне каган тулысынча Булгак алыпка тапшырды. Олы яуга Булгак алып озак еллар дәвамында җентекләп әзерләнде. Ул төрле ыру-кабилә кешеләреннән аерым-аерым алайлар туплады. Аларга булдыклы, оста алыпларны баш итеп куйды. Җитез тулпарларга атланган, яхшы коралланган һәм каты киемле яшь ирләрне, укчыларны, сөңгечеләрне, арканчыларны ул шулай ук аерым-аерым туплады, аларның урыннарын билгеләде. Байракларга, быргыларга, боерык тапшыру ысулларына, ерактан үзара аңлашу чараларына аеруча нык игътибар итте. Аннан соң иң әһәмиятлесе шул булды: ирләр атланган атларны Булгак алып төсләре буенча төркемләде. Шул рәвешчә, кашкалы соры атлар йөз мең, акбүз атлар йөз мең, тимер-күкләр йөз мең, җирәннәр йөз мең булды. Кашкалы соры атка атланган йөз меңлек чирү уң кул дип, акбүз атка атланган йөз меңлек чирү сул кул дип, тимер-күккә атланган йөз меңлек чирү арт ил дип, җирән атка атланган йөз меңлек чирү маңгай дип аталды.

Бөтен чирүне шулай атларның төсенә карап бүлү, шулкадәр күп халыкның, атларның санын бутамас өчен, алар белән төгәл, дөрес идарә итү өчен, уңай булачак иде. Ләкин шул ук вакытта моның тирән мәгънәсе дә бар иде. Кашкалы соры атлар кояш чыгышын, акбүз атлар көнбатышны, тимер-күкләр төньякны, җирән атлар көньякны чагылдыра иде. Бу исә тулысынча бөек Атабыз Кояшның изге рухына туры килә иде. Үзенә турылыклы булган, үзен һәрвакыт исләрендә тоткан бәндәләрен Атабызның әле беркайчан да авыр хәлдә калдырганы юк иде. Бу юлы да ул сөннәргә турылыклы юлдаш булыр, аларга туктаусыз көч-куәт бирер. Иншалла!

Кышның беренче аенда, изге өченче көндә, сөннәр Озын коймага якын килделәр һәм койманың төрле ватык-җимерек төшләреннән, язгы су кебек, көньяк җирләргә бәреп керделәр дә тыелгысыз рәвештә түбән таба ыргылдылар. Уң кулның башы Кәлтә, сул кулның башы Бавыр, арт илнең башы Җидекул, маңгайның башы Сөмәтәй булды. Яхшы коралланган, яхшы өйрәтелгән илле меңлек чиру белән Албуга каган үзәктә барды. Бөтен чирүнең субашы Булгак алып булды. Туктаусыз алга омтылган кораллы ирләр, атлар ташкыны тулысынча аның боерыкларына буйсынды.

Койма аша алар дүрт җирдән чыктылар һәм, тулы сулы дүрт елга булып, бөтен тирә-якны көчле шау-шуга күмеп, тынып калган киң үзәнгә җәелделәр.

Алар Дай өлкәсенә басып керделәр. Чик буен саклаучы Хань чирүләре, бернинди каршылык күрсәтмичә, кайсы кая качыша башладылар. Кайбер төркемнәр шундук сөннәргә бирелүне яхшырак санады. Сөннәр шундый тиз һәм шундый ашкынып килделәр: Дай өлкәсенең башкаласы Маидагы сугыш осталары исләренә дә килә алмадылар. Сөннәр Маины камап алдылар һәм, корал күтәрергә батырчылык иткән аерым төркемнәрне юкка чыгарып, җанлы бөҗраны кысканнан-кыса бардылар. Башкала сакчысы Ханьсин икенче көнне үк кырык меңлек чирүе белән сөннәргә бирелергә теләк белдерде.

Сөннәрнең моңарчы күрелмәгән зур көч белән Дай өлкәсенә басып керүләре, Маиның алынуы һәм Ханьсиннең дошман ягына чыгуы Күк асты илендә чиктән тыш курку тудырды. Хань йортының яңа патшасы Гаоди ашыгыч рәвештә олы киңәшен җыйды һәм сөннәргә каршы үзе барачагын игълан итте. Бик ашыгыч рәвештә Күк асты иленең төрле ягыннан өстәмә көчләр чакыртылды, һәм сугыш остасы бөек падиша Гаоди, беренче очрашуда ук дала кыргыйларын сытып ташламакчы булып, көнчыгышка ыргылды...

1977—1985

Аяз Гыйләҗев
(1928—2002)

ӘТӘЧ МЕНГӘН ЧИТӘНГӘ

(повесть кыскартып бирелә)

I

Һай, биек тә соң Сәләхетдиннәрнең читәне! Бериш юанлыкта, гел бер буй чикләвек чыбыкларыннан җил үтмәслек тыгыз итеп үрелгән, исең китәр! Әнә җитез генә күтәрелеп килгән кояшның кылыч нурлары, читәннең тар ярыклары аша кочкә-кочкә кысылып үтеп, җиргә зәгыйфь ак шадралар сузганнар. Түшен киереп, тамак асты алкаларын селкетеп йөргән кызгылт гаярь әтәч бүген әллә ничә мәртәбә шушы читән янына килеп карады, әмма очып кунарга йөрәге җитмәде. Келәт алдындагы буш ялгашны чукып маташкан тавыклар ишегалдына таралыштылар, җим эзләгән күзләре читән тирәсендә баядан бирле уралган әтәчкә төште. «Әһә! — диештеләр алар, бер-берсенә горур хуҗаларын күрсәтеп,— әтәчебезнең болдыр култыксасына басып кычкырганы бар, лапас өрлегеннән аваз салып таңны уята, өй кыегына сөялгән биек баскычны бар дип тә белми... Инде бу читән башына менеп тә бер тавыш бирсә, бөтен дөнья әтәчләренең котын алачак!»

Әтәч тә җуләр түгел, тәҗрибәсе һәм куәте бар, ишле кәнизәкләренең ни көткәнен күз карашларыннан сизде, тавыклар, аның дәрт-дәрманын көчәйтеп, кырлый-кырлый, читән күләгәсендә сырпаландылар. Ниһаять, әтәч тәвәккәлләде: ишегалдын иңләп, канатларын җилпеде, мәгъруР башын кыегайтып, күккә карады һәм, мә сиңа, читән казыгына очып та кунды. Өстән караганда дөнья бик киң һәм тавыклар бик вак булып күренделәр. Югарыга карады, кояш та тары бөртегеннән әллә ни зур түгел иде...

Муен йоннары күпереп тырпайды, муен бер карышка озынайды, канатлары җил-давыл чыгарды һәм... чү! Ни булды?!

Киң җиһанга дәһшәтле аваз салырга җыенган кызгылт әтәч читәннән егылып төште.

Егылган җиреннән — кычытканнар арасыннан — уктай атылып чыкты да, озын, таза ботларын яхшы юртак кебек як-якка ташлап, яңгырдан-кардан каралып беткән, юан-юан бүрәнәләрдән салынган келәт астына кереп тә качты...

Дөньякүләм чуалышлар күзлегеннән түгел, шушы авыл төбәгендәге хәлләрдән генә чыгып караганда да, бу вакыйгада әллә ни искитәрлек нәрсә юк та кебек, әмма, ул без алдарак танышачак кешеләр язмышына турыдан-туры һәм бик тыгыз бәйләнгән булганга, без бу гадәти йорт кошының шул иртәдә егылып төшү фактын зурлап әйтеп китүне кирәк санадык. Кайчагында тормыштагы бик нәни вакыйгалар да һич көтелмәгән зур нәтиҗәләр китереп чыгара: «Ихтималның арты киң!» — ди безнең тапкыр халык! Бу юлы да шулайгарак китте эш, кызгылт әтәчнең һич көтелмәгәндә егылып төшүе байтак маҗаралар тудырды, шуңа күрә сүзебезне нәкъ әнә шул кеп-кечкенә вакыйгадан башлап киттек. Ни хәл итмәк кирәк, егылды да төште әтәч! Китте кытаклау, купты тавыш, кузгалды ыгы-зыгы, әкәмәт! Моңа күрше-тирә әтәчләре дә игътибар иттеләр: муеннарын сузып күкне күзәттеләр — тилгәннәр эскадрильясы очып килгәнме әллә?! Тауның карурманга якын кыяларында актык көннәрен уздыручы түш йоны коелган карт бөркет, адашып, авыл өстенә килеп чыкканмы?! Өерләре белән карчыгалар берәр яры күченеп барамы әллә?! Һич югында, тавык ите сагынган кызыл төлке су буендагы куе таллар арасыннан ындырларны, тавык-чебеш тибенгән тиреслекләрне күзәтеп ятамы?.. Әллә, мур кыргыры, бүре-явыз ук бармы?!

Юк, күк чалт аяз һәм буп-буш иде. Әнә әллә кайда гына бер разведчик тилгән оча, аның бу көтелмәгән сәер тавыш-гаугага һичбер мөнәсәбәте юк икәнлеге күренеп тора, тавыш Югары очта, ә ул Түбән оч буасы ярларына таралышкан гамьсез каз бәбкәләрен күзли булыр. Бөркет күләгәсе дә тирбәлми, төлке дә тал яфракларын селкетми...

Алайса, нигә купты соң әле мондый гауга? Югары оч әтәчләренә һич тынгы бирмәгән, очның бөтен тавыкларының кайнар мәхәббәтен үзенә яулаган кушйодрык кикрикле, дистә ярым урак койрыклы, иң озын ботлы, иң чыдам сулышлы, иң кыдрач, иң көчле сугыш чукмары, Гәрәйхан кушаматына лаек булган кызгылт йонлы, киң күкрәкле әтәчнең муенын кых-х иттеләрме әллә?

«Әһә,— диештеләр Гәрәйханнан байтак җәбер-җәфа татыган, йолкынган каурыйлы, кутырлы кикрикле бик күп аксак-туксак әтәчләр,— якынрак барырга да җайлы чакта катырак кычкырып, гайрәт бетмәгәнлеген исбатлап калырга кирәк! Күрсеннәр кемнең кем икәнен, тавышны тавыклар да ишетеп калсын!»

Уңнан да, сулдан да, йомылып, әтәчләр чабыша башлады, «Бүгеннән Югары очта беренчелек миндә!» — дип шаулыдылар алар, бер-берсенең күзен чукып алырга әзер торып. Түшләр киерелде, бугазлар бушады.

Китте шикләнү, китте юраулар, фараз кылулар, күрәзәлек, табышмак чишүләр, талаш көчәйде, шулар һәммәсе күршедән күршегә, йорттан йортка күчеп, авылның бөтен кош-кортлары пыр туздылар...

II

Каз-үрдәкләр акрынлап тынычланды, тавышлары басылды, Гәрәйхан, келәт астыннан чыгып, берни дә булмаган төсле гаярьләнеп канатларын җилпеп куйды, җиңелмәвен күрсәтер өчен, үзеннән бер атлам да калмаган куштан сары тавыкка мәхәббәтле караш ташлады. Башын югары чөеп, кикриген калтыратып, күкрәк йоннарын тырпайтып, бая егылган урынына карады һәм янлап-янлап чигенергә тотынды. Читәннең теге ягында, Сәләхетдиннәрнең куе карлыган куаклары арасыннан, иң элек тырпаеп торган чәч күренде, чәч артыннан туфракка буялган тар маңгай, маңгайга ияреп, яфраклар арасыннан ике мут күз елтырады.

Сәләхетдин малае Зәйтүн иде бу. Кулындагы шома саплы рогаткасының кызыл резинкасына үткер кырлы чуерташ кыстырып маташа иде малай. Әтәчнең келәт астыннан чыгуын күргәч, малай читәнгә якынрак тартылды, ике чыбыкны аралап, ярыкка рогаткалы кулын тыкты һәм тагын атып җибәрде; бу юлы тидерә алмады, әтәч, кушаяклап, бер якка сикерде, муенын сузып-сузып, сугыш чукмары малайга карады. Их, арада биек читән булмасамы, дип уйлады бугай ул. Дәһшәтле кош иде Гәрәйхан, бала-чаганы куркыту гына түгел, корычтай томшыгы белән чукый-чукый, олыларны да пыркытып куа торган явыз зат иде!

Ул ара да булмады, Мирфатыйхлар өйалдыннан, озын саплы бакыр чүмеч күтәреп, Зәйтүннең яшьтәше, әтәчнең яшь хуҗасы Әнәс атылып чыкты, һөҗүм дәрте белән мавыккан рогаткалы илбасар аны-моны абайлаганчы, читән кырына барып җитеп:

— Нигә атасың безнең әтәчкә, буксә? — дип чәрелдәде. Елгыр Зәйтүн карлыган яфрагы исе килеп торган ике кулын да югары күтәрде һәм әле учын, әле кул сыртын әйләндереп күрсәтте.

— Мә, кара! Менәтерәк! Бармы әйберем, бармы?

— Син аттың аңа, буксә.

— Атмадым. Сезнең карт әтәчегез үзе егылып төште.

Зәйтүннең мыскыллы сүзеннән гарьләнеп еларга җитешкән Әнәс, чүмечен җиргә атып, ике куллап читән чыбыкларына ябышты.

— Безнең әтәч картмы? Безнең әтәчме?

— Карт, карт,— дип үртәште Зәйтүннең тиктормас авызы.— Безнең әтәч сезнең карт йолкышны борып кына сала! — Зәйтүн хата җибәргәнен тиз аңлады, әтәч турында ярыш сүзен артык озынга җибәрергә ярамый иде. Чынлыкта исә Әнәсләрнең Гәрәйханы аларның былтыргы салкыннарда өшегән кикрикле ак әтәчләренә көн күрсәтми иде. Ялгышын төзәтергә ашыгып, малай җәһәт кенә сүзне борды: — Ә безнең ата каз сезнең ата казның җанын ала!

— Ала! Җанынмы? Һе, килеп кенә карасын. Сезнең ул арык каздан бәбкә дә булмый әле.

Кызганычка, бу сүздә дә Әнәс өстен чыкты: аларның бүрекле ата казлары, метр ярымлы юан муенын сузып, Зәйтүннәрнең казларын шыр җибәртеп куа иде.

— Ә,— дип, һаман бирешмәскә тырышты ул.— Безнең куа сыер ике бозау китерде. Икене, икене!

— Һә, икене! Белдең! Берсен фермадан урлап кайткач ике булды!

Әтәчне бер атуда бәреп төшерсә дә, сүздә тагын ялгышлык җибәрде Зәйтүн, авыл арасында «урланган!» дип телгә кергән игезәк бозаулар турында искә төшермәскә иде! Кош-кортларны куеп торып өй эченә керергә, ялтыравыклы шкафлар, пианино, келәмнәр, телевизор, радиоалгычлар, бәллүр вазалар, ишегалдындагы «Москвич», лапастагы «Иж-Планета» белән мактанырга, тагын әллә нинди саллы сүзләр табып, Әнәсне егып салырга иде... Юк бит, кирәк чагында иң кирәге телгә килми кала! Нишлисең, беренче классны әйле-шәйлегә быел гына бетергән малай өй эче байлыгы белән мактана белми иде әле, әткәсенең: «Бераүгә дә баш бирмә, җиңелгәнне җиңгә бөтерәләр!» — дигән көндәлек катгый боерыгын үтәп кенә Әнәс белән әрепләшеп маташа иде. Телгә тагын әтәч килде, чөнки төз атып бәреп төшергәч, малайның борын шактый күтәрелгән иде.

— Гарьлек, гарьлек! Карт йолкышлары үз хәлен белмичә читәнгә менгән иде, мәтәлеп төште! Гарьлек! Карт булмаса, тавыкларыгыз безнең әтәч янына кереп йөрмәс иде.— Болары Зәйтүн әнкәсенең сүзләре булса да, Әнәскә бик авыр ишетелделәр, ул, кызарынып-бүртенеп, ызгышны олыларга күчерде. Сүз ярышы кызды.

Бәхәс бары тик әтәч аркасында гына чыкты дип ялгыш уйлый күрмәгез тагын, тирәндәрәк аның сәбәбе, эчтәрәк!

Әнәс беренчене гел яхшы билгеләренә генә бетерде, Зәйтүннең язмадан һәм арифметикадан өчле чыкты, аны икенче класска авырлык белән генә күчерделәр. Яхшы билгеләренә генә укыган Әнәскә кичә бүләк — өр-яңа чуар кепка эләкте. Кибеттән әтисе алып кайтып бирде. Әнә ул кепка аның кичә генә бритва белән кырылган озынчарак башын мул кояш нурларыннан саклап

кукраеп утыра. Козырёгы тырпайган, сигезгә бүленгән түбәсендә шаһзадәләрнең алтын таҗы сыман тумпак төймәсе дә бар. Бүген иртән Әнәснең әнкәсе кепканы кулына алды да көлеп җибәрде:

— Күрше Зәйтүннең борыны төсле икән бу төймә, нәкъ үзе,— диде.

Әнәс, урамга йөгереп чыгуга, Зәйтүнне күрде дә:

— Синең танауны минем кепка өстенә такканнар! — дип сөрән салды.

Яңа кепкага кызыгып торган малайлар бердән Зәйтүнгә борылдылар:

— Төймә борын, төймә борын! — дип, дәррәү такмакларга тотындылар.

Уку бетүгә, яңа кепка гына түгел, велосипед белән ботинка да вәгъдә иткәннәр иде Зәйтүнгә — берсе дә эләкмәде. Арифметикадан «өч»ле сөйрәп кайткан төпчегенә Сәләхетдин абзыйның җен ачуы чыкты. Ул дөньяда «санау фәнен» генә «кирәкле һәм бик файдалы» дип исәпли иде. «Башкаларын мәктәптә укыта алмыйлар аның, башка кирәкләрен мин сезгә үзем өйрәтәм»,— дип кабатларга ярата иде ул, еш кына.

Ат кылы кебек эре төкле кашын җыерды да:

— Ә Мирфатыйх бүлтерегe ничәле алган? — дип сорады ул. Әнәснең яхшы укуын, математикадан «биш»ле үк алуын ишеткәч, малайны җилтерәтеп алды:

— Санауны да өйрәнмәгәч, тамагыңны ничек туйдырырсың? Кеше арасына ничек керерсең? Дөньяда яшәүне бик җиңел дип беләсеңме әллә? Авызыңнан тартып алырга гына торалар!..

Малайны тәмам гарьләндереп, әтисе Зәйтүннең борынына чиртте...

Малайның күңелендә үч алу тойгысы кайнады, үч тойгысы тышка бәреп чыкты, һәм аның беренче ударын Гәрәйхан татыды...

Читән-баррикада аша малайлар шактый эреплләштеләр, алай гына бушана алмадылар, читән чыбыгының беренчесен Әнәс суырып чыгарды.

— Нигә безнең читәнне сүтәсең, таз? — дисә дә, икенче чыбык Зәйтүн кулында иде. Малайларның кайсы җитезрәк дисәк, Әнәс монда алдынгылыкны алды, читән арасына баш сыярлык булгач, ул, бакыр чүмечен тотып, теге якка үтеп өлгерде. Керүе булды, чүмеч белән Зәйтүннең башына берне тондырды.

Әле йодрык белән сугарга мөмкин, терсәк белән хәйран нык төрткәләгәннәре бар Зәйтүнне, артына шап итеп тибеп калганнары бар, мәгәр моңа кадәр, шушы хурлыклы көнгә кадәр әле беркем дә аның башына бакыр чүмеч белән кундырмаган иде! Кундыручысы кем диген тагын?! Менә кайда ул гарьлек!

Аның кара күзләреннән ут очкыннары коелды, нәзек муены корыч чыбык кебек турайды, беләк мускуллары каз күкәе хәтле булып кабардылар, ул күлмәк итәге астыннан чалбар каешына кыстырган рогаткасын тартып чыгарды да агач сабы белән Әнәснең чыгынкы, киңчә маңгаена берне китереп төртте. Хурланды Әнәс тә, Зәйтүнгә таба ыргылды, шул мизгелдә алмагачлар, карлыган куаклары белән шыпланган ярым караңгы бакча яктырып китте: аның кепкасы, бөтен оч малайларының күзен кызыктырган сигез бүлкәле, төймә түбәле искиткеч матур чуар кепкасы очып төште, һәм малайның шәп-шәрә ап-ак башы көнгә ачылды...

— Кабак баш,— диде Зәйтүн.

— Чуен маңгай,— диде Әнәс, кепкага иелеп.

Малайлар әүмәкләшә торгач ике карлыган куагын изделәр, байтак кура җиләге сабагын сындырдылар. Ниһаять, Әнәс өскә чыкты, Зәйтүннең корсагына менеп утырды, ике бармагы белән тегенең почык борынын кысты.

— Булдыңмы? Ашадыңмы? Туйдыңмы, бүксә? Тимәссеңме безнең әтәчкә яңадан?

— Җиббәрр! — дип тырпылдады тыңкыш Зәйтүн, яткан җиреннән аркасын дугаландырырга һәм Әнәсне чөеп ыргытырга тырышып. Тик Әнәс аны нык иярләгән иде, ике яктан касыгына үкчәләре белән тибеп, Зәйтүнне бик тиз ипкә китерде.

— Яңадааан атмааам! — дияргә мәҗбүр булды Зәйтүн. Малайлар кепканың аста калганын абайламаганнар, берзаман калкынсалар, җирдә үлән суына манчылып төсе үзгәргән бер чүпрәк кисәге күрделәр. Бу... әлеге дә баягы өр-яңа кепка иде! Зәйтүннең дә эш шәптән түгел: маңгай ике урыннан күгәреп шешкән, күз төпләре тырналган, яңак сыдырылган, чалбар төбе умырылган, күлмәк сәдәпләре коелган. Әнәс бүләк кепкасын тезенә каккалап торды да, сиздермичә генә, Зәйтүнгә берне китереп төртте. Очлы йодрыгы белән Зәйтүннең кабыргасына ямады.

Моңарчы еламыйча түзгән иде Зәйтүн, хәзер авызын түгәрәкләп, урт тешләрен күрсәтеп, бакча тутырып акырырга керешге. Шулчакта Зәйтүннәрнең болдыры ягыннан усал, коры тавыш яңгырады:

— Әй, сугыш чукмарлары! Икегез дә атлагыз әле монда! — Зәйтүннең сигезенчедә укып йөрүче апасы Фирүзә тавышы иде бу. Малайлар сискәнеп куйдылар.

. . . .

Тормыш бик кинәт үзгәрде, тормыш күршеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне дә, ике күрше арасында еллар узып ныгыган дуслыкны да челпәрәмә китерде. Хәзер алар бер-берсенә йомышка бөтенләй йөрмиләр. Бәрәңгене аерым утырталар, аерым алалар.

Ике арадагы читәннең кемнеке икәнен онытып бетергәннәр иде, читән тагын метр ярымга биегәйгәч кенә, Сәләхетдиннеке икәнлеге исләренә төште. Сәләхетдин ара капканы бөтенләй ачылмаслык итеп бикләп куйды, хәзер бер-берсенә керер өчен баштa урамга чыгарга кирәк.

Сәләхетдиннәрдән башланды бугай...

Әллә Мирфатыйхтанмы?

Юк, Сәләхетдиннәрдән, ахрысы.

Биш ел дисәм азрак, җиде ел дисәм күбрәк булыр, берзаман, якшәмбе көн иде, Сәләхетдин районнан мотоцикл алып кайтты. Бишеклене. Башта бер атна ишегалдында тырылдаттылар, аннан, урамга алып чыгып, ай чамасы дырылдаттылар, ай үткәч, берәм-берәм дә, төялешеп тә чаба башладылар. Эте-бете утыра да чаба, Вәзилә дә киткән була, бишеккә чүмәшкән Фирүзәнең авызы гел колакта! Ә Сабан туена, Сабан туена... Кулыннан килә, тәмамысы эт икән Сәләхетдин, мотоциклның бишеген алган да урынына зур чыбык чуман утыртып куйган: мәйдан буласы урынга бөтен семьясын чуманга төяп төште. Шаккаттылар. Бөтен халык көрәш карый, Мирфатыйх хатынының күзе матайда. Бөтен кеше ат чабышын көтеп тора, Мирфатыйх хатыны Гөлмәрьямнең эче яна, күзенә ак-кара күренми... Мәйдан янында дәшми түзгән иде, кайткач, Сабан туе чәе эчеп бетергәнне дә көтмәде: «Әнә кешеләр Сабан туена да машина белән генә төшкәннәр! — дип куйды.— Илаһым, кала кунакларын караучы да юк, бөтен кешенең күзе шунда!»

Гөлмәрьям төне буе борсаланып чыкты, йокламаса да, коймагын изәргә онытып, Мирфатыйхтан әр ишетте, икенче көнне үк, Түбән авыл кибетенә төшеп, бик һәйбәт көзгеле шкаф сатып алды. Шифоньер дип атала икән андый шкаф, «шифалы нәрсә!», затлы кешеләрнең түрендә шул була икән. Язуы артына ябыштырылган: төгәл йөз дә егерме җиде тәңкә! Мирфатыйх: «Бәрәч, балаларга киемгә дигән акчаны тоткансың!» — дип әрләгәч, шкаф тирәсенә береккән хатын: «Акчаны күбрәк эшләрсең, хәзер заманы шул!» — дип кенә җибәрде.

Шкаф Югары очта беренче иде. «Районында бер!» — диде Гөлмәрьям. Күрше-каршылар, кардәш-ырулар икешәр рәт кереп карадылар. Сәләхетдин Гөлбикәсе дә түзмәде, йомыш тапкан булып кагылып чыкты. Бәя кәгазен, хуҗалар күрмәгәндә генә, тырнагы белән кубарып алырга маташты... Атна дигәндә, Гөлбикә дә Зәйнең үзеннән, универмаг складыннан шифоньер кайтартты. Ике көзгелене. Язуын артына кадаклаганнар: йөз дә туксан сигез тәңкә. Күрше-каршы, кардәш-ыру, савылып, иртәдән Сәләхетдиннәргә кереп китте. Бәһасен белгәч, тел шартлаттылар, көнләшүләрен сиздермәслек дәрәҗәдә әйберне мактадылар. Мирфатыйх хатыны Гөлмәрьям кермәде. Аның, кара-

сына батып, пыр тузып, келәт белән өйалды тирәсендә итәк җилфердәтеп җенләнеп йөргәнен Гөлбикә чолан тәрәзәсеннән авыз ерып күзәтеп торды. Икенче көнне Гөлмәрьям, көтү куганда, сыерын да, бозавын да сыек тал чыбыгы белән чаж да чож яра иде...

Шуннан китте, китте...

Шкаф артыннан сервант кайтты. Сервант артыннан диван. Диванга трельяж иярде. Трельяж холодильникны чакырды. Сервантлар буш тормады: Гөлмәрьям дә, Гөлбикә дә дистәсе-дистәсе белән чәшкә-чынаяк, кашык-чәнечке, бәллүр вазалар, путаллы чәркәләр, балчык сыерлар, мөгездән көмешләп ясаган әкәмәтләр, дәү-дәү буш диңгез кабырчыклары, тагын әллә ниләр, әллә ниләр кайтарып тутырдылар. Бу чәшкә-чынаяклар белән чәй эчмәделәр алар, аракыны да кунакларга кырлы стакан белән чөмерттеләр; чәнечкенең әллә ничә төрлесе булса да, ит калҗасын һаман, сызганган беләкләрдән май агыза-агыза, кул белән умырдылар, әмма ярсып-ясканып сервант-шкафларга шыплап мал тутырдылар. Мотоциклларны машиналар алыштырды, хәзергесе көндә Сәләхетдиннең гаражында (ишетәсезме, алты йозаклы, бетон түбәле г а р а ж ы н д а!) «Москвич» тора, Мирфатыйхларда — «Жигули». Берсенеке чия төсле, икенчесенеке — лимон...

Кара мунчалар ашыгып-ашыгып сүтелде, дәү-дәү ак мунчалар өлгерттеләр. Мунча алдына иске «Саратов» холодильнигын илтеп утырттылар, элеккеге атаклы шарлыбашлы тимер караватлар да мунча алдына күчте. Чабынып-коенып чыккач, ачы балны тустаган белән шунда суыткычтан гына алып эчә торган иттеләр. Өйләр дә танымаслык булып үзгәрде: аларга уңнан да, сулдан да бүксә-бүксә такта верандалар кушып салдылар. Мичләрне сүтеп, өйләрне пар белән җылытуга күчерделәр. Верандалар гына сусынны басмады, йортларны сүтеп, алты, сигез почмаклы, егермешәр ниргәле пулатлар салып җибәрделәр. Элек бәдрәф, хәзер культуралы «туалет» исемен алган мәгълүм ханәләрне, галерея ясап, өй белән тоташтырдылар. Кар базларын күмделәр, тәбәнәк җил капкаларны дәү-дәү МАЗлар, КРАЗлар кереп йөрерлек итеп киңәйттеләр, биегәйттеләр. Урман якын, урман үзебезнеке, урман шалкан бәясе! Телибез икән, трактор белән менеп алабыз, телибез икән, бульдозер белән сөйрәтеп алып кайтабыз. «Дружба» атлы пычкы өй борынча, һәр кешедә бар, колхоз бензины бушлай, кисәләр генә йөзәр яшьлек юкәләрне, биш йөз ел дөнья ямьләп утырган имәннәрне егалар гына. Егалар да турыйлар! Җир гүләп, җир ыңгырашып кала, юллар сыкрана, бульдозерлар юл юк җирләргә күкрәк киереп кереп китәләр. Кала кунакларына хәзер яңа сауган сөт тә, яңа язган май да әләкми, алар аертылган сөткә Зәйдән кайткан ипине манып

ашыйлар да, Аллаһы әкбәр, «монда хәлләр алайга борылган икән!» дип, килгән җирләренә тизрәк таю ягын карыйлар...

Көнчелек дигән сүз кергән арага тиз арада дошманлык та кереп оялады. Сәләхетдин белән Мирфатыйх кан дошманнарына әйләнделәр...

....

Гербовой печать һәм имзалар белән расланган шушы белешмәдән сез Хәйдәрнең өченче бала булуын да, механизатор икәнлеген дә белдегез инде. Алдарак без Язкилде авылында кызу эш өсте булуын, һәркемнең эштә булырга тиешлеген, идарә карарыныңныклыгын һәм идарәдә шулай дип уйлауларын искәртеп узган идек инде. Колхоз идарәсендә Хәйдәрне дә бүген эштә дип беләләр һәм ул печән оны ясаучы агрегатта хезмәт күрсәтә дип исәплиләр иде.

Тик бу юлы идарәдә ялгышалар иде.

Хәйдәр бөтенләй колхоз эшендә түгел.

Хәтта авылда да юк.

И балалар, балалар! Бала һәркемгә газиз, керпенең дә баласы йомшак, карга баласы да ак...

Габбас үсеп җитте дә, өйләнгәч, өйдә өч кенә көн торды, Әлмәткә күчте. Күчүенә рәнҗегән иделәр: «Бурычын түләмичә ычкынды». Эшкә универмагка урнашкач куаныштылар: «Авызы-борыны майда булыр!» Габбаслар хәзер ике елга бер генә авылга кайталар, Әлмәт — Язкилде юлын Гөлбикә апа такырлый. Кызлары Раузаны Түбән авыл егете Чаллыдан кайтып алды. Райпотребсоюзда эшләүче егет иде, берсүзсез, дүрткуллап бирделәр. Кибетче иде Рауза, тора-бара мөдир дәрәҗәсенә иреште. «Шулпасы күршедә кайнаса да, ите бездә пешәр!» — Раузаның һәм киявнең яраткан сүзе. Бу сүз Сәләхетдин абзый белән Гөлбикә апаның да йөрәгенә бик ята! Чаллы юлын да буш тотмый Гөлбикә апа, яңа шәһәрнең базарларын, кибет-складларын, бәләкәй ларёкларын гына түгел, якын елларда кайда, нинди кибет ачылачагын шәһәр төзүче иң хәбәрдар кешеләрдән дә төгәлрәк белә.

Хәйдәргә ата белән ана аерым өмет багладылар...

Хәйдәр бер җәй комбайнда ярдәмче булып йөрде дә көзгә Чистайга авыл хуҗалыгы техникумына барып керде.

Монысына да кул куйдылар.

«Чүлмәкчедән күрмәкче» булдымы, әллә күрше Мирфатыйх улы Мидхәтнең Чистайга барып уку нияте элегрәк тә тугандырмы, һич уйламаганда, истә-оста югында Хәйдәр белән Мидхәт бер агымга туры килделәр, бер бүлмәдә укыдылар, бергә практикага йөрделәр.

Мирфатыйхлар йорты белән Сәләхетдиннекеләр пыр тузышып көнләшә, байлык артыннан куышып, мал җыеп ярыша торган караңгы чак иде. Гөлбикә белән Гөлмәрьям бер-берсен

кўралмаслык дәрәҗәгә килеп җиткәннәр иде! Дөрес, терәлеп торган күрше буларак, бер урам-тыкрыклардан йөрергә туры килә, дошманлыкны ачыктан-ачык белдереп булмый, белдерергә дә ярамый, урам-сукмакта очраганда, алар зәһәр елмаешып кына сәлам алышалар, хәл-әхвәл дә сораштыргалап куялар. Әмма алар әллә ни гомердән бер-берсенең йортына аяк басмыйлар, берсе йортында ни барын кермичә дә бик яхшы белеп, тикшеренеп торалар. Өйдә чакта Гөлбикәнең күзе Гөлмәрьямнәрдә, Гөлмәрьям, өйдә туры килгәндә, ике күзен дә Гөлбикәләрдән алмый. Кергән-чыккан кеше, сөйләшенгән сүз, ялгыш кына яңгырап киткән ызгыш-талашлар — берсе дә күршеләрнең игътибарыннан читтә калмый. Ишетәләр, тыңлыйлар, җыеп баралар, икенче көнне үк халык арасына чыгаралар. Бик арттырып, матурлап чыгаралар.

Һәр тарафта кискен ярыш, каулаш бара!

Күбрәк, мулрак, симезрәк, артыграк булсын!

Ике дошман нигездә үскән егетләр чит урында — Чистайда — бергә туры килделәр. Сөйләшүләре, читләшүләре башта иптәшләрен шиккә төшергән иде, аларның авылдашлар икәнлеге бик тиз фаш булды. Иптәшләре алардан егылып көлделәр. Көлкедән ничек тә котылырга кирәк иде, ничектер, янәшә түзеп яшәргә, авылдан койрык булып килгән дошманлыкны онытып торырга иде. Сүздән сүз чыкты, уйны уй ялгады. Язкилде тумалары, авылны сагынышкан чаклары булды, яши-яши, Хәйдәр белән Мидхәт бергә чәй эчтеләр, сөйләшкәләп тә алгаладылар. Өйдән килгән кадерле күчтәнәчләр уртак табынга менде: Гөлбикә апа чәкчәкне бик тәмләп әзерләсә, Гөлмәрьям апаның пәрәмәчләрен күрүгә авыздан су килә иде. Дошманлык онытылмады, дошманлык тарихы аскы катламнарда гына калып торды, күмелде.

Малайлар, үсеп, ныгып, иңнәре киңәеп, егетләнеп, авылга каникулга кайттылар. Яңа гадәтләре аларга Язкилдегә кадәр ияреп кайтты... Тик авылда ике күршенең хәле элеккедән дә яманрак иде. Мидхәт Хәйдәр янына керергә чыкты.

— Кермә! — дип, бер генә кычкырды Мирфатыйх.

Хәйдәр Мидхәтләргә керергә җыенды.

— Йөрмә! — дип, бер генә җикерде Сәләхетдин.

Гөлмәрьям Мирфатыйхны, Гөлбикә Сәләхетдинне куәтләделәр.

— Кермәсен!

— Йөрмәсен!

Икенче көнне капка төбендә бер-берсен күрделәр, танымаганга салышып, берсе кырлар ягына, икенчесе Түбән очка карады...

Көндез очрашмыйлар, кичен бер-берсен күрмәскә тырышалар, танцыда клубның ике читендә бииләр, Югары очка аллыартлы кайталар.

Ләкин дошманлыктан ничек котылмак кирәк?!

Җәй узды, ямьле җәй... Яшьлек җәе. Көзен алар тагын Чистайда очраштылар һәм дошманлык бер дә булмаган төсле күрешеп, белешеп йөри башладылар, бергәләп чәй кайнаттылар. Бәрәңге пешерделәр.

Дошманлык һич котмәгәндә үзен сиздерде.

Практика вакытында булды бу яман хәл. Егетләрнең икесен ике тракторга утыртып, учхоз җирен сөрергә куштылар. Бер әйләнделәр кишәрлекне Хәйдәр белән Мидхәт, ике урадылар, тәмәке тартырга, фикер уртаклашырга туктадылар. Икесе дә аракыны яратып эчә һәм тәмәкене тәмләп тарта башлаган вакыт иде.

Көн эссе, көн бөркү, ник чыпчык җиле иссен... Яндыра! Икәүләшеп, трактор күләгәсенә чүмәштеләр. Суыралар, тарталар, черт тә черт төкерәләр. Ике авыздан, дүрт борын тишегеннән зәңгәр төтен ургылып чыга да һавада озак кына бөтерелеп тора. Зәп-зәңгәр рәшәле чиксез гөмбәздә күкнең йөрәге — тургай талпына.

— Минем трактор шәбрәк,— дип ирәйде кинәт Хәйдәр. Кичә сыра кушып эчелгән аракыдан аның ми тамырлары котырып сызлый иде.— Син арттан сөйрәлеп йөрмәсәң, мин кишәрлекне тизрәк үтәр идем.

— Мактанчык! — диде Мидхәт, җиргә төкереп.

— Әллә ышанмыйсыңмы?

— Трактор трактор инде! — диде, исе китмичә генә, Мидхәт. Аның бер дә юкка сүз көрәштерәсе килми иде.

— Минеке көчлерәк! — диде Хәйдәр, һаман кабарынып. Егетнең башы чатный, күз алдында аллы-кызыллы түгәрәкләр иде.— Әйдә, ышанмасаң сынап карыйбыз. Җиңә алсаң, сиңа бер ящик аракы!

«Сынап карыйбыз» дигәндә Мидхәт куркып калыр дип көткән иде Хәйдәр, әмма ике гаилә, ике егет арасында барган сүзсез көнчелек, каршылык, көрәш — бер-берсен яратмау, күрмессезлек, гаделсезлек белән теләсә нинди бәхәсне хәл итәргә әзер булу үзенекен итте: алар кул сугыштылар, тракторларны сабаннардан аердылар һәм ике ДТ-75, ике гайрәтле гыйфрит, бер-берсенә каршы таранга китте. Бер килеп бәрелештеләр тракторлар, моторлар өзмәс үкерде, металл ышкылган тавыш колакларны ярды. Чигенеп, тагын берсенә каршы икенчесе китте, күзләрен кан баскан егетләр бер-берсен изеп, таптап китәргә әзер иделәр.

Техникум яңа ике тракторын югалтты.

Техникум ике егетен югалтты.

Хәйдәр белән Мидхәткә «боксёр» кушаматы тактылар һәм судка бирделәр. Егетләрнең армия сафларына китәр чаклары

җиткән иде, шул гына аларны аяп алып калды, ата-аналарына шактый штраф түләттеләр дә егетләрне шыпырт кына озаттылар...

«Штраф түләргә» дигән язу кайткач, Сәләхетдин Хәйдәрне үз янына чакырып кертте дә:

— Җиңдеңме, ичмасам, шул сөмсез Мирфатыйх малаен? — дип сорады.

— Җиңдем,— диде, үкчәсе белән идән тырнап, Хәйдәр.

— Алайса, ярый. Түләсәк тә түләрбез шул,— диде Сәләхетдин, акча янчыгын селкеп.

Мирфатыйх та Мидхәттән допрос алды:

— Шул Сәләхетдин тилесенә җиңдермәгәнсең лә? — дип сорады.

— Җиңдермәдем,— диде Мидхәт, муенын кашып, күккә карап.

— Ярый, алайса, түләрбез инде,— диде Мирфатыйх, хатынынннан акча янчыгын тартып алып.

Егетләрне армиягә бер айда алдылар.

«Бер частька гына эләкмәсәк ярар иде!» —дип теләде Хәйдәр.

«Бергә җибәрмәүләрен сорармын!» — дип уйлады Мидхәт.

Теләкләре кабул булды, егетләрнең берсен көнчыгышка, икенчесен көнбатышка озаттылар.

Егетләр икесе бер елда, аллы-артлы диярлек, армия хезмәтеннән кайттылар. «Машина алып бирсәң, авылда калам»,— диде Хәйдәр әтисенә. «Авылда калсаң, машина алып бирәм»,— диде Мирфатыйх Мидхәткә.

Сәләхетдиннәр йортына тиз арада чия төсле «Москвич-412» кайтты. Мирфатыйхныкылар лимон төсле «Жигули»ны абзарларына алып кайтып яптылар да ел дигәндә таш идәнле, бетон түбәле, тимер ишекле, алты йозаклы гараж җиткереп тә куйдылар. «Карак түгел, җил дә үтмәс алар салган гаражларга!»

Шулай итеп, егетләр авылда калды. Башта икесе дә тракторда эшләделәр. «Берүк икесен ике басуга куегыз, югыйсә бетте баш!» — диде Сәләхетдин. «Бәладән башаяк»,— диде Мирфатыйх, акча янчыгын хатынына сузып.

Ике дисәм аз, өч җәй дисәм күп булыр, тракторда эшләгән егетләр, ялынып-ялварып, башка эшкә күчтеләр. «Эссе! Башыма ут каба... Тазалыкка туймыйм!» — диде үгез кебек Мидхәт.

«Акчасы аз төшә, өйләнәсе бар!» — диде Хәйдәр.

Мидхәт механизатор булып терлекчелеккә күчте. Хәйдәр чия төсле машинасына утырып чыгып югалды. Бер атна күренмәде, ике атна кайтмады, төгәл утыз биш көн югалып торды Сәләхетдин Хәйдәре. «Эчеп йөридер әле ул боксёр»,— диештеләр кешеләр. «Караклашып йөридер, шайтан!» — диючеләр дә

булды. Сәләхетдиннекеләр дәшмәделәр. Мирфатыйхлар йортыннан күңелле җыр яңгырады:

Бар, зимагур, кайт иленә,
Кайтсаң иген игәрсең,
Чабатаңны сука итеп,
Бутылкаңны җигәрсең.

Сәләхетдин тумасы — җете соры күзле, юка ирене һәрчак кысылган Хәйдәр — йодрыкларын йомарлап юкка гына йөрми иде читтә. Ул авылдан авылга, колхоздан колхозга, совхозга, әрмәннән грузинга, бригадирларга, әртилләргә юкка гына кагылып, эшләренә кысылып, төпченеп йөрмәде: колхозларда договор белән танышты, белеште, законнарны өйрәнде, документ үрнәкләрен күчереп алды. Кирәк икән юхаланды, кирәк икән, яртыны куйды, тагын да үзсүзләнеп, авызын тәбе төсле йомып, авылга кайтып төште. Язкилдедә яшьтәшләре белән кичке уеннарга чыгып йөрмәде, көндезләрен телевизор карады, кичләрен бик күп адреслар белән хат язды.

Икенче язда, карлар эреп юллар төшкәндә, үз ишләреннән җиде кешелек бригада туплап, күрше район колхозларының берсендә договор белән терлекчелек комплексы сала башлады. Үзен дә аямады, иптәшләренең дә җанын алды. Эшләгән эшләре көлеп тора иде, акчасын да кушуч тутырып алдылар.

Бригадасында ике доцент, өч студент һәм бер бик әйбәт инженер-ташчы бар иде, бер караңгыдан икенче караңгыгача баш күтәрми эшләделәр, төшке ашны аяк өсте генә капкаладылар, аракы белән мавыкмадылар, клуб тирәсенә эз басмадылар, хатын-кыз артыннан йөрмәделәр.

Акча!.. Акча дип таң аттырды Хәйдәр, акча дип кичен озатып җибәрде. Кышын олы өй янына тагын бер өй җиткерделәр. Хәйдәргә өйләнергә кирәк иде. «Тораммы-юкмы монда, белмим, әмма резервта йорт булу бер чакта да зыян итмәс»,— диде ул әтисенә. Сәләхетдиннәрдә җыр яңгырады, Мирфатыйхларда «траур» иде.

Язкилдедән дә, Түбән авылдан да үзенә яраклы кәләш таба алмады егет. Бусы арык, диде әнисе; икенчесен, симез, арты тегермән ташы чаклы дип, бракка, яраксызга чыгарды, улының гайрәтен чигерде.

Кызны читтән, Гөлбикә апаның күзе җитмәгән җирдән табарга кирәк иде. Ниһаять, бик озак эзләгәч, чия төсле «Москвич» бик күп юлларны таптагач, Хәйдәрнең күңеленә ятышлы кыз табылды. Ул Зәй — Чаллы юлы өстендә диярлек уртакул гына Байгол дигән авылда яшәп ятучы бер кыз икән. Әтисе, якын туганнары юк, әнисе белән икәү генә яшәп яталар... Кыз бар яктан да Хәйдәргә ошады.

— Кайсы ягын ныграк яраттың? — дип сорады ата улыннан.

— Аз сөйләшә.

— Хуп, әйбәт сыйфат,— дип мактады ата.— Тагын кайсы төше ошады?

— Өр-яңа «Жигули»е бар.

— Бәрәкалла,— диде ата.— Нигә сүзне шуннан башламадың? Күп сөйләшә торган кеше «Жигули» ала аламы?! Хәере белән килсен!

VII

Гөлбикә дә килен буласы кеше белән бик нык кызыксынды: «Ябыкмы, симезме?» — дип сорады. «Кочаклап ятканым юк бит әле!» — дип ачуланырга өлгермәде дулкынланган Хәйдәр, анасының гадәтен бик яхшы белгәнгә, сүзне озынга сузмады:

— Таманча гына инде,— дип куйды.

Шуннан арысын ата белән ана сорашып тормадылар, һәркайсысы улыннан ишеткән кадәресен зиһеннәрендә сеңдереп, уйларында таркатып йөрделәр. «Машиналы килен! Мирфатыйхларның танавы җимерелә икән! Алар кылдый-былдый матае да булмаган Түбән авылның Хәлилрахман кызын алырга йөриләр!» — дип уйлады Сәләхетдин. «Таманча гына, ди! Бу инде Гөлмәрьямнең булачак килене төсле шүрәле түгел!» — дип уйлады йөзе алланган Гөлбикә...

Ике көн, ике төн узгач, кызның исемен, яшен белештеләр. Исеме дә җанга ятышлы икән, Гөлсабира атлы, ди, яше генә бераз уйга калдырды: Гөлсабира Хәйдәрдән төгәл дүрт яшькә олы — егерме тугызда икән инде. «Әйдә,— диде соңрак ата,— малайның кадерен белер. Машинасы өр-яңа ич, яшь машина!» «Тормышлары ышанычлырак булыр, азып-тузып, мал таратып йөрмәсләр»,— дип килеште ана.

Хәйдәр булачак хатыны турында артык озаклап уйламады, аны машина бик нык кызыктырды. Энекәшләр үсеп килә, әле әтисе дә көчендә, семьяда бер машина белән генә яши торган түгел иде. Дөрес, тырышса, Хәйдәр үзе дә машина юнәтә алачак, ә болай тәгәрәп авызга кереп торганы барында нигә юкка көч сарыф итәргә?! Ул гаражны киңәйтү турында сүз кузгатты, әлеге машина да авылда торырга тиеш иде. Аннан тагын күз күрер... Шулай итеп, Сәләхетдиннекеләр килен төшерергә әзерләнә башладылар.

Гөлбикәнең күңелендә һаман бер шик кала килде, улының «таманча гына» дигәненә ышанып ук бетмәде ана, бүген иртән алар кыз карарга барырга чыктылар. Рульдә — кияү булачак Хәйдәр...

Алар киләсен беләләр иде, көтеп алдылар. Кодагый буласы кеше, «аз-маз ярдәм итәрсең» дип, Байголның ашка-суга гына

түгел, телгә дә шактый оста карчыкларының берсе булган Миңлеҗамал карендәшен дә чакырып китергән иде, йокысыз төн үткәреп, тынгысыз таңны чак-чак уздырган ике карчык кунакларны баскыч төбенә чыгып, кулларын кушырып, баш орып каршы алдылар. Ишегалдына кереп, болдыр турына килеп туктаганчы, Гөлбикә машинадан төшмәде, уклау йоткан сыман туп-туры утырып барды.

Ниһаять, төштеләр, күрештеләр.

— Менә, әни, киленең Гөлсабира шушы була инде,— диде Хәйдәр, капка ябып арттарак калган кызга борылып. Тездән шактый түбән итәкле, эре чәчәкле ачык күлмәк кигән, эре сипкелле битле, җирән чәчләрен кистереп бөдрәләткән урта буйлы кызга карап, Гөлбикә мең уй уйларга өлгерде: «Усал түгелме? Мине санлап торырмы? И Ходаем, ирне ир итәрме? Мал кадерен белерме?» Әмма күңелендә болардан да өстен бер генә уй иде: «Аз гына арыграк икән, каһәр суккыры!» Кодагыйга карап, нибарысы бер уй уйлады: «Симергән, нәләт! Кул арасындагы йорт эшләрен дә кызына тапшырып, түрдә тик утыра икән бу тәмлетамак!»

Кыз карау уртак фикер, уртак теләк белән тәмамланды: туйны Сабан туе тирәсенә, июнь ахырынарак билгеләделәр. «Кызымны ерак җиргә җибәрергә бер дә уйламаган идем бит!» — дип шыңшый башлаган Миңлесоруны ахирәте Миңлеҗамал, кече якка чакырып, себеркесез генә чабып чыгарды: «Тинтәк! Төшкән җирендә таш булсын, дип теләк телә! Ахмак!» — дип, Гөлсабираның яшенә ым кагып алды. Аш-су остасының чыш-пышын бу якта да ишеттеләр, әмма куллар сугылган, вәгъдәләр бирелгән иде, аны-моны күпертеп тормадылар.

Карчыклар мыштырдашкан арада, Хәйдәр, Гөлсабираны чолан ишегенә терәп, коймак исе килеп торган калын иреннәреннән үбеп алды.

Кодагыйлар елашып калдылар.

Хәйдәр, бик әдәпле кыланып, кәләшенә кул бирде, кыз ике куллап аның беләгенә сарылды: «Килеп йөр, Хәйдәр, берүк онытып бетермә. Саргайтырсың инде!» — дип инәлде.

Егет белән кызны Хәйдәр бригадасында ике ел рәттән эшләгән студент таныштырган иде. Алар Хәйдәргә кадәр үк, Байголда эшләгәндә, Гөлсабираларда квартирда торганнар икән. «Алтын кыз»,— диде студент.

«Алтын» сүзе Хәйдәрнең колагын иркәләгән иде.

Бүген менә кәләше егеткә бер дә ошамады. Авызын ныграк ерганда гына җемелдәп китә торган алтын тешләре дә ошамады, кояш яктысында кызыл кан булып күренгән алкалары да, алтын суы йөгерткән чәчләр дә ошамады. Күз карашыннан ук кәләшнең туймас җан икәнлеген тоеп утырды егет. Иң нык ошаганы

өр-яңа, нибарысы өч йөз җитмеш километр узган «Жигули» булды. Бусы чын мал инде! Һәм Хәйдәр аның бердәнбер хуҗасы булачак. Үлчәү табасына салганда, «Жигули» ягы баса иде.

Саубуллашып чыгып киткәч, кул болгап калган Гөлсабира белән чын күз яшьләрен чыгарган ана күздән гаип булгач, Хәйдәр җиңел сулады, авылны чыкканчы, алар бер сүз дә алышмадылар. Гөлбикә апа бик авыр көрәшләрдә җиңеп чыккан батыр кыяфәтен саклап, кулларын тезе өстенә салып, тәрәзәдән иген кырларын, бәрәңге басуларын күзәтеп бара иде.

— Машиналары әйбәтме? — дип белеште һәм, улы җавап бирмәгәч,— болай бик матур күренә икән,— дип, фикерен ныгытып алды.

Әнисе белән бер уйда барулары Хәйдәргә ошамады. Ул җәһәт кенә борылды да чия төсле «Москвич»ны юл читендәге куаклыкка алып кереп туктатты.

— Ай Аллакай гынам, ник кердең? — диде Гөлбикә апа, як-ягына каранып.

— Чишмәсе бар,— диде Хәйдәр, янындагы сумкадан стакан чыгарып. Гөлбикә апа артыгын сорашып тормады, улының кул хәрәкәтләреннән, җитдилегеннән ул барын да аңлады. Ана кеше бернәрсәне генә белми калды: әйткәнебезчә, булачак килен Хәйдәргә бер дә ошамады һәм хәзер, барган саен, ара ерагайган саен, ныграк ошамый иде. Юк гаепләр табарга да әзер иде Хәйдәрнең ачулы җаны. Мондый чакта күңелен аракы белән генә юата торган, тынгысыз җанын исереп кенә юмаларга күнеккән Хәйдәргә бераз тамак төбе чылатып алырга кирәк иде. Ул, әдәп саклап, бер чакта да әти-әнисе янында эчми иде, бүген дә шулай итте, анасына карамыйча гына, шешәне алды, ипи сыныгы белән каплаган каз кисәген бармак арасына кыстырды һәм, шактый читкә китеп, каен күләгәсенә сузылып ятты. Гөлбикә апа да моменттан файдаланды, чишмәне эзләп тапты, учы-учы белән алып, салкын суны кайнарланган киң битенә сипте.

Байтак югалып торды Хәйдәр, машина янына килгәндә, кулында буш шешә һәм таплы стаканнан башка бер әйбер дә юк иде.

— Кузгалыйк, әйдә,— диде, ашыктырмыйча гына, Гөлбикә апа. Мондый чакта улына сүз кушарга ярамаганны белә ул, белә!

— Хәзер, хәзер,— диде Хәйдәр, юл ягына күзен тондырып карап. Менә аның кашлары җыерылып күтәрелде, маңгаена ермач-ермач эзләр сибелде, аскы ирене өскесе астына кереп качты, сулышы ешайды, борын яфраклары алланды. Ул кулындагы буш шешәне агач төбенә китереп сылады, учын тезенә ышкып алды һәм ишеккә ташланды.

— Утыр тизрәк! — дип кычкырды ул, коры тавыш белән.

— Ай Аллам, ни булды тагын?

— Утыр, диләр сиңа! — диде, кай арада кереп өлгереп, машинасын кабызырга маташкан Хәйдәр. Син ашыкканда буламыни, кабынмый гына машина, бер басты стартерга Хәйдәр, ике, газны көчәйтеп карады, ниһаять, кабынды, мотор көндәм генә эшли башлауга, Хәйдәр бар көченә педальгә басты, «Москвич» ургылып алга ашыкты. Ул арада аларның борын төбеннән генә өлгергән лимон төсендәге сап-сары «Жигули» узып китте, рульдә Мидхәт, арткы урында, киерелеп, алагаем зур, калын келәм кочаклап, Гөлмәрьям утыра иде. Гөлмәрьям Хәйдәрнең машинасын күрмәде, машинаны да, кашы иләмсез җыерылган Хәйдәрне дә Мидхәт кенә абайлады, абайлагач та, тизлеген арттырды. Хәйдәр исә Мидхәт машинасы артыннан ук килә торган аллы-артлы КамАЗларга юл бирергә мәҗбүр булды, шактый көтәргә туры килде. Ул асфальтка, олы юлга чыкканда, «сары лимон» хәтсез еракка тәгәрәгән иде инде.

Сәләхетдин абзый белән Гөлбикә апа таза йөрәк биргәннәр улларына, закускасыз диярлек берүзенә бер яртыны эчеп бетерсә дә, кулы нык Хәйдәрнең, күзе әллә кайларны күрә. КамАЗларны куып узды, башка ыбыр-чыбыр машиналарны артта калдырды, күзе алда, керфек какмый, бер төшеп, бер менеп барган дугалы асфальт юлдан җилдәй тәгәрәгән сары машинаны ычкындырмый. Вакыты-вакыты белән Мидхәтнең машинасы аның күзенә сары шайтан, гыйфрит булып күренә башлый, ул, тешләрен ыржайтып, алгарак иелә төшә, газны бер көчәйтә, таучыкларда түземсезләнеп чак кына акрынаеп та ала. Юл буендагы баганалар, агачлар, каршыга килүче машиналар колак яныннан очкан ядрә кебек кенә выжлап калалар.

— Ипләбрәк, ипләбрәк! — диде Гөлбикә апа, аракы эчкән кадерле улына эндәшергә тыелганын бер дә онытмаса да.— Иплән!

— Ипләргә вакыт юк,— диде Хәйдәр, борылмыйча гына.— Күрмәдеңмени, кем узып китте мине?!

— Мирфатыйхныкылар идеме әллә алар?

— Шулар.

— Үзләренә күрә түгел тагын, алга чыккан булалар.— Гөлбикә апа үзе дә сизмәстән улын кыздырып җибәрде.

Зәйгә җитәргә тугыз-ун чакрым калганда, Хәйдәрнең «Москвич»ы озын трубалар төялгән прицеплы машинаны куып җитте. Дәү «Урал», әче куе төтен бөркеп, акрын гына үргә үрмәли иде. Мидхәт прицепны җайлап кына узып өлгерде, Хәйдәр килеп җитүгә, каршы яктан машиналар туктаусыз агылды. Пионерлар төялгән кояшлы автобуслар узды, ялга баручыларны көньяк җылысына тәгәрәтүче җиңел машиналар үтте, йөк машиналары тоташтан тәгәри торды. Хәйдәр һич алга бара алмады.

Ул прицеплы машина шофёрына йодрык күрсәтте, әнкәсенә ишеттермичә генә суганлап-борычлап, русча-татарча сүгенде. Инде кагыйдәләрне бозып, уңнан узар иде, ул якта текә яр, текә ярлар буй-буй бетон баганалар белән читләнгән. Ирнә күперенә төшкәндә, ул прицепны да, башка машиналарны да узды, әмма күз күреме кадәр ераклыкта алда да, артта да лимон төсле «Жигули» юк иде. Ул як-ягына каранды, урман, болын юлларына күз салды, әмма Мидхәт бер җирдә дә күренмәде. Ул тезенә йодрыгы белән авырттырып китереп сукты:

— Уздылар! — диде теш арасыннан.— Утырганда, син мыштырдамасаң, алга чыгармый идем мин аны!

— Аларның машинасы яхшырак худлымыни соң? — дип сорады Гөлбикә апа бераздан.

— Юлы бит, машиналар чебен урынына оча! — диде Хәйдәр, алдагы юлдан күзен аерырга да куркып.

Аларның Зәйдә йомышлары юк иде, үзәк урамнарга кагылып та тормадылар, арткы аулак урамнар аша Язкилдегә кайта торган юл башына чыктылар. Азык-төлек кибете алдына туктаган «сары лимон»ны икесе дә берьюлы абайлап алды.

— Әнә ич алар!

Гөлмәрьям апа кымшанмыйча да үз урынында утыра иде, ниндидер бәләкәй төргәк тотып кибеттән чыккан Мидхәтне күргәч сикереп үк алды:

— Тегеләр дә мыштырдап килеп җитте,— диде ул.

«Москвич» сары «Жигули» янына ук килеп туктады. Мидхәтнең авызы ерылды, кысыграк күзләрен тагын да йома төшеп:

— Я, ничек, Хәйдәр, куып җитеп булдымы? — дип эндәште. Машина эчендә җәелеп утырган Гөлмәрьям апа ияк астына салынган киртләчләрен селкетеп көлә башлады. Ах, шул сүзләреңне әйтмәгән булсаңчы, Мидхәт! Көлмәгән булсаңчы син дә, Гөлмәрьям апа!.. Хәйдәр юлга аркылы куйган машинасына таба атлады.

— Әни,— диде Мидхәт, ишеккә иелеп.— Син, төшеп, мине шушындарак көтеп тор. Бу йолкыш этәчне акылга утыртыйм инде. Узам да хәзер үк сине алырга борылып киләм.

Гөлмәрьям, улы сүзенә буйсынып, келәмен кочаклап, машинадан төште дә дәү әрекмән төбенә барып утырды. Хәйдәр дә әнисенә шыпырт кына эндәште:

— Әллә син дә төшеп торасыңмы?

— Юк,— диде, кабарынып, Гөлбикә.— Шул карачкының келәм кочаклап утырганын карап торыйммы, Ходавәндәм. Син узарсың!

Ишетмәсәң ишет, я Хода. Гөлмәрьям күршесе «карачкы»!

Сез ишеттегезме, хөрмәтле укучым? Бу хурлык тамгасы, яман сүз мине тагын үткән гомергә кайтарды, уллары Мидхәт һәм Хәйдәр белән мавыгып, без аларның газиз әнкәләре Гөлмәрь-

ям белән Гөлбикәне бөтенләй онытып бетергәнбез! Ярамый, һич тә ярамый! Шашкын куышу башланганчы, аз булса да аналарның күңел пәрдәсен күтәреп карыйк.

Бүген авыз тутырып әйтергә дә уңайсыз, әйтми калырга да ярамый, ышанасызмы-юкмы, заманында Гөлбикә белән Гөлмәрьям ахирәт дуслар иде. Әйе, әйе. Җырларда мактала торган, телләрдән телләргә күчеп йөри торган чын дуслар иде алар! Берсе — Түбән оч кызы, икенчесе Олы урамда туып үссә дә, сабый чактан ук гел бергә булдылар: курчаклы уйнадылар, тәтәй җыйдылар, бишташ чөйделәр, качышлы, әбәкле, арка кагышлы, пиштиле уйнадылар — азмы матур уеннар бар иде атаклы Зәй ягының Язкилде авылында! Барын да уйнадылар Гөлмәрьям белән Гөлбикә — аерылмас тату дуслар, ишегалларында, тар тыкрыкларда бәбкә-чебиләр белән бергә аунап, песи борчагы, акбаш ашадылар, ындыр артларына чыгып, шепкән удылар. Берсе — агач сумка, икенчесе киндер букча асып, беренче класска җитәкләшеп барып керделәр. Язларның берсендә, иң ягымлысында, Олы су ташып тынып, ярларына кайткач, яр битләренә сап-сары кимешә башлары чәчелеп утырганда, сандугачлар кунган талларда бермәнчәкләр — тал песиләре — чәчәккә әйләнгәндә, бәбәйтәкле матур күлмәкләрен киеп, беренче тапкыр су буена уенга бергә төштеләр.

Югары очта ике дус, ике яшьти дус үсә иде. Беренчесе — Сәләхетдин, икенчесе — Мирфатыйх. Шул язда, шушы җәйдә алар көлешә-көлешә янәшә кайткан, ал алъяпкычлар ябынган, иңбашларын сикертеп атлаган Язкилде чибәрләре Гөлбикә белән Гөлмәрьям артыннан иярделәр. Әй кызык та инде ул чаклар! Кызлар кайта алдан чыкы-чыкы, Мирфатыйх белән Сәләхетдин аларга якынаерга базмыйлар, бигүк артта да калмыйлар.

Күк гөмбәзе чамасыз биек, йортлар, агачлар саф көмештән коелган, аяк асты йомшак чыклы чирәм, урам-тыкрыкларга хуш исләр кереп тулган. Ямьле Олы су буенда һаман уен бара, бишле бииләр, җырлыйлар, «Кыз алыш» уйныйлар. Анда олыраклар, парлылар калды. Гөлбикә белән Гөлмәрьямнең дә адымнары җиңел, сулышлары иркен, йөрәкләр беренче тапкыр дөпдөп тибә, күңел кытыклана, гел көләсе килеп тора. Чөнки алар артыннан үсмер егетләр килә! Икәүләшеп абына-сөртенә юрттыралар! Борылалар да чыкы-чыкы кiлэләр кызлар. Борылалар да чыркылдап көлеп җибәрәләр. Гөлбикә кыюрак:

— Әй малайлар, бозавыгыз кайтмадымы әллә? — дип эндәшеп алды.

Бу сүз генә малайларны кыюландырмады, алар да көлештеләр, тик якынаерга базмадылар.

— Әниләре эзләп чыгып, ярып алып кайтыр әле менә,— дип, ахирәтен куәтләде Гөлмәрьям.

— Ярырлар менә! — Ике үсмер, тып та тып басып, алар янына чабып килде, ай нурында күзләрен елтыратышып, байтак тик карашып тордылар...

Ике егет гел бергә, ике дус кыз да бергә йөриләр... Беренче мәхәббәт хатын да алар икесе исеменнән берьюлы ике егеткә атап яздылар. «Без сезне сөябез!» — дип, хат ахырында чуклы чәчәкләр арасына җырлар өстәделәр...

А-а, беренче тапкыр су юлын үтүләр!..

Беренче мунчалар, йокысыз төннәр, татлы таңнар... Сөйләшергә уңайсызланганда, ярты ымнан, күз карашыннан, кул хәрәкәтеннән бер-берсен аңлый иде яшь киленнәр, бөтен Югары очны, Олы су буйларын яңгыратып, рәхәтләнеп көлешә торганнар иде. «Киленнәр төште, очыбызга ямь керде!» — дип куанып, Ходайга рәхмәт укыдылар Сәләхетдин белән Мирфатыйхның әтиләре.

Тамак туйгач кына, кашыкның нинди икәнен карыйсың...

Ике гаилә арасындагы мөнәсәбәтләрнең ничек һәм кайчан чатнавы турында мин алданрак сөйләп узган идем инде. Ирләр арасындагы дошманлык бертөсле булса, хатын-кыз арасында туган дошманлык меңгә төрләнә, миллионга тармаклана.

Кыскасы, кайчандыр, моннан байтак еллар элек ахирәт дуслар булып йөрешкән ике хатын арасына бүген якын барырлык түгел! Элек ак алъяпкыч ябынып, чәчләрен талир тәңкәләр белән бизәп, йөгерә-йөгерә Олы судан кайтып килгән кыйгач кашлы, нәзек билле Гөлбикә белән хәзер машинада күпереп, ачуыннан кабарынып утырган юантык хатын арасында җир белән күк аермасы бар инде! Әрекмән күләгәсендә ачы, зәһәр исле тирен сөртеп, аяк очындагы келәмнән май баскан күзен алалмыйча утырган җиңгәчәйне дә элеккеге Гөлмәрьям дип әйтү мөмкин түгел иде. Икенче хатыннар иде инде болар, «шайтан токымнары» иде...

Шулай итеп, ярыш башланды!

Зәй — Сарман юлы такыр, чия төсендәге «Москвич-412» белән сары лимон кабыклы «Жигули» берьюлы диярлек алга ыргылдылар. Авызы чалышайган, теше ыржайган Хәйдәрен күреп, Гөлбикә ап-ак булды, үзенең хәвефле эшкә тарыганын тирәннән үк аңлап алды, кан качкан иреннәре белән «ләхәүлә»сен укыды. Хәйдәрне туктату турында уйларга да, өметләнергә дә ярамый иде. Машиналар, юлны иңләп, бертигез дәрәҗәдә шактый ара уздылар. Аннары тигезлек югалды: әле берсе, әле икенчесе, улап-ярсып, алга чыкты. Моторлар тыелгысыз гүләде, тәгәрмәч шиннары әллә нинди авазлар чыгарып чинадылар, як-якка вак чуерташлар сибелде, сыек тузан күккә күтәрелде. Спидометр уклары туктаусыз уйнап, сикереп торды.

«Узам!» — диде тешләрен кыскан Мидхәт.

«Уздырмыйм!» — дип пышылдады яңак сөякләрен сынар дәрәҗәдә китереп кыскан Хәйдәр.

Машиналар бер-берсенә тия язып калалар, ике арада зәңгәрсу очкыннар сибелә. Инде урта юлга ерак та калмады. Хәзер озын гына үр төшәсе... Хәйдәр Мирфатыйх тинтәген шунда калдырырга тиеш. Икесе дә салмыш, икесе дә ачулы, икесенең дә күзе тонган, алар юл читендәге «Юл төзәтү эшләре бара!» дигән язуны да, чекерәеп торган тамганы да күрмәделәр. Очып диярлек барган шәпкә ике машинаның икесе дә казылган җиргә борыннары белән барып төртелделәр.

Чия төсендәге машинаның дүрт ишеге дә урыныннан каерылып чыкты, арткы ишеккә тотынган Гөлбикә апа, әчтән суырылып чыгып, әллә кая читкә очты, Хәйдәр маңгае белән ал пыялага килеп сыланды, машинасы капланды... әйләнеп аякланды... тагын капланды һәм... дүрт тәгәрмәченә утырып, канауда янтаеп туктады. Мидхәтнең «лимон»ы капланмады, ян белән бераз шуып барды да таш өеменә килеп сыланды.

Өчесе дә исән иделәр.

Юл тузаны утырып та өлгермәде, канау артыннан Гөлбикә апаның сыкраган тыңкыш тавышы ишетелде.

— Кулым, ай, кулым! Үләм!

Хәйдәр дә исән иде исәнен, маңгае ике җирдән каз күкәе хәтле булып шешеп чыккан, яңагы, тирән җәрәхәтләнеп, канга манчылган, күкрәк капкачы яньчелгән иде. Ул машинасыннан чыкты да, иелеп, кан косты, авызын учы белән сөртә-сөртә, машина ишекләрен җыярга тотынды, соңгы ишеккә ябышып яткан гәүдәне күргәч кенә, әнисе барлыгын хәтеренә төшерде.

— Әни, син мондамыни?

— Кулым, бетте! — дип өзгәләнде ана.

Гөлбикәнең кулы сынган иде. Аннан-моннан бәйләштереп, яньчелгән ишекләрне машинага төягәч, Хәйдәр моторны кабызып карады, машина йөри, ул үз ходында иде!

Хәйдәр «ишекләр харап булды» дип йөргән арада, кысылакысыла, Мидхәт тә көнгә чыкты. Аны танырлык түгел — битекүзе кан, иреннәре умырылып ертылган... Машинасының уң ягы яньчелеп эчкә кергән, пыялалар ватык, бензин багы кабартмага әйләнгән... «Шартламаса гына ярар иде!» — дип куркынды Мидхәт һәм Зәй ягына борылып карады. Күз кабаклары шешенгән иде, келәмен күтәреп тыр-тыр йөгереп бирегә килүче әнисен күрә алмады ул. Аның зыңлап торган башына «әле дә ярый аны утыртмаганмын» дигән уй гына килеп китте. Шул чагында Хәйдәр көндәше янына килде. «Сары лимон» йөгерекнең ни хәлгә төшүен күргәч, эчен уып хихылдарга тотынды.

— Ничек? Уздыңмы? Ә? Ха-ха-ха!

— Ертык тишектән көлә,— диде Мидхәт, иреннәрен кулы белән капшый-капшый.

— Минем машинага чурт та булмаган, мене син ничек кайтырсың?!

— Хәйдәр,— диде Мидхәт.— Бар, минем әнине генә алып кил. Ул анда коты чыгып ятадыр. Я йөрәге ярылып үләр.

Хәйдәр әнисенә карады. Йөзен чыткан Гөлбикә башын селкеде.

— Йөрмә, тизрәк булнискә кайтыйк. Чыдар әмәлем юк.— Һәм тоташ уфылдарга, ыңгырашырга керешге.— Ай, үләм! Бетүләрем шушы икән...

Хәйдәр бик кызганган төс белән кулларын җәйде:

— Синең анаң теркелди, минем әнине тизрәк апкайтырга кирәк,— диде ул. Ишекләрне арткы утыргычка төяделәр, Гөлбикә апа бу юлы алга, улы янына утырды.

— Ныгытып ябыш! — дип боерды Хәйдәр.

— Берүк акрын кайт,— дип ыңгырашты яралы ана.

— Әнине барып ал әле, ди егет. Анда барып йөрерлек, ди, безнең хәл! Инспектор-мазар күргәнче тизрәк авылга сызыйк дими!

Һәркемнең үз кайгысы, Гөлбикә апа тезенә сыгылып төшә дә: «Ай, кулым! Сынык кул белән ни хәлләр итәрмен? Туйда, кодагыйлар алдында ничек күренермен?!» — дип сыкрана. Хәйдәр аны ишетми, үз-үзенә сөйләнеп кайта:

— Да-а... Төзәткән хәлдә дә яңа булмый инде ул! Мондый ук буяуны каян табасың?.. Энекәшләргә калыр бу машина.

— Үзең җәяүгә калырсыңмы?

— Гөлсабира яшәсен!

Хәйдәрнең өйләнү-өйләнмәве нәкъ шушы урында, шушы минутта хәл ителде. Чия төсле машина әчендә җилләр уйнамаса, белмим, кияүле була алыр идеме икән Байгөлның сазаган кызы! Тегесен дә, монысын да кат-кат үлчәп, чамалап караганда, Хәйдәрнең күңеленә шик-шөбһә килеп киткәнен бая ук әйтеп узган идек инде. Авариядән соң икеләнүләр тиз онытылды, күз алдында балкып торган машинасы янында, алтын нурларга күмелеп, Гөлсабира гына җемелдәп калды.

Түбән авыл кешеләре Хәйдәрдән, аның дүрт ишегеннән җил узып йөргән ала-кола машинасын күргәч, бармак белән төртә-төртә көлә башладылар.

— Ни булды?

— Юл бит... Булды инде,— диде Хәйдәр.

— Кыз урларга барган җирдән кыйнап кайтарганнар!

«Ну бу авылны!» — диде, ачуына буылып, Хәйдәр һәм Вәзиләне хәтерләде: «Дөрес сөйли сеңел! Качарга кирәк моннан!»

— Бетергәнсең машинаңны!

— Гөл итәм әле мин аны! — дип мактанды Хәйдәр.

Машинаны һәр җәһәттән җентекләп карап, әллә никадәр сүзләр сөйләшкәч, кешеләрнең күзе Гөлбикәгә дә төште.

— Бәй, әниең дә монда икән ич! Ни булды аңа?

— Аз-маз кан түктек әле!

Көч-хәл белән больница ишеге янына барып җиттеләр. Гөлбикә апаның чыраена үлем сарысы йөгерде, иреннәреннән кан качты. «Үләм» дип ыңгырашты ул. Хәйдәр ике куллап тотып, күтәреп диярлек әнисен баскычтан менгерде, ярым караңгы коридорга барып керделәр, ике дә атламадылар — ак ишектән чыгып килүче бер кеше белән бәрелешә яздылар. Ир кеше ахылдап алды, юньләбрәк карасалар, чыгып килүче — Сәләхетдин үзе икән бит. Хәйдәрнең эткәсе. Гөлбикәнең газиз ире...

— Нишләп йөрисез монда? — диде ул, кырыс кына.

— Ә син, эткәсе? Ничек болай? — дип иңрәде Гөлбикә.

— Егылып кулны сындырдым.

— Ә? — диделәр ана белән ул, беравыздан.

Аннары өчесе дә бермәлгә шашып тынып калдылар.

— Әниемнең дә кулы сынды. Юлда капландык. Ике тапкыр тәкмәрләдек. Әле дә ничек исән калдык,— дип аңлатты Хәйдәр, ашыга-ашыга.— Сул кулы...

— Ходай саклады инде,— дип үксергә керешге Гөлбикә.

Әле генә уң кулын гипслатып Сәләхетдин чыккан бүлмәгә, күз яшьләре белән битендәге кан тапларын юа-юа, ыңгырашып, ыңгырашу арасында дөньясына, шушы каһәр суккан шайтан арбаларын уйлап чыгарган галимнәргә, машиналарны авылга кайтарып саткан кибетчеләргә ләгънәтләрен укына-укына, Гөлбикә кереп китте.

Бер кичтә аларның икесен ике палатага больницага салдылар, Сәләхетдин ирләр янына сыйды, Гөлбикә апаны хатыннар палатасына арба белән тәгәрәтеп алып керделәр.

Хәйдәр машинасын Язкилде авылына куды, бер урында да ут янмый иде, төн дә караңгы, күзе дә күрер-күрмәс дәрәҗәгә җитеп шешенгән иде. «Гөлсабира яшәсен!» — дип уйлады егет. Алдагы тормышның бар якты хыяллары хәзер Байголның сүзгә саран, әмма машиналы кызы белән бәйләнгән иде...

* * *

Түбән авыл больницасында кешеләр тынычсыз йокыга талгач, кулының сызлавына, башының авыртуына чыдый алмыйча, Сәләхетдин ишегалдына чыкты һәм баскычта утырган хатынын күреп бик гаҗәпләнде.

— Бөркү,— дип акланды Гөлбикә.— Эреп ага яздым.

— Шулкадәр симермиләр аны! — Сәләхетдин хатыныннан читкәрәк барып утырды.

— Яшь чак түгел инде,— диде Гөлбикә, итәген җилләтеп.

— Ни булды соң сезгә? Кая бәрелдегез? — Сәләхетдин, җикеренеп, хатынына карады.

— Син сорама, мин әйтмим дигәндәй, үзеңә ни булды?

— Җанын алам мин аның!

Кемнең җанын, кайчан һәм ничек аласын сөйләргә җыенганда гына, больница капкасы ачылып, аннан машина килеп керде. Олы урамнан Бибиәсманы бәбәй табарга китергәннәр икән. Яңа хәбәр больницага аңа ияреп килде: Хәйретдин агай үләргә ята икән, үзен яңа зиратка куюларын сораган.

— Бик әйбәт булган,— диде Гөлбикә, исе китмичә генә.— Яшен яшәгән дигәндәй... Менә монда булды әле эшләр! Үлдем дип торам.

Сәләхетдин хатынын кызганып бер сүз дә әйтмәде, киресенчә, сынык куллы хатынына сау чактагы төсле итеп чеәеп җикеренде:

— Чүпрәк баш, чүпрәк баш! Ни беләсең соң син? Кабак баш!

— Ай Аллам, нигә холыксызланасың? Ни әйткән әле мин?

Сәләхетдин аңлатып тормады, тәмәке төпчеген җиргә бәрде дә палатасына кереп югалды. Төне буе керфеге йомылмады, уйлады да уйлады, тик аның уенда машинаны ваткан юньсез Хәйдәр дә, чак кына үлми калган Гөлбикә дә, тиздән судка биреләчәк Мирфатыйх чалыш та юк иде, ул төне буе тоташтан Хәйретдин агай турында, аның әҗәлен сизгәч әйткән васыяте турында гына сызланып уйлады.

1979—1980



Мөхәммәт Мәһдиев
(1930—1995)

КЕШЕ КИТӘ — ҖЫРЫ КАЛА[1]

(повесть)

Атасы үлмәгән кем бар?
Баласы үлмәгән кем бар?
Халык әйтеме

I. Хисмәт кода судлашып йөрмәде...

Бәхетеңне сыер сөзсә, көтү көткән акчаңны да җыеп ала алмассың, диләр... Өйләнүнең бәла-казасы Шәяхмәт агайның нигезеннән килә. Аларның өй бурасында әйләнмәле бер бүрәнә бар. Хәбирә карчыкның әйтүенчә, бөтен бәхетсезлекнең башы шунда. Шәяхмәтнең беренче кат өйләнүе ундүртенче елда булды. Ләкин империалистик сугышның бу мәсьәләгә зыяны тимәде диярлек. Хикмәт анда булмады. Никахтан соң нәкъ кияү булып керәсе көнне генә кыздан хәбәр җибәрделәр: «Үлсәм үләм, Шәяхмәтне куеныма кертмим»,— дип, әтисенә елап тавыш чыгарган. Кызның әтисе кияү төшерәсе көнне, кара кайгысына батып, карт хәзрәт янына килде.

— Хәзрәт, кыз чыгымлап тора, нишлибез? — диде.

Карт хәзрәт сирәк сакалын сыпырып аптырап калды. Соңгы елларда, кызның ризалыгыннан башка никах укыган өчен, берике мулланың указы ычкынган иде. Бу мәсьәләне «Йолдыз» гәзите бик күзәтеп бара, аның һәр санында муллаларның кынгыр эшләрен чеметкәләп торалар. Өйлә намазына дип тәһарәт яңарткан хәзрәт үзенең фамилиясен шул секундта «Йолдыз» битендә итеп күз алдына китерде. Алла сакласын, Алла сакласын...

[1] Кыскартып бирелә.

Шәяхмәт урынына келәткә карт хәзрәт үзе керде. Келәт ишегенең аратасын тыкты да идәндәге ак җәймәле түшәктә тәгәрәп елап яткан буй җиткән кыз янына утырды.

— Асыгыз, кисегез, мулла абзый, яратмыйм шул егетне,— дип, кыз калтыранып елады.

Хәзрәт ике ут арасында калды. Кыз, чыннан да, кызганыч иде. Икенче яктан карагында — ак келәт, ап-ак җәймә җәелгән йомшак урын, Шәяхмәт тә төскә-биткә ярыйсы гына егет. Йә, нәрсә була инде киреләнмәсә? Тагын ни кирәк инде?

— Минем хакка гына,— диде хәзрәт, кызның кул аркасын сыйпап.— Әйе, минем хакка гына. Әгәр син хәзер киреләнсәң, мине харап итәсең. Никах укыган өчен, мине указсыз калдырырлар. Балаларым күп, үзем карт. Минем хакка гына... Бер дә булмаса, ике-өч атнадан аерылырсың. Зинһар дип әйтәм... Бер дә булмаса, аерым йоклап торырсыз. Алай да ярый...

Хәзрәт әйткәнчә, ике атнадан Шәяхмәтнең хатыны аерылып китте. Йортка килен кирәк иде, аннан соң чын җылы түшәкнең дә нәрсә икәнен беләсе килә иде, егет икенче хатын алу турында исәп йөртә башлады. Сугышка китәр алдыннан Шәяхмәт күрше авылдан ире хәбәрсез югалган солдатканы ияртте дә кайтты. Бу юлы инде кияүләп йөрисе түгел иде — хәзрәтне чәйгә алып киләсе дә күз алдында никах кына укытасы.

Хәзрәт бик кәефләнеп көйли-көйли, тәһарәткә әзерләнеп йөри иде.

Даре дөнья
Хуштыр, әмма
Ахры-мәүте улмаса.
Даре гокъба
Хуштыр, әмма
Шиддәте нар
улмаса...[1]

Шулвакыт аны никах мәҗлесенә чакырдылар.

Итле аш исе чыккан тәбәнәк өйгә килеп кергәч, хәзрәтнең күзе чыбылдык артындарак посынып бәлеш майлап яткан яшь киленгә төште. Һай, бу Шәяхмәт! Нинди сылу, яшь солдатканы эләктергән бит! Яшь киленнең тәнендәге куәт, дәрт ике-өч адымнан сизелеп тора иде. Менә бәхетле кеше бу Шәяхмәт... Ләкин авызына керергә язмаган ризык булса юк инде. Аркан белән тартсаң да керми.

— Иреңнең үлгәнлегенә белешмәң бармы? — диде хәзрәт, кулларын кызыл башлы сөлгегә сөртеп. Моны башта әһәмиятсез сорау дип белделәр. Үлгәнлеккә хәбәр юк иде... Хәзрәт чөйдәге бишмәтенә үрелде.

[1] Дөнья йорты, әгәр аның ахыры-үлеме булмаса, бик әйбәт; көчле ут булмаса, ахирәт йорты да әйбәт.

— Һичничек булдыра алмыйм, җәмәгать,— диде ул, авызын ачып катып калган Шәяхмәткә һәм карт-карчыкка карап.— Әйе, булдыра алмыйм. Аның өчен мөфти хәзрәтләренең фәтвасы бар: ире сугышта үлгәнлеккә белешмәсе булмаган хатыннарга никах укымаска. Әнә бүген генә гәзиттә күрдем: Бөре өязендә бер мулланың шуның аркасында указы ычкынган. Мине дә кызганыгыз: үзем карт, алты кызым бар. Указсыз мин нишлим? Ә? Ире исән-сау кайтып минем өстән мәхкәмәгә бирсә, мин нишлим? Алла берүк үзе сакласын...

Чыбылдык артыннан мышык-мышык елаган тавыш ишетелде. Яшь хатын да, Шәяхмәт тә кызганыч булып тоелдылар. Ләкин ни хәл итмәк кирәк?

Еллар үтеп, заманалар үзгәреп, соңгы хатыныннан бер-бер артлы ике бала тугач та, Шәяхмәт:

— Ну, хәзрәт, шулкадәр күңелем кергән иде теге солдаткага, бер генә кич булса да рөхсәт итмәдең,— дип, берничә тапкыр карт муллага чын-чыннан үпкә белдерде.

Өйләнү хикмәтләре нәсел буенча шулай дәвам итәр дип кем уйлаган? Шәяхмәтнең олы улы Хәкимулла тыныч вакытта, яңа заманда өйләнде, мулланың инде кирәге юк иде, шулай да шаушулы булды. Ворчулы булды.

Әтисе кебек йомык кына егет иде өйләнгәнче, уйламаганда бер-ике әкәмәт ясап ташлады. Кыш иде — ел авыр килде. Районда игеннәр начар булды, халык иписез калды. Хезмәт көне аз булган кешеләр Ташлытаудагы крахмал заводыннан бәрәңге бардасы ташыдылар. Район оешканнан бирле, анда РИК рәисе булып эшләгән Габитов шул елны гына озак авырудан соң дөнья куйды. Яман телле кулаклар колхозның икмәксез калуын шуңа бәйләп, теш ыржайтып көлделәр. Имеш, Габитов үләр алдыннан, аның урынбасары, больницага кереп:

— Синнән башка нишләрбез, иптәш Габитов? — дип, борчылып, киңәш сораган.

Тегесе, имеш:

— Бу елга түзегез, бар да булыр,— дигән. Аның урынына калган урынбасар, имеш, шунда «барда булыр» дип аңлаган...

Бераздан атлар кырыла башлады. Яшьләр икмәкле җирләргә эшкә таралдылар. Егетләр лесхоздагы ЧТЗ тракторларына шакмак турарга киттеләр. Ләкин таза егетләргә анда да туйганчы икмәк эләкми икән. Кайсыдыр бер шаян телле егет өенә хат язган да ахырына бер җыр өстәгән.

Хәкимулла, Нургалиләр
Нишләп монда килмиләр?
Кая барсаң да бер кояш,
Туя икмәк бирмиләр.

Шәяхмәт исә малайларын читкә чыгармады. Хәкимулланы ат карарга урнаштырды, аның артыннан буй үсеп килгән Нургалине, Ташлытау ТБУМына йөртеп, ничек кенә булмасын, укымышлы кеше итәргә теләде. Нәкъ шул авыр көннәрдә Хәкимулла, ат җигеп, кичләрен бер-ике тапкыр Атҗабарга барып кайтты. Малайның исәбе йомры иде — әтисе каршы килмәде. Актык күәс ипине салган көнне Хәкимулла төн уртасында кар шыгырдатып ат белән ишегалдына килеп керде. Ишек пары белән өйгә мамык шәл бөркәнгән, кыска жикет кигән, битенә мул итеп вазелин сөрткән кыйгач кашлы кыз да керде. Йортка кершән исе, салкын һава исе таралды. Зәйнәп җиңги самавырын өстәлгә китереп утыртты да, хәл-әхвәл сорашып чәй эчкәч, ак мунчага кунарга кереп киттеләр.

Урын үзгәләпме, нидәндер йокысыз төн кичерделәр. Бигрәк тә Шәяхмәт агайның эче пошты. Бу авылда өйләнүнең нәрсә икәнен аның кадәр кем белә соң? Зәйнәп җиңгинең өзлексез уң кашы тартты...

Каһәр суккан нигез! Тагын нинди борчулар күрсәтәсең бар икән? Иртән алар йортка кайтканда, яшь киленнән җилләр искән иде. Моның хикмәтен Хәкимулла белән кыз алып кайтышкан нәселдәш егет Миңлегали сөйләде. Хәкимулла, имеш, алданган.

— Күземә күренмә, син мине хур иттең,— дип, төнлә җәнҗал чыгарган, имеш.

Йа Алла! Моны күрше-күлән белсә, ни хәл итәрсең? Идарәгә ишетелсә — ни хурлык?

Ләкин монысы әле башы гына булган икән. Кояш чыгып көянтә буе күтәрелүгә, Атҗабардан кода белән кодагый килеп җиттеләр. Биек якалы толып кигән кода дигәне өйгә кереп коры гына сәлам бирде. Кодагый сәкегә утырып дога кылды.

— Хәерле бәрәкәт бирсен йортка, исән-сау торамсыз,— диде. Кода да, кодагый да, як-якка каранып, кыз белән кияүне эзләделәр. Шәяхмәт абзый белән Зәйнәп җиңгигә шул вакытта җир тишеге генә кирәк иде! Ләкин аңлашмыйча булмый. Авыр тынлыкны коры кода бозды.

— Йә, безнең кыз сездәме? Кеше төсле эшләргә ярамаганмыни? Сорап алып китәргә ярамаганмыни? Аның, шөкер, ата-анасы бар! Зинадан тумаган бит ул, тиомать!

Шәяхмәт дер-дер килде. Кода таза, кырык яшьләр чамасындагы мәһабәт ир иде.

Шул минутта йортка Хәкимулла килеп керде. Түбән карап кына, эшне аңлатты.

— Миңниса үзе тавыш чыгарды... Таң алдыннан чыгып китте... Үзе гаепле. Кая киткәнен әйтмәде. Зрәгә пырдымсызланды...

Көтелмәгән хәбәр коры коданы бөтенләй чыгырдан чыгарды. Ул таза йодрыгын әле Шәяхмәт, әле Хәкимулланың авыз тирәсендә уйната башлады.

— Әле сез шулай иттегезмени! Алай икән... Тәк, тәк... Моның өчен беләсезме нәрсә?

Хатыннар елап җибәрделәр. Коры кода калтырана башлады.

— Не смей сез кеше баласын алай страм итәргә! Менә мин сезне хөкемгә тарттырам! Имейте виду, әгәр сезне падсуд торгызмасам! Сез минем кем икәнне белмисездер әле, тиомать! Атҗабарның витсинатары Хисмәт булырмын мин! Сезне судья алдына бастырмасам, я буду собака!

Алар кызу-кызу җыенып чыгып киттеләр. Капкадан атны борганда, Хисмәт кода зур йодрыгын тагын бер селкетте.

— Әгәренки кыз өйгә кайтып кермәгән булса, аталы-уллы авылдан сөрдерәм мин сезне, тиомать!

...Көн уртасына таба буран котырды. Хәкимулла, ат җигеп, Хисмәтләрнең күрше авылдагы туганнарына китте. Кыз аларга кермәгән иде. Кайтышлый адашты. Маяктан маякка ат җитәклəп йөрде, яшь ат юл катысын таба белмәде. Озак җәфалангач, кияү егете маяк төбенә утырды да, йөгән сабын тоткан килеш, үкереп-үкереп елады. Бераздан маяклар арасыннан толып киеп атка утырган бер адәм килеп чыкты. Бу Миңлегали иде.

— Әйдә, Хәкимулла абый, борчылма, тегенең эзенә төштем мин,— диде.— Ташлытауга апаларына барып кергән. Әйдә, буран басыла, авылга таба барып карыйк...

Хисмәт кода судлашып йөрмәде. Күп тә үтмәде, аның кершәнле кызы Ташлытаудагы мануфактура кибетендә эшләүче бер егеткә ябышып чыкты. Авыл халкы бу вакыйганы артык куертмады. Тик Хисмәтнең туйда бөтен кешедән артык эчеп тә теле дә бәйләнмәгәнен шаккатып сөйләп йөрделәр. Имеш, кодалар ат туарган арада, кызыннан бер кадак май белән ярты каз сорап алган да, лапас астына кереп, шуларны сыпыртып чыккан. Ахырдан, никадәр генә сыйласалар да, Хисмәт коданы берәү дә исертә алмаган.

Шулай да Хисмәт туйдан кайтышлый Шәяхмәтләр капкасы янында чанада җырлап узды:

Уралып-уралып ага
Урал буе елгалар.
Урал буена тезелгән
Колхозлар, коммуналар.

Сәнәк күтәреп, ат абзарыннан кайтып килгән Хәкимулла, туй чанасына юл биреп, читкә карап калды. Хисмәтнең елтырап торган үткен карашы белән очрашасы килми иде аның...

III. Мондый авыруга сүз ярамый

Ташлытау станциясе булмаса, тормышны ничек алып барыр идең?

Ташлытау станциясе җирнең үзәге икән. Аннан башка тормыш, яшәеш мөмкин түгел икән. Авылдан берәү чыгып китсә — Ташлытауга. Авылга берәү кайтып керсә — Ташлытаудан. Көзге пычракта бәрәңге заданиесен шундагы крахмал заводына илтеп тапшырасы. Бәрәңге тапшыру — зур эш. Челтәрле үлчәүдә тавык йомыркасыннан кечерәк булган бәрәңге аска коела — анысы исәпләнми. Ат йөге белән килеп кергән күпер — үзе үлчәү. Имеш, карандаш салып караганнар, үлчәү сизгән. Язын ипиең бетсә, Ташлытауга барып я заготзернода, я типографиядә төнге сменада эшләргә мөмкин. Гәзит баса торган машинаны кулдан бер төн әйләндерсәң — бер бөтен түгәрәк ипи. Агитбригада килсә — Ташлытаудан. Әле көз башында гына килеп, мәктәптә сәхнә ясап, пыр туздырып тәнкыйтьләп киттеләр. Куян фермасын, урман буена салдыру планына каршы килеп, су буена салдырган ферма мөдире Шәяхмәткә барыннан да катырак әләкте. Тигез итеп киселгән кыска чәчле ике кыз сәхнәдә чәт-чәт килеп җырладылар:

Кәлимуллин Шәяхмәт —
Вредитель калдыгы.
Ул куяннарның фермасын
Су буена салдырды.

Болар Ташлытау кызлары иде...

Шәяхмәт колхозда абруйлы кеше булып исәпләнә иде — иң алгы рәттә утырган җиреннән торып, клубтан чыгып китте дә, өенә кайткач, җиделе лампасын яндырып, төне буе Ташлытаудагы зур кешеләр исеменә гариза язып утырды. Язды-сызды. «Мин, түбәндә кул куючы...», «Мин, югарыда имзамны күрсәтүче, үтенәмен сездән шул хакта...» Нәрсә хакында? Моны ул үзе дә белми иде. Тик күңел нахак сүзгә бик нык рәнҗегән иде, гарәп хәрефләре белән тулган кәгазь күңел ярасына шифа була алмады.

Ике көн үтмәде, Ташлытауга бәрәңге заданиесе илтергә киткән улы Хәкимулланың юлда аты үлеп калды. Колхоз аты юлда үлгән... Шәяхмәтнең тәбәнәк өен кара кайгы басты. Аның өе мәктәпкә әйләндерелгән мәчет янында гына иде, уразаның соңгы көнендә егетләр, элекке гадәт буенча, манарага әлвидаг[1] әйтергә менделәр. Хәер, бу инде уразаны озатудан бигрәк клуб юклык хикмәте иде. Егетләр манара башына фонарьлар, тальян гармун алып менгәннәр, авызларында тәмәке. Әлвидагның элек мондый бер җыры бар иде:

[1] *Әлвидаг* — саубуллашу, хушлашу.

Хәсәнатлар тәбдил улып
Җөмләдерлү сәйеат...

Телләренә шайтан төкергән яшьләр! Хәкимулланың Ташлытау юлында үтергән аты күрше Хәсәннең утызынчы елда колхозга тапшырган аты иде. Манара башыннан әлвидаг көенә бөтен авылга җыр таралды:

Хәкимулла Хәсән атын
Заданиедә үтергә-ә-ә-н...
Әлвидаг! Әлвидаг!
Хәкимулла Хәсән атын...

Бу җыр Шәяхмәтнең йөрәк бәгырьләрен телгәләде. Шул уңай белән семьяда рәт китте.

— Колхоз идарәсендә син юаш торасың, үзеңне вредитель дип җырлыйлар, малаеңны манарадан торып мыскыл итәләр,— дип, килене Васфикамал ярага тоз салды.

Дөньяда ике явыз булса — шуның берсе Васфикамалдыр. Ни әйтсә — зәһәр чыга, ни сөйләсә — ярага нашатырь сибә. Йортка Васфикамал килгәннән бирле, күрше-күлән белән алыш-биреш бетте. Гомер буе ипи, он, тоз, керәчин алышып яшәгән күршеләр белән Васфикамал бер ел эчендә исәп-хисапны өзде. Шәяхмәтнең «Наданнар өчен уку китабы» дигән каты тыш эченә салган бурыч кенәгәсен күз алдында учакка атты. «Шәйхиләрдән алачак ипи: өч кадак, ике чирек, бер әчмуха, бер кайчы, бер йозак авырлыгы... Хәдичәгә бирәсе солы оны: сигез кадак, бер чирек, бер богау йозагы» дип чуарланган дәфтәр бөгәрләнеп янды. Васфикамал вәгъдәсендә торды, колхоз эшен сытып эшләде. Уракта — беренче. Кеше киленнәре изелеп-елап ун-унике сотый урганда, Васфикамал арышның иң куе җиреннән егерме өч, егерме биш сотый урып килде. Иллә мәгәр бригадир да, башкалар да Ташлытау килененең теленнән куркып качалар иде. Шәяхмәтнең абыйсы — гомер буе авылда киңәш-табыш биреп йөргән Шәйхи хәлфә дә,— Васфикамалның ачы теленә бер эләгеп карагач, капкасыннан чыкмас булды. Беркөнне Васфикамал урман буена утауга киткәч кенә, бәрәңге бакчасының киртәсенә сөялеп, энесе Шәяхмәткә мәзәк сөйләде.

— Ходаның язганы, сәхабәләрнең берсе теленә шайтан төкергән шундый бер хатынга өйләнгән. Теге сәхабәнең иманын суырган бу явыз. Сәхабә кипкән, ябыккан, саргайган. Әйе... Ходаның хикмәте, бер кичне, ачуы чыгып, йөрәкләнеп китеп, теге мәлгунәнең аяк-кулын бәйләгән дә авыл читендәге ташландык коега алып барган. Әйе... Мин синең белән ун ел җәфа чиктем, моннан ары түзәр чамам юк, дигән дә коега ыргыткан. Кайтып тәһарәт яңартып, ясигъ намазын укыган бу. Әйе... Шуннан, Коръәннең ясин сүрәсен укып, сабый баладай йокыга тала бу. Тынычлап

йоклый. Анадан тугандай була. Бервакыт, Ходаның язганы, тәрәзәсен бик каты кагалар моның. Шәмен кабызып тәрәзәсенә килсә, әстәгъфирулла, тәүбә, җиде башлы дию пәрие моның тәрәзә астында җир селкетә, ди.

— Теге явызыңны тизрәк алып кит, кырык ел яшәгән коемнан куып чыгарды,— дип, җиде пар күзеннән яшь коя, ди... Әйе...

Мәзәкнең дәвамы булгандырмы, юктырмы, нәкъ шул вакытта бакча артында баш түбәсенә чүмәлә кадәр печән утырткан Васфикамал күренде. Аның җир бетереп иртәрәк кайтуы икән. Шәйхи хәлфә җәһәт кенә мунча артына сызды. Шәяхмәт, әле генә кайткан булса да, куян фермасына тайды.

Сугышның иң зурысы шул көнне чыкты. Хәер, аның кайсын иң зурысы дип әйтергә дә белмәссең. Инде шактый күрелде. Дөньяның нәрсә икәнен беләсен килсә, я тар аяк киеме ки, я өйлән, диләр бит. Васфикамал явызлыкка явыз, әмма акыллы — хикмәт. Хәкимулла ничә тапкыр кичен өеннән чыгып китеп карады. Кайтмыйм, көтмә, дип китеп карады.

Юк бит, акыллы хатынны аның белән җиңеп булмый икән. Берсендә кичен, елый-елый, капка янында аерылышты.

— Йә, ярар, Васфикамал,— диде ул, күз яшенә тыгылып,— бәхил бул. Төрле вакыт булгандыр. Бәхил бул, яме? Мин тегермән суына төшәм... Бәхил бул...

Караңгы булып килә иде. Васфикамал, иңенә шәлен салган килеш, баганага сөялеп калды.

— Ярый, ярый, бәхил, бик бәхил.— Үзе шунда ук өстәп куйды.— Бар, бар, озак йөрмә, иртәгә эшкә киткәнче печәннәрне печәнлеккә мендерәсе булыр.

Тегесе һаман киреләнде.

— Ярый, көтмә мине, бәхил бул.

Ә бераздан Миңлегалиләр капка төбендә ике тәмәке уты күренде. Кичке тынлыкта Хәкимулланың мыдыр-мыдыр сөйләшкәне ишетелә иде.

— Без инде иртәгә эшкә киткәнче печәнне мендерик. Васфикамалга авырга туры килә. Чүтки хатын-кызга авыр күтәрергә ярамый... Иртүк кер инде син.

...Кич көтү кайткан вакыт иде, Хәкимулла сәнәк күтәреп эштән кайтып керде. Сүзне Васфикамал башлады.

— Кешенең ирләре ир төсле, ат җигәләр, ә син хатын-кыз арасында печән җыеп йөрисең! Хурлыгы ни тора!

Шуннан барысы да буталды. Шәяхмәт, кеше-кара кермәсен дип, капкага арата салды. Васфикамал моны күреп тагы да ярсыды.

— Әле сез, малаегыз белән бергә, капка бикләп мине кыйнамакчы буласызмы? Менә кыйнатырмын мин сезгә! Колхозның беренче ударницасы мин, белдегезме шуны? Сез әле капка бикләсезме?

Шәяхмәт тә, Хәкимулла да ык-мык иттеләр. Кая инде Васфикамалга кагылу, үзе тимәсә... Шәяхмәт тәмле тел белән тынычлык урнаштырмакчы булды.

— Килен, сабыр, зинһар, сабыр. Нишләп без сиңа кул тидерик, ди? Аннан башка да борчулы вакытыбыз. Менә ат түләтәбез дип торалар. Бүген генә идарә утырышы булды. Сабыр, дим...

Ат түләтү турындагы хәбәр Васфикамалны чыгырыннан чыгарды.

— Әһә-ә-ә, алаймыни әле? Әле сез минем бер караңгыдан икенче караңгыга эшләгән белән ат түләмәкчемени? Тотмый торыгыз әле, яме! Тәгәрәп үлсәм үләрмен, сез ужым бозауларын рәткә салырмын! Биетәм әле мин сезне, исән булсам биетәм... Адәм көлкесе бит, адәм көлкесе. Ташлытаудан доктор спрафкысын да кәтүче юк бит, түләргә әзер торалар...

Шәйхи хәлфә, больницага киткән карчыгының озак торуына эче пошып, Ташлытау юлын күзәтергә манарага менгән иде, Шәяхмәтләр ишегалдындагы ыбыр-чыбырны беткәнче карап, тыңлап торды.

Бераздан, карчыгы белән чәй эчеп утырганда, аның чоланын Шәяхмәт какты. Шәйхи хәлфә катасын киеп чоланга чыкты, энесенең сәламен алды.

— Хәкимулланың хәле начарланып китте, авызыннан ак күбек килә,— диде Шәяхмәт, читкә карап кына.— Кереп карап чыксана... Үземнең фермага барасым бар.

Шәйхи хәлфә хәйләкәр елмайды.

— Берәр ярамаган ризык капмагандыр бит, Ходай бәндәсе?

— Юк, бер дә аны-моны ашамады. Эштән кайтты да сәкегә сузылып ятты. Шуннан — телсез-авызсыз. Син кереп чыга күр инде. Әллә нәрсә булуы бар,— дип, Шәяхмәт эшнең асылын яшерде.

Шәйхи килеп кергәндә, чоланда зәһәрләнеп килен елый, Хәкимулла, күзләрен йомып, йортта чалкан ята иде. Аның маңгаена, юешләп, сөлге япканнар, әни карчык умач уганда онга буялган куллары белән Хәкимулланың аяк киемнәрен салдырып маташа. Васфикамал, күзләрен тутырып, зур өметләр белән Шәйхи хәлфәгә карады.

Шәйхи шул вакытта бу йортта тынычлык мәсьәләсенең кинәт кенә үз кулына килеп кергәнлеген сизде.

— Барыгыз да чыгып торыгыз,— диде ул, вәкарь белән генә. Хатыннар, теләр-теләмәс кенә, чоланга таба атладылар. Шәйхи хәлфә ишекне эчтән элде. Сәкегә килеп утырды.

— Йә, ач күзеңне, энем Хәкимулла. Курыкма, бу мин, берүзем.

Хәкимулла, шикләнеп кенә, күзен ачты. Башын күтәреп йорт эчен күзәтте, берәү дә юклыгына ышангач:

— Уф-ф-ф,— дип, авыр сулап куйды.

— Йә, энем, нихәл соң, нәрсә булды?

Хәкимулла иреннәрен ялап алды.

— Үләм, дәү абый, үләм. Нишлим, киңәш бир! Кычыткан белән бер бит Васфикамал.

— Соң, энем, ниме?.. Ниме, дип инде, син аны яратасыңмы соң?

Хәкимулла тагын бер уфылдады, кипкән иреннәрен тагын ялады.

— Сүзнең дөресе кирәк, дәү абый, яратам шул мин аны. Миңа дөньяда бүтән бер кеше дә кирәк түгел. Ну, теле бит, теле...

Шәйхи хәлфә урыныннан сикереп торды.

— Йом күзеңне, энем. Менә шулай. Инде телеңне дә бераз чыгарып тешләп куй. Менә шулай. Бер ярты сәгатьтән айнырсың.

Ул барып ишек келәсен ычкындырды. Ишектән, атылып, Васфикамал килеп керде. Аның артыннан каенана... Килен зур күзләрен Шәйхигә текәде.

— Йә, ничек, Шәйхи абый җаным, ни булган?

Шәйхи ашыкмады. Вәкарь белән генә тамагын кырды.

— Менә нәрсә, җәмәгать,— диде ул.— Мондый авыруны беләм мин. Без Кышкар мәдрәсәсендә укыганда,— дип бер тарих сөйләп алды.— Инде килеп дару мәсьәләсен әйтсәгез, моңа дару бер генә: өйдә тынычлык кирәк. Мондый авыруга сүз ярамый. Келт итеп өйдә бер җайсыз сүз чыктымы — бу егыла. Икенчесендә бөтенләй борып куюыгыз ихтимал. Өйдә тавыш чыгара күрмәгез, тавыш...

Шул минутта, чыннан да, өйдә җылы тынлык урнашты. Васфикамал, көләч елмаеп, күзләрен сөртә-сөртә, Шәйхи хәлфәне ишек ачып озатты. Шәйхи артыннан каенана һәм килен чоланга чыгып баскычка утырдылар. Ташлытау ягыннан дымлы җил исә, күктә гөрелдәгән тавышлар ишетелгәләп куя. Карачкыл күк йөзен телгәләп-телгәләп, еракта яшен ялтырап ала, һавага өлгереп килгән арыш исе — бал катыш яшел башак исе таралган. Арыш басуы иртәгә кияү куенына керергә тиешле җиткән кыз кебек дулкынлана, тигезсез сулый, үзенең яшьлеге белән саубуллаша.

Бу — арыш камчылаган кич иде.

— Арыш камчылый, Хозыр галәйһиссәлам камчысын селти,— дип сөйләнеп, Хәбирә карчык ул кичне бисмилласын әйтеп, морҗаларын ябып йөрде. Аныкын белмәссең, ул Хозыр белән дус. Имеш, узган ел арыш камчылаган кичләрнең берсендә аңа бер карт кергән.

— Әссәламегаләйкем,— дип сәлам биргән.

— Безнең өйдә ир кеше юк, сәламеңне ала алмыйм, түргә уз,— дигән карчык.

Тегесе ап-ак сакаллы, ак күлмәк-ыштаннан, кулында таяк, ди. Бер тастымал җаяргә кушкан. Хәбирә карчык сәкегә ак тастымал салган.

— Рөхсәтең булса, Коръән укыр идем,— дигән юлчы.

Карт укыган арада, Хәбирә карчык тастымал өстенә ике йомырка китереп куйган.

Карт укып бетергән дә:

— Рәхмәт, килен, сәдакаң кирәк түгел, фикереңне сынар өчен генә кергән идем,— дип чыгып киткән. Өйалдына чыккан — ишегалдына чыкмаган, шуннан юк булган...

V. Йомры башлы, кәкре аяклы ир бала

Инде ул көннәр артта калдылар.

Инде бөтен авылга «кысыр» дип даны таралган Васфикамал күрше урыс авылыннан тозлы кыяр алып кайтты. Ташлытауда иртәгә Сабантуй буласы иде. Әче балның үкереп утырган, яңа тарттырган бодай оныннан келәт эчләре ап-ак булган, суелган тәкәләрнең тиресен киереп чормага элгән көннәр иде.

Васфикамал, келәткә он иләргә кергән җиреннән, авыз суын йота-йота, эче бушаган кыярны суырды. Моны әле беркем дә белми иде. Хәерлегә булсын... Көтү кайткан вакыт иде. Ташлытау Сабан туена чакырырга дип, әтисе килеп керде. Почмак яктагы мичкәнең бөкесен дың-дың китереп бәреп ачтылар. Өйгә әче бал исе тулды. Колхоз эшләреннән бераз бушаган вакыт иде, бер уңайдан күрше-күләннең ир-атын да дәшеп алдылар... Әле узган көз генә Шәйхиләрдә сыер суйган көнне ирләр мәҗлесендә сүз чыгарып алганнар иде. Ни чыкмаса, шул Борһаннан чыга инде. Мәҗлестән таралганда, аралыкта, мич башы кырыена эленгән, өелгән киемнәр арасыннан Борһан үзенең бүреген эзләде. Караңгыда ялгыш Хәкимулла бүреген алып кия язды.

— Ах-ха-ха,— дип кешнәде шул чакта Борһан,— ах-ха-ха! Харап кына булыр икән кеше! Хәкимулла бүреген кисәң — беттем диген инде. Әле минем хатынның бер малай үстерәсе килә. Юк, энем, үзеңә булсын, мә, мә... Ах-ха-ха!

Барысы да рәхәтләнеп көлделәр дә бер минуттан оныттылар һәм караңгы чоланда тәмәке кабыздылар. Тик Хәкимулла гына юк булды. Аны бераздан Шәйхи абзасы лапас астыннан алып чыкты. Хәкимулла гарьләнеп үксеп-үксеп елый иде.

...Шулар исенә төшкәч, Хәкимулла анадан яңа тугандай булып китте. Менә бетте, узды ул вакытлар... Не смей сез хәзер теш ыржайтырга!

Акрын гына иртәнге җил исеп куйды. Ул тәмле йокыдагы кешеләрнең өй түбәләрен сыйпап узды. «Йоклагыз, адәм балалары,— диде ул гүя,— йоклагыз! Бу — сезнең тыныч иртәләрегезнең соңгысы. Татлырак итеп төш күреп калыгыз, бу татлы

төш — шулай ук соңгысы. Йоклап калыгыз, сезне зур сынаулар, кара хәсрәт көтә. Нык булыгыз, адәм балалары!»

Бу җил, күп юллар узып, көнбатыштан килә иде. Кара Чыршы авылы өстеннән ул үткәндә, канатларына кара тәре ясалган самолётлар, үлем төяп, көнбатыштан көнчыгышка юл алганнар иде. Төз гәүдәле, озын сыйраклы, пөхтә киемле фашист генераллары танкларын, тупларын тыныч йокыда җәелеп яткан Россия кырларына кертә башлаган минутта Кара Чыршы авылы, чыннан да, татлы йокыда иде әле.

VIII. Ашау белән генә түгел

Сугыш башлангач та, Заһри беренче чиратта үзен кайгыртты. Улының әле сугышка яше керми иде. Райондагы таныш-белешләренә берничә түшкә сарык озатып карады. Аннан шыпырт кына районга ике йөк каен утыны илтеп кайтты. Ләкин комиссиягә чакырудан туктамадылар. Тән, теш, күз таза — нәрсә дип сугыштан калырга кирәк? Тукта, исәп кирәк, хисап кирәк, диләрме әле? Берничә сарык һәм ике йөк утын эшли алмаган эшне ике такта чәй әйләндереп чыгарды. Дөресрәге, Хәбирә карчыкның дәвасы коткарды.

— Менә, күрше, синең үзеңә генә өйрәтәм,— диде карчык,— шушы гөмбә череген, кич ятканда, колагыңа өрдер. Бер көн өрдер, өч көн өрдер, җиде көн өрдер. Колагың саңгыраулаһыр. Мичкә тәгәрәткән бәрәңгедән башка ризык ашама — йөзең саргаер. Иртән йокыдан торгач, бер чокыр тәмәке суы эч — йөрәгең кагар. Комиссиягә барасы көнне ике чокыр эч. Инде бик тә каласың килә икән — үз тизәгеңне аша. Сугыш беткәч, боерган булса, өемне сипләп бирерсең.

Ул көннәрдә Хәбирә карчык Заһрилар белән ике арада күп чабулады. Кара Чыршының МТСта шофёр булып эшләүче бер егет әйткән, имеш:

— Ну, шушы Хәбирә карчыкның ботына счётчик куяр идем, көненә күпме җыяр иде микән? — дип. Чыннан да, аның эше авыр иде, өрлек кадәр Заһрины чирлегә чыгарырга кирәк иде.

Атна-ун көн үтүгә, Заһри саргаеп кипте, күрше-күлән белән сөйләшкәндә, колагына кулын куеп тыңлый башлады. Халык арасында төрле хәбәр таралды. Имеш, комиссия вакытында военком үзе килеп кергән дә, Заһри чыгып барганда, аның янында гына идәнгә чылтыратып акча төшергән. Заһри ялт итеп борылып караган, ди. Ләкин врачлар, йөрәген тыңлап, әлегә калдырып торганнар, ди. Шулай да кодасы Шәяхмәт аны кызык итте. Бернәрсә ишетмәгәнгә салышып йөргән көннәрендә ул Заһрига хәл белергә керде. Хәл-әхвәл сөйләшеп утырган уңайдан ул кодасының кече кызы Гөлфияне янына чакырды да әкрен генә сораша башлады. Төнлә белән кемдер эскерттән

бер ат йөге салам урлаган иде. Шулай, шулай, диде Шәяхмәт, әтиең узган төн салам алып кайттымы, аны кая куйдыгыз, диде. Заһри, күзләрен елтыратып, сәке буенда утыра, Гөлфиягә нәрсәдер әйтмәкче була, ләкин сабый узган төнне булган хәлне сөйли башлый. Шуннан Заһри түзми:

— Гөлфия, бар, дуңгыз, сабагыңны кара,— дип әйтергә мәҗбүр була.

Ахырдан Гөлфиягә әләгә әләгүен, ләкин бу хәбәр халыкка фаш була. Шул көннән башлап халык белән Заһри арасында ниндидер салкын сугыш башлана, мөмкин кадәр аның белән очрашмаска, сәламләшмәскә тырышалар. Ләкин төп мәсьәлә инде хәл ителгән иде — Заһри сугыштан калып торды. Ул арада өлкән улы Әхмәтзарифның да срогы җитте. Монысын инде икенче төрлерәк юллар белән коткарырга кирәк бит, каһәресе. Дөрес, Заһри күптән инде авыл Советы секретаре белән чамадан тыш яктырып сөйләшә башлаган иде.

— Һай, сеңлем, чибәр дә кыз инде үзең, сугыш вакыты булмаса, күземне йомып, үземнең Әхмәтзарифка димләр идем сине,— дип, җае белән бер әйтеп тә салды. Секретарьның егет сайлаудан яше чыгып бара иде — Заһри кызның иң нечкә кылына чиертте. Ул ара да булмады, Ленинград марҗасыннан бер пот бәрәңгегә алыштырган кара йон күлмәк, Заһриның сандыгыннан чыгып, секретарь кыз өстенә күчте...

Яшьтәшләре беренче мәртәбә каралырга киткән көнне Әхмәтзариф, ат җигеп, көлтә кертергә чыкты: авыл Советындагы метрикада нибары бер сан үзгәргән иде.

...Беркөнне кич Заһри, идарәдән кайтканда, Шәяхмәтне сагалап торды да:

— Әйдә, кем, кода, кодагыең бик әйбәт сарык итеннән аш пешереп калды, колхоз-район хәлләрен сөйләрсең, кешесенә күрә генә берәр төрек малае да табылыр,— дип кыстый башлады. Шәяхмәт риза булды. Өрмәгән җиргә утыртмадылар председатель коданы. Өстәл астыннан гына чирегә белән аракы да чыгарылды. Бераздан Заһри шунда утырган җиреннән түнде; Шәяхмәт ашын ашап, бик рәхмәт дип кайтып китте. Икенче көнне кич, нәрәт биргәндә, Заһри кода икмәк тапшырасы атларны төнгә бүрәнә өмәсенә сорый килде. Ләкин шул минутта Шәяхмәтнең пружинасы ычкынды. Ул ачуланып өстәлгә сукканда, Заһриның бите шәмәхә кара белән тулды.

— Күземә күренәсе булма, син мине кода гына дип белдеңмени? — дип, ул аны бөтенләй куып ук чыгарды.

Гомер буенча авылда дошмансыз яшәгән Шәяхмәт өчен бу хәл бик авыр тоелды. Әмма нишләмәк кирәк? Шуның өчен дә сугыш вакыты бит ул. Ләкин бу — Шәяхмәт өенә килгән күңелсезлекләрнең башы гына иде әле...

Хәер, Шәяхмәтнең өенә хәсрәт килгәнгә инде берничә көннәр иде. Моны әле бу йортта белмиләр генә иде. Кара хәсрәт, борчак басуыннан торып, Шәяхмәтнең нигезенә керәм-керәм дип, һәр төнне канатын җилпи иде...

...Аяз төннәрнең берсе иде — Шәйхи картка басуны бер әйләнеп кайтырга куштылар. Борчак җиренә килеп җиткәч, карт анда ниндидер бер чүмәлчекнең кыймылдаганын күрде. Шуннан ни булса ул, язмыштан узмыш юк дип, таягына таянып, карт шул якка таба атлады. Артык курыкмады. Мин изге милекне саклыйм, шаять Ходай Тәгалә ярдәм бирсә кирәк дип, тегенең башына имән таягы белән берне тондырыйм дигәндә генә... теге чүмәлчек әкрен генә аягүрә басты да:

— Сау-сәламәт кенә яшисеңме, дәү абый,— дип кулын бирде. Шәйхи картның шунда егәре китеп теле тотлыкты. Ни күзе белән күрсен, каршысында энесе Шәяхмәтнең улы Нургали басып тора иде. Өс-башы таланган, билгә кадәр кара сакал, яланбаш. Башта безнекеләр нихәлдә, фәлән-төгән дигән булып сорашты. Дәү абый, диде, мине күргәнеңне бер кешегә дә әйтмә. Урман эшенә чыдый алмыйча, ФЗӨдән качкан идем, менә хәзер ерткыч хәлендә калдым, барып җәвит итәргә дә куркам, диде. Шәйхи карт телсез калды.

...Сугыш вакытында кемнең генә йортында кайгы-хәсрәт булмый? Кемнеке үлгән, кемнеке хәбәрсез, кемнеке аяксыз-кулсыз госпитальдә ята. Ләкин халык, гадәт буенча, берсе өстенә килгән кайгыны бөтен ил белән күтәрә, берсен берсе юата:

— Ил белән күрәбез, ил белән. Шунысын уйласаң гына, бераз күңел җиңеләеп китә,— дип, күрше-күлән кайгыларын уртаклаша тордылар. Тик Шәяхмәтләр өенә килгән хәсрәт кенә ил хәсрәтенә бер дә охшамаган, үзенә бертөрле, эчтән кимерә, төн йокысын, ашның тәмен качыра торган хәсрәт иде. Ни булса да булыр, әмма үзенең улы дезертирлыкка чыгар дип, карт һич кенә дә уйлап карамаган иде. Шуның өчен үстергәнмени, шуның өчен дип укытканмыни ул аны? Ничек болай булып чыкты соң әле бу? Кай төштән башлана соң бу афәтнең башы? Колхозда менә дигән итеп тормыш корган Шәяхмәт кай төштә ялгышты соң? Бу сораулар аның үзен дә, Зәйнәп җиңгине дә эштән чыгардылар. Әллә, үземә охшаган дип, иркәләбрәк үстердеме ул Нургалине? Улы турында шундый яман хәбәр чыкканнан бирле, бергә көн иткән агайлар, Шәяхмәткә сәлам бирмичә, күрмәмешкә салынып узалар, күрше-күлән йортка йомышка керми. Ул — председатель генә. Моңа нихәл чыдамак кирәк? Ә бит унсигезенче елда аны авыл халкы комбед председателе итеп сайлаган иде. Шуннан бирле гел җаваплы эштә булды Шәяхмәт. Чүкеч кебек таза егет вакытында бай атларын карап ялчылыкта уздырган көннәрен уны белән, йөзе белән кайтарды

ул. Колхозның беренче елында ук аны ферма мөдире итеп куйдылар. Хезмәт көне мул булды, йорт-җирне рәтләде. Кышлык утынны, Сабантуй җиткәнче, турап, әрдәнәгә өеп куя иде. Бәйрәмдә кунак төшерми калмады. Авылның, ичмасам, бер генә кешесе белән дә сүзгә килмәде, аны халык олылады. Нургалине укытты. Әйдә, рәхәтләнеп үссен, кемнеке — Шәяхмәтнеке дигәндә, белеп торсыннар, диде. Нургали ФЗӨгә чыгып киткәч, атна уздымы-юкмы, Шәяхмәт исеменә беренче һәм соңгы хат килде. «Бик читен, йокы аз, урман эчендә землянкада ятабыз, адәм чыдый торган түгел» дип язган иде аның кече улы. Үз гомерендә күпне күргән Шәяхмәт башта ярсыды: малаеның зоотехниклар курсын ташлавына аның бик нык ачуы килгән иде.

— Һе, шулаймы, читенме, малакасус! Сугыш вакыты диләр аны! Сугышның үзенә эләккәч күрерсең әле! Әле нитукмышты иртә уяту, өчәр тәүлек ат өстендә барган вакытлар була анда,— дип җикеренде, ләкин — ничә әйтсәң дә бала бит — эченнән Нургалине кызганды. Шулай да күңел йомшаклыгын бераүгә дә сиздермәде. Ә беркөнне кичкырын аларның капкасыннан таякка таянган Шәйхи карт, кереп:

— Әссәламегаләйкем! — дип сәлам бирде...

Шул төн эчендә Шәяхмәт ун еллыгын картайды. Йөзенә сары коелды. Яңак сөякләре очлаеп калды. Иртәгесен кырга чыгарга җегәре юк иде.

...Ул көнне көн буе йортта киңәш-табыш барды. Шәяхмәт бер генә нәрсә теләде: кайтып кына керсен иде, җирбит, тизрәк! Корт анасын япкан күк келәткә ябар иде дә туп-туры районга чабар иде. Юк, курыкмас иде дөресен сөйләргә Шәяхмәт. Шул төннән башлап, ул йокыдан калды, ишек шыгырдаса да, капка-койма шалтырап алса да, өй почмагыннан мәче үрмәләп менеп китсә дә, Нургали кайткандыр кебек тоела:

— Син, син, карале дим, ишетәсеңме? — дип, болай да йокламаган карчыгының кабыргасына төртә торган булды.

Ә Нургали алар көткән төндә түгел, чиләкләп яуган яңгырлы, әллә ниткән давыллы-хәвефле бер төн узганда, таң сорылыгы беленеп килгәндә тәрәзә чиртте. Шул көннән башлап, авыл читендәге зәңгәр тәрәзәле йорт кара кайгы, ачы хәсрәт эченә чумды. Келәткә өстерәп чыгарып бикләргә картның тәвәккәллеге җитмәде.

— Бик кәектең әле, энекәш, әллә утыз икегә кыстырырга саегып барамы эшләр? — дип, аны беркөнне Шәйхи карт дәшеп туктатты. Авыру булсаң — хәстәңне, ашарыңа булмаса, югын әйтер идең, эчең бушар иде. Юк бит, кешенеке төсле түгел.

— Ашарга-эчәргә дә әле ярыйсы гына, абый. Әмма ашау белән генә булмый икән әле. Менә мин ун ел буе байда ат карадым, бай атларына гәрәбәдәй солы бирә торган идем. Менә син атны

гел ашатып тор, түлке, кабырга арасына башак таягы белән төрткәләп, җанын кыйнап тор. Тазарамы ул ат? Кәнишне, юк. Стало быть, минем дә хәл шул чамадарак. Кеше сүзен ишетмиммени мин?

Шәйхи карт ә дип тә, җә дип тә җавап бирмәде, тамагын кырып, каланчага таба китеп барды.

Беркөн кичке аштан соң, һәркөнге аh-зарлар чыгып, «оятсыз», «әрәмтамак» кебек сүзләр барысы да әйтелеп беткәч, Шәяхмәт бугазына әллә ниткән генә бер төеннең утырганын сизде. Сүз әйтим дисә, тавышны калтырата, тын алыйм дисәң, тамак төбен буа иде ул төен.

— Менә билләһи, картаймыш көнебездә адәм рисвае итте бит, урамга чыгарлыгыбыз калмады, нәселебез череде,— дип, өзгәләнеп, урыныннан торды да ишек янындагы чөйгә элгән кызыл башлы сөлгегә туры барып битен каплады. Ак күлмәк астында җилкә сөякләре беленеп торган чандыр гәүдәсе калтырана, дерелди иде картның. Әйтерсең лә аның ул дерелдәвеннән бөтен өй селкенә, төнге давыл белән койма-капкалар шыгырдап куя, гүя алар да картны кызганалар:

— Аh, яман, сөйләп бетергесез яман сезнең хәлегез,— дияләр кебек. Нәкъ шул вакытта, чыпчык эзләп менгән мәчене куркытып, чорманың әллә кай җиреннән йөрәк өзгеч иңенче бер тавыш ишетелде. Ул тавыш үзе әллә каян, җиде кат җир астыннан чыккан төсле тонык, кызганыч иде. Бу, ун көн буена качып, чорма тәрәзәсеннән төшкән җәйге кояшның саргылт нурында саргайган, хәлсезләнгән, сакал-мыек баскан, тәмам өметсезлеккә бирелгән Нургали тавышы иде. Ниндидер серле җеп аның йөрәген әтисенең йөрәге белән бергә бәйләде, кемдер шул җепне бер үк вакытта тартты, бер үк вакытта икесенең күңелләрен кузгатты. Менә ул ирек: ул беркемгә дә кирәк түгел, кайтканнан бирле, аңа әнисенең «улым» дип дәшеп караганы юк, аны иртән йокысыннан да уятмыйлар. Ул үзенең беркемгә дә кирәк түгеллеген тәмам аңлады. Һәм күз яшьләре үзеннән-үзе коелдылар, аның саен Нургалигә куркынычрак була башлады.

Нургали хыялы белән рәхәт, дәрәҗәле көннәрне күз алдына китерде. Менә ул авыл клубында кино куя. Аппарат телсез — Нургали яңгыравыклы тавышы белән үзе аңлатып бара. Халык «томанный»га әле ияләнеп бетмәгән, аңлатмыйча булмый. Әле фильмда берәр сугыш картинасы күренсә, барысы да «безнекеләрме?» дип борылып сорыйлар. Малайлар магнето әйләндерәләр — бер пәрдәне әйләндерергә бер малай кирәк — аларны билетсез кертәсе. Качмасыннар өчен бүрекләрен җыеп аласың. Ә алар мышкылдый-мышкылдый әйләндерәләр. Аппарат чытырдый, тузанлы клубта электр яктысы көлтә булып түргә уза, малай-шалай бармаклары белән экранга сурәт төшерә. Кино

лентасыннан тәмле ис килә, соңгы рәтләрдә, аппарат янында гына, мул итеп вазелин яккан, бит урталарын кызарткан кызлар утыра. Җае килгәндә, мутраклары Нургалигә карап күзләрен елтыратып алалар, ә ул, сихерче, кеше аңламастай аппаратны үз кулында уйната... Ах, ул кичләр... Нигә генә башланды соң бу сугыш? Кем уйлаган шундый егет чормада качып ятар дип?..

....

Кызарып, таң ата. Әнә Ташлытауга таба бара торган олы юл. Ташлытау юлы өстендә быел да арыш басуы. Шул юлдан, чатыр чабып, таң атканда, Васфикамалны алып кайтканнар иде. Ул кара туры атны Васфикамал хәтерләп калды. Ул ат очраган саен, Васфикамал, яшь вакытындагы шул бәхетле таңын хәтерләп, авыр сулап, сагыш эченә чума иде. Кара туры сугыш вакытында, ачлыктан егылып, күтәрәмгә калды. Аннан аны суеп, фермадагы төлкеләргә бирделәр... Бу юлдан кырык беренче елда Хәкимулла чыгып китте. Аның киң җилкәсе арыш басуында шактый озак күренеп барды. Аннан аны үгез арбасына утыртып кайтарып куйдылар. Бу юлдан Васфикамалның «урлашкан» каенесе Миңлегали чыгып китте. Миңлегалине дә теге кара туры белән озатканнар иде... Инде бу юлда арба тәгәрмәченең эзен дә күрмәссең. Аннан инде машиналар гына чаба. Бу юлдан атлар беркайчан да атламас инде...

Яшьләр түр башына Шәяхмәт картны да чыгарып утыртканнар икән. Нариман исә һаман басып сыйлый. Инде бераз исерә дә төшкән. Җае чыккан саен, Зөлфиянең әле аркасыннан, әле беләгеннән сөеп ала. Шатлыгы эченә сыймый. Зөлфиянең ялангач беләкләре кояшта каралган, үзе ак күлмәктән. Мәҗлестә аннан чибәр берәү дә юк.

— Дәү әти, тәбриклә мине,— дип, Нариман бабасына кулын бирә.

— Әни, тәбрик ит мине,— дип, Васфикамалга кулын бирә. Васфикамалның сагышлы йөзенә елмаю чыга.

— Зөлфия! Тәбрик ит мине! Минем бүген иң шатлыклы көнем. Бу, беләсезме? Бу — гомергә бер килә. Зөлфия, син дошман сүзенә карама. Дошманнар бервакытта да мактамаслар. Әйбәт яшәрбез. Минем узган елдан калган уналты капчык бодаем гына бар. Дошман сүзенә карама. Безнең әнинең теле үткен булса да, гадел кеше ул. Син аны әле белмисең. Ул сугыш вакытында районында беренче уракчы булды. Әни, кил әле монда, тәбрик ит мине...

Яшьләр Шәяхмәтнең сөйләвен үтенделәр. Стаканнар хәрәкәткә килде. Шаулаштылар.

— Шәяхмәт кода сөйләсен!

— Бабай нәрсә әйтер икән...

— Сорыйбыз, үтенәбез. Тост әйтсен!

Шәяхмәтнең күптән инде сөйләгәне юк иде. Стаканына шыпырт кына ижевский су салып кулына алды. Бөтен гомере күз алдыннан узгандай булды. Аның бөтен гомере шушы Кара Чыршы колхозына багышланды. Колхозга иң беренче радиоалгычны ул алып кайтты. Халык ышанмады, ящик эчендә кеше бар дип уйладылар. Бераздан аны шәһәр радиокомитетына чакыртып сөйләттеләр. Ул көнне Кара Чыршы халкы, идарә янына җыелып, Шәяхмәтне тыңлады. Тамагын кыра-кыра, Шәяхмәт радио аркылы авылдашларына эндәште.

— Фәхернисә, Гыйльметдин, мине ишетәсезме? Мин — Шәяхмәт, шәһәрдән сөйлим. Әйе, мин радио кәмититендә утырам. Мине ишетәсезме?

Анда да ышанмаучылар булды. Борһан, идарәгә кереп, шкаф эчләреннән Шәяхмәтне эзләп йөрде.

— Шушында гына ул, шәһәрдә түгел,— дип, теш ыржайтты. Ә туйдагы яшьләрнең әллә ничәсендә транзистор бар. Чөй саен элеп куйганнар.

Сугыштан соң колхозда беренче электр станциясен салдырганда да, Шәяхмәт карт зур эш эшләде. Идарә, станцияне эзләп-эзләп тә таба алмагач, Мәскәүгә кеше җибәрергә булды. Бер центнер бодай сатып, шуның акчасына Шәяхмәтне Мәскәүгә җибәрделәр. Колхоздан алган бер кәгазь белән йөри-йөри, ул Верховный Советка килеп җитте. Шверник янына керде. Шверник белән алар кордаш булып чыктылар. Шуңа күрәдерме, Шәяхмәт каушамады. Иркенләп сөйләште. Мәскәүдән ул кайтып ун көн уздымы-юкмы, Ташлытау станциясенә йөк килеп туктады. Контейнерга «Кара Чыршы авылы, Кәлимуллинга» дип язылган иде. Шверникның өстәлендәге календарьга Шәяхмәтнең исеме, авылы язылды ул вакытта. Кара Чыршы авылын Шверник белә иде ул чакта. Ә хәзер... Кара Чыршы дигән сүз инде бетеп бара. Хәзер инде ул «Дружба» совхозының өченче әтдилиниясе» дип кенә йөртелә. Хәзер инде директорның исемен белүче дә аз. Кечкенә «әтдилиние»дә ул бөтенләй булмый. Утызынчы елларда салынган яхшы амбарларны, сүттереп, үзәк усадьбага ташытты. Тегермәнне сүттереп алып китте. Хәзер совхоз үзәгендә — электр тегермәне. Бу бик уңай, ләкин, шуларны сүтеп алып киткән саен, Шәяхмәтнең йөрәге әрни. Ә яшьләр моны аңламыйлар. Нәрсә, әллә шул турыда бер-ике сүз әйтергәме? Юк, аңламаслар...

Шәяхмәтнең фикерен стенадагы репродуктор бүлдерде. Анда «өченче отделение»нең бригадиры сөйли иде.

— Иптәшләр, Сабантуйга киткәнче, сыерларны туйдыру мәсьәләсен хәл итәргә кирәк булыр. Әгәр шуны эшләмәсәк, яхшы булмас, иптәшләр. Галимулла, син, арба тагып, аръяк басуга клеверга чыгарсың. Нариман, сиңа да, тракторыңа арба тагып, фермага вика илтеп кайтырга кирәк булыр. Мөмкинлек бирмә-

дек түгел, бирдек, инде өч көн кунак җыясың, туй итү ул,— кәнишне, яхшы эш, но үзеңнең төп эшеңне дә онытырга ярамас. Иптәшләр, һава хәлләре бу арада әйбәт тора, шуннан файдаланып, безнең «өченче отделение»дә эшлисе эшләрне төгәлләргә кирәк... Шуларны эшләмәсәк, яхшы булмас, иптәшләр.

Шәяхмәт карт торып басты.

— Оланнар,— диде ул, тамагын кырып,— балалар! Мин бик озак яшәдем. Әйе, озак. Инде мин, олы кеше буларак, үземнең гомеремдә алган тәҗрибәдән чыгып, бернәрсә әйтмәкче булам: дөньяның төрле вакыты була. Әйбәт чагы эләгә, менә бүгенге төсле күңелле була. Авыр вакыты була — теш кысып яшисең. Кеше үз гомерендә шуларның икесен дә күрә, кичерә. Әмма ләкин, шуның кайсы күбрәк эләгә дигәндә, минемчә, авыр вакыты күбрәк була. Әнә шунысында сынатмаска кирәк. Шунда ир була белергә кирәк. Әнә шуларны күтәрә белергә кирәк. Мин үзем шуларның барысын да үттем. Арысландай ике малай үстердем — беттеләр. Нариманның әтисе гарип булып кайтып үлде. Сезнең кебек чибәр тагын бер егетем бар иде — сугышның соңгысында — Кытай җирендә, кырык бишенче елның августында бетте. Алар гомере миңа калды.

Әмма-ләкин безне бөтенләй бетерә алмады сугыш. Без яшәрбез әле. Без диюем — менә балаларым Нариман белән Зөлфия. Әле мин аларның балаларын җитәкләп йөрермен дип уйлыйм...

Барысы да кул чаптылар.

Шәяхмәт карт, рәвешен китереп, стакан белән суны күтәреп эчте дә, мыекларын сыпыргалап, ишегалдына чыкты. Өйдә, аягүрә баскан килеш, Нариман җырлый иде. Ул Зөлфия ягыннан килгән егетләрнең берсенә кулын биргән, сузып-сузып җырлый:

Ташлытауның юлларыннан
Атлар атламас инде,
Сине миңа, мине сиңа
Ятлар мактамас инде.

Авыл тып-тын. Карт урамга чыкты. Көн инде яктырып килүгә карамастан, багана башындагы электр лампочкалары җемелдәп утыралар. Хәзер электр ерактан килә шул, кызганып тормыйлар.

Нариман һаман бер җыр җырлый. Карт кешегә яшьләр янында җырлау әдәп кагыйдәләренә каршы килмәсә, бабасы икенче бер җыр җырлар иде. Әнә Ташлытау юлы — гомерләр аккан, язмышлар күчергән, бәхет-шатлыклар, кайгы-хәсрәтләр йөрткән олы юл. Шәяхмәтнең бөтен нәселенең — ата-бабаларының, үзенең, балаларының һәм оныкларының — бөтен тормыш юлын шушы юл язышкан. Тормышка шушы юл гына шаһит. Ул юл-

дан күпме ат узган, ул атларда авылдан кемнәр генә чыгып китмәгән, кемнәр генә кайтмаган. Аз гына җил искәндә дә, ул юлдан күпме тузан күтәрелгән, ул тузан да, кешеләр кебек, йә юлдан себереп, йә өермә булып күчкән. Йә Кара Чыршыга таба, йә Ташлытауга таба. Ташлытау юлы — Шәяхмәтләр нәселенең шәҗәрәсен язучы. Яшьләр гаеп итмәсә, Шәяхмәт карт, мәҗлескә кереп, бер җыр җырлар иде хәзер. Бу аның үз гомерендә иң соңгы җыры булыр иде. Ул җыр аның бөтен гомеренә йомгак ясар иде. Карт менә болай җырлар иде:

Олы юлның тузанын лай
Үзем күрдем тузганын.
Белми калдым, сизми калдым
Яшь гомерем узганын.

Әмма, мәҗлескә кереп, карт бу җырны җырламас. Шуны җырласа, ул, йөрәге туктап, шундук егылырмын дип курка. Шуңа күрә ул аны эчтән, йөрәк белән генә җырлый. Әйдә, кычкырып Нариман җырласын. Яшьләрнең җырлар чагы.

Дөнья тын.

Авыл башында клевер басуы калкып ята. Ул басу зиратка барып терәлгән. Зиратта әле яктырмаган. Анда Хәкимулла ята. Анда Шәяхмәтнең карчыгы Зәйнәп, Шәйхи карт белән карчыгы яталар. Анда Нариманның бабасы Заһри кода ята. Анысы ничек түзеп ята диярсең. Яшь чагында мәҗлестә җырлап утыру өчен аннан да шәп кеше булмагандыр. Арыш басуы артыннан поезд тавышы ишетелде — Ташлытаудан иртәнге дачный китәдер. Ә Нариман инде Зөлфияне бер дә кулыннан ычкындырмас. Шуңадыр инде, ул теге җырны кабат башлаган:

Атлар атламас инде...
Сине миңа, мине сиңа
Ятлар мактамас инде.

1958—1978



Әхсән Баянов
(1927 елда туган)

СӘЯХӘТНАМӘ[1]

(Кама этюдлары)

Без җирне үтерәбез.
Жан Дорст, француз галиме

Җирдә биосфераны саклап калу мөмкин булыр.
Д. Арманд, совет галиме

Дөньяның мин килдем үзәгеннән,
Идел буйлап чыктым Камага.
Төнбоеклар үскән күл буена,
Кузгалаклар үскән яланга
Чакыр, әйдә, Кама, яшер мине,
Уйларымнан яшер, арала.
Кыштырдаулар дигән, тынлык дигән
Бөек Республика бар анда —
Чакыр мине, Кама, шул иленә,
Ял, урын бир арган аңыма.
Ыгы-зыгы, юрау, янаулардан
Мескен башым чатный, ярыла.
Ракета һәм яшәү тизлегеннән,
Самолёт һәм поезд шавыннан,
Трамвайлар чинау, калтыраудан,
Машиналар исе, газыннан,
Үкерүеннән... этү-төртүләрдән,
Бәхәсләрдән — яшер барыннан.

---

[1] Кыскартып бирелә.

Чакыр мине, Кама, ашыгу, каушау,
Тизлекләрне мәңге сагынмам.

О Табигать-анам, кайтты балаң
Борыла-борыла аккан көннәрдән.
Рәхәт шавың — бишек җырың тыңлап,
Бәллүемдә кабат тирбәләм.
Ник уяттың мине, төнге Кама?
Су төбеннән сәер тавышлар
Ишетелде. Кемнәр дәшә шулай?
Тавышлары, ахры, танышлар:
«Мин — авылың синең, син яралган
туфрак,

Аунап үскән яшел чирәмең.
Күккә карап чалкан яткан җирең,
Бишек җырың, яшьлек көйләрең.
Беренче һәм үлмәс мәхәббәтең,
Узган гомерең, күмелеп ятамын.
Узган гомере әнкәң, атаңның.—
Син җаныңны ташлап киттең, бала...»

Җавап бирәм, белмим кем өчен:
«Син улыңны артык сагынып бугай,
Бүтәннәрне белми, күрмисең.
Улың үзе генә синдә бәхетле иде.
Хәзер сине күмгән сулардан
Көн-төн ургый нурлар: миллион
күзләр

Бәхет, сөенеч ала шуңардан.
Бәлки, шуңар улың үзе теләп
Бөек хисен корбан иткәндер.
Күз яшьләрен яшерә-яшерә синнән,
Язмыш сүзен тыңлап киткәндер».

«Язмышны мин белмим, беләм тик
сөюне,
Бары шуны сорыйм баламнан.
Бер югалтсаң, булмый табып мине,
Булмый яңадан.
Мин булмагач ирнең йөрәгендә,
Ул соң тиеш кемне якларга?
Кемне яклап китсен яуларга ул,

Каршы ятларга?
Ышансыннар дисә, тиештер ул
Су төбенә төшеп,
Күкрәгемә төшеп ятарга».

Хаклы да син, ана, тик хаксыз да...
Һәм еракта балаң, еракта.
Мин дә менә синнән ары китәм
Үзәннәр һәм ярлар буйлата.
Мин урманнар, таулар буйлап йөрим,
Үзәннәргә эндәшәмен.
Өйләр белән сөйләшәмен,
Бәхәсләшәм, киңәшәмен.

Ава койма, ава читән.
Ир тәзәтми: «Тиздән китәм».
Авыл кучә, сүзләр оча:
— Без бу җирдә вакытлыча.
Без бу җирдә кунак төсле,
Төзү, кору — үкенечле.
Сүзләр оча, һәр көн туса:
— Вакытлыча, вакытлыча...
Яшәү монда барыбер бетәр,
Китәселәр барыбер китәр.
Кал әйттереп, типтереп кал,
Иртәгесен белсен шайтан.
. . . .
Яр буенда яшел тыкрык.
Шаярган сымак кына,
Яшь киленнәр килә суга,
Тар сукмак буйлап кына.
Кояшлар төшеп чиләккә
Уйныйлар чума-чума.
Уза китә яшь киленнәр.
Бер әби кала шунда.
Юл күрсәткән аңа кемдер
Бу чишмәгә кайчандыр.
Ул эзләп йөри хәзер
Тапмак булып шул чакларын.

Өй сүтелгән, күрше авылда
Аны өр-яңа өй кәтә.
Гомер үтелгән — хыял
Күзгә күренми тилмертә.

Сөенми әби, өй белән хәтта
Чишмә күчә дисәң:
«Яуда калган ирем кайтып,
Шушыннан эзләп йөрсә?»

Бер төшә дә бер менә ул,
Нидер укый, ялвара.
Аңламыйсың? Бар, шул яшьтә
Син тормыш башлап кара.
Яңадан башлап кара!
Соңгы кабат сайрый сандугачлар,
Соңгы кабат сөя күлне яз.
Килер язны болын каршыламас,
Диңгез булыр — болын, күл булмас.
Диңгез булыр, ләкин ул шауламас,
Сай суларга җилләр файдасыз.
Сандугачлар, талларыгыз калмас,
Кая кунып, ничек сайрарсыз?
Чит якларны мактап җырларсызмы
Мәңге оя корган җирләрсез?
Сөйгән тирәкләрне эзләрсез дә
Табалмагач кемне тиргәрсез?
. . . .
Яңа юллар ярып бара шау-шу,
Яңа җирләр яулап ала су.
Сез хаклы да, кошлар, тик хаксыз
да —
Кирәк моны белү, аңлашу.
Биеклектә тора Түбән Кама,
Канатларын җилпеп бөркеттәй.
«Әй авыллар, кушылыгыз миңа,
Алып китим зәңгәр киңлеккә!» —
Дигән сыман изи краннарын.
Чыга Чаллы аңа ярышка.
Театрга торган чират кебек,
Тезелә чират «отдел кадров»ка.

Илнең барлык, барлык якларыннан
Нигә дисең кешеләр агыла?
Беләм, күрәм:
Яшәү өләшәләр,
Бәхет өләшәләр
Кама ярында...
Җырларыгыз, кошлар, таныш миңа,
Шундый матур сезнең телегез.

Шул тел белән сөйли безнең сөйгән
Нәселебез, туган җиребез.
Сөйләшик без, әйдә, шушы телдә,
Шикләнмәгез, зинһар, килегез.
Кирәк түгел миңа каурыегыз,
Кирәк түгел мамык-тирегез,
Килегез.
. . . .
Ах, пырылдап тагын югалдыгыз:
Сүзне бүлде мылтык тавышы...
Энеләрем, сеңелләрем, шулай
Өйрәткәннәр сезне куркырга,
Бар кешелек гүя җинаятьче...
Мин дә кеше — сезнең каршыда
Кызарамын, башым июле.
Кичерерсезме, кошлар, сез мине?

Арабызда мең гасырлык чокыр
Аерым иткән безнең телләрне.
Калган сезнең чиста хәтерегездә,
Калган керле бармак эзләре.
Бурыч безнең — юу шуны, бетерү
Һәм ант бозмау һичбер вакытта.
Бар кешелек гаебен алып өскә,
Үзебезнең күңел сафлыкка
Ышандыру сезне... Без ия шундый
көчкә:

Бераз җирләр сорап килсәк тә,
Юк, кормабыз бәхетебезне ләкин
Сезнең исәпкә.
Төлке дустым, син хәйләкәр, кыю,
Алдатмассың, беләм, кил әле:
Нигә болай мине ят итәсез,
Яле, сөйлә әле.
Мин яратам барлык җанварларны
Һәм сине дә сөям, билгеле.
Нинди җавап!
— Беләм: яратасыз,
Тик үземнән бигрәк — тиремне.
Төлке җаным, ялгыш түгел сүзең,
Хак ул, шиксез.
Адәм дә тик шикләнә бит сездән:
Сез ырлыйсыз һәм тешлисез.
Тырышалар сезне сыйпаштырып

Яратырга, иркәләргә.
Ләкин бүрек, яка булып
Менгәч башка, җилкәләргә,
Яратулар була күбрәк —
Бу да шиксез.
Чөнки анда тешләшмисез...

Туган өйдән аерылулар яман...
Кайгырыштык шуңар, елаштык.
Тик елашып озак яшәп булмас,
Тынычланыйк бераз, уйлашыйк,
Уйлашыйк...

Энеләрем минем, сеңелләрем,
Үпкәләшмик, без бит — туганнар.
Вәгъдә бирсә бозмый торганнар
Күбрәк бездә... Корып куйганнар
Ниләр әнә!
Чакрымнарга киткән торбалар
Сузылып ята болын буйлата.
Снарядлар!
Тик атылмый туплар.
Снарядлар
Су астыннан алып ком ата.
Су күмәр як белән сезне аерып,
Дамба дигән ташлы юл ята.
Снарядлар сезнең өскә түгел,
Яклап ата, килгән дә сакка.
Җиребезнең бер өлеше бары
Кала диңгез дигән кунакка.
Кунакка!
Әйдә, килсен,
Яхшы ният белән булгач,
Килсен ул диңгез.
Мәңге шулай йола-гадәтебез:
Ачык чырай бездән, якты йөз.

Энеләрем минем, сеңелләрем,
Әйе, монда дамба үтәсе.
Һәм ил бирде закон: яз-җәйләрдә
Күтәрелмәс мылтык көпшәсе...
Юк, кимемәс сезнең нәселегез,
Юк, югалмас җырыгыз, телегез.
Кунак булгач, килсен ул диңгез...

Илебез киң булгач, өй тараймас,
Киң дә булсын Кама, тирән дә.
Суыбыздан ургып чыккан утлар
Яктылыгы төшсен илләргә,
Ерак өйләргә.
Сәлам булып җитсен,
Шушы җирдән китеп,
Мәңгелеккә калган ирләргә...

Яр буенда — бакча.
Ахры, узганнарны
Сөйли наратлар.
Наратларның сүзен ил-көн ятлар,
Ятлап, ирләр мәңге кабатлар.
Яшь чирәмдә йөри яшь бибиләр,
Үләннәрдән җыеп яшел төс.
Малайлар һәм кызлар
Орлык-күркә
Җыеп йөрде монда иртә-кич.
Һәм чәчтеләр биек киңлекләргә,
Сулар мәңге җитмәс җирләргә.
Яшь наратлар инде башлар игән,
Саубуллашкан төсле тирбәлә...

Төнлә яуды яңгыр.
Яшен суы
Юды ылысларны
Тузан, чүп-чардан,
Яшел төсләр шуңа чистарган.
Яр Чаллының яр буенда бакча
Бәйрәм көткән төсле бизәнгән.
Наратлар тын, салмак чайкалалар
Язгы җилдән, кичке көйләрдән.
Кичке көйләр ылысларны гүя
Чәнчәләр дә качып йөгерәләр.
Твист дигән бер тиле ритмнан
Йомшак билләр меңгә бөгеләләр.
Пычкы белән агач кискән төсле
Чыж-чыж итә көйләр.
Тилеләр
Бииләр.
Әллә гамьсез бәйрәм, әллә хәмер,
Әллә юкса нарат исеннән —
Йомшак башлар йөри тәгәрәшеп:
Йомшак башлар бүген исергән.

— Ah-ha-ha-ha! —
Ботакларга бәреләә
Көлү тавышы — күзсез, кургаш кош.
Авыр туа бөек эшләр бары,
Азгын хисләр туа тулгаксыз...
Соңгы бию монда, соңгы бәйрәм —
Шашкын була соңгы биюләр.
Йөз елларга җитәр шатлыкларны
Татып бетерергә телиләр.
Әй,
Биегез сез, әйдә.
Ә иртәгә...
Твист түгел,
Наратларны төбеннән үк
Кисәр, кыркырлар
Пычкылар —
Гильотина түгел,
Вакыт, язмыш дигән пычкылар.
. . . .
Дөнья — бакча, мәңгелектән мирас,
Без — бакчачы... Ләкин, ахрысы,
Без яраксыз бакчачылар булдык —
Кешелек өчен йөзем кызара:
Иң җайлы һәм ансат ысуллар да
Килешеп тормый безнең кулларга.

Кай төштәдер кибә күл һәм елга,
Диңгезләр дә сусый, кибегәләр.
Җәнлек-кошлар, өйдән, судан язып,
Югалуга таба йөгерәләр,
Йөгерәләр...

Дөнья буйлап гади шартлау йөри —
Җилпенмичә төшә күктән кош.
Кошлар һәм җәнлекләр —
Кешелекнең башы.
Башыбызны үзебез кисәбез.
Шартлау, кисү... Шулай киләчәкне
Кырып, таптап йөри кыргый хис.
Браконьерлык — юаш аю түгел,
Ә нацист ул, расист һәм хәсис.
Гамьсезлектән азган шул кыргый хис
Кешелекнең ырлый үзенә.
Газетада хәбәр:
— Илнең үз хуҗасын —

Соңгы индеецны ябып, кемдер
Дөнья йөзенә
Алып чыккан тимер читлек белән...
Зоопаркка куйган карарга.
Цивилизованныйлар
Кызыл тәннән,
Без яраткан төстән көлеп,
Авыз ерып баккан аңарга.

Бүген аңа, ә иртәгә читлек —
Бүтән халык, бүтән милләткә.
Тик исемнәр йөрер җир йөзендә,
Урманыннан качкан җәнлектәй.

Атом кебек шартлап, үкереп түгел,
Тавыш-тынсыз атлый һәлакәт.
Һаман итәр яшереп хәрәкәт ул,
Бакчабызның кадерен белмәсәк без,
Саклый белмәсәк.

Кызылмы төс, акмы, йә карамы,
Кешелек тоташ бер җан, бер үк тән.
Таза, тыгыз тәндә җәрәхәт һәм
Кутыр күренә элек-электән.
Аңлатты фән: әгәр авыру тәнгә
Сәламәт тән алып күчерсәң,
Авыру бетә...

Камил бер заманнан
Яфрак хәтле генә тән алып
Күчерә алсак шуны безнең чорга,
Китәр иде савыгып, яңарып.

Әй докторлар, табыгыз сез әмәл,
Кемдә, кайда шундый көч-кодрәт?!
Заман безнең көчле, таза, һиммәт,
Ярдәм аңа ләкин бик кирәк.
Ул үзенең тыгыз җилкәсендә
Күкне һаман тора күтәреп.
Калтырый тик тезләр, каушый уйлар:
«Очмас микән кинәт күк янып?
Очмас микән кинәт
Селкенмичә мәңге торган
Аяк баскан җир?
О Табигать-тәңре, киңәш бир!»

Титан сүзен ишетеп ага Кама.
Кошлар шуңа моңсу җырлаша.
Башта минем уйлар, уйлар таша,
Бар дөньяны гүя су баса...
Китәр идем бүтән дөньяга мин,
Күченүләрнең беләм, күрдем газабын...
Саклый алырмынмы?
Керпе улын түгел,
Уч төбемдә
Җир язмышын күтәреп барамын...

Мең тел бергә әйтә алмый сине
Гүзәл дип һич тә.
Туры килде гомрем синең шундый
Чуар чагыңа,
Әллә бәхет, әллә үкенечкә.
Нишлим, нишлим,
Кабул итәм сине
Һәм яратам булган көеңчә.
Әйтәм:
Зәвыгыбызча бизәү кирәк сине,
Саклау кирәк,
Саклау кирәк ләкин үзеңчә.

Чаң кагам мин:
— Бар халыклар!
Барлык теләк-гадәтләрне
Буйсындырып бары акылга,
Кул бирегез бер-берегезгә
Җир хакына, яшәү хакына!

1969

Илдар Юзеев
(1933—2004)

ӨЧӘҮ ЧЫКТЫК ЕРАК ЮЛГА...

(поэма)

Бала чакта бергә шаулап үскән
яшел чирәмнәрдә аунап үскән
яшьтәшеңә юллар чатында
очрыйсың да берчак сөенәсең...
Бала чагың
шунда гына кебек,
якында.
Ул яшьтәшең инде профессормы,
начальникмы... Әллә кем була,
бала чакны искә төшергәндә,
дәрәҗәләр-ниләр онтыла.
«Исеңдәме, яшьтәш?» — дисәләр,
күзләр зәңгәрләнә төшәләр,
җилләре дә гүя үткәннәргә,
балачакка таба исәләр.
...Мин очраттым бүген яшьтәшемне,
тукта,
әллә ялгышаммы?
Юк,
исемдә,
бар да исемдә.
Бер класста укып йөргән чаклар,
тау башына йөгереп менгән чаклар,
әйе, исемдә...
Су өстендә чалкан яткан чаклар,
бергәләшеп җәя тарткан чаклар,
әйе, исемдә...

Синме соң бу?
Әллә күрәм инде төшемдә.
Ул! Ул...
Кара бөдрә чәчләр...
Малай чакның
күләгәсе уйный төсендә...
...Урам буйлап таныш тавыш узды:
тру-тру-тру!
Пионерлар быргы җырын сузды:
тру-тру-тру!
Күңелемнең тирән җирләренә
барып җитте
быргы тавышы.
Гомерем диңгезенең чишмәсенә
алып китте
быргы тавышы.

...Ишетәсезме, Фазыл быргы уйный:
тру-тру-тру!
Зурлар тыңлый аны, кырлар тыңлый,
тру-тру-тру!
Уйна, малай, уйна, Фазылҗан,
тру-тру-тру!
Дусларыңны җыйна, Фазылҗан,
тру-тру-тру!
Әллә чишмә җырлый, әллә быргы:
челтер-челтер...
Куй быргыңны, китер гармуныңны,
китер, китер...
Өчәүләшеп китик көймәдә,
челтер-челтер...
Чишмә койган җирне эзләргә,
челтер-челтер...

Өчәү чыктык ерак юлга,
өчебез,
ишкәк тотып нәни кулга
өчебез.
Ерак киттек чишмәдән
инде без.
Фазыл уйный, без ишәбез
икебез.
Бер-ике-өч!.. Әйдә, дуслар,
ишегез.
Җиңел булыр, җырлап барсак
өчебез.

«Их!..
Бер дә генәй нужа курмәенчә,
ир булалмый ата баласы...»
Яр буйлары урман,
урман шаулый.
Урман арасы,
безгә әле ерак барасы.
Сулар кая илтә икән,
безне ниләр көтә икән, кәк-күк!
Дулкын ярга кага икән,
гомер судай ага икән, кәккүк...
Караңгы көн, болытлы төн,
барулары бигрәк читен, кәк-күк!
Кай юллардан барыйк икән,
әллә туктап калыйк микән, әйт әле, кәк-күк!
Без барында курыкма син,
Фазылҗан,
давылдан,
яңгырдан.
Әнә урман ягыннан,
Фазылҗан,
илһамланып гармуннан,
Фазылҗан,
җавап килә кәккүктән:
«Кәк-күк!
Беләсезме, өзгәләнәм нилектән?
Аерылып калдым ялгыз
кошлардан,
дуслардан
бик күптән...— ди кәккүк.—
Көймә килә, көймә килә,
өчегез дә уникедә,—ди кәккүк! —
Сезнең алда ике юл бар,
теләсә кайсын сайлагыз
үзегез,— ди кәккүк! —
Алда әле борылмалар бик күп, кәк-күк!
Йә түзегез,
йә китегез
кирегә,
хәл итегез
үзегез,— ди кәккүк! — Кәк-күк!»
Боекмагыз, дуслар, тынмагыз,
әкият сөйлим сезгә, тыңлагыз!
Егет бәхет эзләп киткән, ди,
ике юл чатына җиткән, ди,

баганага такта кагылган,
ә тактага болай язылган:
«Уңга китсәң — авыр,
    әмма
бәхет ишеген ачар,— ди икән,—
сулга китсәң — җиңел,
    әмма
бәхет синнән качар»,— ди икән.

. . . .

Беләсезме, егет кайсы юлны сайлаган?
Иеләләр, бөгеләләр
    камышлар
    җил белән.
    Карурманда
    бик куркыныч
    тавышлар
    төн белән.
Кем ул анда, бүре улыймы?
Адашкан бер бала елыймы?
Юк, юк, берәү җырлый урманда...
Кара төндә
нишләп йөри икән ул анда?
Син уйнадың «Кара урман» көен,
күмәк җырдан килеп ул тапты.
Ул күренми үзе — Төн кешесе,
атын яр буенда туктатты.
    Ул кирегә китеп бара иде,
    үзе төн шикелле кара иде.
    Әллә җырлый, әллә кычкыра,
    аңа кушылып аты пошкыра.
«Әйдә, минем көйне сыздыр, энекәш!
Әйттер, типтер, гомер уздыр, энекәш!
Утыр минем арбама, әйдә лә,
газап чигеп барма ла, әйдә, на!
Киттек!»
Туктап калдың ике юл чатында...
    Тып-тын.
    Көтәбез.
Төн кешесе көтә атында:
    «Утыр.
    Китәбез!»
Без кайтмыйбыз, китәбез!
    Ишетәсеңме, урманда
    киңәш бирә кем анда?
    Кәк-күк!

«Ике юл бар синең алда,
Фазылҗан,— ди кәккүк.—
Теләсә кайсын үзең сайла,
Фазылҗан,— ди кәккүк.—
Көймәдә кит, дусларыңны ташлама,—
ди кәккүк,—
ташлама,
гомер юлы әнә шулай башлана,—
ди кәккүк,—
башлана».

Тып-тын...
Сүзсез генә
син көймәдән төштең...
Туктадың.
Гармуныңны алдың.
«Кире китәм, авыр,
уф, ардым...»
Алга чакырып барган кәккүгебез,
чынлап киттеңме син, уйнапмы?!
Хуш инде...

Эх!
Майламаган арба тавышына
синең гармуның да кушылды.
Без калдык уйлап кына,
син киттең уйнап кына:
«Әйттер, типтер, сиптер, әйдә,
без җирдә кунак кына!»
Эх!

Өчәү чыктык ерак юлга,
өчебез,
икәү генә торып калдык
инде без,
иш, дускай!
Кай җирләргә илтеп куяр икән
чишмәбез?
Иш, дускай!
Чыккан юлдан без кирегә
китмәбез! Иш, дускай!
Колак төбендә яңгырый
тәнге ат чабышлары, их, дускай!
Чабыш атларга охшатам
гомернең агышларын, иш, дускай!

Тешләреңне кысып, әйдә,
түз, дускай!
Берешә торган малай түгел
без, дускай!
Иш, дускай!
Исте җилләр, кояш чыкты,—
барабыз,
батты кояш, ай калыкты,—
барабыз.
Туктый көймә — алдан тартып
барабыз.
Һич булмаса — алдан арчып
барабыз.
Килә-килә агымсулар
киңәя,
баруларны җиңеләя
көймәгә.

Җиде көн, җиде төн дигәндә,
алланып таң атып килгәндә,
ниһаять, күренде киң Идел!
    Ул шундый зур, шундый киң иде!
    Күр, дускай, Нур дускай,
    безнең чишмә нинди зур, дускай!
Тагын икәү чыгып киттек
юлга без,
кай җирләргә êояр икән
елгабыз?!
Көймәбездән чын тормышка
күчтек без,
җитдиләндек, үзебез дә
үстек без.
Тирә-якка зәңгәр төтен
таратып,
безне вузга алып бара
пароход.
Омтылабыз Гомер дигән
диңгезгә.
Әй кадерле, әй кадерле
син безгә!
Синдә — яшьлек, синдә — бәхет
таңым да,
сөеләчәк һәм сөячәк
ярым да.

Бик еш кына
тирән уйга чумам,
узган юлларыма карасам...
Тормыш — көймә,
әмма туктап кала,
ишкәк ишеп,
үзең бармасаң...
Һәм без бардык:
ярты ел бардык,
өч ел бардык,
алты ел бардык
һәм беркөнне нәни көймәбезне
диңгезләргә илтеп чыгардык.
Моңлы булгангамы, көймәмне мин
шигырь диңгезенә караттым.
Ә Нур дустым — Каспий диңгезендә,
капитаны зур бер корабның.

Әллә нәрсә җитми күңелемә,
кузгалам да китәм табыннан...
Яшьтәшләрнең күркәм табынында
тик берәү юк,
син юк, Фазылҗан...
Яшьтәшләрем белән басып торам
без кайчандыр
юлга чыккан чишмә янында.
Ул чагында...
«Өчәү чыктык ерак юлга,
өчебез...»
Ник килмисең ерак балачактан
бергә кушылып җырлар кешебез,
бүгенгенең яңа көен табып,
күңелебезне нурлар кешебез?
Көймә. Ишкәк. Ике юл чаты —
уен гына булган дисеңме?
Их, Фазылҗан,
ят җыр арбасыннан
тартып алыр идем мин сине...
　　Соң инде,
　　зур диңгездән
　　кипкән инешләргә
　　һич тә барып булмый шул инде.
Күрәсеңме,
күктә космонавт
яшьтәшләрең сәлам юллыйлар?

Ишетәсеңме,
илгә муллык биргән авылдашлар
яшьтәшеңнең җырын җырлыйлар:
«Кунак булып җиргә килмәдек без,
җиргә хуҗа булып килдек без,
киләчәк дигән гүзәллеккә
алып барышабыз илне без».
Галәм океанына килеп чыктык,
күңелем белән инде мин — айда.
Тулган айга карап гармун сызган,
җырлар сузган яшьтәш, син кайда?
Үтә яшьлек,
күпме дәштек:
«Кәк-күк!» —
чыкмадың,
бер хәбәр юк,
кайда
киткән сукмагың?
Кайда соң син, балачагым кәккүге?
Кәк-күк!
Эзлим сине.
Тик җавап юк.
Дәш инде.
Кәк-күк?!
. . . .
Эзләмәгез аны, яшьтәшләрем,
Кунак көен җырлап ул арыган,
«Әйттер-типтер» дигән көй артыннан
кайларгадыр китеп югалган.
...Җилләр искән,
чишмә челтерәгән,
сулар аккан
гомер шикелле.
Юллар мине бүген суд залына
утырышчы итеп китерде.
Кемне күрәм!
Улмы?
Ул...
Фазылҗан...
Җинаятьче!
Урман да юк монда, көймә дә юк,
ул утыра
агач рәшәткәләр эчендә...
...Исеңдәме?
Минем исемдә,

Ул вакытны...
«...Өчәү чыктык ерак юлга,
өчебез,
Ишкәк тотып нәни кулга
өчебез».
Ах, нигә соң шулчак, ах, нигә соң:
«Мин көймәдән төшмим!» — димәдең?!
Ах, нигә соң шулчак аңламадык
тормыш икәнлеген көймәнең.
Исеңдәме? Минем исемдә...
Пионерлар узды...
Тирән уйга салып китте быргы тавышы,
гомерем диңгезенең чишмәсенә
алып китте быргы тавышы.
Син дә, урыныңнан күтәрелеп,
шул тавышка таба омтылдың,
агач рәшәткәгә тотындың да
кире утырдың...
Исеңдәме? Минем исемдә...
Ишетәсеңме, урманда
аваз бирә кем анда?
— Кәк-күк. Кәк-күк!
Ике юл бар синең алда,—
ди кәккүк.— Кәк-күк!
Теләсә кайсын үзең сайла,—
ди кәккүк.— Кәк-күк!

1964—1965



Туфан Миңнуллин
(1935 елда туган)

ӘЛДЕРМЕШТӘН ӘЛМӘНДӘР[1]

(2 пәрдәле, 4 күренешле, пролог, интермедия һәм эпилоглы комедия)

Күп йөргән, күпне күргән, дөньяның ачысын-төчесен татыган, ләкин күңел көрлеген югалтмаган авылым картларына багышлыйм.

КАТНАШУЧЫЛАР:

Әлмәндәр — Әлдермеш авылы карты, 91 яшендә.
Искәндәр — Әлмәндәрнең өлкән малае, 70 яшендә.
Өммия — Искәндәрнең карчыгы, 65 яшендә.
Хәмдебану — Әлдермеш авылы карчыгы, 70 яшендә.
Евстигней — Әлмәндәрнең Антоновка авылындагы «знаком»ы, 85 яшендә.
Гөлфирә — Әлмәндәр улының оныгы, 17 яшендә генә.
Йөзембикә — Әлмәндәрнең карчыгы, Гөлфирә белән бер яшьтә.
Илсур — Әлдермеш авылының 5—6 яшьлек малае.
Мансур — Әлдермеш авылы егете, 18 яшендә.
Газраил — яше билгесез, ләкин карт икәне күренеп тора.
Әҗәл — ул да яшь түгел.
Фәрештә — Газраилнең секретаре.

Пролог

Беренче пәрдә ачыла. Ут икенче пәрдәне яктырта. Анда Җир шарының ике түгәрәккә бүленгән картасы эленеп тора. Карта каршына, кулына күрсәткеч таяк тотып, Газраил баскан. Ул, авыз эченнән генә ниндидер аңлаешсыз бер көйне көйләп, картадан Әлдермеш авылын эзли. Таба алмагач, кинәт борыла да кесәсеннән телефон трубкасын тартып чыгара.

Газраил *(телефон трубкасына)*. Сезме? Минем янга керегез. *(Фәрештә керә.)*

---

[1] Кыскартып бирелә.

Фәрештә. Тыңлыйм сезне, Газраил әфәнде.

Газраил *(картага күрсәтеп).* Нәрсә бу?

Фәрештә. Җир өстенең картасы.

Газраил. Җир өстенең картасы булгач, кайда монда Әлдермеш?

Фәрештә *(картадан Әлдермеш авылын эзли).* Әлдермеш... Әлдермеш... Әлдермеш... Шәһәрме ул, авылмы?

Газраил. Илле йортлы авыл булырга тиеш.

Фәрештә. Әлдермеш... Әлдермеш... Ул авыл Европаның көнчыгышында яки Азиянең көнбатышында булырга тиештер. Әлдермеш... Әлдермеш... Менә ул! Менә ул Әлдермеш!

Газраил *(картадагы Әлдермешкә таягы белән төртеп).* Кара син аны, әкәянни, кайда качып яткан.

Фәрештә. Әкәянни түгел, Газраил әфәнде, окаянный.

Газраил. Күп белмәгез! Барыгыз, бер мең биш йөз илленче номерлы Әҗәлгә әйтегез, минем янга керсен. *(Фәрештә чыгып китә. Бераздан Әҗәл керә.)*

Әҗәл. Мөмкинме?

Газраил. Кер, әйдә. Хәлләрең ничек, Әҗәл?

Әҗәл. Ярыйсы...

Газраил. Сиңа тагын командировкага китәргә туры киләчәк.

Әҗәл. Кай якка?

Газраил *(таягы белән картадагы Әлдермешкә төртеп).* Менә монда, Әлдермешкә!

Әҗәл. Анда кем бар?

Газраил. Әлмәндәр карт.

Әҗәл. Хәле начармыни?

Газраил. Киресенчә, җир җимертеп йөри.

Әҗәл. Алайса нигә?..

Газраил. Тыңла. Мин бүген Җир өстендәге адәм балаларының исемлеген карап утырдым. Кулыма Әлдермеш авылында яшәгәннәрнең һәм яшәүчеләрнең исемлеге эләкте. Шунда күрәм ки, Әлдермеш авылында элек-электән туксаннан узып яшәгән берәү дә булмаган. Чөнки бөек Алла ул авылның кешеләрен туксан яшьтән узып яшәмәсеннәр дип яраткан. Ә менә Әлмәндәр картка туксан бер. Ишетәсеңме, туксан бер! Бөек Алланың кодрәтенә буйсынмыйча, бер ел артык яшәгән. Бу ни?! Бөек Алла, бу хәлне белеп алса, миңа ни әйтер? Ни карап тордың, диярме? Кыскасы, хәзер үк Әлдермешкә юл тот. Ярты сәгать вакыт бирәм, Әлмәндәрне минем янга алып кил.

Әҗәл. Баш өсте. Әмер үтәлергә тиеш. Исеме ничек дидегез әле?

Газраил. Әлмәндәр. Әлдермештән Әлмәндәр.

Әҗәл. Биографиясе ничек?

Газраил. Картотека минем секретарем Фәрештәдә. Аңардан ал.

Әҗәл. Хушыгыз. Мин Әлдермешкә төшеп киттем.

Ут сүнә.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

I күренеш

Әлдермеш авылында Әлмәндәр картның ишегалды. Верстак. Верстак янында ышкыланган, ышкыланырга әзерләнгән такталар өеме. Ишегалдына өйнең ян тәрәзәләре караган. Койма буенда самолёт трабына охшатып эшләнгән баскыч. Баскыч өстендәге мәйданчыкка, тәхеткә охшатып, әйләнгеч кресло куелган. Ул креслога менеп утырсаң, авыл күренә. Әлмәндәр өе яныннан юл уза. Ул юлдан авыл халкы үтеп йөри. Койма, капка, тәрәзә наличниклары, баскыч төрле төсләргә буялган. Барысы да Әлмәндәр картның кулы белән эшләнгән. Ут янганда, Әлмәндәр карт верстак янында, көйли-көйли, такта ышкылый.

Әлмәндәр. Ала карга дигән әй асыл кош,
Тәүбә иттең мәллә очмаска?
Тәүбә итсәң дә син, мин итмәдем
Чибәр-чибәр кызлар кочмаска.

(Ышкылап бетергән тактасын верстакка сөяп куя да өйнең ишегалды ягына чыга торган тәрәзәсе янына килеп кычкыра.) Әй, кем бар өйдә, чәй чыгарыгыз! *(Баскычтан менеп, креслога утыра. Койма яныннан узучылар Әлмәндәргә сәлам биреп узалар; Әлмәндәр аларның сәламен рәхәтләнеп кабул итә. Кайберәүләре белән сөйләшә.)* Исән бит әле, Сәйфулла... Рәхмәт... Утырырга дигәндә утырабыз да аны... Эшкә ашыгасыңмы?.. Карале, Сәйфулла, бригадир Гаптерине күрсәң әйт, Әлмәндәр абый сиңа ахмак дип әйтте, диген. Мин үз гомеремдә кешегә андый сүз әйтмәдем, менә бүген әйтәм. Ни өчен, дисеңме? Үзе мине мыскыл итте. Эш бирми, син карт инде, рәхәтләнеп ял ит, ди. Сау бул, Сәйфулла, эшләрең уң булсын. (...) Ала карга дигән әй, асыл кош... *(Кинәт кемнеңдер килгәнен күреп, урамга арты белән әйләнеп утыра.)* Ә мин синең сәламеңне алмыйм. Син мине мыскыл иттең. Казанда укып кайткан да бригадир булган, имеш. Казанда укып кайткан булсам, мин әллә кем булыр идем. *(Кинәт урам якка әйләнеп.)* Ни дидең?.. Иртәгәме?.. Сарыклар абзарын ремонтларгамы?.. Рәхмәт, Габдрахман энем. Юкка гына Казанда укып кайтмагансың икән. Һәмишә шулай мәгънәле бул... *(Урамда Хәмдебануны күреп.)* Хәмдебану... *(Тиз генә баскычтан төшеп, капканы ача. Анда Хәмдебану карчык күренә.)*

Хәмдебану. Исәнлекме-саулыкмы, Әлмәндәр абзый.

Әлмәндәр. Шәп бит әле, Хәмдебану. Кай якка таба теркелдисең?

Хәмдебану. Шул теркелдәрлек кенә калды инде. Менә чыккан идем.

Әлмәндәр. Ишегалдына уз, Хәмдебану, сөйләшеп утырыйк. *(Хәмдебану ишегалдына кергәч, капканы яба да бикләп үк куя.)* Әйдә, түрдән уз, утыр.

Хәмдебану *(такталарны күреп)*. Үзең бер генә дә тик тормыйсың, Әлмәндәр абзый. Тагын ни ясарга җыенасың?

Әлмәндәр *(түбәтәен артка чигереп)*. Дача.

Хәмдебану. Ни дидең?

Әлмәндәр. Дача, Хәмдебану, дача! Казанга баргач, Искәндәрнең кызының кызы Казан читендәге бакчаларына алып барды. Шунда тактадан өй салганнар, шул дача дип атала, белдеңме?

Хәмдебану. Алай икән. Син дә шуны эшлим дисеңме?

Әлмәндәр. Ясыйм. Бакча уртасына дача ясап куям.

Хәмдебану. Ындыр табагы чаклы бу өегез кысанга киттемени?

Әлмәндәр. Китте. Килен явызланды. Картая башлады. Картайган саен явызлана. Вулмады, малайның бәхете булмады, озын гомерле хатынга туры килде.

Хәмдебану. Алай димә, Әлмәндәр абзый, үзең дә Аллага шөкер.

Әлмәндәр. Үзең дә... Нәрсә үзем дә?.. Мин — ир кеше. Ир кеше үз гомерендә ике хатын да җирләрлек яшәмәгәч, ир кеше буламы.

Хәмдебану. Әстәгъфирулла...

Әлмәндәр. Син курыкма, Хәмдебану. Мин ике генә дидем, өч димәдем. Син, Ходай кушса, озак яшәрсең. Нишләтим, Йөзембикә белән Фәхриҗамалның гомерләре кыска булды: берсе алтмышта, икенчесе җитмеш дүрттә дөнья куйдылар. Үзең беләсең, гаебем юк, үз әҗәлләре белән үлделәр... Инде менә болай, Хәмдебану, сиңа әйтергә күптән йөрим, ялгыз башың яшәве сиңа җиңел түгелдер... Әллә, минәйтәм... Чык син миңа кияүгә...

Хәмдебану. Әстәгъфирулла...

Әлмәндәр. Өрмәгән җиргә дә утыртмам, җәй көннәре бакча уртасындагы дачада яшәрбез.

Хәмдебану. Килешмәгәнне... Олы башың белән әллә ниләр сөйләп утырасың, Әлмәндәр абзый. Җитмеш яшьлек карчыктан көлмәсәң...

Әлмәндәр. Көлмим мин, чынлап әйтәм, Хәмдебану. Ир башым белән килен кулына карап ята алмыйм ич инде мин. Җир җимертеп йөргән чагымда...

Хәмдебану. Кит, кит, Әлмәндәр абзый. Картая алмадың. Мин белә белгәннән авылның Шүрәлесе булдың.

Әлмәндәр. Шүрәле булып ни явызлык кылдым?

Хәмдебану. Явызлык кылдың димим, кеше көлдерден.

Әлмәндәр. Көлсә ни булган?..

Хәмдебану. Булмаса да...

Әлмәндәр. Син, Хәмдебану, тегеләй-болай дигән булып миннән гаеп эзләмә. Миннән дә әйбәтрәкне таба алмассың. Борганалма, Хәмдебану.

Чәчең бөдрә, чәчең көдрә,
Көдерәсен җил өрә;
Боргаланып йөргән булып,
Кызлар үзен сөйдерә.

Хәмдебану. Әстәгъфирулла... Тфү, кешедән оят! *(Кинәт борылып, капкага таба атлый.)* Чакырып кертеп, рисвай итеп чыгармасаң... *(Капканы тарткалап.)* Кая, нәрсә соң бу?

Әлмәндәр. Бикләнгән ул, Хәмдебану...

Хәмдебану. Ач, ач тизрәк.

Әлмәндәр. Нәрсә кычкырасың. Әйтмәк бар, көчләмәк юк. Хәзер элекке заман түгел, бар да үз иркеңдә. Теләмисең икән, дүрт ягың кыйбла. Үзеңә яхшылык эшләмәкче идем. *(Капканы ачып, Хәмдебануны чыгарып җибәрә. Сөйләнеп кала.)* Муладис карчык, нык тора.

Мансур тавышы: Исәнмесез, Әлмәндәр бабай.

Әлмәндәр. Исәнме әле, малай. Әйдә, кер. *(Мансур керә.)*

Мансур. Кереп торырга вакытым юк. Әлмәндәр бабай, Гөлфирә кайтмадымы әле?

Әлмәндәр. Кем соң ул Гөлфирә?

Мансур. Көлмә инде, Әлмәндәр бабай.

Әлмәндәр. Көләм әле, малай. Гөлфирәнең кем икәнен әйтмәсәң, мин дә әйтмим.

Мансур. Синең оныгың.

Әлмәндәр. Дөрес әйтмәдең, оныгымның кызы. Минем оныгымның кызы сиңа нигә кирәк?

Мансур. Нигә кирәк дип, болай гына.

Әлмәндәр. Бар чыгып кит. Минем оныгымның кызы болай гына кирәк булгач, сөйләшеп тә тормыйм.

Мансур. Кайтмадымыни?

Әлмәндәр. Белмим.

Мансур. Әйт инде, Әлмәндәр бабай.

Әлмәндәр. Әйт, нигә кирәк?.. Яратам, шуңа кирәк диген, җебегән авыз... Кайтмады әле. Кайткач, үзем барып әйтермен.

Мансур. Сау булып тор, Әлмәндәр бабай.

Әлмәндәр. Исән бул, малай. *(Мансур чыгып киткәч, капканы яба да тәрәзә янына килә.)* Әй!.. Әй, дим. Нәрсә анда, әллә йоклап ятасызмы? Чәй чыгарыгыз! *(Җавап бирүче булмагач, тәрәзәне шакырга тотына. Тәрәзә ачыла, анда Өммия.)*

Өммия. Ни булды инде тагын?

Әлмәндәр. Әллә колагыгызга сумала сылап куйдыгызмы? Ярты сәгать кычкырам.

Өммия. Йә-йә, эткәй, узынма. Нәрсә кирәк?

Әлмәндәр. Нәрсә кирәк... Чәй кирәк!

Өммия. Самавыр кайнаган, өйгә кереп эч.

Әлмәндәр. Өйгә кереп эчәргә — беткән, ди, минем эшем. Мин бит сезнең кебек тик ятмыйм.

Өммия. Кем кушкан сиңа... Кирәкле эш эшләп йөрмисең, такта әрәм итеп кенә йөрисең.

Әлмәндәр. Телеңә салынма. Килен булсаң, телеңне тый.

Өммия. Җитәр, болай да кырык ел тел яшердем. Җүләр булганмын.

Әлмәндәр. Кырык ел сөйләмәгәнеңне ун елда чыгарып бетердең инде. Матри, килен!.. Мин кызсам...

Өммия. Кызсам дигән була... Кызып нишләрсең... *(Тәрәзәне ябып куя.)*

Әлмәндәр. Уңмады, уңмады малай. Әрәм үтте гумере малайның. Шулай... Чурту-матыр, дөбер-шатыр, үтте китте яшь гумер, диген. *(Верстак янына килә. Чынаяк күтәреп, өйдән Өммия чыга.)*

Өммия. Кая куйыйм? Бал белән эчәсеңме, эткәй, вәренья беләнме?

Әлмәндәр. Китер монда. *(Өммия чынаякны верстак өстенә куйгач.)* Бал тирләтә, килен, шикәр чыгар. *(Өммия кереп киткәч.)* Акылына килгән. Пәриләрен качырып тормасаң, хәзер азыналар. *(Өммия шикәр чыгарып, верстак өстенә куя да кереп китә.)* Әллә кая югалма, кычкырырлык булмасын! *(Верстак өстенә утырып, чәй эчә.)* Юк инде, үзеңнең хәләл хатының булмаса, юк инде. Чурту-матыр, Йөзембикә ясаган чәйне эчеп җибәргәч, өчәр көн айный алмый йөри идем. *(Шулчак койма өстендә Илсурның чуалган чәчле башы күренә.)*

Илсур. Бабай, нихәл!

Әлмәндәр. А-а-а... Илсур килгән. Төш, әйдә, минем янга, агай-эне ак мыек.

Илсур. Төшмим.

Әлмәндәр. Ник төшмисең?

Илсур. Ату кәнфит бирәсең.

Әлмәндәр. Бирсә ни...

Илсур. Мин аны ашыйм да, тешем авырта.

Әлмәндәр. Кер, кәнфит бирмәм. *(Илсур капкадан керә дә, туп-туры верстак янына барып, верстак өстенә менеп кунаклый.)* Йә Илсур, агай-эне, күрешеп җибәрик. Шапылдатып күреш. *(Кулын суза, Илсур аның кулына чәпелдәтеп суга.)* Менә шулай. Инде кил, борыныңны сөртеп куйыйк. *(Күлмәк итәген әйләндереп, Илсурның борынын сөртә.)* Менә шулай.

Юкса маңкалы борын белән йөрү егетләргә килешми, кызлар сөймәс үзеңне.

Илсур. Мин аны сөртәм, ул тагын чыга.

Әлмәндәр. Йә, нинди яңа җырлар өйрәндең?

Илсур *(кычкырып җырлап җибәрә).*

Су буенда тал-тирәк,
Тал-тирәккә су кирәк;
Кыска буйлы егетләргә
Озын буйлы кыз кирәк. (...)

Әлмәндәр. Әйбәт! Тагын, тагын.

Илсур. Тагын әле өйрәнгәнем юк.

Әлмәндәр. Киләсе юлы күбрәк өйрәнеп кил, ярыймы.

Илсур. Ярый.

Әлмәндәр *(тәрәзә янына барып).* Килен! Әй килен, сиңа әйтәм.

Өммия *(тәрәзәне ачып).* Нәрсә инде тагын?

Әлмәндәр. Кашык белән бал алып бир.

Өммия. Үләм, тирләтә диден бит әле генә.

Әлмәндәр. Үземә түгел.

Өммия *(Илсурны күреп).* Бетмәс монда алар. Бөтен авыл малае безнең ишегалдында.

Әлмәндәр. Әйткәнне тыңла.

Өммия. Кәнфит ярамаган, бигрәк тагын — бал.

Әлмәндәр. Кәнфит ашаса, теше авырта аның.

Өммия. Бал ашаса, эче авыртыр.

Әлмәндәр. Канымны кыздырасың, килен!

Өммия. Соң бит, әткәй...

Әлмәндәр. Әйткәнне эшлә! *(Өммия югала да кашык белән бал алып килеп Әлмәндәргә суза. Әлмәндәр Илсур янына килеп.)* Яле, агай-эне, кабып җибәр әле.

Илсур. Кирәкми.

Әлмәндәр. Нәрсә — кирәкми... Син алай тиз үпкәләүчән булма... Егет бул, кабып җибәр. Ач әле авызыңны. *(Илсур авызын ача, Әлмәндәр бал каптыра.)* Тәмлеме?

Илсур. Әһе.

Әлмәндәр. Әһе булмаска, бал ич ул. Инде болай эшлик, кашыкка сыланганын менә монда сылап куйыйк. Кабып йоткач тиз бетә, болай озак итеп ялап йөрисең. *(Кашыкка ягылган балны Илсурның ирен кырыйларына сылый.)* Инде бар, иптәшләрең янына йөгер.

Илсур. Рәхмәт, бабай. *(Ирен кырыйларын ялый-ялый чыгып йөгерә.)*

Өммия *(ул Әлмәндәрнең кыланышларын тәрәзәдән карап торган).* Сабый да сабый, син дә сабый.

Ә л м ә н д ә р. Синең кебек тумас борын картаймам инде. Җиде бала үстереп, балалар яратмыйсың. Алар булмаса, бу дөнья ни чуртыма... Чәең бетте, чәй чыгар.

Ө м м и я. Үләм, кай арада чүмереп бетердең? Мин сиңа афисәнке түгел.

Ә л м ә н д ә р. Телең тагын озынайдымы?..

Ө м м и я. Озынайса да, кыскарса да — үз телем.

Ә л м ә н д ә р. Үз телең түгел — шайтан теле.

Ө м м и я. Булсын. Үзеңдә дә сандугач теле түгел.

Ә л м ә н д ә р. Әрепләшмә, дим, минем белән. Мин сиңа каената. Кара аны, килен, матри, мин кызсам...

Ө м м и я. Кызсам, дигән була... Кызып нишләтерсең?.. *(Тәрәзәне ябып куя.)*

Ә л м ә н д ә р. Вәт бит, ә! Чәтелдәп тора бит. Уңмады малай, уңмады. Үземдә булса... Юк инде, үземнән дә булмады, юаш булдым. Ни беренче хатынга, ни икенчесенә кизәнгәнем булмады. *(Өйдән, кулына чынаяк тотып, Искәндәр чыга.)*

И с к ә н д ә р. Әй-яй, тынычлап ятып торырга да бирмисең, эти. Нәрсә инде син. Кереп эчсәң булмыймы?

Ә л м ә н д ә р. Булмый. Өстәл артында дөнья онытып чәй эчеп утырырга минем вакытым юк. Син эч чәйне яткан килеш.

И с к ә н д ә р. Беләсең ләбаса, мин авырыйм.

Ә л м ә н д ә р. Чирләшкә! Япь-яшь башыңнан... Җитмеш яшендә чирләп ята.

И с к ә н д ә р *(чынаякны Әлмәндәргә биреп)*. Мин күргәннәрне күрсәң... *(Утын пүләне өстенә утыра.)*

Ә л м ә н д ә р. Нәрсә күрдең?

И с к ә н д ә р. Дүрт ел буе сугышта йөрдем.

Ә л м ә н д ә р. Харап икән. Мин монда дүрт ел буе синең биш ыштансызыңны ашаттым, һәрберсе яәҗүҗ-мәәҗүҗ кебек, балчыкка чыкканчы ашыйлар иде. Өч ел буе присидәтел булып, синең хатының ише зобанилар белән талаштым. Аларның һәрбересе ун нимескә тора. Сугышта йөргән, имеш...

И с к ә н д ә р. Тәнем тулы яра эзләре.

Ә л м ә н д ә р. Җүләр. Пешмәгән, шуңа күрә яра. Кулыңда пушкы була торып, яраланып ят, имеш. Япон сугышында кулымда мылтык кына иде, чурт та булмады. Синең чактагы сыман пушкы артында посып ятмый идек, штык тотып, японның өстенә бара идек.

И с к ә н д ә р. Ярый инде, синең белән бәхәсләшеп буламы.

Ә л м ә н д ә р. Бәхәсләшмә дә. Ник дисәң, үзең гаепле. Авырыйм дип, өйдә ятасың. Чир ул яткан кешене эзләп йөри. Эшләгән кешедән курка. Ник дигәндә, ул аңа ябышып торалмый, тир белән юылып төшә. Бар, утырма күз көеге булып, кереп ят. Чынаякларны ала кер. Хатыныңа әйт, кичкә үзе кискән токмач

белән итле аш пешерсен. *(Искәндәр, чынаякларны алып, әкрен генә өйгә кереп китә. Әлмәндәр аның артыннан карап кала.)* Шулай... Чурту-матыр, Гитлер тәресе, әрәм итте әзмәвердәй малайларны. Чирләп ята торган кешеме? Җитмеш яшеңнән әҗәл көтеп ят инде. *(Әкрен генә капка ачыла, аннан Әҗәл килеп керә.)*

Әҗәл. Әссәламегаләйкүм.

Әлмәндәр. Әлегә мегаләйкүм. Әйдә, түрдән уз.

Әҗәл. Узарга туры килер. *(Әлмәндәр янына килеп.)* Әлмәндәр атлы карт син буласыңмы?

Әлмәндәр. Әлмәндәре мин булам, карты кайдадыр, белмим. Кем дип белим үзеңне, күргән-сөйләшкән кешем түгел, ахрысы.

Әҗәл. Иң әүвәл кул бирешеп күрешик, Әлмәндәр.

Әлмәндәр. Танымаган кешемә кул бирергә ашыкмыйм мин.

Әҗәл. Шулаймы... Ярый, алайса. Ишегалдында кеше-кара юкмы?

Әлмәндәр. Нәрсә син, ышпиун кебек каранасың? Кешедән яшерен эшем юк.

Әҗәл. Син ашыкма, Әлмәндәр. *(Боерган тавыш белән.)* Соравыма җавап бир!

Әлмәндәр. Күреп торасың лабаса, үзем генә.

Әҗәл. Бик яхшы. Кил әле якынрак, утыр минем янга. *(Бүкәнгә утыра.)*

Әлмәндәр *(якын килмичә)*. Кем син?

Әҗәл. Ашыкма, дидем. Утыр. *(Әлмәндәр урыныннан кузгалмагач, үзе Әлмәндәр янына бара.)* Эшне моннан башлыйк, Әлмәндәр. *(Кесәсеннән блокнот чыгарып карый.)* Әйе, исемең синең Әлмәндәр, атаңның исеме Җиһангир, бабаң Моратхуҗа атлы. Телисең икән, җиде бабаңа хәтле санап күрсәтә алам. Моннан өч көн элек сиңа туксан бер яшь тулган. Ике тапкыр өйләнгәнсең. Кыскасы, менә бу дәфтәргә синең бөтен гомереңтәфсилләп язып куелган.

Әлмәндәр. Әкәмәт... Кем соң син?

Әҗәл. Кул бирергә теләмәдең, Әлмәндәр, инде ашыкмыйча тыңла. Бабаң кырыкта, атаң кырык биштә дөнья куйганнар. Син нишләп туксан бергә җиттең?

Әлмәндәр. Анда синең ни эшең бар!

Әҗәл. Бар, Әлмәндәр. Барлыгын соңрак белерсең. Соравыма җавап бир.

Әлмәндәр. Бөтен гумеремне белгәч, анысын да үзең бел. Дөньялар үзгәреп, дөньялар матурланмаса, мин дә кырыктан әллә ни узмый идем.

Әҗәл. Дөньялар никадәр матур булмасын, кеше барыбер үләргә тиеш. Кеше мәңгелеккә килмәгән.

Ә л м ә н д ә р. Туктале, чурту-матыр, син монда... Бар, үтбәләвәй, эшемне калдырып йөрмә. *(Кулына ышкы ала.)*

Ә җ ә л *(Әлмәндәр кулындагы ышкыга тотынып).* Мин шаярырга килмәдем, Әлмәндәр. Мин шаяра белмим. *(Әлмәндәр, аптырап, Әҗәлгә карап тора да кинәт артка чигенеп куя.)* Әллә таныдыңмы, Әлмәндәр?

Ә л м ә н д ә р. Күргәнем бар кебек.

Ә җ ә л. Ялгышмыйсың, Әлмәндәр. Без синең белән өч тапкыр очраштык, монысы дүртенчесе һәм соңгысы.

Ә л м ә н д ә р. Кем соң син?

Ә җ ә л. Мин сине күрүгә үк таныдым. Бераз үзгәргәнсең үзгәрүен, шулай да таныдым. Без синең белән беренче тапкыр бер мең тугыз йөз бишенче елда очрашкан идек. Япон сугышы вакытында. Син яраланып ята идең, мин сине алып китәргә килдем. Син китәргә теләмәдең. Озак көрәштек. Яшь идең шул, көчле идең, мине ектың. Ачуым килде килүен, ләкин, нишләмәк кирәк, кире борылып китәргә туры килде. Хәтерлисеңме?

Ә л м ә н д ә р. Хәтерләмим.

Ә җ ә л. Яхшы. Икенче очрашу бер мең тугыз йөз унбишенче елны булды. Син урман эчендә бил тиңентен сазлыкка баткан идең, пленнан качып чыгуың иде. Мин килдем. Шунда син миңа әйттең, сазлыктан чыгыйм, алып китәрсең, дидең. Мин көттем, син чыктың. Һәм чыккач йөгердең, мине алдадың.

Ә л м ә н д ә р. Син...

Ә җ ә л. Өченче тапкырында, бер мең тугыз йөз утызынчы елда, колхоз төзеп йөргәнең өчен кемнәрдер сәнәк белән кадаганнар иде. Син урман сукмагында ята идең. Мин тагын килдем. Ләкин Евстигней исемле бер кеше килеп чыгып, сине минем кулдан тартып алды. Таныдыңмы инде?

Ә л м ә н д ә р. Син Әҗәлме?

Ә җ ә л. Нәкъ үзе.

Ә л м ә н д ә р. Ник килдең?

Ә җ ә л. Әҗәл кешеләр янына ни өчен килә?

Ә л м ә н д ә р. Мин сине чакырмадым.

Ә җ ә л. Теге чакларда да син мине чакырмаган идең.

Ә л м ә н д ә р. Мин бит яралы түгел, исән-сау.

Ә җ ә л. Менә монысы икенче мәсьәлә. Ходаның кодрәтеннән узып, артык яшәгәнсең. Иң күп дигәндә син туксанга гына җитәргә тиеш идең. *(Кесәсеннән кәгазь чыгарып.)* Менә шушы урынга кулыңны куй.

Ә л м ә н д ә р. Нәрсә ул?

Ә җ ә л. Повестка. Шуңа кулыңны куюың була, туп-туры безнең шеф Газраил янына юнәләсең.

Ә л м ә н д ә р. Сөйләмә юкны.

Әҗәл. Мин ялган сөйләмим. Куй кулыңны, вакытым тар. План үтисем бар. Бу юлы мине ега алмассың, алдатмам да, коткарып калучы да булмас. Кулыңны куй.

Әлмәндәр *(паузадан соң)*. Вакыт җитте, дисеңмени?

Әҗәл. Әйе, җитте.

Әлмәндәр. Бик тиз була түгелме соң?

Әҗәл. Нинди тиз. Туксан бергә җит тә тиз, имеш.

Әлмәндәр. Ярый, уйлап карармын.

Әҗәл. Бернинди уйлау юк. Кулыңны куй. Минем белән бәхәсләшергә, тарткалашырга уйлама. Бер генә адәм баласының да мине җиңгәне юк. Галимнәр дә, патшалар да — барысы да җиңелеп киләләр.

Әлмәндәр. Эшлисе эшләрем бар бит әле.

Әҗәл. Бер генә адәм баласының да дөньядагы эшне эшләп бетергәне юк. Әгәр бөтен эшне син эшләп бетерсәң, синнән соң килгәннәргә эш калмас иде. Эшсезлектән гаҗиз булган кешеләр акылдан язарлар иде. (...)

Әлмәндәр. Куярмын, ашыкма. Тотып тор тактаның теге башыннан.

Әҗәл. Син минем белән алай сөйләшмә. Ачуымны чыгарма. Ачуым яман минем, мине тыңламаганнарга рәхимсез мин.

Әлмәндәр. Күзең чыкмаган булса күр, җыенам бит.

Әҗәл. Үләргә җыенган кеше такта ышкыламый.

Әлмәндәр. Ахмак! Минем каберемә чардуган кирәк булачакмы? Чардуган корыр өчен такта кирәкме?!

Әҗәл. Анысы икенче эш, әйдә, тизрәк ышкыла.

Әлмәндәр. Туксан бергә җиткәч, тиз ышкылап булмый шул. Тот, дим, тактаның теге башыннан.

Әҗәл. Мин монда такта башы тотарга килмәдем.

Әлмәндәр. Алайса, көт. *(Такта ышкылый, үзе җыр суза.)*

> Ала карга дигән әй асыл кош,
> Тәүбә иттең мәллә үлмәскә?
> Син тәүбә итсәң, мин дә иттем
> Әҗәл дуска кулым бирмәскә.

Әҗәл. Сүзеңнең кинаясенә төшенмим.

Әлмәндәр. Сүз түгел бу — җыр. Җырның җыртыгы юк. *(Эшеннән туктап.)* Син җырлый беләсеңме?

Әҗәл. Ышкыла, туктама. Әйдә, әйттем бит, вакытым тар, болай да озак юандым.

Әлмәндәр. Ашыктырма, арыдым... Озак яши ала карга... Адәм баласына ала карга гумере дә кызганыч диген, ә!

Әҗәл. Анысы минем карамакта түгел.

Әлмәндәр. Карамак, карамак. Муеның сузып, минем янга син килгәнсең ич әле...

Әҗәл. Бу нинди тупаслык? Онытма: син мине түгел, мин сине алырга килдем.

Әлмәндәр. Укаң коелмас. Син минем гумеремне өзәргә килгәнсең әле, бер дә танавымны җыермыйм. *(Такта ышкыларга керешә.)*

Әҗәл. Ә син нигә үзең эшлисең? Бүтәннәр эшләр иде чардуганыңны.

Әлмәндәр. Үз эшемне кешегә калдырганым юк.

Әҗәл. Карап-карап торам да, бик ни күренәсең...

Әлмәндәр. Ни күренәм?

Әҗәл. Бик ни. Бик алай нитмә, синең кебекләрне күргән мин.

Әлмәндәр. Мин дә сине күргән.

Әҗәл. Аһа! Ошый башладың әле син миңа, картлач. Кайберәүләр мине күргәч мәлҗерәп төшәләр. Кул куйганда, куллары калтырый. Алып китүе дә кызык түгел. Күрәм: синең белән шактый ук кызык булачак. Болай булгач көтәм, әйбәтләп ышкыла чардуганыңның тактасын.

Әлмәндәр. Карылдап торма янымда, бар, урамга чыгып утыр.

Әҗәл. Юк, мин синең яныңнан китмим.

Әлмәндәр. Эшләгән кеше янында торганчы, пес иткән кеше янында тор.

Әҗәл *(авызын зур ачып, рәхәтләнеп көлә)*. Шәп! Күптән көлгәнем юк иде. Куеп тор эшеңне, Әлмәндәр, утыр яныма. Тагын көлдер мине. *(Капка ачыла, Гөлфирә керә.)*

Гөлфирә. Дәү бабай, мин кайттым. *(Әлмәндәр ишетмәгәч.)* Дәү бабай, дим! Мин кайттым.

Әлмәндәр *(борылып карап)*. Ай, кызым кайткан. Кил әле монда, кил, кочакла дәү бабаңны.

Гөлфирә *(йөгереп килеп, Әлмәндәрне кочаклый)*. Кычкырам — ишетмисең.

Әлмәндәр. Әҗәлетдин бабаң белән сөйләшеп тора идек.

Гөлфирә. Кем соң ул?

Әлмәндәр. Бер юньсез нәрсә инде шунда.

Гөлфирә. Алай димә, дәү бабай. Син үзең әйтәсең, кешеләргә ямьсез сүз әйтергә ярамый, дисең... Бабай белән әби өйдәләрме?

Әлмәндәр. Өйдәләр, кызым, өйдәләр. Әтиеңнәр ни хәлдә?

Гөлфирә. Әйбәт. Сәлам әйттеләр. Сиңа бик матур күлмәк җибәрделәр.

Әлмәндәр. Рәхмәт, кызым. Бар инде, өйгә кер. *(Гөлфирә йөгереп өйгә кереп китә.)*

Әҗәл. Чибәр кыз үсеп килә.

Әлмәндәр. Күзең салма, явыз. Сиңа минем кебек ямьсезләр дә җитеп арткан.

Әҗәл. Әлмәндәр, бер акыл өйрәтимме үзеңә?

Әлмәндәр. Кирәкми, үз акылым җиткән. Арттан кергән акыл җил белән кире чыга.

Әҗәл. Ярый соң, үзеңә кара. Кызык, әйеме, Әлмәндәр, берәүләр мине көтеп торалар, мин килмим. Син көтмәдең — мин килдем. Хикмәт шунда, Әлмәндәр: чакырылмаган җиргә кешеләр дә соңга калмыйча килә.

Әлмәндәр. Такылдап утырма, чурту-матыр, килгән юлыңнан кире кит.

Әҗәл. Ничек инде — кит?.. Ничек аңларга?

Әлмәндәр. Шулай. Кәгазеңә кул куймыйм. Газраилең үзе килсен.

Әҗәл. Алай булмый.

Әлмәндәр. Була. Минем анда барырга вакытым юк. Өйләнәсем бар.

Әҗәл. Нишлисең бар?

Әлмәндәр. Өйләнәсем.

Әҗәл *(тагын рәхәтләнеп көлә)*. Әкәмәт кеше син.

Әлмәндәр. Нигә авызыңны ерасың? Әгәренки дә беләсең килсә, сугышта югалган дүрт малаемның икесе өйләнмәгән иде. Үзем өчен бер өйләндем, бер малаем өчен икенче өйләндем, икенче малаем өчен тагын бер өйләнәсем бар. Ә син, тинтәк, җанымны сорап килгәнсең.

Әҗәл. Гафу ит, мин сорамыйм, Әлмәндәр, таләп итәм.

Әлмәндәр. Куркытты. Әлмәндәрнең мыегы да селкенмәде.

Әҗәл. Алайга китсә... *(Әлмәндәр өстенә килә.)*

Әлмәндәр *(такта күтәреп)*. Килеп кара.

Ут сүнә.

II күренеш

Алма бакчасы. Бакча рәшәткә белән уратып алынган. Рәшәткә яныннан сукмак үтә. Сукмактан узучылар Әлмәндәргә сәлам биреп узалар. Әлмәндәр җавап бирә. Әлмәндәр белән Әҗәл алачык ясыйлар. Әҗәл кадаклый, Әлмәндәр тактаны тотып тора.

Әлмәндәр. Кыздыр, әйдә, Әҗәлетдин, кыздыр.

Әҗәл. Әйтмә шул сүзеңне.

Әлмәндәр. Әйтмә, җаным, шул сүзеңне,
Йөрәгемә ярамый.
Чүкеч сабын алай тотмыйлар, сарык, бармагыңа сугасың. Менә болай тот. Әйдә, әллүр. *(Әҗәл, тырышып-тырышып, такта кадаклый.)* Хәзер ничек, җайлымы, Әҗәлетдин?

Әҗәл. Эш түгел лә бу.

Әлмәндәр. Кәҗә маеңны чыгарамыни? Шулай ул. Ярый, ял итеп ал. Йә, минем урынга үзең аягыңны сузарсың. Аннары җавап тот синең өчен теге дөньяда.

Ә җ ә л. Мин үлемсез. *(Кадаклаудан туктап, фәлсәфәгә бирелә.)* Үлемсез булу начар, Әлмәндәр. Үлү — зур бәхет ул. Сез, кешеләр, шуңа бәхетлеләр. Минем миллиард ел яшәвем сезнең бер ел гомерегезгә тормый. Сез төзисез, сез өмет белән яшисез. Минем өмет юк, мин җимерүче.

Ә л м ә н д ә р. Җимермә, кем куша җимерергә.

Ә җ ә л. Дөнья шулай корылган, Әлмәндәр.

Ә л м ә н д ә р. Әйдә, ярар, кадакла.

Ә җ ә л. Ял итик бераз. *(Берсе бүкәнгә, икенчесе алачык идәненә утыралар.)*

Ә л м ә н д ә р. Алып китәм, дисең инде, ә?

Ә җ ә л. Шулай итәргә туры килә, Әлмәндәр.

Ә л м ә н д ә р. Хәзер үк, дисең инде, ә?

Ә җ ә л. Шулай булыр инде, Әлмәндәр.

Ә л м ә н д ә р. Әллә соң бераз көтәсеңме?

Ә җ ә л. Күпме?

Ә л м ә н д ә р. Илле ел.

Ә җ ә л. Шаярма, Әлмәндәр...

Ә л м ә н д ә р. Хет ун ел.

Ә җ ә л. Булмый.

Ә л м ә н д ә р. Бер ел.

Ә җ ә л. Әйтәм бит, Әлмәндәр, булмый. Ярамый.

Ә л м ә н д ә р. Бер ай, бер атна...

Ә җ ә л. Булмаганны сөйләмә.

Ә л м ә н д ә р. Соң, явыз, минем оныкларым бар, оныкларымның уллары, улларының уллары бар. Мин үлгәндә, алар минем янда булырга тиеш. Минем соңгы киңәшләремне ишетеп калырга тиешләр. Алар читтә, аларга хәбәр итеп өлгерергә кирәк.

Ә җ ә л. Телеграмма сук, бүген кайтып җитәрләр.

Ә л м ә н д ә р. Сиңа җиңел. Телеграмма сук, имеш. Синнән башка белмиләр, ди. Алар бит хөкүмәт эшендә.

Ә җ ә л. Нәрсә, министр булып эшлиләрмени?

Ә л м ә н д ә р. Ахмак. Кем булып эшләүдәмени хикмәт. Эшләгән җирләрендә алар кирәк. Аларны эшләреннән аерырга ярамый. Мин үзем алар янына барырга тиеш.

Ә җ ә л. Гафу ит, алай булмаячак. Сиңа мин иң күбендә чардуганыңны эшләп бетерерлек кенә вакыт бирәм.

Ә л м ә н д ә р. Базардагы сыман сатулашма инде.

Ә җ ә л. Эшем күп бит, Әлмәндәр. Хуҗа әйтте, озаклама, тиз алып килеп җиткер, диде. Синең аркада шелтә аласым килми.

Ә л м ә н д ә р. Бар соң, кит, бүтән эшләреңне эшли тор, вакыты җиткәч килерсең.

Ә җ ә л. Һәркемнең үз нәүбәте, Әлмәндәр. Әйдә, тотындык, ләкин бу юлы син кадакла, мин такта тотып торам.

Икесе дә торып эшкә тотыналар. Сүзсез генә бераз эшлиләр.

Әлмәндәр. Әйт әле дөресен, Әҗәлетдин, ни өчен мин синең кәгазеңә кулымны куярга тиеш?

Әҗәл. Әйттем ләбаса. Ходаның кодрәтеннән узып, син бер ел артык яшәгәнсең.

Әлмәндәр. Шулаймы?

Әҗәл. Әлбәттә, шулай...

Әлмәндәр. Минем берсеннән-берсе таза биш малаем бар иде. Кырык беренче елда бишесе дә сугышка киттеләр. Дүртесе кайтмады. Иң олысына утыз алты, иң кечесенә егерме яшь иде. Әгәр дә синең Ходаң безнең авыл кешеләренә туксаннан узарга рөхсәт бирми икән, нигә минем малайларымның туксанга җиткәнен көтмәгән?

Әҗәл. Анысы минем эш түгел бит, Әлмәндәр.

Әлмәндәр. Әһә, синең эш түгелме?! Китереп терәгәч, синең эш түгелмени?

Әҗәл. Сугышны адәм балалары үзләре чыгаралар.

Әлмәндәр. Адәм балалары түгел, адәм актыклары чыгара. Синең Газраилең ни өчен сугыш чыгаручыларның җанын алмый?

Әҗәл. Алды.

Әлмәндәр. Ничаклы яхшы кешеләрнең башына җиткәчме? Сугыш чыгарырга җыенуларын күрүгә үк муеннарын борырга иде аларның.

Әҗәл. Бик эчкәрегә кермә, Әлмәндәр.

Әлмәндәр. Кермәме?! Кермим алай булса — чыгам. Бар, Газраилеңә кайтып әйт, Әлмәндәргә үләргә иртәрәк, диген. Дүрт баласы яшәячәк гомерне яшисе бар әле аның, диген. Киметеп санаганда йөз утыз ел. Мин нәфесле түгел, миңа тагын утызкырык ел җиткән. Шуннан соң килерсең. Дөрес әйтәмме?

Әҗәл. Соң үзеңчә дөрестер дә инде ул... Әмма дә ләкин сабыр гына уйлап кара әле, Әлмәндәр. Тагын, әйтик, утыз ел яшәдең, ди. Ул яшәүнең ни кызыгы? Кемгә кирәк син?

Әлмәндәр. Шаярма, Әҗәлетдин. Үзең ишеттең, присидәтел, лифкавай машинасы белән бакча янына туктап, нәрсә диде? Печән өябез, нигә эскерт башында торырга чыкмадың, Әлмәндәр бабай, дидеме?

Әҗәл. Ул бит аны көлеп әйтте. Күреп тордың, елмайды.

Әлмәндәр *(көлеп)*. Тагын эләктең, Әҗәлетдин. Кеше мине күреп елмая икән, мин кирәк дигән сүз була. Минем яннан елмаеп киткәч, бүтәннәр янында да елмая ул. Аның елмайганын күреп, бүтәннәр дә елмая. Минем аркада ничаклы кеше елмая. Шуннан соң кирәк булмыйммы инде мин?

Әҗәл. Өйләнәм диюең нәрсә инде? Туксан бер яшьлек картка кем чыксын?

Әлмәндәр. Чиләгенә күрә капкачы табыла.

Әҗәл. Ярый, табылсын да, ди. Өйләндең дә, ди. Ни кызыгы инде?

Әлмәндәр. Әй агай-эне. Аның кызыгын өйләнгән кеше үзе генә белә.

Әҗәл. Мактанасың ла инде.

Әлмәндәр. Мактанса ни. Ир мактаныр, корал эшләр. *(Шак иттереп, чүкеч белән кадакка сугып куя да.)* Әйдә, утыр, ял итеп алыйк. *(Рәшәткә янына Илсур килә.)*

Илсур. Бабай, нихәл!

Әлмәндәр. А-а... Илсур. Кер, әйдә, кер.

Илсур. Кермим, корт чага.

Әлмәндәр. Балыңны ялап бетердеңме соң?

Илсур. Бетте шул.

Әлмәндәр. Алайса, чакмый. Кер.

Илсур. Минем бал ашыйсым килми.

Әлмәндәр. Нәрсә ашыйсың килә?

Илсур. Алма. Өчне бир. Илдус белән Ринатка да.

Әлмәндәр. Нигә үзләре килмәде?

Илсур. Вакытлары юк. Су буенда каз сугыштыралар.

Әлмәндәр. Хәзер, алай булса, хәзер. *(Түбәтәенә алма тутырып, Илсур янына бара да алманы Илсурның күлмәк итәгенә бушата.)*

Илсур. Җырлыйммы?

Әлмәндәр. Ашыгасың бит.

Илсур. Ә син нәрсә ясыйсың?

Әлмәндәр. Дача.

Илсур. Нәрсәгә ул?

Әлмәндәр. Йокларга.

Илсур. Төнлә дәме?

Әлмәндәр. Төнлә, билгеле. Көндез кеше йоклап ятамы?

Илсур. Курыкмыйсыңмы?

Әлмәндәр. Нәрсәдән куркасың, ди. Бар инде, йөгер, иптәшләрең көтәдер.

Илсур. Рәхмәт, бабай! *(Чыгып йөгерә.)*

Әҗәл. Карале, Әлмәндәр! Син, чардуган корабыз, дидең, тагын алдаштың. Дача салып ятасың икән ич. Нәрсәгә ул, дип сорагач, йокларга, дидең.

Әлмәндәр. Тинтәк! Әҗәлнең ни икәнен белмәгән сабыйга каберем өстенә чардуган дип ничек әйтәсең. Мин сабыйлар белән сөйләшкәндә, син кысылма.

Әҗәл. Шунысы да аңлашылмый: чардуганны нигә бакчага корасың, зират бар.

Әлмәндәр. Үлмәс борын зират өстендә чардуган корганымны күрсәләр, кешеләр ни уйлар? Үзләре дә чардуган өчен такта ярдыра башларлар. Нигә аларны ашыктырырга.

Әҗәл. Һич кенә дә сүз табып булмый сиңа.

Әлмәндәр. Тапмасаң, тик утыр.

Әҗәл. Бик утырасы да бит... Нишләргә инде синең белән? Усаллансам, шык та итә алмыйсың алуын. Тик, әллә нигә, усалланасым килми.

Әлмәндәр. Тукта!.. Хәмдебану килә. Миңа хатын булырга тиешле карчык. Син, Әҗәлетдин, читкәрәк авышып тор. Мин Хәмдебану белән сөйләшкәндә килеп комачау итмә. Мин сүземне сүз итәргә тиеш. Ризалыгын бирсен. Өйләнәмме, өйләнмимме — анысын күз күрер.

Әҗәл. Сабый булма, соңгы сәгатьләреңдә үзеңнән көлдермә.

Әлмәндәр. Юк, әлеге көнгә хәтле, шушы яшемә җитеп, сүземне аста калдырмадым. Хатын-кыздан көлдермәдем.

Әҗәл. Хәмдебану ризалыгын бирсә, минем кәгазьгә кулыңны куясыңмы?

Әлмәндәр. Карарбыз.

Әҗәл. Өзеп әйт, юкса комачаулыйм.

Әлмәндәр. Бәйләнчек эт булдың. Куйсам куярмын инде, чурту-матыр, мәтәлеп кит.

Әҗәл. Бар, алайса, тәвәккәллә.

Рәшәткә янында Хәмдебану күренә, Әлмәндәр рәшәткә янына килә.

Әлмәндәр. Хәмдебану! *(Хәмдебану җавап бирмичә, үтеп киткәч.)* Хәмдебану, әллә үпкәләдеңме?

Хәмдебану *(борылып килеп)*. Үпкәләмәскә соң, Әлмәндәр абзый, тузга язмаганны. Үземнән үзем оялып йөрим. Андый сүзне ишетмәгәнемә утыз ел. Башка берәү шулай дип әйтсә, таяк белән башын бәреп ярыр идем...

Бакча ягына Өммия чыга. Хәмдебану белән Әлмәндәрнең сөйләшеп торганнарын күреп, колак сала.

Әлмәндәр. Бигрәк киребеткән хатын булдың. Өзеп әйтәсең инде, алайса? Миңа кияүгә чыкмыйм, дисең.

Хәмдебану. Әйттем бит, юк сүзне сөйләмә, Әлмәндәр абзый. Гомерең буе миңа бәйләндең. Башта бүтәннәргә димләдең, хәзер үзеңә. Шаярып әйтәсеңдер дисәм, чынлап икән.

Әлмәндәр. Яшьрәк чагында яшьрәкләр кирәк иде сиңа. Картайгач — мин дә бик әйбәт. Ныклап уйла, Хәмдебану.

Хәмдебану. Уйлыйсы-итәсе юк. Үзеңнән биздерәсең килмәсә, бүтән бу сүзеңне сөйләмә, Әлмәндәр абзый. *(Кузгалып китә.)*

Әлмәндәр. Риза булсаң, килеп әйтерсең, ялынып бармам. Чынлап әйтәм, Хәмдебану. Бик нык уйла! *(Хәмдебану киткән якка карап кала. Өммиянең кычкырып көлеп җибәрүеннән сискәнеп китә.)*

Өммия. И-и-и... И Аллам! И Ходаем! Үләм, үләм!.. Тагын ниләр кыланырсың икән?

Әлмәндәр. Нәрсә авызыңны ердың. Әллә тыңлап тордыңмы?

Өммия. Үләм, үләм... Бөтен урамга шар ярып сөйләшеп тора да, тыңлап тордыңмы, дигән була. Нәрсәгә такта турый, ни кыланырга җыена дисәм, башка чыгарга йөри икән. Үләм, үләм...

Әлмәндәр. Үлсәң үләрсең, мин үләргә җыенмыйм.

Өммия. Әйтәм, малаеңа кереп әйтәм, урамга чыгып кычкырам, белсеннәр кем икәнеңне.

Әлмәндәр. Нәрсә, нәрсә очынасың? Матри, килен!

Өммия. Әйтәм, Искәндәргә кереп әйтәм. *(Кереп китә.)*

Әлмәндәр *(аның артыннан кычкырып кала)*. Килен!

Әҗәл. Күрдеңме инде, Әлмәндәр?

Әлмәндәр. Нәрсә — күрдеңме, нәрсә син дә авызыңны ерасың?

Әҗәл. Көләләр үзеңнән, Әлмәндәр.

Әлмәндәр. Белмичә көләләр, аңламыйча көләләр.

Әҗәл. Аңламаслык берни дә юк. Көлдермә үзеңнән, әйдә, кулыңны куй да китик тизрәк.

Әлмәндәр. Хәмдебану ризалыгын бирмәде, тыңлап тордың.

Әҗәл. Аның ризалык биргәнен көтсәң... Булмаганны өмет итмә.

Өммия, Гөлфирә, Искәндәр бакчага чыгалар. Гөлфирә Искәндәрне култыклаган, үзе көлә.

Өммия. Күрегез әнә, үзеннән сорагыз. Менә шушы урында унсигез яшьлек егетләр кебек сайрап торды.

Искәндәр. Әти, нишләвең инде тагын?

Әлмәндәр *(Өммия каршына атылып барып)*. Теңкәмә тидең, явыз килен!

Өммия. Үләм, үләм!.. *(Үзе Әлмәндәрдән кача.)*

Гөлфирә *(Өммияне куып йөргән Әлмәндәрне кочаклап алып)*. Дәү бабай, дәү бабай, ярамый.

Әлмәндәр. Җибәр, кызым. Азды әбиең, азды.

Гөлфирә. Ярамый, ярамый. Син бит бик акыллы, бик әйбәт дәү бабай. Әби ялгыша. Кил, утыр, тынычлан.

Өммия *(Гөлфирәгә)*. Син нәрсә аның сүзен сөйлисең? Кем ялгыша?

Гөлфирә *(Өммияне барып кочаклап)*. Юк, әбием, ялгышмыйсың, син дә дөрес сөйлисең. *(Әлмәндәрнең утырган урыныннан сикереп торганын күреп, аның янына килә.)* Юк, юк, дәү бабай, син бик әйбәт. Бөтенегез дә бик әйбәт. Мин сезнең барыгызны да сагынып кайтам. Килегез, барыгыз да тезелешеп утырыгыз.

Өммия. Утырасым да килми. Үзе генә җитмәгән, безне адәм көлкесенә калдырырга җыена. Үләм, үләм... Өйләнәм, ди, бит, өйләнәм, ди.

Гөлфирә. Өйләнсә ни булган?

Искәндәр. Син, кызым, тик тор. Син бернәрсә дә аңламыйсың әле.

Гөлфирә. Ничек инде аңламыйм! Бабай ялгыз яши. Өйләнсә, ни гаебе бар?

Өммия. Ничек ялгыз яши? Ә без?

Гөлфирә. Сез икәү. Бабай синең картың, син бабайның карчыгы. Дәү бабай ялгыз.

Әлмәндәр. Рәхмәт, кызым. Менә алар җитмештән узып та шуны аңламыйлар.

Искәндәр. Алай түгел ул, әти. Өйләнмәдең түгел, өйләндең. Әнкәй вафат булгач, ун ел да йөрмәдең, өйләндең бит, сүз әйтмәдек.

Әлмәндәр. Кем әйтмәде? Хатының әйтмәдеме?

Өммия. Әйтмәдем, ул чакта тел яшерә идем.

Әлмәндәр. Иреңнең колак итен ашадың. Әллә мин ишетмәдемме?

Искәндәр. Ярый, анысы булган беткән. Инде хәзер, йөз яшеңә җиткәндә...

Әлмәндәр. Син, малай актыгы, минем яшьне санама.

Гөлфирә *(Искәндәргә)*. Син, бабай, дөрес әйтмисең. Йөз яшеңә җиткәндә, димә, йөз яшеңә дә җитмәгән килеш, диген. Сиңа, дәү бабай, чыннан да, өйләнергә иртәрәк. Йөзгә җиткәч, була. (...)

Искәндәр. Гөлфирә, олылар әйткәнне тыңла.

Гөлфирә. Кайчан картаермын, мин әйткәнне дә тыңларлар иде. Әйдә, әбием. *(Өммияне култыклап ала. Кереп китәләр.)*

Искәндәр. Менә шулай, әти.

Әлмәндәр. Нәрсә шулай?..

Искәндәр. Шулай.

Әлмәндәр. Нәрсәнең шулай икәнен белмисең бит, улым. Хатының да әйтә, кызык-кызык дип кенә яшәде, ди. Кызыкның нәрсә икәнен белми, мәгънәсенә төшенми. Син дә, аңа кушылып, мине ачуланасың.

Искәндәр. Ачуланмыйм, әти.

Әлмәндәр. Ачулансаң да үпкәләмим. Дүрт энең дә кайтып, бишәүләп ачулансагыз сөенер генә идем. Хәлең ничек?

Искәндәр. Юк ла инде, беткән.

Әлмәндәр *(кинәт үзгәреп).* Зарланма! Зарланасы булма!

Искәндәр. Үзең сорыйсың бит.

Әлмәндәр. Яхшы! диген. Көл! Җырла! Бие! «Шулай»ның мәгънәсе шунда, «кызык»ның да мәгънәсе шунда. Әгәр, син зарлана дип, мин зарлансам, син сукрана дип, мин сукрансам, ни була... *(Урыныннан торып.)* Бераз гына утырып тор.

Искәндәр. Кая барасың?

Әлмәндәр. Үзем беләм. *(Чыгып китә дә бераздан бер чирекле шешәне кочаклап керә.)* Кил ышыккарак.

Искәндәр. Ансыз гына сөйләшик.

Әлмәндәр. Нәрсә сөйлисеңне беләм, минем ни әйтәсемне син дә беләсең. Әче бал эчеп, җырлашып утырсак, икебезгә дә шифасы тияр. Рамнарны кырып ясап куйган идем, өлгерүе җиткәндер. *(Алмагач ботагына элеп куйган кружканы алып, Искәндәр янына чүгәләп утыра.)* Теләсәң ни әйт, хатының усал. Шушы чиреклене өйгә керттерми бит тәки. Нәрсәсе бар инде. Бал бит бу, чын бал. Аракыны, үзең беләсең, үзем дә өйгә кертмәдем. *(Кружкага бал салып.)* Яле, тотып куй.

Искәндәр. Авырайтмас микән?

Әлмәндәр. Атаң кушкач авырайтмас. *(Искәндәр балдан авыз итә дә кружканы Әлмәндәргә суза. Әлмәндәр кружкада калган балны эчеп бетерә.)* Менә шулай, улым.

Искәндәр. Нәрсә шулай?

Әлмәндәр. Үләргә ашыкма, дим.

Искәндәр. Мин ашыкмыйм да бит...

Әлмәндәр. Ашыгасың. Син әле дүрт энекәшең өчен дә яшәргә тиеш. Кызык менә шунда була: сиңа Әҗәл килеп әйтә, Искәндәр, саубуллаш дөнья белән, ди. Барыбер зарланып ятасың, ди. Син үзең дә болай интегеп яшәгәнче дип риза буласың. Риза булмаска кирәк. Алдарга кирәк Әҗәлне.

Искәндәр. Алдарсың аны.

Әлмәндәр. Ә син алда. Җаен тап. Моның вакыты җиткән дип, Әҗәл килә. Куркыткан була. Ә син сер бирмисең. Ул синең белән мәшәкатьләнгән арада, көн үтә, бүтәннәр янына барырга соңга кала, синең аркада бүтәннәр дә озаграк яшәп кала. Менә шулай...

> Ала карга дигән әй асыл кош,
> Кунган җирең кайсы имәндә?
> Син башың исән дә, мин имәдем,
> Башкаема хәсрәт килгәндә. (...)

Искәндәр. Өйгә керим.

Әлмәндәр. Сөйләшмәдек бит әле, улым.

Искәндәр. Булды, әти, сөйләштек. *(Утырган урыныннан торырга азаплана, булдыра алмый. Әлмәндәр аңа ярдәм итмәк-*

че булып кулыннан тота.) Үзем. *(Көч-хәл белән торып, өйгә таба атлый.)*

Әлмәндәр. Хатыныңа әйт, бераздан миңа чәй чыгарсын. *(Искәндәр артыннан карап калып, җыр суза.)*

Ала карга дигән әй асыл кош...

Әҗәл. Аңлашылды, Әлмәндәр.

Әлмәндәр. Ни аңлашылды, Әҗәлетдин?

Әҗәл. Үз хәйләңне үзең ачып бирдең, һаман мине алдап йөртәсең. Килешми, Әлмәндәр. Яхшылыкка яманлык белән кайтарасың. Алайга китсә... Куй хәзер үк кулыңны. Куй, бргаланып маташма, картлач.

Әлмәндәр. Нәрсә җикеренәсең? Куймыйм, дигәнем юк. Китер кәгазеңне.

Әҗәл *(кесәсеннән кәгазь алып, Әлмәндәр каршына җәеп сала)*. Аңлашылырлык итеп куй.

Әлмәндәр. Кайсы җиренә? Шушындамы?

Әҗәл. Шунда.

Әлмәндәр. Яза белмим бит мин, Әҗәл дус.

Әҗәл. Хәйләләмә. Председатель булып эшләдең.

Әлмәндәр. Соң, җаным-бәгырем, вакыты шундый иде.

Әҗәл. Кил, кулыңнан тотып яздырам.

Әлмәндәр. Орынма. Әлмәндәр дип искечә яза беләм. Тик аз гына сабыр ит, бал кабып куйыйк.

Әҗәл. Капмыйсың, Әлмәндәр.

Әлмәндәр. Балдан ни була?

Әҗәл. Өйрәнеп алдым мин сине. Бал кабам дип, этлек эшләргә җыенасың.

Әлмәндәр. Юк ла инде. Нәрсә син ул чаклы? Кил, утыр, торма каршымда тасраеп. *(Кружкага бал салып.)* Йә, тотып куй, минем исәнлеккә.

Әҗәл. Юк, юк... Беренчедән, миңа ярамый, икенчедән, ничек инде синең исәнлеккә эчим, ди? Мин бит синең янга исәнлек-саулык теләп килмәдем.

Әлмәндәр. Минем җаным өчен тот, алайса. Озакка сузма, кул да куясы бар.

Әҗәл. Шулай дисәң генә. *(Кружкадагы балны эчеп куя.)*

Әлмәндәр. Менә шулай. *(Үзенә дә салып эчә.)* Менә шулай. Ничек, әйбәтме?

Әҗәл. Беләм инде, син начар нәрсә эчмисең.

Әлмәндәр. Шулай шул. Тот тагын берәрне. Әйдә, бер утырган — бер гумер. Син мине бүтән күрмәячәксең. Сагынып сөйләрлек булсын.

Әҗәл. Аз гына сал.

Әлмәндәр салып бирә, Әҗәл эчә. Әлмәндәр дә салып эчә.

Әлмәндәр. Әйдә, хәзер рәхәтләнеп сөйләшеп утырыйк.

Әҗәл. Яратам мин сине, Әлмәндәр дус. Валлаһи дип әйтәм, тимәс идем мин сиңа... Нишлим... Кил, Әлмәндәр дус, кочаклап үбим бер үзеңне.

Әлмәндәр. Анысы булмый, Әҗәлетдин.

Әҗәл. Яратмыйсың син мине, Әлмәндәр, беләм. Дошман күрәсең. Эх!.. *(Әлмәндәрнең казакие өстенә ава да гырлап йокыга китә.)*

Әлмәндәр, аның янына килеп, йоклаганмы-юкмы икәнен карый. Әҗәлнең йоклаганлыгына ышангач, казакиен тартып алып, шыпан гына бакчадан чыгып ычкына.

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Интермедия

Прологтагы күренеш. Сәхнәдә Газраил белән Фәрештә.

Газраил. Бер мең биш йөз илленче номерлы Әҗәлдән хәбәр юкмы?

Фәрештә. Юк.

Газраил. Нишләп йөри ул? Унике сәгать вакыт үтте. Әлмәндәр һаман исән. Нәрсә бу?

Фәрештә. Белмим. Бәлки, Әлдермеш авылын таба алмый йөридер.

Газраил. Юкны сөйләмәгез. Кесәсендә Җир өстенең картасы бар.

Фәрештә. Сез булып сез дә картадан Әлдермешне таба алмадыгыз.

Газраил. Күп белмәгез. Барыгыз, эшегездә булыгыз.

Фәрештә китә, Әҗәл керә.

Әҗәл. Мөмкинме?

Газраил. Һә, кайткан. Кайда Әлмәндәр?

Әҗәл *(башын аска иеп)*. Юк.

Газраил. Ничек юк?

Әҗәл. Кызгандым мин аны.

Газраил. Нәрсә-ә?!

Әҗәл. Кызгандым. Жибадур кебек тап-таза, менә дигән кеше.

Газраил. Нинди жибадур?!

Әҗәл. Әлдермеш авылында «живодёр» дигән сүзне, үзгәртеп, «жибадур» диләр. Ләкин яхшы мәгънәдә кулланалар. «Бо-

лото» дигән сүзне «мулата» диләр. «Во саду ли во огороде» дигән җырны «Ассалуди, былгаруди» дип җырлыйлар.

Газраил. Син нәрсә лыгырдыйсың?

Әҗәл. Лыгырдамыйм, дөресен әйтәм. Әлмәндәр үзе җырлады. «Ассалуди, былгаруди гуләйт иттек кыз белән» дип җырлады.

Газраил *(Әҗәл каршына атылып килеп)*. Син!.. Син, Әлмәндәрне алып киләсе урынга, җыр өйрәнеп яттыңмы?! Бу ни бу?! Нәрсә бу?! *(Шулвакыт телефон шалтыраган тавыш ишетелә. Газраил кесәсеннән телефон трубкасын ала.)* Әйе, тыңлыйм. Тыңлыйм, бөек Алла. *(Трубканы кесәсенә салып.)* Бетте баш, әгәр ул сизеп алган булса, мәрхәмәт көтмә! Беркая да китмичә, шушында мине көтеп утыр. *(Тиз генә чыгып китә. Фәрештә керә.)*

Фәрештә. Эләктеме?

Әҗәл. Булды бераз.

Фәрештә. Нигә соңладың?

Әҗәл. Син дә сорау алма әле.

Фәрештә. Ә мин беләм.

Әҗәл. Нәрсә беләсең?

Фәрештә. Син Әлмәндәр картны югалттың.

Әҗәл. Каян беләсең?

Фәрештә. Минем белмәгәнем юк.

Әҗәл. Кайда ул Әлмәндәр?

Фәрештә. Әйтимме соң?

Әҗәл. Нәрсә чытлыкланасың? Минем хәлне күреп торасың ич.

Фәрештә. Күреп торам... Газраилгә баш бирергә теләмәвең өчен, мин сине хөрмәт итәм.

Әҗәл. Рәхмәт. Хөрмәт иткәч әйт, кайда Әлмәндәр?

Фәрештә. Антоновка авылында. Евстигней исемле карт янында.

Әҗәл *(карта каршына барып, Антоновка авылын эзләп таба)*. Кара, карт төлке, кая сызган. Рәхмәт сиңа. Бу юлы ычкына алмассың, Әлмәндәр.

Фәрештә. Ни өчен син Әлмәндәр картны яклыйсың?

Әҗәл *(кинәт кызып)*. Яклыйм?.. Әйе, яклыйм! Хакым юкмы әллә?! Әгәр беләсең килсә, җанкисәгем, дөнья үлемнән генә тормый. Туйдым! Әгәр кулымнан килсә, мин үзем Әлмәндәр урынында булыр идем. Без кемнәр синең белән? Үлемсез булуыбыздан ни мәгънә? Безнең бар белгәнебез: кайгы, хәсрәт, күз яшьләре.

Фәрештә. Оһо! Син үзгәреп кайткансың.

Әҗәл. Ни кызганыч, әмма мин үзгәрә алмыйм. Үзгәрә алсам, Әлмәндәр картны Газраил кулына бирмәс идем.

Фәрештә. Әлмәндәр дә Әлмәндәр, дисең. Кем соң ул? Галимме? Искиткеч бер ачыш ясаганмы? Танылган җырчымы?

Әҗәл. Юк. (...) Гап-гади кеше. Ләкин гомере буе яшәүнең кадерен, тәмен белеп яшәгән кеше. Иң авыр чакларда да тормыштан ямь таба белгән, күңел көрлеген югалтмаган кеше. Ул — авылның шатлыгы, өмете. Аны күреп сөйләшкән кеше кайгысын оныта. Мин дә Әлмәндәр карт яшенә җитәрмен дип өметләнә. Азмы болар? Хәер, без нәрсә аңлыйбыз соң?

Фәрештә. Ә нигә аңларга? Аңламау, бәлки, хәерлерәктер.

Әҗәл. Бәлки, бәлки. Шулай да...

Фәрештә. Ләкин шуны бел: хуҗа бу юлы онытмаячак.

Әҗәл. Аңладым.

Фәрештә. Килә... Мин сине хөрмәт итәм, шуңа күрә кисәтергә уйладым. *(Чыгып китә.)*

Газраил *(кереп)*. Бәхетең, сизмәде. Күрсәтә идем мин сиңа «ассалуди, былгаруди»еңны. Бар хәзер Әлдермешкә. Әлмәндәрсез борылып кайтасы булма.

Ут сүнә.

III күренеш

[Әҗәлдән качкан Әлмәндәр күрше Антоновка авылындагы «знакумы» Евстигней карт янына килгән. Ике карт үткән тормышларын, берберсенә ярдәм итешеп яшәүләрен искә төшерәләр. Евстигней кунагына кунарга урын хәстәрләтергә дип кереп киткәч, Әҗәл килеп чыга. Әлмәндәр карт кәгазьгә кул куярга ризалык бирә, ләкин ул, кешене борчуга салмас өчен, моны үз авылында эшләячәк... Ахирәтенең кинәт юкка чыгуын күреп, Евстигней карт аптырый.]

IV күренеш

Әлмәндәр карт бакчасы. Эшләнеп бетмәгән алачык идәнендә Әлмәндәр белән Әҗәл утыралар. Вакыт — төн. Әрәмәлек ягыннан гармунга кушылып җырлаган тавышлар ишетелә.

Әҗәл. Ятып ял итеп ал, Әлмәндәр. Шактый юл үттең, арыгансыңдыр.

Әлмәндәр. Акылың алтын икән. Ял итеп ал дигән булып мәңгелеккә йоклатырга җыенасыңмы?

Әҗәл. Нәрсә инде син. Кем дип беләсең мине ул кадәр? Син генә ул алдашасың, мин гадел эш йөртәм. Кулыңны куймаган килеш сиңа орынаммы?.. Синең өчен эләгәчәк миңа. Ләкин барыбер соңгы төнеңне үзеңә бирәм.

Әлмәндәр. Маташтырма.

Әҗәл. Валлаһи, билләһи. Төнлә алып китмим сине. Таң атканда, кояш чыгар алдыннан, көн уянганда. Күңелең гел якты булгач, үлемең дә якты булсын. Ә бүген төнлә син теләгән нәрсәңне эшли аласың.

Әлмәндәр. Җәйге кыска төндә ни эшләп булсын. Ашап туймаганны ялап туеп булмас.

Әҗәл. Уйла. Үкенечләрең калмыймы?

Әлмәндәр. Юк. Мин кылган эшләремә үкенмәдем. Эшләргә ниятләгән эшемне ахырына җиткезеп туктадым. Ярты юлда менә шушы алачык кала, тагын... тагын... Дөнья кала. Төзелеп бетмәгән дөнья кала. Төзеп бетерәсе иде. Кешеләр үлсәләр дә, ичмасам, минем яшемә җитеп, үз үлемнәре белән үлсеннәр иде. Уттан кырылмасыннар иде.

Әҗәл. Нәрсә әле син мескенләнеп коелып төштең, Әлмәндәр? Шундый күңелле иде синең белән, кинәт сүндең. Салындырма борыныңны, җебемә, чурту-матыр. Тор, әйдә, алачыгыңны кадаклап бетерәбез.

Әлмәндәр. Төнлә шакылдау килешми. Кешеләр йоклый.

Әҗәл. Нишләргә соң инде синең белән?

Әлмәндәр. Китер кәгазеңне.

Әҗәл. Әлмәндәр...

Әлмәндәр. Китер, диләр.

Әҗәл. Нигә инде... Мин үзем әйтеп торганда...

Әлмәндәр. Белеп тор: мин кул куйдырдым, Әлмәндәрне җиңдем дип мактанасы булма, үзем куям.

Әҗәл. Хет өйдәге улың, киленең, оныгың белән саубуллаш.

Әлмәндәр. Йокылары бүленмәсен.

Әҗәл. Ярый соң, алайса, әйтмәк бар, көчләмәк юк. Соңыннан миңа үпкәләмә. *(Кәгазь белән карандашны Әлмәндәргә суза.)* Әлмәндәр, кызганам мин сине, валлаһи кызганам. Сиңа ярдәм итәсем килә, ничек ярдәм итәргә белмим. *(Кинәт бер фикергә килә.)* Таптым! Таптым, Әлмәндәр дус! Син исән калачаксың!

Әлмәндәр *(кәгазьне атып бәреп)*. Әйт тизрәк!

Әҗәл. Искәндәр! Улың Искәндәр! Фамилиягез бер, исемнәрегез охшаган. Абайламас Газраил. Сизелмәслек итеп эшләрмен. Искәндәр үзе дә Әҗәл көтеп ята. Керим мин аның янына, кул куйдырып чыгыйм.

Әлмәндәр *(сикереп торып)*. Ни дидең? Ни дидең син, явыз?! Минем бердәнбер улыма? *(Әҗәлнең якасына ябыша.)*

Әҗәл. Нишлисең, җибәр!.. Әйтерсең мин үзем өчен.

Әлмәндәр. Дәшмә!

Әҗәл. Синең өчен бит, яшисең килә бит.

Әлмәндәр. Дәшмә, дим!

Әҗәл. Дәшмим, чурту-матыр, мәтәлеп кит. Ике тиенлек тә акылың юк. «Ала карга» дип җырлап йөрергә генә беләсең. Аңарга китсә, ала карга асыл кош та түгел әле.

Әлмәндәр. Булмасын. Ул — җан иясе.

Әҗәл. Аның кемгә кирәге бар?

Әлмәндәр. Дөньяда булгач, кирәге бардыр. *(Пауза.)*

Әҗәл. Гафу ит, Әлмәндәр. Мин Искәндәрне исеңә төшереп ялгышканмын. Синең Әлмәндәр икәнеңне онытып җибәргәнмен. Әй дөнья, дөнья... «Ассалуди, былгаруди...» *(Җирдә яткан кәгазьне алып.)* Ярар, синеңчә булсын. Бөтенесе син дигәнчә булсын, мә. Мә, карандаш.

[Әлмәндәр кул куярга җыенганда, бакча рәшәткәсе янына Гөлфирә белән Мансур килеп туктыйлар. Карт белән Әҗәл ике яшьнең сөйләшү-аңлашуын кызыксынып күзәтәләр. Башта тырт-мырт барган сөйләшү аңлашу белән тәмамлана.]

Мансур *(бар көченә кычкырып)*. Яратам! Я-ра-та-а-а-ам!

Гөлфирә. Нишлисең, җүләр!

Мансур *(җырга күчеп)*.
Уфа тараклары белән
Күңелле чәч таравы;
Үзәкләремне өзәдер
Бер елмаеп каравы...

Гөлфирә. Нишлисең, Мансур! Кешеләр ишетә.

Мансур. Беркем дә юк, Гөлфирә, дөньяда без икәү генә.

Әлмәндәр *(Гөлфирә белән Мансур ишетерлек итеп)*. Ә мин?! Мине кая куясыз. Мин бар, мин — шаһит! *(Мансур белән Гөлфирә Әлмәндәр тавышын ишетеп сызалар. Әлмәндәр, төзәеп, бакча уртасына баса.)* Ә мин?! Мин бар дөньяда! Мин исән! Кит, Әҗәл. Китеп тор янымнан! Эх!.. *(Мансур җырлаган көйгә җырлап, бакча буйлап йөренә.)*

Уфа тараклары белән
Кем чәчләрен тараган;
Фани дөнья авыр диләр,
Кем күтәреп караган...

Бакчага Өммия чыга. Аптырап, Әлмәндәргә карап тора. Әлмәндәр, җырын дәвам итеп, аның каршына бара.

Өммия. Әллә инде акылың ук җиңеләйдеме, Ходаем. Өйдә югыең лабаса, Антунга китте, дигәннәрие. Кай арада кайтып җиттең? Булсаң да булырсың икән.

Әлмәндәр. Кушылып җырла миңа, килен.

Өммия. Әстәгъфирулла. *(Тиз генә кереп китә.)*

Әлмәндәр. Надан! *(Алачык янына бара-бара сөйләнә.)* Дөнья ямен аңламый. Япь-яшь башларыннан йоклап яталар. Эх, егерме генә елга яшь булсам! *(Алачык идәненә утырып.)* Утыз гына елга. Кырык... Илле... Алтмыш... Җитмеш...

[Шунда, алышынып китүе булса кирәк, Әлмәндәр үзен 70 ел элек сөйгәне Йөзембикә белән су буенда очраша итеп күрә. Яшьләрчә сөйләшү-аңлашу: шаян тапкырлык, бер-берсенә эчкерсез ихтирам, саф хисләр...— болар ярдәмендә һәр ике яшьнең холкы, менәз сыйфатлары ачыла. Бакчага Өммия белән Искәндәр чыгалар.]

Өммия. Күр, үз күзләрең белән күр.

Әлмәндәр. Күрәм, Йөзембикә, күрәм.

Искәндәр *(Әлмәндәр янына килеп)*. Әти...

Әлмәндәр *(ике аягына басып, текәлеп, Искәндәргә карап тора)*. Улым, синме соң бу?

Искәндәр. Мин, әти, мин...

Әлмәндәр. Мин әле әниең белән сөйләшеп утырдым.

Өммия. И Ходаем, шул гына җитмәгән иде.

Әлмәндәр. Килен, син дә мондамыни?

Өммия *(курку-ыбрак)*. Монда, әткәй, монда.

Әлмәндәр. Ачуланма инде, килен.

Өммия. Ачуланмыйм, әткәй, ачуланмыйм.

Әлмәндәр. Авыр сүз әйтеп күңелеңне рәнҗеткәнем булмады бит, килен. Ачуланганда да яратып, үз итеп ачуландым.

Өммия. Шулай, әткәй, шулай...

Әлмәндәр. Әй телең, килен. Бигрәк тәмле. Сандугач кебек сайрыйсың. Шундый телне кырык ел миннән яшереп яшәдең.

Искәндәр. Әти, өйгә керик.

Әлмәндәр. Минем белән әрепләшү синең үзеңә дә дөнья рәхәте бит, килен. Синең юньсез ирең көн озынына өч сүз дә әйтми. Ә хатын-кыз сөйләшмичә тора алмый. Дөрес әйтәмме, килен?

Өммия. Хак, әткәй, хак сөйлисең. *(Искәндәргә шыпырт кына.)* Малайларга, кызларга хәбәр итәргә кирәк.

Әлмәндәр. Ни сөйләшәсез, килен?

Өммия. Сине мактыйбыз, әткәй.

Әлмәндәр. Шулай, дөрес. Юкса кара аны, матри, килен. Килегез, тезелешеп утырыйк әле. *(Алачык идәненә утырып.)* Улым, син уң ягыма, килен, син сул ягыма утыр.

Өммия. Утырабыз, әткәй, утырмыйбызмы соң. *(Утыралар. Өммия шикләнебрәк кырыйгарак утыра.)*

Әлмәндәр. Якынрак кил, килен. Менә шулай. Күрәсезме, балалар, таң ата. Озакламый кояш чыгар. *(Искәндәргә.)* Син нигә өстеңә кимәдең? Таң атканда салкын була. *(Өстеннән казакиен салып, Искәндәр иңенә яба.)*

Өммия. Авырткан җирең юктыр бит, әткәй?

Әлмәндәр. Йөрәгем урынында түгел. Кош булып очып йөри.

Өммия. Алай икә-ән. Болай кайда утырганыңны, нишләп йөргәннәреңне беләсеңме соң?

Әлмәндәр. Килен, бар әле, Хәмдебануны чакырып кер.

Өммия. Хәмдебануны?.. Йоклыйдыр ул, әткәй.

Әлмәндәр. Таң атканда йоклап яталармы?

Өммия. Анысы шулай да... Син дә ятып тор... Җиңеләеп китәрсең.

Әлмәндәр. Әйткәнне тыңла, килен.

Өммия. Искәндәр, нишлим?

Искәндәр. Бар, чакыр.

Өммия. И Ходаем... *(Дия-дия бакча капкасына бара. Анда Гөлфирә белән Мансурны очрата.)* Кайда йөрисең син бу вакытка чаклы? Дәү бабаң...

Гөлфирә. Нишләгән?..

Өммия. Нишләгән, нишләгән... Акылы җиңеләйгән. Бар, Хәмдебану әбиеңне чакыр.

Гөлфирә. Нигә?

Өммия. Белмисезмени, өйләнәм дип саташа бит. Үләм, Ходаем, адәм көлкесенә калып бетәбез. Вакытында үлә белмәсәң, шулай инде ул. Бар инде, күңеле булсын.

Әлмәндәр. Килен, үзеңә кушкан йомышны бүтәннән эшләтмә.

Өммия. Үләм. Колагын кара син аның. И Ходаем... *(Китә.)*

Гөлфирә *(тиз генә бакчага керә, Әлмәндәр янына килә).* Дәү бабай...

Әлмәндәр. Сөйгән егетең нигә кермәде?

Гөлфирә. Дәү бабай...

Әлмәндәр. Бар, алып кер.

Гөлфирә. Анда беркем дә юк, дәү бабай.

Әлмәндәр. Алып кер. *(Гөлфирә, бакча капкасына барып, Мансурны чакырып кертә. Мансур кыюсыз гына Әлмәндәр янына килә.)*

Әлмәндәр. Ник алай, әйбер урлаганда тотылган сыман киләсең?

Мансур. Исәнмесез, Әлмәндәр бабай. Исәнме, Искәндәр бабай.

Әлмәндәр. Исән булмый, нишлик. Ничек дидең әле, дөньяда без икәү генә, дидеңме? Шәп әйттең, муладис. Кара аны, арагызга өченче кешене кертмә, колагың борып өзәрмен. Менә, Искәндәр улым, оныгыңның кияве шушы егет була. Белә идеңме?

Искәндәр. Әти...

Әлмәндәр. Әй, сиңа сүз әйткән мин җүләр. *(Гөлфирәгә.)* Дәү әбиеңә охшагансың икән син, кызым, бәхетле булырсың. Кил, утыр яныма. Син, кияү... Мансурмы әле исемең?

Мансур. Мансур.

Әлмәндәр. Илсур атлы энең дә бармы әле синең?

Мансур. Бар.

Әлмәндәр. Кайда ул?

Мансур. Йоклыйдыр.

Әлмәндәр. Алып кил.

Мансур. Мондамы?

Ә л м ә н д ә р. Алып кил дигәч, монда була инде.

Г ө л ф и р ә. Дәү бабай...

Ә л м ә н д ә р. Йокысыннан уяна алмаса, күтәреп алып кил. Бар инде, бар. Егет кеше ике әйткәнне көттерми. *(Мансур чыгып китә.)*

И с к ә н д ә р. Әти, өйгә керик.

Ә л м ә н д ә р. Бакчага кунаклар чакырдым, өйгә кереп качыйммы? Дөрес бит, кызым?

Г ө л ф и р ә. Дәү бабай, син кыланасыңмы?

Ә л м ә н д ә р. Ни дидең?

Г ө л ф и р ә. Син кыланасың гына бит, әйеме?

Ә л м ә н д ә р. Дәү бабаң гумере буе кыланчык булды, кызым.

Бакча капкасы янында Хәмдебану белән Өммия.

Ө м м и я. Нишләтәсең инде, Хәмдебану. Элек тә тулы түгелие, хәзер булганы да чыгып беткән. Оят инде, оят.

Х ә м д е б а н у. Хәерле булсын.

Ә л м ә н д ә р. Килгәч, нигә керми торасың, Хәмдебану!

Х ә м д е б а н у. Керәм, Әлмәндәр абзый, керәм. *(Өммия белән алачык янына киләләр.)*

Ә л м ә н д ә р. Йоклый идеңме, Хәмдебану?

Х ә м д е б а н у. Юк, Әлмәндәр абзый, уянган идем.

Ә л м ә н д ә р. Берьялгызың күзгә йокы кермидер шул. Менә мин дә йоклый алмыйм.

Х ә м д е б а н у. Йокларсың, Алла боерса.

Ә л м ә н д ә р. Йокларбыз, диген, Хәмдебану.

Х ә м д е б а н у. Әй Алла...

Ө м м и я. Сөйләмә дә инде.

Ә л м ә н д ә р. Кияүгә чыкмыйм дисең инде, алайса, Хәмдебану?

Х ә м д е б а н у. Чыгарбыз, Әлмәндәр абзый, чыгарбыз.

Ә л м ә н д ә р. Кемгә?

Х ә м д е б а н у. Кемгә дип... Әй Алла... Исән-сау терел дә, чыгарбыз.

Ә л м ә н д ә р. Мин авырумыни?

Х ә м д е б а н у. Юк, Әлмәндәр абзый. Алла сакласын.

Ә л м ә н д ә р *(кинәт көлә башлый. Көлеп туктагач)*. Әй килен, килен. Каенатаңны ничек чирләтергә белми аптырыйсың ла инде. Авырмыйм мин, Хәмдебану, тап-таза мин.

Х ә м д е б а н у. Шулай булмый соң... Шулай, Әлмәндәр абзый.

Ә л м ә н д ә р. Кил әле, утыр әле яныма. Кит, улым, читкәрәк, кыз белән егет сөйләшкәнне тыңлап утыру — гөнаһ. Утыр, Хәмдебану, курыкма, тимим.

Х ә м д е б а н у. Утырам, Әлмәндәр абзый, нидән куркыйм. *(Утыра.)*

Әлмәндәр. Әгәренки кулым белән ялгыш кагылсам, колак төбемә утыртырсың, ярыймы? Теге вакытта түбән очның бозау Закирга суккан шикелле итәрсең. Хәтереңдәме?.. Егерме биш яшеңдә ирсез калып, берәүне дә якын җибәрмәдең шул. Һаман берьялгызың. Үзсүзле хатын булдың, Хәмдебану. Димләп карадым, гумереңне заяга үткәрмә, интекмә дип, бүтәннәргә димләп карадым, ачуланган чакларым булды. Сүземне тыңламадың. Үземә кияүгә чык дип бәйләндем — ачуландың. Рәхмәт, рәхмәт, Хәмдебану, сынатмадың. Ирең мәрхүмне рәнҗетмәдең. Әгәренки мин хөкүмәт башында торсам, синең кебекләргә мидал бирер ием. Ишетәсеңме, Гөлфирә кызым? *(Өй ягыннан бакчага Евстигней чыга.)*

Евстигней. Альмандар, ай, Альмандар!..

Әлмәндәр. Здич мин, Ястәгнәй.

Евстигней *(алачык янына килеп).* Син — шайтан, Альмандар. Кая качтың? Бакча чыгам — син юк. Аптыраш. Бригадирга барам, ат бир әйтәм, Альмандар барам. Начар, Альмандар. Дус качкан, начар. Килям. Ызба керәм — юк. Тыңлыйм — гургур-гур — син тавыш.

Әлмәндәр. Садис, Ястәгнәй. Малы-малы балакыем. Сын, сноха, дучка, Хәмдебану сидим балакыем, хураша. День идёт, сулныцы идёт.

Евстигней *(башкаларга).* Якшимисиз?

Өммия. Зрастуй, Ястәгнәй дәдәй. Старик ни слушай. Маклашка давай. Один сад ходит, писнәләр пают. *(Гөлфирә көлгәнне күреп.)* Нигә көләсең?

Искәндәр. Сөйләшә белмәсәң, тик тор, Өммия!

Өммия. Сез генә оста инде.

Евстигней. Ничево! Якши, якши, килин. *(Әлмәндәр янына утырып.)* Ну, как кайткан? Мин курыккан.

Әлмәндәр. Хураша, Ястәгнәй. «Ассалуди, былгаруди». Спасибы.

Йоклаган Илсурны күтәреп, Мансур керә. Бакчага кергәч уятырга тырыша.

Мансур. Уян, диләр! *(Колагын уып.)* Уян! *(Илсур тибергенә.)*

Әлмәндәр. Тимә! Ник тиясең малайга.

Мансур. Уянмый ич. *(Илсурны җиргә бастыра. Илсур җиргә утыра, күзләрен уа.)*

Әлмәндәр. Кешене шулай уяталармы, кит яныннан. *(Илсур каршына тезләнеп.)* Нәрсә, йоклаулары бик тәмлемени? Йокла, йокла. *(Илсур, күзләрен ачып, Әлмәндәргә карап тора.)* Таныдыңмы? Мин ич бу. Кәнфит кирәкме?

Илсур. Кирәкми.

Ә л м ә н д ә р. Бал ашыйсың киләме?
И л с у р. Ю-ук.
Ә л м ә н д ә р. Алма биримме?
И л с у р. Бирмә.
Ө м м и я. Интектермә инде баланы.
Ә л м ә н д ә р. Илсур, мин китәм бит.
И л с у р. Кая?
Ә л м ә н д ә р. Әллә кая, бүтән кайтмыйм.
И л с у р. Китмә.
Ә л м ә н д ә р. Уянсаң китмим.
И л с у р. Мин йокламыйм.
Ә л м ә н д ә р. Менә мулалис. Яле, бер җырлап җибәр.
И л с у р. Җырлыйсым килми.
Ә л м ә н д ә р. Мин җырлыйммы соң?
И л с у р. Җырла.

Ә л м ә н д ә р *(көйләмичә генә).* Без андый малай түгел,
Без мондый малай түгел:
Безнең башлар балык түгел,
Куырып ашамаслар.

И л с у р *(елмаеп).* Алай түгел.
Ә л м ә н д ә р. Ничек соң?
И л с у р. Беләсең. Юрый-марый гына кыланасың.
Ә л м ә н д ә р. Кыланмыйм инде. Онытканмын. Шуңа күрә сине чакырып китердем.
И л с у р. Көләсең.
Ә л м ә н д ә р. Көлмим ич инде.

И л с у р *(көйләмичә генә).* Без андый малай түгел,
Без мондый малай түгел:
Кая барсак та ярыйбыз,
Күгәргән калай түгел.

Ә л м ә н д ә р. Муладис! Әйдә, хәзер көйләп...
И л с у р. Алма бир.
Ә л м ә н д ә р. Алмамы? Бирәм. Ал үзең өзеп.
И л с у р. Син үзең бир.
Ә л м ә н д ә р. Үземме? Хәзер, хәзер... *(Якындагы алмагачтан алмалар өзеп, Илсур алдына өеп куя.)* Менә... Булдымы?

И л с у р. Булды. *(Җырлый.)* Без андый малай түгел лә,
Без мондый малай түгел:

(Илсурга Әлмәндәр кушыла.)

Кая барсак та ярыйбыз,
Күгәргән калай түгел.

(Әлмәндәрнең күзе алмагач артында басып торган Әҗәлгә төшә.)

Ә л м ә н д ә р. Яле, Илсур, тагын берне сыздыр. «Шырдый»-ны...

Илсур. Мин җырлыймын бырдыйны,
Бырдый белән шырдыйны.
Минем җырны ошатмасаң,
Үзең җырла шундыйны.

[Илсур җырлаганда, Әлмәндәр Әҗәл янына бара. Әҗәлнең кулыннан кәгазь-карандаш алып, кәгазьне Әҗәлнең сыртына җәеп кул куя. Җырның соңгы ике юлын кабатлап җырлап, алачык янына килә.]

Әлмәндәр. Минем җырны ошатмасаң,
Үзең җырла шундыйны.

Ут сүнә.

ЭПИЛОГ

Пролог һәм интермедиядәге күренеш. Сәхнәнең бер ягыннан Газраил, икенче ягыннан Әҗәл чыга.

Газраил. Кайда Әлмәндәр?

Әҗәл *(кәгазьне сузып).* Алыгыз, сезнеңчә булды.

Газраил. Кайда үзе?

Әҗәл. Алгы бүлмәдә утыра.

Газраил. Алып кер. *(Алгы бүлмәдә Фәрештәнең чәрелдәп кычкырганы ишетелә, һәм Фәрештә, атылып, Газраил кабинетына килеп керә.)*

Газраил. Ни булды?

Фәрештә *(кытыкланып).* Ул, ул мине кочаклый.

Газраил. Кем?

Фәрештә. Карт.

Әҗәл. Карт түгел, Әлмәндәр. Әлдермештән Әлмәндәр. *(Алгы бүлмәдән Әлмәндәрнең «Бырдый белән шырдый»ы яңгырый.)*

Пәрдә төшә.

Бетте.

1976

Равил Фәйзуллин
(1943 елда туган)

МИНЕМ ТЕЛЕМ

Минем телем —
меңәрләгән ишләре күк,
тыйнак тел ул.
Гайрәтләнмәс, артык һаваланмас,
яңгырыйм дип кабаланмас,
егәр чиген белер,
йөрер җирен...
Басынкы ул:
халыкара конгресслар,
парламентлар ачып йөрми,
акча, чеклар битенә менми.
Сугыш ачмыйлар минем телемдә,
капитуляция дә ясамыйлар...

Түзем тел ул.
Окопларда, төрмәләрдә, лагерьларда
атылса да, асылса да,
җиңү рухын җуймаган ул.

Гильотина өсләрендә
яшәү җырын җырлаган ул!

Минем телем —
меңәрләгән ишләре күк,
моңлы тел ул.
Үзенә җай, үзенә ятыш аның көе:
«Сак-Сок»лары, «Рамай»лары, «Сарман»нары,
«Гөлҗамал»ы, «Карурман»ы, «Әллүки»е...

Гавами ул,
бик гади ул.
Минем телдә иген үсә,
сөт парлана, җеп эрләнә,
нефть чыга, тире иләнә...
Туендыручылар,
киендерүчеләр дигәндә,
минем телем искә төшсен!

* * *

Җаныңның ваклыгын
сылтама заманга.
Куркырга, өркергә
җай бар ул һаман да.

Ә бит бар кешеләр —
шәхесен ватмаган,
хаклыкны сатмаган,
вөҗданны саклаган.
Әйткәннәр: тарихтан
түгелсәм түгеләм,
изелсәм изеләм —
әмма дә бөгелмәм!

Үзләре сеңсә дә,
рухлары калыккан.
...Әнә шулар үлеме
җан өрә халыкка.
Асылыңны яшереп
кыланма ни генә, —
буыннар хәтерендә
бары да чигелә!

Җаныңның ваклыгын
сылтама заманга...

* * *

Кер чайкыйлар кызлар.
Тезләрендә — Кояш!

Уйларны да, керләр кебек,
ак иткәнче, пакь иткәнче,
ах, чайкарга иде!

Сагышларны ике куллап,
кысып-кысып, кысып-кысып
сыгарга иде!
Шатлыкларны иң өстенә
сыйган кадәр, сыйган кадәр
өяргә иде!

Чын җырларны җилфердәргә
биеккәрәк, биеккәрәк
эләргә иде!
Кер чайкыйлар кызлар.
Тезләрендә — Кояш!
Күзләрендә — яз!
Ярым ачык күкрәкләре
оялган күк бераз...

* * *

Мин сиңа йомшак таң җиле
юллаган идем,—
Чәчләреңнән иркәләр дип
уйлаган идем.

Сәфәреңдә илләр кичеп,
тауларда куныш,
Ул сиңа ирешкән икән
зилзилә булып.

Мин сине сагынып бер җыр
чыгарган идем;
Җан дуслар аны яратып
тыңлаган иде.

Җыр сиңа ошар дип йөрдем,
ваемсыз булып.
Ә ул сиңа барып җиткән,
авыр сүз булып.

...Хәзер җилләр дә юлламыйм,
чыгармыйм җыр да.
Әгәр теләсәң, җанымны,
үзең кил, тыңла.

СӘЙДӘШ

(поэмадан өзек)

II. Җыр

> Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
> Һәм уларга кыю ир булып!
>
> *М. Җәлил*

Халыкларның җаны ул — җыр, диләр.
Җыр, диләр дә бездә, моң, диләр.
Телгәләсә, киссә бәгырьләрне,
татар җыры инде — шул, диләр.
Монда баскан, изгән, туглаган... Юк,
безнең җырлар — киңрәк, тирәнрәк!
Ничек тоташ хәсрәттән торсын
хезмәт дәртле тулы бу йөрәк!
Җиң сызганып эшли белгәннәрдә
күпме куәт, күпме ярсу бар!
Мәхәббәт бар, сөю, ачу бар!

Ренат Харис
(1941 елда туган)

ӨЯНКЕ

Өскә үсмәсен әле дип,
баш ботагымны киссәң,
мин бит як-якка үсәм!..

Киңлеккә китмәсен диеп,
ян-якларымны киссәң,
мин куелыкка үсәм!..

Куелыкка үсмәсен, дип,
ябалдашымны киссәң,
мин тамыр якка үсәм!..

Бәгыренә чабыймчы, диеп,
казып тамырыма төшсәң,
кабрең өстендә үсәм!

АК СӨЛГЕ

Ихтирамымны белгертим
Хак сүз белән:
Кунак килсә каршыладың
Ак йөз белән;
Дошман килсә чыкмадың
Кулын юарга,
Һәм булмадың ак төстәге
Сатлык байрак!
И ак сөлге, беркайчан да
Пычранмадың —
Күпме сөрттең гаделләрнең
Хәләл канын!
Син көрәштең Сабантуйда,
Билгә яттың.
Көрәшченең гаделлеге,
Көче артты.
Көрәшләргә озатып калдың
Син ирләрне,
Сау бул, диеп, кулга кушылып
Җилфердәдең.
Җилфердәдең кызыл туйлар
Пар атында,
Әверелеп туйның бәхет
Канатына...
Җеназада син, ак сөлге,
Безнең кулда.
Озатасың гүр иясен
Соңгы юлга...
Кичерешләрнең таныш сиңа
Һәркайсысы,
Илемнең һәрбер шатлыгы,
Һәр кайгысы.
Син бит үзең дә халкымның
Күңеле төсле —

Сөттән сеңгән зур пакьлекнең
Бер көзгесе.
Һәрбер эшнең, һәр ниятнең
Өмете — уңыш.

Кешеләрнең нияте зур,
Сөлге,
Булыш!

АЛТЫН ТӨРӘН

Җир сөрәм...
Гасырлар катламнарына үтеп керәм...
Туфракта Киек Каз Юлының тузанын күрәм...

Җирнең бәгърен кояш нуры белән кавыштырам,
ерак тарих серен бүгенгегә таба авыштырам,
ашлык тамырын космик токым белән таныштырам.

Континенттан континентка дуслык буразнасы сызам,
халыклар каһарманлык кылган юллар аша узам,
акыл һәм хис арасына Җир әйләнә сукмак сузам.

Мин чәчүгә кыр әзерлим,
тынычлыкка җыр әзерлим,
Җиргә тыныч чор әзерлим!

Миндә — Киек Каз Юлының ак төсе,
даһи маңгаенең яктысы,
бәхет учагының чаткысы.

Миндә — Җирнең иң мәрхәмәтле аңы!
Ышанычлы — мәхәббәтнең миңа таянган таңы!
Миндә — кешелекнең газиз җаны!
Мин җир сөрәм —
кеше язмышын буразнага һәм кояшка кушып үрәм.
Мин — мәңге тутыкмас алтын төрән!

СУСАП КИЛ!

Кунак килсә, чәе дә бар,
Мае да бар бу җирнең.
Һәркемне шаккатырырлык
Җае да бар бу җирнең.

Иркәли дә белә бу җир,
Кырыслана да белә —
Ничә гасыр тиешенчә
Кунак каршылап килә:

Кайсына биек, кайсына
Бик җайлы бусагасы...
Ул ярата кунакларның
Дуслыкка сусаганын.

ЭЛЕГИЯ

Бүлмәмдә — кук төтен,
Урамда — сары көз.
Көз көне китмә син,
Кышкача, зинһар, түз.

Мин имән түгел ич,
Түгел ич мин каен —
Бу кышка керергә
Яфрагым саргаеп.

Бу көзгә көз өстәп
Өзелсәң күңелдән,
Мин, шәрә агачтай,
Ак карга күмеләм...

КЫРГЫЙ КЫЗ

Үзе — ялкын,
Үзе — боз...
Кырын-кырын карап ала
Кыргый күзле
Кыргый кыз.

Башкаларны, һич югында,
Без күз белән назлыйбыз.
Кая кулны,
Күз карашын да тидертми
Кыргый кыз.

Сөзеп караса, күзенә
Сыя ай һәм бар йолдыз...
Тик мине генә күзенә
Һич сыйдырмый
Кыргый кыз.

Йөрәгемдә минем яра.
Яра аша әчкә уз!
Үзе — ялкын,
Үзе — боз,
Яралаганын да сизә,

Дәваламый ничек түзә?
Кырын-кырын карап ала
Кыргый күзле,
Кырыс сүзле
Кыргый кыз.

САБЫЙ ТУГАЧ

Елгалар:
«Үргә ага башлыйбыз икән»,— диделәр.
Үрләр:
«Шар тәгәрәмәслек булабыз икән»,— диделәр.
Шарлар:
«Энә очында торачакбыз икән»,— диделәр.
Энәләр:
«Ниһаять, кое казыйбыз икән»,— диделәр.
Коелар:
«Җирне үтә чыгабыз икән»,— диделәр.
Җир:
«Шатлыгым артырмы, кайгыммы?» — диде.



Мөдәррис Әгъләмов
(1946—2006)

ТУКАЙДАН ХАТЛАР

(поэмадан өзекләр)

Уйланырга вакыт, тирәлектә
Талкыса да гайбәт сине, мине,—
Баш өстендә кояш
Тугры карый...
Ә калганы аның үзгәрүле.

Уйланырга вакыт, узып киткәч
Сәбәп эзләү
кирәк
булмас —
Беләм.
Менә бүген булган иртә-кичең,
Үткәнең һәм киләчәгең өчен
Ант итәрлек булсын кояш белән.

Биеклекне бер омтылу белән
Алу түгел,
Көнләп алу кирәк.
Киләчәккә — кем дәвамы? диеп
Сорамаслык итеп бару кирәк.
Бу көндәлек ваклык, гадәтләрнең
Бар әле ул күп кат алышынасы,
Берсен берсе кабатламаса да,
Гасыр башы инде гасыр башы.

Мин Тукайны укыйм —
Салкыннарда

Туңа-туңа язган хатларын...
Гасыр башындагы капиталның
Ярсып котырынган чаклары...

...Шуңа каршы баскан яшь Тукайның
Янып үлгән шигъри чаптарын
Хәтерлим дә...
Янган учакларның
Күмерләрен, димен, актарыйм.

Ә ил елый, күзге җилгә кушылып,
Җилләр исә, җанны кисә-кисә.
...Ә ил елый... Кемнең кайгысы бар
Бу зур илнең кайгы-зарларында?
Тик дөньясы тыныч булып аның,
Маллар тулы булсын амбарында.

...Ә ил елый... Кемнең кайгысы бар
Моңнар белән аккан күз яшендә?
Һәркайсының үз кайгысы кайгы,
Вакыты юк илгә эндәшергә.

...Ә ил елый... Аның елавыннан
Безнең өчен нәрсә үзгәрә дип,
Шамакайлар жырлый-жырлый бии
Үз жырыңны, синең йөзгә бәреп...

Баш өстендә чорның кара кулы,
Дөнья тулы аның кара колы,
Күрсәт бармак белән төртеп кенә,
Ярылачак —
Эче кара тулы.

Юкка гына шагыйрь
Ишмиләрнең
Исләренә моны төшермәгән...

Чор үзенең кара колларына
Кагылганны буган,
Кичермәгән...
Моны белгән шагыйрь.

Егерме җиде ел гомер яшәп,
Шагыйрь һәммәсенә өлгерәчәк...

Кара чорның кара кулы шунда
Бугазына аның үреләчәк.
Шагыйрь биек,
Чорның кулы җитми —
Күкрәгенә барып тыгылачак.
Егылачак шагыйрь,
Мәңгелеккә —
Халык йөрәгенә егылачак!

СОҢГЫ СҮЗ

«...Мин кайтып җиттем. Бернәрсәгә дә аптырамадым. Әлегә җитәр».

12 май, 1912 ел
Уфадан Казанга
Кәбир Бәкергә язган хаттан

Дүртенче том кулда... Егерме хат,
Иҗат түгел, бары хат кына...
Күк капусы ачылгандай, алда
Көрәшче һәм шагыйрь яктыра.

Көрәшче һәм шагыйрь,
Сиксән биш ел
Элек язган язма, хатларын
Кулга алыйм дисәм,
Кулым пеште,
Уттан гайре берни тапмадым.

...Бүген менә бераз,
Үрелеп кенә,
Утлы күмерләрен актардым.

1972—1985

АКМУЛЛА АРБАСЫ

(поэма)

Кереш

Акмулланың арбасын
Буяганнар дан өчен...

Халык бәетеннән

...Үз арбасы, юл арбасы булган,
Өч бүлектән торган ул арба.

Кайсы якка гына юл алмасын,
Кайсы якка гына бармасын,

Көтеп алган халык Акмулланың
Өч бүлектән торган арбасын.
Йорт салырга — оста кулын көткән,
Юл салырга — шигъри хикмәтен.
Барыннан да бигрәк үзен көткән —
Аклыкның ул белгән кыйммәтен.

Күренүгә — казан асып куйган,
Әзерләнгән каршы алырга...
Менә бүген тагын аны көтә —
Кала бары таңга калырга.
Йортын салса салган сокланырлык,
Чат ябышып яткан ниргәләр.
Бүген алар, борылып карый алсаң,
Чорлар аша калкып күренәләр.
Җыр чыгарса, көйләп бирә белгән,
Акын-чичәннәрне уздырып.
Халыкларның йөрәгенә кергән,
Кунак булып түгел, үз булып.

* * *

...Саф алтынны нәҗескә буяу илән
Нәҗес китәр, алтынның заты китмәс!..

...Тик бер гасыр үткән. Ишетелә
Келтер-келтер һаман барганы.
Теләр идем һәрбер чордашыма
Өч бүлекле шундый арбаны.

Башланмаган яңа гасыр әнә
Киләчәккә дәшеп торганда,
Йөзләп шагыйрь чыккан өч урынлы
Шул арбага яулык болгарга!

Ринат Мөхәммәдиев
(1948 елда туган)

АК КЫЯЛАР ТУРЫНДА ХЫЯЛ[1]

(повесть)

— Алсу нигә китә?.. Калдырыгыз Алсуны... Алсу, китмә! — дип кычкыра-кычкыра йөгерде Азат. Җигүле ат басу капкасыннан чыгып күздән югалганчы йөгерде. Башта ул Алсу утырган чананы менә-менә куып җитәм дип йөгерде. Бер як үрәчәгә тотынам дип үрелгәндә генә, инде үрәчәгә бармаклары кагылды дигәндә генә, йөзтүбән егылып калды. Ә пар ат җигелгән чана уйнаклап китеп барды. Торып тагын йөгерде, атка тагын якынлашты. Чана түрендә мамык шәлгә төренеп утырган Алсуны да аермачык күрде. Аның: «Әйдә, әйдә, Азат, йөгер...» — дигән сүзләрен дә ишетте. Чанадагылар исә, баш очларында сыек чыбык болгап, көлешә-көлешә, атны куаладылар: «На-а-а, юкса икенче кызыбызны алып калырга да күп сорамас бу Нурлы Алан егетләре. На-а-а... Ха-ха-ха...»

...Юлның урта бер җирендә тәгәрәшкән «ат алмалары» арасында ятып калды ул. Ә чана уйнаклый-уйнаклый китеп барды. Күз төпләрендә, кар бөртекләре эрүдәнме, кайнар тамчылар йөгереште. Шул авыр тамчылар аңар башын калкытырга, торырга ирек бирмәде. Маңгай астыннан гына әрнеп, гарьләнеп карады ул соңгы тапкыр. Алсу да нәкъ шул чакны, чана түрендәге урыныннан кымшанып, аңар нидер дәште, кул болгады төсле.

Азат берни ишетмәде, ишетүдән узган иде. Бөтен ачуын алырга теләп, ялан кулларына эләккән «ат алмалары» белән карлы юлны төя-төя шыңшыды. Озак ятты шулай. Олыларның үзен аңларга теләмәвенә әрнеде малай күңеле.

Җылы кар өстендә тәгәрәп тынычлана төшкәч кенә аякларына басты. Кесәдән йон бияләйләрен тартып чыгарды. Шап-шоп

---

[1] Кыскартып бирелә.

сугып, карга чумган өстен какты. Бер як җиң очы белән җәлт кенә борынын сөртеп алды. Күз төпләрен уды.

Кодаларның атын чыгарырга дип киереп ачылган капка әле ябылмаган иде. Ишегалдында әле һаман кодаларны озаталар. Тальянга кушылып, туган-тумача әйттерепме-әйттерә, биюен белә...

Кичен өйдә ирләрчә сөйләшү булып алды.

Әтисенең малларны ашатып-эчертеп ишегалдыннан керүе, мич каршындагы урындыкка килеп утыруы булды, уңаен көтеп кенә торган Азат шундук аның тезләренә менеп кунаклады.

— Мине дә өйләндер әле, әти!

Ата кеше ирексездән елмаеп җибәрде. Әмма үзен шундук кулга да алды. Уйчан кыяфәткә кереп, колак артын кашып куйган булды...

— Кемгә өйләнергә дисең инде?

— Алсуга, әти, Алсуга!

— Кайсы Алсу? Кем кызы соң ул?

— Исемнәрен белмим. Хуҗа абзыйларның өр-яңа кодасы инде... Миңлегали абый өйләнде бит, шуларның бәләкәй кызы инде...

— Ә-ә, шул буламыни инде Алсу... Соң, бик бәләкәй түгелме соң әле ул? Теге көнне капка келәсенә буе җитми азапланган кызны әйтәсеңме?..

— Һи-и, әти, үсә ул! — дип тынычландырырга ашыкты малай әтисен.— Туй көнне без Миңлегаяз белән тыңлап тордык. Хуҗа абзый менә болай җырлады: «Бәләкәй булсын, матур булсын — кочаклагач үсә ул». Ишегалдына ук ишетелде. Үзең дә шундаең бит.

Серләшүен ярым пышылдаудан башлаган Азат инде, дөньясын онытып, шар ярып сөйләргә тотынган иде. Авызы да ерылганнан-ерыла барды.

— Һи-и, әти,— дип җанланып китте ул кинәт,— әле мин сиңа Алсуның шәле, бияләйләре турында сөйләмәдем. Аларны күрсәң, исең китәр. Менә каз бәбкәсе сыман йоп-йомшак һәм күпереп тора. Шәл дисәң дә шәл ул, әти, менә шундый йомшак инде, гел мамык кына...

— Шәлен дә тотып карадыңмыни?

— Юк! Тотына, ди! Күзгә шулай йомшак күренә ул.— Малайның күзләрендә очкын кабынган иде, ул мавыгып сөйләвендә булды.— Аларның бә-ә-әк еракта, бә-ә-әк биек таулар ягында бер туганнары бар икән. Менә шул тауларда шундый дә-әү мөгезле кәҗәләр йөри икән... Шул кәҗәләрдә генә шундый йомшак мамык була икән... Шул туганнары кәҗә тотучылардан шундый кәҗә сатып алган. Шул кәҗәнең мамыгы бик күп була икән.

Беләсең килсә, әти, шул туганнары Алсуларга да шул кәҗә аучыларыннан берәр кәҗә алып җибәрербез дип язганнар...

Азат та үзсүзле малай булып чыкты. «Алсуны алырга кайчан барабыз?» — дип, һаман әтисен йөдәтте. Әти кеше, юк сәбәпне бар итеп, малай зарыгып көткән ул көнне чигерә килде. «Бу арада себереп тә тора, буран чыкмагае»,— диде. «Урманга карны тирән салган, бераз юл төшсен инде»,— диде.

Малай көтә бирде. Бердәнбер юанычы яңа көн туган саен Айсылу апасын күрү иде. Миңлегаяз янына кергән саен, аның: «Кем дип торам, кияү кергән икән бит. Үзебезнең кияү!» — дип, үз итеп каршылавы бигрәк тә ошый иде Азатка. «Үзебезнең кияү бит ул, мә, Азат!» — дип, Айсылу апасы аңар әллә ничә тапкыр инде кушуч тутырып чикләвеген тә бирде. Беркөн, Миңлегаяз югында, кулына күтәреп, аркасыннан да сөйде әле ул аны. Күкрәкләренә кысып сөйде, яратып сөйде. Әллә ничек кенә рәхәт тә, читен дә булып китте аңар шул чакны...

Оялудан, тизрәк төшәргә итенеп тартынган булды. Ә үзенә югыйсә Айсылу апасының йомшак җылылыгын тою бик тә рәхәт иде. Булмаска, Алсуның бертуган апасы ич ул.

Ниһаять, зарыгып көткән көн килеп җитте. Ул кичне әтисе күршеләрдән күтәренке күңел белән чыкты.

— Иртәгә иртүк юлга. Хуҗа абзыйның үзе белән барырга булдык,— диде ул, ишектән килеп керешкә.

— Үзе баргач, юлыгыз уңар, шәт... Әйбәт булган,— диде әнисе.— Бирсәләр генә ярар иде инде...

Берне кунып, икенче көнне төштән соң гына кайтып төште әтиләре. Аларны Азат авыл башына ук чыгып көтеп алды. Иптәшкә Миңлегаяз да бар иде. Юыртып килгән ат, алар янына килеп җиткәч, атлауга күчте. Азатның күзе чана түренә текәлгән. Тик анда, көмеш нурлар уйнатып торган мамык шәлгә төренеп Алсу утырырга тиешле чана башында, толыпка чумган Хуҗа абзый иде. Улының сораулы карашына җавап рәвешендә, әтисе коры гына әйтеп куйды.

— Өйдә булмады, чана шуарга чыгып киткән...

Хуҗа абзыйларның капка төбендә Миңлегаязның энесе — кайры тун һәм бүрек өстеннән җылы шәл белән уранган төпчекләре Вакыйф көтеп тора иде.

— Адат, Адат,— дип йөгереп килде ул аларның каршына,— безнең әтиләрнең кәҗә бәкәйләре качкан.

— Нинди кәҗә, нәрсә телеңә салынасың,— дип, коры гына кистереп куйды Миңлегаяз.

— Югары Сөн кодаларга, теге, әллә нәрсәкәй җирдән кайткан кәҗә бәкәе алырга барганнарые, Адатның атасы белән,— диде

Вакыйф, шуны да белмисезмени дигәндәй. Һәм, авыз-борынына уралган шәлен читкә тартып, йөзен ача төште.

— Нигә кәҗә алырга барсын алар. Монда чыгып телеңә салынып торасың,— дип, ачуланып дәште абыйсы...— Бирермен мин сиңа кәҗә баласы...

Вакыйф аңа типтермәде, бөтерчек сыман читкә тайпылды һәм йөгереп китте. Барыбер үзенекен итте — тыңларга теләүче булмаса да, дөреслекне ачып салды.

— Кәҗә булгач кәҗә! Ата кәҗә баласы. Урман буена кайтып җиткәч, чаналарыннан төшеп качкан. Куып караганнар, тоттырмаган. Кар тирән, ди...

Тагы ике көннән Югары Сөн кода үзе килеп җитте. Чана башындагы толып астында нидер кыймылдаганны күргәч, капка төбендә трай тибеп йөргән Миңлегаяз белән Азат сагаеп калдылар. Ул да түгел, толып астыннан әкрен генә «ми-и-и» дигән тавыш ишетелде. Югары Сөн кода чанадан төште һәм толыпка үрелде. Аның астында, керт-керт солы саламы чәйнәп, нәни генә бер җан иясе — кәҗә бәтие утыра иде. Аяклары киндерә белән ике як үрәчәгә бәйләнгән булуга да карамастан, чана янына ук килеп баскан Миңлегаяз белән Азатка ул бик кәефле булып күренде. Алмаш-тилмәш ул аларның күзләренә текәлеп торды. Исем бер дә китми, дип әйтүе булдымы, үзе һаман, сагыз чәйнәгәндәй, авыз эчендә салам уртлап тора.

Кәҗә бәтиенең маңгаеннан күренер-күренмәс кенә булып нәни мөгезләре төртеп тора. Ә мамыгы, әйтеп аңлатырлык кына түгел, аяз көндәге зәңгәр күк төсендә. Хәтфә кебек кабарып, күпереп тора, Алсуның шәле һәм нәни бияләйләре кебек. Кәҗә бәтие Азатка шундук ошады.

— Аякларын чишегез, ул сезгә,— диде Югары Сөн кода, атның аркалыгын төшереп торган җирдән.— Ләкин качыра күрмәгез, карагыз аны. Алсуның бүләге — икегезгә дә уртак булсын!

— Кемгә? — дип сорап куйды Азат, үзен дә белешмәстән. Ул бит Миңлегаязларга гына кода. Миңлегаяз белән Вакыйфка диюедер...

— Кемгә булсын, Миңлегаяз белән сиңа,— диде Югары Сөн кода, кабатлап.— Алсу бүләге! Качырасы булмагыз. Мондый кәҗә бәтиен җиде кат җир астына төшеп эзләсәгез дә таба алмассыз бүтән...

Чана башында утырган кәҗә бәтиенә беренче булып Азат якын килде. Бер кулындагы бияләйне салып, сак кына, бармак очлары белән генә, аның муеныннан сыпырып алмакчы булып үрелде. Кәҗә бәтиенә исә бу ошамады — дертләп китеп, кисәк кенә муенын читкә борды һәм бөтен гәүдәсе белән кагынып

куйды. «Тиясе булмагыз, кулыгыз юылганмы?» дип кисәткәндәй, усал итеп, маңгай аша сөзеп карады ул Азатка.

— Юк инде, малай, син безнеке хәзер,— дип янап куйды аңар моңарчы читтәрәк торган Миңлегаяз. Һәм ул кәҗә бәтиенең янына ук килеп, сөйләшә-таныша да башлады.— Үнә ул Азат абыең булыр. Мин — Миңлегаяз кодаң. Киртеп куй колагыңа: Гаяз түгел, Миңлегаяз! Менә миңем дә бар...

Кәҗә нәкъ шул чакны, ишеттем, аңладым дигәндәй, әкрен генә «ми-и-и» дип тавыш биреп алды. Малайларга бу кызык булып тоелды, үзара карашып, рәхәтләнеп бер көлешеп алдылар.

— Әллә башлы кәҗә инде, малай. Син әйткәннәрне гел аңлап торды бугай ул,— дип җанланып китте, үзенең куанычы белән уртаклашырга ашыкты Азат.— Билләһи дим, күзенә карап тордым. Эх тә итми тыңлады, син сөйләгәндә.

— Башлы булмый... Ул бит сиңа тегенди-мондый гына түгел, әллә каян, биек таулар ягыннан кайткан кәҗә. Пләмәнни, бик беләсең килсә!

Шулай ерактан килдеңмени дип, гаҗәпләнеп, шаккатып күзәтте аны Азат.

— Вәт, малай,— дип, үзенең соклануын яшерә алмыйча сузып куйды ул.— Кәҗә дисәң дә кәҗә, ичмасам. Бу инде сиңа безнең авылдагы бакча караклары, ристаннар гына түгел, иеме, Миңлегаяз... Исеме бармы икән?..

Бертын ни эшләргә белми аптырап торган Миңлегаяз, Азатны үртәргә булып, үзенчә кызык тапты. Кинәт кенә чанага сузылып ятты да, кәҗә бәтиенә текәлеп, бар көченә дип әйтерлек кычкырып сөйләшә башлады.

— Кәҗә, ә кәҗә... Синең исемең ничек? — Үзе сорау бирә, үзе, үпкәләмиме дигәндәй, борылып-борылып, Азатка күз ташлап ала. Үпкәләргә уйламады да Азат. Аңа ни, кызык кына ич. Миңлегаяз исә тагы да җанланыбрак теленә салына башлады.— Ник әйтмисең, әйт инде, кәҗә! Әнә бит Азат абыең сорый. Әй, юк, Азат абыең түгел, Азат җизнәң!

Гаҗәпсенеп карап торган кәҗә бәтие шунда аваз салмасынмы:

— Ми-и-әй... Ми-и-әй...

Миңлегаяз чанадан сикереп үк торды. Азат белән бер-берсенә төртешә-төртешә сикергәли башлады алар. Куанычларына чик-чама юк иде.

— Исемен белә, исеме бар...

— Башлы кәҗә дип әйттем бит...

— Вәт, малай, исемен әйтә бит. «Ми-әй», ди.

— Кабатлап та әйтте, «Ми-әй» түгел, «Микәй», диде бугай.

Миңлегаяз шатлыгыннан бер-ике мәртәбә бүреген күккә чөеп алды һәм ишегалдын әйләнеп сикергәли башлады. Йөгереп кенә өйгә дә хәбәр салып чыкты.

— Кәҗәнең исеме бар, үзе әйтте. «Микәй» диде. Микәй...

Миңлегаяз белән Азатның шатлыгын уртаклашырга өй ишегеннән аннан-моннан гына киенгән бәләкәй Вакыйф килеп чыкты. Авыз тутырып, нидер чәйни иде үзе. Абыйлары янына килгәч, кесәсеннән берәр уч бавырсак чыгарып, Миңлегаяз белән Азатны да сыйлады.

— Югары Сөн кодагый җибәргән,— диде ул, авыз тутырып чәйнәвеннән туктамыйча.— Сезгә — кәҗә, миңа — төш. (...) Чишмәгез, тагы кача. Кәҗә ич, ристан ич ул.

Миңлегаяз аңар кулын гына селтәде.

— Синнән сорамыйлар. Әнә лапас артына барып кил дә артың катканчы керен йөгер өйгә.

— Адатның атасы белән беднең әтидән качкан кәҗә ул, бик беләсегед килсә...

Вакыйфның әйтеп бетерүе булды, Миңлегаязның култык астыннан кәҗә бәтие сикереп чыгып та чапты.

— Капканы ябыгыд, капканы бикләп куегыд тидрәк,— дип кычкырды Вакыйф көтелмәгән бу хәлдән югалып калган абыйларына.

Азат, шап итеп, капканы бастырык белән бикләп тә куйды...

Бәйдән ычкынган кәҗә бәтие ишегалдының бер почмагыннан икенчесенә ук кебек атылып чабулап йөрүен дәвам итте. Өчәүләшеп үзен тотарга дип йөгергән малайларны бар дип тә белмәде, араларыннан выжт кына үтә дә кире якка торып чаба иде. Бер почмакка кысрыклап, инде тоттылар дигәндә генә, ул тагын Миңлегаязның бот арасыннан чыгып шылырга өлгерде. Ишегалдын ду китереп тик чабулавын белде. Артыннан чаба торгач, малайлар хәлдән тайды, карга чумып беттеләр. Сулуларына капты. Итек эчләренә кар тулды, бияләйләрен югалттылар. Вакыйфның бер галошы төшеп калган булып чыкты, койма читенә өйгән көрттән ул шуны эзләп маташа иде.

Малайларның тынып калуын күреп, Микәй дә тукталды. Ишегалдының урта бер җирендә җиңүче сыман тик басып тора. Якягына карангалап байтак кына шулай торды да, кинәттән ук кебек атылып, сөяп куйган колгалар өстеннән лапас түбәсенә менеп тә китте. Нәрсә-нәрсә, әмма мондый елгырлыкны аңардан берәү дә көтмәгән иде. Лапас түбәсе кадәр лапас түбәсенә шулай җиңел генә менү юлы барлыгын башларына да китереп карамаган булыр иде бу тамашаны үз күзләре белән күреп торган малайлар...

(...) Кәҗә бәтие Миңлегаязларның утын лапасындагы җылы почмакта яши башлады. Инде урынлы-урынсызга качам дип куркытмаса да, барыбер кулга ияләшергә ашыкмады. Ишегалдына чыгаруга, дөньясын онытып чабулап йөри дә аннан ни эшләргә белми бераз тик басып тора. Һәм әллә кай арада гына

бер карарга килеп, теге вакыттагы тәвәккәллеге белән, сөяп куелган колгаларга таянып, бер сикерүдә лапас түбәсенә менеп җитә. Иязәнгән урынына — кыекның нәкъ очына ук барып баса. Күкрәкләрен киерә төшеп, башын турайта һәм күңеле булганчы урманга таба карап тора.

Аны инде хәзер һичкем борчымый, куаламый аннан. Урамнан узучылар күрсә, гаҗәпсенеп бертын карап торалар да, башларын болгап, үз юлларыннан китеп баралар. Белсәң иде — кая карый? Нәрсә көтә? Кемне юксына, кемне эзли икән ул шулай?..

...Кинәт әллә нидән генә аякларына көч, гәүдәсенә дәрт, нәни мөгезләренә гайрәт килә башлавын тойды ул. Бер урында тик кенә басып тора алмыйча, алгы аяклары белән түбәдәге карны тырнарга керешә. Күзләре очкынланды, иңбашларына пар канатлар чыккандай хис итте ул кинәт үзен. Менә хәзер шушы лапас түбәсеннән кушаяклап этенеп китсә, аның иңбашында канатлар җилпенә башлар, һәм, күз ачып йомганчы, ул урман аръягындагы теге ак юлларга барып җитәр. Шулай итәчәк тә — ике уйлап тормый алга, югарыга томырылды Микәй.

Әмма иңбашларында җилпенергә тиеш булган канатлар хыянәт итте, тыңламады. Ак болытларга күтәреләсе урында, тирән көртә төшеп чумды Микәй. Ләкин кимсенү, өметсезләнү турындагы уй аның мөгез очларына булса да килеп карамады. Ничек итеп көрттән чыгуын һәм бакчалар аша бата-чума ничек басуга чыгып чапканын хәтта үзе дә абайламый калды. Күкрәгенә тулган дәрт, аякларын алгысытып торган көч, мөгезләреннән чәчрәп торган гайрәт канатлардан болайрак ашкындырды аны...

Дөньясын онытып шулай алга омтылганда, кинәт тояк астындагы карның шуыша башлавын сизде ул. Ничек дип юрарга белмәде ул моны, ак кар булып ак кар аңа шулай хыянәт итәрме?.. Читкә сикерергә омтылды, өлгермәде... Соң иде инде... Үзе артыннан ишелгән кар тавына иярәп түбәнгә — ак упкынга тәгәрәвен абайлады Микәй...

Озакка сузылгандырмы ул шау, Микәй абайламады анысын. Ниһаять, бары да тынды, туктап калды. Үзенең, карга күмелгән хәлдә, текә яр астында ятуын аңлады ул. Тояк астында да кар, мөгезләре очында да кар. Бөтен хыяллары белән бергә ак кар астында калган. Кузгалырлык, кымшанырлык кына түгел. Арыган гәүдәсе, кызышкан аяклары, оеп, рәхәт бер талгынлыкка күмелә барган төсле булды. Күзләре дә йомылырга итте.

Шунда аның бөтен тәнен яшен ташы телеп үткәндәй булды. Тукта, ул шулай хәлсезләнеп кар астында оеп ятса, нәрсә була соң әле бу?.. Озаккамы ул монда?.. Ә гел бөтенләйгә булса?.. Шушы кар астындамы! Ә урман аръягындагы ак хыял булып үзенә тартып торган ак юллар... Ак кыялар иле... Әнисе...

Торырга дигәч торырга! Кайнар агым акты да акты, иңнәрендә чын-чынлап канат талпынгандай тоелды. Мөгез очларыннан гайрәт ташкыны бәреп чыкты. Бу юлы инде аны һични тотып тора алмаячак... Һәм шулай булып чыкты да — кар тавы аның алдында баш иярга мәҗбүр булды...

Көн кичкә авышып бара иде инде. Җылы нурлары белән озата килгән, җемелдәшкән кар бөртекләре аша аның күзләренә өмет өстәп торган, гайрәт биргән кояш та алсуланып баерга җыена иде. Шулай да кирегә юл юк — анда салкын инеш, анда текә яр һәм анда ялгызлык. Ә алда — алсу шәфәкъ нурларында коенган ап-ак чиксезлек. Шул ак киңлек янә аның күңелендәге ак хыялларны яңартып җибәрде һәм, алгысытып, үзе артыннан әйдәде...

Ниһаять, күз алдында ак шәүлә төсле генә булып урман төсмерләнә башлады. Кояш инде офык читендә эленеп торган ак болытларга кереп күмелә язган. Караңгы төшә баруга да карамастан, аклык кимемәде...

Нишләргә?.. Хыялындагы ак юлларын эзләп, урман эченә кереп китәргәме?.. Әйләнә-тирәне томалап алган дөм караңгылык, җил һәм агачлар шавы күңелгә шом өстәп тора... Урманга керми генә ак юлларны ничек табар соң ул? Күпме ара үтелгән, күпме газап... Хыялындагы ак юллардан хәзер аны бары тик шушы урман гына аерып тора. Тәвәккәлләргәме әллә?.. Тәвәккәлләргә! дип боерды аңа җаны. Көч табылды — урманга таба ыргылды Микәй. Әмма күп китәргә өлгермәде, колакларын сагайтып туктап калды.

— У-у-у...

...Ул-бу ишетелмәгән төсле үзе. Шулай да аның артындагы ак караңгылык эчендә әледән-әле нәрсәдер ялтырап киткән сыман тоела. Бу нәрсә?.. Ике утлы күмер кисәге диярсең — аермачык күренеп-күренеп ала. Әллә курыкканга гына куш күренәме?

Башта мөгез очлары, аннан берьюлы бөтен тәне чымырдап куйды кәҗә бәтиенең. Аяклары тыңламас булып туктап калды. Шунда гына үзе артыннан куа килгән әлеге шәүләдән качып котылу мөмкинлеге чамалы булуны аңлап алды. Башка чара калмаган иде. Ни язса, шул булыр дигәндәй, бер пар утлы күмергә ияреп килгән шәүләгә каршы борылып басты. Аякларын терәп куйды, башын селкеп, нәни мөгезләрен барлап алды. Күләгә исә, тагы да якынлаша төшкәч, өч-дүрт сикерем ара калдырып туктап калды. Әллә аны да сагаю һәм шом туктатты, табышының инде качып котылыр җае булмауны аңлап үзенә күрә ләззәтләнүе идеме?.. Соңгы сикереш ясар алдыннан, бераз гайрәт җыеп, теш кайравы гына булдымы?..

— У-у-у...

Микәйгә аның бу авазы өстәмә көч бирде. Ерткычның шөбһәгә калуы һәм урманга ярдәм сорап мөрәҗәгать итүе дип аң-

лады ул моны үзенчә. Аның каршында басып торган Микәй соры ерткыч өчен, бәлки, тагы да куркынычрак җанвар булып тоелгандыр. Бәлки, Микәйнең күзләре дә кышкы урман буендагы бу караңгылыкта, дошман күңеленә шом салып, куркыныч елтыраша торганнардыр...

Әлеге киеренкелеккә күнегә төшкән Микәй як-ягына да күз салырга өлгерде. Үзеннән ун-унбиш сикерем ераклыгында биек итеп өелгән печән кибәне торуын күреп алды ул.

Байтак озынга сузыла башлаган тынлыкны теге соры нәрсә бүлде. Ул аякларына басты. Шуышып дип әйтерлек саклык белән Микәйгә якыная башлады. Күзләре янә утлы күмер сыман ялтырарга керештеләр. Мәкерле рәвештә шуышып килүче җанвар аермачык күренә башлады. Үзенә нинди куркыныч янавын кәҗә бәтие шунда гына аңлады булса кирәк. Икеләнер ара калмаган иде, ул кинәт кенә кырт борылды да печән кибәненә таба торып чапты. Дәү ерткыч аннан мондый елгырлык көтмәгән булып чыкты. Хәтта, үзенә ташланудан шүрләпме, сискәнеп, бер мизгелгә туктап та калды бугай. Кәҗә бәтиенең качарга җыенуын аңлагач та артык исе китмәде. Мондый төндә, мондый урында аннан берәүнең дә котыла алганы юк иде әлегә. Кая китсен, ерак китә алмас...

Кибән янына салган кар, ни хикмәттер, каты булып чыкты — аяклары батмады Микәйнең. Әллә ак төснең аны шулай үз итүе булды — ак кар аны иңнәренә алды. Томырылып килгән җирдән сикерүе булды Микәйнең, бурап салган кар өстеннән тырманатырмана печән кибәненең түбәсенә менеп тә басты. Артыннан ишелеп калган кар өемнәреннән ул елгыррак булып чыкты.

Куа килгән соры бүре, киресенчә, бата-чума башлады. Әйтерсең лә аның авыр гәүдәсен ак кар күтәрергә теләми иде, баскан саен шыгырдап торган кар, убылып-убылып, түбән төшеп китә. Тәпиләрен никадәр иплерәк һәм җайлырак итеп басарга тырышмасын, ак кар соры шәүләне барыбер үз итмәде. Аяк терәп этенергә һәм кибән өстенә сикерергә дип күпме генә талпынмасын, бүре кибән тирәсенә бурап-бурап салган көрттән аерыла алмады. Дәү тәпиләренә басып сикерергә талпынуы була, ул янә түше белән тирән кар эченә кереп чума иде...

Йөреп-йөреп тә рәт чыгара алмагач, печән кибәне итәгенә чүгәләп, тешләрен кайрады, иреннәрен ялап, улап та алды. Тагын торып хәйлә эзләде, берни майтара алмый, яңадан барып чүкте — таңга кадәр печән өстендә утырып чыккан ялгыз кәҗә бәтиен күзләп авыз суын корытты. Яктырып бетте дигәндә генә, артына борылып карый-карый, башын түбән иеп китеп барды соры ерткыч. Микәй шунда гына иркен сулыш алды һәм, төн буена сузылган киеренкелектән бушанып, печән өстенә сузылып ятты. Ирексездән күзләре йомылды. Изрәп йокыга талды. Иртән-

ге салкынны да, басу ягыннан исеп торган ачы җилне дә тоймас хәлгә җиткән иде инде.

Татлының да татлысы булган төш керде аңа.

Имеш, таң вакыты. Зур булмаган кәҗә көтүе биек-биек таулар, дәү-дәү ташлар арасында йөри икән. Кәҗәләр арасында аның әнкәсе дә бар... Ул кыя читендәге олы бер таш өстенә менеп баскан да ерак-еракларга, офык читендәге мәһабәт ак тауларга карап тора. Шунда алгы аяклары белән ташны тырнап торган әниләре бәтиләрен үзе янына чакырды. Микәй, энесе белән икәү, дөньяларын онытып, таштан ташка сикереп, куышлы уйнап йөри иде. Чакырганны күреп, алар шундук, уеннарын ташлап, әнкәләре янына томырылып килделәр. Һәм, әнкәләренә охшарга тырышып, аның белән янәшәгә, кыя читенә килеп бастылар.

— Мә-ә-ә,— дип дәште әнкәләре, тыныч кына.— Каршыдагы үзәнлек аръягындагы ак калкулыкны күрәсезме?..

— Ми-ә-ә,— дип, бер-берсен бүлдереп җавап кайтарды бәтиләр.— Күрәбез, күрәбез...

— Шул ак калкулыкның да аргы ягында ап-ак болытларга ашкан ак кыялар бар...

— Ә ул ап-ак болытларга җиткән ак кыяларда ни бар?

— Бәхет, бәтиләрем. Бәхет...

— Бәхет ул ни була, әнкәбез?..

— Ул — тынычлык һәм ирек дигән сүз... Әнә ул ак кыяларда сезнең бәхеткә һичкем кул сузмас, бәтиләрем. Шунда гына сез рәхәтләнеп иректә йөри алырсыз.

— Монда да бик тыныч, иркен ич, әнкәбез...

— Тыныч иде...

— Нигә «иде»?..

— Кеше эзләре, бәтиләрем!.. Кеше эзләре күренә бу кыяда.

— Ә кеше ул нинди була?

— Кешеме? — дип, ничек әйтергә белми уйга калып торды әнкәләре.

— Әйе, әйе, кеше... Ул нинди була, әйт инде, әйт, әнкәбез?..— дип тынгысызланды алар.

— Ул ике аяклы, бәтиләрем. Һәм мең мәкергә ия!.. Аюбүредән качып була, ә кешедән качу кыен, бәтиләрем.

— Әнкәбез, әнкәбез... Ә ул ап-ак болытларга ашкан ак кыяларда юкмы кеше?..

...Урман аръягындагы ак юллар турындагы уйлар аны урыныннан кузгатты. Инде үзен саклап чыккан кибән өстеннән сикерергә әзер иде. Әмма бая соры ерткыч китеп барган юнәлештән нииндидер авазлар ишетелү аны тыелырга мәҗбүр итте. Кибән очында чокыраеп төшкән урынына кереп яшеренергә ашыкты ул.

Тавышлар якынайды. Микәйгә таныш авазлар иде бу. Ул алардан курыкмады.

— Үнә, үнә, кибән өстендә. Колаклары белән мөгезе күренеп тора,— дип, чаңгыда килүчеләрнең берсе таяклары белән этенә-этенә алга чыкты. Азат иде бу. Аның артыннан җан-фәрман Миңлегаяз куалый. Ә өченчесе,— аркасына мылтык асканы, Азатның әтисе. Ул чана тартып килә.

— Мин беренче күрдем, мин беренче,— дип тантана итте Азат.

— Теге бүре Микәйне сагалап торган,— дип нәтиҗә ясады Миңлегаяз.

— Һавага атма, дидем, әти... Ул бит Микәйне кызганмас иде,— дип, Азат әтисен шелтәләргә кереште, ләкин, Миңлегаязның үзен узып барганын күргәч, янә торып чапты.

Кибән төбен өчесе өч яктан урап алган танышлары янына Микәй үз иреге белән төште. Малайларның шатлыклары эчләренә сыймады. Микәйне инде күптән бүре карынындадыр дип хафаланган иде ич алар. Кәҗә бәтиен исән күрүдән икесенең дә күзләре дымланды, бугазлары тирәсендә нәни төерләр уйнап алды.

Кулларын як-якка ташлап, иртәнге урман-кырларны яңгыратып, Азат шатлыгыннан бар көченә кычкырып җибәрде.

— Микәй исән! Ур-ра, Ми-кәй и-сә-ән...

...Әкияттәге батыр сыман, ай үсәсен көн үсте, ел үсәсен ай үсте Микәй. Аяк торыклары нык кына калкынды, күкрәге күзгә күренеп киңәя төште. Аеруча сокландырганы аның мөгезләре иде.

Буынтыклы-буынтыклы булып нык тамырдан үсеп чыккан юан кара мөгезләре... Әле кайчан гына үзенә мөгез сузган дәү кәҗәләр дә хәзер, аның яныннан үткәндә, койрыкларын кыса төшеп, көяз генә карангалап узды...

Ул, Азатка ияреп, алар ишегалдына кунакка йөрергә дә күнекте. Тора-бара Миңлегаяз белән Азат Микәйне үзләре белән чана шуган җиргә ияртеп төшә башладылар. Малайлардан бигрәк, кәҗә бәтиенең үзенә ошады бу.

Тау шуарга йөргән малайларның телләрендә хәзер гел Микәй исеме иде. Көннәрдән бер көнне түбән очтан Фаяз да үзенең овчарка токымы дип йөргән Дүрткүзен ияртеп төште. Шундый токымлы этен күрсәтеп, аның да үзенчә мактанасы килгәндер инде.

Дүрткүз анда кәҗә тәкәсе йөрүен генә ошатмады. Чанадагы малайлар артыннан дөньясын онытып кушаяклап чабып төшкән кәҗәне күргәч, эт аяк астындагы карны тырный-тырный өрергә тотынды. Ә Микәйнең исә анда гаме юк — малайлардан алда ук тау өстенә менеп баса да шунда аларны сабыр гына көтеп тора. Тегеләрнең шау-гөр килеп, этешеп-төртешеп шуып төшеп китүе

була, алар белән куыша-куыша уйнаклап, Микәй дә түбәнгә томырыла.

Һәркем шулай үзенчә кызык табып йөри иде. Тау итәгендә мәтәлешеп яткан малайларны сабыр гына күзәтеп тора иде кәҗә тәкәсе, байтактан инде бәйләнергә җай эзләп йөргән Дүрткүз, кинәт котырынып өрә-өрә, аңа ташланды.

— Ул бит овчарка, ботарлап ташлый хәзер кәҗәне,— дип кычкырыша башлады малайлар.

— Тый этеңне, бетерә бит кәҗәне! — диделәр Фаязга.

— Дүрткүз... Дүрткүз! — дип кычкырды Фаяз.

Хуҗасын ишетүдән узып, эт өрүендә булды. Гәүдәгә дә Микәйдән шактый калку күренә иде ул. Ә кәҗә бәтие исә ни эшләргә дә белми тик боргалана тау итәгендә — койрыгыннан эләктерергә чамалап тирәсендә бөтерелгән Дүрткүзгә таба башы белән борыла да сер бирмичә сагаеп карап тора. Малайлардан берәве дә алар янына якын килергә базмады, көтмәгәндә килеп чыккан гаугадан югалып калганнар иде...

Эт, аның саен котыра биреп, хәзер үк ботарлап атарга теләгәндәй, Микәйнең өстенә үк ыргыла башлады. Үзеннән курыкмаска иткән бу кәҗә бәтиенең шулай бер урында таптанып торуы чыгырыннан чыгаргандыр, ахрысы. Эт якынрак килгән саен, Микәй сагая, бер йодрыкка җыелган пружина сыман кысыла барды.

Һәм шунда малайларны шаккатырган бер хәл булып алды. Тешләрен зәһәрле ыржайтып котырынган эт бәтинең арт санынннан каптырып алды дигәндә генә, Микәй күз иярмәс тизлек белән кинәт башын болгап алды да, мөгезләренә эләктереп, этне үзе аша икенче якка тотып ыргытты. Кар өстенә аркасы белән барып төшкән Дүрткүз, чиный-чиный, артына да борылып карамыйча, авылга таба торып чапты. Чаналарын онытып күзәтеп торган малайлар үз күзләренә үзләре ышанмадылар...

— Малай, күрдеңме, башаркан ыргытты бит, име...

— Ие булмый, мамык урынына очыртты бит...

— Вәт кәҗә дисәң дә кәҗә, малай!

— Овчаркасын гел бетереп атты!

— Ниткән овчарка токымы булсын ул, кәҗәдән шулай мыскыл иттергәнне...

— Бетерү генәме соң, урамга чыгарлыгын калдырмады.

Нишләргә белми бер урында басып торган Фаяз гына үзенең мактанычы булган овчарка токымлы Дүрткүзен кызганды. Ул бертын мыштым гына борынын тарткалап торды да, бу гарьлеккә артык түзә алмыйча, елый-елый, тыкрыкларыннан менеп йөгерде...

Мәктәптән кайтучы малайлар хәзер, Микәйне күрер өчен генә, алар урамыннан урап уза иде. Койма читенә өелгән бүрәнәләргә

менеп күзәтәләр, капка-койма ярыкларыннан карыйлар. Кәҗә бәтиенең лапас түбәсендә чагына туры килсәләр, гел телсез калалар, бер-беренә төртешеп пышылдашырга тотыналар.

— Үнә, үнә, күрәсеңме?..

— Кәҗә түгелдер бу, малай. Күрәле син аны, канатлы атмыни!..

Күрше-тирә малайлар мәктәптән кайтып аннан-моннан капкалап алырга өлгерәләрме-юкмы, ничектер җаен чыгарып, Хуҗа абзыйларга таба элдертү ягын карыйлар. Миңлегаязның, кәҗә бәтиен ияртеп, урамга чыгуы була — китә уен, китә тантана. Микәйнең үзенә дә ошый иде алар белән куышып уйнау. Торабара кәҗә бәтиенең холкын, бөтен сәер гадәтләрен белеп бетерде малайлар...

Көннәрдән бер көнне, мәктәптән кайткач та, Миңлегаяз атылабәрелә Азатларга йөгереп керде.

— Микәй сездәме? Микәйне күрмәдеңме? — дип сорады ул кергән уңаена.

— Әле генә лапас түбәгездә кадаклап куелгандай басып торае...

— Анда юк. Киртә аша чыгып качкан.

— Нигә качсын, урамдадыр,— диде Азат, дустын тынычландырырга ашыгып. Ләкин үзенең дә күңеленә шом керде. Чынлап торып качкан булса?.. Хәзер кыш көне түгел, эзеннән барып табармын димә. Боз кузгалып, сулар ташыган чак...

Икәүләшеп урамга йөгереп чыктылар. Кая барырга белми икеләнеп торгач, иң элек пожар өе һәм кибет тирәсеннән урап килергә булдылар.

Иртә язда һәм кышларын ир-атның җыелып гәпләшә торган урыны — пожар өе янында, ни хикмәттер, кеше юк дип әйтерлек иде бүген. Сугышта бер кулын калдырып кайткан Гаяз абый гына ат җигеп азаплана.

Тагы бераз киткәч, юлда очрашып нидер сөйләшеп торган ике әбигә игътибар итте алар. Дөньяларын онытып, рәхәтләнеп сөйләшкән сүзләре, тыңламыйм дисәң дә, әллә каян ишетелеп, колакка бәреп тора.

— Теге нәмәрсә кайткан, шуңа дип менгәнием әле, Маһитап абыстай.

— Минем дә шунда таба теркелдәвем, соңгарак калып ишеткәнием шул, соңгарак калып, җитсә генә ярар иде кәнә.

— Җитәр, җитәр, Маһитап абыстай, икешәр чешә генә бирәләр — әҗәл дарулары иттеләр инде шул, билләһи, шайтан суын...

— Әҗәл даруы булмый ни, безнең ише карт-корының утынын да шул кисә, шул турап та өя, бакчасын да сукалый, койманы,

каралты-кураны рәтлим дисәң дә, шул чукынган нәмәрсәкәй кирәк бит.

— Әйтмә дә инде, Маһитап абыстай, әйтмә дә... Чистый бар эшкә дә ярый торган булып китте шул җен каргаган нәрсә. Менә безнеке, сабанга төшкәнче, кыш чыккан тәкәне чалам, ди. Сугымы да шунсыз булмый хәзер. Кодалар да киләсе барые... Икене генә бирәләр шул. Ике чешә белән нишләмәк кирәк, кеше алдында оятка калуың бар...

— Ярар, кем, Галимә, ие... җүгерим әле мин. Мин сузылып менеп җиткәнче бетеп куя күрмәсен.

— Бар, бар, Маһитап абыстай, сүзнең ни, аның бетәсе җук, чиратка баса тор...

Кибет урамына борылгач та, хәйран калды алар. Кибет каршында сирәк була торган җанлылык иде. Берсе керә, берсе чыга: кулларына сумка-сетка ише әйбер тоткан авылдашлар арлы-бирле йөгерешә. Кибетнең ишекләре як-якка киереп ачылган, урамга аннан җылы пар бөркелеп тора. Сату-алу гөрләп барган урыннарда гына була торган ыгы-зыгы һәм авазлар яңгырап тора. Шаяру һәм уен-көлке арасында кемнәрнеңдер сукрану сүзләре дә ишетелеп куя.

— Кем чыгарган ул закунны, нигә ике генә шешә? — диде калын тавышлы ир кеше.

— Бүчкәсенә төшерсәң дә туймассыз сез.

Җавап бирүченең кибетче Миңнурый апа булуын әллә каян таныды малайлар.

Шунда хатын-кыз затыннан икенче берәүнең тавышы яңгырады:

— Чиратсыз бирмә, Алланың кашка тәкәсе түгелдер ләбаса...

— Кырга тирес чыгарасы бар, күзеңә тилчә чыкмагандыр бит, кем апа... Әнә трактор эшләп тора,— дип җавап кайтарды чиратсыз керүче. Монысы Аю Гаяны тавышы иде, әле ике ел элек унны бетергән егет. Чаңгы буенча район чемпионы. Узган елны Сабан туенда батыр асты калды...

Малайлар үзләренең кибет ишеге төбенә үк килеп җиткәнлекләрен дә абайламый калдылар. Ишек төбеннән сузылып киткән чиратның очында уңайсызланып кына басып торган Миңлегали абыйсын күргәч, Миңлегаяз сискәнеп үк куйды. Нигә икәнен ул үзе дә аңламагандыр, мөгаен. Азатның җиңеннән тартып, тизрәк китәргә ашыкты. Микәйне эзләргә чыгуларын оныта язганнар ич...

Шулай да кибет ишегеннән чыккан тагы бер яңалык колакларын торгызды аларның.

— Аракысын алалар, ә шешәсен тапшыру дигәндә — юк,— дип зарлана иде кибетче.

— Тапшырмый нишләтәсең, ул буш шешә кемгә кирәк?..— дип, ыгы-зыгы килде берничә кеше.

— Үзем дә аңламыйм, гомер булмаган хәл. Кая куялардыр буш шешәне, әллә шешә ашаучылар килеп чыккан?..

Миңлегаязның карашы янә абыйсына юнәлде — ул тәмам коелып төшкән, үз якасы эченә яртылаш кереп чумган иде инде. Абыйсын шундый хәлдә күрмәс өчен генә булса да китәргә ашыкты ул...

Үзенең эчкерсез көләчлеге һәм яшьлеге белән өйне балкытып йөргән Айсылу җиңгәсенең йөзендә Миңлегаяз шул кичне беренче тапкыр борчылу чаткылары күрде. Кичке ашка алар Миңлегали абыйларыннан башка гына утырдылар, җиңгәсе белән янәшәдәге урын буш торды. Ә Миңлегали мич артындагы итек киптерә торган сәке өстенә яткан да ыңгырашуын белә.

— Ярар, исегез киткән икән, бүтән эчмәс,— дип кенә куйды Хуҗа абзый.

Айсылу дәшмәде. Миңлегали ягына карангалап ала да тик башын иеп утыруын белә. Әминә апа башына чөйгән яулык чите белән, башкаларга күрсәтми генә, күз төпләрен сөртеп-сөртеп ала иде.

— Әрмиягә киткәндә, салып биргән рүмкәсен дә, иптәшләреннән яшереп, өстәл читенә куеп киткән бала бит ул. Кайткач та күпме гомер иснәп карамаган бала,— дип сукранды үзалдына.— Кемнең генә күзләре тиде икән, и-и бала...

— Дөньяның асты өскә килмәгәндер ләбаса. Җитәр, балавыз сыкмагыз! — дип, сүзгә тагын Хуҗа абзый кушылды. Ул үзе дә борчыла иде, әлбәттә. Шулай да сүзне, үзенчә шаяртмакчы булып, бүтәнгә борырга итте: — Анда әнә шешә ашаучылар күренә башлаган, ди, авылда...

Урынсыз шаяру итеп кенә кабул иттеләр бу яңалыкны. Берәү дә дәшмәде, Миңлегаяз гына, кая куялар икән ул шешәне дип, үзалдына уйлап куйды.

Утлар сүнде. Өй тынып калды. Миңлегаязның күзләренә йокы кермәде. Бүген көндез кибет янында күргәннәре бер-бер артлы хәтерендә яңарып торды. Урамда сөйләшеп торган ике апаның һәр сүзе күңеленнән уазды. Кибет ишегеннән бүселеп чыккан чират... Шул чиратның очында кыяр-кыймас басып торган Миңлегали абыйсы...

— Миңлегали, җаным, тор,— дип пышылдаганы ишетелде аның мич артыннан.— Әйдә, урыныңа барып ят... Итекләреңне сал, һич булмаса...

Абыйсы нидер мыгырданды төсле, әмма кеше аңларлык сүз әйтә алмады. Сәке тактасын шыгырдатып боргаланды да янә гырылдый башлады.

— Тор инде, Миңлегали...— дип, тагы да ягымлырак һәм акрынрак итеп нидәрдер пышылдады Айсылу җиңгәсе.

Миңлегаяз аны кызганып куйды.

— Миңлегали, дим, куркам, дим...

Бу юлы инде елар-еламас эндәште Айсылу җиңгәсе. Ә абыйсы аны ишетмәде. Ул, өметен өзеп, кире өй түрендәге үз чаршауларына таба узды. Миңлегаязга аның хушбуй исләре бөркеп торган эчке күлмәк җилләре кагылып үтте. Шунда, кулын суза төшеп кенә, җиңгәсенең иңбашларына таралган озын чәчләренә кагыласы, «Курыкма, җиңги, мин йокламыйм, курыкма!» дип әйтәсе килде Миңлегаязның. Кыймады...

Нурлы Аланда ул көнне гадәттәгедән күпкә иртәрәк уяндылар. Лапас капкалары шыгырдап ачылуга, «нигә болай иртә?..» дигән сыман кычкырыша-кычкырыша, ишегалларына беренче булып сарыклар йөгерешеп чыкты. Йокылы күзләрен челт-мелт йомып, кәҗәләр кузгалды. Сыер мөгрәп алды. Күрше ишегалларында сыер савып утырган апалар һәм җиңгиләр, тынгысызланган сөтлебикәләрен тынычландырырга теләп, әледәнәле билләрен турайтты. Түгелмәсен дигәндәй, сөт тулы чиләкләрен сак кына ак алъяпкычларына таба елыштырып куйдылар. Җылы сөт исен сизенгән яшь бозаулар сузып-сузып тавыш бирде. Бүгенгә җитәр дигәндәй, соңгы тапкыр әтәчләр хәбәрләшеп алды. Кетәклектән, пырхылдашып, берәм-берәм тавыклар коелды. Каз-үрдәк капка астыннан урамга чыгу җаен эзләде. Йокылы күзләрен уа-уа, ишегалды һәм капка тирәләрендә сыек чыбык тоткан малайлар кайнашты... Көтү чыккан беренче көн иртәсе шулай башланды...

Микәйнең шултикле мал-туарның бергә туплануын әлегәчә күргәне юк иде. Шуңа гаҗәпләнеп торган арада, урамнардан һаман саен төркем-төркем килә торган дәү мөгезле һәм бөдрә йонлылар аны төрле яктан уратып та алган. Кысынкылыкта калу билгеле ошамады аңа, әмма ул бөҗрадан чыгу да җиңел түгел иде. Атлап китү түгел, урыныңнан кымшанырга да өлгермисең, «бә-ә-әй, күзең чыкканмы әллә-ә-ә, кая төртенәсең» дигәндәй, бөдрә йонлылардан йә тегесе, йә монысы дөнья бетереп кычкырырга керешә.

Көтү кузгалып авыл башына җиткәч кенә, төркемнең бер читенә килеп чыгу җаен тапты Микәй. Һәм шунда ук үзенең әйләнә-тирәсендә, җанга рәхәт биреп, тамак төпләрен кытыклап торган җылы төскә, ягымлы төскә төренгән киңлекне күреп хәйран калды. Бу кадәр мул, җылы һәм ягымлы төсне әле аның күргәне юк иде. Күрү генә түгел, ул хакта хыялланганы да булмады. Аны алгысытып торган якты, матур дөнья төшләренә гел ак төстә булып кына керә иде бит әлегәчә. Тоташ бер ташкын сыман алга таба аккан көтүдән аерыласы — дәү мөгезлеләрне һәм бөдрә йонлыларны ташлап качасы, иксез-чиксез яшеллек эченә кереп адашасы, бәкәлләре талганчы, шушы җылы һәм

ягымлы тау читләре, үзәннәр буйлап йөгерәсе, чабасы килде аның. Күңеленә килгән нияти аны шундук читкә каера башлады. Әмма гел уйламаганда борын төбендә генә иләмсез озын чыбыркы шартлады. Борылып караса, ни күрсен — кеше. Дәү-дәү атлап аның артыннан ук җитеп килә иде инде. Микәй шундук әнкәсе кисәтүен хәтерләде һәм сискәнеп куйды: «Кешедән сак булыгыз, бәтиләрем... кешедән!» Ашыга-кабалана, ул кирелән бөдрә йонлылар төркеменә елыша төште һәм, башын игән булып, тын гына баруын белде — шартлый торган чыбыркы тоткан кешенең узып китүен көтте.

Кеше, аның ниятен каян белгән диярсең, узмый да узмый гына бит, авызыннан әче төтен өреп, тик йөренә аның тирәсендә. Тагылган сыман янәшәсеннән Микәйне күзәтеп бара. Хәтта, мин монда дигәндәй, иелә төшеп, берничә тапкыр аның аркасыннан да сыпырып алды. Ә бөтен әйләнә-тирәне уратып алган теге ягымлы төс, җылы төс һаман саен үзенә чакырып, әйдәп тора. Күзләрне камаштырып кызыктыра. Микәйнең түзәр хәле калмады, йөгерәсе-чабасы килүдән бәкәл очлары, сызлагандай итеп, тынгылык бирмәде. Мөгезләреннән бәреп торган гайрәт очкыны артканнан-арта барды. Һәм ул кинәт кенә арт санына бөтен авырлыгын ташлап, кушаяклап этенде дә, җылы һәм ягымлы яшеллек кочагына ташланырга теләп, алга ыргылды. Янәшәсендәге бөдрә йонлылар, аның бу сәрсәнлегеннән сискәнеп, читкә тайпылды, дәү мөгезлеләрнең аяклары буталып алды. Кеше кулындагы озын чыбыркы да хәрәкәткә килде. Ләкин муен турында гына шартлау авазы чыгарып, бер ягын көйдереп алган чыбыркы усаллыгы гына туктатырлык идеме соң аның бу ашкынуын?..

Онытылып тагы күпме шулай чапкан булыр иде әле Микәй... Инеш кискен борылыш ясаган турыда, үги ана яфраклары гына үскән кызыл яр читендә аны бер төркем кардәшләрен күрү генә тыелырга мәҗбүр итте. Үзе кебек ук көтүдән качкан «кәҗә взводы» иде бу. Микәйнең шулай тилереп чабуына гаҗәпләнгән идеме алар, аның сәер кыяфәтенә, көмеш ука сыман елкылдап торган мамыгынамы? Төптән юан чыгып шактый саллы күренгән мөгезләренә киттеме исләре? Һәрхәлдә, тау читендә дөньяларын онытып йөргән кардәшләре, шым булып, карашларын аңа текәгән иде.

Микәйнең ашкынып, берөзлексез алга ыргылып торган аяклары туктап калды. Ниндидер сәер, үзенә дә ачык кына аңлашылып җитмәгән инстинкт туктатты бугай аны. Ул кызыл яр читенә текәлде. Кызыл яр читендәгеләр аны күзәтте. Шулай күпме үткәндер һәм тагы күпмегә сузылган булыр иде әле бу карашып тору... Кәҗә төркеменнән берсе — иң дәү гәүдәлесе кузгалып куйды һәм, үзе артыннан башкаларны да әйдәп, читкә борылды.

— Ме-е-е,— диде ул, ишетелер-ишетелмәс кенә тонык аваз чыгарып.— Бер дә харап инде, исегез киткән...

Башка кәҗәләр, буйсыну белдереп, шундук аңа иярделәр. Ләкин дәү кәҗә артыннан кызыл яр читен калдырып киткәндә, арадан берсе, иң соңгы булып кузгалганы, кабат-кабат каерылып, Микәйгә таба моңсу караш ташлады...

Үзенең яңа танышына сокланып туймады Микәй. Муеннарын турайтып, мөгезләрен күккә чөеп, аны чит-читләп әйләнеп чыкты. Бер урында гына басып тора алмады. Ул кәҗәгә тыныч кына карау мөмкин түгел иде шул. Җыйнак кына мөгезләр, тар маңгай, туры аяклар һәм бигрәк тә шомырт сыман кара күзләр, шулай ук кара туны аны моңарчы ул күргән һәммә тереклектән аерып тора иде. Микәйнең аңа җылы итеп дәшәсе килде. Башын аның муенына салып, һич булмаса мөгезләре белән аның аркасын тарап, озак-озак янәшәсендә торырга иде. Ләкин кабалана-кабалана ары китеп барган кәҗәләр Шомырткараны аның янында калдырырга теләмәде. Тагы шул әлеге дә баягы алдан элдерткән дәү мөгезле кәҗә тынгысызланды.

— Мә-ә-ә, Шомырткара, сине көтәбез...— диде ул, кырыс кына.

Шомырткара бер Микәйгә карады, бер дәү мөгезле кәҗә ягына. Шулай икеләнеп, ни эшләргә белми торгач, теләр-теләмәс кенә урыныннан кузгалды. Аяклары кардәшләренә таба тартты, ә күзләрен Микәйнең көмеш ука сыман елык-елык килеп торган мамыкка төренгән гайрәтле гәүдәсеннән аера алмады...

Ә дәү тәкә күптән инде аның каршысына килеп баскан, үзе белән көч сынашырга чакырып, аны көтә иде. Алгы аяклары белән җир тырнап, муен өстендәге йоннарын кабартып, очлы мөгезләрен аңарга төбәп куйган бу иләмсез һәм шыксыз тәкәнең кан сауган күзләреннән генә дә куркып качарлык... Ләкин качарга ярамый!.. Арт аякларын ипләбрәк куяр өчен, җайлы урын эзләде Микәй. Сөзешәсе килми иде аның, ә сөзешергә кирәк. Никадәрле генә иләмсез һәм шыксыз булмасын, ул дәү тәкәдә бер ачуы юк иде аның. Ашыкмады, бәлки, тынычланыр дип көтте Микәй. Тик ул уйлаганча барып чыкмады. Аның шулай икеләнеп торуын куркуы дип белдеме, качарга ният итүе дипме, нәфрәтен басарга ярсып атлыккан дәү тәкә аңа җан-фәрман китереп төртте. Гел көтмәгәндә, уйламаганда булды бу. Микәй үзенең зур хата ясаганлыгын аңлады: артында текә кызыл яр булуын хәтердән чыгарган икән бит ул. Дәү тәкәнең авырлыгыннан аяклары, ирексездән, артка чигеп куйды, ул үзенең шул кызыл ярдан тәгәрәп төшеп китүен сизми дә калды...

Чарасыз калган Микәй Шомырткараның карашын тотып алды. Мизгел эчендә елкылдап киткән ул караш кызгану түгел, ышаныч белән тулы иде. Шул караш аның тән авыртуларын

дәвалады, шул караш аның әрнүләрен юкка чыгарды. Шул караш, аның монда берьялгызы гына түгел икәнлеген искәртеп, Микәйнең оеп барган канына яңадан кайнар учак якты. Бөтен тәненә һәм мөгезләренә ташып-ташып, актарылып гайрәт тулганны тойды ул шунда. Иңнәренә тагы канат үсте. Һәм бар гарьлек, кимсенүләрен берьюлы онытып, кире кызыл яр өстенә менеп басты ул...

Дәү тәкә көч сынашырга әзер иде. Арт аякларын җәя төшеп терәгән дә, әле синдә аз булдымыни дигәндәй, мөгезләрен тырпайткан да тик тора.

Бу юлы да беренче булып ярсуын тыя алмаган дәү тәкә китереп төртте. Микәй аның бу сөзүеннән кымшанмады да, ул бу юлы әзер иде инде. Ник шунда аяк астындагы җир убылмый яисә өстенә тау ишелми — ул җиңәргә тиеш. Хәлиткеч сикереш ясау нияте белән Микәй бөтен гәүдәсен пружина сыман җыерып китерде һәм үзен кыерсытучыга ташланды. Дәү тәкәнең сеңере нык булып чыкты, ул да бирешмәде, аякларында калды. Алар маңгайны маңгайга, мөгезләрне мөгезгә терәп сөзешергә керештеләр. Шак та шок бәрелүдән мөгезләр аварга җыенган агач сыман шыгырдап, сыкрап-сыкрап куйды. Мөгезләрдән очкын чәчрәде, күз төпләрендә ут күренде, күкрәкләрендә ялкын дөрләде. Тояк асларында җир актарылды, зәңгәр күктә нурлар чайкалып торды...

Гомерендә үзенә мөгез күтәрүчене күрмәгән дәү тәкә бу сәер җан иясеннән болай ук көтмәгән иде, әлбәттә. Тәмам әлсерәде, аякларын тоймый, мөгезләрен буйсындыра алмый башлады. Тик бирешергә уйламады. Үзенә каршы торырга сәләтле табылуга ышанмады. Ярсыганнан-ярсый барып, Микәйне янә кызыл яр читенә таба кысрыклый башлады. Әмма бу юлы яшь тәкә аннан елгыррак булып чыкты: бер ыргылуда читкә тайпылды да аның үзен шул кызыл ярга таба төрткәләргә тотынды. Кабаланды дәү тәкә, боргаланды, әмма берни кыла алмады — арт аяклары инде кызыл яр читендә иде...

Аны кызыл ярдан тәгәрәтү өчен, хәзер гайрәте арттканнан-арта барган Микәйгә җиңелчә хәрәкәт ясап тагы бер кизәнү җитә. Ләкин алай итмәде Микәй, артка чигеп, дәү тәкәнең яңадан уртага чыгуын көтте. Бу изгелекне бөтенләй көтмәгән тәкә бертын аңыша алмый торды. Кызыл яр астына тәгәрәүдән исән-сау котылу куанычыннан кәҗәләренә күз төшереп алды. Алар янында сынатырга ярамый дигән уй ярып үтте аның ике мөгезен. Әмма бөтен гәүдәсе белән җыелып, башын югары чөйгән, мөгезләрен сөзешергә әзерләп куйган Микәйне күрүгә, яңадан бәкәлләре калтыранып куйды. Юк, булмый, күпме генә тырышмасын, бу хикмәтле тәкә затына каршы торырлык егәр калмаган иде инде анда. Шуны яхшы аңлаган дәү тәкә кире борылды һәм,

башын түбән салындырып, теләр-теләмәс кенә, авыл ягына таба китеп барды.

Ул көнне авылга шактый соң, эңгер-меңгер вакыт җиткәч кенә кайтырга чыкты Микәй. Башын горур тотып, вак-вак кына адымнар белән нык басып иң алдан ул кайтты. Аннан алга чыгарга бирәү дә кыймады. Артыннан кәҗәләр теркеме ияргән иде. Янәшәсеннән, аз гына калыша төшеп, Шомырткара атлады.

Җил исте, сулар акты — вакыт үзенекен итте. Ай үсәсен көн үскән Микәй иң дәү кардәшләреннән дә калкурак, гайрәтле бер тәкә булып үсеп җитте. Нык, калын сыйраклар өстендә торган тыгыз тән, туры муен һәм текә маңгай, елык-елык килеп күзләрне камаштырып торган көмешсу мамык дисеңме, бер пар чалгы сыман һава ертып торган туры озын мөгезләрме — болар бары да тик анда, Микәйдә генә. Көтү җыелган урынга ул төшми торып, кәҗәләрне урыннарыннан кузгатырмын димә. Авылдагы барлык кәҗә көннең көн буена аның тирәсендә. Көтүчеләр дә күнекте моңа, авыл кешеләре дә. Микәй күренә икән, димәк, көтүдән бер кәҗә дә качмаган дигән сүз. Микәй кая китсен, болай да һәрчак иректә ич. Иртәнге тынлыкны ертып, көтүнең ук очы сыман, беренче ул атлый. Чыкта коенган ямь-яшел үзәнгә беренче булып ул аяк баса. Чыклы үләндә беренче булып аның дүрт тоягы эзе кала. Һәр иртәнең сусыл үләннәрен иң элек ул татып карый. Инеш аркылы чыкканда, аз гына да болганмаган йөгерек шарламага сакал очын тидереп, көмештәй саф суны башкалардан элегрәк ул эчә.

Микәйнең инде тынгылык белмәс җаны да тынычланып килә. Алай гына да түгел, үзен тулы бәхеткә ия тәкә итеп хис итә ул хәзер. Шундый тыныч һәм якты көннәрне тоташтырган гадәти бер төндә, татлы йокысыннан бүленми генә, төш күрде ул. Микәйнең хәтерендә җуела барган үткәнне, тәмам онытылган бер хыялны яңартып, яңадан балкытып, дөрләтеп җибәргән төш булды бу.

Имеш, ул үзенең кәҗәләре белән, ерак аралар үтеп, Ак кыялар илендәге ап-ак киңлекләргә барып чыккан. Бөтен әйләнә-тирә ап-ак нурда коена икән. Тавыш-тын юк. Янәшәсендәге кәҗәләрнең андый аклыкны беренче генә күрүләре икән — исләре китте, һәммәсе берьюлы телдән язды. Бу нинди аклык бу, диләр. Бу нинди матурлык бу, диләр. Син булмасаң, без бу ак кыяларны әле кайчан һәм ничек күргән булыр идек, диләр. Син үзең дә шул кыялар сыман нурланып балкыйсың, шул кыялар кебек горур, шул кыялардай тәкәбберсең, Микәй, диләр. Мактап һәм олылап туймыйлар аны.

...Төшнең шул урынында кинәт лапас капкасы шыгырдап ачылды. Ике ут арасында чарасыз калган Микәй уянып китте. Ишегалдында иртәнге ыгы-зыгы башланган. Өй каршындагы

ак каеннарның бөдрә тармакларыннан мөлдерәп торган яшел нурлар коела. Микәй әле генә игътибар итте: җанына аеруча үз булган, аклыклары белән березлексез аның карашын иркәләп торган каеннар дөньяга яшел нур чәчә икән бит. Ак каеннар дөньяга яшел нур булып тама икән. Шомырткара, яшеллек дип, юкка гына өзгәләнми, димәк. Ак төс һәм яшел төс алар бербөтен түгелме соң?.. Бер үк иркенлек, хөрлек һәм бәхет төсләре ич! Ак һәм яшел — Микәй белән Шомырткара дигән сүз. Аларны берберсенә каршы куеп, Микәй ялгышкан икән ич... Кышын ап-ак булган урман-кырлар да җәйгә очраклы рәвештә генә ямь-яшел төскә кермәгән булса кирәк. Дөньяда ак белән яшел һәрчак бергә, һәрчак янәшә. Микәй белән Шомырткара да шулай.

Шулай итеп, урман аръягындагы ак юллар һәм шул юлларның очындагы ак кыялар турындагы ак хыял аның хәтерендә янә калкынып алды. Шул ак дөнья торган саен ешрак искә төшеп, билгесез ераклыкларга алгысытып, ашкындырып торды. Микәй түзде, үзенең ни өчен һәм ниләр уйлап өзгәләнүен берәүгә дә, хәтта Шомырткарага да сөйләмәде. Ул вакыт-вакыт әйләнәтирәдәге яшеллекне, яшел үлән өстендә көязләнеп терт-терт басып йөргән кәҗәләрне дә күрмәс хәлгә килә иде. Мөгез очлары сыкрый, тояклары кымырҗый, күзләренә мөлдерәмә бөртекләр тула иде кайчак. Микәй барыбер түзде. (...)

Аклыгы белән куандырып кыш килде... Кышны яңа язлар алыштырды, табигатьтә яшел төс тантана итте. Көтү чыккан беренче көнне зарыгып каршы алды Микәй. Койма читендә җыелып торган кәҗәләрне күрү аңар чиксез дәрт һәм шатлык китерде. Тагы да үсеп, тазарып киткән Микәйне дә кәҗәләр зарыгып сагынган иде. Аны абайлап алу белән, кәҗә төркеме өстеннән җиңелчә дулкын үткән сыман булды. Тыкрык башы җанланып китте. Килә-килешкә иң элек Шомырткараны эзләде ул. Берсеннән икенчесе купшырак нәфис туннарга төренгән ике бәти иярткән Шомырткара киртә читендә тыйнак кына аны көтеп тора иде. Микәй шундук әнисе янында уйнаклашып йөргән ул бәтиләрнең кара төстә түгел, көмеш сыман елкылдап торган мамыкка төренгән булуларына игътибар итте. Иртәнге яктылыкта үзләреннән шундый ук көмеш нурлар тараткан сылу бәтиләр башка кәҗәләр тирәсендә дә күренә иде. Килә-килешкә бер кат күздән кичерде дә, мөгезләрен югары чөеп, аякларына нык-нык басып, күкрәген киерә төшеп, Микәй туп-туры кәҗәләр җыелган почмакка үтте. Ул үткәндә, сарыклар читкә тайпылып юл бирде, сыер булып сыерлар да аның озын һәм нык мөгезләрен күргәч сагаеп калдылар.

Ниһаять, көтүче чыбыркысы шартлады. Кузгалдылар... Микәй алга узды. Микәйгә ияргән бердәм һәм тату кәҗәләр

төркеменә сыерлар һәм сарыклар алдан ук килешеп куйган сыман юл бирделәр. Яңа җәйнең әле яңа яшәреп килгән беренче үләннәренә иң элек Микәй тояклары эзе төште.

Көтүдә бер хәл. Авылда да хәзер Микәй иң хөрмәтле затларның берсе булып китте. Малай-шалай турында әйтеп тә торасы юк, аның исемен ишетүгә үк, колаклары үрә тора иде аларның. Аның белән элеккечә үк уйнарга, шаярырга яратсалар да, хәзер ялгышып та аны котыртучы юк иде инде. Янәшәсендә басып тору, күпереп торган мамыкка төренгән аркасыннан, юан муеннарыннан бер сыйпап алу малайлар өчен зур бәхет һәм дәрәҗә иде...

Соңгы кыш эчендә Микәй олыгаеп та киткән. Малай-шалай белән куышып чабуларга, уйнакларга бер дә атлыгып тормый ул хәзер. Күбрәк зурлар тирәсендә, ир-ат булган җирдә чуалырга ярата. Иртә яз һәм көз көннәрендә, кышкы суыкларда булсын, лапаста ябылуда яисә ишегалдында бикләнеп ятудан кызык тапмыйча, берөзлексез урамга, Нурлы Аланның ыгы-зыгылырак урыннарына тартыла иде. Үз көе белән чыгып, үз вакытында кире кайтырга күнеккәч, аның авыл буйлап сәяхәтенә хәзер Хуҗа абзыйлар да каршы килми башлады. «Нәселе шундыйдыр, башка маллар кебек алдына салганга риза булып, ишегалдында чемченеп йөри белми шул... Җанына урын тапмый, ямансулый торган мал булып чыкты»,— дип, кәҗә тәкәсен урамда үз иреге белән йөрүдән тыймадылар.

Әле ат абзарына барып чыкты Микәй, әле каравыл өе янында җыелып тәмәке көйрәткән ирләр тирәсендә чуалды. Ат чанасына килеп керт-керт печән ашады, урамда коелган тукранбаш чәчәкләрен җыештырды. Аны һичкем кумады, һичкем селтәнмәде аңа. Үз көенә, зур хөрмәткә лаек ирекле бер сәяхәтче булып, тик йөри иде авыл буйлап. Ләкин кайда гына булмасын, ул берөзлексез кешеләрне күзәтте.

Ир-атлар да аны үз иттеләр. Ара-тирә кесәләренә кыстырып килгән ипи кисәкләре белән сыйладылар. Әлеге дустанә мөнәсәбәттән ике як та үзенә бер ямь таба иде. Аяк астындагы карны шыгырдатып, эшлекле бер кыяфәт белән, Микәйнең, фырт-фырт атлап, машина һәм тракторлар паркына килеп чыгуын зарыгып көтеп ала торган булды ирләр.

...Март урталары иде булса кирәк. Көннәрдән бер көнне, колхозның ремонт мастерскоеннан кайтып барышлый, кибет каршында җыелып торган ирләрне күреп, Микәй алар янында да тукталып алды. Ирләрнең кызып-кызып нидер сөйләшүен, әледән-әле җанлана төшеп, шаркылдашып көлешеп алуларын күзәтеп тору мәзәк иде аңа.

Янәшәдә генә җигүле ат тора. Шуның чанасы артына барып басты Микәй. Чанада хуш исле солы саламы, ара-тирә чемченеп

алырга да була. Мөгезләре очында гына кояш эленеп тора. Аның җылы нурлары күзләрне чагылдырып ала, тәннәрне иркәли, күкрәкләрдәге ярсуны кузгата. Ничек ташлап китәргә кирәк...

— Егетләр, әнә Микәй дә килеп чыккан,— диде ирләрнең берсе, сүз арасында, аңа күрсәтеп.

— Егетләрнең асыллары кайда, Микәй шунда,— дип, чертләтеп бер читкә төкереп куйды шунда Курай Назыйм.

— Микәйгә җиткән егет булырга кирәк әле,— диде икенче берәве...

Ул үзенә күрә шактый мәгънәле итеп әйтергә теләгән иде, әмма аның сүзләренә булган игътибарны Мөдир бүлдерде. (Ул трактор-машиналар паркындагы мөдирлегеннән чыгарылса да төшеп калмаган иде. Төшемле җирдә — колхозның склад мөдире булып эшли. Мөдир булып тугандыр, күрәмсең, Мөдир булып калды.)

— Әйдә, Рәфәгать, чыгар әле фильтрлыңны, булгач-булгач шәһәрчә булсын, бер тартып җибәрик,— дип дәште Мөдир.

Шәһәр Рәфәгате сигарет таратты. Кесәсеннән шырпы чыгарды. Ирләр борыннары белән берәм-берәм ут кабызучының кушуч арасына кереп чыктылар.

— Саранланма инде, Микәйгә дә чыгар өлеш,— дип дәште Мөдир, сигарет тартмасын кесәсенә тыгып торган Рәфәгатьне яртыюлда туктатып... Шәһәр Рәфәгате, сигаретын сузып, Микәйгә таба атлады. Хуш исле солы саламы чемченеп торган Микәй шундук башын читкә борды.

— Синнән ник алсын?.. Әнә Миңлегалигә бир,— диде Мөдир.— Ул үз кеше.

Миңлегалинең күңеле тартмады. Әмма, правосын алдыргач, соңгы көннәрдә генә Мөдир үзе янына эшкә алган иде аны — Мөдирнең сүзен аяк астына салып таптый алмады. Миңлегали Микәйне үзе янына чакырды. Тәкә хуҗасын таныды, теләр-теләмәс кенә булса да килергә мәҗбүр булды. Бертын үзенә таба сузылган кулга карап торды, кулдагы әйбернең ни икәнлеген чамалап өлгергән иде инде. Исе борынын ярып керде. Юка кәгазьгә төрелгән ул сасы нәрсәгә ничәмә-ничә мәртәбәләр тап булганы бар иде бит аның. Авыл әйләнәсендә, койма читләрендә үскән үләнгә үрелим дигән саен, шул ис килеп бәрелә иде борынына. Тәңкәсенә тигән, күңелләрен болгаткан ис бит ул. Бер нәрсәне аңлый алмады ул — нигә әле аңа һәрчак сөеп, үз итеп караган хуҗасы шул сасы нәрсәне тәкъдим итә? Микәйгә начарлык телиме ул?.. Алай дисәң, үз авызыннан да әче төтен исе бөркелеп тора. Үз-үзенә дошман булмас кеше... Кеше кадәр кеше ничек итеп шундый ахмаклык эшләргә мөмкин?..

Берни аңыша алмады Микәй. Хуҗасының күзләренә текәлде. Карашларын мөлдерәтеп, зур ышаныч белән карап торды ул аңарга.

— Кабызып бир, дип әйтә бит... Әнә көтеп тора,— дип пышылдады арадан берәү.

— Шырпы китер. Шырпыңны сыз,— дигән сүзләр ишетелеп алды.

Тамаша итеп торучыларның кызыксынуы Миңлегалигә дә күчте, аны да мавыктырды. Бер кулы белән тәкәнең муен астыннан сыпырып торды ул, икенче кулы белән, ипле генә итеп, сигаретның фильтрлы башын Микәйнең иреннәренә тидерде.

Берни аңламады кәҗә тәкәсе. Нарасыйларча мөлдерәп, әле хуҗасының күзләренә, әле аның кулындагы сасы нәрсәгә тик карап торды. Кеше кадәр кеше аңа начарлык теләмәс. Кеше кадәр кеше начар әйбер тәкъдим итмәс бит... Шуның өстенә әле монысы хуҗа кеше. Аны көн саен диярлек үз итеп, аркаларыннан сөеп, иркәләп киткән хуҗасы. Юк, кешеләр ихтыярына каршы бара алмады ул. Кешегә булган ышанычы һәрнәрсәдән югарырак иде. Микәй сак кына иреннәрен кыймылдатты...

Ирләргә шул җитә калды. Кешеләр һәммәсе берьюлы җанланып куйды, шаккаттылар. Баш түбәсендәге бүрекләр колак читенә шуышып төште, күзләр маңгайга кунаклады. Берсен икенчесе бүлдереп гөрләшергә тотынды ирләр.

— Капты бит, капты...

— Микәй тәмәке тарта...

— Вәт, кәҗә дисәң дә кәҗә ичмасам...

Ирен арасына кыстырылган сигаретны нишләтергә белмәде Микәй. Бәхетле гөрләшкән кешеләргә карап торды. Тел очын гына тидереп, авызындагы әйбернең тәмен белеп карарга булды — иреннәре һәм теле әчетә башлады. Авыз эченә кергән ис күңелен болгатты, күзләреннән мөлдерәп яшь бәреп чыкты. Артык түзә алмады ул, сасы нәрсәне кире төкереп, дымлы күзләрен яшерергә теләгәндәй, ирләр яныннан китеп барды. Кычкырып-кычкырып сөйләшкән, көлешкән кешеләр шунда торып калды.

«Микәй тәмәке тарта» дигән хәбәр авылны аркылыга да, буйга да гизде. Шул тәмәке дигәннәрен ирен очларында бераз тотып торгач, тагы да ныграк үз итә, кадерләбрәк сөя иде аны кешеләр. Микәй дә әллә ни югалтмый, кешеләрнең дә күңеле була. Кешеләр канәгать!..

Микәйнең яңа шөгыле турындагы хәбәр Азат белән Миңлегаязга да килеп җитте. Озак кына ышанмый да йөрделәр. Шулай да көннәрдән бер көнне үзләре сынап карарга булдылар. (...)

Микәйнең әле яңа гына чираттагы биләменнән кайтып төшкән чагы иде. Ишегалдының урта бер җиренә баскан да, башын бер якка янтайтып, мөгез очы белән аркасын кашып тора. Малайларны бөтенләй күрмәмешкә салыша, күзләрен кояшка таба борган да йома төшкән.

— Ничек бирәбез, шул көе генәме? — дип кызыксынды Азат.

— Тәмәкене ничек тарталар, солдат?

— Ут төртеп, иптәш Миңлегаяз генерал.

— Ут төртмиләр, солдат, кабызалар!

— Мә, алайса, кабыз.

— Юк, син кабыз, солдат!

— Авызга капсаң, исе килә. Син тотып тор, мин кабызам!

Ничәмә-ничә шырпы сызып, сигарет башын күпме генә көйдерсәләр дә, аның башыннан төтен чыкмады. Миңлегаяз, тәвәккәлләп, авызга алды. Һәм, аның әче төтененә буылып, шундук ютәлләргә дә кереште.

— Фу, сас-сылы-гы моның. Үскәч ничек тартырсың?..

Микәй, иреннәрен ялый-ялый, байтактан инде аларның кулындагы сигаретны күзәтә иде. Миңлегаязның кулына ул үзе үк үрелде һәм сигаретны иреннәренә алды. Суырмады ул аны, әвәләде-әвәләде дә, уты сүнгәч, комсызланып чәйни үк башлады.

Малайларның исе китте. Ни куанырга, ни борчылырга белмәде алар. Микәйдән моны көтмәгәннәр иде, бөтенләй югалып калдылар. Кәҗә тәкәсе исә, авызына тәмәке керүгә, аларның барлыгын да онытты. Аның өчен бар идеме алар, юкмы — үз хәле хәл, ләззәтләнеп чәйнәвен генә белде.

— Тартмый ич, ашый ул аны, ашый,— дип, тагы буылыпбуылып ютәлләргә тотынды Миңлегаяз.

— Микәй, кире чыгар! Ашама! Бир монда...— дип ялварырга кереште бу хикмәттән куркуга калган Азат.

Кәҗә башын читкә борды, урам буйлап кибет ягына таба торып чапты.

Беркөнне көтүдән качты Микәй...

Елдагыча зарыгып көтелгән җәй башы иде югыйсә. Үләннәрдә чык бөртекләре җемелдәшкән якты иртә. Сулышларны иркәләп, күкрәкләрне кытыклап, мамыкларны тарап, талгын җил исеп тора. Тояклар астында — җылы йомшак балчык. Бөтен әйләнә-тирәдә күзләрне чагылдырырлык дәрәҗәдә саф яшеллек тантана иткән чак.

Кышның кыш буена лапас һәм ишегалларында бикләнеп яткан, әлеге иртәне зарыгып көткән кәҗәләр дә монда. Язны тизрәк җиткерергә теләп, тояклары белән ишегалларындагы каты карны күпме тырнаганнарын үзләре генә белә алар. Килеш-килбәте белән карашларын гына түгел, хыялларын да белеп алган Микәйне бер күрергә ничек зарыгуларын әйтеп аңлатырлык түгел. Мактаулы һәм киң күңелле тәкә турында әлегә ишетеп кенә белгән көмешсу бәтиләр дә шунда. Кайсының гына Микәй сыман гайрәтле һәм данлы булып үсәсе килми иде икән?

Шуларның һәммәсен белсә дә качты Микәй. Хыянәтчел төстә калдырып качты. Аның юкка чыгуын, тигәнәк һәм алабута баскан ташландык нигез турына җиткәч үк, ни арада күздән югалуын янәшәсендә барган Шомырткара да абайламый калды...

Юк, ак юллар һәм ак кыялар турындагы хыяллары сәбәпче булмады бу качуга. Кая? һәм ни өчен? дигән сорауларга, мөгаен, үзе дә җавап бирә алмаган булыр иде ул. Зур хата ясавын да аңлады үзенең. Әмма кире борылмады. Юлбашчысыз калган көтү турында уйламаска тырышты, ашыкты, кабаланды Микәй.

Урамнар иртәнге ыгы-зыгыдан тынычланып, бушанып калган. Ул туп-туры кибет каршына үтте. Анда берәү дә күренми иде әлегә. Моңарга да исе китмәде. Түмгәк-түмгәк булып кипкән көлсу балчык өстеннән, комсызланып, тәмәке төпчекләре чүпләргә кереште. Авызына җыйды да, башын күтәрә төшеп, озак кына ләззәтләнеп чәйнәп торды. Акрын гына күз аллары ачыла төшкәндәй булып китте, тынгысыз җаны изри башлады. Кибет янында берүзе чемченеп, ул байтак йөрде. Кояш аның мөгезләре очына менеп җиткәч кенә, ирләрне юксынып, ремонт мастерскоена таба китте...

Күңеленә ятышлы ис сизеп, тимерче алачыгы ишеге төбенә килде Микәй. Анда ике ир-ат тәмәке тарткан көйгә тимер чүкеп маташа иде. Тукталды. Һәм моңлы гына итеп, аларның бер кулларына, бер авызларына карап тора башлады. Күзләрен мөлдерәтеп озак торды шулай. Тимерчеләрдән күзен бер генә мизгелгә дә читләштермәде. Авызыннан сулар килде, тамак төбе янды, күзләре эренләп чыкты. Ләкин аны, никтер, аңламадылар һәм аңларга теләмәделәр. Ул гына да түгел, яннарыннан ук кудылар. Микәйнең китәсе килмәде. Борын тишекләрен иркәләп торган шул төтен исе өчен генә дә торырга риза иде ул. Төпчекләрен ташлаганны көтте. Үч иткәндәй, анысын да аяк астына түгел, утлы күмер өстенә аттылар. Микәйгә күз читләрен генә төшереп, үзара сөйләшеп алды кешеләр.

— Күр инде, бичара, әнә ничек газаплана. Бирикме соң әллә берне генә?..

— Бирәсе түгел!

— Соңгысы итеп кенә, кызгандыра ич...

— Ә болай кызганыч түгелме?!

Кешеләр сөйләшүендә булды. Күзләреннән сизеп, күреп торды — усаллык белән карамыйлар иде, элеккечә үк яратып, үз итеп карыйлар югыйсә. Ә сигаретларын кызганалар.

Көтеп-көтеп тә бер эш чыгара алмагач, ул тагы бер мәртәбә гараж алдыннан урап узды, рәткә тезелеп торган комбайннар каршыннан үтте. Бара торгач, ремонт мастерскоеның түр почмагында аунап яткан тимер-томыр ватыклары өеме өстенә

менеп туктап калды. Мөгезләре тагы да авыраеп китте кебек, бөркүлеккә түзәрлек түгел. Аяклары да талган. Бераз хәл алырга исәпләп, көн кызуын җыйган кара калай кисәге өстенә, кояшка арка куеп сузылып ятты Микәй. Йоклыйсы килде аның — йоклый алмады. Башын аркасына салып изрисе, онытылып торасы килде — барып чыкмады. Бер сәбәпсезгә тынычсызланды, берәзлексез кыбырсып торды. Үз-үзен кая куярга белмәде.

...Офык читендә кара болытлар күренеп-күренеп алды. Алсуланып кояш баеганда, дымсу салкын җил исте. Төннәрен берәзлексез әллә яшен, әллә аҗаган уйнады. Яңгыр булуы бар, яңгырга китмәгәе дип хафаланды нурлы аланлылар. Басуда әле сугылмаган иген — сабан бодае бетмәгән, арпа коела, солы чират көтеп ята. ...Шундый чакта ничек кул кушырып утырырга мөмкин. Инде бишенчегә күчкән Азат та, Миңлегаяз кебек үзеннән өлкәнрәк дус-ишләре белән бергә, ындыр табагыннан кайтып кермичә, өлкәннәргә булыштылар. Көрәк тотып, үзтөягечләргә ашлык этеп тордылар. Капчык өстерәделәр — төяделәр, бушаттылар. Капчыкларның баш-башыннан тотып, хатын-кызлар өстерәде, картлар кыймылдады, яшь-җилкенчәк булышты.

Ир-ат та кул кушырып тормады, билгеле. Комбайннар көнне төнгә ялгап эшләде, икмәк төягән машиналар тыз да быз йөреп торды. Салам җыйды, җир тырмалады, җир сөрде ирләр. Ирләр колхозның ындыр табагында да аз түгел. Бер ишеләре янып-көеп эшләп йөрде. Ә икенчеләре...

Икенчеләре дә бар иде. Таза-таза ирләр, колак артына карандаш кыстырып, күпме икмәк кайтканны, киткәнне хисаплап торды. Ирләр амбарда, каравыл өендә, үлчәүдә, һәр көшел янында кәгазь тотырып торды. Сырлап-боргалап, көннең көн буена кәгазьгә кул куйдылар, тамга ясадылар, чут төймәсе тарттылар. Ирләр һәр склад ишеген, һәр чистарткычның, һәр бушаткычның ничек эшләвен күзәтеп торды. Ирләр арлы-бирле йөрде, эшлекле йөрделәр. Үткән-сүткәндә, капчык өстерәгән яшь киленнәргә шаян сүзләр әйтеп үттеләр, куллары сузылгалап алды.

Ирләр ындыр табагының түрендәге каравыл өе турында җыелып әңгәмә корырга да өлгерде. Пышын-пышын гына мәзәк хәлләр сөйләргә дә вакыт чыкты. Каравыл өенә эшлекле генә кереп чыккаладылар. Кайберәүләрне аяклары гел шунда каерып торды: мыштым гына кереп киттеләр дә кош тоткандай очынып чыктылар. Шунда кереп, быелгы уңыш өчен, исәнлек-саулык өчен, йөзгә байлар төсе чыксын өчен, көннәр матур торсын өчен, кәеф яхшы булсын өчен, ди-ди күтәрде алар...

Мөдир ышанычлы кешеләре белән үзенең эш урынына — ремонттагы орлык киптерү корылмасына таба үтте. Бу корылма ындыр табагында үзенең биеклеге, серлелеге һәм тыныч почмакта урнашкан булуы белән башка һәммә корылмалардан

аерылып тора. Мөдир рөхсәтеннән башка анда керү катгый тыела. Тәртип куелган. Ишекләр бикле була, теләсә кемгә ачылмый. Пароль — шешә чыңы!

Корылманың ишеге ачылу белән, иң алдан Мөдир үзе узды. Баскан саен челтер-челтер килеп, җаннарына рәхәт һәм сихәт биреп, шешәләр шалтырады. Ул да түгел, көчәя барган шешә чыңы астында ул югары күтәрелә башлады. Ни җитте баскычтан гына түгел, шешәләрдән өелгән баскычтан. Исең-акылың китәрлек — корылманың түшәменә җитәр-җитмәс биеклектә әрдәнәләп шешә тавы өелгән иде. Мөдирнең осталыгына хәйран калырлык, шешәләрне ул шундый итеп өйгән, цементсыз-кадаксыз дигәндәй пирамида корган да куйган...

Ул да түгел, пәри туе уйнатып, давыллап, җил исә башлады. Көшелләр өстенә капланган җәймәләрне дер селкетте, чит-читкә өелгән кибәкләрне тузгытты җил. Күк күкрәде, яшен яшьнәде. Коеп ява да башлады. Чыр-чу килеп, ябулы урыннарга йөгерешге халык. Кулындагы себеркесен ташлап, туксан белән барган Сөләйман карт та амбар алдына теркелдәде. Микәй булып Микәй кабаланды, ындыр табагының ерак почмагында торган орлык киптерү корылмасына таба чабып үтте...

Азат исә каравыл өе кыегы астында ышыкланып калган иде. Бер җай табып, малайлар янына элдерим дип торганда, авылдан ындыр табагына таба кемнеңдер ашыгып-кабаланып йөгергәнен күреп алды ул... Чит-ят түгел, әле бая гына ындыр табагында булган йөк үлчәүче икән. Ярым бөкрәйгән хәлдә йөгереп килеп җитте ул аның янына. Еш-еш сулыш ала, манма суга баткан... Ә кәефе күтәренке!

— Безнекеләрне күрмәдеңме? — дип сорады сулуы һаман да басылмаган йөк үлчәүче.

— Кемнәр?

— Мөдир белән капчык хисаплаучы, ягъни мәсәлән.

— Юк, күрмәдем.

— Ә Микәйне?..

— Микәй әнә теге якка чапты,— диде Азат, кулы белән орлык киптерү корылмасына күрсәтеп.

Йөк үлчәүче, бөкшәя төшеп, ике дә уйламый, Микәй чабып үткән якка элдерде...

«Нигә әле Микәй артыннан йөгерде бу йөк үлчәүче?.. Микәй бит берьялгызы чабып үтте...» Сорау кызыксынуга әверелеп, кызыксыну Азатның үзен дә шул якка тартты. Күлдәвекләрне ерып, нәни-нәни гөрләвекләр аша сикереп, ындыр табагының аргы почмагына таба йөгерде ул да...

Ачык калган ишектән эчкә үтте Азат, һәм күзләре чагылып куйды. Каршыда түбәгә җитеп килгән шешә тавы өелгән, ул бертын үз күзләренә ышана алмый торды. Бу кадәр шешә каян

килгән монда?.. Һәм аны кем ташыган, кем өйгән?.. Ничек итеп өйгән? Башка сыя торган түгел.

Алар өчәү иде — Мөдир, йөк үлчәүче һәм капчык хисаплаучы. Шешә тавының нәкъ түбәсенә үк менеп кунаклаганнар да иркенләп кәеф-сафа сөреп утыралар. Өстәлләре дә, дөньялары да түгәрәкләнгән. Алларында әле бушарга өлгермәгән өч шешә һәм бер стакан. Ботарлап атылган какланган каз, кыерчыгы сындырып алынган түгәрәк икмәк. Егет шулай гаҗәпләнеп торганда, «әле монда мин дә бар» дигән сыман, янәшәдә генә Микәй башын болгап алды һәм бар гәүдәсе белән калтыранып куйды. Кышын салкын җилдә сыкраган агач кәүсәләре сыман, аның дәү кара мөгезләре шыгырдап куйды. Микәй чаптыр-чоптыр алдындагы консерв банкасын ялый иде. Бар дөньясын онытып ялый...

Капчык хисаплаучы янәшәдә яткан шешә этикеткаларына язылган «нәрәт»ләрне укырга керешге: «Этәмән планы урманыннан утын кайтарту өчен. Габдерәхим абзаң». «Ат сикерткән тау астыннан — нигезгә таш. Фәйрүзә кодачаң»...

Моңарчы тын гына ялмануында булган кәҗә тәкәсе үзенең монда икәнлеген белдереп кымшанып куйды һәм, шешәтау итәгенә үк килеп, мөлдерәмә күзләре белән югарыга текәлде. Аны күрмәделәр. Ал аягының тояк очы белән нигездәге шешәләргә шак-шок бәреп хәбәр салды Микәй, үзенә игътибар сорады, акрын гына «мәэлдәп» алды.

— Тутырып сал,— дип, Мөдир шешәне капчык хисаплаучыга төртте.— Күтәрмә үзен.

Шешәтау түбәсеннән алпан-тилпән түбән төшеп, консерв банкасына өч-дүрт «буль-буль» агызды капчык хисаплаучы. Азат сискәнеп китте һәм үзен үзе белешмичә кычкырып җибәрде:

— Нишлисез, шайтаннар...

Аны әйтерсең бөтенләй ишетмәделәр. Ул монда, гомумән, юк иде сыман. Капчык хисаплаучы шешәләрдән өелгән баскыч буенча ничек төшкән булса, челтер-челтер иткән чың астында шулай ук ипле генә кире менеп тә китте. Ә кәҗә тәкәсе, почтыр-почтыр килеп, банканы яларга керешге.

«Миңлегали абый, туктагыз, нишлисез... Миңлегали абый...» дип кычкырырга ачылган авызыннан сүзе чыкмады Азатның. Текәлеп карап торган капчык хисаплаучы аны, чынлап та, танымый иде. (...)

Ә шешәтау итәгенә килеп, Микәй алгы тояклары белән шак-шок янә хәбәр бирә башлаган иде инде. Мөдир белән йөк үлчәүче аңа игътибар итмәде. Микәй тагы шакылдатты, тагы... Аны ишетмәделәр. Азат Микәйне куарга итеп карады, ничек кенә булса да ярдәм итәсе, бу куркыныч корылма астыннан аны исән-сау коткарасы килде малайның. Зур мөгезләр каршы төште, кан

баскан акайган күзләр... Аны һичкем күрергә дә, ишетергә дә теләми иде бугай монда. Шифер түбәгә шыбырдап яуган яңгыр тавышы, көчәйгәннән-көчәя барып, аның колагын, зиһенен томалады. Торган саен ныграк шаулый барган колакларын учлап, каралтыдан чыгып китми чарасы юк иде малайның.

Ишекне ачып чыгуга, саф һава килеп бәрелде. Әмма, куллары ишеккә ябышкан диярсең, Азат бертын корылманың бусага төбендә тоткарланды. Эчке яктан яңгырап ишетелгән Мәдир тавышы тоткарлады аны.

— Егетләр... Микәй исәнлеге өчен эчтекме соң әле без?..

— Эчтек,— дигән тавышы ишетелде йөк үлчәүченең.

— Эчсәк, тагы берне!..

— Ике булды инде...

— Өч фарыз! Өч!.. Үзенә дә салыгыз, җанкисәккәйнең. Онытырга ярамый бәгырьне... Әйдә, Микәй исәнлеге өчен!

Үзе җиңел генә күтәреп куйды да Мәдир янәшәсендәге йөк үлчәүчегә бәйләнергә тотынды.

— Син нәрсә, Микәйгә исәнлек теләмисең?.. Болай булмый, юк-юк, калдырма... Сезнең ишеләрнең бишенә тора ул Микәйбәгырь...

Микәй тагы бер банканы ялтыратып куйды. Аңа тагы шайтан каргаган шул эчемлек җитми башлады. Ләкин аны кайгыртучы, аңарга эчемлек салырга җыенучы юк иде. Аның дөньяда барын онытканнар. Җен ачуы чыкты кәҗә тәкәсенең. Кан сауган күзләре акайганнан-акая барды, бөтен гәүдәсе калтыранырга тотынды, дөнья айкала-чайкала башлады. Тутык төсендәге калай банкага, тутык төсендәге шешәләргә һәм шешәтауга чыкты аның ачуы. Аннан тутыкка чумган кешеләргә текәлде. Тутыккан кешеләр кайсы кайда түнеп ыңгыраша, тәгәрәшә башлаган иде. Ул да түгел, әле генә тутык сыман тоелган әйләнә-тирә аның күз алдында ялкын төсенә кереп яна башлады. Каршындагы калай банкадан ут күтәрелде. Тау булып өелгән һәр шешәдән ялкын бәреп чыкты. Шешәтауны тоташ ут ялмап алды. Тау гына түгел, тутыккан кешеләр тәгәрәшеп янарга кереште. Шул ук ут аның үзен дә чорнап алды, үзе дә яна — ялкынланып, дөрләп яна... Януын яна, әмма торган саен суыграк була барып, тәмам калтырата, туңдыра да башлады.

Үзе яну бер хәл, дөрләп, ыңгырашып янган кешеләр кызганыч тоелды аңа. Яналар, көяләр, харап булалар ич... Кешеләр яна! Кеше дип әйтерлекләре калмый. Чара күрергә, ярдәм итәргә кирәк... Уятырга теләп, мөгез очлары белән төрткәләде ул күз алдында дөрләп торган кешеләргә. Уянмадылар. Шешәтау итәгендә ятуларын гына беләләр. Кузгатырга теләп, ул аларны төртеп-төртеп җибәрде — шешәләр белән бергә тәгәрәштеләр, әмма уянмадылар... Яналар, дөрләп яналар ич. Алардан чыккан

ут дөньяга капмасын... Дөньяны коткарырга иде ул уттан. Дөнья бер генә, ул янмаска тиеш! Янмаска!! Дөньяда яшел төс — яшәү һәм яшьлек бар! Дөньяда аклык — ак юллар, ак кыялар, ак кыялар турындагы ак хыял бар! Уттан сакларга кирәк үзләрен, уттан...

Дәрләп януларында дәвам иткән кешеләрне эвәләргә, сөзеп тәгәрәтергә керешә ул. Мөгезләрен кызганмады — ялкыннары гына сүнсен...

Орлык киптерү корылмасы астыннан ярдәм сорап кычкырган авазлар ишетелде. «Каравыл» кычкыру һәм ыңгырашуга күчте ул авазлар. Яңгыр үтеп көннең шулай аязуына куанып эшкә керешкән нурлы аланлылар берни аңышмады, ни диярга белмәделәр. Югалып калдылар. Ялвару катыш хәвефле тавышлар көчәйгәннән-көчәя генә барды...

Ул да түгел, корылма эчендә кинәт әйтеп аңлату мөмкин булмаган шау һәм гүләү авазлары яңгырарга тотынды. Җир тетрәдеме, яшен суктымы, тау ишелдеме — һич аңларлык түгел иде. Күз алдында корылманың капкалары як-якка ачылып китте. Ташкын булып тәгәрәшкән шешәләр арасыннан, җан-фәрман чабып, зур кара шәүлә атылып чыкты. Анда-монда борылмады шәүлә, туп-турыга чапты һәм гәрбил тактадан тотылган биек койма өстенә ташланды. Кинәт яшен суккандагыдай тавыш ишетелде — имән баганалар урыннарыннан кузгалды, калын гәрбилләр, урталай сынып, йомычкадай як-якка чәчелде, пыран-заран килде. Ә койманың аргы ягында упкын сыман тирән чокыр — кара шәүләне ай күрде, кояш алды...

— Шайтан...— дип ухылдады бөтен ындыр табагы.

— Шайтан түгел, Микәй ул! — дип, җан авазы чыгарып, шешә ватыкларын ера-ера торып йөгерде Азат. Кәрәк һәм себеркеләрен эләктереп, аның артыннан сак кына башкалар кузгалды. Пыяла өстеннән йөрергә күнекмәгән халык «ух-ах» килде.

Тимер-томыр кисәкләре, пыяла ватыклары белән тулган тирән чокыр төбендә ятучы Микәй тынып калган иде инде...

Кичен, берьялгызы ындыр артына чыгып, озак кына уйга бирелеп йөрде Азат. Микәй белән бергә үткән борчу-хәсрәтсез елларын, хыялый бала чагын да мәңгегә җуя түгелме ул?.. Ничек болай килеп чыкты? Табигатьнең шундый камил һәм риясыз җан иясе нигә эле шундый аянычлы язмышка дучар булды?.. Кем гаепле моңар? Кем?.. Кешеләргә бит Микәй һичнинди зыян китермәде. Кешеләрне үз итте һәм яратты Микәй. Ул кешеләргә ышанды. Бөтен авыл җылы мамык шәлгә төренде... Мамыгын гына түгел, җанын да бирергә риза иде бит ул кеше өчен. Нәтиҗәдә әнә ничек килеп чыкты... Кешеләр дә начарлык теләмәде бит югыйсә...

Сораулар үсмер малайның бәгырен телгәләде. Тамак төбенә төер булып тыгылды, ике чигәсен китереп кысты шул ук сораулар.

Шунда бакчалар ягыннан кемнеңдер үзенә якынлашып килүен абайлап, сискәнеп куйды Азат. Айсылу апасы булып чыкты.

— Азат...— дип гаҗәпләнде ул, көтелмәгән бу очрашудан каушый калып.— Нишләп йөрисең монда?

— Болай гына, Айсылу апа... Ә син кая?

— Югары Сөнгә...— диде ул, кулындагы төенчеген кая яшерергә белми уңайсызланып.

— Нурлы Аланны күрәсең дә килмәс инде... Шулаймы, Айсылу апа?

— Нурлы Алан үз авылым кебек, Азат,— диде Айсылу, малайга гел якын ук килеп. Күрәмсең, аны аркасыннан гына булса да сөясе килгәндер. Азатның инде гәүдәгә шактый калкынган булуын искә алып кына ниятеннән кире кайтты.

— Айсылу апа,— дип дәште малай, күзләрен аңардан яшерергә тырышып.— Башка беркайчан да күрешмәбез инде...

Малайның кәефен күтәрәсе килепме, Айсылу шаяртырга итеп җанлана төште.

— Әле Алсуны алырга киләсең бар бит...— дип елмаерга итте ул. Һәм бертын, күзләрен тутырып, Азатка карап торды.

Айсылу ашыга-кабалана китеп барды... Күбәләк кар явып торган бер көндә кыңгыраулар таккан пар атка утырып килен булып төшкән Айсылу шулай тын гына караңгы сукмак эченә кереп югалды. Авылга илткән тыкрыктан кемнеңдер адашып өйгә кайтмый калган ялгыз кәҗә бәтие сузып-сузып кычкырырга кереште...



Рабит Батулла
(1938 елда туган)

СИРАТ КҮПЕРЕ[1]

Драмада катнашучы шәхесләр сәхнәгә чыгу тәртибендә язылды:

Тукай — 27 яшьтә.	Туташ — 18 яшьтә.
Ядкәр — 30 яшьтә.	Сагышлы — 28 яшьтә.
Шәүлә — 30 яшьтә.	Бикчура — 28 яшьтә.
Агабәк — 27 яшьтә.	Ханым — 22 яшьтә.

Вакыйга Тукай бүлмәсендә бара. Тукай ялгыз. Ул йоклаганда саташа.

Тукай. Нигә мине читлеккә яптыгыз? Ни өчен мин төрмәдә? *(Ядкәр керә.)*

Ядкәр. Тукай! (...)

Тукай. Ә? Кем бар?

Ядкәр. Тукай, бу мин — Ядкәр!

Тукай. Ядкәр. Хөрмәтле Ядкәр! Сине күрер көннәрем дә бар икән.

Ядкәр. Син авырыйсың. Ятып тор. Төсең качкан. Салкын тидергәнсең, ахрысы... Даруың...

Тукай. Куйсаңчы, Ядкәр! Даруга гына калгач, булмый инде ул...

Ядкәр. Ни сөйлисең, Тукай? Димәк, телеграммалар дөрес сөйли?

Тукай. Нинди телеграмма, Ядкәр?

Ядкәр. Редакцияләргә телеграмма килде. Имеш, Тукай каты авырый. Имеш, Тукайны хастаханәгә салырга җыеналар икән.

Тукай. Мин беркемгә дә телеграмма сукмадым, Ядкәр. Кем эше икән ул? Дөрес, өченче көн минем янда доктор булып китте. Ләкин ул һични әйтмәде. Гап-гади бер бизгәк авыруы, үтәр, диде.

---

[1] Кыскартып бирелә.

Я д к ә р. Шулай була күрсен. Юкса котны очырдылар. Мин, бар эшемне ташлап, синең янга кайттым.

Т у к а й. Төш күрдем бугай мин... Имеш, урамда мин, нәмаешта[1]. Халык белән бергә каядыр барабыз. Шатланабыз, кычкырабыз. Кинәт күктән зур каракош атылды. Ике башлы шул каракош кешеләрнең башларын, күзләрен чукырга тотынды. Мин кычкырам, каракошка ташлар атам. Аннан кинәт кенә үземне читлектә күрдем... Читлектә, төрмәдә...

Я д к ә р. Төш түгел ул, Тукай, өн. Без барыбыз да төрмәдә. Без барыбыз да читлектә. Кемнеңдер читлеге таррак, кемнекедер киңрәк. Аерма бары тик шунда гына. Царизм — халыклар төрмәсе.

Т у к а й. Царизм ул төрмә генә түгел, царизм — халыклар җәһәннәме. Җәһәннәм булды, җәһәннәм булып калачак. Бигрәк тә мөселман халыклары өчен.

Я д к ә р. Дөрес, җәһәннәм булды. Әмма җәһәннәм булып калмаячак. Хөррият, азатлык, тигезлек, туганлык киләчәк Россиягә. Киләчәк, Тукай. Аның өчен тагын бер революция кирәк, Тукай.

Т у к а й. Революция? Әнә бит революцияң. Булды бит инде бер революция. Кан белән сугарылды җир. Революцияне асарга агачлар җитмәде. Каберләр өч аршын түгел, меңәр сажин чокыр казыдылар революцияне күмәргә.

Я д к ә р. Тагын агач саен асылынып торачаклар әле, Тукай. Әле тагын кан коелачак, Тукай.

Т у к а й. Ташла, Ядкәр. Козгындай каркылдарга килмәгәнсеңдер бит минем янга? Кил, бер күрешик үзебезчә... Исәнсаумыни син, хөрмәтле Ядкәр?

Я д к ә р. Тукай! Үзең исән-амансыңмы?

Т у к а й. Исән. Хәзергә исән, Ядкәр. Мин исән, ә менә син югалдың.

Я д к ә р. Безнең эш сезнекенә караганда яманрак, Тукай. Исем үзгәртәбез. Ике көнгә бер фатир алмаштырабыз. Бер урында озак тормыйбыз. Розыск игълан ителгән миңа. Минем баш хәзер бик кыйбат тора. Әле менә Уфадан.

Т у к а й. Гафури ни хәлдә анда, Уфада?

Я д к ә р. Гафури да синең сыман борын салындырып утыра. Баш алып, бу җирдә тормый, бер тараф качмак булам, ди Гафури. Качып кая бармак була? Япония мөселманнарынамы? Барыгыз, бар. Әллә төрек солтанына олтан булыргамы? Барыгыз, бар. Анда сезне ерак әбиегез кияү коймагы пешереп, мунча ягып көтә, ди.

Т у к а й. Ха-ха-ха, мунча үзебездә дә бар. Өченче отделениенең ләүкәсе бик шәп кыздыра, ди.

---

[1] *Нәмаеш* — демонстрация.

Я д к э р. Ә син беләсеңме, Тукай, сиңа көлү килешә. Валлаһи, килешә. Көл син, Тукай. Елмай син, Тукай. Синең асылыңда көлү ята.

Т у к а й. Син, Ядкәр, комплиментларыңны барышняларга калдыр.

Я д к э р. Үпкәләмә. Синең бу турсаюың абыйсына турсайган сабыйныкы кебек.

Т у к а й. Көл, әйдә, көл. Көлү сиңа да килешә.

Я д к э р. Иҗатыңда көл син. Сатираң шәп бит синең, чукынмыш. Тукай көлүе кирәк хәзер.

Т у к а й. Көләрсең монда, тотса мәскәүләр якаң. Көләрсең монда, утырса хуҗаң урынына бер ишәк, килмешәк, күсәк. Театрлар ябылу алдында. Артистлар мескен хәлдә. Көләрсең, көлә-көлә үләрсең.

Я д к э р. Революция җиңелде, Тукай. Бусы әле баласы гына. Революция үлмәде, Тукай.

Т у к а й. Тагын кан коелачак икән әле...

Я д к э р. Революция, Тукай, корбансыз булмый.

Т у к а й. Революция корбан сыйфатында мине алырга килмәгәндер бит?

Я д к э р. Революция синең сатираңны сорарга килде, Тукай. Илдә кап-кара реакция хөкем сөрә. Революция попутчиклары чери, таркала. Интеллигенция үләргә йөз тоткан. Кемдер авылга качты, керәштән читләште. Кемдер жандармериягә сатылды. Халык шомлы тынлык эчендә. Халык көтә. Сатира-юмор көтә. Шушы шомлы мохит эчендә дә шаяра-көлә торган лидер кирәк. Күрсәт, Тукай, татар интеллигенциясенең үлмәгәнлеген, курыкмаганлыгын. Самодержавиенең дарлары, зинданнары, канлы якшәмбеләре генә баса-сыта алмаган рух барлыгын аңласын халык. Көл син, Тукай, елмаю сиңа бик килешә. Анда, Уфада, Гафури елап утыра. Монда, Казанда, Тукай пыскый. Кая керер урын юк, кругом юеш. Татар халкына суык тигән — ютәлли. Татарны кыерсытканнар — ул елый. Татар ютәленә дәва юк, Тукай. Елак татарны юатучы булмаячак, Тукай. Татар халкы хәзер — ажгырып торган дәрьяга ташланган сабый. Йөзә белсә — чыгар. Белмәсә — тончыгыр.

Т у к а й. Йөзә белсә — чыгар... Белмәсә — тончыгыр... Ха-ха-ха, шигырь ич бу, Ядкәр. Усал. Чыннан да, усал, рәхимсез сүз әйттең, Ядкәр. Дөрес сүз. Йөзеп чыгарлык булмаса, халыкның яшәве нигә кирәк. Бетсен ул. Син чибәр егет кенә түгел, Ядкәр. Син революционер гына түгел, куәтле педагог та икәнсең. Рәхмәт! (...) *(Коридорда аяк тавышлары ишетелә.)*

Я д к э р. Тсс... Кайсы яктан китеп була?

Т у к а й. Бу якка!

Я д к э р. Яз син, Тукай, яз! *(Китә.)*

Т у к а й. Хуш, Ядкәр! Хөрмәтле Ядкәр! *(Шәулә керә.)* Кем ул анда? Кем бар, дим?

Ш ә у л ә. Мин әле бу. Базар хәерчесе.

Т у к а й. Уз, әйдә. Печән базарының кәләпүш карагы, Карамалай синме? Ыштан төшә, каеш юк. Каеш булыр иде, каеш алырга акча юкмы? Әнә өстәлдә бер сум! Уз, нәрсә карап каттың?

Ш ә у л ә. Уздым. Узма дисәң дә узам. Уз дисәң дә узам.

Т у к а й. Карамалай, синме соң бу?

Ш ә у л ә. Малай дисәң дә ярый. Бабай дисәң дә үпкәләмим. Мин үпкәли белмим. Артыма типсәң дә үпкәләмәм. Кабахәт дип сүксәң дә зарланмам. Үпкәли башласаң, бу дөньяда үпкәң җитмәс. Шулай, Тукай әфәнде. *(Тукай җиңелчә генә ютәллэп ала.)* Ә үпкә сиңа да бик кадерле нәрсә.

Т у к а й. Яп авызыңны, ишекне дә яп!

Ш ә у л ә. Хи-хи-хи, шигырь белән сөйләшүчеләрне тыңлавы кызык та соң. Авызымны да ябам, ишекне дә ябам. *(Ишекне ябып куя.)*

Т у к а й. Кем син?

Ш ә у л ә. Хәерче. Менә Тукай үлем хәлендә, дигәннәрие, хәл белергә килдем.

Т у к а й. Кем үлем хәлендә? Каян алдың бу сүзне?

Ш ә у л ә. Бөтен базар сөйли сине, бик чирле, диләр.

Т у к а й. Йә, хәзер әйт, сиңа монда ни кирәк?

Ш ә у л ә. Эндәшә батыр утынчы: «Сиңа миннән ни кирәк?»

Т у к а й. Син шүрәлемени?

Ш ә у л ә. Хи-хи-хи, тапкыр әйттең, Тукай әфәнде. Логика! Батыр утынчы сүзләрен син әйткәч, әлбәттә, мин шүрәле булам инде. Ләкин әз генә хаталандың, Тукай, мин шүрәле түгел, шәүлә!

Т у к а й. Шәүлә?

Ш ә у л ә. Шәүлә!

Т у к а й. Кемнән төшкән күләгә соң син?

Ш ә у л ә. Күләгә түгел, шәүлә!

Т у к а й. Аермасы?

Ш ә у л ә. Агачның күләгәсе була. Койманың күләгәсе була. Кешенең дә була күләгәсе. Күләгә ул хуҗасына ияреп йөри. Яки хуҗасы янында тик тора. Ә шәүлә күләгә була алмый. Шәүлә ул җисемнең үзе. Кояш баеп беткәч, офыкта агачларның күләгәсе түгел, шәүләсе кала. Шул мохиткә берәр кеше килеп керсә, кешенең күләгәсе түгел, шәүләсе күренәчәк. Күләгә куркыныч түгел. Күләгә кояш яктысында гына була ала. Көндез. Ә шәүлә шомлы, шәүлә куркыныч, шәүлә — кеше шәүләсе — һәрвакыт куркыныч җинаятьләр тирәсендә йөри.

Тукай. Кызык фәлсәфә. Чыннан да, шәүлә — башка, күләгә башка булып чыга икән шул. Ха-ха-ха, моңарчы бу турыда уйламаганмын да. Кызык кеше син, Шәүлә!

Шәүлә. Син шагыйрь, Тукай. Күп нәрсәне матур хыял аша күрәсең. Хыялларның барысы да тормышка аша алмый. Ә тормыш бай, катлаулы. Тормыш ул парадокслар белән бизәлгән. Синең тирәдә шикле кешеләр йөри. *(Каранып ала.)* Алар сиңа дус булып күренә. Синең тирәдә сиңа каршы фикер әйтүчеләр дә күп, син аларны үзеңә дошман санныйсың. Төче телләләре сиңа дошман булуы ихтимал. Тегеләре чын дусларың булуы да бик мөмкин. Дошманнарыңны син иркәлисең, дусларыңа каршы таш атасың булып чыга. Чөнки синең холкың шундый, Тукай. Шулай итеп, син холкың аркасында үзеңә дә, халкыңа да, әдәбиятка да зур зыян эшлисең.

Тукай. Син шактый эзлекле сөйлисең. Әмма әдәбиятка, халыкка зыян эшләүче мин түгел.

Шәүлә. Әлбәттә, мин дөресен сөйлим, әфәндем. Ләкин дөресен сөйләгәннәргә дә ышанма. Дөрес сүз сөйләр, бәгыреңә үтеп керер, дустың булыр, аннан илтеп сатар.

Тукай. Кем син?

Шәүлә. Шәүлә, дидем ич инде.

Тукай. Кушаматыңмы ул?

Шәүлә. Кушаматым да, үзем дә Шәүлә.

Тукай. Кем шәүләсе?

Шәүлә. Бөек держиморда, патша самодержавиесенең ике башлы каракошы һәм дә урыс шовинизмының Шәүләсе! Ха-ха-ха...

Тукай. Тсс, бу көндә мондый сүзләр өчен каторга!

Шәүлә. Шәүлә өчен каторга ни дә, катыргы ни? Ярлы янаудан курыкмый.

Тукай. Кызык кеше син. Ни белән тамак туйдырасың?

Шәүлә. Күрәзәче мин.

Тукай. Чегәнмени?

Шәүлә. Сорашма, Тукай. Чегән дә, чорт та түгел, мин — күрәзәче. Багыйммы?

Тукай. Давай! Әйт: минем турыда ни беләсең?

Шәүлә. О-о, Тукай, мин синең турыда күп нәрсә беләм.

Тукай. Мә! *(Кулын суза.)*

Шәүлә. Түләү?

Тукай. Әнә өстәлдә бер сум көмеш синеке.

Шәүлә. Юмарт кеше син, Тукай. Ярый. Юмарт булсаң, юмарт бул. Тагын ни бирәсең?

Тукай. Нәрсә тагын? Әле карый башламаган...

Шәүлә. Базар хәерчеләре әйтә: имеш, син сорап кергәнгә соңгы тиенеңне биреп чыгарасың. Имеш, синең бүлмәң тулы

кеше була икән. Бүген мин беренче булып килгәнмендер әле. Шулай бит?

Тукай. Ялгыштың, Шәүлә, мин һәрвакыт ялгыз.

Шәүлә. Ә син алдаштың, Тукай... Ярый, шулай да булсын, ди. *(Тукайның уч төбенә бага.)* Һу-у, сызыклар, юллар, үзгәрешләр... Һу-у, Тукай, сине алда яңалык көтә. Мәхәббәт. Кара чәчле, кара кашлы, кара күзле чибәр кыз. Ул сиңа гашыйк. Син дә аны читтән күрмисең шикелле... Зур гына байлык синең кесәгә менә керәм, менә керәм дип тора. Тик ачык кына әйтә алмыйм. Ул байлык туры мәгънәсендә байлыкмы, әллә теге кызмы. Ә-ә, минемчә, алар икесе берьюлы керә. Син бер бай кызына өйләнәсең.

Тукай. Ха-ха-ха, шактый остаргансың син, күрәзәче. Мәхәббәте кирәк түгел, акчасы булса ярый, булса ярый...

Шәүлә. Ха-ха-ха, мин сине яратам, Тукай. Шаянлыгыңны, шигъри усаллыгыңны, турылыгыңны. Ошбу милләт ертыгының җөен җөйлим. Җебем — кара, энәм каләм булсын имди. Көн-төн донос ясыйсың, вөҗдансызсың тидия. Надо же бит, әй. Шулай әйтергә кирәк бит, әй. Суга печ иткән юләр син, иблискә юлдашчысың. Ха-ха-ха...

Тукай *(ул да көлә)*. Ярый, булды. Шәүлә, мин эшкә утырам. Бар!

Шәүлә. Киттем. Менә бу...

Тукай. Ал, казылык синеке. Өстәмә түләү булыр.

Шәүлә *(казылыкны сындырып ашый башлый)*. Тәшәккер[1], Тукай, ләббәйкә[2].

Тукай. Бар инде, бар.

Шәүлә. Рәхмәт, Тукай әфәнде. *(Китә.)*

Агабәк күренә.

Агабәк. Җыен әтрәк-әләм хәерчене син җыеп ятасың. Аннан теге әйбер югала, бу әйберне табып булмый, дисең.

Тукай. Хәерче түгел ул, философ. Күрәзәче. Беләсеңме, Агабәк, ул миңа күрәзә ачты. Уч төбемә карап, дөп-дөресен әйтте дә бирде. Син дустыңа ук атасың, ди. Дошманнарыңны иркәлисең, ди. Хак бит. Сагышлы егетебезне ничә тапкыр рәнҗеттем. Мотыйгины ничә чәнечтем. Сүнчәләйнең бәгыренә ук аттым. Бичара Бикчурага миннән көн юк. Ә бит алар дус. Дөрес әйтә бит бу йолкыш күрәзәче...

Агабәк. Йолкышларың күбәеп китте әле синең бу арада...

Тукай. Агабәк, минем авыруым турында редакцияләргә син телеграмма суктыңмы? Уфада да шул ук турыда телеграмма алганнар.

---

[1] *Тәшәккер* — яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү.

[2] *Ләббәйкә* — *монда:* менә мин синең алдыңда!

А г а б ә к. Үзем дә шуны ишетеп аптырадым.

Т у к а й. Кем таратты икән бу ялганны? Доктор түгелдер бит инде?

А г а б ә к. Аңа нигә кирәк ул? Хәер, аның белән сөйләштем инде. Аннан чыккан нәрсә түгел. Гаҗәп, гаҗәп...

Т у к а й. Кемгә кирәк булды икән соң бу нәрсә? Ядкәр дә атылып кайтып җиткән.

А г а б ә к. Кемгәдер кирәк, димәк. Кемгәдер синең авыру булуың кирәк.

Т у к а й. Ә мин авыру түгел. Ә, әйтергә оныткнмын. Күрәзәче әйтә, менә-менә синең кесәгә байлык керәчәк, ди. Кара кашлы, кара күзле бер гүзәл алдыгызда тора, ди. Ха-ха-ха!..

А г а б ә к. Ни булды сиңа?

Т у к а й. Бәйрәм булды. Бүген иртән иртүк күңел күтәрүчеләр генә килә. Мин көч сизәм, Агабәк. Миндә куәт бар. Язам әле мин, Аллаһ боерса, язам, Агабәк. Сатира язам, көлке язам. *(Өстәле янына утыра.)*

А г а б ә к. Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен, көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен. Кирәк түгел, мәгънәсе юк көлкеуен.

Т у к а й. Анысы да хак. Ачы хәсрәт көен мин күп көйләдем һәм көйләячәкмен. Ә сатира, Агабәк, хәзер кирәк, бүген кирәк, бә-әк кирәк.

А г а б ә к *(кулындагы кәгазьне әйләндереп)*. Күрәзәчең дөрес әйткән.

Т у к а й *(язуыннан аерылмыйча)*. Нәрсәне? Ә-ә, дус-дошман турындамы? Дөрес шул, Агабәк.

А г а б ә к. Юк, акча мәсьәләсендә. Күрәзәчең синең исемгә Сираҗидан килгән йөз сумлык извещениене укыган. Мә!

Т у к а й. Ха-ха-ха, рәхмәт. Сыйланабыз икән. Теге күрәзәче Шәүлә соңгы казылыгымны алып чыгып киткән иде.

А г а б ә к. Мәхәббәт турында да төгәл әйткән. Монда кергәндә, күрәзәчең залда утыручы туташны да күргән. Туташ анда син бушаганны көтеп утыра.

Т у к а й *(кинәт)*. Ничек? Кем? Кайда?

А г а б ә к. Залда.

Т у к а й. Әйт, өйдә юк, диген.

А г а б ә к. Тиле, ул синең өйдә икәнлегеңне белә бит.

Т у к а й. Әллә ничек бит әле бу, Агабәк. Бүлмә җыештырылмаган.

А г а б ә к. Каушама. Әнә борының тирләп чыкты. Нәрсә шашасың ул кадәр? Тирләгән борын белән гүзәл туташны кабул итә алмассың, тынычлан.

Т у к а й *(сөлге белән битен сөртә)*. Юк, Агабәк, бар, чыгып әйт, авырый, диген, хәйлә тап инде, син оста бит.

А г а б ә к. Үзең әйткәндәй, юләр балык син, Тукай. Ни ара җир узып килгән. Сине күрү аның өчен бәхет булачак. Аннан бит иҗатыңны яттан белгән туташны кире бору ахмаклык булыр иде, әфәндем. Высший кругларда да мужиклык мокытлык дип атала.

Т у к а й. Без синең кебек высший кругларда әйләнмәгән шул.

А г а б ә к. Бик кызганыч. Высший кругларда капкорсак байлар гына түгел. Анда Пушкин да, Лермонтов та, Дәрдемәнд тә бар.

Т у к а й. Ни сөйләшим мин ул туташ белән? Вәт җүләр балык, әйләнәм дә тулганам...

А г а б ә к. Җүләрен җүләр инде син, Тукай. Түлке балык түгел. Җүләр гашыйк син.

Т у к а й. Анысы нәрсә тагын?

А г а б ә к. Мәҗнүн син бүген.

Т у к а й. Ни турыда сөйләшим соң аның белән? Син бит үзең затлы туташлар белән күп мөзакәрә[1] кылган кеше, өйрәт.

А г а б ә к. Утызга җитеп килгәндә дә хатын-кызлар белән нишләргә кирәклеген дә белмәгәч, ник тудың, ә?

Т у к а й. Утызга түгел, егерме җидегә генә әле, картайтма.

А г а б ә к. Шигырь сөйлә.

Т у к а й. Булмый.

А г а б ә к. Алайса, мәзәкләр сөйлә. Бер күрер өчен, ни җир килгән бит.

Т у к а й. Уф, тәсмагы бин Мөгайди хәйрен мин ән тәраһе! Мөгайдинең үзен күреп белгәнгә караганда ишетеп белү яхшырак.

А г а б ә к. Алайса, үзе килеп кочаклаганны көтеп, тик утыр җүләр балык сыман. Туташны озак көттерү килешми.

Т у к а й. Чакырып китермәдем.

А г а б ә к. Сөйләшергә сүз таба алмасаң сораштыр. Мичегезгә ничә ипи сыя, туташ, диген. Аяк размерларын сораштыр. Йә үзең белгәннәрне сөйлә. Чистайда — мишәрләр, Алабугада керәшеннәр яши, диген. Французлар — французча, урыслар урысча сөйләшәләр икән, диген. Бетте! *(Ишеккә таба.)* Узыгыз, туташ. *(Туташ керә.)* Мәрхәбә! *(Туташка.)* Шигырьләрен мактамагыз — җене сөйми мактаганны. Шигырьләрен хурламагыз — хурлаганны да яратмый. *(Тукайга.)* Мине бүлмәмдә кешеләр көтә. Кичерегез! *(Чыгып китә.)*

Т у т а ш. Исән-амансызмы!

Т у к а й. Узыгыз, утырыгыз.

Т у т а ш. Сезне хастаханәгә салганнар икән, дигәннәр иде.

---

[1] *Мөзакәрә* — фикер алышып, сөйләшеп утыру.

Тукай. Мин сау-сәламәт.

Туташ. Сөендем. Рәхмәт!

Тукай. Ни өчен?

Туташ. Сәламәт булган өчен. Мин бөтен хастаханәләрне йөреп чыктым. Юк, диләр. Ә сез бүлмәгездә, сау-сәламәт. Шөкер, мең шөкер. *(Чәчәкләргә ишарә.)* Хөрмәтле Тукай әфәнде, бу чәчәкләр сезгә.

Тукай. Рәхмәт, туташ!

Туташ. Бу чәчәкләр сулмыйча озак тора. Шулай да суга утыртып куйсак, яхшырак булыр иде.

Тукай. Хәзер, менә бу банка...

Туташ. Үзем, зинһар, борчылмагыз, Тукай әфәнде. Бу эшләрне мин үзем эшләргә яратам. *(Өстәлдәге артык нәрсәләрне алып, чәчәк савытын уртага утырта. Өстәлдәге кәгазьгә күзе төшә.)*

Туташ. Кичерегез, Тукай әфәнде, мин сезне эшегездән аердым бугай.

Тукай. Борчылмагыз, туташ, зарар булмас.

Туташ *(Тукай каршысына утыра. Уңайсыз тынлык. Икесе дә сүз башларга форсат көтә. Икесе дә берьюлы тын ала).* Э-э...

Тукай. Туташ...

Туташ. Беләсезме, Тукай әфәнде, мин сезне күптәннән күреп йөрим.

Тукай. Ие-ие, мәдәният йортында безне таныштырганнар иде...

Туташ. Аңа кадәр дә мин сезне күп мәртәбәләр күрдем... *(Тынлык.)* Беләсезме, Тукай әфәнде, ни өчен матурлык билгесе чәчәк санала?

Тукай. Уйлаганым булмады, шунысы кызганыч.

Туташ. Егет кызга, кыз егеткә ни өчен чәчәк бәйләме бүләк итә? Тантана вакытларында кешеләр бер-берсенә чәчәк бирә. Мәшһүр шәхесләрне чәчәккә күмә халык. Карабодай, ясмык белән рәттән адәмнәр гөлбакча үстерә. Ни өчен?

Тукай. Матур булгангадыр. Чәчәк үзе матурлык бит.

Тынлык. Тукай белән туташ бер-беренә карап ала. Тукай карашын чәчәк бәйләменә күчерә. Туташ та чәчәккә карап утыра. Музыка. Тукай, бер чәчәкне алып, озак кына карап тора.

Тукай. Гаҗәеп матур! Нәкъ менә мин яраткан төс. *(Туташ кигән күлмәк төсен әйтә.)* Зәңгәр төс. Зәңгәр чәчәк. Зәңгәрнең дә иң нәфисе — зәңгәрсу төслесе. Бәгыремә, каныма якын иң матур чәчәк бу, туташ. Бу чәчәккә карасам, авыру чагым булса савыгам. Кайгылы чагым булса, күңелем күтәрелә. Илһамсыз каңгырап йөргәндә, иҗат дәртем уяна. Рәхмәт сиңа, зәңгәрсу чәчәк! *(Чәчәкне туташның күлмәк якасына кадап куя.)*

Т у т а ш *(салмак кына аягүрә баса, ак чәчәк ала).* Гаҗәп бер гүзәллек! Ак чәчәк — минем сөйгән чәчәгем. Аклык ул — пакьлек галәмәте. Ак чәчәк — иң нәфис, иң саф чәчәк. Чәчәкле җәйне сөйсәм дә, мин ап-ак карлы кышны яратам. Күзләрне камаштырырлык ап-ак, пап-пакь кар өстенә карасаң эреп югаласың. Бернинди башка төс юк. Берни күренми. Ап-ак бушлык. Ап-ак бушлык мәңгелек кебек тоела башлый. Ап-ак кар яуган кыр өстенә карасаң, вакыт югала, дөньяның матдилеге онытыла. Син хыял дөньясында эреп юк буласың. Бу чәчәк — минем иманым, бу чәчәк — минем саф хисләрем билгесе. *(Чәчәкне Тукай күкрәгенә кадый.)* Хисләр билгесе итеп адәмнәр сүзләр уйлап чыгарган. Хисләр билгесе итеп шигырь язганнар. Хисләр билгесе итеп музыка, җыр чыгарганнар. Хисләр билгесе итеп кешеләр чәчәк бүләк итүне уйлап тапкан. Япониядә чәчәкләр теле бар икән. Нәфрәтләрен дә, кайгыларын да, мәхәббәтләрен дә алар чәчәк аша әйтәләр икән. Шулай дигәч, минем бер дус кызым: «Нәрсәкәй, әллә аларның теле юкмы?» — дип сорады.

Т у к а й. Телсез түгел алар. Мәхәббәт аларны телдән калдырган.

Т у т а ш. Сез мине аңладыгыз, Тукай әфәнде. Гыйшык аларны мәҗнүн ясаган.

Т у к а й. Телсез түгел алар японнар. Табигатькә гашыйк алар. Күк йөзенә, океан-диңгезгә, таш-тауларга гашыйк алар. Ә гашыйк кеше күп сөйләшми. Артык гашыйк кеше, гыйшкы утыннан янып, көлгә әверелә. Телдән кала. Сүзе бетә. Хәтта үлеп гашыйк булган кайберәүләр, янып үлмәс өчен, үз мәхәббәтеннән качып йөри. Гади мәхәббәт ул куркыныч түгел. Ә бөек мәхәббәтнең һәр ике якны да яндырып, көйдереп ташлавы ихтимал. Ике шырпы бер-берсенә үлеп гашыйк булган, ди. Ниһаять, алар кавышканнар. Кавышып башларын башка тидерүгә, гөлт итеп ут чыккан. Ике шырпы икесе дә янып көлгә әверелгән, ди.

Т у т а ш. Чи усак утыныдай чыш-чыш пыскып ятканчы, олуг ялкында янып бетүең мең кәррә артык.

Т у к а й. Ә сез, туташ, олуг мәхәббәт барына инанасызмы? Нәрсә ул мәхәббәт? Күпме шагыйрь гомерен баглаган, шуңа җавап эзләп. Аңлы кеше әле дә булса мәхәббәтнең ни-нәрсә икәнен төп-төгәл генә әйтә алмый.

Т у т а ш. Бәлки, төп-төгәл җавап кирәк тә түгелдер, Тукай әфәнде? Төп-төгәл генә җавап әйтелсә, мәхәббәтнең, гыйшык утының калыбын коручылар табылыр иде. Бөтен кеше үз хисләрен шул калыпка куып кертергә тырышыр иде. Аның мәхәббәте бер төрле. Минем мәхәббәтем гел икенче төрле. Әлбәттә, һич шөбһә юк ки, олуг мәхәббәт бар. Мин инанам. Менә сезне, Тукай әфәнде, яратучылар аз түгел.

Т у к а й. Туташ!

Т у т а ш. Сезне яшертен генә сөюче ханымнар, туташлар бихисап.

Т у к а й *(көлемсерәп).* Рәхмәт инде, туташ.

Т у т а ш. Сез көлмәгез. Мин дөресен әйтәм.

Т у к а й. Ни өчендер, моңа кадәр берәүнең дә телдән әйткәне булмады.

Т у т а ш. Гашыйк икәнеңне әйткәч, гыйшык кача икән бит, Тукай әфәнде. Сүз мәхәббәтне үтерә... Әнә шул сезгә яшертен гыйшык тотучылар һәммәсе дә сезне аерым, үзенчә сөя. Шөһрәтегез өчен. Сезне бай дип уйлаучылар бар, байлыгыгыз өчен. Сезне күреп белмәгәннәр баһадир гәүдәле дип уйлый, каһарман булганыгыз өчен. Яшертен гашыйк булганнарның кайберәүләре... сезнең вөҗүдегез[1], иҗатыгыз, иҗтимагый хәлегезне белеп, сезне саклар өчен, үзе өчен түгел, бичара татар халкының бердәнбер җаны булган туры Тукайны саклар өчен, җанын фида кылырга әзер. Көймә бата, йота торган балык өчен фида булган мөрәүвәтле[2] бер җан кирәк.

Т у к а й. Туташ!

Т у т а ш. Тыңлыйм, Тукай әфәнде.

Тынлык. Музыка көчәя.

Т у к а й. Хөрмәтле туташ, минем вөҗүдемне, халәтемне берәү дә белми. Ихлас әйтәм, хәтта күрше бүлмәдәге иң якын дустым Агабәк тә белми... *(Тынлык. Бу тынлыклар һәр икесе өчен дә рәхәт. Икесе өчен дә зур мәгънә, зур сүз. Шуңа күрә берсе дәшми торса, икенчесе ашыктырмый. Тукай дәвам итә.)* Мин үземнең халәтемне һичничек тә сезгә аңлатып бирә алмам. Зинһар, минем тупас, гади сүзләрем сезне рәнҗетмәсен... Сүз кирәк түгел... Кешеләр дәшмичә дә бер-берсен яхшы аңларга тиеш... Сез дә мине аңларсыз. *(Тынлык.)* ...бервакыт сабын күбеге кабартып уйнаганда... нәүмиз калдым. Сабын күбеге һавада очканда гаҗәеп матур була. Могҗизалы шарда салават күпере төсле йортлар, тәрәзә шәүләләре күренә. Шул шарны тотып карыйсы килә. Матурлыкны озакка саклыйсы килә. Тотасың — матурлык та, тылсымлы дөнья да шундук юкка чыга. *(Тынлык.)* Төшемдә әллә ничә тапкыр чык тамчыларын җыйдым. Төшемдә әле дә сабын күбеген тотам. Шул матур шарны тотам да рәхәтләнеп капшап карыйм. Ни кызганыч, менә, ниһаять... матур шарым да булды дип сөенечемнән кычкырам да уянып китәм... *(Тынлык.)* Бар шундый кул җитмәслек, кеше акылы җитмәслек нәрсәләр. Бая сез әйткәнчә, мәхәббәтне аңлатырга кирәк түгелдер, ихтимал. Салават күперен тотарга тырышу

---

[1] *Вөҗүдегез* — барлыгыгыз.

[2] *Мөрәүвәтле* — кешелекле.

ахмаклыктыр, ихтимал. Аңа карап сөенергә генә, сокланырга гына кирәктер? Бәлки, ак болытлар да, ак кардагы бушлык та, аландагы сәйләннәр дә бары хыял гынадыр? Шулай хыял килеш алар яхшырактадыр. Ихтимал... *(Кинәт туташка игътибар итә.)* Туташ! Сезгә ни булды? Сезнең күзегездә яшь.

Туташ. Юк-юк, Тукай әфәнде, бу болай гына... Сез бик тәэсирле сөйлисез. Гап-гади нәрсәләрне дә ничектер фаҗигале тавыш белән әйтәсез.

Тукай. Кичерегез, туташ, белмәдем.

Туташ. Мин бик озак утырдым... Зинһар, миңа тагын килергә рөхсәт итегез, Тукай әфәнде...

Тукай. Ихтыярыгыз, туташ... *(Түшендәге ак чәчәкне алып, туташ якасына беркетә.)*

Туташ. Тәшәккердән гаҗизмен, әфәндем. *(Китә.)*

Тукай. Хуш, гүзәлем. Хуш, ак чәчәккәй! *(Язарга утыра. Агабәк керә.)*

Агабәк. Җә, нәрсә, кыргый Тукай? Булдымы?

Тукай. Нәрсә «булдымы»?

Агабәк. Аңлашу булдымы?

Тукай. Булды.

Агабәк. Димәк, эш пешә?

Тукай. Нинди эш?

Агабәк. Димәк, шуңа өйләнәсең?

Тукай. Ни сөйлисең син, Агабәк? Нинди өйләнү? Кемгә?

Агабәк. Атаң башына! Туташның кәефенә караганда, сез матур сөйләшкәнсез.

Тукай. Сөйләштек лә без, Агабәк. Ләкин аңлашмадык шикелле...

Агабәк. Ничек аңлашмадык? Шул гомер буенамы?

Тукай. Аңлашырга вакыт тимәде. Мин авызымны ачтым да калдым. Ул бит — мәхәббәт алиһәсе, Агабәк. Мин әле моңарчы мондый зәукый[1] ләззәт кичергәнем булмады. Бу — хыял. Бу — шигырьнең үзе. Җыр бу, музыка!

Агабәк. Котлыйм! Ниһаять, Тукай күңелен яулардай туташ та табылыр икән.

Тукай. Беренче тапкыр мәдәният йортында күргәндә үк, мин аңа гашыйк идем инде. Аңа атап шигырь дә яздым бугай...

Агабәк. Сизәм, Тукай. Лирик шигырьләреңнең илһамчысы — әлеге туташ.

Тукай. Мин шулкадәр бәхетле идем, Агабәк, хәтта шүрләп куям. Бу кадәр олы бәхеткәме соң мин фәкыйрь лаек? Сәрхуш бер йолкышны зур акча куркыткан кеби, мин дә куркып калдым гыйшкым алдында.

---

[1] *Зәукый* — эстетик.

Агабәк. Олы шәхеснең гыйшкы да олы булырга лязим[1], дустым.

Тукай. Төнлә саташып уяндым. Куркыныч төшләр күрдем. Уянсам, мине шатлык, бәхет көтә икән... Тик шунысы эчне пошыра: кем телеграммалар сукты да, кем таратты икән яман хәбәрне? *(Язарга утыра. Агабәк салмак кына атлап чыгып китә.)*

Бүлмәдә Бикчура, Агабәк, Сагышлы егет, Тукай.

Сагышлы. Тукай! Бөтен дөнья шаулый: имеш, Тукай хастаханәдә авырып ята. Ә Тукай җир җимертеп эшләп ята. Яшә, Тукай!

Агабәк. Ул хәбәрне кем таратты икән? Сез түгелме, егетләр? Кем суккан телеграмма бөтен редакцияләргә? Уфага, хәтта Троицкига.

Сагышлы. Син ни сөйлисең, Агабәк? Каян килеп? Ни өчен? Әле менә шул хәбәрне ишетеп йөгереп килдем.

Бикчура. Кем сукса да бер түгелмени? Доктор суктыргандыр.

Агабәк. Юк! Доктор авызыннан сүз алып булмый.

Сагышлы. Менә нәрсә җитми иде бу көннәрдә безгә. *(Кулындагы газета-журналларны селки.)* Менә нәрсә җитми иде халыкка. Тукай кирәк иде. Усал Тукай кирәк иде. Әнә газета-журналларны талашып алалар. Мин гомер буе татар талашканга каршы булдым. Ә менә бүген татарның талашканын күреп сөендем. Талаша татар, белем өчен талаша, фикер өчен талаша. Алалар, һәр санын зарыгып көтеп алалар. Ә! Болай булгач, яши халык. Без дә яшибез.

Бикчура. Яшә, Зөбәйдә, яшибез без дә! Үзегезне үзегез алдамагыз, әфәнделәрем. Шулкадәр дә беркатлы ахмаклар булмагызсана. Хаста адәм үләр алдыннан сәламәтләнгәндәй була. Торып йөри. Ашарга сорап ала. Ашый-эчә, сәламәтләндем дип куана да... ятып үлә. Үлем җәрәхәте алган атны атып үтерәләр яки чалып калалар, әфәнделәр. Бу гуманно. Хайванның сызлануын озакка сузмас өчен, шулай кылганнар ата-бабалар. Ә сез газеталарыгыз, журналларыгыз белән үлем җәрәхәте алган татарны бераз яшәтмәк буласыз. Интекмәсен, тизрәк үлсен милләт! Ябыгыз журналларны! Бетсен татар!

Сагышлы. Нигә әле син газеталарыгыз, журналларыгыз дисең? Ул газеталар синеке дә түгелмени?

Бикчура. Юк! Мин ваз кичтем бар нәрсәдән. Бикяр[2] безнең эшләребез. Юк без! Беттек! Ноль!..

---

[1] *Лязим* — кирәк, тиеш.

[2] *Бикяр* — файдасыз.

А г а б ә к. Милләт бетмәсен өчен эшләргә кирәк, егетем. Эшләргә, янарга кирәк. Сафсата сатып, елап йөрүдән, аракы эчеп мескенләнүдән милләт тәрәккый итмәс. Татар халкының синдәй уллары күбрәк булса, әлбәттә, милләт бетәчәк.

Б и к ч у р а. Сез ни эш кылдыгыз соң әле, әфәнделәр? Сездәй уллар күп булганнан ни файда? Без тозакта. Без кире чыга алмаслык тарлавыкта. Неужели сез шуны аңламыйсыз?

А г а б ә к. Адәм соңгы чиккәчә үлем белән тарткалаша. Соңгы чиккәчә тормышка, яшәешкә тырнаклары, тешләре белән ябыша. Бу — табигый. Халык та шулай. Үз эчендәге бөтен мөмкинлекләрне сарыф иткәннән соң гына, халык үләргә мәхкүм[1]. Ә татар халкы, әфәндем, көрәшчегә бай. Син көрәшмәсәң, башкалары табылыр.

Б и к ч у р а. Бай! Байлар бар! Алар да берән-сәрән. Алары да надан. Алары да, урыстан куркып, намазга тәһарәтсез йөри.

А г а б ә к. Куй бу эшеңне, егет. Ташла елавыңны. Менә синдәйләр коткы тарата. Синең кебекләр халык арасында паника куптара. Без эшләгәнне сездәйләр юкка чыгара бара. Тугыз корбан суеп алган теләгебезне синең кебек мәми авызлар бетерә бара.

Б и к ч у р а. Кем инде ул сез? Бу Сагышлы шагыйрьме? Ха-ха-ха, беләбез, беләбез без аның кем икәнен. Ул миннән дә елаграк. Ул миннән дә куркаграк. Шигыре саен — мең пот күз яше. Тукаймы? Тукай ул — Тукай! Бөек Тукай, әмма аның бөеклеген күрсәтер өчен җирлек юк. Киң мәйдан юк. Халык юк. Интеллигенция юк. Россиянең бөтен авыр эшен башкаручы ишәк-татарлар өере бар. Милләт юк. Булган зыялылар Төркиядә, Кытайда, Финляндиядә, Америкада...

С а г ы ш л ы. Син бүген артыграк салгансың, ахрысы. Һич тыела алмыйсың.

Б и к ч у р а. Коточкыч рәхимсез цензура. Матбугат мәче тырнагындагы тычкан кебек. Кыймылдарга да урын юк. Бу озакка бармас, дип уйлыйсызмы? Бу катылык бушар, дисезме? Ха-ха! Беркайчан да ирек булмаячак татарга. Вакыт узган саен, кысыш катырак булачак! Сез шуны күрмисезмени? Күрмәмешкә салышасызмы?

Т у к а й. Юк, күрмибез, Бикчура. Без бит сукыр. Халык өстендә торган кап-кара болытны күрмибез без. Әгәр күрсәк, синең кебек елакка әйләнербез сыман. Аны күрергә безнең вакытыбыз тар. Карагруһчыларга каршы көрәшергә дә, шовинистлар хәнҗәреннән читкә тайпылырга да, шымчы-шпикларны алдарга да кирәк. Язарга, сугышырга, кан коярга кирәк. Иң куркынычы: сездәйләр тараткан коткыны да йомшартырга көч

[1] *Мәхкүм* — хөкем ителгән.

табарга кирәк. Әфәндем Бикчура! Бу бүлмәгә кереп, тагын бер тапкыр балавыз сыксаң, мин сиңа дус түгел! (...)

Бикчура. Карагыз әле, мин бит сезгә хакыйкатьне ачарга дип килдем. Сезгә ярдәм итәргә уйладым. Мин дә бит халык мәнфәгатьләрен кайгыртучы бәндә. *(Елар дәрәҗәдә.)* Их сез, аңламадыгыз! *(Китә. Тынлык.)*

Сагышлы. Елап китте.

Тукай. Еласын! Аңа шул кирәк.

Агабәк. Таркалабыз, тарката безне реакция. Дошманнарга, теге йорттагыларга безнең үзара талашуыбыз, таркалуыбыз кирәк тә.

Сагышлы. Котлыйм, Тукай, син киң колач белән тагын эшкә тотындың. Көчле шәхес син, Тукай.

Тукай. Бер шәхес кенә берни дә эшли алмый, дустым. Йодрык кирәк. Тыгыз, какшамас йодрык кирәк. Син дә читтә йөрисең.

Сагышлы. Их, Тукай...

Тукай. Нигә язмыйсың син? Синең шигъриятең җитми миңа. Синең җәүһәрдәй камил, хисси шигырьләреңне сагынам мин. Хәер, мин генә түгел, сагына халык!

Сагышлы. Нигә кирәк алар? Кемгә кирәк? Минем, кем әйтмешли, пессимистик шигырьләремнең кемгә кирәге бар?

Агабәк. Ялгышасың, туган. Чын поэзия һәрвакыт кирәк.

Сагышлы. Чын поэзия ул — Тукай.

Тукай. Тукайның үз урыны, синең үз урының. Урысның бар Пушкины, бар Фетлары, Бальмонтлары!

Сагышлы. Халыкка кирәк түгел шигырьләр язасың, дип мине ышандырдылар инде.

Тукай. Һәр өргән эттән курыккач, син, чыннан да, язма! Үл! Яки әнә мулла булып Уфага кит.

Агабәк. Син дә Бикчура коткысына тагылып киттең, ахрысы. Халыкка ни кирәген беләме алар? Андыйлар өчен Тукай да кирәк түгел. Яз син шигырь, аны бастыр. Бастыра алмасаң, астан тарат. Халык үзе сайлар, кирәкме аңар синең шигырь, әллә юкмы...

Сагышлы. Ярый. Хушча калыгыз, дуслар. *(Китә.)*

Тукай. Монысына ни булган тагын?

Агабәк. Эчендә нидер бар егетнең.

Тукай. Эче тулы сагыш аның. Шәп шагыйрь. Тукайдан алда әнә кем ул бөек шагыйрь.

Агабәк. Бөек түгел ул, боек шагыйрь. Боеклатты аны заман. *(Китә.)* (...)

Ханым керә. Ул чадра бөркәнгән.

Ханым. Рөхсәт итсәгезче, Тукай әфәнде.

Тукай. Узыгыз. Ә-ә, сез Мәфтуха түти асравымы? Узыгыз.

Ханым. Юк, Тукай әфәнде, мин Мәфтуха тутагыз асравы түгел. Мин — бөтенләй башка зат. Сез көтмәгән кеше мин.

Тукай. Тыңлыйм сезне, туташ.

Ханым. Ханым!

Тукай. Кичерегез, тыңлыйм сезне, ханым.

Ханым. Бу маскарадым өчен гафу итегез, Тукай әфәнде. Мин шулай бөркәвеч ябынып килергә мәҗбүрмен.

Тукай. Алайса, сез бик чибәр. Йөз нурыгыз минем икенче күземне дә сукырайтмасын дип яптыгызмы? Яки сез дөнья ямьсезе. Чыраемны күреп, кешенең коты очмасын дип шулай яшерендегез.

Ханым. Аһ, сез усал, Тукай әфәнде. Өченче сәбәп мине яшеренергә мәҗбүр итә. *(Карана.)* Безне тыңлап тормыйлармы?

Тукай. Курыкмагыз, мин ялгыз.

Ханым. Тукай әфәнде, зинһар, кызмагыз, ачуланмагыз бичара бер хатынны. Мин сезнең китапларыгызны кат-кат укыйм. Шигырьләрегезне укып елыйм. Сезне күреп белергә ни гомер хыялландым. Әмма мин ирекле түгел. Никахтагы хатын мин. Сезне күрү хыял була килде. Ниһаять, шушы ысул белән сезне күрү бәхетенә ирештем. Зинһар, шушы китапларга истәлек имзагызны салсагыз иде.

Тукай. Кемгә диеп языйм соң, ханым?

Ханым. Алтаң туташка, диеп языгыз.

Тукай. Алтаң туташка. Матур исем. Әгәр дә...

Ханым. Борчылмагыз, Тукай әфәнде, Алтаң минем сеңлем. *(Тукай берничә китапка имза сала.)* Мең-мең рәхмәт.

Тукай. Хушыгыз, ханым.

Ханым. Килүемнең төп сәбәбе бу түгел иде... Имза алу — сылтау гына. Зинһар, мине тыңлап багыгыз, әфәндем. Мин сезнең иҗатыгызны читтән генә күзәтүче түгел, мин сезнең химаячегез[1] булырга телим, Тукай. (...) Сезнең талантыгыз үзегезнеке генә түгел. Сез тулаем халыкныкы. Шуңа күрә сезне аеруча сакларга, иркәләргә, үстерергә кирәк. Сез Руставелилар, Фирдәүсиләрдән бер дә ким түгел, әфәндем. Нигә сезгә мәйдан тотмаска? Сез, һичнинди мохтаҗлык күрмичә, ипи-тоз, торак-фатир турында уйламыйча, бары тик иҗат белән генә, бары тик әдәбият белән генә, бары тик халык язмышы белән генә яшәргә лязим. Ташлагыз журналларда ми черетеп утыруыгызны. Ташлагыз пароходсабын рекламаларын. Сезгә заказчы хуҗа кирәкми. Сез үзегез хуҗа. Тукайның көчен юк-барга сарыф итәргә кемнең дә хакы юк. Вак эшләрне йөртер өчен, сезнең үз адвокатыгыз, йорт эшләрен карарга сезнең үз хезмәтчеләрегез булыр. Сез — даһи шагыйрь, иҗат итегез! Калганы минем эш...

---

[1] *Химая* — яклау, саклау.

Т у к а й. Менә хәзер аңлый башладым инде, сез Фон-Мек?

Х а н ы м. Тәбриклим! Афәрин! Браво! Мин ялгышмаганмын. Сез — хәбәрдар шагыйрь. Дөрес, мин Фон-Мек кебек сезнең химаячегез булырга телим.

Т у к а й. Ханым, сез...

Х а н ы м. Шикләнмәгез, Тукай. Менә, алайса, мин кемлегемне сезгә ачарга мәҗбүрмен. *(Балдагын суза.)*

Т у к а й. Могҗиза! Сез тайный советник Әхтәмов кызы?

Х а н ы м. Тсс! Бу балдак — сезгә булган хөрмәтем һәм мәхәббәтем билгесе. Алыгыз!

Т у к а й. Кичерегез, ханым, мин бүләкләр алырга күнекмәгән.

Х а н ы м. Сезнең тәкәббер икәнегезне мин яхшы беләм. Балдакны кулыгыз белән алмасагыз, өстәлегезгә куям. Ә икенче балдак миндә кала. Укыгыз!

Т у к а й *(беренче балдакны карый).* Мөгайдине ишетеп белүгә караганда...

Х а н ы м *(икенче балдакны суза).* Дәвамы бусында.

Т у к а й. ...күреп белү яхшырак.

Х а н ы м. Сезнең яраткан сүзегез: тәсмагы бин Мөгайди хәйрен мин эн тәраһе. Мөгайдине күреп белүгә караганда ишетеп белү яхшырак, дисез. Ә мин, ике балдакка бүлеп, үземчә хакыйкатән, Мөгайдине ишетеп белүгә караганда күреп белүең яхшырак, дип яздырдым. Дөрестән дә, сезне күрү — минем өчен зур бәхет. Берсе сездә, берсе миндә калыр балдакларның. Мин чыгып киткәч, теләсәгез тәрәзәдән атыгыз, Тукай әфәнде, хәерчеләргә бүләк итегез, әмма минем алда кире какмагыз. Бу — минем олы үтенечем. Мин сезнең дустыгыз. Уйламагыз: мин ире өстеннән йөрүче хатын түгел. Ирем минем хөрмәткә лаек. Ләкин ул минем җанымны аңламый. Ул — эш кешесе. Ул — миллионер. Фәкать шик вә шөбһә килмәсен күңелегезгә: мин ирем акчасына сезгә химаячелек итәргә җыенмыйм. Үз акчама. Тарсынмагыз, ярдәмемнән баш тартмагыз.

Т у к а й. Ханым-әфәнде, хатын-кыз хисабына яши алырлык сутенёр түгел бит мин. Сез мине рәнҗетәсез.

Х а н ы м. Зинһар, рәнҗемәгез. Чайковский рәнҗемәгән бит. Рус музыкасының җаны, бөек Чайковский Фон-Мек хисабына иҗат итәргә тарсынмаган, оялмаган. Цель оправдывает средства. Иҗат азатлыгы кыйммәтрәк, тәкәбберлеккә караганда кыйммәтрәк. Фон-Мек булмаса, Чайковский шундый бөек әсәрләр иҗат итә алыр идеме икән? Юк!

Т у к а й. Ханым, сүз бетте кебек. Мин сезнең тәкъдимегезне кабул итә алмыйм, кичерегез.

Х а н ы м. Тукай җаным, сезнең каршыгызда җүләр хатын түгел. Миңа талант кына бирелмәгән, мин халыкның җаны

булыр идем. Мин — максатлы хатын. Идеягә табынып, үзен үзе корбан итә ала торган шәхес мин. Тукайны матди мохтаҗлыктан, вак мәшәкатьләрдән коткара алам...

Тукай. (...) Мин бит акчага мохтаҗ кеше түгел, ханым. Дөрес, минем кесәмдә акча озак торырга теләми, чыга да кача. Капитал сөймәгәнгә күрә, шулай озак тормый ул миндә. Бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй мин. Шулай яшәве рәхәт. Акчам бар чагында барчасын сыйлыйм. Булмаса, акча эзләп йөрмим.

Ханым. Альтруист[1] сез, Тукай.

Тукай. Дөрес, мин — альтруист.

Ханым. Сездән, бурычка дип, акча алалар, кайтарырга оныталар. Сез аны сорап йөрмисез. Бу бит — ялкауларны, жуликларны үзындыру. Сезнең бу яхшылыгыгыз комсызларны, кеше хисабына яшәүчеләрне генә арттыра. Алар сезнең акчаны ашап бетергәч, сезне сүгеп йөри башлый. Бүлмәгездәге әйберләрне урлап саталар.

Тукай. Сатсыннар. Кара савытымны гына урламасыннар. Кара савыты белән каләмемне алсалар гына, җенем чыга.

Ханым. Кеше ярдәмен кабул итмәвегез — һич кирәксез тәкәбберлек. Җиңегез ул тәкәбберлекне. Җиңегез дә рәхәтләнеп иҗатка чумыгыз. Сезгә берни комачауламас. Сезнең нинди малга яшәгәнегезне беркем белмәс. Хатын-кыз химаячелеге сезнең горурлыгыгызга тисә язып барырсыз. Үзегез акчалы булгач кире кайтарырсыз.

Тукай. Сез — акыллы хатын, сез кешене ышандыра аласыз. Ләкин сез мине һаман аңламыйсыз кебек. Минем кире холкым моңа ризалаша алмый.

Ханым. Ә Чайковский? Потомственный интеллигент Чайковский идея өчен, музыка өчен, горурлыгын җиңеп, Фон-Мек химаясен кабул иткән ләбаса!

Тукай. Чайковский шуннан башка юл күрмәгән. Ә минем юлым бар: халык юлы. Кичерегез, мине эшем көтә.

Ханым. Хатын-кыз, үзе килеп, ир-егеткә тәкъдим ясаса һәм отказ алса, мәңге дә гафу итми. Хатын-кыз үч ала башлый. Хатын-кыз интрига кора белә. Мин — тайный советник кызы, мин — миллионер хатыны. Мин корган тозактан ычкыну мөмкин булмаячак.

Тукай. Ха-ха-ха, тәкъдимегез ихлас булса, сез беркайчан да пычрак эшләр белән шөгыльләнә алмассыз. Тәкъдимегез астында мәкер, шәхси бер дан ятса, әлбәттә, отказдан соң сез ятьмә кора башлаячаксыз. Әмма, ханым-әфәнде, мине бернәрсә дә куркыта алмый. Ярлы кеше янудан курыкмый.

[1] *Альтруист* — бүтәннәр өчен үз мәнфәгатьләрен корбан итүче кеше.

Х а н ы м *(бөркәнчеген сала, гүзәл бер яшь хатын).* Җиңдегез, Тукай.

Т у к а й. Беләм, тайный советник кызы Гәүһәршатны сорап хәтта генерал-губернатор үзе йөргән, диләр.

Х а н ы м. Губернаторның энекәше полковник Шаитовка.

Т у к а й. Тукай губернатордан да, миллионердан да, полковниклардан да олырак булып чыктымыни?

Х а н ы м *(ихлас).* Көлмәгез, Тукай әфәнде. Сез мине түбәнсетә аласыз, куып чыгара аласыз, ләкин ихласлыгыма шик белдерергә сезнең хакыгыз юк. *(Елар дәрәҗәдә.)* Мин бит сезнең дәвамыгыз, Тукай. Сезнең шигырьләр миндә милли горурлык уята. Мин бит гимназиядә русча тәрбияләнгән кыз. Мин, татар беркайчан да әдәбиятлы, мәдәниятле була торган халык түгел, дип үскән кыз. Аңсыз бер кыздан мөрәүвәтле бер җан ясаучы — ул сез! Бүгенге көндә мин татар халкының бүгенгесе, киләчәге турында уйлар дәрәҗәдә сездән тәрбия алган хатын. Аңы уянган, халык өчен хезмәткә атлыгып торган үз шәкертегезне сез читкә куасыз. Шушымы гаделлек, Тукай?.. Алайса, ни өчен, ни өчен кирәк булды сезнең ачыргаланып татар кызын, татар хатынын уятырга, шәхес итәргә тырышып кычкыруыгыз? Ни өчен? Сез мине дөньядан биниһая канәгать бер бай кызы дип уйлыйсыздыр, мөгаен. Маена чыдаша алмыйча, үзенә бөек яр эзләргә чыккан хатын, дип уйлавыгыз да ихтимал. Ә мин укытучыма, остазыма ярдәм сорап килдем. Сез түгел, мин ярдәмгә мохтаҗ, Тукай. Мин дә, остазым Тукай кебек, татар халкы өчен хезмәт итәргә дип җан атам.

Т у к а й. Кичерегез, ханым-әфәнде. Сезнең ихласыгызга зәррә кадәр дә шигем юк. Әмма... мин сезнең химаягезне кабул итә алмыйм. Сорашмагыз, сез аны тиздән аңларсыз.

Х а н ы м. Рәхмәт, ихласымны җиргә салмаганыгыз өчен рәхмәт, Тукай. *(Икенче балдагын сала.)* Алыгыз, Тукай, миңа хәзер аның кирәге калмады. Тулы җөмлә булып икесе дә сездә калсын: Мөгайдине ишетеп белгәнгә караганда күреп белү яхшырак. *(Китап ала.)* Әрсезлегем өчен гафу итегез, Тукай. Бу китабыгызны миңа бирегез, зинһар. Гәүһәршат ханымга, дип тутырып языгыз.

Т у к а й *(яза, аннары китапны аңа суза).* Хөрмәтле Гәүһәршат ханым-әфәндегә ихластан бәхет теләп калгучы...

Х а н ы м. Рәхмәт! Хушыгыз, Тукайҗан, мәңгегә! *(Коридорда аяк тавышлары. Сөйләшкән авазлар. Ханым тиз генә пәрәнҗәсен бөркәнә.)* Моннан соң мин дә Казанда кала алмыйм. Мин Парижга китәм ирем белән... Бәхил булыгыз, Тукай! *(Китә.)*

Б и к ч у р а керә.

Б и к ч у р а. Oh-oh, комедия плаща и шпаги. Маскерад-с!

Т у к а й. Дәшмә!

Бикчура. Сер? Гизли-гизли гөрүшнормусунуз[1], әфәндим?

Тукай. Шамакайланма, Бикчура!

Бикчура. Шамакайлансам да ярамый. Зарлансам да ярамый. Кем соң мин? Нигә соң мин? Нигә мине берәү дә сөйми? Яхшылык кылсам шикләнәләр. Яманлык кылсам сүгәләр...

Тукай. Димәк, синең мәсләгең юк. Мәсләге булмаган кеше көләсе урында елый, кайгырасы урында куана. (...)

Бикчура. Өйрәтү ансат... Яшисе килми, Тукай. Дөнья пычракка баткан. Ә мин шуның төбендә ятам. Яшисе килми.

Тукай. Ха-ха-ха, ни булган татар интеллигентларына? Зарланалар, елыйлар, мескенләнәләр. Син бит милләт байрагын тотып чыккан зат. Егылдың, ике чакрым да китми. Бездә көч юк, без бетәргә мәхкүм, дисең.

Бикчура. Әй, син үзең дә мәсләксез бит, Тукай.

Тукай. Дәвам ит.

Бикчура. Мәсләксез, принципсыз син дә. Шигырьләреңдә еладың-еладың да аннан көлә башладың. Хәзер тагын елыйсың. Бер карыйсың, Тукай халыкны күккә чөя. Имеш, татарның узганы шанлы, тарихы бай, Болгары бар. Икенче үк санда укыйсың: татар халкы үләргә мәхкүм, татар черек милләт тә, татар надан... Өченче тапкырында Тукай яза, имеш, без — бриллиант кашлар.

Тукай. Татар кешесен чабаклап уятырга кирәк. Чабаклап уятырга да көзгедән үзенә үзен күрсәтергә кирәк иде. Күрсен, оялсын, үзгәрсен, тәрәккый итсен. Рухы сыныкларның күңелен күтәрер өчен мактарга, күтәрергә кирәк. Көн нинди максат куя татар шагыйре алдына, без шуны үтәргә тиеш. Катып калган принцип принцип түгел, дустым, ул консерватизм дип атала.

Бикчура. Сез генә барысын да беләсез инде. Сез генә фидаиләр[2]. Сез генә укымышлы, сез генә зыялы. Ә мин — дивана, мин берни аңламыйм. Мин — неудачник!

Тукай. Без дә алтын сарайларда яшәмибез, Бикчура.

Бикчура. Мәсләгеңне сатсаң, син алтында яши аласың. Ләкин синдә кирелек куәтле... Синең урыныңда булсам, мин бәдрәфемне дә асылташлар белән бизәр идем... Их, Тукай, төкерергә иде бу дөньяга, ә? Әйдә, үләбез, Тукай. Үлик без. Яшәмик бу фани дөньяда, ә? Калсын дөньягыз үзегезгә дип, язу калдырыйк та...

Тукай. Үлик соң! Ә ничек итеп үләбез?

Бикчура. Кабан күлендә кызлар кер чайкый торган бер бәке бар. Шунда батып үлик.

---

[1] *Гизли-гизли гөрүшнормусунуз?* — Яшерен-яшерен күрешәсезмени? (төрекчә)

[2] *Фидаи* — фидакяр.

Тукай. У-у, суы салкын, кирәкми анда.

Бикчура. Син шаярасың, Тукай, ә мин шаярмыйм... Әгәр дә мин сатлыкҗан булсам, шымчы, доносчы булсам, син ни әйтер идең?

Тукай. Таптың сүз.

Бикчура. Ха-ха-ха, куркып калдыңмы? Син күз алдыңа да китерә алмыйсың шул, Туры Тукай, Беркатлы Сабый Тукай.

Тукай. Син салгансың, ахрысы?

Бикчура. Йөрәк янганда, тагын ни кыласың? Ә син күз алдыңа да китерә алмыйсың, Тукай.

Сагышлы керә.

Бикчура. О-о, бөек поэзия вәкиле килде, неудачник китә. Хуш, Тукай!

Бәхил бул, дус, мин һәм тиздән менәм дарга;
Туйсын ашап җансыз тәнне козгын-карга;
Тормыйм инде, бу дөньядан туйдым инде!
Моңар чаклы торганмын мин гакыл тарга. *(Китә.)*

Сагышлы. Ни булган аңа?

Тукай. Салган ул.

Сагышлы. Салган. Сак бул син аннан.

Тукай. Нигә алай?

Сагышлы. Сак бул.

Тукай. Аннан да шикләнә, синнән дә шикләнә, моннан да шикләнә. Язмаска, сөйләшмәскә, дәшмәскә, көрәшмәскә. Дөньямы бу, әллә төрмәме?

Сагышлы. Сизмисеңмени соң син, Тукай? Синең турында җыен юк-бар хәбәрләр тараталар. Синең тирәдә шикле кешеләр йөри.

Тукай. Ишек ачык. Кем тели, керсен. Акча кирәк булса алсын. Ашарга кирәк булса, казылык бар, алсын. Тик кара савытым белән каләмемә генә кагылмасын.

Сагышлы. Син — даһи, беркатлы даһи. Бөтен нәрсәгә синең күңел сизгер. Гап-гади, ап-ачык нәрсәләрне күрмисең.

Тукай. Нәрсә, әллә Камалдан да, Фатихтан да, үзеңнән дә шикләнергә кушасыңмы?

Сагышлы. Их, дускай, җанашкай... Сәгать ничәләп бар инде?

Тукай. Ике.

Сагышлы. Киттем. Вакытым чыкты. Хуш. Сак бул теге егеттән, Тукай, сак бул. *(Китә.)*

Тукай. Кая киттең? Еракками?

Ядкәр керә.

Ядкәр. Тукай, син өйдәме?

Т у к а й. Ядкәр җаным! *(Ядкәр кочагын җәя.)* Якын килмә миңа, Ядкәр. Миндә грипп.

Я д к ә р. Грипптан курыккан юк, башкасы булмасын.

Т у к а й. Башкасы да ерак йөрмәс бездән.

Я д к ә р. Тукай, сорама, менә бу төргәкне яшер.

Т у к а й. Ядкәр, ни булды?

Я д к ә р. Яшер, тиз бул. Мин чыгып китү белән тәрәзәдән урамга ыргыт.

Т у к а й. Нигә ашыгасың? Утыр. Хәзер самавыр китертәм.

Я д к ә р. Артка койрык тагылган иде. Шуннан качам. Яшә, Тукай! Шәп язасың! Халыкка син елмаю-өмет өләшәсең. Яшә, дускай Тукай! Рәхмәт! Бу эшең синең бомба, беләсеңме, Тукай, бомба! Тукай исеме халыкның гимны икәнен аңла да күп яшә, Тукай! *(Китә.)*

Коридорда аяк тавышлары. Тукай төргәкне тәрәзәдән ыргыта. Аста кем алганын күрә.

Т у к а й. Ядкәр! Менә кемнәре бар милләтнең. Чибәр, мәһабәт. Теләсә кайда рәхәт сөрердәй акыллы зат. Җылы өен ташлап, халык бәхете өчен төрмәләрдә черергә әзер фидаиләре бар татарның. Менә кемгә һәйкәл куярга кирәк Казан уртасында! *(Шәүлә керә.)* Бәлки, син әйтерсең, Шәүлә, минем тирәдә нindидер серлелек. Дусларым ишарә, киная белән генә сөйләшә. Әйтергә телиләр, әйтә генә алмыйлар. Эт шикелле күзгә карап торалар-торалар да чыгып китәләр.

Ш ә ү л ә *(тәрәзәгә килә, кемгәдер сизелер-сизелмәс кенә кул изи).* Дөнья бит бу, Тукай. Ишарәсез, кинаясез тормыш булмый. Йә, ни-нәрсә борчый сине, дускай?

Т у к а й. Син дә нәрсәдер беләсең, әйтмисең генә. Син дә бик серле бәндә булып чыктың.

Ш ә ү л ә. Без, базар хәерчеләре, бөтен нәрсәне белеп торабыз, Тукай. Ләкин белгәннәребезне беркемгә дә сиздермибез. Сиздерсәң, белгәнеңне пычак белән каерып алачаклар. Пычак булмаса, сатып алачаклар сереңне. Үзең беләсең, Тукай, мине акча кызыктырмый. Бу мәсьәләдә без синең белән бертуган. Ә пычактан үләсе килми. Шуңа күрә мин белгәнемне белгертмим.

Т у к а й. Тагын нәрсәләр беләсең?

Ш ә ү л ә. Синең бик еш ютәлләгәнеңне беләм. Синдә...

Т у к а й. Яп авызыңны, Шәүлә!

Ш ә ү л ә. Ябам.

Т у к а й. Ишекне дә теге яктан яп!

Ш ә ү л ә. Ябам, авызымны да, ишекне дә ябам! *(Чыгып китә.)* (...)

Ютәле кузгалып, Тукай урынга ята. Ярым караңгы. Ш ә ү л ә керә.

Ш ә ү л ә. Йоклыйсыңмы, Тукай?

Т у к а й. Кем ул? Ә-ә, синмени, базар пәйгамбәре? Ник йөрисең шәүлегәндәй тавыш-тынсыз?

Ш ә ү л ә. Язмыш куып йөртә, Тукай, язмыш.

Т у к а й. Синең эш рәхәт, уч төбенә карыйсың да тамак туйдырасың. Иртәгесе өчен кайгырмыйсың.

Ш ә ү л ә. Хи-хи-хи, бичара Тукай, син берни дә аңламыйсың шигырьләреңнән гайре...

Т у к а й *(сикереп торып, Шәүләнең якасыннан ала)*. С-син, карачкы, әйтмә миңа бичара дип!

Ш ә ү л ә. Ярар, ярар, әйтмәм лә, ай Аллам.

Т у к а й. Бичара Тукай, ятим Тукай, мескен Тукай, фәкыйрь Тукай... Фәкыйрь түгел мин! Мә, ал кирәк хәтле! *(Акча чәчә. Шәүлә акчаларны җыя. Берсен алып, калганнарын өстәлгә куя.)* Ал тагын. Печән базарындагы бөтен йолкышларны сыйла. Кайдан алдың, дип сорасалар, үзем таптым, диген.

Ш ә ү л ә. Юк, күп акча кешене боза ул. Миңа шунысы бик җиткән. Моңа әллә ничә тапкыр күрәзә кылырмын әле мин сиңа.

Т у к а й. Ятим түгел мин! Күп миллионлы халкы булган шагыйрь ятим буламыни? Бөтен Россиядә урыстан кала икенче милләт баласы, Идел буендагы егерме биш миллион мөселманы булган, Урта Азиядә, Себердә, Уралда тагын шулкадәр укучысы булган шагыйрь мескен буламыни? Алтын эчендә яши алам мин бу халкым белән. Ләкин аңа вакыт тар, Шәүлә. Халкым биргән байлыкта яшәргә минем хакым бар, базар әүлиясы!

Ш ә ү л ә. Булды, ярар, бер сүзне өзми дә, куймый да... Сузма... Якадан алдың бит инде, җитәр. Кирәксә, артыма тибеп чыгар. Мә!

Т у к а й. Кичер, дускай, кызган чакка эләктең... *(Ютәлли.)*

Ш ә ү л ә. Ташла. Соңыннан гафу сорау сиңа килешми. Мин үпкәләмим. Үпкәли башласаң... *(Бүлмәне караштыра.)* Уһу...

Т у к а й. Йә күрәзәче, бер-бер күрәзә кыл әле. Бу юлы ничек алдарсың икән?

Ш ә ү л ә. Монда Сагышлы шагыйрь булган икән, аңлашылды...

Т у к а й. Булды шул, каян белдең?

Ш ә ү л ә. Шуны да белмәгәч, күрәзәче булып йөрүең ни пычагыма кирәк... Уһу, елак милләтче Бикчура да булып киткән икән. Ул иртәрәк чыгып тайган булырга тиеш... Монда Агабәк утырган икән. Ә-ә, бай әфәнде Сираев та килдемени? Ул сиңа бик каты ачуланып чыгып киткән!

Т у к а й. Ха-ха-ха... *(Ютәлли.)* Шайтан икәнсең син, Шәүлә. Каян беләсең син боларны?

Ш ә ү л ә. Мантыйк инде, мантыйк. Дедуктив алым вә логик фикерләү. Күзәтүчәнлек вә янә дә күңел сиземләве, вә дәхи борынымның ис сизүе. Бу трость-таяк Сираев әфәндедән калган. Бу таякны ул Париждан кайтарткан иде. Беркайчан да үзеннән калдырмаган кыйбатлы таягын калдырган икән, димәк, монда зур бәхәс булган. Син аны куып чыгаргансың. Агабәкнең монда булуы табигый. Ул синең янга көненә биш-алты тапкыр керә. Елак милләтче Бикчура һәр көн саен сиңа кереп чыга. Ул төрек тәмәкесе тарта. Ул булган җирдә шундый ис кала. Төпчеге калса ни гаҗәп. Төпчек күрсәтә. Сагышлы шагыйребез дә бик борчулы, гасаби булган. Әнә өстәлдәге кәгазьгә нидер сызгалаган, рәсем ясаган. Рәсемнең логикасы юк. Ул кешенең эчендә ниндидер кайгы булырга тиеш.

Т у к а й. Син Шерлок Холмс бит, Шәүлә! Нигә син хәерче булып йөрисең? Эшлә син частный детектив булып. Син бөтен җинаятьләрне ачып бетерер идең.

Ш ә ү л ә. Их, Тукай җаным, кайгым шул гына булса икән... Да, кстати, ә менә син нигә бу бүлмәдә яшисең, ә? Күселәр, тычканнар... Суык, бәдрәфе дә урамда. Яшә модерный номерларда.

Т у к а й. Яп авызыңны!

Ш ә ү л ә. Ябам, ябам. Шулай шул, Тукай. Миңа да ирекле хәерче булып йөрү кыйммәтрәк. Менә мин турысын әйтәм, иеме? Мин беркемнән дә курыкмыйм. Беркем дә миңа ачуланмый. Мин теләсә кемгә теләсә нәрсә әйтәм. Шул ук сүзләрне мин бай булып әйтсәм, дөнья тулы дошманым булыр иде. Хәерче сүзен чынга алмыйлар. Исерек адәм патшаны акырып сүгеп бара. Аңа берни дә юк. Ә менә син сүгеп кара патшаны!

Т у к а й. Сиңа сүз табалмассың.

Ш ә ү л ә. Тагын кемнәр булды монда?

Т у к а й. Кем белә инде аларны, Шәүлә. Минем ишек ачык тора бит. Кем кергәнен, кем чыкканын күрми дә калам кайчакларда. Йә көзгемне чәлдерәләр, йә кара савытын алып чыгалар, денсезләр.

Ш ә ү л ә. Байлыгың булса, бикләр идең әле.

Т у к а й. Сәер хәерче син, Шәүлә, чын исемең кем соң синең?

Ш ә ү л ә. Кем белә инде аны? Базар хәерчеләренең үз исемнәре булмый, Тукай. Кушаматлары гына була.

Т у к а й. Шулай да.

Ш ә ү л ә. Ни әйтсәм дә, ялган булыр. Габделмән улы Фәррах Зөлфикаров дидем ни дә, Ильминский Иван Николаевич дидем ни...

Т у к а й. Әйтмәсәң әйтмә.

Ш ә ү л ә. Әйттем бит инде, сиңа тагын ни кирәк?

Т у к а й. Син, малай, минем белән сөйләшмә алай. Минем ачуым яман.

Ш ә ү л ә. Ачуланганга исем китми лә минем. Якамнан алганыңа да үпкәләмим. Ул яканы күп умырдылар инде. Әле умырасылары күпме булыр? Артыма тибеп чыгарсаң да, ачу сакламам мин сиңа.

Т у к а й. Нигә әле син гел үзеңне кыйнатырга гына йөрисең, ә? Синдә мазохизм[1] авыруы бармы әллә?

Ш ә ү л ә. Андый авыру юк, әмма шөһрәт ярату авыруы бар. Тукай аягы тигән җир тәмугта янмас. Шуңа күрә, тәмугта янмасын дисәң, син мине кыйна, салып таптa.

Т у к а й. Сәбәп юк.

Ш ә ү л ә. Әгәр дә син минем кара янмаган җиремне калдырмыйча таптасаң, мин бәхетлеләрнең бәхетлесе булыр идем.

Т у к а й. Менә сиңа логика!

Ш ә ү л ә. Син үлгәч... ә син әбизәтелне миннән алда үләчәксең... син үлгәч, мине очрашудан очрашуга гына йөртерләр иде.

Т у к а й. Ни өчен?

Ш ә ү л ә. Менә бу төшемә Тукай аягы тиде, Тукайның йодрыгы менә бу җиремә тиде дип, мин халыкка алдымны да, артымны да күрсәтер идем. Тукай аягы тимәгән җире юк моның дип, мин үлгәч, гәүдәмне, катырып, музейга куярлар иде.

Т у к а й . Ха-ха-ха, тилергән Шәүлә! Әгәр дә киресе булса? Тукайны эттән алып эткә салып сүгә башласалар?

Ш ә ү л ә. Киләчәк буын Тукайны сүгә башласамы? Сүксә соң! Аннан миңа ни зыян? Миңа барыбер почёт булачак. Менә бу кешене кабахәт Тукай кыйнаган, измәсен изгән бичараның дип, тагын мине халыкка күрсәтеп йөртерләр иде.

Т у к а й. Ха-ха-ха, җитте, Шәүлә! *(Ютәлли.)* Үтерәсең син мине. Миңа бит көләргә ярамый.

Ш ә ү л ә. Ярамый! Ярый! Үзең көләсең. Каһкаһә белән көләсең. Әллә ниләр бастырып, кемнәрдәндер көләсең. Сатира! Һөҗү, имеш. Шул сатираң, шул һөҗүең синең башыңа җитәчәк тә. Белеп тор. Җүләр балык син, Тукай. Печән базары корольләре белән нигә кирәк сатулашулар?.. Янә дә килеп, нигә кирәк булды сиңа властьларга кул күтәрү?! Хакимең булса ишәк, килмешәк! Татарга һәрвакыт ишәк һәм килмешәк түрә булачак. Оек кебек кайтарылып чыкса да, татар үзенә үзе хуҗа була алмаячак. Губернаторга барып җитмәс дип уйлама син. Барысы да барып җитә тора. Губернаторың әнә татарча өйрәнеп ята. Татар халкының теленә гашыйк булганнан түгел, татар халкының азатлыкка омтыла торган идеяләрен буар өчен өйрәнә ул татар телен. Ышанмый үзенең шымчыларына. Оригиналдан укырга тели Тукайны, кабахәт. Болытлар куера, Тукай...

[1] *Мазохизм* — җенси бозыклык төре.

Т у к а й. Ә син каян беләсең әле мондый тәфсилле нечкәлекләрне?

Ш ә ү л ә. Мин — күрәзәче, мин — күзәтүче, Тукай. Мин Печән базары шымчыларын яхшы беләм... Тукаевны Уголовное Уложениенең биш статьясының сигез параграфы буенча җавапка тартырга...

Т у к а й *(кинәт кырысланып)*. Җитте, Шәүлә! Яп авызыңны! Дәшмә!

Ш ә ү л ә. Дәшмим. Зинһар, дип сорыйм, тынып кал. Беразга гына дәшмә.

Т у к а й. Тынмасам?

Ш ә ү л ә. Тынмасаң, юллары күп аның. (...) Һич югында, сине үтерә торган гайбәт таратачаклар.

Т у к а й. Гайбәтләр күп булды инде, түзәбез. Тукай эчә, Тукай фәкыйрь, Тукай сукыр...

Ш ә ү л ә. Монысы каршында алары чүп кенә.

Т у к а й. Нинди гайбәт таратырга мөмкин инде? Бөтен булган-булмаганны чәйнәп бетерделәр бит инде.

Ш ә ү л ә. Мөмкин таратырга.

Т у к а й. Димәк, син беләсең? Әйт!

Ш ә ү л ә. Әйтмим.

Т у к а й. Әйт, буам!

Ш ә ү л ә. Бу! Барыбер әйтмим!

Т у к а й. Әйтәсеңме, юкмы?

Ш ә ү л ә *(Тукай колагына нидер пышылдый)*. Шуңа күрә өйләнә алмый интегә икән...

Т у к а й. В-о-н, сволочь! Кабахәт! Юга-ал!

Ш ә ү л ә. Бу сүз таралмаган әле, мин аны тараттырмаячакмын, Тукай.

Т у к а й. Кит, карачкы! *(Шәүләне куып чыгара. Кәефсез.)*

А г а б ә к керә.

А г а б ә к. Нигә кычкырышасыз?

Т у к а й. Йолкыш, базар каргасы!

А г а б ә к. Берәр нәрсәңне чәлдергәнме әллә?

Т у к а й. Чәлдерүен чәлдермәгән, әмма теле кеше үтерер, валлаһи.

А г а б ә к. Сиңа телеграмма бар. Мә!

Т у к а й *(Агабәк сузган телеграмманы ала)*. Сагышлыдан. *(Укый.)* «Тукай, кичер, саубуллаша да, бәхилләшә дә алмадым. Минем арттан күзәтүчеләр күп иде. Ни булса да, мине ярлыка. Сагышлы дустың...» Нәрсә бу, Агабәк?

А г а б ә к. Урта Азиягә китте ул.

Т у к а й. Нигә, ни калган анда аңа? Кинәт кенә... Серле генә...

А г а б ә к. Син белмисеңмени?

Т у к а й. Юк, белмим. Мин бернәрсә дә белмим. Сез генә беләсез.

А г а б ә к. Сине сатмас өчен китте ул.

Т у к а й. Ничек? Кемгә сатмас өчен?

А г а б ә к. Сагышлы шагыйрь охранка агенты иде.

Т у к а й. Агабәк! Бу шаяра торган сүз түгел.

А г а б ә к. Ә мин шаярмыйм, Тукайҗан. Ул охранка белән бәйләнештә иде.

Т у к а й. Бу бит башка сыймый. Ничек?

А г а б ә к. Китереп кыссалар, сыя ул. Китереп кыссалар, була ул. Охранкадагы җәзалау, куркыту, шантажлау ысулларын белмисең щул син, Тукай.

Т у к а й. Аның охранка агенты икәнен син белә идеңме?

А г а б ә к. Белә идем.

Т у к а й. Ха-ха! Менә сиңа тагын бер яңалык. Миннән яшереп, монда әллә ниләр эшләнә, бары тик мин генә белмим.

А г а б ә к. Тукай! Үпкәләмә, иң якын дустыңа да бар белгәнеңне сөйләп булмый торган замана бу.

Т у к а й. Сагышлыбыз монда ни сөйләнсә, шуны җиткерә торганмы?

А г а б ә к. Юк! Озак тарткалашты ул, китереп кыскач, әнә качты. Тукайны сатмас өчен, вөҗданын пычратмас өчен, барыбыздан да качты.

Т у к а й. Коточкыч Казан. Нинди мәмләкәттә яшибез соң без? Дус дусны сата. Татар башын татар ашый.

А г а б ә к. Икенче яңалык... Бәхетсез егетебез Бикчура асылынган.

Т у к а й. Ни дидең?

А г а б ә к. Бикчура асылынып үлгән. Менә язуы. Сиңа.

Т у к а й *(укый)*. «Үзегезгә булсын дөньягыз...» Коточкыч хәлләр! Әле күптән түгел генә монда булды. Шушы сүзләрне миңа әйтте. Мин аны усал шаяру буларак кабул иттем. Нигә? Ни өчен? Бер аңа гына түгел, тормыш барыбызга да авыр.

А г а б ә к. Тормыш авырлыгыннан асылынмыйлар. Вөҗданы саф булмаган, димәк.

Т у к а й. Сагышлыбыз әйтте бит, биш-ун тапкыр әйтте, сак бул аннан, диде. Димәк, алар бергә эшләгәннәр?

А г а б ә к. Ихтимал, очрашкалаганнардыр...

Т у к а й. Менә сиңа ике югалту... Ничек, ни өчен Сагышлы белән Бикчура жандармериягә ялланган? Аңлый алмыйм.

А г а б ә к. Ялланмаган. Ялланылган... Ялланырга теләмәгәннәрнең язмышы белән таныштыргач, әллә кемнәр ялланa, Тукай... Поезд астына кергән, мәрхүм. Исерек килеш катып үлгән, бичара. Печән базары рәтчеләре кыпты белән чәнчегәннәр. Ан-

дый алымнар мең төрле, Тукай. Инквизиция һаман яши, инквизиция һаман чәчәк ата...

Т у к а й. Сагышлы шагыйрь... Кеше ышанмаслык эшләр бит бу... Бичара Бикчура... бүрек ташлап, бүредән котылырга уйлаган...

Бәхил бул, дус, мин һәм тиздән менәм дарга;
Туйсын ашап җансыз тәнне козгын-карга;
Тормыйм инде, бу дөньядан туйдым инде!
Моңа чаклы торганмын мин гакыл тарга.

(Тукайның үз дөньясына кереп чумганын күреп, аның сагышлы уйларын бүлдерергә теләмичә, Агабәк әкрен генә чыга.) Халык башыбыздан кичердекләребез көннәренең өметсез-кара көннәр икәнен белеп калсын. *(Язарга утыра.)*

Ш ә ү л ә керә.

Ш ә ү л ә. Тукай, газеталарыңны кертимме?

Т у к а й. Керт! Ләкин озак торма!

Ш ә ү л ә *(газеталарны бер читкә куя)*. Син миңа ачуланма инде. Мин шулай инде... Язасыңмы?

Т у к а й. Перес, хайван!

Ш ә ү л ә. Мияу!

Т у к а й. Син менә дигән клоун булыр идең, Шәүлә.

Ш ә ү л ә. Мин актёр. Актёрның да нindие әле! Гений перевоплощения. Сәхнәдә әверелеш даһие мин.

Т у к а й. Син зерә укымагансың. Синнән менә дигән театр белгече чыгар иде. «Актёрское перевоплощение» тәгъбирен ничек матур тәрҗемә иткәнсең. Актёрның сәхнәдәге әверелеше. Бәлки, алмашынышыдыр?

Ш ә ү л ә. Алмашынуның башка мәгънәсе дә бар.

Т у к а й. Ә «герой любовник» гыйбарәсен ничек әйтер идең?

Ш ә ү л ә. Мәхәббәт каһарманы.

Т у к а й. Ха-ха-ха, дөрес бит. Ә героиня?

Ш ә ү л ә. Мәхәббәт гүзәле!

Т у к а й. Афәрин! Дөрес бит. Ә безнең театр тәнкыйтьчеләре әсәрнең төп «герое, героинясы» дип авыз суы корыталар.

Ш ә ү л ә. Наданнар. Әйттем исә кайттым, әверелеш сәхнәдә генә түгел, тормышта да гел булып тора ул.

Т у к а й. Кит аннан!

Ш ә ү л ә. Ышанмасаң, артистның тормыштагы әверелешен мин сиңа бүген күрсәтермен. Күрсәтимме?

Т у к а й. Кирәкми! Соңыннан! Газеталар өчен акчаңны өстәлдән ал. Ал да тай! Комачаулама! Перес, дуңгыз!

Ш ә ү л ә. Мырык-мырык... Әйтимме бер сүз?

Т у к а й. Әйтмә!

Ш ә ү л ә. Әйтәм. Сине дә зур әверелешләр көтә. Кайгы көтә, Тукай!

Т у к а й. Кайгы? Нинди кайгы?

Ш ә ү л ә. Беренчесе-соңгысы түгел, кайгырма.

Т у к а й. Бәгырьсез син, Шәүлә. Кешегә кайгы килүен каркылдыйсың.

Ш ә ү л ә. Минем эштә бәгырь комачаулый гына. Баш кирәк безгә. Хис кирәкми. Менә мин хиссез синең өстәлеңә бу газетаны ташлыйм. *(Тукай алдына газета куя. Тукайның күзе газетага төшә. Ул чайкалып китә.)* Тукай, Тукай, ни булды?

Т у к а й. Кабахәт кеше син, Шәүлә.

Ш ә ү л ә. Кабахәт, кабахәт. Килешәм. Тик егылма гына.

Т у к а й. Агабәк! Ага-абә-әк! *(Диварны төя. Кабаланып, Агабәк керә.)*

А г а б ә к. Нәрсә бар?

Т у к а й. Ядкәр вафат. Хөрмәтле Ядкәребез юк!

А г а б ә к *(газетаны ала)*. Әле генә исән кеше. Сау-таза кеше. Ничек була соң бу, ә? *(Укый.)* «...мәшһүр революционер Ядкәр әфәнде Хөрмәтов вафат булды. Ядкәр әфәнденең гаять серле һәм шикле шартларда вафат итүен газета идарәсе әгъзалары бәян итә. Үләргә ике минут кала мәрхүм, почмактагы лавкадан алып, бер стакан җимеш суы эчкәнлеген әйткән. Бу шикле эшне тикшерү өчен, докторлар китертелде һәм җимеш суы сатучы янына тикшерүчеләр озатылды».

Т у к а й. Бетәбез, кырылабыз, Агабәк. Күз алдында ничә кеше китте. Берсе дә үз үлеме белән түгел, Агабәк. Хәзер кемгә чират? Синдәмы? Миндәмы? Бөҗра кысыла, Агабәк.

А г а б ә к. Башкалар да белсен, хәбәр итәргә кирәк. *(Китә.)*

Т у к а й. Канатларын җәя каракош. Каплый дөньяны каракош. Сәер үлемнәр, серле җинаятьләр берлә тулды Казан. Дөнья бәһасе кешебез — хөрмәтле Ядкәребез вакытсыз китте.

Ш ә ү л ә. Беләм мин аны, ул революционер иде.

Т у к а й. Хәер, син белмәгән нәрсә юктыр бу дөньяда... Хөрмәтле Ядкәр, кадереңне белмәделәр үзең исән чакта. Зурлыгыңны күрмәделәр. Бармыни бездә кешенең кадерен белү, мескен үлеп аңлатмагач!..

Ш ә ү л ә. Үлгән артыннан үлеп булмый, Тукай. Бүген син бар, иртәгә юк!

Т у к а й. Каркылдама, Шәүлә!

Ш ә ү л ә. Тукайҗан...

Т у к а й. Зинһар, үземне генә калдыр. Күземнән югал! Кабат кереп йөрисе булма, эттән туган дуңгыз баласы! Син яман хәбәр белән генә йөрисең. Кит, Шәүлә! *(Шәүлә китә.)* Эттән кубәйде дошманым... Нишли алар? Нишли халык? Халык упкынга бара. Саф гакылларга богау салалар кабахәтләр. Күпме калгандыр гомер?

Шул мизгелләрне тулысы белән файдаланып калыйм дисәң, төрле яклап изәләр. Кая барыйм? Нинди мохит бу? Кайда шаттәбәссемле[1] хәят? Авыр уйлар сатты гаклымны. Агуланган тәнем җир куенына тарта. Артыма борылып карасам сызланам. Юк майтарган әшем. Алга карыймын да үксеп елыйм. Бетте көчем...

Туташ керә. Ул шат, бәйрәмчә киенгән. Чәчәкләрен суга утырта.

Туташ. Менә килеп тә җиттем әле. Болары сулганнар инде. Тукай, сез авырыйсызмы?

Тукай. Юк, мин сәламәт, туташ.

Туташ. Ә минем сөенечем бар.

Тукай. Котлыйм, туташ.

Туташ. Сөенечем шул: соңгы матбугатта сезнең шигырьләрегез бик еш басылды. Гаҗәп истигъдадлы[2] әсәрләр, Тукай әфәнде. Бер яктан, куәтле сатирагыз, шаян әсәрләрегез халыкның рухын күтәрә. Икенче яктан, мәхәббәт циклыгыз гаҗәеп бер омтылыш белән яшьләр күңеленә кереп урнаша. Алар бер уку белән күңелгә сеңә.

Тукай. Сез укыйсыз, алар сезнең күңелгә хуш килә, ә халыкның бер өлеше шул әсәрләрем өчен мине каргый.

Туташ. Ә сез аларга игътибар итмәгез, әфәндем. Кизәнгәнсез икән — сугыгыз. Сукмансыз икән — үкенмәгез. Кәефегез юкка шул гына сәбәп булса, ташлагыз. Сезгә курку хәрәм... Ә мин атам белән анама сезнең белән һәр күрешү хакында сөйләп барам. Борчылмагыз, минем алардан яшерен серләрем юк. Алардан сер чыкмый. Беләсезме, җәй уртасында мин сезне авылга алып китәрмен. Кызык булыр. Безнең якта кымыз да бар. Кызык та бар. Казылык та бар. Кыз да бар. *(Яңгыратып көлә. Тукай көлемсерәп куйганны күреп, аның эчке халәтен аңлый кебек. Тынлык.)* Сез минем түшкә кадаган чәчәкләрне мин һаман саклыйм. Җыр дәфтәрем эчендә икесе бергә... Ак чәчәк белән зәңгәрсу чәчәк. *(Ак чәчәк алып, Тукайның күкрәгенә кадап куя.)* Матур! Сезгә килешә. Сез чәчәк өчен яратылган, Тукай.

Тукай *(зәңгәр чәчәк ала, ләкин туташка тапшырырга ашыкмый)*. Зәңгәр чәчәк. Кайгымны таратучы зәңгәрсу төс... *(Чәчәкне кире савытка куя; туташ моны игътибар белән күзәтә. Тынлык.)* Чәчәк үзенең көче җиткән вак кайгыларны гына тарата ала. Кичерегез, туташ.

Туташ. Сезгә нәрсәдер булган, мотлак ни дә булса булган. Сөйләгез, Тукай әфәнде, сөйләгез. Мин аңлармын. Зинһар, яшермәгез миннән.

Тукай. (...) Туташ... Зинһар... безнең танышлыкны онытыгыз!

---

[1] *Тәбәссем* — елмаю, көлемсерәү.

[2] *Истигъдадлы — монда:* зирәк.

Туташ. Мин аңлый алмый калдым, сез ни әйттегез?

Тукай. Онытыгыз, кирәкми бу очрашулар. Зинһар...

Туташ. Мин һичнәрсә аңламадым, Тукай әфәнде.

Тукай. Кичерегез минем дорфалыгымны. Зинһар, миңа рәнҗемәгез. Мин алга таба сезнең белән күрешә алмыйм.

Туташ. Берәр яры китәсезме? Әстерханга яки Җаеккамы?

Тукай. Ераграк, туташ.

Туташ. Ераграктан да кайтырсыз. Тагын Питергамы? Хат язарсыз. Мин дә язармын.

Тукай. Кирәкмәс! Хат та кирәкмәс!

Туташ. Алайса, телеграмма сугарсыз. Мин сезне каршы алырмын.

Тукай. Юк! Туташ, безгә аерылышырга кирәк. *(Усал көлә.)* Кушылмаган килеш аерылышырга кирәк.

Туташ. Ни өчен? Ни-нәрсә үзгәрде шул арада? Гаҗәп матур мизгелләр сез миңа бүләк иткән идегез... Без икебез бер җан идек шикелле...

Тукай. Ул сезнең фантазиягез, туташ. Ул сезгә шулай тоелган гына. Без — икебез ике кеше, ике аерым җан. Юллар аеры безнең, юллар.

Туташ. Ышанмыйм! Туры Тукай ул вакытта алдамады. Икесенең берсе — ялган. Күземә карагыз, Тукай. Туры карагыз! Сезгә гайбәт ирештергәннәр. Шулаймы? Сез мине Тукайга тиң санамыйсыз?

Тукай. Йа Раббем, ни әйтим соң сезгә?

Туташ. Минем турыда гайбәт була алмый. Алайса, ни сәбәп?

Тукай. Мин бик кыен һөнәр иясе, туташ.

Туташ. Беләм: миңа сезнең белән бик кыен булачак. Сезнең холкыгыз фәрештә холкы түгел, беләм. Дошманнарыгыз да күп. Сезгә яшәве көннән-көн кыен булачак. Сезгә дә, сезнең белән яшәүче хатынга да... Беләм... Белгәнгә күрә, сезне сөям!

Тукай. Мин сезне сөймим!..

Тынлык.

Шуны аңладым шушы вакыт арасында, туташ.

Туташ. Туры Тукайның беренче һәм соңгы ялганы!

Тукай. Хушыгыз, туташ.

Туташ. Ярый, сез дигәнчә булсын... Хушыгыз... *(Чыгып китә.)*

Тукай *(үзалдына)*. Хуш, бәгырем, мәңгегә бәхилләә бу ялганымны! Мәхәббәт шигырьләремнең илһамчысы, хуш, бәхил бул! Әльәман[1], туташ, әльәман. Әлвидаг[2], туташ, әлвидаг!

---

[1] *Әльәман* — ярдәм итегез, коткарыгыз.
[2] *Әлвидаг* — хуш, сау бул!

Агабәк керә.

Агабәк. Тукай, бу ни эшең? Туташ, тыела алмый елый-елый, битен каплап китеп барды. Синме аны рәнҗеттең?

Тукай. Синме булдың адвокат? Юат, син бит высший круг кызларын юатырга өйрәнгән!

Агабәк. Тукай әфәнде, минем белән шундый тонда сөйләшергә кем рөхсәт итте? Извольте аңлатырга, нигә елый кыз бала? Аның ни гаебе бар?

Тукай. Агабәк! Мин еламыйммы? Күр! Мин аннан катырак елыйм лабаса. Минем бу күз яшьләрем аныкына караганда мең кәррә әчерәк.

Агабәк. Нигә? Ни өчен ачуланыштыгыз? Һәй, татуланышырсыз әле...

Тукай. Без ачуланышмадык. Кушылмыйча аерылдык. Шулай мәгъкуль. Кем мин? Ул әйтә, күземә туры кара, ди. Ә миндә *(күзенә сугып ала)* печать проклятия! Ул — нәзек хисләр иясе. Ул — нәфислек алиһәсе. Ә мин — чир баскан, шик баскан бер буйдак.

Агабәк. Син үзеңне юкка кимсетәсең, Тукай. Син беркемнән дә ким түгел. Син — бөтенебездән дә югары кеше, Тукай. Хәйлә генә ул синең. Сәбәп башка булырга тиеш.

Тукай. Шул фәрештәгә өйләнеп, аны бәхетсез итимме? Ул гүзәлләр гүзәле, ул газәлләр газәле, олуг бер мәхәббәткә ия булырга лязим.

Агабәк. Тукай мәхәббәтеннән дә олуг мәхәббәт юк аның өчен, аңгыра балык! Ул туташ синең белән бәхетсез булуны бәхет саный, дивана!

Тукай. Сафсата! Суган суфие! Түбәсе тишек лапас өчен яратылмаган ул туташ. Ул яшь, ул чибәр. Үзенә тиңен табар. Шулай кирәк, Агабәк... (...)

Агабәк. Тукай!

Тукай. Дәшмә! Башыңа китер: япь-яшь, гүзәл тол хатын. Аягүрә әрәм булачак. Мин үлемгә хөкем ителгән, Агабәк! Дәшмә! Шулай! Син генә бел. Ә хәзер кит! Ялгыз калыйм! *(Агабәк китә.)* Менә шулай җиңелрәк булыр, Апуш! Тукайга әверелә барган саен, йөгең авырая. Шулай кысты сине, Апуш, кысты язмыш. Дөньяда үз мәхәббәтен таба алмыйча үлеп киткән бичаралар бихисаптыр. Ә мин мәхәббәтемне таптым. Сөйдем. Сөйгеле булдым. Үз кулларым белән, үз сүзләрем белән кире эттем. Әйт син, Апуш, бер мизгел мәхәббәт ләззәте өчен корбан итә ала идемме мин туташны? А-а, юк! Үкенмә! Кылган батырлыгыңа үкенмә!

Шәүлә керә.

Шәүлә. Тукай, син өйдәме?

Тукай. Мин өйдә юк! Кермә, мин авырыйм! Бар, эшеңдә бул, Шәүлә! *(Ютәлли.)*

Шәүлә. Бу юлы без синнән сорап тормаска булдык, Тукаев әфәнде!

Тукай. Кем инде ул «сез»? Николай патшамы?

Шәүлә. Без! Николай патша булмасак та, жандармерия идарәсенең өченче бүлеге әһелләре!

Шәүлә бик нык үзгәрә. Элеккеге базар йолкышыннан мәһабәт бер кешегә әверелә.

Тукай. Чираттагы әверелешеңме, күрәзәче Шәүлә?

Шәүлә. Юк! Чираттагы эшемнең ахыргы нәтиҗәсе, Тукаев әфәнде. Күрәсез ки, әфәндем, мин үз эшемне шактый оста башкарам. Бу операциягә нокта куярга вакыт җитте! *(Тукайга документ күрсәтә.)*

Тукай. Аһ, шулаймыни? Елан тек елан, ха-ха-ха...

Шәүлә. Рәхмәт, әфәндем. Бу миңа бик зур комплимент-с!

Тукай. Хәшәрәт! Казылык белән сыйладым бит мин бу хәерчене. Күрәзә караган саен, берәр сум көмеш бирдем бит шул сатлык җанга.

Шәүлә. Беләсеңме, Тукай, барыбер мин сине яратам. Сүксәң дә, типкәләсәң дә яратам.

Тукай. Сөя-сөя суясың, ярата-ярата таркатасың, юха елан.

Шәүлә. Син бик тә сихерле кеше бит, Тукай. Синең арттан шымчылык итәргә куелган агент үзеңне ярата башлый. Синең өстән язарга теләми, сине яклый башлый. Сагыйплы шагыйрь качты. Бикчура асылынды. Полковник Жуховицкийдан миңа боерык булса да, мин сиңа кагылмадым. Мин сине харап итәр урында саклап йөрдем. Әйе-әйе, мин булмасам, сине әллә кайчан бетерәләр иде. Үзегезнекеләр үк. Яңа Бистә, Печән базары әһелләре сине мең тапкыр үтерә иде. Мин аларның юлын кисә бардым. Тукайга кагылсагыз, бөтенегезне кырып бетерәм, дидем.

Тукай. Рәхмәт инде, үзең үтерер өчен башкалардан саклап калганыңа күрә, мең шөкер. Хәзер сәбәбен әйт инде.

Шәүлә. Тукай мәшһүр, Тукайга тартылалар. Тукай миңа җим буларак кирәк иде. Алдавыч җим ул Тукай. Государственный преступник Хөрмәтов Ядкәрне розыск ничә еллар тота алмады. Ә мин тоттым. Әһә, минәйтәм, бу хәйләкәр төлке Хөрмәтов Ядкәр Тукай дигән җимгә килми калмас. Һәм хак, чиртте Ядкәр Тукай дигән җимгә. Килде Ядкәр Тукайга һәм тотылды... Авыр туфрагы җиңел булсын. Менә ни өчен Тукайны мин җаным кебек сакладым.

Тукай. Революцияне буучы палач син!

Шәүлә. Ха-ха-ха, ялгышма, Тукай. Чын революцияне яклаучы мин. Революция ясаучыларның туксан проценты надан

була. Бит-ун хыялыйның идеясенә котырып, наданнар баш күтәрә. Баш күтәрү вакытында акыллылары үлеп бетә. Революция юлы уртасында шыр наданнар гына торып кала. Баралар наданнар, кая барганнарын белмиләр. Кая барабыз соң без, барабыз да барабыз, дип сораганнарны әлеге наданнар революция исеме белән кырып ташлыйлар. Интеллигенция бетә, аек фикерлеләр атыла, шикленәрне асалар. Алай-болай булмагае дип, һич гаепсезләрне дә төрмәләргә тыгып бетерәчәкләр. Илне шом, деспотизм шаукымы басачак. Һәр палач, гөнаһсыз башны чапканда, бисмилла урынына: «Яшәсен революция!» — дип акырачак. Менә нәрсә ул әзерлексез революция. Хөрмәтов Ядкәр хыялланган революция ул революция түгел, ул ирексезләү, көчләү хәрәкәте генә булып калачак. Әгәр Ядкәрләр җиңә калса, Россияне «грядущий хам» — тупаслык, әдәпсезлек басачак. Россия әле чын революциягә әзер түгел. Мин менә шуннан куркам, Тукай. Әнә шундыйлар Россия халыкларын ялгыш юлдан алып китмәгәе дип, бөтен көчемне, талантымны биреп көрәшәм.

Тукай. Халык аңы үсәр, Шәүлә, Россия революциягә әзер булыр. Җиңәчәк революция. Шул вакытта син нишләрсең икән, Шәүлә? Революцияне буып торучы Шәүлә ни кылыр икән?

Шәүлә. Ха-ха-ха, сабый син, Тукай, валлаһи. Нинди генә булса да, хөкүмәткә өченче отделение кирәк булачак. Любой власть алмашыначак. Без алмашынмабыз. Без яңа властька да хезмәт итә алабыз.

Тукай. Сез урам фахишәләре кебек икән, алайса. Акча түләсәләр, теләсә кем белән йокларга булдыра аласыз.

Шәүлә. Без — принципсызлыкны принцип итеп алган бәндәләр, Тукай. Сез бездәйләрне кимсетә алмыйсыз. Даһиларны даһи иткән — без. Без булмасак, сезнең кадер булмас иде...

Тукай. Күп күрдем мин сафсата сатучыларны, әмма дә ләкин һәр кабахәтлекне бөеклек дип, һәр караны ак дип әйтүчеләрнең синдәен очратканым булмады.

Шәүлә. Кыенлык күрмәгән шәхес зур шагыйрь була алмый. Шагыйрьне биографиясе бөек итә. Ә сезнең биографияне без ясыйбыз. Сезгә кыенлыклар тудыру һәм сезне бөек итү — безнең төп максатыбыз. Булгарин булмаса, Пушкин булмас иде. Булгарин — стимулятор. Булгарин — катализатор. Дошманнары булмаса, Пушкин Пыскин гына булып калыр иде. Пушкин, дошманнарына үч итеп, Булгаринга ачу итеп, аларны таланты белән, әсәрләре белән күмеп ташларга теләп иҗат итә, сугыша, эпиграммалар яза, ягъни үзенә һәйкәл әзерли. Моцарт булмаса, Сальери, шулай ук Сальери булмаса, Моцарт була алмас иде. Герострат кем соң ул? Изге храмга ут төртеп, дан яуламакчы булган бер бәндә. Ә исеме, чыннан да, тарихта калган бит. Ә мин кем соң? Бер шәүлә. Әмма ләкин Тукайны даһи итәргә алынган

шәүлә. Тукай белән беррәттән минем шәүләм дә еллар, гасырлар буе ияреп йөрер...

Тукай. Никадәр көч сарыф ителә, никадәр акча түгелә. Барысы да бер Тукайны бетерер өчен.

Шәүлә. Ялгышасың, Тукай. Тукайны гына түгел, татар халкын бетерер өчен.

Тукай. Татар халкы белән Тукай тәңгәлмени?

Шәүлә. Рус халкының иң зур дошманы — татар. Ә шул дошманның җаны син — Тукай.

Тукай. Татар халкы рус халкына дошман түгел.

Шәүлә. Тукай дошман һәр рус әйберсенә. Диненә, культурасына, халкына... Син татар халкын да руска каршы котыртасың.

Тукай. Мин Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам. Толстойны егылып укыйм. Шаляпинның сәнгатенә гашыйкмын.

Шәүлә. Пушкин да, Лермонтов та монархиягә каршы булган. Шаляпин да күзәтү астында. Ул да — маёвкаларда катнашкан җинаятьче. Шуларга теләктәшлек белдергәнең өчен генә дә, синең муеныңа кызыл камыт кидертергә була.

Тукай. Димәк, без рус халкына тулаем каршы түгел.

Шәүлә. Татар дошман руска. Бар фетнәнең башында татар тора. Разин, Пугачёвлар артыннан сиксән процент татар күтәрелде хөкүмәткә каршы. Бүген дә татар халкы Пугачёвны күтәп ята. Син Пугачёв белән Разиннан да куркынычрак хәзер самодержавие өчен. Менә ни өчен Тукайны изеп бетерү кирәк иде!

Тукай. Пётрның Персиягә походында да, Наполеонга каршы да, Порт-Артур сугышларында да бихисап татар халкы рус җире өчен һәлак булганлыгын сез күрмәмешкә салышасыз, әфәндем. Халыкка каршы халыкларны сез котыртасыз. Татар фетнәче түгел, тыныч вакытта ат кебек, ишәк кебек Россиягә эшләп, сугыш чыкса, җаны-тәне белән Россияне дошманнардан саклаучы тугры эт ул татар, әфәндем. Сез — бөек фетнәнең башында.

Шәүлә. Монысын дөрес әйттең, Тукаев. Бу фетнәләрнең башында — мин. Бикчураны мин шул хәлгә китереп җиткерүче... Дөрес, Сагышлы шагыйрь качты. Бездән алай гына качып котылып булмый. Ул анда озак тора алмас. Театрларын, журналларын ябып бетергәч, өненә егерме чиләк су салган әрләндәй, ул өскә калкачак. Дөрес, Хөрмәтов Ядкәрне дә... урыны җәннәттә булсын... без юк иттек. *(Тукайда кискен үзгәреш.)*

Тукай. Хәзер чират миңамы?

Шәүлә. Хәзер чират синеке, Тукай. Менә сине алырга ордер! Ләкин мин сиңа кагылмаячакмын.

Тукай. Ни өчен? Казылык белән сыйлаганыма күрәме?

Шәүлә. Юк! Син үлемгә хөкем ителгән инде. Мин докторлар белән сөйләштем. Бөтен җиргә телеграммалар сугучы — мин.

һәм Ядкәрне шул телеграмма чакырып кайтарды. Синең соңгы сәгатьләрең, Тукай. Шуңа күрә мин сиңа бөтен нәрсәне ачык сөйләргә тиешмен. Тагын бер хәбәр бар синең өчен.

Т у к а й. Нинди хәбәр? Әйт тизрәк!

Ш ә у л ә. Моннан чыгып киткән туташ үзен-үзе суга ташлаган.

Т у к а й *(сабыр)*. Ялган!

Ш ә у л ә. Хакыйкать, Тукай.

Т у к а й *(шашып)*. Ялга-ан!

Ш ә у л ә. Туташ үзен үзе суга ташлаган!

Тукай бөгелеп төшә. Шәүлә катып кала. Тукай салмак кына тора башлый. Тукай башта тыныч кына көлә. Шәүлә каушап кала.

Әй, кем бар анда? Тукай, сиңа ни булды? Мин шаярдым гына, туташ исән, авылына кайтып китте. Мин юри генә әйттем, Тукай!

Т у к а й *(аякка баса. Шәүләгә туры карый, Шәүлә чигенә)*. Ха-ха-ха, шүрләдеңме, Шәүлә? Юк, мин үлмәдем әле, мин акылдан да язмадым, курыкма... Мин үләсемне докторларга кадәр дә, сиңа чаклы да яхшы белә идем. Син мине үлем белән куркыта алмыйсың. *(Ютәлли.)* Мине бернәрсә дә куркыта алмый хәзер. Мин үлгәч, миннән соң ни булачак? Без түккән бу тирләр, коелган каннар бикяр булырмы? Файдасызгамы бу көрәш? Әйт, күрәзәче шәүлегән... Әйт: нигә куркасың? Минем соңгы сулышым... курыкма, әйт. Әйт: карачкы, ни көтә?

Ш ә у л ә. Синең һәр бәйрәмеңне олылап бөтен Россия, бөтен Европа күләмендә уздырачаклар... Синнән кала Әмирханнар, Рәмиевләр, Кариевлар, Сәхипҗамаллар, Камаллар даһи саналачак.

Т у к а й *(көлә)*. Соң, шулай булгач, мине үлем куркыта аламы? Их син, йолкыш Шәүлә, базар карачкысы Шәүлә, шуннан башка миңа ни кирәк? Әгәр мине милләт, илтифат итеп, искә алса, шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем...

Кыйналып-суелып
Бетмәгән
Шигъри динем, исән бул!
Изелеп-кырылып
Үлмәгән
Татар халкым, исән бул!

1986



Ризван Хәмид
(1941 елда туган)

ҖИДЕ БАҖА[1]
(ике бүлекле драма)

КАТНАШАЛАР:

Күгәй.
Көбра — аның хатыны.
Дая — кызлары.
Искәндәр — төпчек уллары.
Вилена — Искәндәрнең кәләше.
Чуракай — төнге каравылчы.
Дулат — колхоз рәисе.
Сатай — авыл Советы рәисе.

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

I күренеш

Кояшлы җәйге иртә.
Авыл үзәге. Авыл Советы, колхоз идарәсе, культура йорты биналары ярымтүгәрәк ясап урнашканнар. Бер читтә, тирәк агачы янында, постаментта ак җәймә белән бөркәлгән бюст күренә. Мәйданга авыл Советы рәисе Сатай, колхоз рәисе Дулат һәм, кызы белән хатынын ияртеп, Күгәй карт килеп керә. Сатай утыз яшьләрендә, Дулат сакал-мыеклы, күн пиджактан, яшен тәгаен генә әйтүе читен. Шулай да Күгәйнең кызы Даядан шактый өлкән икәнлеге сизелә. Даяга егерме өч-егерме бишләр тирәсе. Күгәйгә җитмеш-җитмеш биш яшь биреп була, Көбра аңардан бик азга калыша.

Дулат *(бераз тантаналы)*. Әнә ул! Ошатсаң — ике көннән ачабыз, ошатмасаң — яңаны заказать итәбез, Күгәй абзый! Килештекме? *(Кулы белән бөркәүле бюстка күрсәтә.)* Һәйкәлең әзер — хет шушы минуттан тантаналы митинг җый!

---

[1] Бераз кыскартылды.

Д а я *(шаян)*. Тез буыннарың йомшармадымы, эти, үз һәйкәлеңне үзең күрәсең! *(Күгәйгә сынап карыйлар, ул җавап бирми.)*

Д у л а т *(Даяның шаяруын күтәреп алгандай, кулын аның җилкәсенә куя, кыз игътибар итми)*. Чынлап та, Дая, син хаклы, ахрысы! Әтиең телсез калды! *(Көлә.)*

С а т а й. Нахакка төрмәгә алып киткәндә дә сер бирмәгән Күгәй абзыйның да телсез калыр көне булыр икән! *(Даяга ярымшелтә белән пышылдый.)* Минем белән коры сөйләшүеңнең сәбәбе аңлашыла хәзер... *(Читкәрәк китә.)*

К ү г ә й *(кискен, беркемгә дә адресламыйча)*. Искә төшерүегез өчен рәхмәт!

К ө б р а *(килештерергә теләгәндәй)*. Җыйнаулашып төрттерергә ашыкмагыз әле, Сатай. Һәйкәлне күрик башта... *(Кызын җиңелчә шелтәләп.)* Урамда икәнеңне онытма, Дая кызым. Адәм сыман кылан.

Д у л а т *(уңайсызланып, кулын Даяның җилкәсеннән ала)*. Нәкъ үз ирең, Көбра апа! Суйган да каплаган. *(Сатайга ымлый.)* Менә Совет власте алдашырга ирек бирмәс. Сатай башлап йөрде.

С а т а й. Пар чыкканчы чабарга туры килде, анысы. Махсус Казанга барып эшләттек. Дулат скромничать итә, ул үзе дә Казан юлын ике мәртәбә урады... *(Киная белән.)* Чабуын чаптык, әҗере булырмы, юкмы — белмәгән әлегә... *(Күгәйгә ымлап, Дулатка төртә, карт ни әйтер, янәсе.)*

К ү г ә й. Турайда элегрәк бер председатель барые. Труддинга түләү башланугa, бөтен йорт буенча йөреп чыга торган иде: ул ипи өләшкән, янәсе, хәзер сезнең чират аны сыйларга...

Д у л а т. (...) Картыңның яңа костюмын үтүкли башла, Көбра апа! Үзебезнең район җитәкчеләреннән башка, Казаннан да киләчәкләр. (...)

С а т а й. Курыкма, Күгәй ага! Ошатмасаң, скульпторны якасыннан сөйрәп китереп, икенчене ясатабыз. Тегенди-мондый гына нәрсә түгел ул! Зур акча тора.

К ү г ә й *(чынлап та, уңайсызланып калган сыман, тик сер бирми)*. Хәтерем ялгышмаса, Күгәй абзаң үстергән чөгендерне бер җепкә тезсәң, Җир шарына билбау итеп бәйләп куеп булыр иде дип, син язып чыккан идең кебек, Сатай энем? Тик, нишләптер, ул «бил каешының» бәясен ачыкламагансың.

Д у л а т. Дөрес, Күгәй абзый, һәйкәл бәясе чаклы гына бар!

К ө б р а *(иренең сүзен җөпләгәндәй)*. Әйдә, үзең ач, булмаса, Дулат энем. Син — колхоз председателе.

Д а я. Их, эти, эти! Ат кебек камыт киеп эшләргә дигәндә — син иң алдан! *(Һәйкәл янына килә һәм ак материалны бәйләгән бауны чишә. Бөркәүнең бер читеннән тота.)* Бер, ике...

Дулат, Сатай *(беравыздан аңа кушылалар).* Өч!

Дая ак бөркәүне тартып төшерә, постамент өстендә ботаклы-чатаклы гап-гади агач түмәре тора. Постаментка алтын хәрефләр белән татарча һәм русча:

«Ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое
Гыймазетдинов Күгәй Сәет улы

Дважды Герой Социалистического Труда
Гимазетдинов Кугай Саетович»,—

дип язылган. *(Бермәл өнсез торалар.)*

Дая *(беренче булып аңга килә һәм кычкырып көлеп җибәрә).* Ничек, һәйкәлең шәпме, эти?!

Дулат. Ни дигән сүз бу? *(Сатайга карый.)*

Сатай *(җилкәсен җыера).* Берни аңламыйм, Дулат... Башка сыйдыра алмаслык хәл! Кичә кичтән урынында иде ич... *(Постаментны кулы белән капшап карый.)* Шөрепләрен сүтеп алып киткәннәр, кабахәтләр!

Көбра *(Дулатка).* Каравыл куймаган идегезмени?.. *(Сатай белән Дулат, «ничек инде?» дигәндәй, аңа аптырап карап куялар.)*

Сатай. Ниткән каравылчы?.. Туктале, Көбра апа. Бөтен мир күзе алдында торган нәрсә ич!

Көбра *(кырт борыла).* Әйдә, атасы! Без мондый мыскылга күнекмәгән.

Дулат. Мда!.. Менә сиңа тантаналы митинг. *(Көбра китәргә кыймыйча тора.)*

Дая *(шаяруын дәвам итә).* Кайгырмагыз, җитәкчеләр, һәйкәле табылмаса, митинг вакытында постаментка этинең үзен бастырып куярбыз! *(Сатай кычкырып көлеп җибәрә һәм, Дулатның ачуланып каравын күреп, тотлыккандай тынып кала.)*

Көбра. Көл, көл, Сатай энем... Хәзер көләргә генә калды бит.

Күгәй *(Дулатка).* Нишләргә уйлыйсыз, Дулат энем? *(Постаментка ымлый.)* Цементы катып өлгермәгәнгә охшый, сүтүе кыен булмас. Халык алдында оятка калмас өчен.

Сатай *(урынсыз көлгәне өчен аклангандай).* Ничек инде сүтәргә, ди?! Бөтен дөньяга шаулаганнан соңмы?!

Күгәй. Шауламаска кирәк булган икән шул.

Дулат. Чарасын табарбыз, Күгәй абзый. Борчылмагыз. Тик мине бернәрсә гаҗәпләндерә: нүжәли... авылдашларыгызның эше?

Сатай *(ашыгып).* Тузга язмаганны! Күгәй абзыйга да үч саклаучы булса безнең авылда! Белмим инде...

Көбра. Көнләшүчеләр беткәнмени!

Күгәй. Нәрсәдән?! Юкны лыгырдама әле син дә.

Д у л а т. Алда башланмаган ике көн бар, табылыр.

К ү г ә й. Халык белән җыйнаулашып, бөтен тирә-якны актарып чыксагыз гына инде. *(Көбрага.)* Әйдә. *(Күгәй белән Көбра китәргә кузгалалар.)*

Д а я *(шаяруга бора)*. Менә сезгә беренче җитди сынау, иптәш яңа председатель! Четерекле хәлдән ничек чыгарсыз икән? Тора-бара үзен тагын да күрсәтер әле безнең авыл. Начало интересное! *(Культура йортына кереп китә. Ике рәис постамент янында басып кала.)*

С а т а й *(алар югалгач, аптыраганнан)*. Туктагыз әле, Күгәй ага, Көбра апа!

Д у л а т. Туктатып ни әйтмәкче буласың аларга?! Әйдә, тот! *(Ак бөркәүгә тотына.)*

С а т а й. Нишлибез?

Д у л а т. Ябып куябыз. *(Постамент өстеннән агач тумәрне алып ташлый. Постаментны ак бөркәү белән ябып, бәйләп куялар.)*

С а т а й. Вәт «чепе» дисәң дә «чепе» бу! Районда ишетсәләр!.. Район гынамы — югарыракта?! «Голос Америки»га барып җитәрлек факт бу! Анда җитсә, баш бетте дигән сүз!

Д у л а т. Кем иде бүген төнге каравылда?

С а т а й. Шул Чуракай карт инде бездә бердәнбер төнге каравылчы. Кибетне дә ул саклый, конторларны да... *(Кул селти.)* Аның саклавы, ташка үлчим! Сельсовет приёмныена кереп йоклый, бөтен эше шул.

Д у л а т. Кеше йөгерт, чакырсыннар. Үзең дә тирә-күрше йортлар буенча йөреп чык: алай-болай шикле кеше күрмәделәрме икән? Бөтен кәҗә-сарык кара төнгә чаклы шушы тирәдә ауный, мал-туарын эзләүчеләр булгандыр... Көн дә һәйкәл салмыйбыз, игътибар итми калмаслар.

С а т а й. Ай-һай, шикләнәм: элек кенә ул хатыннар көтүдән кайтмый калган сарыкларын эзлиләр иде, хәзер кәҗә-сарыкта түгел кайгылары. Эчеп йөргән ирләрен табалмый интегәләр!

Д у л а т. Участковыйны да җигәргә туры килер, ахры.

С а т а й. Кая ул!.. Ул бит шундук районга җиткерәчәк! Бала-чага эше булуы мөмкин. Күгәй абзыйга берәрсе үч иткән, дияр идең... Дошманнары юк бугай... Хотя... Кем белә!

Д у л а т. Парторг та ялда чак, җитмәсә! *(Колхоз идарәсе ягына юнәләләр.)*

С а т а й. Син — бездә яңа кеше. Ә авыл халкы... Бер-берсенең кендегенә кырыкмаса-кырык төен аша үзара бәйләнгән.

Д у л а т *(кинәт)*. Нинди төрмә турында сөйләндең син бая? Күгәй абзый төрмәдә утырган кешемени?

С а т а й. Ә, Сталин заманнарында булган хәл ул. *(Тирә-ягына каранып пышылдый.)* «Наганым булса, Сталинны атып үтерер

идем, дип әйтте»,— дип, өстеннән донос язганнар, имеш. Үзе теләп төрмәдән прәме сугышка китеп кенә исән-имин котылды ул Күгәй абзый.

Д у л а т. Нигә пышылдап әйтәсең аны? Һаман өркәсең, ахры?

С а т а й. Алай димә, дөнья бу!.. Кем белә: бәлки, шул адәм актыгы әле дә исәндер.

Д у л а т. Исән булса?

С а т а й. Сакланганны саклармын, дигән. *(Көлә.)* Җаны көяр дә шул: Күгәй агай төрмәдә дә утырды, ике мәртәбә Герой исеме дә алды! Өстәвенә үзе исән чагында һәйкәл салып ятабыз.

Д у л а т. Пионер лагеренда берәрсе бармы әле?

С а т а й. Бар бугай.

Д у л а т. Күгәй абзый дөрес киңәш бирә безгә. Трай тибеп йөргән өлкәнрәк малай-шалайларны шуларга өстә дә конкрет задание куй: Кыдашның бөтен чоңгыллы урыннарын, тал-тирәкле тугайларын актарып чыксыннар. (...) Каравылчы картны чакыртырга онытма. Мин Дүртбога урманнарын тикшерүне оештырам. *(Колхоз идарәсенә кереп китә. Сатай авыл Советына юнәлә. Культура йортыннан Дая чыга.)*

Д а я *(Сатайга кычкыра)*. Сатай абый!

С а т а й *(туктый)*. Нәрсә, Дая?

Д а я. Нишләргә уйлыйсыз инде хәзер?

С а т а й. Нишлик? Эзлибез. Тапмасак, милициядән тикшертәбез.

Д а я. Әти урынында булсаммы мин!

С а т а й. Нишләр идең?

Д а я . Хөкүмәт карарында һәйкәл әтинең туган җиренә куелырга тиеш, диелгәнме? Диелгән! Ә әтинең туган җире — Аксаковка посёлогы. Димәк, ничу хөкүмәт карарын бозарга! Ташландык авылга куеп, оятка каласыгыз килми икән, авылны рәтләгез. Кара, ничек әтинең башына килмәгән бу фикер?! Кайткач котыртырга кирәк әле үзен.

С а т а й *(чынга ала)*. Соң... һәйкәле монда — колхоз үзәгендә куелуын атаң алдан белеп торды ич! Күптән монда яшисез, монда эшлисез! Ә туган авылыгызда, ачуым килмәгәе, биш-алты йорт калды. Шуңа анда куйдыртасы килмәгән, димәк.

Д а я. Ни дип әйтсен соң ул сезгә?! Бүләк атның тешенә карамыйлар.

С а т а й. Эш узган бит инде! Постамент куелган, һәйкәле әзер! Район җитәкчеләре белән килешенгән.

Д а я. Бер дә узмаган әле! Башта һәйкәлегезне табыгыз! Табылгач та соң түгел. *(Хәйлә белән.)* Зурга җибәрәсем килсәме?.. Наглый рәвештә Верховный Совет карарын бозасыз! *(Шатланып.)* Бик әйбәт булды әле бу. Утлы табада биетәм мин сезне хәзер! Нәрсә сорап керсәм дә кире бора идегез!

Сатай. Кайчан кире борганыбыз бар? Видеомагнитофон алалмыйбыз, дидек, анысында син хаклы. Баегач, ул да булыр.

Дая. Юк инде. Хәзер аның белән генә котыла алмассыз.

Сатай. Тагын нәрсә кирәк?

Дая. Мине... Культура йортына директор итеп куясыз!

Сатай *(бермәлгә исе-акылы китеп тора)*. Уһу, кызый! Менә бу хватка, ичмасам! Сорагач-сорагач, сразы патша кызы булырга телим, диген инде син аны!

Дая. Миңа ике мәртәбә Герой кызы булу да бик җиткән! Нигә өнсез калдың? Кыл да кыймылдатмыйча, зарплата алып утырган Мәмдүнәдән кай җирем ким минем? Ул культпросветшкола бетергән, мин — культура институтын! Мин көне-төне эш артыннан чабам, ә ул ыжлап та бирми! Җитмәсә, минем өстән төрле гайбәт таратып ята икән. Бер тинтәк хатын кулы астында җан көйдереп утырасым килми!

Сатай. Бу сүзләреңне Мәмдүнә үзе ишетсә?

Дая *(чаялык белән)*. Ишетсен! Кирәк икән, йөзенә дә чатнатып бәреп әйтәчәкмен мин аңа! Читләтеп тормам!

Сатай. Мәмдүнә үзе — ладны инде. Иренең парторг икәнен оныткансың, ахры, кызый.

Дая. Их син, Совет власте, имеш! Безнең илнең исемен онытмадыңмы әле? «Советлар Союзы» дип атала ул! «Парторглар Союзы» дип түгел! Димәк, авыл Советы председателе — баш, парторг муен булырга тиеш дигән сүз. Барып җиттеме?

Сатай. Әллә ниләр сөйли башладың әле син, кызый! *(Баш чайкый.)* Менә кешене әйбәт беләм дип йөре...

Дая *(киная белән)*. Моңа кадәр миңа такылдаган сүзләреңнең чыны-ялганы шунда ачыла инде, Сатаетдин әфәнде!

Сатай *(дәртле караш белән)*. Чәчәкне матурлык харап итә, Дая! Ут белән уйныйсың, кызый!

Дая. Ә син пешүдән куркасыңмы?

Сатай. Мин нәрсә... Мин егет кеше. Кызлар куркырга тиеш.

Дая *(көлеп җибәрә)*. Егет кеше?! Утызга җитепме?! Утызга җитеп тә егетлеген күрсәтә алмаган «егет кешедән» ары ни өмет итәргә кирәк! Уйламыйча ычкындырдың бу сүзне, Сатай абый, бүтән кызлар ишетә күрмәсен — мәңге өйләнә алмый картаерсың!

Сатай *(кыюланып)*. Нишлисең бит. Авылның бөтен чибәрләре читтән килгән күн пинжәкләр тирәсендә бөтерелгәч! Кызарып пешкән бар алманы алар беренче булып өзә тора. Инде синдә генә якты өмет калды! Соңгы сүзеңне көтәм, Дая...

Дая *(сүзне кинәт икенчегә бора)*. Димәк, килештек?

Сатай. Нәрсә турында килештек?

Д а я *(шаян)*. Урак ургач, кибән коргач, туйларда биергә!

С а т а й. Ә кем туенда?

Д а я. Кем тәвәккәл, шул башлап туй ясый инде, Сатай ага! Директорлык турында чынлап уйларга киңәш итәм. Кара аны, колхоз председателе инициативаның кемнән чыкканын белмәсен! Сүз ике арада калсын. *(Культура йортына кереп китә.)*

Сатай бер урында таптанып кала. Мәйданга төнге каравылчы Ч у р а к а й карт килеп керә. Аның башы бинтка уралган.

Ч у р а к а й. Авыл влачына яшьләрдән сәлам. Нихәл, яшьти! Нишләп, үпкәләп, анасының имчәгенә артын терәгән бозау шикелле, сельсәвитең төбендә катып торасың?

С а т а й *(сискәнә)*. Ә, Чуракай абзый! Нәкъ менә син кирәк идең. Күгәй кордашыңның һәйкәле кайда?!

Ч у р а к а й *(ваемсыз)*. Сатып эчтем. Нинди разбуйник башыңны ярды, дип сорамый! Әйдә, мөһереңне сугып, акты төзеп җибәр әле тиз генә! *(Авыл Советының ишеген ача.)*

С а т а й *(Чуракайны туктата, катгый рәвештә)*. Мин чынлап сорыйм синнән! *(Җилкәсеннән тотып, һәйкәл ягына таба бора)*. Әнә кара!

Ч у р а к а й *(кинәт бөтерелеп, Сатайның кулыннан ычкына)*. Кулыңа ирек бирмә! Ишь! Мода алганнар!.. Хатыныңны бөтергәләрсең. Өйләнергә җөрәгең җитсә... *(Ниһаять, ак бөркәүле һәйкәлгә карый.)* Бәрәч! Аягүрә төш күрәмме әллә! Күгәй кордашның акурат башын кискәннәрме дисәм?! Ә бит алдан ничә әйттем мин аңа, куйдырма, дидем. Җүнлегә бетмәс, минәйтәм. Үлгәч, кабереңөстенә куярлар әле! Колагына да элмәде. Ярый әле, Хуҗа Насретдин әйтмешли, җилкәсендә тагын бер башы бар! *(Көлеп, һәйкәл янына юнәлә.)*

С а т а й *(ду килеп, аның артыннан иярә)*. Уен түгел бу, Чуракай абзый, җавап бирергә әзерлән!

Ч у р а к а й *(ак бөркәүне чишәргә тотына)*. Борычлама әле! Нүжәли бармак илле бакырны кисәргә базнат иткәннәр?! Атчаянный егетләр бар икән әле дөньяда!

С а т а й. Ачма, ачма! Хәзер кеше җыелачак!

Ч у р а к а й. Җыелса ни? Гласныс заманы хәзер! *(Ачып ташлый.)* Фьиют! Эш башы белән генә бетмәгән монда, бөтен гәүдәсеннән җилләр искән! Баш биреп кенә котыла алмаган, димәк, Күгәй кордаш! Әйттем бит! Справидливыс бар ул, дидем. Баемас кояш юк бу дөньяда.

С а т а й *(ачуы килеп, ак бөркәүне Чуракайның кулыннан тартып ала)*. Нинди справедливость турында ләчтит сатасың тагын?! Нәрсә бутыйсың? Төнлә ни карадың, син миңа шуны әйт?! Башыңны тилегә салып торган буласың!

Ч у р а к а й. Җөдәтмәле! Нарат сагызы кебек бәйләнде инде. Кызлар янында гүләйт иттем! Синең кебек, тумас борын картаймаган әле мин, Сатайка энем! *(Алар янына, идарәдән чыгып, Дулат килә. Дулатка.)* Әйт әле шушы димагукка, персидәтел: нигә бәйләнә ул миңа, ә?! *(Сатайга.)* Мин нәрсә, синеңчә, төнге каравылчы дигәч тә, бакыр Күгәйне кочаклап утырырга тиешмени?! Алдан уйла, аннан сөйлә!

Д у л а т. Әкренрәк! Кычкырышмыйча гына. Б'ген төнлә каравылда сез тордыгызмы?

Ч у р а к а й *(ул шактый кыза төшкән)*. Торсам? Шуннан?!

С а т а й. Шулай булгач! Аңгыра сыман кыланасың!

Ч у р а к а й. Күкле-җәшелле тавышың белән кытакламале монда! Вәт перәшке!

Д у л а т *(аларны тынычландырырга тырыша)*. Ашыкма, Сатай. *(Чуракайга.)* Һәйкәлнең кичтән куелганын белдегезме?

Ч у р а к а й. Аңа килсә, белү генә түгел, үзем куештым!

Д у л а т *(коры)*. Сез — төнге каравылчы. Җаваплы кеше. Юридик яктан җаваплы. Сез постта чакта авылның үзәк мәйданыннан һәйкәл югала. Димәк...

С а т а й. Өр-яңа һәйкәл! Энә түгел бит ул!

Ч у р а к а й. Җугалса?

Д у л а т. Ничек инде — җугалса?

Ч у р а к а й. Җугалса булганга — җугалса! Җә, әйтегез әле, кем мине һәйкәл каравылларга җаллады? Җиңел генә, гаепсезгә җәза бирмәкчеләр! Нәрсә өчен башым белән җавап бирергә тиешлегемне бик җахшы беләм мин. Теләсәгез, хәзер үк раслап күрсәтәм. Минем өстә кибет — бер булдымы? Тагын сельсәвит — икеме? Аннан килеп, калхуз кәнсәләре — өчме! Һәм бетте-китте и вәссәлам!.. Калганында эшем җук! Шылдымы?

С а т а й. Син безнең алда бакча киртәсенә кысылган кәҗә күк боргаланма, Чуракай абзый! Син җаваплы монда барысы өчен дә. Каравылчы итеп куйганнар икән — будь добр, яхшылап каравылла! Бүген төн энә табарлык якты булды.

Ч у р а к а й *(кәҗә тоягы күрсәтә)*. Менә моны күрдеңме, энекәем? Буд добр, имеш! Акыллы баш килгән! Акка кара белән җазылган килешү дагауры бар минем кесәдә, төшендеңме? Төшенмәсәң, тагын да ачыграк итеп төшендерә алам.

Д у л а т *(Чуракайның хаклы икәнлеген аңлый)*. Мда... Ә башыгызга ни булды?

Ч у р а к а й. Ни булсын! Егылдым. Менә бу хәчтрүш димагуктан акты төзетмәкче идем.

С а т а й *(кызып)*. Сүзеңне үлчәп сөйләш, Чуракай абзый! Перәшке булып мин нишләгән?!

Д у л а т *(аны бүлдерә)*. Кызмый тор... *(Чуракайга.)* Бәлки, төнлә берәр шикле кеше күренгәндер сезгә? Ул-бу сизелмәдеме?

С а т а й. Каян сизсен ул! Эшенә килүгә, сельсовет приёмныена кереп бикләнә дә гырлап йокыга чума!

Ч у р а к а й *(тыныч).* Чумсам? Анда синең ни эшең бар? Кибетләрнең исән-иминлеге өчен син җавап бирмисең ич! Чуракай абзаңны куркытма: син гаурәтеңне кешедән җәшерергә өйрәнеп җөргәндә, минем оныкларым аналарының имчәкләрен имә иде инде! *(Дулатка.)* Аңлат әле шушы адәм тәганәсенә: канымны кыздырмасын, читкәрәк китеп торсын! Җукса мин аны... *(Кинәт ажгырып ташланып, Сатайның якасыннан эләктереп ала һәм буе җитмәгәч сикереп-сикереп кычкыра.)* Читкәрәк китеп тор, диләр сиңа! Читкәрәк кит! Читкәрәк! Олылар сөйләшкәндә! Җәшең баш әлегә! Мин сугышта контужен кеше! Буташтырма мине!

Д у л а т *(аларны аера).* Чү! Чү! Сугышалар, диярләр! Тезгенеңне бушата төш, Сатай! Бар, сөйләшкәнне оештыра башла. *(Сатайны куып җибәрә.)* Бар, бар!

С а т а й. Икенче вакытта бүтәнчә сөйләшербез без синең белән, Чуракай абзый! *(Бармак янап, авыл Советына кереп китә.)*

Ч у р а к а й *(көтелмәгән тыныч тавыш белән).* Һаман гайрәт ора! Да, нинди җәш үзе, ә уже нервный. Сельсовет председателе димәссең. Булса да булыр икән. *(Дулатка таба борыла.)* Мин үзем болайрак уйлыйм, иптәш персидәтел: бәгъзе берәүләр, куеп өлгергәнче үк, һәйкәлне урлаганнар. Мир күргәләгәнче. Хикмәте дә шунда. Аңлашылмадымы? Ызначит, Күгәй кордашны һәйкәлгә недастуен санаучылар бар! Һәр агуның даруы була. Астыртын нияткә охшамаган бу. Нindидер хикмәт бар монда.

Д у л а т. Туктагыз әле... Достоенмы ул, түгелме — аны Совет хөкүмәте хәл иткән инде! Илле иләктән узган аның кандидатурасы. Күгәй абзый кебек кешеләргә алтын һәйкәл дә җәл түгел!

Ч у р а к а й. Шалишь, брат, мин ни сагласен!

Д у л а т. Менә ничек?

Ч у р а к а й. Шулай, иптәш персидәтел. (...) Күгәй кордашка һәйкәл куясыз. Ә кем ул? Мин үзем, җәшермим, тач кына әйтеп бирә алмас идем!

Д у л а т. Гомерегез буе бергә яшәпме?!

Ч у р а к а й. Ызначит, шулай килеп чыга, энем! Сиңа кадәр, ишеткәнсеңдер, шәт, җиде персидәтел кимерде безнең калхузны. Димәк, җидесе җиде төрле эш иткән дигән сүз. Ә без нишләргә тиеш идек? Җидесенә дә: «Баш өсте!» — дип торыйкмы?! Шалишь, брат! Минем үземнең баш чүлмәгемдә дә кайбер нәрсәләр кайный. Җидегезгә дә җарап җәши алмыйм мин.

С а т а й *(авыл Советыннан чыга).* Чуракайның әкияте бетмәс анда, Дулат! Пионерларга шалтыраттым: «Ура!» — кычкырып риза булдылар. Радио аша халыкка хәбәр итәм. Вакыт уза бит.

Дулат. Ашыкма.

Чуракай. Ә нигә? Игълан итсен. Ихтималның ихатасы киң.

Дулат *(коры)*. Безнең вазифага керәсез түгелме, Чуракай абзый? *(Сатайга «кит» дип кул селти. Сатай авыл Советына кереп китә.)* Һаман да тел төбегезне аңлап бетермәдем әле, Чуракай абзый.

Чуракай. Әйтеп торам ич: мин үзем, җәгъни мәсәлән, Күгәй дуска памятник куюга — катигарически!

Дулат *(ирексездән көлеп җибәрә)*. Менә сиңа дус!

Чуракай *(үпкәләми)*. Көнләшә икән, дисеңдер. Бер дуңгыз гына көнләшә белми. Ләкин бу бөтенләй бүтән нәрсә! Үз башың бар. Акылың да бар сыман. Минем сүзләрдән үзең нәтиҗә ясаса, энем. *(Китәргә кузгала.)*

Дулат. Стоп, стоп, ашыкмагыз, Чуракай абзый! *(Чуракай туктый.)* Күгәй абзый һәйкәлгә лаек түгел, сезнеңчә?

Чуракай. Ник лаек булмасын? Бик лаек! Ике җолдызына да кул куйдым. Ихластан. Үгез кебек җигелеп эшләде, ат кебек карусыз булды. Начар җулда йөрмәде. Тагын ни кирәк?

Дулат. Шулай булгач!

Чуракай. Җолдыз нәрсә ул! Әнә үзбәк Рәшидов аны бер шешә аракыга сата торган булган. Куе каш Брежнев белән икәүләп. Анысы да татар булып чыкты бит әле! Бәдретдиновлар нәселеннән булган икән ул. Урыслашкан. Үз дененнән ваз кичкән кешедән өмет чыгамы? «Наука и жизнь» журналы җазып чыкты. Тәкыштү, җолдыз түшкә таксаң — бар ул, такмасаң — җук. Ә һәйкәл — бөтенләй башка катигури. Уйланырга киңәш итәм.

Дулат. Кызык...

Чуракай. Кызык шул! Баскычны җугарыдан себерә башлыйлар, персидәтел. Беләсеңме нәрсә? Син Күгәй кордаштан элеккеге персидәтелләр турында сорашып кара. Зерә дә кызык кешеләр иде алар! Җиткермәделәрме әле куштаннарың? Җиткермәгән булсалар, миннән ишетүең әйбәтрәк тә. Гурты белән Күгәйнең раднуй кияүләре иде алар. Җиде бажа, ызначитсә. Җиде бажаны бер бүре ашаган, диләрме әле? Ә бездә киресенчә килеп чыкты: җиде бажа бер бүрене ашады.

Дулат. «Бүре» дигәнегез кем була?

Чуракай. Ә менә анысын үзең ачыкла инде, персидәтел энем. *(Китәргә кузгала.)*

Дулат. Тагын бер генә сорау, Чуракай абзый. Нәрсә ул «перәшке»?

Чуракай. Шуны да белмәгәч! Пар атка өстәп җиккән ат була. Иярчен сыман, тагылып җөрүче дигән сүз!

Китә. Дулат колхоз идарәсенә кереп китә. Мәйданда беразга тынлык урнаша. Машина тавышы ишетелә. Мәйданга Искәндәр белән Вилена килеп керә. Кулларында кечерәк чемоданнар, автобустан төшеп калган булырга тиешләр.

Вилена *(тирә-ягына каранып)*. Гүр тынлыгы... Сәгать ничә, Искәндәр?

Искәндәр. Сигезенче ярты. Халык кырдадыр инде. Авыл халкы бер караңгыда тора, икенче караңгыда ята, Вилена. Күнегә башла. Язылмаган закон буенча, авыл хатыннары ирләреннән соң ятарга, алардан алда торып, иртәнгә кайнар аш әзерләргә тиеш. Такой образ жизни устраивает вас, мадам?

Вилена. Ә сине?

Искәндәр. Мине?.. Мине син устраиваешь. *(Елмая.)*

Вилена. Хәйләкәр син! *(Бармак яный.)*

Искәндәр. Әйдә, бөтенләйгә монда кайтабыз.

Вилена. Не дури, Македонский!

Искәндәр. А что?.. Здоровье өчен иң главное нәрсә кирәк? Солнце, воздух и вода! Ә монда өчесе дә бар. Причём в первозданном виде. Тагын ни кирәк?

Вилена. Син — серьёзно? Авылда яшисем килсә, Дулатка ияргән була идем мин.

Искәндәр. Дулатның бөтенләй икенче мәсьәлә! Аңарда — карьеризм.

Вилена. Дулатны мин бөтенләй дә осуждать итмим. Ә может, карьеризм түгелдер аңарда? Деловитостьтыр? Просто... дөньяда ул минем өчен юк хәзер. Чөнки дөньяда син бар, Искәндәр. *(Сүзне икенчегә бора.)* Ну так, сөйлә, Македонский: зачем приезжал сюда вчера?

Колхоз идарәсеннән Сатай белән Дулат чыга. Аларны күргәч тынып калалар.

Дулат *(бераз каушап)*. Вилена?!

Вилена *(үзен чагыштырмача тыныч тота)*. Мин, Дулат. Исәнме?

Дулат. Син ничек... хәбәрсез-нисез монда?

Вилена. Шулай, Дулат. Таныш бул: Искәндәр. *(Искәндәргә.)* Дулат.

Дулат *(шат)*. Сез дә безгә кунаккамы?

Искәндәр. Исәнмесез. *(Баш ымлап исәнләшә. Сатайга.)* Нихәл, Сатай? Яшәреп буламы?

Сатай *(ачык күңел белән күрешә)*. Һу, Искәндәр! Молодец! Кайтып шәп иткәнсең! Ишетеп кайттыңмы? Без, понимаешь, монда атаңа һәйкәл куеп ятабыз — синнән хат-хәбәр дә юк! *(Дулат аның бу сүзләреннән соң кинәт Искәндәргә күтәрелеп*

карый.) Берсекөнгә иртән тантаналы митинг. Тик аяк астыннан «чепе» килеп чыкты бит әле, парин. Һәйкәлне урлаганнар. Таба алмыйча, утка баскан кебек, тудим-судим чабабыз... Синдә да кушылырга туры килер, ахры...

Искәндәр. Күз күрер әле. Вилена, мин сине көтәм.

Вилена *(әйле-шәйле)*. Хәзер, Искәндәр...

Дулат *(гаҗәпләнеп)*. Ничек?.. Вилена, мин берни аңламыйм... Ничек ул сине көтә?! Вилена! *(Виленаны җилтерәтә.)*

Вилена *(тыныч)*. Шулай, Дулат. Күпме сузарга була? И зачем? Что толку? Дулат, мин... рәсмиләштерергә дип кайттым. Сезнең авыл Советында мөмкинме ул эш?..

Дулат *(салкын)*. Димәк, соңгы сүзең шул?

Вилена *(елмая)*. Ул гына түгел. «Соңгы сүзем» минә каршында басып тора — Искәндәр. *(Дулат сүзсез кала, Сатай ничек аңларга да белми.)* Вакытсыз йөриләр, дисәң... Ашыкмаска мөмкин. Без ике көнгә кайттык.

Сатай. Нигә сузарга? Бүген үк хәл итеп куябыз. Калган эшкә кар ява, диләр. Тем боли, иртәгә ыгы-зыгыдан баш чыкмаячак. Митингысын әзерләргә, тегесе-монысы дигәндәй. Һәйкәлне таба алсак, әлбәттә! Я, сузмагыз, гозерегез нинди?

Дулат *(Вилена җавап биргәнче әйтеп калыйм дигәндәй, ашыгып.)* Яхшы. Кичке якта кил... килегез.

Вилена. Рәхмәт, Дулат. Ике көнгә генә булса да түзәргә тырыш, зинһар, ярыймы? Күперләр яндырылган. Кабат төзәтелә алмавын икебез дә әйбәт беләбез. *(Искәндәргә таба борыла, шат күренергә тырышып.)* Әйдә, Искәндәр, предкиларыңны күрсәт!..

Искәндәр белән Вилена китәләр. Алар югалгач, Дулат, ыңгырашкандай итеп, идарә ишеге төбенә утыра.

Сатай *(җилкәсен җыера)*. Син берәр нәрсә аңладыңмы, Дулат? Кем ул Вилена дигәне? Зерә чибәр нәмәрсә күренә, чукынчык! Күгәй малаена ияреп кайткан, ахры.

Дулат. Минем хатын... иде.

Сатай *(башына күсәк белән суккандай, артка чигеп куя)*. Кит аннан?! Әйтәм аны! Нишләп әле атасының һәйкәле урлануына исе дә китмәде моның дип гаҗәпләнгән идем аны! Юкәдә икән чикләвек!.. Инде нишләргә уйлыйсың?

Дулат. (...) Законлаштырырсың.

Сатай. Анысы — сама собой! Формалист түгел Сатай дустың... Күгәй абзыйның һәйкәлен әйтәм мин. Аңлагансыңдыр: хатыныңны тартып алган кеше — аның малае ич! *(Дулат дәшми.)*

II күренеш

Күгәй картларның йорты. Гади крестьян хуҗалыгы. Бары тик бернәрсә игътибарны җәлеп итә: Күгәйнең хуҗалыгында крестьяннарча пөхтәлек җитенкерәми. Гадәттә, шундыйрак шыксызлык вакытлыча яшәгән урыннарга хас була.

Күгәй карт ишегалды түрендә «бозау сыйрагы» көйрәтеп утыра...

Көбра чыга.

Көбра *(бот чабып)*. Кая олакты икән бу, дисәм!.. Тартмале шул сасы нәмәрсәңне! *(Картның авызыннан тәмәкесен тартып алып җиргә ташлый һәм таптый.)* Кайгысы беткән берәүнең! Бөтен дөньясы ал да гөл! Перседатель шалтыратты: үзебез эзлибез, ди. Йомып калырга телиләр, ахры!

Күгәй. Мин нишләргә тиеш, синеңчә?

Көбра *(җен ачуы кабара)*. Нишләргә тиеш?! Тирескә баткан абзарыңны саклап утырырга тиеш! Сорап тора ишшу! Чаң сук! Бөтен нәчәлствоны аякка бастыр! Кирәк булса — Казанга кадәр җит! Кемне мыскыл иттерәләр: минеме, синеме?!

Күгәй. Укытучы икәнлегеңне бик тиз оныткансың, ахры, карчык. Пенсиягә чаклы гына җиткән бугай сабырлыгың.

Көбра. Дивана булып кыланып утырма инде, ичмасам. Мин булмасам, йолдызларың да тәтеми иде ич сиңа! Йөрер идең шунда... Кем ни кушса, шуңа баш өсте дип!

Күгәй. Йолдызларыңны моннан соң үзең тагарсың инде, алай булгач. Мин каршы түгел. *(Елмая.)* Юләр син. Дөньяда бер генә нәрсә кадерле.

Көбра. Нәрсә инде ул, синеңчә?

Күгәй. Яраткан эш!

Көбра. Яңалык ачты берәү! Ат гомер буена эшли әнә! Ыштансыз йөри!

Күгәй *(көлемсери)*. Ыштанлы атлар да буламыни дөньяда?

Көбра *(дулап)*. ...Телефоның бар бит! Райком секретарена шалтырат! Аларга нәрсә? Сүз генә таралмасын!

Күгәй *(тыныч)*. Ни өйрәткәнеңне үзең белмисең, ахры, карчык. Мин хәтта лагерьда да әләкче булмадым. Бугазга пычак терәгәндә дә! Барып төшкән көнне үк өч сәгать буе тәпәләп караганнар иде.

Көбра *(исе китеп)*. Моңарчы әйткәнең булмады ич!

Күгәй. Кырык сират күпере аша уза анда кеше...

Көбра. Ә нигә кыйныйлар?

Күгәй. Сынаулары. Таянырга буламы миңа киләчәктә, юкмы?.. Иң курыкканнары әләкчедән иде. Чөнки утыручыларның күбесе шул әләкчеләр аркасында лагерь шулпасы чөмерә. Кайсысын җан дусты саткан, кайсысын — яшерен дошманы. Кыйнамагыз дип ялварсаң, бөтенләй адәм мәсхәрәсе итәләр...

К ө б р а. Анысы ничек?

К ү г ә й. Җыйнаулашып өстеңә пес итәләр дә башта... Барак ишеге төбенә чыгарып ташлыйлар. Кем иренми, шул чүпрәк урынына аягын сөртеп үтә.

К ө б р а. Син ничек котылдың соң?

К ү г ә й. Котылырсың тиз генә... Бирешмәскә кирәк! Бәйләнделәр-бәйләнделәр дә кул селтәделәр. Бер-икесенең бугазын чәйнәп өнен алганнан соң... Әнә шуннан соң инде «Татар Бүресе» дигән кушамат тактылар үземә... Кайда да сынала кеше. Үзәгең таза булмасамы?!

К ө б р а. Гел-гел намус саклап кына торып та булмый инде. Һәркемгә үз кадере кадер. Кияүләре председатель булмаса, мәңге күрми иде ул йолдызларын дип гайбәтеңне саталар ич әнә. Суккул чувашы бер адым да калмый миннән, дип әйтә килдең ич үзең, ә кая соң аның йолдызлары?

К ү г ә й *(кычкырып җибәрә)*. Кияүләрнең ни катнашы бар минем йолдызларымда?! Сүзеңне үлчәп сөйлә! Картайдың дип тормам, салып торып очырырмын!

К ө б р а *(каушап)*. Әһе... Шул гына калды бит хәзер! Катырҗанлыгы исенә төште берәүнең! *(Чуракай керә. Әкрен.)* Бу йолкыш ни иснәнеп йөри тагын? Үләксә сизгән козгын кебек... *(Кычкырып.)* Башыңны кем ярды, күрше?

Ч у р а к а й. Һу! Күгәй кордаш траур игълан итмәдеме икән, кәефен белешим әле дип керсәм, ул карчыгы белән пар күгәрчен кебек гөрләшеп утыра! Маладис! Ничу беттән фил ясап балавыз сыгарга. Шулай бит, Көбра килен? *(Күгәй каршына түмәргә утыра.)* Җаңа хуҗаны уйлап килешем әле... *(Көлә.)* Персидәтелнең нечкә җиренә тидем, ахры: Күгәй кордаштан элеккеге персидәтелләр турында сорашып кара, дигән идем, шундук җөзен кара болыт басмасынмы! Җук, минәйтәм эчемнән генә, җаратмый нәчәльство үзеннән алда эшләгән түрәне. Җене сөйми! Кияүләрегез, артларыннан сөйләү булмасын, тәхеткә менеп утырганы берсе баҗаларының башына кәкәй итәләрие. Мыскыл итә димәгез — үз кияүләрегезне миннән шәбрәк беләсез. Теш кысып булса да, кызларыгыз хакына түзеп җәшәгәнегезне күреп тордык. Инде бусы бүтән сөяктән җасалганмы дисәм, шул ук бер чыбыктан сөрелгәнгә охшый. (...) Монысы белән дә калхузның борчагы пешмәс, пажалый. Әнә ишеттегезме, радиудан беркөн безнең илдә унсигез мульон нәчәльник бар дип сөйләделәр. Унсигез мульон артык кашык дигән сүз. Силый армия! *(Көлә.)* Монысы китсә дә җәтим калмабыз, боерса!

К ө б р а *(коры)*. Син озак утырма, атасы. Сүзегез бетмәс. *(Өйгә кереп китә.)*

Ч у р а к а й *(Көбра артыннан кереп киткәнче карап кала)*. Тәки гомере буе өнәмәде мине хатының! Ә син нишләп авызыңа

су каптың, Күгәй кордаш? Кайгырма: ат аунаган җирдә төк кала, тиз табарлар. *(Тавышын әкренәйтә.)* Анысы-анысы, менә син миңа шуны әйт, Күгәй кордаш: төпчек малаегыз Искәндәр кайларда җөри икән?

Күгәй *(сагаеп)*. Нигә кинәт кенә кирәк булды әле ул сиңа?

Чуракай. Хаты-хәбәре юкмы, дим?

Күгәй. Булса ни дә сиңа, булмаса ни?

Чуракай. Атасына памятник куйганда да кайтып күренмәвенә шаклар катам! Телеграмма-мазар сугуы да ишетелмәде. Гәҗит укый торгандыр ич ул. Указны күргәндер.

Күгәй *(тәмәке кабыза)*. Бер кайтмаса, бер кайтыр әле. Синекеләр дә хат язарга ашкынып тормый.

Чуракай. Әйтмә дә, кордаш! Безнең төпчек тә бер кәлимә сүз сызгалап салырга иренеп җата, сабакы малай. Бәлки, безнең үзебездәдер хаталык. Бала барын да күреп үсә бит ул. Африкада шундый бер пләме бар икән: хөкем карары чыгарыр алдыннан соңгы сүзне җинаятьченең баласына бирәләр икән. Баласының җавабына карап, атасының җазмышын хәл кылалар, имеш. Кыргый халык димәссең бер дә. Бездә дә шуны кертәсе иде. Кызык: атаңа һәйкәл куйыйкмы дип сорасалар, Искәндәр ничегрәк җавап бирер иде икән, ә? *(Күгәй дәшми. Тынып торалар.)* Кая барып чыгарбыз болай, бер Алла белсен. Үзебезнең пачулкыны гына ал инде син? Пиреспик түгел дип, монда күченергә котырттылар да, хәзер авылыбыз, әҗәл көткән карчык кебек, ни үлеп бетәлми, ни җәшәп китәлми. Бөтен пачулкының терәге булып бер Мәкәрәм калган иде, ул да, пенсиягә чыккач, Октябрьскига китәргә план корып җата, имеш. И-их!.. Вакытында шунда шкул ачып җибәрәсе калган! Синең кулда, бригадир кешедә, форсат та бар иде җугыйсә...

Күгәй *(кабынып)*. Шкул, шкул! Нигә соң ачмадыгыз?! Син дә бригадир булгансың ич! Мин лагерьда чакта. Саруымны кайнатасың!

Чуракай. Искә төшкәнгә генә кузгатуым. Артка борылып карыйм да кайчак... Кызык та инде бу кеше дигәнең... Күзеңә карап кат-кат алдыйлар, ә ул барыбер ышана. Менә үзебезнең җитәкчеләрне генә алыйк, мәсәлән...

Күгәй. Җитте! Туйдырдың.

Чуракай. Тукта, әйтеп бетергәнне көт син. Кияүләрең икәнен онытып тор. Кылган эшләре турында мин. Хәтерлисеңме, кордаш, барысының да җараткан бер сүзләре бар иде? Килгәне берсе намаз урынына шуны кабатлыйлар иде.

Күгәй. Шуларның сүзләрен генә хәтерләп торасым калды!

Чуракай. Зерә. Исеңә төшмәсә, үзем төшерәм. Дилбегәне кулына эләктергән берсе: «Миңа кадәр таптаган җулыгызның кыйбласы дөрес түгел, ул кәҗә сукмагы гына иде, чын җул

менә болайга таба бара!» — дип башлый торган иде. Иң кызыгы шунда: барысы да калхузны төзегән иң беренче персидәтелне примерга куя. Бер үк сүзне тукыйлар, ә бөтенләй кире якка талкавать итәләр. Ну, анысы чуртысним. Алга китеш ташкаулчим бит! Ак-караны тиз генә аерам димә...

Күгәй. Алай бик акыллы булгач, нишләп соң моңа чаклы тыныңны чыгармадың? Авызыңны тегеп куймаганнар иде ич!

Чуракай. Мин — бер прастуй мужик.

Күгәй. Мескенләнмә! Мине Себергә җибәрергә бик кулыгыздан килде! Прастуй мужик, имеш!

Чуракай *(ачуы чыгып, сикереп тора).* Минем сине төрмәгә утыртканым җук! Нахак бәла җакма! Һәйкәл ташындагы каен түмәрен күрдеңме? Күрсәң, уйлап карале, нигә именне ботаклычатаклы төп куйганнар? Нишләп бүтән нәрсә түгел? Аңладыңмы ишарәне? Син дә әллә кем булып кыланма дигән сүзләре ул!

Күгәй. Ә нигә аңа эчең поша?

Чуракай. Барып җитте микән, шуны беләсем килгәнгә сорыйм.

Көбра *(өйдән чыга).* Атасы! Дулат сине телефонга чакыра.

Чуракай. Тапканнармы әллә?

Күгәй. Нәрсәгә?

Көбра. Үзеннән сора. Берәр үчле-мазар кешесе юкмы икән авылда, ди.

Күгәй *(ачулы).* Йөрмәле монда! Ачу китереп!

Көбра. Синең өчен тырышалар ич!

Күгәй. Үчле кеше, имеш! Менә минем каршымда утыра берсе! Чуракай кордашыннан шикләнә, диген! Гомергә җанны ашап тәм таба. *(Көбра кул селтәп кереп китә.)*

Чуракай. Рәхмәт! Канса-кансу, әйтеп бирдең, кордаш, эчеңдәгене.

Күгәй. Бар әле, юлыңда бул син дә! Һәйкәл йокы бирми, ахры? Кыртлаган тавык кебек янымда бөтереләсең!

Чуракай. Ахмак син! Беләсең килсә, дөнҗада минем кебекләр булмаса, тәтеми иде сиңа ул һәйкәл.

Күгәй *(кычкырып көлеп җибәрә).* Ну!

Чуракай *(тыныч).* Кеткелдәмә, кеткелдәмә, зерә кеткелдисең.

Күгәй *(ирония белән).* Ачуланма, һаман да синең миңа тигән ярдәмең аңлашылып җитмәде.

Чуракай. Чөнки минем кебекләр булмаса, калхузның каккан казыгы да калмас иде. Ә хәерче калхузга кем Герой исеме бирсен?

Күгәй. Алаймыни?! Рәхмәт инде, алайса! Без көне-төне җир актардык, ә син шул вакытта эленке-салынкы чутават булып йөрдең. Белмәгән идек, синең аркада җыеп алынган икән ул мул

уңышлар. Колхоз шуның аркасында бөлгенлеккә төшми калган икән, мең-мең рәхмәт сиңа!

Чуракай. Чуракайны ике сүз белән сыртына җыгып салдым дисеңдер инде, үзеңчә. Ике сүзнең берендә мин фәлән иттем, мин төгән иттем дип күкрәк кагасың. *(Бармагы белән югарыга ымлый.)* Әгәр дә без, синең кебек, аннан төшкән һәр әмерне кабалана-кабалана үтәргә җөгерсәк, әллә кайчан, кулыбызга капчык тотып, хәер сорашырга чыгып китәргә кала иде безгә! Беләсеңме нишләтә идек без ул приказларны? Колак яныннан мима җибәреп тордык. Әнә шуның аркасында сакланып калды калхузның кайбер казыклары! Бер генә пример китерәм, алайса. Калхуз умарталыгын кем бетертте? Соңгы киявең! Ә хәзер, карабодай басуына умарта чыгарган өчен, калхуз үзе миңа акча түли. Шулай булгач, кемнең заслугасы күбрәк: синекеме, минекеме? Һәйкәлеңне нигә урлаганнар дисең соң син? Шуны җахшылап уйлап кара!

Күгәй. Һәйкәлдә кайгың булмасын!

Чуракай. Чукынышып бетмәссезме! *(Чыгып китә.)*

Күгәй, кинәт кенә нидер исенә төшкәндәй, аның артыннан ташлана. Урамнан Вилена белән Искәндәр килеп керә.

Искәндәр. Нихәл, әткәй? Безне каршы аласыңмы, Чуракай абзыйны куа чыгуыңмы? Корт чаккандай капкадан чыгып чапты! *(Көлә.)* Һаман да элеккечә тыныша алмыйсыз, ахры?

Күгәй *(аларның кайтуын көтмәгән, шуңа күрә бераз каушап кала).* Кайсы якка китте ул? Мин хәзер... *(Капкага ташлана.)*

Искәндәр *(гаҗәпләнеп).* Тукта, әткәй, кешечә күрешик башта. Исән-сау гына торасызмы? *(Әтисе белән күрешә, Виленага ымлап.)* Булачак киленегез. Исеме Вилена. «Владимир Ильич Ленин» дигәннән кыскартып ясалган. Шулай булгач, килеңнең нинди кеше икәнлеген аңлыйсыңдыр. *(Елмая.)* Минем вкус начар түгел, шулай бит, әткәй? Анкетасы болай: миннән ике яшькә кечерәк. Вуз бетергән. Эше әйбәт, тузанлы түгел, социолог. Гадирәк әйткәндә, кешеләрнең эшләгәнен карап торучы. Тагын нәрсә әйтелми калды, Вилена? Ә! Яхшы нәселдән. Туган-тумачалары шактый күп. Ну, монысы сезгә барыбер — сез кунакка йөрешүне яратмыйсыз. Кияүдә булган. Бетте бугай? Вилена, кул биреп күрешү — бездә культура билгесе.

Вилена *(елмая).* Исәнмесез, әти? Шулай дип эндәшергә рөхсәт итәсезме миңа? *(Кул бирә.)* Искәндәр миңа сезнең хакта бик аз сөйләде, шуңа күрә...

Искәндәр. Ашыкма, Вилена. Соңрак.

Күгәй. Аңлап бетермәдем, өйләнеп кайтуыңмы бу, улым?

Искәндәр. Шулайрак, әткәй. Хупмы? Барысын да берьюлы әйтеп бетерик, Вилена.

Вилена. Барыбер ишетелер.

Искәндәр. Эш болай тора, әткәй... Вилена — яңа председательнең хатыны була.

Вилена. Иде диген, Искәндәр.

Искәндәр. Иде дип әйтеп бетереп булмый бит әлегә. Үзәсе нәрсәләрегез бар.

Вилена. Дулат белән бик күптәннән бергә яшәмибез без, әти. Тик законлаштырылып бетмәгән. Искәндәр шуны әйтмәкче була сезгә.

Искәндәр *(елмая)*. Яраткан председателегезнең хатынын тартып ала димә, әткәй. «Яраткан», дидем дә... Бусын әллә яратып бетермисеңме? *(Әтисе дәшмәгәч.)* Ну, анысы!.. Өйләнүемнең сәбәбен аңлатам. Беренчедән, Вилена алданрак мине белсә, бәлки, Дулатка кияүгә чыгып та маташмаган булыр иде. Яшьлек хатасын төзәтүе. Икенчедән... Гел-гел генә председательләр безнең нәселдән ясак түләтергә тиеш димәгәндер, алар да үзләреннән безгә, рядовойларга, өлеш чыгарсыннар, шулай бит! *(Көлә.)*

Вилена. Улыгыз бәләкәйдән үк шундый шук сүзле идеме, әти? Һич көтмәгәндә әллә нәрсәләр уйлап чыгарып, көн дә шулай шаккатыра ул мине. Әкренләп характерына ияләшеп киләм инде.

Күгәй. Төрлечә булгандыр инде... Кем аны истә тота... Ни, килен тиеш кеше... Искәндәр барында бер сүзем бар сиңа... Дулат хатыны икәнлегеңне әнисенә әйтми тор. Монысы аңлашыладыр. Искәндәр белән өйләнешүегезгә каршы килмим. Мәхәббәт эшедер. Әмма Дулатны ташлавыңны хупламыйм. Ташлап китәрдәй ир түгел ул, минемчә. Димәк, сукыр булгансың.

Искәндәр. Әйттем бит — яраткан председателегез дип! Бездә бөтен председательләрне о-бо-жают, Вилена. Бигрәк тә... Булды, әткәй, барысын да берьюлы әйтеп бетермә, башка вакытка да калсын.

Вилена. Әйтү-әйтмәүне үзегез хәл итәрсез инде. Сез — семья башлыклары.

Искәндәр. Менә монысын дөрес әйттең, Вилена! Әнкәй өйдәме? Ул нихәлдә?

Күгәй. Ару әлегә. Йорт кошы инде ул хәзер. Вакыты күбәйде. Шуңа күрә атаңның җилкәсен игәүләргә мөмкинлеге артты. Әйдәгез, кердек. *(Өйгә керәләр.)*

Искәндәр *(капка төбендә Чуракайны күреп, артка кала)*. Мин хәзер, керә торыгыз... Дөньялар арумы, күрше? *(Күрешә.)*

Чуракай. Пычагым булсынмы бу дөньяга? Без картаябыз, ул сызгырып та бирми. Сине күреп, тәртәмне кире бордым.

Юкса борын белән боз тишәрдәй чак. Атаңның һәйкәленә аю мае сөрттеләр бит әле, әйткәндер?

Искәндәр. Картайсаң да, дөнья үзгәртә алмаган икән үзеңне. Һаман шул ук җор телле Чуракай абзый!

Чуракай. Кашки, шулай булса иде дә! Үзгәрмәссең бу заманда. Ике аягыңны бер кунычка тыгып куйса, нибуч... Ни әйтмәкче идем соң сиңа? *(Башын кашый.)*

Искәндәр. Башыңа ни булды, Чуракай абзый?

Чуракай. Көзгегә карасам, үземнең дә ис-акылларым китә, Искәндәр улым! Әллә төшемдә, әллә өнемдә булды бу хәл! Ответственный эшкә күчкәнемне беләсеңме әле син?

Искәндәр. Юк. Нинди эш ул?

Чуракай. Төнге каравылда мин хәзер.

Искәндәр. Чынлап та, җиңел эш түгел икән шул.

Чуракай. Әйтмә дә! Кичә кич шушы мәрәкәгә төштем. Жаңа эшем аркасында. Путле эш булмады ул, каһәр. (...) Гаҗәп хәл булды ул! Сельсәвит ишеге төбендә утырам шылай. Күтәрелеп карасам, кемдер клуб янындагы тыкрыкка таба шыпан-шыпан тертләттерә! Сарык бәрәнен сыртына салып качкан бүре кук, җилкәсенә нindидер авыр бернәрсә салган. Ышту-ты ошамый бу миңа. Куып киттем тегене. Нәрсә күтәргән дисең? Атаңның һәйкәлен! Акурат синең гәүдәлерәк кеше. Пинжәге дә тач синеке.

Искәндәр. Сыртына салырга иде шунда казык белән.

Чуракай. Путле көн булмады дип торам ич! Миннән хәйләкәррәк бәндә икән, мөртәт! Артыннан тыкрыкка борылуым булды — шалт Мөхәммәтҗан! Аяк чалды, паразит! *(Башын тота.)* Башым белән мәтәлеп очып төштем. Әле дә көчкә түзеп торам авыртуына.

Искәндәр. Их, күрше, күрше!.. Шуны да кулдан ычкындыргач инде... Менә хәзер тотып кара син аны! Әллә соң ниме... көмешкәңә пробаны күбрәк ясап ташлаган идеңме, Чуракай абзый?

Чуракай *(гаҗәпләнеп)*. Кем әйтә аны?! Ниткән көмешкә?!

Искәндәр. Сельсоветта кайнаткан көмешкәңә, дим?

Чуракай *(сүзсез кала)*. Каян алдың?!

Искәндәр *(елмая)*. Кайнатмыйсыңмыни, Чуракай абзый? Булмас! Сиңа кадәр торган каравылчылар гел шуның белән кәсеп итә иде. Агач башыннан егылып төшеп үлгән Фәтхетдин абзый да хәтта. Куркакларның куркагы. Ә нигә? Төн. Тыныч вакыт. Иң главное — беркем шикләнми. Кайнатмыйм дип юри әйтәсеңдер, Чуракай абзый? Что-то ышанасы килми. *(Сүзне икенчегә бора.)* Ни әйтмәкче идең миңа?

Чуракай. Кайчан?.. Ә, ни иде... Ладны, кайтып кергән сәгатеңдә үк башыңны аптыратмыйк әле. Важный, җитди әйбер

түгел ул. Соңрак бер әйтермен әле, җае чыккач. Башта бераз кунак бул.

Искәндәр. Әлегә хуш иттек, алайса, күрще! Әнкәй белән күрешмәгән бит әле мин. Көттерү килешмәс, шулай бит? *(Өйләренә кереп китә.)*

Чуракай *(Искәндәр кереп киткәч, капка төбендә таптанып тора)*. Вәт хәерсез! Тфү! Митингтан соң атасы белән бергә һәйкәл җуармын дигән идем. Каян шул арада күреп өлгергән диген, малай актыгы!.. Әллә инде, чынлап та... Булыр да! Бөтен нәселләре белән чукныттыйлар! *(Китә.)*

Искәндәр *(керә)*. Мине югалттыгызмы? Исәнме, әнкәй! *(Әнисе янына үтеп, кул биреп күрешә.)* Пенсиягә чыккач, яшәреп киткәнсең, ахры!

Көбра *(табын әзерли)*. Шулайдыр шул. Яшәргәнмендер... Бигрәк тә сиңа әйбәтрәк күренәдер инде ул, улым, соңгы тапкыр кайтып киткәнеңә биш кенә ел үтте бит. Ә минем пенсиягә чыкканыма яренгә бер ел тулачак инде, Алла боерса...

Вилена. Әниең файдасына бер — ноль, Македонский!

Искәндәр. Гаеп миндә, әнкәй, ике кулымны берьюлы күтәрәм! Һәм бүгеннән сүз бирәм үзеңә: озак кайтмый торуыбызның әүвәле-ахыры шушы булыр. Ел саен хет бер мәртәбә монда кайтып йөриячәкбез хәзер. Син әйтмешли, Алла бирсә!

Көбра. Алла боерганны көтеп торасыз шул хәзер барыгыз да... Үзегезнең теләк сизелми.

Вилена *(чемоданнан күчтәнәчләр чыгара)*. Үгет-нәсыйхәтне катырак бирегез, әни. Астына су кермәсә, әле дә кузгаласы түгел иде улыгыз...

Көбра *(килененең һәр сүзгә катнашуын өнәп бетермичә)*. Балаң булгач, син дә үгет-нәсыйхәт бирә башларсың, килен. Нинди су керде астыгызга?

Искәндәр *(Виленага күз кыса)*. Сиңа да әләктеме? Әйтәбезме, Вилена? Озакламый малаебыз булыр дип уйлыйбыз, әни. Оныкк әзерлибез сезгә!

Көбра. Бирсен Ходай...

Вилена. Чынмы ул, Македонский? Нишләп аны моңарчы миңа әйтми йөрдең? *(Көлә.)* Әни, менә боларны, зинһар, карап алып куярсыз инде. Искәндәр үзе барыгызга да атап алды.

Көбра. Рәхмәт... *(Бүләкләргә күтәрелеп карамыйча.)* Утырышыгыз, әйдә. Атасы, нишләп син авызыңны чөйгә элдең? Әллә нигә бер кайткан малаең белән сөйләшмичә утырасың. Калдырып торыгыз чемоданнарыгызны. Бер яры качмас. *(Дая кайтып керә, ул сизелерлек ярсыган.)* Син нишләп иртәләдең?

Дая. Искәндәр абыең председательнең хатынын урлап кайткан, дигәннәр иде — хак икән! Әй, нихәл, абый? Мине дә таныштыр трофей хатының белән!

К ө б р а *(катып кала)*. Сеңлең дөрес әйтәме, Искәндәр?

Д а я *(кызган баштан дәвам итә)*. Нигә гаҗәпләнәсең аңа, әнкәй? Заманы шундый бит хәзер, үзең беләсең, мин дә заманнан калышмаска тырышам. *(Виленага.)* Вилена бит исемегез? Сезнең белән квиты хәзер: гайбәтчеләр минем исемне элекке ирегезнең исеме белән бәйләп тәм табалар иде! *(Көлә.)*

К ү г ә й. Телеңне кыскарта төш, кызый! Бар нәрсәне заманага сылтый башладыгыз! Үзең сәбәп бирәсеңдер! Үзең гаепле булмасаң, гайбәтең чыкмас!

Д а я *(аңа таба борыла)*. Әй Онытып торам икән! Минем киләчәгем турында аталарча кайгыртуың өчен мең рәхмәт сиңа, эткәй! *(Абыйларына.)* Эткәйнең нинди кеше икәнлеген моңа кадәр беребез дә белеп бетермәгәнбез икән, Искәндәр абый. Бүген ул тагын бер яхшы ягын күрсәтте. Мине культура йортына директор итеп куймакчылар иде, эткәй, ашыкмагыз әле дип, барып әйткән! Шундый честный кеше инде ул безнең ике тапкыр Герой этиебез! Чынлап та, һәйкәл куярлык шәхес син, эткәй! *(Эчке якка кереп китә.)*

И с к ә н д ә р. Чын булса, юкка катышкансың, эткәй. Даяның кулыннан килә торган эш ул. Синең геннар күчкән аңа. Җитәкче булып туган. Кечкенәдән дус кызлары арасында да баш иде ул.

Көбра Виленаның чемоданын, ябып, кулына тоттыра.

В и л е н а. Не поняла? *(Искәндәргә карый.)*

К ө б р а *(икенче чемоданны улына бирә)*. Бу йортта кеше бәхете исәбенә яшәүче булмады моңарчы. Намусы саф кешеләр генә яши монда. Моңа кадәр биш ел кайтып күренмәдең — тагын биш ел күренмәскә мөмкин! *(Эчке бүлмәдән, кулына чемодан тотып, Дая чыга.)*

Д а я. Нинди кешеләр яши дисең, әнкәй?

К ө б р а. Ә син күпне ишетмә! (...) *(Кызының кулындагы чемоданны күрә.)* Кая җыендың әле болай?!

Д а я. Намуслы кешеләргә генә яшәргә ярый безнең өйдә дип әйттең ич үзең?

К ү г ә й. Нинди аерым гына серле сөйләшү бу?

И с к ә н д ә р. (...) Нәрсә, Вилена, от ворот поворотмы? *(Мин нишли алыйм дигәндәй, кулларын җәя.)* Фатир эзләргә киттекме? Күреп торасың — бездә түгел кайгылары.

К ү г ә й *(каршы әйтмәслек итеп)*. Ашыкма. Әлегә атагыз бар дөньяда! *(Көбрага.)* Ә син тезгенеңне тарта төш. Мәктәптә түгелсең. Үзе тапкан — үзе багар.

Шулвакыт радиоалгыч телгә килә.

Д у л а т т а в ы ш ы. Кадерле иптәшләр! Авылда бик җитди «чепе»: бүген төнлә кемдер колхозыбызның даны һәм намусы,

ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое Күгәй абзый хөрмәтенә куелган һәйкәлне алып киткән. Башка сыймый торган хәл бу! Бәлки, ул карак шушы минутта минем сүзләрне тыңлап торадыр. Таң атканчы китереп куй урынына! Әгәр дә һәйкәл иртәгә иртән постаментында тормаса, үзеңә үпкәлә!

Кобра. Һе! Үзеңә үпкәлә, имеш! Ботыңнан асачакбыз, дими!

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

IV күренеш

Икенче көнне берничә сәгатьтән соң.

Күгәй картның өендә төшке аш тәмамланып килә. Өстәл артында хуҗа карт үзе, карчыгы, килене белән малае. Күгәй карт тыныч кыяфәтле. Карчыгы Кобра вакыт-вакыт телефон аппаратына карап ала.

Кобра *(ниһаять, түзми)*. Оныттылар, ахры, болар безнең турыда!

Күгәй. Кемнәр?

Кобра. Председатель! Һәйкәл табылуга шундук шалтыратабыз дип җавап биргән иде бая.

Күгәй *(ачулы)*. Ә кем сиңа шалтыратырга кушты?

Кобра. Үзең пошмагач!

Күгәй. Һәйкәлсез яшәдек бит моңарчы, моннан соң да яшәрбез! Тагын бер телефон янына киләсе булсаң! Кара аны! Һәйкәл кирәк булган берәүгә. *(Авыр тынлык.)*

Кобра. Ичмасам, син дә, улым, борчылмыйсың.

Искәндәр. Ишетеп торасың — әткәй кушмый бит, әнкәй.

Күгәй. Кушмыйм шул! Һәм шуның белән җитте! Бүтән сүзегез юкмыни? *(Тагын тынып торалар.)*

Кобра. Кызың кая олакты инде... Бүген иртәрәк кайтам дигән иде! *(Табынны җыештыра.)*

Вилена. Китер, әни, үзем...

Кобра *(аның сүзләренә игътибар итми)*. Барыгыз да кирәкмәгән үзсүзле...

Вилена, Искәндәргә карап, кулларын җәеп куя һәм урынына кире утыра.

Искәндәр *(берни эшли алмыйм дигәндәй, җилкәсен җыерып куя)*. Кайтмый ул, әнкәй. Автобуска утырып, Октябрьски ягына киткән.

Күгәй. Кем рөхсәте белән?

Искәндәр. Аның яшендә рөхсәт сорап тормыйлар шул, әткәй. Үз акыллары җитә башлый.

Кобра. Кем күргән?

Искәндәр. Колхоз идарәсендә секретарь кыз әйтте. Дая белән икегез сөйләшеп торганда, Даяның чемоданын күргәч,

яннарына бармакчы идем, бик каты әрепләшәләр, ахры, дип туктап калдым, ди.

К ү г ә й *(Көбрага)*. Үзең озатып йөрисең икән әле кызыңны! Төшке ашка кайтмый, имеш! Сезнең өчен мин хәзер дөньяда да юк, димәк?!

К ө б р а. Башымны катырма син дә! Артыннан куып җитеп, чемоданын алып калган идем. Шәрә көйгә утырып сызган инде, алай булгач! Өстендә юка күлмәк кенә иде!

К ү г ә й. Тамагы ачыккач кайтып төшәр әле... Ничу аның өчен балавыз сыгып утырырга!

К ө б р а. Кайтыр пычагым. Бөтен балаларыңны куып таратып бетердең инде. Берсе дә сыймады үз яныңа.

К ү г ә й. Ычкындыңмы әллә?

И с к ә н д ә р *(тынычландырырга теләгәндәй)*. Янында акчасы җитәрлек аның, кайгырмагыз, әнкәй... Туктарга урын бар. Фатирыбызның ачкычын бирдем мин аңа.

К ө б р а. Икәүләп сүз берләшеп эшләгәнсез икән әле!

И с к ә н д ә р. Үз сеңлем бит. Запас ачкычың бармы дип сорап алган иде кичә. Барганда өйдә-фәлән булмасак дип...

В и л е н а. Ну син даёшь, Македонский!

И с к ә н д ә р *(елмая)*. Ашыкма, синең өчен тагын бер яңалыгым бар әле. Мин бүген Дулат янына бардым... *(Бармагын ирененә куя.)* Тихо, анысы соңрак. *(Кычкырыбрак.)* Соңгы вакытта үзебезнең зиратка барганыгыз бармы, әткәй?

К ө б р а. Атаңда зират кайгысымыни инде!..

И с к ә н д ә р. Бабакайлар ничәлдә яталар икән, дим.

К ү г ә й. Яталардыр. Кая китсеннәр?

И с к ә н д ә р. Мал-туар таптап бетерми микән? Ихатасы элек кайтканда ук аварга тора иде. Бүген бергә җыелышып барып кайтабызмы әллә? Вилена да танышып кайтыр иде.

В и л е н а *(бераз кыланып)*. О, мин — пас. Зираттан куркам мин!

К ү г ә й *(кинәт кузгала)*. Дөрес әйтәсең, улым! Әйдәгез! Әйдә син дә, анасы. Дөнья куу бетмәс монда. Их, гомерләр узды... Кабат башлыйсы иде дә!

К ө б р а. Менә иске авыздан яңа сүз! Сиңа ни җитми тагын?!

К ү г ә й. Ни җитми... Хәтереңдәме, Чарджоуда хезмәт иткәндә, үзебезнең частнең чемпионы идем дип сөйләгән идем?

И с к ә н д ә р. Шахматтамы? Минем дә истә, әткәй.

К ү г ә й *(улына таба борыла)*. Командир шунда ничә әйтте, давай Мәскәүгә җибәрәм мин сине, баш бар синдә, әрәм итмә, укы, диде! Юк, тыңламадым. Чөгендер кадерлерәк булган.

К ө б р а. Кем чөгендер үстерә, кем чемпион була инде. Язмышың шундый булгач.

Күгәй. Аңлыйсыңмыни син?! Чөгендер! Ә җан азыгы кая?! Дөньяга мәңгегә килмәгән бит без! Кеше — иң главный! Чөгендер, имеш!

Чуракай *(ишек шакып кычкыра)*. Өйдәләрме?

Көбра. Тагын килеп җитте инде!

Күгәй. Өйдә, өйдә! Өйдә булмый, кая булыйк без...

Чуракай *(керә)*. Исәннәрмесез, барыгыз да!

Искәндәр. Әйбәт әлегә, Чуракай абзый. Әйдә, түргә үт.

Чуракай. Син эндәшкәч үтәм, Искәндәр улым. Әниең кыстаса — ышанмас идем, атаң — гүпчим кыстый белә торган кеше түгел. *(Көлә.)* Ярар, ярар, кордаш, сырт җоныңны кабартма — шаяртам гына. *(Күрсәткән урындыкка утыра.)* Киленегез — күз тимәсен, тфү-тфү, бик чибәр икән, Көбра килен! *(Виленага.)* Исемең ничек була, килен?

Вилена. Вилена исемле булам, абзый кеше!

Чуракай. Алаймы? Бик әйбәт, өстендә тузсын. *(Көлә.)* Малаеңны мактарга кердем, Күгәй кордаш! Маладис икән!

Искәндәр. Ни өчен мактыйсың мине, Чуракай абзый?

Чуракай. Ә кәкже? Пачулкыны кабат тергезергә алынгансың бит! Бир әле шуның өчен уң кулыңны! *(Сикереп торып, Искәндәрнең кулын кыса.)* Хуплыйм, хуплыйм! Катигарически! Камандаңа мине дә ал. Бүгеннән җиң сызганып эшкә тотынырга риза! Атаңны белмим — ул андый эшкә тиз генә кузгала торган кеше түгел. Дөрес, авылны таркатырга дигәч, иң беренчеләрдән булып ул кузгалды монда күчәргә. Ладны, урыс әйтмешли, кем узганны искә төшерә, шуның күзе шартласын!

Көбра. Нәрсә сөйлисең син, күрше? Ни уйлап чыгардың?

Чуракай. Нишләп мин уйлап чыгарыйм? Менә малаеңнан сора. Яңа персидәтел белән килешү дагауры төзеп кайткан. Күрсәт әле шуларга дукәмәтеңне! *(Көлә.)*

Искәндәр. Договор төзергә иртәрәк әле, Чуракай абзый. Правление карыйсы бар.

Чуракай. Прауление? Персидәтел «за» дидеме?

Искәндәр. Ул «за»лыкка «за»...

Чуракай. Шулай булгач! Персидәтел «за» дигәч, килешү дагаурыңны кесәмдә дип сана инде син аны, Искәндәр улым! Прауление нәрсә... Прауление ул персидәтелнең перәшкәсе генә! Җә, нигә тынып калдыгыз? Әйтмәгән идеңмени әле аларга?

Күгәй. Азга гына булса да тынып торчы, күрше!

Чуракай. Булды, булды, кордаш. Мишәт итмим бүтән. Улыңның кулын кыстым — күңелем булды. *(Артка чигә-чигә, ишеккә юнәлә.)* Ә, оныткачы... Бабаңнарның зиратында булдыгызмы әле, Искәндәр улым? Барырга ниятегез булса — минем ат җигүле, килеп алам. Бер сурприз күрсәтермен үзегезгә.

Вилена. Точно вакытында туры китердегез, абзый кеше. Искәндәр әле генә шул турыда сүз башлаган иде.

Чуракай. Шулаймы, килен? *(Искәндәргә бармак яный.)* Әлегә бер серне ачмый торам, Искәндәр! Миннән башка китеп бармагыз! *(Чыгып китә.)*

Күгәй *(аның артыннан ишегеи ныклап ябып кала)*. Балабулка! Нәрсә лыгырдады ул монда, улым? Сүзенең ата-анасы юк, юньсезнең.

Искәндәр. Авыз тутырып сөйләшер нәрсә әлегә юк, эткәй...

Көбра. Авылыбыз турында нидер мыгырданды түгелме соң?

Искәндәр. Үзем дә сезгә ничегрәк әйтергә белми утыра идем, Чуракай абзыйның керүе шәп булды. Яшелчә бакчасын арендага алырга булдым, эткәй. Туган авылыбыз тернәкләнеп китмәсме?..

Вилена. Как это?

Күгәй. Ай-һай, улым... Берүзең нишли алырсың икән? Һе! Яшелчә бакчасы!..

Искәндәр. Нишләп берүзем булыйм? Ә сез? Кемдер төзәтә башларга тиештер бит? *(Елмая.)* Вилена фирманың учёный секретаре булыр.

Вилена. Я ничего не поняла, Искәндәр? Ты что, собираешься насовсем вернуться сюда?

Искәндәр. Кайтырга җыенмыйм — кайттым. Дөресрәге, икәү бергә кайттык. *(Виленаның җавабын көтә.)*

Вилена. Не смеши меня, Македонский!

Искәндәр. Мин чынлап әйтәм, Вилена.

Вилена *(картларга карый)*. Малаегыз с ума сошёл, ахры, эти! Мин ни за что риза түгел! Городны ташлапмы?! Ты что, до сих пор не понял, почему я не живу с Дулатом?

Искәндәр. Калдырып тор, Вилена... Бүтән вакытта аңлашырбыз.

Вилена. Ты — как хочешь! Я сегодня же уезжаю! Так и знай!

Көбра *(әкрен генә)*. Киткән кешене көчләп тотмабыз анысы.

Искәндәр. Әнкәй, моны үзебез хәл итәрбез. Ни әйтерсең, эткәй?! Дөресен генә әйткәндә, синең эш тәҗрибәң бик кирәк булачак. *(Вилена, сүзсез генә торып, әйберләрен җыя башлый. Аның кыланышларын күзәтеп торалар.)* Ник дәшмисең, эткәй?

Күгәй. Ныклап уйлап эш итәсең микән, улым...

Искәндәр. Кире чигенергә уем юк, эткәй. Яки-яки. Яки җиңеп чыгачакмын, яки борын канатачакмын.

Күгәй. Борын белән генә котыла алсаң бик әйбәт тә... Их! Картаелды шул инде, улым... Аренда дигән нәмәрсәләр кимендә

моннан бер ун-унбиш еллар элегрәк чыккан булса!.. *(Вилена әйберләрен җыеп бетерә.)*

Искәндәр. Җыеп бетердеңме? Хуш, алайса! *(Әтисенә таба борыла.)* Кул көчең кирәкми синең, әткәй! Зирәклегең кирәк. Кеше белән эш итә белүең.

Күгәй. Тукта, улым, монысы турында соңыннан сөйләшербез. Алай тырт-пырт кына семьяңны җимереп ташлый күрмә...

Көбра. Син катышмый тор, атасы. Адым саен «китәм» дип куркыткан хатын хатын түгел инде ул — бәла! *(Телефон шалтырый. Тизрәк телефонга ташлана.)* Тавышланмый торыгыз әле!.. Әллү! Сатай энем, синме? Чынлапмы?! Кайда булган?! Алаймыни... Менә ничек?.. Ә кем... Ярый, рәхмәт яхшы хәбәрең өчен!.. Өйдә булмый, кайда булсын ул... Юк иде шул. Шәһәргә киткән, ахры... Бөтенләйгәме дип, кем белгән инде хәзерге яшьләрне... *(Трубканы куя.)* Һәйкәлең табылган, атасы!

Күгәй *(иркен сулап куя)*. Ну, вәт!.. Кайда яшергән булганнар, ди?

Искәндәр. Зиратта, әткәй. Бабакайның кабере янында.

Көбра *(шаккатып)*. Бәрәч!.. Син белә идеңмени?!

Искәндәр. Ничек белмәскә... Чөнки мин үзем илтеп куйган идем аны! *(Аптырашып, Искәндәргә карап торалар. Хәтта Вилена гаҗәпләнеп катып кала.)* Закон буенча һәйкәлең үзебезнең туган авылыбызга куелырга тиеш бит, әткәй. Ә туган авылыбыз үлеп бара. Кабат терелтәсе бар әле...

Өйгә, атылып, Дая кайтып керә, ул кулына газеталар тоткан.

Дая *(керә-керешли үк)*. Укыдыгызмы?! Яңа указ чыккан! Хәзер үзе исән чагында беркемгә дә һәйкәл куелмый икән! Хәтта ике тапкыр геройларга да, әткәй!..

1988



Шәукәт Галиев
(1928—2011)

МИНЕМ ГОМЕР...

Минем гомер, нәсел җебе буйлап,
Бик еракка барып тоташа —
Килгән күпме үлемнәрне җиңеп,
Килгән күпме хәвеф, ут аша.

Гасырларны кичеп, миңа иңгән
Ерак бабамнарның каннары,
Сеңгән аңа күз яшенең тозы,
Алсулыгы сеңгән таңнарның.

Кубыз, сорнай, гөслә моңнарыннан
Нечкәргәннәр күңел кыллары,
Ә күзләргә рәсем булып төшкән
Болгар сылуының сыннары.

Бөтен тарих үткән йөрәк аша;
Берсеннән дә читтә калмаган —
Гүзәллекләр аны иркәләгән,
Хаксызлыклар аны талаган.

Гомер арты гомер алмашынган,
Офык арты офык ачылган,
Тел очына килгән җыруларны
Әйтәлмәүдән бабам ачынган.

Күңелләрдә калган бик күп хисләр
Бөреләнгән икән җыр булып;
Каләм төрткәч, гасыр төпләреннән
Басым белән чыга ыргылып.

Алар әйтеп өлгермәгәнне дә
Мин әйтергә бүген тиешле,
Шигырь ритмын бирә буыннардан
Күчеп килгән йөрәк тибеше.

Ничек миңа шуның кайнарлыгын
Һәм илһамлы дәртен тоймаска —
Мең еллардан халкым куәт җыйган,
Яңа-яңа эшләп кояшта!

1966

ИМАН

Бер карасаң, бу дөньялар
Кызганыч, кызык кына,
«Иман» сүзе дә яшәде,
Сүзлеккә посып кына.

Ахры, «имамнар калдыгы»
Булып күренгәндер ул,
Тере телдән заманында
Шуңа сөрелгәндер ул...

Җанны әрнетеп, күп еллар
Вөҗданда иман сызлар —
Үрчеде буш йөрәклеләр,
Ишәйде имансызлар.

«Башын киссәң, тагы үсә...» — дип,
Өметләрен өзмәгән,
Тугры уллар тайпылмаган
Тарих салган эзләрдән.

Хаклык өскә калкасына
Инанганнар үзләре,
Саф күңелләрдә сау калган
Халыкның рух үзәге.

Гасыр чирләрен җиңәрлек
Савыктыргыч им анда —
Туфаннар гүзәл гамендә —
Кешелекле иманда.

Шәмаилдә яңа дога —
Җырлап торган «Туган тел»,
Яшәвебез, саулыгыбыз,
Иманыбыз булган тел.

Әйе, җирдә халыкларның
Саны — миллионнарда,
Әмма сыйфат рәвешләре,
Җаны — милли улларда.

Мин ышанам могҗизага:
Халык булдыра килә —
Үзен мәңге яшәтерлек
Дәвам тудыра килә.

Мин ышанам: гасырларда
Бар безгә дә урыннар —
Вәкаләтле илче булыр
Оныклар һәм торыннар!

Әйләнер дөнья-куласа,
Киләчәккә күчәр гел,
Имин булсын да уң булсын —
Иман булсын күчәре!

1988

КОЛ ГАЛИГӘ

Сигез гасыр элек җырларыңны
Яраткан да халык, ятлаган,
Шуннан бирле аны онытмаган,
Күңелендә көйләп саклаган.

Каерылган күпме канатларның
Каурыеннан каләм очладың?
Көнләгәнсең әле: шул кошлардай,
Ник иректә бераз очмадым...

Кушаматың нигә «Кол» икән дә,
Кемнәр сиңа богау кидерде?
Мәхәббәтең — җырның канатлары
Сине азат көнгә китерде.

Күңел белән күрәм мин барыбер
Кулларыңны бәйсез кул итеп;
Галине дә мөмкин кол итәргә,
Чын шагыйрьне булмый кол итеп!

1962

ТЕРЕКЛЕК СУЫ

Ни булгандыр
Бер имәнгә —
Имән корый.
Колачларын
Күккә җәеп
Ярдәм сорый.

Имән зарын
Очып барган
Кошлар тыңлый:
«Җыр бирербез,
Бүтән ярдәм
Бездән булмый...»

Имән зарын
Узып барган
Болыт тыңлый:
«Дым бирербез,
Бүтән ярдәм
Итеп булмый...»

Имән зарын
Иртән чыккан
Кояш тыңлый:
«Нур бирермен,
Бүтән ярдәм
Итеп булмый...»

Соң шул инде,
Юкка имән
Яфрак коймый —
Җыр ишетми,
Дымны сизми,
Нурны тоймый...

Коткарырлык
Бирәр әмәл
Тагын бармы?..
Күршеләре
Суза аңа
Тамырларын;

Донор сыман
Тармакларын
Капшап таба —
Дымны сала,
Җырны сала,
Нурны сала!

Имән тәмам
Тернәкләнгән,
Телгә килгән:
«Бу тереклек
Суын кем соң
Бирде?» — дигән.

«Кайсы микән?» —
Диеп, үзе
Күтеп торган.
«Дуслык!» — диеп,
Беравыздан
Әйткән урман.

1974

БУШ ВАКЫТ

Буш вакыт буш савыт түгел,
Савыт кына буш тора —
Буш вакытын һәрчак кеше
Ни беләндер тутыра...

Телевизор белән тулган
Бик күпләрдә буш вакыт...
Кемнәрдер әле үткәргән
Бушны бушка бушатып.

Бер малай буш вакытына
Трай типкән, туп керткән,
Берсе кызыгып укыган
Китаплар тезеп киткән.

Ә берәү буш арада гел
Нәрсәдер әмәлләгән —
Бүтәннәрнең эрәм калган
Вакытын да җәлләгән...

Эшчәннәрнең буш ара юк —
Бар күңелгә хуш эше.
Ялкауның буш вакытыннан
Үсеп җитә буш кеше!..

1983

ХӘЗИНӘ

Хәзинәләрне
Борын-борыннан
Эзләп бакканнар
Төрле урыннан.

Ята кебектер
Таулар артында.
Ә үзе сиңа
Бик тә якында.

Мөгаен, син дә
Уйга каласың,
Хәзинә диеп
Хыялланасың.

Төшә аласың
Бик тиз эзенә —
Китапханәдә
Ул бай хәзинә!

1968

ТЫЛСЫМЛЫ КӨЗГЕ

Андый көзге түгел бу,
Мондый көзге түгел бу,
Гади көзге түгел бу,
Серле көзге — тылсымлы!

Басса булмә түренә,
Аңа бар да күренә.
Күрә ул бөтен якны,
Якынны һәм еракны.

Күренә мәктәп ишеген
Соңарып ачучылар
Яки табан ялтыратып,
Дәрестән качучылар.

Күренәләр ялкаулар да,
Өс-башы шапшаклар да;
Буялмыйм, дип эштән качкан
Куллары ап-аклар да.

Күренә, кулын күтәреп,
Сөйләүне сөймәүче дә,
Пыш-пыш килеп, мыш-мыш килеп,
Колакка сөйләүче дә.

Кем дә кем «мин» дә «мин» диеп
Борынын чөеп йөри
Яки, сугышып, маңгае
Каралып-көеп йөри,

Кем дә кем иптәшләренә
Булышуны тарсына —
Урын җитәр бу көзгедә
Андыйларның барсына!

Кыек булса әгәр эшең,
Көзгегә үпкәләмә,
Дөп-дөресен күрсәткәнгә
Читләтеп үткәләмә;

Күр дә үзеңне көзгедә,
Төзәт начар ягыңны;
Аннары көзге күрсәтер
Синең әйбәт чагыңны!

1961

ТӘМЛЕ РӘХМӘТ

Бакча буйлап
Узып киттем,
Төрлесеннән
Авыз иттем.

Алмагачка,
Кураларга,
Чияләргә,
Карлыганга:

— Тезелгәнсез
Рәт-рәт, дидем,
Тәмле-тәмле
Рәхмәт! — дидем.
Бабай юри

Сорап алды:
— Кем үстергән
Соң аларны?

— Син үстергән
Рәтләп, дидем,
Сиңа да бик
Рәхмәт, дидем,
Син дә бик-бик
Тәмле! — дидем.

— Туган җиргә,
Тәмле телем,
Әллә рәхмәт
Әйтәбезме?

Ул үстергән
Һәммәбезне:
Алмаларны,
Әбиләрне,
Чияләрне,
Бәбиләрне,
Куралары,
Бабайларны,
Карлыганны,
Малайларны!

1980

КОМЛЫ КОМСЫЗ

Кадыйрларның комы бик күп —
Капка төбе тау кебек.
Килде күрше малайлары,
Кәтү төсле, шау килеп.

— Комы да комы, диләр,
Кем өйдә моны? — диләр.

Зур өемгә ятып, Кадыйр
Ауный, уйный, таптана:
— Әти тагын бер машина
Кайтара! — дип мактана.

Шатланып тора малайлар:
— Йомшак икән, кайнар да,
Рәхәтләнеп кызынырбыз,
Кызык булыр уйнарга!
Кадыйр аларга ни әйтә?
Ул аларга шуны әйтә:
— Уйнамый торыгыз, ди,
Бу безнең комыбыз! — ди.

Шулай ди дә уйный бирә,
Берүзе, тавыш-тынсыз.
Малайлар китә, борылып:
— Берүзең уйна, комсыз!

Ком тавында уйный Кадыйр,
Ясый ул әллә ниләр.
«Комым күп бит, нигә миңа
Малайлар «комсыз!» диләр?!»

1962

ЧИШМӘ ЯЗМЫШЫ

Чишмәләр туа
Туган туфракта,
Үтәр юллары
Ерак-еракта...
Җырлап кузгала.
Моңаеп бара:
«Туган төбәкләр
Гомергә кала...
Илдә яшәгән
Күлләргә рәхәт...»
Чишмә язмышы —
Мәңге хәрәкәт.
Хәтерли һаман
Илдә чагын ул,
Чишмә язмышы —
Мәңге сагыну...

Әмма ышана:
«Ерак-еракта
Чыганак исән
Туган туфракта!»

1976

КЫҢГЫРАУЛЫ МӘКТӘП ЕЛЛАРЫ

Кошлар да бер шулай таралалар,
Сау бул инде, туган оябыз,
Офыкларга карап очар өчен,
Иңнәрдә без канат тоябыз.

Әйтерсең лә пар атларда үтте
Кыңгыраулы мәктәп еллары;
Күңелләрдә гомерлеккә калыр
Шушы соңгы моңлы чыңлавы,
Кыңгыраулы, кыңгыраулы,
Кыңгыраулы мәктәп еллары!..

Зур юлларга безне чыгардың син,
Күңелләргә бирдең омтылыш.
Соңгы звонок булсын беренчесе —
Син каршыла безне, зур тормыш!

Әйтерсең лә пар атларда үтте
Кыңгыраулы мәктәп еллары;
Онытылмас, кая юл тотсак та,
Сагындырыр таныш чыңлавы,
Кыңгыраулы, кыңгыраулы,
Кыңгыраулы мәктәп еллары!..

Алда әле заман имтиханы,
Күп сынаулар әле үтәсе,
Максатларга әле ирешәсе,
Хыялларны чынлык итәсе!

Әйтерсең лә пар атларда үтте
Кыңгыраулы мәктәп еллары;
Киләчәккә безне озатканда,
Онытылмас дәртле чыңлавы,
Кыңгыраулы, кыңгыраулы,
Кыңгыраулы мәктәп еллары!..

1969

Роберт Миңнуллин
(1948 елда туган)

БАТЫР БУЛЫГЫЗ!

Җәлилче батыр Зиннәт Хәсәновның авылдашларына —
Иске Кәшер малайларына багышлыйм

Сезнең чишмә шифалыдыр!
Бәлки, шуңадыр
Нәкъ менә сезнең авылда
Батыр тугандыр?!

Зиннәт Батыр эчеп үскән
Суларны эчкәч,
Сез дә бары батыр гына
Булырсыз үскәч!

Чөнки сезнең суыгыз — бер,
Җирегез — уртак.
Сезнең суны эчкән кеше
Булалмый куркак!

Сез дә солдатлар буласы,
Әзер торыгыз!
Зиннәт Хәсәнов шикелле
Батыр булыгыз!

Батырлыкны эшли ала
Бөтен кеше дә.
Аның өчен кирәк түгел
Алып көче дә.

Яратырга кирәк бары
Туган җиреңне,
Әтиеңне-әниеңне,
Туган илеңне!

Зиннәтулла да булгандыр
Нәкъ сезнең сыман.
Ә үзенең йөрәгенә
Күпме көч сыйган!

Үзенең туган халкыннан
Җыйган ул аны.
Авыр чакта хәтерләгез
Зиннәтулланы!

Һәм батыр җәлилчеләрне,
Җәлилнең үзен,
Буласыгыз килсә әгәр
Батыр һәм түзем!

Бөек Җиңү таңын да бит
Алар аттырды!
...Авыр чакта хәтерләгез
Зиннәт Батырны!

МАЛАЙЛАР СӨЙЛӘШӘ

— Мин үскәч абый булам,
Аннары бабай булам!
— Ә мин, бабай булгач та,
Гел әйбәт малай булам!
— Мин үзем әти булам!
— Ә мин дәү әти булам!
— Үскәч кем буласымны
Мин әле әйтми торам!
— Мин батыр солдат булам!
— Ә мин космонавт булам!
— Ә мин Третьяк булам,
Капкада сакта торам!
— Ә мин корыч коючы,
Чуен коючы булам!
— Мин күз буучы булам!
— Ә мин аучы булам да
Көн дә йөрим сунарга!
— Ә мин белмим, әнидән
Оныткანмын сорарга...
— Ә мин бик озын булам,
Үсәм әле тагы да!
— Ә мин начальник булам,
Йөрим «Волга»да гына!
— Ә мин кибетче булам
Яисә итче булам!
— Ә мин бик көчле булам,
Әтием төсле булам!
— Мин комбайнчы булам,
Кырда иген урырга!
— Ә миңа әни, үскәч,
Куша Кеше булырга!

ӘТИЕМ ПАЛАС КАГА

Сызгана да җиңнәрен,
Ала да сыек чыбык,
Кыйный әти... паласны,
Урамга алып чыгып.

Урамда уйнап йөргән
Малайлар, кыз балалар
Үрле-кырлы сикергән
Паласны кызганалар.

Әти көлә: «Бу палас
Тузанланып беткән, ди,
Тузаннарын кагарга
Кирәк булган күптән!» — ди.

Мин дә бит, уч иткәндәй,
Тузанга кергән идем,
Урамдагы бар тузанны
Туздырып йөргән идем.

Әтием палас кага,
Миңа да күз салгалый.
Бер — паласка, бер миңа
Карап-карап алгалый:

Ахры, минем тузанны да
Каккаларга чамалый.

ҮЗЕМ БУЛАСЫМ КИЛӘ!

Әтиемә карыйм да,
Әти кебек
Батыр буласым килә.

Әниемә карыйм да,
Әни кебек
Матур буласым килә.

Мин бабама карыйм да,
Бабам кебек
Бабай буласым килә.

Һәм көзгегә карыйм да,
Үзем кебек
Малай буласым килә!

ӘНИЕМӘ ЯЛ КИРӘК!

Әй кызлар!
Әй малайлар!
Тик торыгыз, тыныгыз!
Аз гына да чыкмасын
Сезнең тавыш-тыныгыз!

Кошкай, син дә җырлама!
Пескәй, син дә мырлама!

Бозау, син да мулама!
Акбай, син дә улама!

Шаулама син дә, тирәк! —
Әниемә ял кирәк!

Ул эшеннән
Туктасын!
Тизрәк ятып
Йокласын!
Ял итсен,
Көч тупласын!

Әнием, син болай да
Ял итәсең бик сирәк!
Сиңа да бит ял кирәк!
Арыгансың бит инде,
Әнием, ял ит инде —
Мине йоклат та тизрәк!

ПЕЧӘН ӨСТЕ

Авылда җәй.
Җәйге болын.
Печән өсте.
Печән чапкан
Абыйларга
Ай-яй эссе!
Печәнчеләр
Бу эсседә
Янып пеште.
Ярый әле,
Аз булса да,
Җилләр исте.
Печән исә
Биек кибән
Булып үсте.
Күренми дә
Кибән өсте.
Кибән өсте
Нәкъ тау төсле!
Качып кына

Менеп киттек
Кибәнгә без.
И уйныйбыз,
И уйныйбыз,
Кинәнәбез!

Тик кибәннең
Асты өскә
Килә язды.

Үзебезнең
Түбә күккә
Тия язды!

Безнең хәтта
Буй да бераз
Үсә төште.
Безнең якта
Бигрәк биек
Печән өсте!

КАЕННАР ТЕЛЕНДӘ

Каеннар шауламый,
Каеннар серләшә.
Алар бит үзләре
Телендә сөйләшә.

Теләгән кешеләр
Аңа тиз төшенә.
Иң матур бер тел ул —
Төшенгән кешегә.

Шул каеннар белән
Каеннар телендә
Сөйләшкән, серләшкән
Чаклар бар минем дә!

МАЛАЙЛАР СУГЫША

Малайлар сугыша,
Җиңнәрен сызганып.
Малайлар бер-берсен
Тормыйлар кызганып.

Канга батырганчы
Кыйныйлар бер-берсен.
Малайлар сугыша...
Ни өчен? Кем белсен?!

Көчсезрәк малайга
Ник башлап сугарга?
Көчеңне башкача
Була бит сынарга.

Бернинди сәбәпсез
Рәнҗетү кешене,
Сугышу, кыйнашу
Егетләр эшеме?

Ник шуны онытасыз?
Әйтегез, әйт, нигә?
Тынычлык кирәк бит
Әнигә, этигә!

Тынычлык кирәк бит
Өйдә һәм урамда.
Без көчле — үзара
Тик дуслар булганда!

Дуслыктан башлана
Тынычлык үзе дә.
Кызыллык китермик
Туган ил йөзенә!

Һәм шуны оныта
Күрмәгез берүк сез —
СУГЫШУ һәм СУГЫШ
Бер үк сүз,
Бер үк сүз!

МЕНӘ ШУНДЫЙ КЕШЕ УЛ!

Ул мине соңга калып
Кайтканга тиргәсә дә,
Иртәдән кичкә кадәр
Уйнарга бирмәсә дә,
Ул — җирдә
Иң шәп кеше!
Шәп кеше,
Гаҗәп кеше!
Китап укып ятканда,
Миңа йомыш тапса да,
Үзе, кайткач, диванда
Гәзит укып ятса да,
Ул — иң-иң
Уңган кеше!
Тырыш һәм
Булган кеше!
Минем әле бер кат та
Колакны бормаса да,
Сабантуйларда мине
Җиңгәне булмаса да,
Ул — иң-иң
Көчле кеше!
Баһадир
Төсле кеше!
Ул зирәк тә, шаян да,
Акыллы да, әйбәт тә!
Иң-иң әйбәт ул кеше —
Минем әти, әлбәттә!

БЕЗНЕҢ ЯКТА...

Безнең якта бөркетләр юк,
Бөркетләр без үзебез.
Ә шулай да, бөркет эзләп,
Күкне күзли күзебез!

ӨМЕТ

Сөн, диңгезгә әйләнергә,
Агып китә еракка!
Әйләнер микән минем дә
Кәгазь көймәм корабка?

ДУЛКЫНЛАНУ

Бөркет канат кагынды —
Үләннәр дулкынланды.
Былбыл канат кагынды —
Күңелләр дулкынланды.

УЙЛАМЫЙ ЯРАМЫЙ!

Мин йөрим
Урам буйлап,
Мең төрле
Уйлар уйлап!

Төрле-төрле-төрле уйлар
Ала мине бөтереп.
Уйлыйм-уйлыйм-уйлыйм-уйлыйм...
Булмый уйлап бетереп.

Тыя алмыйм уйларымны —
Уйлата да уйлата.
Минем башымда, ахрысы,
Йөз... мең... төрле уй ята.

Уйлыйм мин уйнаганда да,
Уйлыйм йоклаганда да.
Уйламый да ятып карыйм —
Уйлаттыра анда да.

Беләм инде, уйлануның
Сез дә кимен куймыйсыз!
Уйламый ярамыйдыр шул —
Ә сез ничек уйлыйсыз?

ӨЗМӘДЕМ

Әллә яңгыр булганга,
Гөмбә тулган урманга.

Әкәмәт!
Шаккаттым мин —
Йөзләп гөмбә таптым мин!

Берсеннән-берсе әре,
Әрерәк тапкан бере!

Миннән ләкин көлмәгез —
Кайтып киләм гөмбәсез.

Тырысым буп-буш минем,
Ә күңелем хуш минем!

Тик йөрмәдем тик кенә,
«Тапмадым шул» дип кенә.

Чынлап гөмбә эзләдем,
Тик берсен дә өзмәдем.

Өзмәдем шул, өзмәдем.
Әй, көлгәннәр көлсен лә.

Гөмбәне яратканга
Өзмәдем мин берсен дә!

ЕЛМАЮЧЫ... БҮРЕЛӘР

Ясадым мин дәфтәремә
Бүренең би-ик явызын:
Озы-ын иттердем тешләрен,
Зу-ур иттердем авызын...

Шуннан соң ул миңа таба
Карап тора башлады.
Курыктым да бүрене мин
Тизрәк ертып ташладым.

Юкса нишли дип торам,
Мине тешли дип торам.

Бүреләрне усал итеп
Ясамам мин моннан соң —
Бүреләр ямьсез булса да,
Усал, явыз булмасын!

Мин ясаган бүреләр гел
Әйбәт кенә булырлар,
Тыйнак кына утырырлар,
Елмаешып торырлар.

Безгә килгәч, рәсемемне
Дусларым да күрерләр.
Ошамый калмас аларга
Елмаючы... бүреләр!

ЯҢА ЕЛ

Карлар ябалак-ябалак,
Көннәр-төннәр яңа, ак!
Бу Яңа ел — иң яңа ел,
Барсыннан да яңарак!

Тылсымлы икән Яңа ел —
Капкасыннан кергәч тә,
Кинәт кенә үсеп җиттек,
Үсеп киттек бер яшькә!

Тик Яңа ел бер үк елда
Булсын иде берничә.
Яңа елның берсенә дә
Калмас идек кермичә!

Яңа ел еш булса, күптән
Дәү кеше булыр идек,
Күбрәк «биш»ле алыр идек,
Бик көчле булыр идек!

Хәер, җәй көне диңгезгә
Ялга киткән арада,
Әбиләргә, бабайларга
Ярдәм иткән арада,
Җәйләр үткән арада,
Кышлар көткән арада,

Сизми дә калырбыз әле —
Яңа елга җитәрбез,
Тагын бер яшькә үсәрбез,
Тагын бәйрәм итәрбез!

Алдагы ел белән тагын
Якыная арабыз.
Тик килсен дип, Яңа елга
Без үзебез барабыз!

Теләсәгез, әйдәгез,
Без сезне дә алабыз!

ЭЧТӘЛЕК

Гаяз Исхакый
Көз 3
Нәкый Исәнбәт
Идегәй 46
Муса Җәлил
Шигырьләр 92
Фатих Кәрим
Шигырьләр 110
Гомәр Бәширов
Намус 124
Хәсән Туфан
Шигырьләр 144
Әмирхан Еники
Матурлык 158
Гариф Ахунов
Хәзинә 167
Нурихан Фәттах
Сызгыра торган уклар 190
Аяз Гыйләҗев
Әтәч менгән читәнгә 234
Мөхәммәт Мәһдиев
Кеше китә — җыры кала . . 258
Әхсән Баянов
Сәяхәтнамә 278
Илдар Юзеев
Өчәү чыктык ерак юлга... 288
Туфан Миңнуллин
Әлдермештән Әлмәндәр . . . 297
Равил Фәйзуллин
Шигырьләр 329
Ренат Харис
Шигырьләр 332
Мөдәррис Әгъләмов
Шигырьләр 335
Ринат Мөхәммәдиев
Ак кыялар турында хыял . . 339
Рабит Батулла
Сират күпере 371
Ризван Хәмид
Җиде бажа 407
Шәүкәт Галиев
Шигырьләр 433
Роберт Миңнуллин
Шигырьләр 440

Учебное издание

Составители:

Ахмадуллин Азат Гильмуллович
Галиуллин Талгат Набиевич
Юзиев Нил Гафурович

**ХРЕСТОМАТИЯ
ПО ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ**

Для 11 класса
средней общеобразовательной школы
с татарским языком обучения

Издание четвёртое, исправленное

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Төзүчеләре:

Әхмәдуллин Азат Гыйльмулла улы
Галиуллин Тәлгат Нәби улы
Юзиев Нил Гафур улы

ӘДӘБИЯТТАН ХРЕСТОМАТИЯ

Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең
11 нче сыйныфы өчен

Төзәтелгән дүртенче басма

Мөхәррире *Н. К. Нотфуллина*
Тышлык рәссамы *Р. А. Сәйфуллина*
Бизәлеш мөхәррире *М. Д. Вәҗиева*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
Л. И. Матвеева
Корректоры *Г. Р. Ногманова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 27.08.2011.
Форматы $60\times90^1/_{16}$. Шартлы басма табагы 28,0 + форз. 0,25.
Тиражы 1500 д. Заказ Р-1253.

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 519-45-22.
http: //tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

...Халыкның иң зур байлыгы, иң кадерле рухи хәзинәсе, һичшиксез, аның теле. Халык үзенең телен, оста бакчачы кебек, яман җилләрдән, рәхимсез салкыннар куырудан саклап, мең еллар буена үстереп килгән, өзлексез баетып, матурлап, иң тирән фикерләрен, иң нечкә хисләрен дә аңлатып бирер дәрәҗәгә китергән.

Гомәр Бәширов